**Мәдинә Маликова**

# САФ СӨЮ ТУРЫНДА КЫЙССАЛАР

Хикәяләр, повестьлар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-3:31
ББК 84(2Рос=Тат)-44
М19

**Маликова, М.Г.**

Саф сөю турында кыйссалар : хикәяләр, повестьлар / Мәдинә Маликова ; кереш сүз авт. Л.Хисмәтова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 447 б.
ISBN 978-5-298-01925-5

Бу китапка язучы Мәдинә Маликованың төрле елларда иҗат ителгән хикәяләре һәм повестьлары туплап бирелде.Әлеге әсәрләр замандашларыбыз, аларның яшьлек мәхәббәте, катлаулы язмышы турында.

УДК 821.512.145-3:31
ББК 84(2Рос=Тат)-44
ISBN 978-5-298-01925-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Маликова М.Г., 2010

## ЯШЬЛЕКТӘ БИРГӘН АНТКА ТУГРЫЛЫК

Язучы Мәдинә Маликованың иҗаты узган гасырда әдәбият тарихының үзенчәлекле чорына туры килә. Бу дәвердә иҗат ителгән әсәрләр шул елларның әдәби мирасын тәшкил итеп кенә калмыйча, милли фикер үсешен, сәясәтнең торышын, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне чагылдыра.

Дүрт дистә ел дәвамында әдибәнең иҗаты киң катлам укучыга заман таләбе белән тәкъдим ителә. Аның әсәрләре рухи кыйммәтләребезне, үткәнебезне һәм бүгенгебезне кабул итүгә, үзебездә булган уңай һәм тискәре якларны анализларга, кимчелекләрдән арынырга ярдәм итә.

Беренче хикәяләре белән үк ул тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы, күзәтә белүе, тормышчан детальләрне оста тотып алуы белән укучыларның игътибарын җәлеп итә. Аның һәр хикәясендә истә калырлык образлар, матур эпизодлар бар. «Чаллы баскычлары» хикәясендә мондый юлларны күрәбез: «...Кешеләр бормалы-сырмалы биек баскычтан яр башына менәләр. ...Рәүф, баскыч култыксасына таянып, халыкны күзәтә. Ник кенә берсе баскычтан йөгереп менсен!

Ә менә Ләйсән бу баскычның барлык такталарын үкчәләре белән тиз-тиз санап үткән иде: тек-тек, тек-тек-тек!»

Шушы күренештән үк тормыш юлының җиңел түгеллегенә ишарә ясала, Ләйсән исемле кызның башкалардан нык аерылып торуы, Рәүфнең аны яратуы, сагынуы сизелә. Бу икәү арасында җаннарны тетрәндерерлек вакыйгалар булган – әсәрнең башыннан ук укучы шуны тоеп ала.

Бу чыннан да шулай булып чыга. Рәүф Ләйсәнне беренче тапкыр Чаллы пристаненең биек баскычыннан йөгереп менгән чагында күреп ала. Шул беренче күрүендә үк гашыйк була. Алар өйләнешәләр. Әмма гаилә ныклы булсын өчен яратышу гына җитми, омтылышларның бер булуы да кирәк икән әле. Рәүф тормыш баскычларыннан салмак атлап узучылар кавеменнән. Ләйсән исә очынып-ашкынып менүчеләрдән. Гаилә кысалары аның өчен тар, ул шәхес буларак үзен расларга омтыла, институтка керә, шәһәргә китә. Вакытлыча дип уйлый. Әмма Рәүф аны көтеп ала алмый, башка берәү белән бәйләнә. Моңа җитди сәбәпләр дә бар...

Күргәнебезчә, әсәрнең сюжеты гади генә, күпләрне язмыш шуңа охшаш хәлләрдә сынагандыр. Кем гаепле монда? Кем хаклы? Автор геройларны сурәтли генә, – тик берсенә дә бәя бирми, нәтиҗә ясауны укучы хөкеменә калдыра.

Иҗатының башлангыч чорында Мәдинә Маликова хикәяләр остасы буларак танылa. Ул әсәрдән әсәргә үсә, каләме йөгерегрәк, ышанычлырак була бара. «Кар сулары», «Күрше бәхете», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Узма, гомер!» кебек хикәяләр укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Бу әсәрләрнең геройлары арасында балалар да, бабайлар да, авыл кешеләре дә, шәһәрнекеләр дә очрый. Аларның кичерешләре, уйланулары укучының күңел кылларын тибрәндерерлек тәэсирле итеп тасвирлана, гүяки автор геройларының хис-тойгыларын йөрәккә ятышлы ачык, шул ук вакытта йомшак буяулар белән тасвирлый.

Язучының һәр әсәрендә мәхәббәт тарихы чагыла. Аның күләмле һәм җитди беренче әсәре «Казан каласы – таш кала» повестенда да бу шулай. Повесть 1968 елны «Казан утлары» журналында басылып чыга һәм укучылар арасында зур кызыксыну, төрле фикерләр уята. Әсәрне китап итеп чыгарганда язучы үзенең иҗади юнәлешенә туры килгән фикерләргә колак сала, туры килмәгәннәрен кире кага. Монда аның үз инануы буенча эш итүе, принципиальлеге күренә.

Повестьның төп герое – архитектор Мәрьям. Әсәрнең шактый өлеше – беренче мәхәббәт, сөйгән яр белән кавыша алмыйча, башка берәүгә кияүгә чыгу тарихы – искә алулар рәвешендә бирелгән. Шәхси тормыштагы йөрәк яралары өстенә иҗади хезмәттәге кыенлыклар килеп өстәлә.

Мәрьямнең уйлануларына ияртеп, автор безне дә яңадан-яңа вакыйгалар эченә алып керә. Әсәрнең сюжеты оста корылган, күтәрелгән мәсьәләләрне ачу өчен отышлы һәм күп сыйдырышлы әдәби форма табылган.

Мәгълүм булганча, совет хакимияте иҗат әһелләренә көчле басым ясап, тар кысаларда тота иде. Мондый шартларда рухланып иҗат итү, чын сәнгать әсәрләре тудыру мөмкин түгел. Моның нәтиҗәләре шәһәрләр төзелешендә дә адым саен күзгә төртелеп тора: Ерак Себердән алып Көньяк чикләргә кадәр һәркайда биналар бер калыптагы типовой проектлар буенча бастырып куела, архитекторларга талантларын ачарга мөмкинлек юк. Мәрьям исә замандашларының һәм килер буыннарның бәхете хакына моңарчы күрелмәгән гүзәл кала торгызу турында хыяллана.

Бу якты хыяллар ахыр чиктә тормышка ашмаса да, игелекле; иҗат хезмәте аңа юаныч, яшәү көче бирә, рухы сынудан саклый.

Архитекторлык һөнәре Мәрьямгә ябыштырылып, тагып кына куелмаган. Ул аның холкына, характерына, үз-үзен тотышына, яшәешенә һәм кешеләргә мөнәсәбәтенә мәгълүм бер эз салган. Әсәр баштан ахырга кадәр тормышны танып белергә омтылу, тынгысызлык, эзләнү рухы белән сугарылган. Һәр образның үз йөзе, үзенә генә хас сыйфатлары тасвирлана, һәркайсы катлаулы, истә калырлык җанлы образ.

Язучы үзе күтәргән мәсьәләләр, шәхесләр, җәмгыятьнең торышы турында тиешле югарылыктан торып, заманча фикер йөртә. Әсәр яшь язучының үз йөзе, үз стиле формалашып килүе турында да сөйли. Ул әллә каян кычкырып, ялтырап торган буяуларны яратмый, гади, тыйнак язарга омтыла. Тормышның үзеннән, классикларыбыздан ук килә торган гадилек, табигый агым аның иҗатында елдан-ел калыплана,

ныгый бара. «Казан каласы – таш кала» – әдәбиятыбызның тематикасын, офыгын киңәйтергә булыша торган әсәр.

Язучы иҗатында ана образы киң урын алып тора. Аналарның төрлесе бар: баласы өчен җанын бирергә әзер булганнары белән бергә каты бәгырьлеләре дә очрый. «Егетлеккә бер адым» повестенда автор шушындый ике хатынны – үсмер малай Бикташның әнисе Салиха белән үги әнисе (этисенең икенче хатыны) Бәһиҗәне капма-каршы куеп тасвирлый. Мәдинә Маликованың иҗатына, гомумән, хас булганча, бу повесть та мавыктыргыч сюжетка корылган. Озак еллар буе күзгә-башка күренмичә читтә йөргән эти кеше көннәрдән бер көнне беренче хатыны янына кайтып төшә. Урамда очрашкач, ата – улын, малай атасын танымый. Баксаң, бу адәм улын үзе белән шәһәргә алып китәргә карар кылган икән. Нияте изге – буй җитеп килгән Бикташны шәһәрдә укытып, киләчәктә яхшы эшкә урнаштыру. «Салиха апа тышкы кыяфәте белән генә түгел, холкы-фигыле белән дә үсмер кызларга охшаган иде, – дип яза автор. – Гаҗәп дәрәҗәдә эчкерсез, беркатлы, ышанучан». Бу юлы да ана кеше аерылган иренең сүзләренә ышана. Малайның исә, әлбәттә инде, күңеле зур шәһәргә тарта.

Шактый вакыт узгач кына, ата кешенең үз теләге белән түгел, яшь хатыны Бәһиҗә кушуы буенча йөргәнлеге ачыклана. Аларга артык кашык һич кирәк түгел, чөнки яннарында үзләренең уртак улы үсеп килә, Бикташ исә аларга вакытлыча гына, үзләре өчен бик мөһим бер мәсьәләне хәл итү өчен генә кирәк булган икән. Максатларына ирешкәннән соң, алар малайны урамга куып чыгаралар...

Мәдинә Маликова замандаш хатын-кызларыбызның образларын рухи яктан ачып, хисләр каршылыгын, югалту-табышларын үз күңеле, үз җаны аша үткәреп иҗат итә. Ул хатын-кыз бәхетен имин-төзек гаилә коруда, инсафлы балалар үстерүдә һәм шул ук вакытта җаның үз иткән өлкәдә хезмәт итүдә, иҗтимагый тормышта үз сүзеңне әйтүдә дә дип күрә. Хатын-кыз ир хатыны, балалар анасы булу белән бергә иҗат итәргә, җәмгыятьтә лаеклы урын алырга хаклы шәхес тә. Бу ике өлкәдә дә уңышка ирешү җиңел түгел. Моның мисалын без «Янар таулар яктысында» повестендагы рәссам Зуфирә образында ачык күрәбез.

Зуфирә – хыялга бирелүчән, омтылучан шәхес. Хисләреннән исереп, ул яшьлегендә тыштан ялтырaганга алдана, булдыксыз, аумакай егет белән язмышын бәйли. Моның өчен аңа бик кыйммәт хак түләргә туры килә – гомеренең күп өлешен ул, иҗат эшен ташлап, гаилә йөген ялгызы тартырга, хаста каенанасын тәрбияләргә тиеш була. Әмма көнкүреш ничек кенә изсә дә, ул киң дөньяга чыгып, көчле шәхесләр белән аралашу, кешеләрнең тормышын бизәрлек картиналар язу турындагы хыялларыннан ваз кичми. Ниһаять, океаннар гизгән капитан белән очрашу аңа үзен иҗатка багышларга көч бирә.

Мәдинә Маликова – татар әдәбиятында хатын-кыз язучы тарафыннан иҗат ителгән беренче романнарның авторы. Иҗат эшчәнлеге дәверендә ул күп меңнәрчә әдәбият сөючеләрнең мәхәббәтен казанды. Аның әсәрләре җиңел укыла, теле тәмле, хикәяләү рәвеше хисле, тасвирлы, кайчак моңлы, кайчак җор. Күпләр бу әсәрләрдә үз язмышлары белән уртаклык табалар, шул ук вакытта бик күп яңалыклар ачалар.

Ул үзенең әсәрләрендә XX гасырның икенче яртысында һәм XXI гасырның башында шәхес белән җәмгыять арасында булган һәм яңа туган каршылыкларны күрсәтә, җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең шәхескә йогынтысын ачып сала. Бу проблема Икенче бөтендөнья сугышы чорыннан бирле дөнья әдәбиятында иң мөһимнәренең берсе булып тора. А.Камю Франция әдәбиятында, Э.Хемингуэй Америка әдәбиятында, А.Солженицын рус әдәбиятында бу каршылыкны «шәхес иреге» ягына чишәләр. Шул ук вакытта шәхес җәмгыятьтән кача алмый һәм бу каршылыкны үзенең яшәү рәвешен сайлаганда ничек тә булса хәл итәргә тиеш.

Мәдинә Маликованың дөньяга киң карашлы булуы, иҗтимагый һәм рухи актив тормыш белән яшәве бөтен иҗатына тирән эз сала. Ул, язучы буларак, чорның актуаль мәсьәләләрен, өлгергән проблемаларын таба, мавыктыргыч сюжет һәм истә калырлык образлар ярдәмендә җәмәгатьчелекнең игътибарын шуларга юнәлтә белә. Бу иҗат образларның бай галереясы, кеше – мохит – чор бәйләнеше, стиленең төрле сурәтләү чараларына бай булуы белән дә әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше булып тора.

Лилия Хисмәтова,
*филология фәннәре кандидаты*

# ХИКӘЯЛӘР

## Чаллы баскычлары

Көн эссесе бераз сүрелгәч, кояш кызарып, куе урманнар каплаган калкулыклар артына тәгәри башлагач, сулыш җиңеләя, тәнгә рәхәт булып китә. Күңелдә матур истәлекләр уяна, йөрәк җилкенә, кояш киткән якларга барасы, карасу калкулыклардагы урманнарны кичеп, алланган офыкның теге ягына чыгып карыйсы килә. Әнә бит Кама дулкыннары да кояшка таба йөгерәләр. Су өстендәге алтынсу юл да шул якка сузыла...

Ялтыравык тәңкәләр сибелгән юл өстеннән ак «Ракета» оча. Пристаньга җитәрәк, ул түше белән суга ята.

Кешеләр бормалы-сырмалы биек баскычтан яр башына менәләр. Авыр менәләр, әкрен атлыйлар. Соңгы басмага чемоданнарын куеп, бераз ял итеп алалар да тузанлы урамнан автобуска таба юл тоталар.

Рәүф, баскыч култыксасына таянып, халыкны күзәтә. Ник кенә берсе баскычтан йөгереп менсен!

Ә менә Ләйсән бу баскычның барлык такталарын үкчәләре белән тиз-тиз санап үткән иде: тек-тек, тек-тек-тек!

Ул көннәрдән соң инде Камадан күпме дулкыннар йөгереп узды, ничәмә-ничә тапкыр кояш баеды, кышы-җәе үтеп торды, ә һаман онытылмый. Хәзергедәй күз алдында Рәүфнең: сумкасын болгап, башындагы ефәк шәлен җилфердәтеп йөгереп менде ул. Рәүф аның шәл чугыннан эләктереп алды да:

– Кая кабаланасың? Үргә каршы чабалармыни? Йөрәгең ярылыр бит! – диде.

Кызның шәле башыннан шуып төште.

– Җибәр! – диде ул. – Автобуска ашыгам.

Кыз шәл чугын Рәүф кулыннан тартып алды да йөгереп китеп барды. Ул чакта Рәүф аның бөдрә чәченә, нәзек зифа буй-сынына сокланып карап калган иде.

Әйе, менә шушы баскычта беренче тапкыр күргән иде ул аны. Колхоз председателе кушуы буенча «Волга» белән кемнедер каршы алырга килде дә, очрата алмыйча, кайтырга чыкты. Күперне үткәч, автовокзал турында тагын әлеге ефәк шәлле кызга тап булды. Ул автобуска өлгермәгән, ахры, кулын күтәреп, юл читендә басып тора.

– Рәхим итегез! – диде Рәүф, ишекне ачып. – Кайсы якка барырга боерасыз?

Кызый әз сүзле булып чыкты. Сораштыра торгач, Рәүф аның күрше авыл кызы булуын (кара син аны, ничек моңарчы очратмаган!), исеме Ләйсән икәнен, туганнарыннан кунактан кайтып килүен, быел унынчы класска күчкәнен белде.

Шыгай тавы итәгендә туктап, елгада бит-кулларын юдылар. Рәүф яр буена юри туктады, бигрәк эссе, дигән булды. Анысы дөрес, көн чыннан да бик эссе иде. Ләкин тукталуның төп сәбәбе ничек тә булса юлны озаккарак сузу иде.

Рәүф, председательнең күзенә чалынмас өчен, үз авылының ындыр артыннан гына элдереп, Ләйсәнне капка төпләренә чаклы илтеп куйды.

– Рәхмәт! – диде Ләйсән. – Менә, мә! – Һәм йомарланган берлек сузды.

Рәүф кесәләрен актарып караган булды һәм, кәефсезләнгән кыяфәт белән:

– Кара әле, сдачам юк бит! – диде. – Ну ярар инде, китер, бер үткәндә сдачасын кертеп чыгармын әле.

– Мәшәкатьләнмә юкка, мин болай да бик бәхил.

– Юк инде, синең акчаң кирәкми миңа, – дигән булды Рәүф. – Үз өстемдә бурыч тота алмыйм. Иртәгә турыгыздан үтәрмен, чамалабрак тор.

Иртәгесен ул, мотоциклы белән тырылдап, Ләйсәннәрнең капка төбенә килеп туктады. Ләйсән аны көтмәгән икән. Ишектән чыкканда, күзләре гаҗәпләнүдән зур ачылган, кашлары җәя кебек киерелгән иде.

Ел буе Рәүф, бер зур сөенече бар кешедәй, дәртләнеп йөрде. Ул Ләйсәнне сеңлесе кебек якын итә, аны төрле җил-бураннардан саклыйсы, аның белән янәшә буласы килә иде. Ләйсән белән һәр очрашу үзе өчен бәйрәм булгач, кызга да аның килүе шатлыклы вакыйга булуын теләде Рәүф. Аның үзе белән һәрвакыт нинди дә булса кучтәнәч була: йә алма, йә сирень, гөлҗимеш яисә ромашка чәчәге.

Көз көне алар өйләнештеләр. Дөрес, башта Рәүфкә бик нык борчылырга туры килде, чөнки Ләйсән ике сүзнең берендә: «Врач булам, институтка керәм», – дип тәкрарлый иде. Рәүфнең бәхетенә каршы, Ләйсән институтка керә алмады, кире кайтты, шулай итеп алар арасындагы соңгы киртә җимерелде.

Кызның әтисе, моннан бер-ике ел гына элек яшь хатынга өйләнгәч кеше, Ләйсәннең тизрәк күзле-башлы булуын, үги анадан ераккарак китүен хуп күрде.

Дөрес, Ләйсән үзенчә шарт куйган булды: «Миңа институтта укырга ярдәм итәрлек булсаң гына», – диде ул. Бала гына иде бит әле ул Ләйсән! Бала чакта Рәүф үзе дә очучы, ким дигәндә, эскадрилья командиры булу турында хыяллана иде. Хәзер менә шофер булып йөри, колхоз председателе аның үзенә команда бирә. Тормыш син кушканча гына бармый шул, кешене үз җаена бора. Ләйсән дә акылга утырыр, булыр-булмас хыяллар артыннан куып йөрмәс дип уйлады Рәүф.

Әйе, тормыш бик матур, бик күңелле бара иде. Рәүф, машинасын ташлап, тракторга күчте. «Волга»да кеше ташу туйдырган иде инде. Эштән кайтканда, очкынлы күзләрен балкытып, елмаеп Ләйсәне каршы ала, тирәсендә бөтерелеп йөри, каенана Зәйнәп түти дә аларның мәхәббәтенә сөенеп бетә алмый иде. Җир җимертеп эшләп торганда, бер-береңне янып-көеп сөйгәндә, бәхет өчен тагын ни җитми?

Шулай гөрләшеп яшәгәндә, бәхетсезлек килеп чыкты: Зәйнәп түти каты авырып китте.

Күз ачкысыз буранлы көн иде. Рәүф кичен эштән кайтып ишекне ачуга, Ләйсән:

– Бар, тизрәк ат җигеп кайт, больницага барырга кирәк! – дип кычкырды.

– Тукта әле! – дип сыкранды Зәйнәп түти. – Бу буранда ничек юлга чыкмак кирәк! Караңгы төште бит инде!

Рәүф әнисе янына килде:

– Хәлең бик авырмыни соң, әни?

Зәйнәп түтинең ак чәчләре, тиргә чыланып, маңгаена ябышкан, ул урын өстендә әле тегеләй, әле болай ятып карый һәм ирексездән ыңгырашып куя иде.

– Теге шул элекке чирем инде... – диде ул. – Тагын эчем авырта. Үтә ул, үтә, хафаланма...

– Ничек инде ул алай, үтә дип, – диде Ләйсән. – Ичмасам, медсестраны чакырып килим.

Ул киенеп чыгып китте. Рәүф урындыкка утырды да әнисенә карап тора башлады. Ул нишләргә белми аптырап калган иде.

Зәйнәп түтине бу читенсендерде, ахры.

– Улым... – диде ул. – Ашап ал... Катык бар анда.

Әмма Рәүфнең тамагына ризык үтмәде. Медсестра килде, ул да бернинди ярдәм күрсәтә алмады.

– Тизрәк больницага илтегез, сукыр эчәгесе авырта кебек, – диде.

Зәйнәп түти төне буе ыңгырашып чыкты. Рәүф белән Ләйсән ни утырып, ни басып торырга белмәделәр.

Төн урталарында, инде тәмам башлары миңгерәп, түзәр хәлләре калмагач, Ләйсән ишеккә атылды. Салкын тидерер бу дип борчылып, мамык шәл күтәреп, Рәүф тә өйдән чыкты. Чыкса, ни күрсен, Ләйсән ишек яңагына капланган да үксеп елый.

Рәүф аның иңбашына шәл салды.

– Ләйсән, болай кыланма, салкын тидерерсең. Син дә чирләп китсәң, берүзем нишләрмен? – диде ул.

Ләйсән борылып, караңгыда сәер ялтыраган күзләрен иренә күтәрде:

– Нишләп ярдәм итә алмыйм соң мин аңа, ә? Тик утырам бит янында, тик утырам! – Ләйсән Рәүфнең күкрәгенә капланып үкси башлады. – Минем әнкәем дә, бәгырькәем... Больницадан кайткач, ике ай өйдә ятты. Үлем килгәнен күреп тордым, күреп тордым... белеп тордым... Ярдәм итә алмадым... Көчсез булдым...

Рәүф Ләйсәнне иңбашларыннан тотып селкеде:

– Җитте. Ничаклы еласаң да, әнигә аннан җиңеллек юк. Күз яше түгеп кенә терелтеп булмый аны.

Алар ат җигеп юлга чыктылар һәм, таң атар-атмас, больницага килеп тә җиттеләр.

Рәүфнең Зәйнәп түтине күтәреп керүе булды, тын коридорда тыз-быз ак халатлы кешеләр чабыша башлады.

Йокысыннан уятып, баш врачны – Сәлимҗанны – өеннән чакырып китерделәр. Ул, халат итәкләрен җилфердәтеп, берничә врач ияртеп, Зәйнәп түти яткан палатага кереп китте.

Бераздан алар чыктылар да коридорда кызып-кызып сөйләшә башладылар. Ишек төбендә үк басып торган Рәүф белән Ләйсәнгә аерым сүзләр генә ишетелде:

– Соң шул... өмет юк... – ди Сәлимҗанның калын тавышы.

Калынрак гәүдәле бер ханым, хирург булса кирәк:

– Хәзер үк... Мин уйлыйм... Чарасын күрергә... – ди.

Баш врач кул селти, ханым халатын төймәли.

– Операционный әзерме? Авыруны әзерләгез.

Ул арада Зәйнәп түтине, носилкага салып, операционныйга алып кереп киттеләр. Коридор тынып калды.

Ләйсән, аяк очларына гына басып, операционныйның ишеге янына килгән генә иде, ишек кинәт ачылып китте, аннан бер кыз килеп чыкты һәм йөгереп киткән уңайга кул селтәде:

– Китегез! Комачауламагыз!

Менә Ләйсән, әкрен генә атлап, Рәүф янына килде. Уйчан күзләрен каядыр төбәп, аңлашылмас сагыш белән:

– Алар нишләргә кирәген беләләр, – диде.

...Зәйнәп түтинең хәле өч көн авыр булды. Өч көн, өч төн Ләйсән аның яныннан китмәде. Больницадан кайтканда, күз кабаклары шешенеп, кызарып беткән, гәүдәсе тагы да ябыгып калган иде.

Каенанасы терелеп кайткач, Ләйсән бик тырышып имтиханнарга әзерләнә башлады. Көн саен кулына китап-дәфтәр алырга вакыт таба. Зәйнәп түти әкрен генә өй эшләрен эшләп йөри, Ләйсәнгә: «Борчылма, кызым, тынычлап укы», – дип кенә тора.

Кичләрен урынга яткач, Рәүфнең йокысы кача. Ул, өстәл лампасы яктысында китапка иелгән хатынына карап, күңелсез уйларга чума. Йә, ни җитмәгән инде бу Ләйсәнгә? Врач булам дигән булып, җайга салынган тормыштан алты елга әллә кая чыгып китәләрмени? Алты ел бит ул. Анда ул үзенә тиң берәр студент тапмасмыни? Ни әйтсәң дә, сөйкемле хатын. Әнә иңнәренә кадәр төшкән дулкынлы йомшак чәчләре генә дә ни тора! Простой колхозчы белән торасы килмәс инде аның. Хәер, укып бетереп Рәүф янына кайтса да, аннан ни сөенеч! Рәүф гомер буе «теге врач Ләйсәннең ире» булып хатыны күләгәсендә йөрерме? Юк инде! Аның хәзер дә яратуы шуның чаклы гынадыр әле, югыйсә ташлап чыгып китәргә атлыгып тормас иде.

Рәүф сикереп тора да лампочканың төймәсенә баса:

– Укып галим булмассың, чукып карга булмассың... Әйдә ят, күптән вакыт!

Ничәмә-ничә тапкыр Рәүф Ләйсәнне хыялыннан ваз кичтерергә тырышып карады.

– Йә институт, йә – мин! – дип кырт кисеп куя иде ул аңа.

Ә Ләйсәннең күзләре томан каплагандай була.

– Сине сөяр өчен бер тормыш, хыялымны тормышка ашырыр өчен икенче тормыш бирелмәгән, – ди. – Бер яшәгәндә, икесен дә сыйдырырга туры килә. Институтка кергән өчен генә мине ташламассың ич инде? – ди.

Үгетләү дә, куркыту да, үпкәләү дә ярдәм итмәде: китте Ләйсән. Рәүфнең бар өмете шул иде: Ләйсән сынауларын бирә алмас әле, былтыр бирә алмады бит. Институт тирәсендә таныш-белеше, туган-тумачасы юк, сынауны яхшы бирсә дә, керә алмавы бик мөмкин дип уйлаган иде. Рәүф хатынын Чаллыга кадәр озата барды.

Дебаркадерда хушлашканда, ярым шаярып:

– Кара аны, сынауларыңны яхшы бирәм дип, артык тырышма, – диде. – Кире кайтырга тырыш.

Алар мәш килгән халык алдында үбештеләр.

Ак пароход, китимме-юкмы дип уйланып торгандай, бик ялкау гына урыныннан кузгалды да, юл уңаена борылып, су өстендә сузылган ялтыравыклы юлдан баеп килә торган кояшка таба юнәлде. Ләйсәнне алып китте ак пароход. Рәүф Чаллы үрен ялгыз менде.

Кире кайтмады Ләйсән. Бер-ике атнадан хаты гына килеп төште: *«Ура! Сынауларны бирдем, инде студентка булдым,* – дип язган. – *Рәүф, җаным, укулар башланганчы группаны колхозга җибәрәләр. Мин кайтып килергә рөхсәт сорамакчы идем дә, башта ук иптәшләр арасында ак чәүкә булырга кыенсындым. Эштән кача дип уйлаулары бар».*

Рәүф бу хатны кара көеп укыды. Урак өсте, коеп яңгыр ява, эш һич кенә дә алга бармый, җитмәсә, салкын тидереп, Зәйнәп түти тагын урын өстенә егылды. Карчыкка күз-колак булырга, өй эшләрен караштыргаларга кеше кирәк иде. Ләйсәннең беренче хатына да, калган хатларына да җавап язарга кулы бармады Рәүфнең.

Баштанаяк чыланып, тәмам кәефсезләнеп эштән кайтып килгән Рәүф күрше кызы Халисәгә тап булды. Кыз көтү каршыларга чыккан, ахры, иңенә пинҗәк кенә салган, әкрен генә сибәләгән тымызык яңгырга һич игътибар бирмичә, капка төпләрендә басып тора. Таза беләкләрен күкрәгенә кушырган, әйтерсең озын кара толымын кысып кочаклаган.

«Менә ичмасам кыз! – дип уйлады Рәүф. – Бу инде ирен ташлап әллә кая чыгып китмәс!»

Халисә – Рәүфнең яшьтәше, алар бер класста укыдылар. Үсеп җиткәч, клубтан кайтканда, Рәүф Халисәне капка төпләренә чаклы озаткалап та куйгалый иде, үбешкән чаклары да булмады түгел. Авылда «инде бигрәк пар килгәннәр, өйләнешерләр болар» дигән хәбәр дә таралган иде. Әмма Ләйсән очрагач, Рәүф күңелендә күрше кызына бөтенләй урын калмады. Өйләнгәннән соң егет Халисәне күрмәде дә шикелле.

Бу юлы Халисәне күреп, аның ничектер күңеле күтәрелеп китте.

– Исәнме, яшьтәш!

– Сәлам, – дип җавап бирде Халисә шаян тавыш белән. – Хатын ташлап киткәч, кәефләр ничек соң?

– Кәеф шәптән түгел, дөресен генә әйткәндә. Әни дә авырып ята менә. Ә син, күрше була торып, хәлне белергә дә кермисең, ичмасам.

Халисәнең йөзе кинәт кенә җитдиләнде:

– Шулаймыни? Карале, мин белми дә торам тагын. Кереп чыгармын, керми соң!

Кичен Халисә керде, өйне җыештырып, савыт-сабаларны юып чыгып китте.

– Мәшәкатьләнәсе юк иде, – диде Зәйнәп түти. Аның тавышында канәгатьсезлек сизелде. – Болай гына ятып тора идем әле.

Әмма Зәйнәп түти тиз генә торып китә алмады. Халисә иртә-кич кергәләп, сыер савып, суга барып, ашарга әзерләп йөри торган булды.

Яңгырлы, күңелсез, караңгы кич иде. Рәүф өйалдындагы караватында әчпошыргыч уйларга чумып ята. Нишли икән бу кичләрдә Ләйсән? Кемнәр белән сөйләшә, кемнәргә елмая икән? Ул зур, якты шәһәрдә, яңа дус-ишләр арасында күңелле яшидер, кичәләргә йөри торгандыр әле! Кем кочагында бии икән? Рәүфне искә аламы икән? Юктыр!.. Әнәниләр язган бит соңгы хатында: *«Килеш-килбәте белән сиңа охшаганрак егет бар безнең группада. Сине сагынганда, шуңа карап юанам кайчак»*. Шул арада юатыр кешесе дә табылган инде! Җитмәсә, ник хат язмыйсың дип, Рәүфкә үпкәләп маташкан була. Сөюе хак булса, китмәс иде. Рәүф йөрәгендә үч алу хисе кабарды.

Өй ишеген шартлатып ачып, Халисә килеп чыкты да:

– Тыныч йокы, Рәүф! – дип, тышкы ишек келәсенә тотынды.

– Халисә! Кил әле, бер сүз әйтәм.

Кыз якын килгәч, Рәүф аның кулыннан тотты:

– Син чыгып йөрмә инде. Салкын да... яңгыр да...

Халисә кулын тартып алмады. Күзләрен аска төшереп, толым очын сул кулына бер урады, бер сүтте.

Иртән, Халисә дөбер-шатыр чиләкләрен алып суга киткәч, Рәүф өйгә керде.

Зәйнәп түти мендәреннән башын күтәрде дә рәнҗүле тавыш белән дәште:

– Улым, Ләйсән кайтмаска киттемени соң?

– Ә син аны көтеп ятасыңмыни? Юк инде, моннан ризыгын өзеп китте ул.

Зәйнәп түти стенага таба борылды, аның иңбашлары калтырап куйды.

Рәүф ишегалдына чыкты. Җирне сөт шикелле ак томан каплаган. Өй түрендә Ләйсән үстергән йөнтәс кызыл чәчәкләр башларын игәннәр, алардан эре тамчылар тама.

«Әһә, алаймы, – дип уйлады Рәүф, чәчәкләргә үчле карап. – Үзең гаепле, үзең мине ташлап киттең. Үкенерсең әле син дә...»

Көянтә авырлыгыннан бераз сыгылып, аска карап, капкадан Халисә кайтып керде, һәм Рәүфнең хәтеренә келт итеп бер кечкенә вакыйга килеп төште. Ләйсән бар чакта да Халисә бер тапкыр шушы капкадан су күтәреп кергән иде бит. Зәйнәп түти янәшә атлый иде. Рәүф төшке ашка кайткач, бу хәлне күреп гаҗәпсенмәде. Мөгаен, әни иртән Ләйсәнне уятырга кызганган да сусыз калгандыр, инде үзе көянтә-чиләк күтәреп суга баргач, Халисә очрап, карчыкка ярдәм итәргә булгандыр дип уйлады.

– Әни, су ташырга тагы бер килен алыйкмы әллә? – дигән иде Рәүф, шаярып.

Шаярып әйткән сүзләр, Зәйнәп түти әйтмешли, фәрештәләрнең «амин!» дигән чагына туры килде микәнни?

Яшь килен Халисә бер сандык бирнә алып керде. Рәүф эштән кайтканда, тәрәзәләрдән Ләйсән элгән болан сурәт-ле чаршаулар юкка чыгып, алар урынында кечкенә генә чигешле ак пәрдәләр эленеп тора иде.

Үз вакытында Рәүф әлеге чаршауларны үзе дә өнәп бетермәгән иде: «Ник кирәк шулчаклы чүпрәк, кечкенәрәге ярамаган тагын», – дигән иде.

Хәзер исә өй эче күңелсезләнеп киткән төсле булды.

– Үзебезнекеләрне элдем, – диде Халисә, – кеше әйбере белән гомер тормабыз бит.

Өй түрендәге йөнтәс чәчәкләргә кырау төшкәнен күргәч тә, эче сызды Рәүфнең. Ләйсән булса, ул чәчәкләрне җыеп алып керер, ике зур бәйләм итеп өстәл уртасына һәм Зәйнәп түтинең караваты янындагы тумбочкага куяр иде...

Халисә – эшчән килен, авыр басып, салмак йөри, иртә таңнан кичкә кадәр кулыннан эш төшми, башын да күтәрмичә юа, ямый, пешерә.

Ләйсән идәнгә тияр-тимәс җил кебек очынып кына йөри иде. Өй эшләрен әллә кай арада эшләп бетерә дә: «Әйдә бераз йөреп керик әле, әнә бит нинди күңелле, ай тулган чак!» – дип, Рәүфнең теңкәсенә тия иде.

Халисә кояш чыкса, эссе, ди, яңгыр яуса, пычрак, ди. Ә Ләйсәнгә һәрнәрсә кызык иде: «Ай-һай, кояш кайнар үбә: «яисә» Карале, бөтен дөньяны чистарткан яңгыр», – ди торган иде.

Ябалак кар ява башлагач, Халисә: «Ну изрәтер инде дөньяны, ни кар, ни яңгыр түгел», – диде. Ә Рәүфнең күз алдында тагын Ләйсән. Шушындый ук ябалак карлар яуган кичне клубтан кайтып

киләләр алар. Ләйсән башын күтәреп баса да йөзенә төшкән кар бөртекләренә елмаеп тора. Рәүф түзми, аның дымлы иреннәрен үбә...

Халисәнең озын кара толымы да Рәүфнең күңеленә хуш килмәде, Ләйсәннең озын бөдрә чәчләрен, дөньяга бераз гаҗәпләнеп, якты елмаеп карый торган күзләрен сагынды ул.

«Туктале, болай булырга тиеш түгел бит, Ләйсән кайтмасмы, тормыш үзгәрмәсме», – диебрәк тә уйланып йөрде Рәүф. Аның тормышы, көзге болытлы көннәр кебек, тымызык кына бара башлады. Шулай да күңел түрендә «бу болытлар таралыр, тагын кояш чыгар әле» дигән өмет яшәп килде.

Халисәнең буйга узганын белгәч, Рәүф ул өметләрнең нигезсез икәненә тәмам ышанды.

Ә Ләйсәннең хатлары һаман килеп, йөрәкне талпындырып, үзәкне өзеп торды. Бер хатында: *«Халисә кереп, ярдәм итешеп йөри икән, рәхмәт инде»*, – дип язган иде.

Хатларны Зәйнәп түти почтальон кыздан үзе барып ала иде. Соңгы хатны да ул, гадәтенчә, Халисә күрмәгәндә, алъяпкыч кесәсеннән чыгарып, Рәүфкә бирде.

Рәүф Халисәнең өйдән чыгып киткәнен дә көтеп тора алмады, сыер абзары почмагына сыенып, ярым караңгыда укыды:

*«Рәүфем, бердәнберем! Ятлар сүзенә ышануым өчен гафу ит мине, бәгырем! Авылдан әллә ничә хат килде инде, баштарак кеше сүзенә ышанмаган идем, кат-кат укыгач, тәмам шиккә төшерделәр инде. Алар сүзен сиңа язарга озак кыймый йөрдем. Башым тәмам тинтерәгәч, гаҗиз булгач кына язам. Имештер, син Халисә белән торасың, диләр. Ышанмыйм мин бу гайбәткә! Ялган сүздер бу. Безнең арага кеше керерлекме соң? Син мине сөясең бит, әйе бит? Шулай да аптырадым инде. Кешеләрдән хат килә, ә син бер генә тапкыр да язмадың. Мин киткәнгә шулчаклы үпкәләдеңмени соң? Үпкәң никадәр генә зур булмасын, мәхәббәт барысыннан да өстен бит! Син миңа бары бер сүз генә яз. Юк, телеграмма бир, «Көтәм!» дип кенә. Бу шик-газаплардан тизрәк коткар мине, бәгырем!*

*Төннәрне йокысыз уткәрәм. Чәчләреңнең хуш исен, кулларыңның назлы иркәләвен күз алдыма китерәм... Тагын кеше хатлары искә төшеп, тетрәнәм. Бу әшәке шикләрем өчен ачулан мине!*

*Озакламый каникул җитә. Ләйсәнең-Сәйләнең кайтып муеныңа сарылыр, барысы өчен дә каршыңда тезләнеп елый-елый гафу үтенер. Ике көннән синең телеграммаңны көтәм!*

*Ләйсәнең».*

Ни дип җавап язсын Рәүф бу хатка? Ни дип телеграмма бирсен?

Кышкы салкын көн иде. Рәүф төшке ашка кайткан, Зәйнәп түти чәй ясый, ә Халисә мич алдында коймак пешереп азаплана иде.

Капка төбенә машинасын туктатып, күрше авыл егете Нурулла килеп керде:

– Саулармы сез!

– Шөкер әле, – диде Зәйнәп түти. – Әйдә, чәйгә утыр.

– Рәхмәт, вакытым бик тыгыз. Рәүфкә йомыш бар ие.

Нурулла, бик мәгънәле итеп, Рәүфкә карады. Рәүфнең йөрәге жу итте: егетнең Ләйсән турында хәбәр китергәнен сизенде ул.

Алар урамга чыктылар.

– Ләйсән китә бит! – диде Нурулла турыдан-туры.

– Ничек... китә? Кайткан идемени ул?

– Әтиләренә кайтып ике кич кенә кунды... бүген менә әле генә аэродромга илтеп кайттым. Күрешәсең килсә, әйдә утыр, ярты сәгатьтән анда булабыз. Җитешәсең әле!

Рәүф, ярдәм эзләгәндәй, артына борылып карады. Болдырда, толымын кочаклап, Халисә басып тора иде...

Рәүф Ләйсәнне беркайчан да күрмәде. Ул күп тапкырлар аның янына барырга, ерактан гына булса да аңа карап кайтырга талпынды, әмма үзен-үзе тыеп калды: Ләйсәннең сораулы гаҗиз күз карашы белән очрашудан курыкты ул...

Хәзер инде менә Ләйсән белән очраклы рәвештә очрашырга өметләнеп йөри Рәүф. Ул тагын машинага күчте, күбрәк Чаллы юлында йөрергә ярата, Кама буена килеп, баскыч култыксасына таяна да әрле-бирле йөргән халыкны күзәтә: арада Ләйсән күзгә чалынмасмы...

*1965*

## Күрше бәхете

Хәдичә апаның гомер иткән сул як күршесе, йорт-җирен сатып, Әлмәткә китеп барды. Аның урынына Казаннан бер гаилә күченеп килде.

Бакчасында суган чүбе утап азапланган Хәдичә апа, машина тавышы ишеткәч, койма өстеннән башын сузып карады.

Урындык, өстәл, шкаф ише җиһаз тулы кузовта кара бөдрә чәчле, озын буйлы яшь кенә ир белән ябык кына гәүдәле, нечкә сары толымлы хатын утыра иде. Башта ир машинадан үзе сикерде, аннары хатынын күтәреп төшерде.

Ул арада кабинадан шәһәрчә киенгән малай белән кызчык төштеләр. «Ул белән кыз үстерәләр икән. Минем Нуриям белән Гаязым да шулай пар үскәннәр иде. Гомер диген, үстеләр дә, очтылар да», – дип, Хәдичә апа, кияүдәге кызы белән укудагы улы турында уйлап, көрсенеп куйды.

Күршеләр дүртәүләшеп капкадан кереп киттеләр. Хәдичә апа, чәнечкеле куралардан шәрә беләкләрен тырнатып, ике арадагы койма янына килде.

Тегеләр ишек төбендә гөрелдәшәләр. Хатыны иренең беләгенә тотынган, балаларын җитәкләгәннәр.

– Хәерле сәгатьтә, – ди ир. – Уң аяктан атлап керик.

Тик, бусагадан атлыйк дигәндә, әле малай, әле кызчык аякларын ялгышып аптырадылар.

Хәдичә апа койма буеннан китеп үз эшенә тотынса да, нәрсәдер аның эчен пошырып, күңелен тынгысызлап торды. «Ни булды соң әле?» – дип, үзеннән-үзе төпченә торгач, тынгысыз уйның очы яңа күршеләргә, дөресрәге, аларның ишек төбендә кумәкләшеп көлешеп торган минутларына килеп тоташты.

Көтү каршына чыккач, уң як күршесе Мәүлихәттәй белән дә шуны сөйләшеп алдылар:

– Ышанма-а, Хәдичә, ышанма-а, – диде Мәүлихәттәй, сүзләрен сузып-сузып. – Ире әртис ди бит, клубта тиятр уйнап төчеләнергә өйрәнеп беткән ул. Кеше алдында гына шулай кыланалар! Өйгә кергәч, пыр талашалардыр, сугышалардыр әле. Әртис кеше шул хатынга гына карап торамы соң! Хатынын әйтәм, үзе сары, үзе юка, тәнендә черки тешләр ите дә юк!

Мәүлихәттәй, кай арада белеп өлгергәндер, сары хатынның укытучы икәнлеген, ә иренең клуб мөдире булып эшләячәген әйтеп бирде. Сөйли торгач, чутсыз мавыгып, көтү кайтып беткәнен, ала кәҗәсенең үтеп киткәнен күрми калды. Ахырда, кулына озын чыбык алып, итәкләрен кыстырып, каргана-сукрана су буена төшеп китте.

Мәүлихәттәй сөйләгәннәр, гәрчә ышандырып ук җиткермәсәләр дә, Хәдичә апаның күңеленә хуш килде.

Әмма сыерны савып, мал-туарны абзарга япкач, яңа күршеләр тагын күңелне кытыклый башлады.

Ахырда түзмәде Хәдичә апа, бер җамаяк җылы сөт күтәреп, чирәм үскән ишегалдына барып керде.

– Рөхсәтме? – диде ул, өй ишеген ачып.

Сары хатын янып торган мич каршысыннан кузгалды.

– Рәхим итегез, узыгыз!

Мичкә ягып та өлгергәннәр. Өстәлдә, олы чуен табада, мичкә тыгарга әзер өчпочмаклар. Яшь булсалар да, эшнең рәтен беләләр икән: мичкә якмый, өйгә ямь керми бит.

Таныштылар: сары хатын – Фәридә, ире Рөстәм исемле икән. Хатын рәхмәт әйтеп сөтне алды да балаларын чакырды. Олы як ишеген каерып ачып, куыша-куыша әлеге малай белән кызчык килеп чыкты. Ачык ишектә гаилә башлыгы күренде: ул идән юып маташа иде...

Бу күренештән өнсез калган Хәдичә апа Фәридәнең сүзләрен ике-өч тапкыр кабатлагач кына ишетте:

– ...Өчпочмак ашарга керегез. Парлашып. Абый өйдәдер бит?

– Эштән кайтып җитмәде шул әле.

– Ул эштән кайтуга, безнең өстәл әзер булыр. Керегез, яме?

Фәридәнең чын күңелдән, теләп чакырганы сизелеп тора иде. Хәдичә апа баш тартырга җөрьәт итмәде.

«Ай-һай, юньле ир түгелдер бу, – дип уйлады ул капкадан чыгып килгәндә Рөстәм турында. – Кулыннан эш килә торган кеше булса, хатыншаланмас иде».

Җиргә эңгер-меңгер төшкәч кенә кайтты Шакир абзый. Яңа күршеләр килгәнен, үзләренең кунакка чакырулы икәнен белгәч:

– Һе, ялкауга ял килгән, сиңа аш пешермәскә җай чыккан икән, – дип кеткелдәде.

– Менәтерә, сүз дисәң ие! Кайчан аш пешерергә иренгәнем бар минем?

Хәдичә апа, өй котлап бирергә дип, сандык төбеннән чиккән башлы озын сөлге тартып чыгарды. Заманча бүләк түгел түгелен, кибеткә барырга вакыты тар шул.

Табын матур гына иде. Хәдичә апа тәмләп чәен эчте, башкалар мәеннән авыз иттеләр.

Шакир абзыйга яшьләр бер күрүдә ошады. Рөстәм белән чишелеп, рәхәтләнеп Казан хәлләрен сөйләшеп алдылар. Казанда нинди төзелешләр бара, театрларданиләр куела, халык ничегрәк яши... Шакир абзый, тәмам ачылып китеп, үзенең дә клубны читләтеп узмаганын, яшь чакларда «Асылъяр» пьесасында Шәрәфне уйнаганын исенә төшерде.

– Хәзер дә чакыргалыйлар әле, тик Шәрәфне уйнарга кушмыйлар, һаман киребеткән картлар ролен тоттыралар.

– Карагыз әле, Шакир абзый, безнең Фәридә Ләлә ролен уйнаган иде бит, – диде Рөстәм һәм, урыныннан кузгалып, почмактагы тартмадан ялт-йолт итеп торган олы баянын чыгарды. – Әллә соң, җыен артист бергә җыелгач, бер җырлап алыйкмы?

– Кхм-кхм, – дип тамак кырып куйды Шакир абзый. – Хәзер инде «Асылъяр»ны җырларлык чама юктыр...

Фәридә, елмаеп, кулын селтәде:

– Юк-юк, «Асылъяр»ны җырламыйк. Ул пьесаны куйганда болай да Рөстәм гел үпкәли иде миңа. Мин чит егеткә гыйшык җыры җырлыйм, ә ул, бичара, сәхнә артында баянда уйный, үзе, арттырып җибәрмәсен бу дип, мине күзәтә...

Рөстәм, үзен шаяртканнарын сизмәмешкә салышып, баян төймәләренә басты.

Шакир абзый, җитди төс алып, куе, калын тавыш белән әкрен генә башлап җибәрде:

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек...

Ул җырның сүзләренә игътибар да итмәде, бары тик, дөрес җырлыйммы, ялгышмыйммы дигәндәй, үз тавышын гына тыңлады.

Аңа Фәридәнең артык көчле булмаса да, матур, аһәңле тавышы кушылды, ара-тирә керфекләре аша гына иренә күз ташлап алды ул: «Мин юри генә җырлыйм моны, сер сөйләр кешем бар минем, ул – син, миңа бүтән берәү дә кирәкми...» – ди иде аның карашы.

Бу минутта ул җәйге таңда талпынып сайраган кошны хәтерләтә иде. Аннан тыйнак нәфислек, хисләр тирәнлеге бөркелеп тора, яшь кызларныкы кебек җиңел сөякле зифа гәүдәсе, янып торган бит алмалары, сөрмәле зәңгәр күзләре теләсә нинди егетне дә гашыйк итәрлек. Бер куплет бетеп, баян гына уйнаганда:

– Хәдичә апа, әйдәгез, сез дә кушылыгыз, – диде ул.

Юк, олы хатын ир-ат алдында ничек инде авыз күтәреп җырлап утырсын ди! Аның җырын балалары гына, алары да бишектә чакта гына тыңлады.

Өстәвенә Хәдичә апа арада авызына бер тамчы хәмер капмаган аек кеше иде. Ул бик җентекләп каршында утырган яшьләрне күзәтте һәм аларның әле бүген генә бер-берсенә гашыйк булгандай сөешеп карашуларына, бер-берсен олылау-хөрмәтләүләренә хәйран калып утырды. Фәридәне тәнкыйть иләгеннән үткәрде, бер дә искитәрлек җирен тапмады, аның бу чаклы бәхетле булуын берничек тә аңлата алмады.

Өйгә чыккач, Хәдичә апа картыннан:

– Ошадымы соң яңа күршеләр? – дип сорады.

– Ир белән хатын инде. – Шакир абзый, йокысы килгәнен белгертеп, озак итеп иснәде. Бу инде баягы Шакир абзый түгел, аның арыганлыгы да, олыгайганлыгы да берьюлы бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан иде.

– Сизденме, бер-берсеннән күзләрен алмыйлар.

– Алмасалар алмаслар, үз ирекләрендә. Йә, җәй әле урынны!

Арыган булса да, йоклый алмый аптырады Хәдичә апа. «Яшьләр шул әле, – дип уйлады ул күршеләре турында. – Яңа җиргә, ят кешеләр арасына күчеп килгәч, хисләре яңаргандыр, бер-берсенә тагын да кадерлерәк, якынрак тоелалардыр. Рөстәме дә гел хатынын мактап тора, безнең Фәридә аш-суга оста, дигән була. Баксаң, өчпочмаклары бер дә әллә ни түгел иде: тозы да җиңел, борычы да әзрәк».

Ә Хәдичә апа катыкка гына изеп, сары майда йөздереп пешергән бодай кабартмалары ярата иде... Бар иде аларның да шундый яшь чаклары. Менә шулай берзаман Шакир урам буйлап велосипедында кайтып килә. Моны ян тәрәзәдән күзәтеп торган Хәдичәнең йөрәге дөп-дөп тибә.

Шакир, ишектән керә-керә иснәнеп:

– Ни пешердең? – ди.

– Кабартма...

Шакир кылыч борынын җыера:

– Бар белгәнең шул көлчә!

Аннары кире велосипедына атлана да су коенырга китеп бара. Бер-ике сәгатьтән, шау-гөр килеп, бер көтү дусларын ияртеп кайта ул:

– Кая, ашарга китер!

Кесәләрдән өстәлгә шешәләр чыгып утыра. Ашау-эчү, шау-шу, җыр китә. Хәдичә, ашыгып-кабаланып, учакка яга, битләре янып пешкәнче, йөрәге сулкылдап типкәнче, чи утынга өрә. Өстәл белән мич арасында соса кебек йөреп тора. Ул, Шакир белән икәү кара-каршы утырып ашарбыз дип, көндез дә авызына ризык алмаган, хәзер дә ашап алырга вакыт тими.

Өстәл янында көлешәләр:

– Иртәрәк өйләнеп ташлагансың, Шакир, – ди берсе. – Юкка ашыккансың камыт кияргә.

– Абындым шул, егетләр, бүрәнәгә абындым, – ди Шакир, кара мыегын бөтереп.

Исерек баштан әйтелгән бу сүзләр утыз ел үткәч тә онытылмаслык булып Хәдичә апаның күңеленә сеңеп калган. Актарына башласаң, йөрәккә кадалып калган андый шырпылар берәү-икәү генә түгел алар!

Шакир, Хәдичә гомер буе аз сүзле дип исәпләп йөргән Шакир, берәр кеше ияртеп кайтса, сөйләшеп туймый иде. Кая аның серен алган кешеләр?! Баксаң, хатыны Хәдичәдән дә якын кешесе юк бит...

Ниһаять, төн урталарында мәҗлес тәмамлана. Эчкәндә беркайчан да чамасын югалтмый торган Шакир, өйалдына чыгып, әзер урынга үрмәли. Хәдичә өстәлдән савыт-сабаны, аш калдыкларын, үзенә рәхәтләнеп утырып ашарга насыйп булмаган кабартма сыныкларын җыеп ала, пычранган идәнне юа.

Мондый «күңел ачулар» Хәдичә апа гомерендә аз булмады! Ә менә үз өендә түр башына менеп, матур киеме белән масаеп, кунаклар алдында ире тарафыннан макталып утырганын хәтерләми ул.

Эченнән генә әрнеп, офтанып яткан Хәдичә апа таң алдыннан гына йокыга талды. «Хәдичә! Хәдичә!» дигән чәрелдек тавышка уянса, көтү китеп бара икән. Ул ничек кирәк алай өстенә бишмәт эләктереп, яланаяк ишегалдына йөгереп чыкты да саумаган сыерын, зарыккан сарыкларын урамга куып чыгарды.

– Ай-һай, тәмләп йоклыйсың! – диде Мәүлихәттәй, көлемсерәп. – Кичәге кунак килеште сиңа, ә?

– Уятуыңа рәхмәт инде, Мәүлихәттәй. Тәки маллар көтүдән каладырые, – дип, сүзне шома гына борып куйды Хәдичә апа.

Ул суга барырга чыкканда, Мәүлихәттәй, көянтә-чиләкләрен күтәреп, аны көтеп тора иде. Иртәнге саф һава йокыны бик тиз качырды. Кояш чыгып кына килә, тыкрыктагы бәбкә үләнендә, күзне камаштырып, чык ялтырый. Атлаган саен чүәк башыннан тамчылар чәчри. Елга суы чык тамчыларыдай салкын, чиста, төбендә сыр-сыр булып утырган ком аермачык күренеп тора. Казлар төшеп суны болгатып өлгермәгән әле. Тулы чиләкләрдән көмеш тамчылар сибелә. Дөнья матур, дөнья картаймый.

– Ниләр кылана соң теге әртис? – диде Мәүлихәттәй.

– Соң килештерәләр инде, килештерәләр. Хәлил белән Галиябану кебек күзләрен күзләрдән алмыйлар.

– Ышанма-а, Хәдичә, ышанма-а! Мөгаен, ире йөргәндер дә хатыны берәр кыз белән тоткандыр. Минем Гайнетдин, чуалып кайткач, гел күземә генә карап торадырые, мәрхүм. И-и, үткән гомер – искән җил, диген. Бар иде безнең дә яшь чаклар, ә!

Әрәмә артыннан тәгәрәп чыккан кояшка хатыннарның күзләре чагыла. Әйе, дөнья картаймый шул. Кеше генә картая. Хәер, һәркемнең үз пары, Хәдичә апаның янында үз Шакиры. Әлегә икесе дә сау-сәламәтләр, гомерләре дә гөл кебек. Бу рәхәт дөньяда иркәләшеп, бер-береңне кадерләп яшәмәгәч!

Судан кайтып, көянтәсен иңеннән төшергәч тә өйгә керде һәм өстәл турындагы көзге каршына басты Хәдичә апа. Башка чыккач та алынган бу зур көзгә самовар парыннан башта сипкелләнде, аннары шадраланды. Көзгедәмени хикмәт, үзе шадра булса да, биттәге җыерчыкларны аермачык күрсәтә. Картаелган шул, нихәл итәсең. Заманында билгә төшеп торган коңгырт толымнарны вакыт дигәнең сиздерми генә йолкып бетергән... Шулай да зур соры күзләр уңмаган әле, тешләр дә таза, ак. Матуррак итеп киенеп тә җибәрсәң... Бу корымга, сөткә, тавык боламыгына буялган алъяпкычны салып ташласаң, яңа оеклар киеп куйсаң...

Кичен, Шакир абзый эштән кайтканда, өй ялт иткән, авыздан сулар китереп, итле аш исе аңкый иде. Көрән йон күлмәген кигән, мәк чәчәге төшкән яулыгын артка бәйләгән Хәдичә апа ирен болдырга чыгып ук каршы алды.

– Әллә кунак-мазар килдеме? – ди Шакир абзый, шикләнеп. – Киенгәнсең, ясангансың.

– Үзебез дә бу дөньяда кунак кына, үзебез өчен ясандым.

Хәдичә апа иренә кулъюгычтан юынырга ирек бирмәде, комганнан җылы су салып торды. Өйгә керү белән тәрәзә пәрдәләрен корып, электр уты кабызды. Өстәлгә кадерләп тота торган ашъяулык җәйде, табак белән аш, аерым тәлинкәдә бәрәңге белән тавык ите китерде. Икесенә дә аш бүлде дә, уйланып, Шакирына карап утыра башлады.

– Аша, нәрсә утырасың, – диде ахырда Шакир абзый. – Ашаганда авызыма карап торганны яратмыйм мин.

Өстәлгә җырлап торган җиз самоварны куйгач, Хәдичә апа картына янә бер өздереп карады. Утырды, чәй ясады. Шакир абзыйның такыр итеп кырган башын сыйпыйсы килә иде аның. Кытыршыдыр. Уч төпләрен кытыклыйдыр... Аңа да рәхәт булыр микән? Хәдичә апа кулын күтәрде. Юк... йөрәге җитмәде, кыймады. Гомер андый нәрсәләргә күнекмәгәнгә, кыенсынды, кыз кеше

кебек оялып куйды. Шакир абзый, бик мавыгып, шырпы кыйпылчыгы белән тешен казый иде. Сул кулы тезендә ята. Хәдичә апа, батыраеп, зәңгәрсу тамырлары бүртеп чыккан шул зур, кызыл кулны сыйпады. Шакир абзый борылып та карамады, ул хатынын аңа ялгыш кына орынды дип уйлады, күрәсең.

– Приемникка бас әле. Дөньяда ниләр бар икән.

Иренә сүзсез буйсынырга күнеккән Хәдичә апа урыныннан кузгалды.

– Дөнья хәле, дисең... – диде ул әрнеп, иренә карамыйча. – Минем хәлне белмисең. Әнә кешеләр ничек матур торалар. Кешенең хатыны да кадерле...

Шактый вакыт сүзсез торгач, табышмакны чиште Шакир абзый:

– Ә-ә, син теге яңа күршеләрдән күрмәкче инде. Соң, алар яшьләр бит. – Монысы гына аз күренде, ахры, ул тагын бер дәлил китерергә булды: – Хәзерге яшьләрнең бозыклыгы да чиктән ашкан. Аларга карасаң... Кая, тагын бер чынаяк чәй яса да урын салып бир. Арылды бүген.

Хәдичә апа авыз ачарга да өлгермәде, радиоалгыч кызды һәм рус телендә калын ир тавышы белән бөтен өйне яңгыратып сөйләргә тотынды. Шакир абзый карчыгын онытты.

Карты ятып йоклады, ә Хәдичә апа суынган самовары янында моңаеп утырып калды. Аның йөзендә үпкәләү дә, үкенү дә, сүнеп барган өмет тә чагылды. Сөйкемле дә, кызганыч та иде ул бу минутларда. Тик аның янында юатучы, аның уйларын тыңлаучы юк иде шул. Бары радиоалгычның яшел күзе генә аңа текәлгән һәм шул җансыз күз яшь койгандай бер киңәя, бер кысыла иде.

Хәлбуки Хәдичә апага нинди дә булса юаныч бик-бик кирәк иде. Һәм ул, саламга ябышкандай, Шакир абзый әйткәннәргә тотынды: «Ие шул, яшьләр артыннан куып җитәрлекме соң? Сугыштан соң үскән балалар кайгы-хәсрәт күрмәде, дөньяның рәхәтен генә татып яшәде. Аларга ни кылансалар да килешә. Менә башлары ул-бу бәлагә тарыса, олы хәсрәт килсә, күзгә-күз карашып кына яши алмаслар әле нибуч!»

...Көннәрнең берендә Рөстәм кулларына ике чиләк тотып иртәдән төшкә чаклы су ташыды, өй артында күгәреп яткан тимер мичкәне тутырып куйды хәтта.

Аннары Хәдичә апаларга килеп керде.

– Бик зур үтенечем бар иде сезгә, – диде ул, бераз кыенсынгандай. – Мин Казанга китәм. Мин югында Фәридәгә бераз ярдәм иткәләсәгезче... Аңа авыр эш ярамый.

– Бәй, бик озакка китмисеңдер лә?

– Аз дисәң дә, бер өч-дүрт көнсез кайтып булмас. Якын ара түгел бит.

– Керермен, керермен, бер дә борчылма, – диде Хәдичә апа. Үзе эченнән генә: «Өч көн өчен шулчаклы килештереп йөрмәсәң! Нинди авыр эше булсын аның, айлык суын ташып куйдың бит инде», – дип уйлады.

Иртәгесен көн болытлады, игеннәр өчен бик шифалы, талгын яңгыр ява башлады. Хәдичә апа, бәйли торган оекбашын күтәреп, Фәридә янына кереп китте.

Бакча якка чыга торган тәрәзә шар ачык. Карлыган яфраклары яңгырда шыбырдый. Рәхәт шундый көннәрне сөйләшеп утырулары. Фәридә Рөстәм кайтуга дип яңа күлмәк тегә, аның да ашыгыч эше юк.

– Хәзерге яшьләр гел калага китү ягын карыйлар. Сез ничек монда кайтасы иттегез?

– Авылның һавасы әйбәт бит, Хәдичә апа... Миңа саф һава кирәк.

Хәдичә апа сагаеп куйды:

– Авырмыйсыңдыр бит?

– Авырган идем шул... Үпкәм слабыйрак. Шуңа авылга күчәргә булдык. Шәһәрдә квартирабыз бик яхшы иде, калдырырга туры килде.

Хәдичә апа туктап торган энәләрен тагын хәрәкәткә китерде.

– Һи-и, бик дөрес эшләгәнсез, бик дөрес. Безнең авылның һавасы бик шифалы. Менә ай да үтмәс, тазарырсың әле. – Үзе Фәридәнең кыенсынганын сизде һәм сүзне икенчегә борырга кирәк тапты. – Рөстәмне әйтәм, көн дә баянын тага да клубка чыгып китә. Гел-гел яшь кызлар арасында чуала. Көнләшмисеңме?

Фәридә елмаеп куйды:

– Юк, Хәдичә апа, көнләшмим. Чөнки мине башка берәүгә мәңге алыштырмаячак ул.

– Ышангансың икән ирләргә!

– Ышандырды ул мине... – Аннары, шактый тынып торгач: – Әгәр ташларлык булса, элегрәк ташлар иде. Ул мине бик авыр чагымда больницадан өенә алып кайтты, шуннан соң өйләнештек. Ул булмаса, мин бу дөньяда яшәмәс тә идем инде, мөгаен...

Хәдичә апа, күзләрен зур ачып, Фәридәгә гаҗәпләнеп карап утырды. Белсәң иде нинди мәхәббәте бар икән бу очлы борынлы, ак чырайлы, ябык хатынның? Менә диган чибәр Рөстәм ничек өйләнгән аңа?

Өенә чыккач та һаман шул турыда уйлады ул. Ничек шулчаклы иреннән уңган икән бу сары хатын? Дөньяда бәхет, мәхәббәт дигәнең кешенең кай ягына карап бирелә икән?

Яшь чагында Хәдичә апа шул сары чәчле Фәридәише генә идеме соң? Кече урамның беренче чибәре иде. Ак, шома тула оеклар, шыгырдап торган яңа чабаталар киеп, чулпыларын чылтыратып урамнардан үткәндә, бер генә егетнең йөрәге җилкенмәгәндер. Ашыкмады Хәдичә, уйлады, сайлады, авылның иң шәп егетенә, армиядән яңа гына кайткан кара мыеклы, яшькелт күзле Шакирга чыкты... һәм каенана белән каенатага, каенишләргә килен хезмәте күрсәтә башлады.

Каенатаның, түр башында кулына китап тотып:

Әтәч суйсаң, элек алгыл ботыны,
Хатын алсаң, элек алгыл котыны, –

дип, акыл өйрәтеп утырганы әле дә хәтерендә. «Ник алай рәнҗетәсең мине?» – дип әйтә алмады килен, чөнки ул элекке гадәт буенча тел яшерә иде. Шакир исә атасы сүзләрен сеңдереп кенә барды.

Нәкъ шул елларда Хәдичәнең яшьтәшләре төрле курсларга укырга киттеләр, бер-ике елдан медсестралар, укытучылар булып кайттылар. Хәдичәне дә укырга димләгәннәр иде, бармады: «Гаиләбез зур, күбесе ирләр, ничек ташлап китим», – диде. Ахмак, диген, юләр. Килен хезмәте укып чыккач та качмас иде әле. Шакир да аны җибәрергә риза түгел иде. Кая ул, җибәрәме соң, биш ай буе аның кулына комганнан җылы суны кем салып торыр?

Зирәк иде югыйсә Хәдичә. Мәктәптә укыганда, кызык өчен китаптагы шигырьләргә үз такмакларын кушып җибәрә торган иде. Соңрак гарәп хәрефләре бетте, латинча яза башладылар. Ликбезларга йөреп, анысын да ничек кирәк алай өйрәнеп, гадәтләндем генә дигәндә, рус хәрефләренә күчтеләр. Русчасын Хәдичә апа тәки булдыра алмады, Ильясова дип фамилиясен көчкә куя. Газетаны да хәрефләп кенә укый. Надан булып калды зирәк Хәдичә...

Армиядән аң-белем алып, күтәрелеп кайткан Шакир чит авылларга җитәкчелек итеп йөрде.

Башка чыккач, ир бала тапкан иде Хәдичә. Урак өстендә, дүрт яше тула дигәндә, ул бала эч китүдән үлде. Шакир ерак авылдан баланы күмәргә генә кайтып җитте. Хәдичә аның өйалды почмагында үксеп торганын күрсә дә, янына барырга кыймады, ул үзе күз яшен түгеп бетергән иде инде. Теле белән әйтмәсә дә, Шакирның кыяфәтеннән: «Шул баланы саклый алмадың», – дип үпкәләү сизелә иде.

Кайгыдан суырылып калган Хәдичә ерак басуга ашлык сугарга китте.

Көндез ярыйсы. Кояш эссесендә бәйләнгән авыр көлтәләрне молотилкага атып торганда уйланырга вакыт калмый.

Караңгы төшкәч, ригада*, кылчыклы салам өстенә яткач авыр. Хәдичәгә улы үлмәгәндер, элеккечә, тәрәзә төбенә басып, әнисен көтәдер, инде елап ярсып беткәндер кебек тоела башлый. Ул, иптәшләрен уятмас өчен, ригадан сак кына чыга да авылга йөгерә. Көзге айсыз төннәр караңгы. Туктап-туктап юлны кулы белән капшый ул. Сулышына кабып, капкадан кайтып керә. Ә өйдә тынлык, шомлы почмаклар, салкын мендәр. Аңа өйдә бигрәк тә авыр...

Бер башына төшкән хәсрәт түгел иде югыйсә, уртак кайгы иде. Шакир да газиз улын югалтты лабаса! Ул да чит өйләрдә, ят түшәкләрдә төннәрен йокысыз үткәргәндер, мөгаен! Алар кайгыларын аерым кичерделәр, шуңа күрә ул икеләтә авыр тоелды.

Сугышы, ачлыгы, авыр эше – болары ил белән килгән кайгы, аны бөтен халык белән күтәрделәр. Ярый әле Хәдичәнең бәхете булды, Шакиры исән-сау әйләнеп кайтты.

Шакир абзый кайтып кергәч, сөенечтән бераз аңына килгәч, Хәдичә апа сандыгыннан картының дүрт костюмын тартып чыгарды.

– Карале син, сал инде ул гимнастеркаларыңны. Бу костюмнарыңны кайчан киясең?

Тизрәк ирен гади костюмнан күрәсе килде. Бары шунда гына сугышның бетүенә, тыныч тормыш башлануына күңеле ышанып җитәчәк иде аның.

– Боларны ничек сакладың син? – диде Шакир абзый, сөенеп тә, гаҗәпләнеп тә. – Берсе калса, бүтәннәрен сатсаң да сүзем булмас иде... Үзең дә өстеңне алыштыр инде, болай булгач. – Ул карчыгының селтедә юудан төссезләнгән ямаулы күлмәгенә ишарә ясады.

Хәдичә гаепле кешедәй кызарынып башын иде:

– Юк шул... бүтән күлмәгем юк... Яхшыларын ипигә алыштырып бетердем...

Ул минутларда Шакирның күңелендә хатынына рәхмәт хисе, аны кызгану, хөрмәтләү, иркәләү теләге уянган иде.

Әмма көннәр үтте, мөнәсәбәтләр элекке эзгә кайтып төште. Хәдичә һаман бик күпләр каршында бурычлы кеше саналды. Ул колхозда сутый куарга тиеш (эшләмәгән – ашамый), ирен, балаларын тәрбияләргә тиеш (ир хакы – Тәңре хакы), каенанасына, каенатасына, каенишләренә ярарга тиеш (килен кеше – ким кеше). Һәм ул, ничаклы гына тырышса да, күпме генә чапса да, нихәтле генә аз йокласа да, бу бурычларны тиешенчә үтәп бетерә алмый иде; көн артыннан көн килә, таң аткан саен, эш арта, Хәдичә апаның үзе турында уйлап карарга вакыты да калмый иде: «Тукта, картның кәефе кырылмасын», «Тукта, балалар бераз исәйсен», «Кыш үтсен», «Игеннәрне җыеп бетерик»...

Шулай дия-дия, утыз ел гомере үткән дә киткән. Шул гомер эчендә берәү дә Хәдичә апага ярарга тырышмаган, беркем аның күңелен күрмәгән, аның хис-уйлары белән кызыксынмаган...

Хәзер инде тормыш та рәтләнде, балалар үсте, колхозда эшләр җиңеләйде. Инде үзеңне карарга да вакыт җитәрлек. Әмма утыз ел гомерне кире кайтарып булмый шул.

Утыз ел эчендә ничаклы сүзләр сөйләнмичә күңелгә төер булып утырган! Күпме бәйрәмнәр, бәхетле булырдай минутлар сизелми үтеп киткән! Никадәр сөелү-назлану күрелмәгән!

Бөтен җаны-тәне белән иренә әрнеде Хәдичә апа. Әгәр ул аңа кешечә караган булса, дус-иптәш итсә, болай кадерсез үтмәс иде аның гомере! Ул гынамы, калган гомере дә шулай кадерсез үтәчәк бит әле!

Хәдичә апа, яңгыр туктаганны да көтмичә, җил-җил колхоз бакчасына китеп барды. Анда әллә ни эш юк иде, шулай да караңгы төшмичә кайтмады ул.

Шакир абзый өйдә иде инде. Ул карчыгын биләмдә йөргән дип белде булса кирәк.

– Кая, ашарга берәр нәрсә әмәлләп бир әле, – диде.

– Әмәлләрмен. Тик әүвәл син миңа су алып кайтып бир. Хәтирәттәйләр ындырына да күз сал, сыер шунда йөрмиме икән?

Шакир абзый карчыгына, акылдан яздыңмы әллә, дигәндәй карады.

– Бәлеш! Мин суга барырга, син хаста түгел бит әле.

– Хаста мин, бик хаста! Авыр күтәрүдән эчем төшкәнгә унбиш ел инде! Әнә күрше хатынына бер чиләк су да күтәртми! Мин, юләр, егылганчы чабам! Утыз ел чаптым, сиңа ярый алмадым! – Хәдичә апа тәмам ярсыган иде.

Шакир абзый:

– Сыер дуласа, аттан яман, – дип мыгырданып, капкадан чыгып китте. Кибет тарафына юнәлде, тагын кая барсын.

Иртән Хәдичә апа торып чыкканда, карты, өстен дә чишенмәгән килеш, өйалды идәнендә толып өстендә йоклап ята, янында таш кебек каткан прәннекләр ауный иде. Ул, ишек шакылдаган тавышка уянып, өйгә керде.

Урамнан ашыгып Рөстәм кайтып килә иде. Кулында бер бәйләм эре-эре йөнтәс чәчәкләр, Фәридәсе, яңа кулмәген киеп, балаларын җитәкләп каршысына чыккан!

Рөстәмне тәрәзәдән күргән Шакир абзый:

– Менә бит син аларны, нинди матур тормышыбызны боздылар! – дип мыгырданды.

Ә Хәдичә апа, җил капка аратасына ябышып, күршесен яшьле күзләре белән озатып калды.

*1967*

## Кар сулары

Ибраһим абый Газиның
якты истәлегенә багышлыйм.

Мин кар суына барам. Күгелҗем сукмак буйлап тау арасына менәм. Сукмак тар, аякларны туп-туры басарга кирәк, юкса батасың. Элекке заманнарда авыл кызлары эзләренең җепкә тезелгәндәй тигез булуы белән мактанганнар. Ә без үстек, шәһәргә киттек, аннан аяк башларын ике якка каратып йөрергә өйрәнеп кайттык.

Мин балачактагыча туры басарга тырышам. Сукмак кырыенда карның өсте челтәрләнгән. Ул кыш көнендәге шикелле күзләрне чагылдырмый, асылташлар сипкәндәй җемелдәми. Кар да картая икән. Дөрес, биредә ул шәһәрдәге кебек каралмаган, пычранмаган, тик тоныкланган, басылган, авырайган. Уйсу җирдә ул әле нык ята, ләкин яз кояшы аны тау түбәсеннән куган инде, ул, күкселләнеп торган текә тау битенә өр-яңа җыерчыклар салып, агып төшкән. Күптән түгел әле биредә малай-шалай, чаңгы киеп, таудан тауга очкандыр. Кечкенәләр, чыр-чу килеп, пальто итәкләре, ыштан төпләре бозланып катканчы, чана шугандыр. Озакламый алар тау араларында, йомшак чирәмдә тәгәрәп уйнарлар.

Минем кулымда ак чиләк, аның эчендә яшел чүмеч. Без бәләкәй чакларда сыңар чиләк белән суга йөрү юк иде. Хәзер инде мин иңемә көянтә асудан күптән биздем, чөнки каладагы квартирабызда су краннан агып тора. Авылда да өебез турына ук колонка китереп куйганнар. Аннан чишмә суы ага. Ул су җиргә күмелгән торбалар буйлап, тау өстендәге басулар аркылы, еракта агып килә. Ә без чишмәгә, урам очыннан чыгып, зират турыннан узгач, тауга менеп, шактый озак бара торган идек. Ул су бик кадерле була, аны самоварга гына тоталар иде.

Язын чишмә юлларына ташу төшә, Минзәлә елгасы яман болгана иде. Әнкәем суны тау арасыннан – кар астыннан алып кайта иде. Кар суы, чишмә суы кебек тәмле булмаса да, салкын, чиста була, керне ныграк агарта, чәчне әйбәтрәк йомшарта иде.

Шуңа күрә мин дә бүген кар суына барам. Беренче карашка кар бик нык ята әле, беркайда да чүмечләп-чиләкләп алырлык су күренми. Ләкин бу өстән караганда гына шулай. Менә мин балачактан билгеле урында, кар астыннан бер почмагы гына күренеп торган зур соры таш янында туктыйм. Таш тирәли кар эреп, уелып төшкән. Сукмак кырыендагы карны чүмеч белән чумырып алам. Чумырган саен, чокыр тирәнәйгән саен, кар авырая, чылана бара. Ниһаять, чокыр төбендә үлән күренә. Кар астыннан, сиздерми генә, су агып ята икән. Әнә ул узган елгы корыган үлән сабакларын да, яшел чирәмне дә үз юлы уңаена каратып, тарап куйган. Кар суының саф җиле битемне иркәләп, сыйпап үткәндәй була. Мин тагын бер сайрак чокыр казыйм. Аңа, кардан саркып, сабый күз яшедәй чиста су җыела. Үземне күрергә теләгәндәй, су өстенә иеләм, су агышын ишетергә тырышып, тынып калам. Әйе, мин чыннан да үземне күргәндәй булам, тик, күп юллар үтеп, гомер уртасына җиткән кешене түгел, унөч яшьлек чандыр кызны күрәм; мин ишетәм, ләкин су челтерәвен түгел, вак ташлар өстеннән сикереп аккан чишмә кебек саф, яңгыравыклы тавыш ишеткәндәй булам.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

Рафис тавышы бу. Әллә соң аның җыры тау өстендә сакланды микән дә, һәр яз саен, кар суларына ияреп, авылга төшә микән?

Иделне безнең беребезнең дә күргәне юк иде. Рафис җыры буенча мин аны болайрак күз алдына китерә идем: авылыбызның уртасыннан ага торган Минзәлә елгасының язгы ташуларда да тулып җитмәс биек ярларын саф чишмә суы белән мөлдерәмә тутырсаң, аңа озын муенлы ак казлар куып төшерсәң, нәкъ Идел төсле булыр иде шикелле. Су төбенә сырланып утырган кызгылт комы, комлыклардагы бака кабырчыклары, яр өстендәге карт өянкеләре белән бу хыялый Идел чыннан да бик матур булачак иде.

Мин, алтынчы класста укучы, тамагы ипигә туймаган арык кыз, унөч яшемдә шушы Идел турындагы җырны һәм аны җырлаучы малайны яраттым.

Кай җире матур иде ул малайның, дип сорасалар, аңлатып бирә алмас идем, мөгаен: түгәрәк ак йөз, кара чәч, буйга кечерәк кенә. Тик кара күзләрендә үзәкләргә үтә торган моң-сагыш бар иде аның. Рафис ятим малай иде. Әтисе сугышта үлгән, әнисе улын әбисенә китереп куйган да үзе читкә китеп барган... Малай җиде классны укып бетерсен, ә мин шәһәргә урнашыйм, ныгытып төпләнгәч, кайтып алырмын, дигән. Китереп куйган, дим, чөнки Рафис башка авылда туып үскән малай иде.

Безнең арада ярым ятимнәр күп иде, ә менә тулы ятим, өстәвенә ят авылда яшәргә мәҗбүр бала ул берүзе иде. Авыл малайлары аны чит күрделәр, араларына кертмәскә тырыштылар. Бәлки, шуңа күрәдер аның күз күрмәгән Идел турындагы безнең өчен яңа җыры бәгырьләрне телгәләрлек моңлы иде.

Аның тау өстендә мал саклаганда җырлаганын мин онытылып тыңлый идем, аның язмышы белән үз язмышым арасында уртаклык барын тоя идем.

Дөрес, мин ятим түгел, атам-анам исән-сау, ләкин урамда, бала-чага арасында үземне ялгыз хис итә идем, чөнки гаиләдә бердәнбер бала идем. Йорт саен дүртәр-бишәр бала, алар бер-берсенә дус та, яклаучы да, ярдәмче дә. Ә мин, шук малайлар башым белән карга тыгып китсәләр дә, коенганда күлмәгемне суга ыргытсалар да: «Их, абыем булса, мине болай кыерсытмаслар иде!» – дип өзгәләнеп елый идем.

Чит авылдан килгән малайның, уеннарга, шаяруларга катнаша алмыйча, читтәрәк йөрүен күргәч, мин аны кагылган каз бәбкәсенә охшаттым. Кайчак казлар да соң чыккан зәгыйфь бәбкәне шулай кагып-чукып интектерәләр, ә ул һаман, бераз ара калдырып булса да, үз оясына ияреп йөрергә мәҗбүр – башка кая барсын соң?

Балачакта кеше ялгызлыкка бигрәк чыдамсыз була, аңа иптәш, уендаш, дус кирәк.

Кайчан ярата башладым мин Рафисны? Әйтә алмыйм. Бу хис минем күңелемдә, кар астыннан аккан су кебек, сиздермичә, күренмичә уянды. Кар суының беренче тамчысы кайчан, кайда хасил булганын кем генә әйтә алыр икән?

Унөч яшьлек баланың күңелендә яз башлану да бөтен кеше өчен сер иде. Кайчан, кайда ул минем яратканымны сизде? Әллә башта мин аның яратканын белдем микән? Ул җиденче класста укый, ә мин – алтынчыда. Без бер-беребездән китап-дәфтәр алыша башладык. Алар арасында кыска гына язулар да була иде...

Безнең мәктәп дөньядагы иң әйбәт мәктәп булгандыр, мөгаен. Ул бер катлы гына булса да, биек, тәрәзәләре зур иде. Тышкы ишектән туп-туры залга килеп керәсең. Зал тирәли – класс ишекләре. Сугыштан соңгы елларда, әтиләр әз калган булса да, укучы балалар бик күп иде: ике алтынчы класс, ике җиденче.

Хәзер генә ул бер укытучы ике-өч классны берьюлы укыта. Искесен күптән сүттеләр, яңа кечкенә мәктәптә башлангыч класслар гына укый. Тәнәфесләрдә аларны көләч йөзле Нурҗиһан апа «Барыня» көенә такмаклап биетә.

Ә безнең иске мәктәптә бик оста гармунчылар бар иде. Кышкы салкыннарда да залда рәхәт. Озын тәнәфестә җиденче класс егете Зиннур, сәхнә янына утырып, гармунын сыздырып җибәрә, без әйлән-бәйлән уйныйбыз:

Алга, дибез, алга, дибез,
Алга таба барабыз;
Алга барырга кушкан бит
Безгә Ленин бабабыз.

Аннары туктап кул чабабыз, ә уртада икәү култыклашып әйләнә:

Золотой радиатор,
Золотой регулятор,
Золотой карбюратор,
Золотое магнето.

Әйлән-бәйлән уйнаганда, без «очраклы гына» Рафис белән янәшә туры килгәли идек. Бер-беребезгә күз салу юк инде ул, учны учка куеп йөрү генә дә безнең өчен бәхетнең иң зурысы иде. Андый минутларда бездән дә дәртләнебрәк, бездән дә кычкырыбрак җырлаучы, мөгаен, булмагандыр.

Яңа ел җитеп килә иде. Гадәттәгечә, олы тәнәфестә уеннар оештырдык. Уртада алмаш-тилмәш бииләр, ә калганнар, түгәрәк ясап, карап тора. Түгәрәк кечкенә, балалар берничә рәт баскан. Шунда Рафис минем артка килеп басты, биючеләрне күрергә теләгәндәй, җилкәм аша үрелеп карады һәм, тирә-яктагыларга сиздерми генә, кесәмә нидер салды. Мин кулым белән капшап карыйм – салкын, каты әйбер. Алып карарга җай юк, кем дә булса күрер дип куркам. Класска кергәч, бигрәк тә сак булырга кирәк: янымда, бит очларын чокырайтып, зәңгәр күзләрен чекерәйтеп, усал малай – Нур утыра, берәр нәрсә сизсә, бөтен мәктәпкә фаш итәсен көт тә тор.

Дәресләр беткәнен ничек газапланып көткәнемне, аннары кызлар белән авыл урамы буйлап кайтканымны тәфсилләп сөйләп тормыйм.

Ниһаять, абзарга кереп, калтыранган кулларым белән бүләкне кесәдән чыгардым. Ул тар гына кызыл каеш булып чыкты. Андый бил каешларының модага кереп кенә барган чагы, аларны табу бик кыен иде. Күрәсең, Рафисның әнисе посылка җибәргән булгандыр. Ул елларда читтәге кешеләр авыл җирендәге туганнарына шундый вак-төяк товар җибәргәлиләр иде. Аларны азык-төлеккә алыштырып була иде.

Гадәт буенча мин, егетнең бүләгенә каршы бүләк итеп, чиккән кулъяулык бирергә тиеш идем. Бик пөхтә итеп, аллы-гөлле бизәкләр белән чиккән булыр идем мин ул кулъяулыкны! Дөньяда иң матур кулъяулык булыр иде ул! Ләкин, күпме генә хыяллансам да, мин бу эшне башкара алмадым. Чөнки минем ситсым да, чигү җепләрем дә юк иде.

Мин ситсы белән җеп табу җаен эзләп йөргән арада, яз җитте. Ул елны кар сулары акканын тәрәзәдән генә карап яттым, чөнки бик озак вакыт бизгәк белән авырдым. Тау өстенә малларны миннән башка гына менгерделәр, балалар, миннән башка гына, узган елгы коры-сарыны җыеп, бәрәңге пешереп ашадылар.

Ниһаять, башымны күтәреп, тәрәзәдән урамга карагач, беренче күргәнем түбән оч малайлары булды. Аларның күгәрчен тәпиедәй кызарган аяклары ирексездән күзгә ташлана иде. Урамда җыелган суларның киткәненә сөенеп, күтәрмәле чабаталарын салып та ташлаганнар, югары очка – мәктәпкә җиңелчәдән, ялантәпидән генә элдертәләр. Ә язгы иртә салкын, нык кына кырау төшкән булып, тау артыннан күтәрелеп килгән кызгылт кояш нурлары ул кырауны эретсә дә киптерергә өлгермәгән әле.

Малайлар сер бирмиләр, аяклары туңганны сиздермиләр, чүпрәк букчаларын болгап, сөйләшә-сөйләшә узып баралар. Мәктәпкә бара алмавына уфтанып, тәрәзәдән карап утыручы чирле кызга күз салган кеше юк. Бер кырыйданрак Рафис бара, ул да яланаяк, ул да безнең тарафка карамый. «Кулъяулык бүләк итмәгәнгә үпкәләгәндер инде, шуңа карамыйдыр», – дип уйлыйм мин, үзәкләрем өзелеп. Белми бит ул ситсы белән чигү җепләрем юклыгын! Югыйсә бер генә дә иренмәс идем, менә әле авырып яткан арада да, аркамны ястыкка терәп булса да, чигәр идем.

Мин көн буе хыялларга чумып ятам: тизрәк үссәм, кеше булсам, акча эшли башласам, күп итеп ап-ак батист белән чигү җебе алыр идем. Ал, кызыл, зәңгәр, яшел, шәмәхә җепләр белән бәләкәй сандыкны шыплап тутырып куяр идем. Аннары рәхәтләнеп, кич утырып, армый-талмый кулъяулыклар чигәр идем!

...Мин үстем, һөнәрле булдым, айга ике тапкыр уч тутырып акча алам. Ләкин инде беркайчан да чигү җебенә кызыкмадым, чөнки бер генә егеткә дә чиккән кулъяулык бүләк итәргә туры килмәде...

Их, шунда, кирәк чакта, дәфтәр бите чаклы батист кисәге белән берничә саплам җеп булсачы! «Үпкәләгән, гафу итмәс, бүтән мине бар дип тә белмәс», – дип уйладым мин.

Кичкә таба ишектән Рафис килеп кергәч, минем гаҗәпләнүемне, сөенүемне сөйләп-аңлатып бетерерлек булмады. Рафис, гомер буе бусагабызны атламаган Рафис, минем уйларымнан чыкмаган Рафис, көпә-көндез килде дә керде бит.

Дөрес, ул берүзе түгел, күршебездә яшәүче ерак кардәше Наил абый белән иде.

Әнкәй белән миңа кычкырып сәлам биргәч, Наил абый:

– Зәйтүнә, синең әдәбият дәреслегең бармы? – дип сорады.

– Бар.

Тавышым бик хәлсез чыкты. Мин нәкъ ишеккә каршы, түрдәге сәкедә әнкәемнең эре шакмаклы палас-шәлен ябынып ята идем. Рафис кергәндә түшәк өстендә аунап ятуыма бик гарьләндем.

Наил абый күрше авыл мәктәбендә тугызынчыда укый иде. Ул кече яктан сәерсенеп карап торган әнкәйгә алтынчы класс дәреслегенең үзенә ник кирәк булганлыгын озак итеп аңлатырга кереште. Мин, урынымнан кузгалып, түшәм астындагы киштәгә үрелдем. Хәтеремдә: ябыклыгымнан, хәлсезлегемнән, аякларымның аклыгыннан кыенсындым. Сәкедән төшеп, күзләрем белән идән ярыгына текәлгән хәлдә, китапны Наил абыйга суздым. Ләкин кире менеп китәргә өлгермәдем, Наил абый дәреслекне актаргалады да:

– Ә-ә, безгә кирәк тема юк икән монда, – дип кире бирде.

Мин сәкегә басып, киштәгә үрелгән идем, китап арасыннан бер кәгазь очы килеп чыкмасынмы! Аптырап, Наил абыйга карыйм, ә ул миңа ым кага: яшер, янәсе. Кәгазьне бит араларына эчкәрәк төртеп, китапны киштәгә куйдым. Аллага шөкер, казан астына иелгән әнкәй аны-моны сизмәде. Ул суга киткәч тә, китапны кире алдым. Аннан хат килеп чыкты. Хатның беренче юлы – «Зәйтүнә!» – ялтырап торган нечкә бакыр чыбыктан үрелеп, кәгазьгә беркетелгән иде.

Дөньяда минекеннән матур исем юклыгына шунда ышандым. Ул алтын белән язылгандай балкып тора иде: «*Зәйтүнә!*» Рафис аны шундый оста, шундый тигез итеп үргән иде! Аннары ул минем белән очрашып сөйләшәсе килүе турында язган: «*Кич белән турыгыздан җырлап үтәрмен, чык әле*», – дигән иде.

Бәхеткә каршы, эткәй өйдә юк иде, бик иртә торырга күнеккән әнкәй яту белән йокыга китте. Ә мин, йөрәгем тибүе аша җыр тавышын ерактан ук ишетергә теләп, тын да алмый ятам.

Менә түбән очтан Рафисның җырлап килгәне ишетелде:

Идел өсләрендә йөзгән
Аккошларга тиң бит ул...

Аның җырын ишетеп, авыл халкы күңелен моң-зар басканга шулай җырлый инде бу бала дип уйлагандыр, бәлки. Рафисның җыр белән миңа мәхәббәтен аңлатканын, аккошларга тиң итеп мине атаганын без икәү генә белә идек шул.

Мин җәһәт кенә торып ишек янына бардым. Шыпырт кына чыгып китәргә кирәк иде. Әмма, кул белән кагылуга, ишек ыңгырашып куйды, бу тавыш тынлыкны ярып, йөрәгемне көйдереп узды. «Баш бетте!» – дидем мин. Бераз торгач, әнкәй урыныннан кузгалмагач, ишекне ныграк эттем – ул тагын да яманрак шыгырдады. Тагын шым булдым. Бераздан, батырлыгымны җыеп, каһәр суккан ишеккә ныклап ук төрткән идем – әнкәйнең куркынган тавышы ишетелде:

– Кем бар анда?

Мин телсез-өнсез калдым. Үземне зур җинаять өстендә тотылгандай хис иттем.

– Кем ул? Зәйтүнә, синме әллә?

– Мин...

– Нишлисең анда?

Мин, еламсырап:

– Су эчәсем килгән ие, – дидем.

– Ә-ә... – диде әнкәй, тынычланып.

Ишекне каерып ачтым да өйалдына чыктым. Аның шыгырдавына шулхәтле күнегелгән, мин аны ул көнгәчә сизмәгәнмен дә икән.

Кинәт тамагым кипкәнен тоеп, чүмеч белән салкын чишмә суы алып эчтем. Рафис кире югары очтан түбән очка таба җырлап узды:

Караңгы төн, томанлы көн,
Без аерылган төн бит ул...

Йөрәгемдәге ялкынны бер чүмеч су гына түгел, киң Идел дә сүндерә алмас иде шикелле.

Рафис тавышы торган саен ерагайды, мин кире өйгә кердем. Гомеремдә беренче тапкыр егет белән күзгә-күз очрашырга тырышуым шулай тәмамланды.

Озакламый мин терелеп җиттем, эткәйнең солдат шинеленнән бозып тегелгән бишмәтемне киеп, тауга сыер сакларга мендем.

Кич иде, тауда әле бала-чага берән-сәрән генә. Өйдә озак утырганга, саф тау һавасыннан, җир исеннән минем башым әйләнеп тора иде.

Шунда миңа партадашым Нур бәйләнде бит. Әле төртә, әле бишмәт җиңемнән тарта, мыскыллы сүзләр әйтә, көлә. Башка чакта минем моңа әллә ни исем китмәс иде, читкәрәк тайпылып, дәшмирәк торсам, үзе үк мине онытыр иде әле. Ләкин Рафис та шунда булганга, мин бик гарьләндем. Хәер, Нур үзе дә мине Рафис алдында юри кимсетә, чөнки безнең мәхәббәтебез малай-шалай өчен сер түгел иде инде. Нурны этеп җибәрүгә, аның сүзләренә тагын да ачырак итеп җавап бирергә батырлыгым да, көчем дә җитмәде.

Шулчак Рафис, егетләрчә нык басып, безнең янга килде дә, кара күзләрен утлы күмердәй яндырып, үзеннән шактый калку Нурның якасына ябышты, бөтен тауны яңгыратып ачулы тавыш белән:

– Син ник аны обижаться итәсең? – диде.

Әйе, «обижать» түгел, «обижаться» диде. Чит авыл малае булганга, ул безгә ят, сәер сүзләр ычкындыргалый иде. Бала-чага аның бу сүзеннән туйганчы көлде. Ләкин Нур көлмәде, ярсыган малай белән сугышу хәлсез кызны кыерсытуга караганда көчне күбрәк сорый иде шул.

Ул көнне тауга Нурның дуслары менеп җитмәгән иде әле. Соңрак, әлбәттә, Рафистан үчен алгандыр. Әмма шуннан соң ул миңа тора салып бәйләнүдән туктады. Шулай итеп, минем дә яклаучым булды. Абыем кебек якын итүче, кирәк икән, минем өчен утка керүче кешем булды.

Ул чакта дүртенчедән башлап укучылар һәр язны сынау бирәләр иде. Озак авырып яткангa күрә, мине сынауларга кертмәделәр. Алай да мин борчылып-дулкынланып йөрдем – Рафис чыгарылыш сынаулары бирә иде бит. Классташларыма тау битеннән чәчәкләр, исле гөлләр җыештым, Минзәләнең саеккан суында малайларның вак балык тотканын карап тордым. Балыкларны сулы банкага җибәрәләр иде дә, өстенә чәчәк утыртып, укытучы өстәленә куялар иде. Укытучылар балыкларга карап утыра, ә укучылар мыштым гына китап актара, имеш.

Шундый кызыклар һәм борчулар белән сынаулар бик тиз үтеп китте. Рафисның читкә, әнисе янына китәр чагы җитеп килә иде.

Мин әнкәйгә йон оек бәйләргә ниятем барлыгын әйттем. Үзебезнең сарыкның язгы йонын яздым, бик нечкә итеп җеп эрләдем. Аннары күрше авылдагы кардәшләребезгә кунакка барып, ике көн эчендә бер кием перчатка бәйләдем. Бөтен осталыгымны җигеп, баш бармак төбенә сырлар куеп бәйләдем мин аларны. Кунакта чакта юып киптерергә генә вакыт җитмәде.

Өйгә кайткач, мин күрше кызы Ләләгә серемне чишәргә мәҗбүр булдым, ул перчаткаларны юарга ризалык бирде.

Бер кисәк сабынның яртысын тегәрҗеп белән кисеп алдым да перчаткаларны күтәреп чыгып бара идем, каршыма әнкәй килеп чыкты. Мин сабын белән перчаткаларны артыма яшердем.

– Нәрсә ул, ни яшерәсең? – дип сорады әнкәй, гаҗәпләнеп.

Мин, кызарынып:

– Юк... Бернәрсә дә юк... – дигән булдым.

Ярый әле әнкәй артык төпченмәде. Мөгаен, ул сабынның юкка чыкканын күргәндер, ләкин аны-моны әйтмәде.

Ләләнең әнисе Хөснихатимә түти дә кызының, бер самовар су кайнатып, сабын күбеге күпертеп, перчатка юганын күргән. Ләләгә ни, ул әнисенә, Зәйтүнә перчаткасы бу, дип әйткән дә биргән.

– Нигә үзе юмый соң ул? – дип сораган Хөснихатимә түти.

Ләлә бу сорауга рәтле җавап бирә алмаган.

Ул перчаткаларны, кадерләп кенә, чормага элеп киптергән. Перчаткалар кершәндәй ак, каз мамыгыдай йомшак һәм җылы иде.

Мин аларны кәгазьгә төрдем дә бишмәтемнең куен кесәсенә тыктым. Кич җылы, күлмәкчән дә туңмас идем, ләкин бишмәт кимәсәм, перчаткаларны яшерер урыным булмас иде.

Без Рафис белән очрашу турында алдан килешеп куя алмадык. Ләкин бу – аның авылда соңгы киче, иртәгәсен ул китәчәк иде. Кичке уенда да без бер-беребезгә якын килә алмадык, аннан соң мин кызлар белән – югары очка, ул малайлар белән түбән очка кайтып китте.

Мин иптәшләрем белән хушлашып калдым, тик өйгә кермәдем, җилкапка араталарына сөялеп, аны көттем. Караңгыда, тынлыкта берүзем озак көттем. Ул, әлбәттә, килде...

Без бик аз сөйләштек. Хат язышырга да вәгъдә бирешмәдек, хәтта ул бәхеттән дә без мәхрүм идек, чөнки авыл почтальоны хатларны эткәйгә йә әнкәйгә бирәчәк иде.

Без өй буендагы эскәмиядә янәшә утырып тордык. Мин перчаткаларны бүләк итәргә җай таба алмадым. Яланаягым белән каты җиргә караңгыда күренмәс сызыклар сызам, кымшанган саен кесәмдәге кәгазь кыштырдый. Моны ишетеп, Рафис:

– Ни кыштырдый ул кесәңдә? – дип сорады.

Җәй уртасында кешегә йон перчатка бүләк итү ничектер бик уңайсыз, көлке эш булып тоелды. Мин, беткән баш беткән дип, суга чумгандай тәвәккәлләп, тирән итеп сулыш алдым да бүләгемне кесәдән чыгардым:

– Бу... сиңа...

Рафис өенә кайтуга, кичтән тутырып куелган чемоданын ачкан, әбисеннән куркып, перчаткаларны оекбаш эченә үк яшергән.

Ләкин йокыга сак карчык оныгының чемодан актарганын сизеп яткан, таң ату белән торып, Рафис сабыйларча изрәп йоклаган арада, аның әйберләрен тентегән, перчаткаларны күреп, бик сөенгән. Кызганычка каршы, үзе сөенеп кенә калмаган:

– Менә минем улыма кызлар перчатка бүләк иткән! – дип, күршесенә йөгереп кергән.

Ә аларда Ләләнең әнисе Хөснихатимә түти утыра икән...

Шулай итеп, минем Рафиска перчатка бүләк итүем бөтен авылга фаш булды.

Рафисның машинага утырып, тимер юл станциясенә китүен күрү, аны озатып калу бәхетләре миңа тимәде. Җәрәхәтле йөрәгемә тоз салып, авыл малайлары артымнан:

– Пирчәткә... пирчәткә... пирчәткәнең бер бармагы поездга кысылып өзелгән бит, – дип кала торган булдылар. Ачыктан-ачык мыскылладылар, чөнки яклаучым киткән иде шул инде.

Малайлар көлгәч, мин үзем дә зур мәгънәсезлек эшләгәнемне аңладым. Торып-торып, кара инде, җәйге челләдә кешегә йон перчатка ник кирәк, шунда бер кулъяулык чигеп бирә алмадым дип, үземне тирги идем. Бәхетем булып, күрешсәк, Рафиска кулъяулык бирми калмам дип уйлый идем.

Ул чакта безнең авыл аша машиналар сирәк үтә иде. Гүләгән тавыш ишетелгән саен, миндә, бу машинага утырып Рафис кайтмадымы икән дигән тиле өмет кабына иде. Ул кайтмады. Бер елдан мин үзем дә авылыбыздан чыгып киттем. Мин кояш баешына юл тоттым, ә Рафис кояш чыгышына киткән иде. Шулай итеп, безгә очрашулар насыйп булмады.

Бик күп еллардан соң гына мин шуны белдем: Рафис поездга билет ала алмаган икән. Ул төннәрен вагон ишегенең тоткасына ябышып барган. Җәй булса да төннәр салкынча, вагоннар, һаваны ерып, җилләп бара, тимер тоткалар боздай суына. Әмма Рафисның куллары туңмаган, чөнки мин бүләк иткән, каз мамыгыдай йомшак һәм җылы перчаткаларны кигән булган ул...

Минем күңелемдә күп кышларның карлары ята. Ул тыныч, үзгәрешсез, хәрәкәтсез кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Ул карлар астыннан, сиздерми, күренми генә гомерем язының ташкын сулары ага...

Мин чиләгемә кар суы тутырам. Саф чиста су өстендә эреп бетмәгән шикәр кебек кар йөзә. Атлаган саен, чүмеч чиләккә бәрелеп чыңлап куя.

Чиләгемдә кар суын, күңелемдә Рафис җырын, беренче мәхәббәтемнең онытылмас истәлеген алып кайтам.

*1971*

## Ай сүрелгән чак иде

Нигә ул һаман искә төшә икән?

Баштарак Дания моның сәбәбе хакында уйламый иде. Гомернең берәр тыныч чагында, үткәннәр һәм киләчәк турында ашыкмый гына уйланганда – безнең ашыгып-кабаланып яшәгән тормышыбызда да була бит андый минутлар! – бигрәк тә җыр тыңлаганда яки шигырь укыганда, җиңел сагышлы рәхәт чакта, кинәт күз алдына килә дә баса ул. Аның ямансу йөзе, торышы, башын алгарак сузып сөйләшүе, күз кабакларының тетрәнүе шулкадәр аермачык күзаллана, Дания аны әле кичә генә, юк, хәтта берничә сәгать элек кенә күргән сыман була. Аның күзләре җавап таләп иткәндәй карыйлар, һәм ул карашны күтәрү елдан-ел авырлаша бара. Күңелдә үкенү, кызгану кузгала, шул ук вакытта Даниягә аның язмышы белән үз язмышы арасында ниндидер уртаклык бардыр һәм ул уртаклык еллар үткән саен зурая барадыр кебек тоела.

Ләкин ни гаебе булсын Даниянең аның каршында? Нинди охшашлык булсын аларның язмышында? Аннары күпме гомер үтте, күпме яңа очрашулар булды, вакыт ераклыгында һәм яңа танышлыклар күләгәсендә әллә кайчан онытылырга тиеш иде бит инде ул.

Юк, онытылмый, торган саен үзәкне өзебрәк искә төшә. Кайчак Дания аның турында шулхәтле якын итеп уйлый, әгәр мөмкин булса, ерак дип тормас иде, янына барып кайтыр яки, һич булмаса, күңелендәген әйтеп хат язар иде.

Әмма хатлар бармый, юллар илтми торган җирдә шул инде ул...

Хезмәте буенча Даниягә күп йөрергә, күп кешеләр белән очрашырга туры килә – ул фәнни институтта эшли, халыкның тел хәзинәләрен җыю белән шөгыльләнә.

Шундый ук йомыш белән ул бер кышны бездән шактый еракта урнашкан бер шәһәргә барып чыккан иде. Хәер, нигә яшереп маташырга – Җаек шәһәре иде ул, кайчандыр Габдулла Тукай

укыган, беренче шигырьләрен язган кала. Үз вазифаларына турыдан-туры кагылмаса да, Дания шагыйрь истәлегенә бәйле урыннарда булмый китә алмады. Кар баскан тын урамда кечкенә Габдулла яшәгән Госмановлар йортын эзләп тапты – асты таш, өсте агач ике катлы йортның стенасына Тукайның сурәте ясалган таш такта эленгән иде. Шәһәрнең типографиясенә дә Тукай исемен биргәннәр икән, аның директоры – өлкән яшьтәге ачык чырайлы рус апа – зур горурлык белән Даниягә гасыр башыннан калган басу станогын күрсәтте. Хәзергә кадәр эшләп ята, Тукай чордашларының оныклары язган сүзләрне баса. Кайда алар, аның тимер күкрәгенә беренче булып үзләренең кургашыннан коелган сүзләрен китереп салган кешеләр?.. Ай-һай ла кыска икән кеше гомере, бер машина ничә буынны күрә! Күрә, тик сөйли алмый, теле юк.

Дания Тукайның беренче укытучысы Мотыйгулла хәзрәтнең йортына да барды. Ике катлы кызыл кирпеч бина икән. Тар агач баскычтан икенче катка менде, караңгы коридордагы ишекләрнең кайсына орынырга белми аптырабрак калды: күрәсең, биредә берничә гаилә яшәп ята иде. Ул түрдәге ишекне шакыды, аңа каршы чыккан урта яшьләрдәге ир кеше татар икән. Әмма гасыр башында бу йортка бөек шагыйрьнең килеп йөргәнен, аның шушы йорт хуҗасыннан сабак алганын ул беренче булып Даниядән ишетте...

Шагыйрьнең үзен күргән-белгән кешеләрне очратасы килә иде Даниянең. Бу бик мөмкин иде шикелле, чөнки җитмеш-сиксәнгә җиткән кешеләр әзмени?

Эзли-сораша торгач, ниһаять, бер оешмада, билгеле инде, русчалап:

– Адам Соломонович белән сөйләшегез, – диделәр. – Шигырьне бик ярата бит ул, Тукай дигән шагыйрьне теленнән төшерми. Белә ул, белә! О, аның белмәгән нәрсәсе юк!

Бу сүзләрдә Адам Соломоновичны олылау һәм ихтирам итү белән бергә аның сәерлегенә ишарә ясап көлемсерәү дә бар иде. Шул икеле-микеле көлемсерәү Даниянең кызыксынуын тагын да арттырып җибәрде. Адам Соломонович? Кем ул? Ни өчен ул Тукай белән мавыга? Юкка гына булмаска тиеш бу.

Дания турыдан-туры аның милләтен сорарга яхшысынмады. Читләтеп кенә шуны ачыклады: Адам Соломонович гомере буе шушы оешмада эшләгән икән, әле менә яше сиксәнгә җитеп килсә дә, бер генә дә җибәрәселәре килмәгән, тик үзе бик сорагач кына, күптән түгел зур хөрмәт белән пенсиягә – йомшартып әйткәндә, лаеклы ялга озатканнар.

Аның адресы язылган кәгазь Данияне каланың элеккедән калган тын урамына китерде.

Ашкынып-ярсып чапкан заман тормышыннан читтәрәк калган сыман иде бу урам. Ике якта, нык ихаталар эчендә йомылып утырган төзек йортлар да, аларның торбаларыннан аксыл күккә күтәрелгән күгелҗем төтен баганалары да, киң урта юлның ике ягына икешәр рәт булып тезелеп утырган, шәрәләнеп калган агачлар да, ап-ак карга төшкән карасу күләгәләр дә гасырлар буе үзгәрмәгән кебек тоела иде. Мөгаен, яшь шагыйрь ярсып атлап узганда да, бу урамнар шундый булгандыр, ул аяк баскан саен кар шыгырдап, уңган киленнәр юган тәрәзә пыялалары төсле чиста, үтә күренмәле салкын һава зыңгылдап куйгандыр. Шундый йортларга карап, бәлки, шагыйрь: «Ник йоклыйсың, мужик?» – дип язгандыр да әле! Керсез карны алсуландырып, әкрен генә түбәнәеп барган кояш та нәкъ шушындый булгандыр, бер ягы кителеп, югарып калган сары йөзле карт ай да, инде миңа барыбер дигәндәй, вакытын-ниен санап тормыйча, кояш баеганны көтмичә, күккә менеп киткәндер...

Адам Соломоновичның кирпеч йорты урам чатында икән. Дания рус капканың боҗрасын каккалап торды, тавыш-тын булмагач, үрелеп тәрәзәгә чиертте, анда да кеше-кара күренмәгәч, аптырап, йортның икенче ягына чыкты.

– Нишләп йөрисез анда? Кем кирәк сезгә? – дигән тавышка сискәнеп борылды.

Урамнан аңа таба озын буйлы, төз сынлы берәү килә иде. Бүреген басып кигән, ике кулын кыска кара тунының кесәләренә ныклап батырган.

– Мин Адам Соломоновичны эзли идем, – диде Дания, үзе дә сизмәстән каушап.

– Мин ул.

– Сезме?

Абзый беренче карашка Даниягә ир уртасы чамасы гына булып күренгән иде. Дания, аның сиксәнгә җиткән бабай булуына бик ышанып җитмәсә дә, үзенең йомышын әйтте.

– Әйдәгез, – диде абзый, укучысына дәшкән укытучы шикелле итеп.

Дания, аңа ияреп, җыйнак кына ишегалды аша үтте, караңгы өйалдына барып керде. Абзый өй ишеген ачып җибәрде дә туктап калган Даниягә, саф татарча иттереп:

– Рәхим итегез! – диде.

– Ә мин аптыраган идем: нишләп Адам, ни өчен Соломонович!

– Әдһәм атлы мин. Әдһәм абыегыз булам.

– Сөләймановичмы?

– Әйе, Сөләйман углы. Салыгыз өстегезне. Кая, пальтогызны элеп куйыйм.

Даниянең күңеле күтәрелеп китте: болай булгач, аның юлы уңуда шик юк иде. Ул борылып өй эчен күздән кичерде.

Әле генә урамда, кичкә авышкан булса да, якты көн иде, әле генә бөтен дөнья саф иде, пакь иде. Караңгы өйалдында Дания гүяки көн белән кичне, яктылык белән караңгылыкны тоташтырган җөй аша атлап узды: монда эңгер-меңгер, күңелсезлек, караусызлык хөкем сөрә иде. Мич күптән агартылмаган; стенага ябыштырылган кәгазь урыны-урыны белән кубып, тастымал-тастымал булып салынып төшкән, идән каралган почмакларга пәрәвез сарган, һәр җирдән ятимлек, өметсезлек, сары сагыш саркып тора иде.

Дания аптырап артына борылды һәм... Әдһәм абыйны танымады. Мәһабәт кыяфәтле ир уртасы кеше урынына аның каршында каз мамыгыдай ак юка чәчле, арык сынлы бабай кызарынган күз кабаклары арасыннан тонык зәңгәр күзләре белән мөлдерәп карап тора иде. Әйтерсең лә ул бөтен мәһабәтлеген, ныклыгын, кырыслыгын бүреге һәм кыска туны белән бергә салып, ишек янындагы агач чөйгә элеп куйган!

– Рәхим итегез, утырыгыз, – диде ул, өстәл янындагы артсыз урындыкка ишарәләп. Үзе Дания каршына утырды, сөякчел, авыр кулларын өстәлне каплаган иске клеенка өстенә кушырып салды да, ак башын иеп: – Минем Тукайны күргәнем булмады, – диде. Әкрен, ләкин шикләнергә урын калдырмаслык нык итеп әйтте: – Без бер калада егет булып җитешкәнбез, әмма төрле мәдрәсәләрдә укыганбыз. Булмаганны булды дия алмыйм, күрмәгәнне күрдем дия алмыйм.

Дания кузгалырга омтылыш ясады. Аның бу кешедә башка йомышы юк иде. Әдһәм абый, башын күтәреп, аңа таба сузыла төшеп, ялварулы тавыш белән:

– Ләкин мин аны бик яратам, мин аның шигырьләреннән башка яши алмыйм, – диде.

Бик яхшы, ләкин Дания өчен Тукайны яраткан кешене эзләп Җаекка кадәр килүнең һич кирәге юк иде. Ул үзе дә Тукайны ярата, әнисе дә. Гомумән, аны яратмаган кеше бармыни?

Дания торып басты. Әдһәм абый да урыныннан кузгалды һәм урамдагыча нык тавыш белән:

– Туктагыз, ашыкмагыз әле, – диде. – Хәзер чәй куям. Казан хәтле Казаннан килгән кешене чәй эчерми җибәрәмме соң!

Даниянең һәр минуты саналган-исәпләнгән, аның монда озаклап утырырга нияте юк иде. Шәһәрдә бик матур театр бар, бүген кич шунда барырга тиеш иде ул. Ләкин Әдһәм абыйның тавышында шундый ихласлык ярылып ята, шуның өстенә аның нидер әйтергә теләгәнлеге, бик мөһим сүзе барлыгы сизелеп тора иде. Шунлыктан Дания артыгын карыша алмады.

Әдһәм абый такта белән генә бүленеп куелган ишексез кече якка кереп керосинка кабызды, чәйнек куйды. Артсыз урындыкка басып, сузылып, биек кием шкафы өстеннән өч литрлы банка белән варенье алды:

– Үзем кайнаткан идем, үзебезнең бакчаның кура җиләгеннән, – диде. Кече яктан кәгазьгә төрелгән бәлеш сыныклары алып чыкты: – Монысын өченчекөн генә бер туганымның хатыны пешереп китергән иде. Бәхетле авыз икәнсез, мул чакка туры килдегез.

Бәлеш сыныклары катып киткән, варенье ачыган иде. Әдһәм абый үзе моны сизми иде булса кирәк. Дания дә сер бирмәскә тырышты.

Хәер, абый чәйне үзенә болай гына ясап куйган иде. Ул өстәл янына утыруга, кулына китап алды. Әкрен тавыш белән укый башлады:

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урнында анда тулган айның яктысы...

Булмадың алтын ярым – салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы...

Бу урынга җиткәч, Әдһәм абый туктады, башын сузыбрак, мине гаепләмисеңме мондый шигырь укыганга дигән сыман, Даниягә сынап һәм кыенсынып карады.

– Әдһәм абый, гафу итегез... Сез күптәнме шушылай... ялгыз яшисез?

Бу соравы белән Дания үзе дә сизмәстән картның күңел бикләрен берьюлы ачты да җибәрде. Әйе, Тукайның бу юлларыннан соң ул нәкъ менә шушы сорауны бирергә тиеш булган икән. Егерме җиде яшендә дөнья куйган шагыйрь даһи каләмен үзеннән соң бик күп еллар яшәп картаячак кешенең хисләренә, хәсрәт-сагышларына манып язган булган икән бу шигырен...

Ике авыз сүз белән хәлен аңлатып бирде Әдһәм абый: моннан ике ел элек аның хәләл җефете дөнья куйган. Ә бердәнбер кызы каядыр Себердә ире һәм ике баласы белән яшәп ята. Карт кулындагы китапны сыйпап куйды, әйтерсең лә калганын менә шушыннан белергә була дию булды.

Дания һәр почмагына ятимлек һәм өметсезлек кереп оялаган өй эчен тагын бер кат күздән кичерде, караңгыланган саен әйтерсең лә бирегә гүр салкыны иңә бара иде.

– Өйләнергә кирәк сезгә, Әдһәм абый. Үлгән артыннан гүргә кереп булмый. Исән кеше яшәү турында уйлый. Бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Әдһәм абыйның кызарган күз кабаклары ачыла алган кадәр ачылды, күзләре, Даниянең җанын актарырга теләгәндәй, аңа текәлделәр. Дания аның эчендә ни кайнаганын аңлап бетерә алмады, әмма ниндидер зур газап бар иде картның күңелендә, зур шик бар иде.

– Әллә соң үзегезгә ошаганын таба алмыйсызмы? Хәзер тол апалар күп бит югыйсә. Теләгәнне сайлап ала аласыз.

Әдһәм абый тамагына утырган төерне йотып җибәргәндәй итте дә, башын иеп, әкрен генә:

– Анысы мин артык сайланмас идем, – диде. – Мин бит күпне таләп итмим. Бөтенесен үзем эшләр идем, өен караумы, чәен куюмы. Әле менә ихатада йөзем куаклары бар, аларны да үзем карар идем. Каршыма утырып чәй эчсә, шигырь укыганымны тыңласа, сөйләшеп утырса, шул җитә миңа. Янымда бер тере кеше сулап кына торса да җанга ял булыр сыман.

– Соң, өйләнегез алайса!

– Сез менә шулай дисез дә бит... Минем кыз башкача уйлый шул. Инде шул яшькә җиткәч, өйләнеп йөрсә оят булыр дип, кеше аркылы сүз ишеттерде. Яхшы түгелдер, шулайдыр...

– Олыгайган кешегә тормыш иптәше бигрәк тә кирәк, Әдһәм абый! Авырсагыз кем карар да күңелегез төшенке чакларда кем юатыр! Ә бәлки, кызыгыздан сорап та тормаскадыр? Өйләнергә дә куярга. Соңыннан бер сүз дә әйтмәс әле, мөгаен.

– Алай булмый ул. Булмый... Ул минем балам бит. Әгәр аның күңеле кабул итми икән, ояты ни тора!

Әдһәм абыйның күзләре шундый сагыш һәм сафлык белән өздереп карады, Дания тетрәнеп китте.

– Ни ояты булсын аның, Әдһәм абый! Сездән генә калмаган лабаса!

– Сез менә минем кызым белән бер яшь тирәсе. Әйтегез әле, минем кызым урынында булсагыз, ни әйтер идегез?

Аны юатыр өчен, «нәкъ менә хәзергечә әйтер идем!» димәкче булып авызын ачкан иде инде Дания. Ләкин Әдһәм абыйның саф күзләренә карап алай дисә, алдаячагын аңлап башын иде.

Даниянең әтисе моннан берничә ел элек үлде, әнисе тол калды. Кече улы белән бергә яши, балалар үстерешә. Әгәр көннәрдән бер көнне ул кияүгә чыгам дисә? Даниягә бу бик көлке, сәер һәм хәтта мәгънәсез тоелмас идемени? Ул үзенең әнисен кем белән булса да янәшә күз алдына да китерә алмый. Әтисе урынына җиде ят агайны утыртыргамы? Юк, бу һич мөмкин эш түгел, аның әнисе Даниянең әтисенә, аның истәлегенә берничек тә хыянәт итә алмас иде. Хыянәт? Ә соң Әдһәм абыйның кызы өчен дә башка бер ят карчыкның бу өйгә, ул туган-үскән йортка хуҗа булып кереп утыруы гайре табигый эш булып, әтисенең хыянәте булып тоелмас идемени?

Ләкин аңлыймы соң ул ялгыз картның хәлен?

Ничек итеп, ни рәвешле аңлата алсын бу инсафлы карт үз хәлен гомеренең яртысына җитеп кенә килгән баласына?

Без яшь чакта хисләрнең тирәнлеген дә, кайгыларның ачылыгын да үз чамабыз белән үлчибез. Ләкин олыгайгач чамалар башка, бөтенләй икенче була, күрәсең. Яшьлекнең иң авыр кайгыларын да картлык сагышлары белән чагыштырып булмый. Яшьлек бәхет, тигезлек, мәхәббәт таләп итәргә үзен хаклы саный, әмма картлыкны бу хокуклардан мәхрүм итә. Яшьлек үз хокукларын аяк терәп яклый, ә картлык тыйнак, саф, оялчан була икән. Ничек җәлеп итсен ул үзенә игътибарны? Яшьлекнең үз хәленә игътибарны җәлеп итү өчен бик зур чарасы – киләчәккә өметләре бар. Ул ачу итеп, ярсып, өметләрен аклый яки, көче җитмәсә, өметләрен үз кулы белән кисеп, язмыштан шулай үч ала. Ә картлыкның куллары буш, аның өметләре беткән, югалтыр әйберсе дә, үч алыр чарасы да юк.

– Әллә соң мин кызыгызга барын да аңлатып хат язып карыйммы? – диде Дания.

– Юк, ярамый алай. Сезгә сер сыяр, сездән чыкмас дип кенә сөйләшүем, шуңа гына иң эчке уйларымны ачуым. Әгәр кызыма ирешсә, күңеле тагын рәнҗер, ярамас.

Әдһәм абый, күзләреннән мөлдерәп тамган яшьләрен күрсәтмәс өчен, башын читкә борды. Әле һаман кулыннан төшермәгән зәңгәрсу тышлы китапны күрсәтеп:

– Укымыйлар бит Тукайны, укымыйлар, белмиләр, – диде. – Мин аңа китапны җибәргән идем, кайбер урыннарына каләм белән сызып та куйган идем. Айлар узды инде, һаман ул хакта бер сүз язмый...

Дания, аңларга тиеш иде ул... ә бәлки, аңлар әле, дип нәрсәдер әйтергә тырышса да, картны юатырлык бер сүз дә әйтә алмасын төшенеп, тынып калды.

Ул урамга чыкканда, җирне төн караңгылыгы баскан, китек ай күтәрелеп, бирешмим әле дигән сыман дөньяны яктыртырга тырыша, ләкин аның нурлары күңелне яктыртмый, киресенчә, сагышландыра гына иде.

Даниянең хәтеренә:

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урнында анда тулган айның яктысы, –

дигән юллар килде. Тулган ай түгел шул инде, сары йөзле китек ай, сүрелеп барган ай иде Әдһәм абыйның тормыш күгендә!

Себер ягындагы калада яшәүче хатын, Әдһәм абыйның кызы, күрә иде микән бу айны?

Ике баласы, ире бар, эшлидер дә әле үзе. Шәһәрдә кайчан гына күккә күтәрелеп карый да кайчан гына ай яктысын күрә икән ул? Әйтик, менә хәзерге минутларда нишли икән? Эштән соң кибетләрдә чират торып арып-талып кайткандыр. Бәлки әле, берәр баласын бакчадан-фәлән кереп алгандыр. Ашыгып ашарга пешергәндер, балаларын көйлидер, эшем күп дип зарланадыр. Ләкин ал син аннан шул мәшәкатьләрне, шул ваемнардан азат ит, аның өчен яшәүнең бер кызыгы да калмас, аның көннәре дә сары сагышларга уралыр. Ләкин менә әтисе турында бер утырып уйларга, ул җибәргән шигырь китабын алып укырга вакыты бар микән аның? Шигырь юлларыннан газиз әткәсе әйтергә теләгәнне төшенеп утырырга зирәклеге җитә микән? Ай-һай ла, юктыр, мөгаен, юктыр.

«Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә» дигән юлын укыса да, әтисенең хәлен белә алмастыр ул, Әдһәм абый юкка гына көтәдер...

...Шул очрашудан соң Дания Әдһәм абыйны башка күрмәде. Берәр айдан соң яшь бер галим, аны институт коридорында туктатып:

– Сиңа Әдһәм абыйдан сәлам, – диде.

– Сез аны беләсезмени?

– Безнең туганнар бар бит Җаекта, шулар белә икән.

– Өйләнмәде микән әле ул?

– Анысы белән бер дә кызыксынган юк иде. Хат аша сорашып язарга була.

– Миннән сәлам әйтегез, зинһар.

Дания башка әйтер сүз тапмыйча китеп барды, яшь галим аның артыннан карап калды.

Тагын бер-ике айдан соң теге яшь галим, коридорда очрап:

– Сез ишеттегезме, Әдһәм абый үлгән бит, – диде.

– Шулаймыни?! Белмисезме, өйләнгән булды микән?

– Юк дип язганнар иде туганнар.

– Ә нидән үлде икән? Нык күренә иде бит әле ул. Йөземнәр үстерә иде. Йөзем өлгергәнен күрә алмаган икән...

Яшь галим иңнәрен генә сикертеп куйды: ул Әдһәм абыйның нинди чирдән үлүен белми иде. Хәер, аның әйтүе нигә, Дания үзе дә бик яхшы белә иде бит: ялгызлыктан үлгәндер Әдһәм абый, мөгаен. Дания бар почмакларыннан сары сагыш саркыган ятим йортны күз алдына китерде. Үлгәндә иреннәрен чылатучы булды микән?

Дания тагын нидер сорамакчы иде. Ләкин яшь галим аны ялгыз калдырып китеп барган иде инде.

Бу хәлләрдән соң шактый еллар үтте. Вакыт узгач кына Дания шагыйрь Тукай турында, гомумән, шигърият турында беркем сөйли алмаслыкны Әдһәм абыйдан ишеткәнен аңлады. Тора торып Әдһәм абыйны ешрак искә төшерә башлагач, шигъриятнең зур бер сере ачылып киткәндәй булды аңа. Хәзер җыр тыңлаганда да, шигырь укыганда да аның күңеле кузгалып, зиһене сизгерләнеп китә. Ул җырда, ул шигырьдә Даниянең ярдәменә, ә бәлки, җылы сүзенә мохтаҗ берәр кешенең тел белән әйтеп биреп булмый торган күңел серләре яшеренгәндер кебек тоела.

Ләкин аңа берничек тә ярдәм итеп булмый бит инде. Гомер юлында бары бер генә тапкыр очрашып сөйләшкән башка бүтәннәр шикелле үк, ул да хәтер түрендә әкренләп томанга уралырга, онытыла барырга тиеш иде кебек. Нигә соң ул һаман, үзәкләрне өзеп, искә төшә икән?

*1978*

## Узма, гомер!

Без аның белән иртүк очрашабыз: йокымны туйдырып, иртәнге ашка хәтле коенып алырга дип ашыгып чыкканда, ул инде әллә кайлардан уратып кайтып килә. Куе, биек чинарлар, пирамидаль тупыллар белән әйләндереп алынган аллеяда ул күренгәч, күләгәле бакча минем өчен яктырып киткәндәй була. Бакчага ул Джанни Родари әкиятләреннән килеп кергәндер кебек тоела, чөнки кыяфәте белән сөйкемле кабакны хәтерләтә.

– Степан Петрович, тагын мине көтмәгәнсез, – дим мин, үпкәләгән булып.

– Иртәрәк кузгалдым шул, – ди ул, елмаеп. Аның тавышында акланырга тырышу да, мине гаепләү дә сизелми. – Урманнан ук әйләнеп кайтуым инде.

– Иртәгә мин дә сезнең белән барам. Барам дигәч барам! – дим мин инде ничәнче тапкыр.

Һәм диңгезнең текә ярында шаулап утырган урманны күз алдына китерәм. Нарат-чыршылы, каен-усаклы, җиләс һавалы, җиләкле урманны... Аның татлы һавасын күкрәк тутырып сулагандай булам.

Иртәнге ашка килүемә, кыргый йөзем куаклары белән уратып алынган ашханәнең ишеге төбендә мин тагын Степан Петровичны очратам. Бу юлы аның өстендә пөхтә күлмәк, үтүкләнгән чалбар. Ул сак кына терсәгемнән тотып ала да, ишекне ачып, җиңелчә баш иеп, мине алдан уздыра, өстәл янында урындыгымны рәтләп куя. Ә өстәлдәге кечкенә вазада мине ак ромашкалар, сарут чәчәкләр, зәңгәр кыңгыраулар көтә. Аларны һәр көн иртән Степан Петрович китереп куя, вазасын да официанткадан ул сорап алды. Башка хатыннар чәчәкләргә кызыгып карап узалар.

Без аның белән ялның беренче көнендә үк таныштык. Ашханәдә мине пенсия яшендәге өч абзый янына дүртенче кеше итеп утырттылар. Мин аларга үземне «Зәйтүнә ханым» дип таныштырдым. «Ханум, ханум...» – дип кат-кат кабатладылар алар. Тавышларында җиңелчә көлемсерәү, читләтү, баласыту ишетелгәндәй булып, каушап киттем.

Абзыйларның яшьрәге, ләкин әле алтмышны гына тутырса да, арада иң төссезе, көл төсле сирәк чәчле һәм күгәргән ябык чырайлы Федор Иванович минем белән янәшә бүлмәдә яши икән. Бер өстәл янында утыргач һәм бүлмәбез дә күрше булгач, ул мине беренче көннән үк якын итә башлады. Ашханә юлында мине көтеп тора, хәлемне сораша, кыюрак булырга өнди, бүлмәсенә кофе эчәргә чакыра.

Мин исә, билгеле инде, үз ишләремне эзлим, утыз белән кырык арасындагы хатын-кызларга сүз кушам. Эчпошыргыч, ямансу беренче көннәр узгач, без, хатын-кызлар, дуслашып та киттек, бер-беребезгә зарланышып та алдык. Рәхәтләнеп танцевать та итмәгәч, нинди көньяк та, нинди ял инде ул, диештек. Тирә-юньдә ял йортлары, санаторийлар җитәрлек, кичләрен шунда барырга кирәк дигән фикергә килдек. Озакка сузмыйча, киттек бер кичне «Китобой» дигән санаторийга.

Санаторийның зур бакчасын көндез үк карап чыккан идек. Кичен ул очсыз-кырыйсыз урман булып, серле булып күренде. Каяндыр агылган дәртле көй үзенә чакыра, күңелләрне ашкындыра иде. Безнең аяклар үзеннән-үзе көй яңгыраган тарафка ашыкты. Менә агачлар арасында асфальт җәелгән киң генә бию мәйданчыгы күренде. Бию көе шундагы баганага асылган репродуктордан агыла икән. Мәйданчык лампочкалар белән яктыртылган, тирәли эскәмияләр куелган. Кил, рәхәтләнеп бие. Чыннан да, уртада ике-өч пар рәхәтләнә. Ә калган халык, эскәмияләрдә боегышып, аларны күзәтә, кайсылары карамаска тырышып утыра. Ник дисәң, калганнары тоташ хатын-кызлар. Бу хәтле хатын-кыз «Китобой»га каян килгән дип хәйран калырсың. Әллә инде океаннарда кит тоту эшен дә алар үз кулларына алган микән?

Эскәмияләрдә ямансулап утырганнарның сагышын дәртле бию көе дә тарата алырлык түгел иде. Без диңгез ярына басып ай сузган юлга бераз карап тордык та кире кайтып киттек.

Мин, күршеләремне борчымас өчен, ишекне сак кына ачтым, аяк очларыма гына басып кердем. Монда стеналар фанердан гына корыштырылган, сулаганыңа хәтле ишетелеп тора.

Икенче көнне иртән ашарга килгәч, каршымда утырган Федор Иванович миңа өстәл аркылы сынап карады да:

– Кичә китобойлар белән бию рәхәт булдымы соң, ханум? – дип сорап куйды. «Ханум» сүзе аның авызыннан шулхәтле мыскыллы булып чыкты ки, мин үземә алай дип дәшәргә рөхсәт итүем өчен үкенеп куйдым.

– Бик күңелле булды, – дидем мөмкин кадәр көр тавыш белән.

Бу җавабымнан Федор Ивановичның сирәк чәчләре кабарып, йөзе тагын да күгәребрәк киткәндәй булды.

– Эзләгән табар, – диде ул, мәгънәле итеп. – Кайберәүләр монда диңгез эзләп кенә килми шул...

Бу сүзләрнең мәгънәсе миңа тиз генә барып җитмәде. Ә аңлагач, өстемә салкын дулкын ишелеп төшкәндәй булды – жаным-тәнем өшеп китте.

Мин үзем авыл кызы, ләкин яшьли өйдән чыгып китеп җиде ят арасында күп айкалырга туры килде. Шулай да бала чактан табигатемә сеңгән йомыкыйлык, сагаю канымнан һаман чыгып бетмәде: ятларның җәберләвенә чәчрәп чыгып, үзләреннән усал итеп җавап бирергә гомер өйрәнеп булмады. Аннары чит кешеләр белән аралашуның тагын бер кыенлыгы бар бит әле: син аларның нинди очракта нәрсә әйтерен, ничек җаныңны кыйнасын, рәнҗетерен алдан чамалый алмыйсың, шунлыктан, берәрсенең кырын карашын сизүгә, күңел шомлана, җан калтырый башлый. Бу куркаклык түгел, ә бәлки чарасызлыктан, үзеңә каршы килгән көчнең синнән күпкә кодрәтлерәк икәнлеген аңлаудан туган хис. Хәтеремдә, бер шәһәр егете, мине шундый хәлдә күреп:

– Коты алынган чыпчык баласы! – дип авыз ерып көлгән иде.

Менә хәзер дә мин үземне нәкъ шул чыпчык баласыдай хис иттем. Мамыгымны кабартырга, сер бирмәскә тырышам, әмма каурыйларым астында тәнемнең, җанымның бөрешкәнен тоям. Йа Алла, бу көл чырайлы картны шушындый ачы телледер дип кем уйлаган! Ул мине кимсетте, ләкин яклаучы юк, чөнки бу өч карт күптәнге танышлар, сөйләшүләреннән аңлашылган иде инде. Алар – өлкән яшьтәге ир кешеләр, ә мин – япа-ялгыз хатын-кыз. Яшьтәшләр булсак, бер хәл, ничек тә үземне якларга тырышыр идем, болай телдән калып утырмас идем. Әмма олыларга каршы әйтергә ярамый дигән кагыйдә ана сөте белән канга шулхәтле сеңгән, мин үзем олыгаеп килгәндә дә бу кагыйдәне бозарга, өлкәннәрнең чи нахак сүзенә дә каты итеп каршы әйтергә гомер буе батырчылык итә алмадым.

Тәмам сыгылып төшкән идем инде. Шулчак сул ягымда утырган абзый – Степан Петрович телгә килде:

– Аңламыйм мин сезне, дустым, – диде ул, Федор Иванович тарафына борылып.

Мин, гаҗәпләнеп, башымны күтәрдем. Бу рәвешле горур, шул ук вакытта илтифатлы сөйләшкәннәрен, дөресен генә әйткәндә, борынгы зыялылар турындагы кинофильмнарда гына ишеткән бар иде. Шундыйрак сүзләр һәм шушындый тавыш белән алар, гадәттә, үзләрен рәнҗеткән адәмнәрне дуэльгә чакырганнар.

– Моннан ике мең ел элек үк инде кешеләр җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен уйлап чыгарганнар, ул кагыйдәләр гасырлар буе яшәп килә. Ә сезнең өчен алар гүяки бөтенләй юк диярсең. Үзегез интеллигент кеше бит югыйсә! Зәйтүнә ханум сезне рәнҗетерлек берни эшләмәде, бер сүз әйтмәде, ә сез аны кимсетергә җөрьәт итәсез. Кичерегез, ләкин мин сезнең бу эшегезгә берничек тә түзеп тора алмыйм!

Ул үсмер малайга вәгазь укыгандай сөйли, ул сөйләгән саен, минем эчемдәге коты алынган чыпчык баласы кечерәя, әкренләп юкка чыга, аның урынына гүяки аллы-гөлле койрыклы, озын-нәфис муенлы, иркә һәм гүзәл тавис кошы башын күтәрә. Мин сынымны турайтыбрак утырдым.

Ни хикмәттер, Федор Иванович күршесенә каршы сүз әйтми, баш иеп тик утыра. Бәлки, күршесе аннан өлкәнрәк булгангадыр, – Степан Петрович җитмешне тутырып килә иде инде. Ә бәлки, Степан Петровичның тавышында яңгыраган катгыйлык һәм хакыйкать, ышаныч һәм сабыр горурлык аны үзенә буйсындыргандыр.

Шуннан соң Федор Иванович миңа, тыенкы гына баш иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә сәлам бирүдән узмый торган булды. Аның урынына Степан Петрович белән без бик дуслашып киттек. Дөресен әйткәндә, мин үзем аның белән очрашуны эзлим, чөнки ул янымда чакта ял йортының зур бакчасы, туган ихатам шикелле, күңелгә якын булып тоела, минем адымнарым ук ныгып китә иде. Чөнки беләм: ул барда мине берәү дә рәнҗетә алмаячак, миңа бернинди куркыныч та, көтелмәгән хәл дә янамый.

Көндезләрен без сирәк очрашабыз. Аңа коенырга ярамый, ул машинкада нидер басып утыра, ә мин озак-озак диңгездә коенам, кызынам. Безнең очрашу сәгате – көн сүрелгәч, кичке аштан соң, бала-чага, карт-коры телевизорны сырып алгач. Бәхеткә каршы, Степан Петрович та телевизордан футбол, хоккей карау белән мавыкмый икән.

– Мин үзем яшь чакта күп типтем ул тупны, – ди ул. – Көчен кая куярга белмәгән үсмер егетләр өчен менә дигән шөгыль инде, әйтәсе дә юк. Ләкин бездә арттырып җибәрәләр. Кемнең тупка кайсы аягы белән ничек китереп типкәнен, ул тупның нинди почмак ясап кайсы тарафка очканын сәгатьләр буе бөтен ил халкына сөйләп утыру нәрсәгә кирәк? Аның ни әһәмияте бар?

Без ике яктан биек агачлар белән ышыкланган аллея буйлап әкрен генә атлап китәбез. Аллея уртасындагы киң түтәлдә роза гөлләре кып-кызыл чәчәктә. Алардан һәм катальпа дип аталган киң яфраклы агачларның шәмәхә кыңгырау төсле чәчәкләреннән аңкыган хуш ис бераз гына башны әйләндерә. Аллеяның бер башы диңгез ярына барып тоташа, икенче башы урам капкасына хәтле барып җитә. Урамнан кайчак трамвай зыңгылдап уза. Халык аны «Көт мине, мин кайтырмын» дип атый, чөнки рельслар бер генә пар, аргы башка киткән трамвайның кире әйләнеп килгәнен көтәргә туры килә. Аллея буйлап йөреп арыгач, без катальпа күләгәсендәге эскәмиягә утырабыз.

– Телисезме, мин сезгә бер җыр җырлыйм? – дидем мин, бер кичне эскәмиядә утырганда.

– Җырлагыз, Зәйтүнә ханум! – Степан Петрович, дикъкатен туплаганны белдереп, башын миңа табарак иде.

Мин, үткән-сүткәннәргә ишетелмәслек итеп, әкрен генә җырлый башладым:

Ялгыз яшәп булмый,
Бабай шуны уйлый;
Ничек кенә уйласаң да,
Ялгыз яшәп булмый.
Карчык алып кайтсаң,
Эшләп кинәндермәс;
Ничек кенә уйласаң да,

Эшләп кинәндермәс.
Яшь кыз алып кайтсаң,
Ул бабайны сөймәс;
Ничек кенә уйласаң да,
Бабайны кыз сөймәс.

Мин күз кырые белән генә Степан Петровичны күзәтәм. Юкка гына җырламыйм бит мин аңа бу җырны, киная белән җырлыйм. Хатын-кызларга хас мин-минлек уянды минем күңелдә: Степан Петрович мине генә якын итсен, аллея буйлап минем белән генә йөрсен, иртәләрен миңа гына чәчәк бүләк итсен, минем күңелне генә күтәрсен дип тели күңел. Җырым белән дә шуны аңлатасым килә. Ә ул тын гына елмаеп утыра, күзләрен кыса төшеп, карашын гөл-чәчәкләргә төбәгән, әллә аңлый кинаяне, әллә юк.

Карчык та мантытмас,
Яшь кыз да мантытмас;
Ничек кенә уйласаң да,
Өйләнеп рәт чыкмас, –

дип тәмамлыйм мин җырны, һәм юри генә көрсенеп кабатлыйм:

– «Өйләнеп рәт чыкмас...»

– Бик дөрес, – дип чын күңелдән хуплый Степан Петрович. – Картайгач өйләнеп йөрүнең бер мәгънәсе дә юк.

– Ялгыз яшәү кыендыр бит, Степан Петрович!

– Мин өч хатын белән яшәгән кеше бит инде, Зәйтүнә ханум. Һәрберсе аерым бер кыйсса.

– Сөйләгез әле, Степан Петрович!

– Сөйләргә була, ләкин аның өчен иркенләп утырырга кирәк. Бүген күп йөрдек инде, җитәрдер.

Мин аның кыйссаларын төн буе тыңларга әзер, әмма ул ялынырга урын калдырмый, синең дәрәҗәңне төшерми генә үз сүзен үткәрә белә. Мин, җиңелчә генә көрсенеп, аңа тыныч йокы телим дә урынымнан кузгалам.

* * *

Степан Петровичның бүлмәсеннән кечкенә генә верандага чыгып була, аңа безнең якларда үсми торган үрмәле яшел агач уралган. Верандадан диңгез күренә.

Диңгез мине беркайчан да туйдырмый. Давыллаганда, мин дулкын шавын тыңларга яратам, тын чагында суга озак-озак карап торам. Ул мине вак-төяк борчулардан арындырып, зур омтылышлар турында, мәңгелек турында уйларга мәҗбүр итә, гүяки рухыма утырган тузаннарны саф сулышы белән юып ала.

– Күпләрнең диңгез дип исе китә, ә мин аңа бер дә ах итмим, – диде верандада минем белән янәшә басып торган Степан Петрович. – Миңа ул буш сыман тоела. Анда яшәеш, тереклек сизелми.

– Әйе шул, сез урманны яратарак төшәсез бугай, – дидем мин, гаҗәпләнгәнемне сиздермәскә тырышып.

– Сезнең халыкта «урман куены», «табигать кочагы» дигән сүзләр бармы? – дип, көтелмәгән сорау бирде ул.

– Бар, әлбәттә. Бик матур сүзләр!

– Ә менә «диңгез куены» дигән сүз юк, шулай бит? Диңгезнең карыны гына бар. Ул юата, тынычландыра белми, йота гына ала. Аннары «туган су» димиләр, «туган җир» диләр... Диңгез ул мәңгелекне генә хәтерләтә, ул Галәмнең мәңгелектән килеп, мәңгелеккә бара торган бер кисәге. Ул безгә хәтле дә шушылай булган, бездән соң да нәкъ шушылай булып калачак. Ә җир, урман һаман үзгәреп тора. Мин туганчы, ул башкача булган, мин киткәч тә башкача булыр. Ул минем язмышымны уртаклаша. Урман шавы минем күңелем белән аваздаш, ә диңгез миңа битараф, ул чиксезлек көен генә көйли белә...

Степан Петрович бераз вакыт тынып торды да үзенең тормыш кыйссасын сөйли башлады. Мин аны табигатьнең ике халәте чигендә, диңгез белән урман тоташкан урында, ай нурының серле яктысында тыңладым. Күңелемдә аңа аваздашлык таптым, шул ук вакытта аның башыннан үткәннәрне диңгез үлчәме белән – мәңгелек үлчәме белән үлчәдем шикелле.

– Олыгайгач, яшь чагында үзең кылган кайбер нәрсәләрне аңлау да кыен, – дип башлады сүзен Степан Петрович. – Кеше гомеренең һәр чоры үз законнарына буйсына икән шул. Беренче мәхәббәтем искә төшү белән, күз алдыма малай чагымда булган бер хәл килеп баса. Минем абзыем, революция башлангач, башкалар кебек үк, Беренче дөнья сугышы окопларын ташлап кайтты. Өстендә ертык шинель, кулында зур мылтык. Минем күз, билгеле инде, абзыйда түгел, шул мылтыкта. Кич авыл агайлары белән әңгәмә корып утыра иде бу, мин мылтыкны алдым да

ишегалдына чыктым. Үзем чамалаганча төзәп карыйм тегене. Агачтагы грушаларга да төзим, өй түбәсендәге ләкләк оясына да, күршеләрнең түбә кыегына да. Имән бармагым тәтегә басарга кымырҗып тора, кызык бит, тигерә алырмынмы, юкмы? Атудан көчкә тыйдым үземне. Төн буе төшемдә мылтык атканымны күреп чыктым, иртән абзый кузгалганчы сикереп тордым да өйалды почмагыннан тагын алдым мин моны. Чыктым болдырга. Күрәм: безнең кызыл әтәчебез койма өстенә кунган да, аллы-гөлле канатларын җилпеп, кычкырып азаплана. Иртәнең матурлыгыннан дәртләнгән дә үзенең көязлеген тавыкларга күрсәтмәкче, янәсе. Күтәрдем мин мылтыкны, әтәчнең кызыл кикриген нәкъ мушка өстенә туры китердем. Шунда үзем дә сизми калдым, имән бармагым тәтегә басты бит. Нидер башыма китереп органдай итте, шартлау авазын ишетми дә калдым, карасам, әтәчебез, канатларын тырпылдатып, койма янында ята. Тавышка әни йөгереп чыкты да тотынды мине орышырга. Бер көтү тавыкка бердәнбер әтәч иде, ни үчең булды, бәдбәхет, ди... Ә мин аптырап карап тик торам. Әти чыгып кулымнан мылтыкны алды да, корал шундый куркыныч нәрсә ул, ат, ат, дип, һаман котыртып кына тора, диде... Хәзерге вакытта коралланy һәм коралсызлану хакында газеталардан укыганда, әтинең шул сүзләре гел искә төшә. Ләкин монысы сәясәт өлкәсеннән... Бер уйласаң, яшь кешенең күңелендә йөз төрле ымсыну ята бит. Алар кешене төрле эшләргә котыртып торалар. Ә олыгайгач, алар берәм-берәм каядыр югалалар. Шунлыктан өлкәннәргә яшьләрне аңлау кыен да. Олыгайгач, яшьлектә кылганнарны да аңлап бетереп булмый икән.

Минем беренче тапкыр өйләнүем дә шулайрак килеп чыкты.

Унсигез яшемдә мин үзебезнең авылдан шактый ерак бер местечкога барып эшкә урнаштым. Шунда үземнән сигез яшькә өлкәнрәк Мария исемле бер тол хатын белән бәйләнеп кителде. Матур гына кызы үсеп килә иде. Миңа аның янында бик рәхәт, ләкин алай да гомерлеккә бергә булырбыз дигән уй башка килми, ниятем армиягә бару, командир булу. Хәер, армиягә киткәнче үк аерылды безнең юллар. Мин кире авылга кайтып киттем, армиягә үзебездән алындым. Алай да китәр алдыннан, туры юлны уравыч итеп, бер сугылып чыктым аның янына. Без вәгъдәләр бирешми, үпкә сүзләре әйтешми генә аерылыштык.

Армиядә мин бик тырышып хезмәт иттем. Күңелнең каядыр очынган чагы, Мария искә төшкәләсә дә, артык сагынмыйм да шикелле, бәхетем алдадыр кебек тоела. Шулай үземне ирекле кош кебек хис итеп йөргәндә, ят кул белән язылган хат китереп тоттырдылар миңа. *«Гражданин Коваль!* – дип бик кырыс башланган иде ул хат. – *Сез минем сеңел белән яшәп, аны бәбиле итеп киткән идегез. Хәзерге көндә Мария үлем чире белән түшәктә ята, кайтыгыз да өч айлык улыгызны алып китегез. Әгәр яхшылык белән балагызны алмасагыз, мин сезне судка бирәчәкмен!»*

Бу хатны укыгач, минем нинди хәлдә калганымны сез күз алдына да китерә алмыйсыз. Балам бардыр дигән уйның моңарчы башыма да килгәне юк иде бит әле! Бу инде сиңа кызыл әтәчне койма башыннан атып төшерү генә түгел!

Мария белән без никахланышмаган, мине, теләсәм дә, җибәрмәячәкләр. Кырыс агай суд белән янап юкка куркыта куркытуын, әмма ана белән баланы ярдәмсез калдырып булмый бит инде! Гәрчә Мария үзе миннән ярдәм сорамаса да, бала хакында язмаса да, мин бу очракта битараф кала алмый идем...

Степан Петрович ике генә түгел, өч ут арасында калганын сөйли. Ә мин билгесез Марияне күз алдына китерергә тырышам. Урман белән диңгез тоташкан урында, тонык ай нурында хатын-кыз шәүләсе чагылып үткәндәй була...

Әгәр теле ачылып, башыннан кичкәннәрен әйтеп бирә алса, ниләр сөйләр иде икән ул шәүлә? Әлбәттә, Степанны яратуы хакында сөйләр иде ул. Әле хәзер дә сөйкемле сөяге бар Степан Петровичның, ә яшьлегендә ул көләч йөзле, тәмле телле, йомшак табигатьле, җитез хәрәкәтле егет булгандыр, Мария аны чын хатын-кызларча, аналарча яраткан, үзенә ни кыен чакта да борчырга теләмәгән. Белдеме икән ул үзенең үлем чире белән ятканын? Юктыр-юктыр, егерме алты яшендә кеше үләренә ышана аламыни! Ул яшәү хакында, мәхәббәте хакында, баланы аякка бастыру хакында уйлагандыр. Менә берзаман Степан ишекне ачып килеп керер дип көткәндер. Әйе, берзаман ул килеп керер, бала әтисе төсле якты күзләре белән аңа турсаеп, ятсынып карар. «Степан, таныйсыңмы?» – дип, дулкынланып сорар Мария. Степан гаҗәпләнүеннән, сөенеченнән шактый вакыт телсез басып торыр. Бераздан гына: «Минем сабый чагым бит бу! – дияр. – Кил, улым, кил!» – дип кулларын сузар. Ул улын түшәмгә чөяр, ә Мария, башын югары күтәреп, янәшә басып торыр. Дөньядагы барча сабыйларның иң зур бәхете ул – әтиләренең көчле кулларында түшәм астына очып менеп, бар нәрсәгә өстән карау һәм астан үзенә төбәлгән, соклану һәм чиксез мәхәббәт тулы ике пар күзне күрү. Дөньядагы барлык хатыннарның иң татлы хыялы бу – башны артка ташлап, елмаеп, әтисе түшәмгә чөйгән балаңа карап тору.

Менә шуларны күз алдына китергәндер Мария, шул көнне өзелеп көткәндер. Ә хәзергә сабыр итәргә кирәк, тыныч хезмәт итсен Степан, теләгенә ирешсен, командир булсын дигәндер. Иң авыр

чакларында шуларны уйлап юангандыр Мария, шул уй аның ирен читләрендә елмаю кабызгандыр. Чын мәгънәсендә сөя белгән хатын-кыз ахыр чиктә дә үзен түгел, сөйгән ярын кайгырта.

– Уйладым мин, төрлесен уйладым, уйларымның очына чыга алмадым, – дип дәвам итте Степан Петрович. – Күпме генә баш ватсам да, эти-әнигә баш орудан башка чара тапмадым. Минем эти-әнием – гади крестьяннар. Җирдә нинди генә сугышлар, фаҗигаләр булмасын, игенченең эше бер аның – ипи булдыру. Аның рухы да хезмәтенә тәңгәл килерлек: ул борынгыдан килгән әхлакый кагыйдәләрне нык саклап яши. Бу яктан караганда, минем әни бигрәк тә катгый, законсыз туган баланы якын да китерәчәк түгел ул. Безнең халыкта андый балаларны «байстрюк» дип атыйлар, «байстрюгым бар» дип, кеше арасында мактанып булмый... Кыскасы, әнидән ярдәм сорауның мәгънәсе юк. Әти кала. Ул мәрхәмәтлерәк, киң күңеллерәк, йомшаграк. Ләкин мин китергән хурлык йөген күтәрергә риза булырмы? Өстенә зур мәшәкать алырмы? Мин, үзалдыма кызарынып, хат язарга утырдым. *«Кадерле атам!* – дип бик кечелекле итеп башладым. – *Миндә шундый-шундый хәлләр килеп чыкты бит әле. Балам туган иде, әнисе бик каты чирли дигән хәбәр килде. Ул фәлән местечкода... Үзем исән чакта баланы тере ятим итәсе килми, син аны барып ала алмассыңмы?»*

Бу хатны алгач, өйдә давыл кубачак, билгеле, әни өермә булып бөтереләчәк. Ләкин ничек кенә кызса да, бераз суынгач, әни үзенең крестьян хатыны икәнлеген исенә төшерә, өйдә барыбер әти сүзе сүз була иде. Әти нәрсә әйтер бит!

Рәхмәт аңа, җавапны озак көттермәде. Хатны ачып, беренче сүзен укуга, эчкә җан керде. *«Улым,* – дип язган иде әти. – *Хатыңны алу белән юлга чыктым, улыбызны үзебезгә алып кайттым. Мариянең хәле яхшыдан түгел, озак яши алмас, ахрысы. Ә улыбыз бик тере, таза, матур, үзеңә охшаган. Яхшы гына үстереп, аякка бастыра алсак, шул балаңның игелеген күреп яшәрсең әле!»*

Мондый хатны бары тик минем әти генә яза ала иде. Иңемнән тау төшкәндәй булды. Дөресен генә әйткәндә, аңарчы күңел түрендә бер шик корты бар иде әле. Мин соңгы тапкыр Мария янына сугылып чыккан көннән санап-санап карыйм, бер дә өч айлык бала булырлык вакыт узмаган иде бит әле. Балабыз бар дип Мария үзе хәбәр итмәде, моны абзасы гына язды. Ә ул каян белә?.. Шундыйрак уйлар чагылып китә иде башта. Ләкин әтинең хатын укыгач, шик-шөбһәләрем юып алгандай юкка чыкты: баланы миңа охшаган дип яза бит, ә минем әтинең күңел өчен дә ялган сөйли торган гадәте юк.

Соңыннан гына улымның җиде айдан туганын белдем.

Шуннан соң әтием, баланың хәлен белдереп, хатларны ешрак яза башлады. Почта килгән саен, минем йөрәк сикерә. Гаҗәп икән ул ата булулар!

Берничә айдан Мария, инде озак яши алмам, ахрысы, улымны алып килегез, соңгы тапкыр күреп каласым килә, дип, әтигә хәбәр җибәргән. Әти баланы күтәреп шундук юлга чыккан. Ә ул чакта юл йөрүләрнең авырлыгын хәзер күз алдына да китереп булмый...

Озак та үтмәде, Мариянең үлгән хәбәре килде, – дип, кыйссасын тәгәлләде Степан Петрович. – Ә ул минем хатларыма җавабында: «Бер дә борчылма, тыныч кына хезмәт ит, мин озакламый терелләм», – дип язган иде.

Степан Петрович тынып калды. Нәрсәдер әйтергә кирәк иде кебек, ләкин мин сүз таба алмадым.

– Ул исән чакта без ир белән хатын булып яши алмадык, – диде, ниһаять, Степан Петрович. – Ләкин мин аны гомерем буе хатыным дип исәпләдем. Минем башка балам булмады, әмма, бәхетемә каршы, әтинең сүзе рас килде, улымның игелеген күреп яшим. Хәзер дә бергә торабыз. Инде оныгым үсеп җитте менә...

Мин диңгездән күзләремне ала алмый басып тордым. Су өстенә яткан ай нурында акка төренгән шәүлә чагылып үткәндәй булды... Мария күптән инде тормыш бакчасыннан киткән, күптән инде, диңгез кебек, төнге күк йөзе кебек үзгәрешсез, исәннәр өчен аңлаешсыз халәткә кергән. Ә мәхәббәте яши, мәхәббәте сөйгәнен җылыта, тормышына мәгънә бирә. Диңгез өстендәге нурлы юлда шәйләнгән зифа сын шул хакта сөйли иде шикелле.

*** * ***

Икенче көнне иртә белән Степан Петрович кыска балаклы чалбарын, күксел киндер кепкасын киеп, вак-вак атлап бакча аллеясыннан килгәндә, мин аны капка төбендә көтеп тора идем инде.

– Иртәләгәнсез бүген, Зәйтүнә ханум, – диде ул, гадәтенчә елмаеп.

– Нигәдер йокым качты, – дидем мин, кичәге сөйләшүгә кинаялэп.

Ул, башын иеп, ямансу гына көлемсерәде.

Иртә кояшлы, җылы, әкрен җил исә иде. Мин үземдә гаҗәп бер җиңеллек тоеп, тын, яшел урам буйлап Степан Петрович белән янәшә атлап киттем.

Менә йортлар, бакчалар артта калды, алда сирәк кенә агачлык күренде.

– Әйе, урман һавасы бөтенләй икенче шул, – диде Степан Петрович, агачлар арасына барып кергәч.

– Урман? Бумы урман?

Мин, аптырап, як-ягыма карадым. Тирә-ягымда эсседән куырылган яфраклы, кәкре-бөкре зәгыйфь имәннәрдән башка агач күрмәдем. Әле ул имәннәр дә, телеграм баганалары кебек, бер-берсеннән тигез ара калдырып утыртылганнар, араларында күләгә тоташмаган, ачык урыннарда үлән көеп утыра.

– Мин урманны башкача күз алдына китерә идем, – дидем. – Ник монда имән утырттылар икән соң? Ул, күрәсең, бу якта начар үсәдер. Ял йорты бакчасындагы кебек акацияләр, тупыллар, катальпалар утыртсалар ярамас иде микәнни?

– Өстән шундый күрсәтмә булгандыр, – диде Степан Петрович. – Бездә һәрнәрсәне өстән кушканча эшлиләр бит. Ә шулай да әйбәт, җиләс!

Мин тагын як-ягыма карандым. Әйе, чыннан да ярыйсы икән бит! Ни дисәң дә яшеллек, әнә агач төпләрендә ромашкалар, кыңгырау чәчәкләр күренә. Көн саен ашханәдә мине көтеп ала торган чәчәкләр. Бүген мин аларны үзем җыям.

Степан Петровичка ияреп, сабый шикелле, агач арасында адашып йөрим. Нидер сөйләшәбез, ләкин сүзнең мәгънәсендә түгел хикмәт, җаннарның ял итүендә. Бу урманны утыртып, мин килүгә шушылай итеп үстереп куйган кешеләргә рәхмәт!

Без урманны аркылы чыктык һәм шундук күкрәгебез белән тоташ стенага килеп бәрелгәндәй булдык. Алда кечерәк кенә, ләкин ерып узгысыз бодай кыры башлана иде. Минем бу кадәр куе, биек, эре башаклы игенне күргәнем юк иде әле! Менә нинди икән ул Украинаның дан тоткан игеннәре! Безне урманнан алып чыккан сукмак, басуны пычак белән кискәндәй итеп, каршыдагы йортлар тарафына узган. Степан Петрович, гадәттәгечә, башын ия төшеп, мине алга уздырды – сукмак тар, янәшә барырлык түгел. Тук башаклардан җылы, татлы ис аңкып, күңелне дәртләндерә. Басу артындагы өйләр оҗмах куышлары булып күренә, анда фәрештәләр яшидер кебек тоела.

Ләкин басу кырыена җитүгә, каршыга һау-һаулап бозау чаклы эт килеп чыкты. Мин, нишләгәнемне үзем дә аңламыйча, кинәт кенә җиргә чүгәләдем: беренчедән, бурзай шәрә балтырымнан каптырып алыр дип курыксам, икенчедән, хәрәкәтсез кешегә эт тими дигән сүз искә төште.

Ул арада Степан Петрович, алга чыгып, гәүдәсе белән мине ышыклап баскан иде инде. Ул биек капкадан чыгып килүче караңгы чырайлы чандыр кешегә катгый, нык тавыш белән дәшеп, этен тыярга кушты.

– Шул кирәк сезгә! – диде теге адәм. – Иртә таңнан парлашып бодай арасында йөрмәссез!

Мин тураеп бастым. Кәефем кырылган булса да, ирексездән елмаеп җибәрдем: Степан Петрович белән без гашыйклар булып та күренә алабыз икән әле!

Степан Петрович гадәтенчә әдәпле, шул ук вакытта буйсындыручан нык тавыш белән тагын берничә сүз әйтүгә, теге адәмнең тавышы әкренәйде, үзалдына мыгырдауга әйләнде, ниһаять, ул, этен ияртеп, капкадан кереп китте.

– Сез андыйларга карап күңелегезне төшермәгез, – диде Степан Петрович, миңа борылып. – Яшәешнең мәгънәсен әшәке кешеләр билгеләмә. Гөлләр чәчәк ата, кояш безгә нурын сибә, яхшы кешеләр елмая. Без шуларны гына күрик!

– Ярый ла явыз этләр очраган саен янда сездәй егет булса! – дидем мин, шаярып.

– Булыр, булыр, Зәйтүнә ханум. Сезне бер эттән дә тешләтмәсләр, сакларлар.

Әйе, чыннан да шулай бит дип уйладым мин. Күпме тулгандым инде бу җирдә, ләкин эт тешләгәне юк бит әле. Һаман кем дә булса саклап килә.

Шушы уй күңелсез очрашуның юшкынын күңелдән юып ташлады, мин тагын юл кырыендагы ромашкаларга үрелдем.

* * *

Табигатьтә һәрнәрсә кабатланып тора: җәй артыннан – кыш, кыш артыннан тагын яз һәм җәй килә, төн артыннан көн туа. Билгеләнгән вакытында ай тулып, тиешле чагында юкка чыгып тора. Ләкин ныклабрак карасаң, бу үзгәрешләр бер-берсен һич тә кабатламыйлар икән. Узган җәй – бусына, бер иртә икенчесенә охшамый.

Әле кичә генә диңгез өсте тыныч, күк йөзе аяз иде, бүген йолдызларны карасу болыт каплаган, диңгездән салкын ачы җил исә.

– Салкынча, – диде Степан Петрович. – Әйдәгез, бүлмәгә керик, Зәйтүнә ханум.

Ул өстәл лампасын гына кабыза, кечкенә бүлмә тагын да кечерәеп киткәндәй була. Мин бердәнбер кәнәфигә утырып, түземсезлек белән аның кыйссасын көтәм. Ә Степан Петрович ашыкмый, өстәл тартмасыннан полиэтилен капчык белән эре, сусыл, саргылт-кызыл төче чияләр чыгара.

– Бүген базарга барган идем. Рәхим итегез, сыйланыгыз.

Ах, Степан Петрович, чия кайгысымыни миндә! Мин теге, «Мең дә бер кичә»дәге кебек, әкият дәвам иткәнне көтәм бит! Тик сезне ашыктырырга гына яхшысынмыйм. Шулай да түзмим:

– Сез миңа икенче хатыныгыз турында сөйләмәкче идегез бит, – дип, сак кына аның исенә төшерәм.

– Ә-ә, – ди ул сүлпән тавыш белән. – Икенчесе кызык түгел. Анысы белән мин һич тә мактана алмыйм.

Ул өстәлдән читкәрәк утыра, йөзе күләгәдә кала. Мин аера алмыйм: әллә ямансулый ул, әллә елмая?

– Дөрес, без аның белән бөтен кагыйдәләргә туры китереп, язылышып яшәдек, – ди Степан Петрович, бераз җанлана төшеп. – Дөресен генә әйткәндә, мин улымны ияртеп аның шәһәрдәге квартирасына йортка кердем. Бик әйбәт итеп яшәргә иде ният, тик булдырып булмады. Гел ыгы-зыгы, ызгыш туып тора иде безнең өйдә...

Мин Степан Петровичны һич тә хатын-кыз белән дәгъвалашкан хәлдә күз алдыма китерә алмыйм. Шуңа күрә сүзен бүлеп сорыйм:

– Ә сәбәбе?

– Сәбәбен аның әйтеп тә булырлык түгел инде. Әйтик, иртән йокыдан тора да тыр да пыр йөри бу, аны-моны сорасам, теш арасыннан чыжылдатып кына җавап бирә. Мин аптырыйм, ни булды сиңа, Ванда? дим, ә ул, син, ди, нишләп мине иртән торгач үпмәдең? Әйбәтләп миңа хәерле иртә теләмәдең? Мин ни дияргә белми аптырап калам. Соң, төнне бергә үткәрдек бит инде, серләр бик килешкән иде. Ул яктан мәхәббәт көчле иде безнең, төнлә ызгышкан булмады. Тик ул мәхәббәт күләгәдә, караңгыда гына уяна иде шикелле. Таң әтәче кычкыруга, пәри шикелле юкка чыга иде ул. Шулай да мин аннан аерылырга исәп тотмый идем. Бәлки, этле-мәчеле яшәп тә бетергән булыр идек, алай гомер иткән кеше азмыни. Ләкин сугыш һәркемнең җанын актарып салгандай итте, күңелнең иң яшерен почмакларын үзенең аяусыз уты белән яктыртты. Мин кадровый офицер идем бит. Безнең часть чолганышта калды. Сугышлар белән чолганыштан чыкканда, үзебезнең шәһәр янында узарга туры килде. Мин разведкага барып, өйгә сугылу җаен таптым. Ванда белән очрашу бик кайнар булды. Ә бераздан, күзләребезгә туры карагач, арабызда боз суыклыгы тойдык. Ул миңа, китмә, кал, ди, тыныч кына яшәсәң, кушканнарын үтәсәң, немецлар да сүз әйтмәс, иелгән башны кылыч кисми, сугышның ничек бетәсен белеп булмый, җан саклау ягын кайгыртырга кирәк, ди. Соң, мин әйтәм, Ванда, вөҗданың йоклаган булса да, акылың бардыр бит синең! Фашист ерткычлар итеге астында чыдап яшәр дип уйлыйсыңмы син әллә халыкны? Мәңге булачак түгел ул хәл! Күр дә тор, себереп түгәчәкбез без аларны! Ул әйтә, бик әйбәт булыр, ди, тик син берүзең нишли аласың анда? Әллә исән барып җитә аласың, әллә юк, монда посып кына көтеп утырсаң, ярамасмыни? Озак бәхәсләшергә вакыт юк иде. Мин аның озын керфекләр белән уратылган зәңгәр күзләренә карадым да эчендә куркып, калтыранып яткан җанын күргәндәй булдым. Әйтерсең лә өр-яңадан таныштык без ул көнне. Шунда гына кемлегебезне аңладык.

Ничек тә малайны коткарырга кирәк иде. Мин аңа, бәләкәй арба тартып, әтиләргә кайтырга куштым. Унөч яшьлек баланы дошман кулындагы җир буйлап өч йөз чакрым юл узарга чыгарып җибәрдем.

Безнең частьлар Киевны азат иткәннән соң гына улымның да, Ванданың да язмышы беленде. Бәхетемә каршы, улым әтиләргә исән-сау кайтып җитә алган. Ә Ванда бөтен көчен, тырышлыгын, уңганлыгын җан саклауга багышлаган. Башкалар кичергән кайгы-хәсрәтләрне, ачлык-кимлекләрне кичерәсе килмәгән аның. Аны йортлар идарәсенең җитәкчесе сыманрак бер кеше итеп сайлаганнар. Ул хәтта дошманның хәрби формасын киеп йөргән, без төзәп ата торган форманы. Ә хыянәт дигән нәрсә бик харап бит ул: машина тәгәрмәче шикелле, бармагың эләксә, кулыңны суыра, аннары үзеңне үк тартып ала. Ул шуңа барып җиткән ки, Германиягә коллыкка озату өчен исемлекләр төзеп йөргән...

Степан Петровичның шушы сүзләренә кадәр мин тыныч кына тыңлый идем әле. Әмма «коллыкка озату өчен исемлекләр төзегән» дигәнне ишеткәч, тәнем тартышып куйды. Узган сугыш илдәге һәр гаиләгә төзәлмәслек яра ясады. Әмма дошман таптап узган җирләрдә ул яралар аеруча тирән, аеруча күп, алардан әле дә булса кан саркып тора сыман. Ул яраларның иң ачысы – унөч-ундүрт яшьлек балаларның коллыкка озатылуыдыр, мөгаен. «Неметчина» турындагы җырларны тыңлаганда тәннәр чымырдый, шулхәтле сагышлы, шулхәтле әрнүле алар...

Билгеле инде, ул эшкә катнашкан кешеләргә халык тарафыннан бернинди рәхим-шәфкать булырга тиеш түгел иде. Андыйны җирдә яшәтәләрме соң!

– Шулай да сугыштан соң сезгә очрашырга туры килдеме? – дип сорадым мин.

– Кая! Ярый әле теге чакта улымны кайтарып җибәрдем дип куанырга гына калды. Ә Ванда немецлар белән качкандырмы, үчле кешеләр кулына эләгеп, суд каршына бастырылгандырмы, белмим. Мин инде аны эзләп тормадым. Сугыштан соң берничә ел исән иде әле ул, күңелем шулай сизә иде. Аннары ул кинәт юкка чыккандай булды. Үлде, дидем мин үз-үземә.

Шул вакыт пыяла веранданың ишегендә ниндидер кара күләгә чагылып узгандай булды, «у-уф!» дигән сызланулы аваз ишетелде. Мин сискәнеп киттем. Бераздан гына бу авазның мәче башлы ябалак кычкыруы икәнлеген аңладым.

Мин, күңелемдәге шомны таратырга тырышып, шаяру тавышы белән:

– Ә бит сез кешене һәртөрле афәтләрдән коткарып кала беләсез, – дидем. – Явыз кешеләрдән дә, явыз этләрдән дә...

– Әгәр явыз эт кешенең үз эчендә булса, аннан коткару мөмкин түгел. Дөрес, мин тырышып карадым, ләкин булдыра алмадым.

Степан Петрович тәрәзәдәге күләгәне күрмәде, әлеге авазга илтифат бирмәде, башын иеп уйланып утырды. Аның йөзе күләгәдә иде, шунлыктан бу минутта яшәреп киткән ул йөздә нинди хисләр чагылганын белеп булмый иде, әллә сагыш, әллә җиңелчә генә елмаю иде анда...

* * *

Шуннан соңгы берничә көн буена безгә иркенләп сөйләшергә туры килмәде. Мин ерак-еракларга экскурсияләргә барам, арып кайтыла, кичләрен Степан Петровичны очратып булмый иде.

Ул арада киң аллеядагы роза гөлләренең чәчәкләрен кистеләр, катальпалар да хуш исле кыңгырауларын койды. Безнең инде ял итү вакыты бетеп килә, күңелне аерылу алдыннан була торган моңсулык били башлаган иде.

Шулай бит ул: әле көннәр күп кебек, очрашырсың да, туйганчы сөйләшерсең дә шикелле, ә карасаң, вакыт үтеп тә киткән, хушлашыр сәгатьләр килеп житкән...

Без төрлебез төрле якка таралышырбыз, бакча эчендәге йортларга яңа кешеләр килер, киң аллеялар буйлап алар йөрер, алар өчен түтәлдәге гөлләр икенче тапкыр чәчәк атар... Шуның өчен кисәләр дә бит инде аларның сабакларын.

– Менә сез дә минем тормышымнан атылган йолдыз кебек сызылып үттегез, – диде бер кичне Степан Петрович. – Гомеремнең тагын бер бизәге үткәннәргә таба авышып бара.

– Алай димәгез, Степан Петрович! Без очрашырга тиешбез, исәннәр бер күрешмәсә, бер күрешә! – Аны үз тормышымнан һич кенә дә сызып ташлыйсым килми иде минем.

– Мин бит инде шундый яшьтә, Зәйтүнә ханум, киләчәккә зур өметләр баглап яши алмыйм. Минем яшьтәге кешегә теләсә кайсы вакытта теләсә нәрсә булуы ихтимал. Мин кесәмдә паспорт йөртәм, аның эчендә кечкенә генә кәгазь кисәге, анда берничә кешенең исеме, адресы. Минем белән бер-бер хәл булса, хәбәр бирер өчен. Мин ул исемлеккә сезне дә теркәп куйдым, Зәйтүнә ханум. Шулай булгач, сез минем дөньядамы-юкмы икәнемне белеп торачаксыз.

Ул боларны тыныч тавыш белән, гади итеп әйтте, әмма минем күзләремә яшь килде. «Юк, сез андый сүз сөйләмәгез, сез әле яшәргә тиеш, сезнең кебекләрне әҗәл әйләнеп үтәргә тиеш!» – дип әйтергә теләдем мин, әмма бу сүзләрнең ясалма яңгыраячагын аңлап, дәшмәдем. Аның сүзләрендә чын хакыйкать иде, ул хакыйкать шундый тыныч, сабыр, ышанычлы тавыш белән әйтелде, бәхәсләшергә урын калмады.

Без диңгезнең биек ярындагы беседкага кереп утырдык. Диңгез тыныч, аның өсте тонык яктылыкта карасу-зәңгәр булып күренә. Ул шулай мәңгегә тынып калган кебек һәм бу хәрәкәтсезлек күңелне дә тынычландыра иде.

Яр астындагы бөдрә ябалдашлы таллар арасыннан кинәт бер егет тавышы ишетелде:

Розпрягайте, хлопци, коні,
Та лягайте спочівать,
А я вийду в сад зелений,
В сад криниченьку копать...

Аннан кемнәрдер җырны күтәреп алдылар. Ах, бу украин җырлары! Җаннарны актара торган нинди көч бар икән аларда?!

– Мин инде бу җирдә үкенерлеген калдырмадым, – диде Степан Петрович. – Мәхәббәтен дә, бәхетен дә татыдым. Дөрес, аларга мин уравыч, авыр юллар белән барып ирештем, ләкин барыбер ирештем. Яулап алдым дияргә була. Теге чакта мин Ванданы калдырып киткәч, без фронт сызыгы аша исән-сау үтә алдык. Ничек үткәнбез – анысы икенче кыйсса. Андый эш беркемгә дә җиңел бирелмәде. Безнекеләр кочак җәеп каршы алды дип әйтә алмыйм. Чолганыштан чыкканнарга ничек тиз генә ышансыннар? Андыйлар арасында төрлесе бар иде бит. Шулай булгач, үпкәләргә урын юк иде. Алай да артык каты бәйләнделәр дип әйтә алмыйм. Ватанны саклау хокукыннан мәхрүм итмәделәр, шунсына рәхмәт. Мине гади солдат итеп штурмовой батальонга җибәрделәр, уналтынчы штурмовой батальонга. Дөресен әйтергә кирәк, без дошманнан аяусызлыгыбыз, куркусызлыгыбыз белән аерылып тора идек, бөтенебез ул явызлар басып алган җирләрдә нинди фаҗигаләр булганын үз күзләребез белән күргән кешеләр. Безне фронтның иң авыр нокталарына һөҗүмгә җибәрәләр иде.

Шуның өчен штурмовой батальон да бит инде ул! Без чигенүнең ни икәнен белмәдек, исән калуга өметебез дә зурдан түгел иде. Шулай да әҗәл мине читләтеп үтә торды. «Минем бәхетем саклаган сине! – ди торган иде соңыннан Ирина. – Ярalануың да минем белән очрашыр өчен генә булган!»

Рига өчен барган каты сугышларда минем күзләремә кыйпылчыклар керде. Врач әйтә, кыйпылчыкларны магнит белән алырга тырышып карарбыз, ди. Әгәр кара металл булса, синең бәхет, ди. Төсле металл булса, анда инде магнит ярдәм итә алмый. Бу нәрсә тиз генә ачыкланмады. Чөнки госпитальдәге врачлар, алгы сызыктагы шикелле, артык кабаланмыйлар, мөмкин кадәр җентекләбрәк карыйлар, аз гына өмете булганын дәваларга бөтен көчләрен куялар иде. Җиңүчеләрнең врачлары иде бит алар, һәртөрле имгәнү-гариплекләрне җиңүдә моңарчы күз күрмәгән уңышларга ирешергә омтылалар иде һәм алар моңа күп очракта ирештеләр дә. Әйтергә кирәк, аларның батырлыгы, тапкырлыгы, фидакарьлеге һаман тиешле бәясен алып бетермәде әле, минемчә.

Шулай язмышым хәл кылынганны көтеп ятканда, минем яндагы койкага шулай ук күзе яраланган тагын берәүне китереп салдылар.

– Без окопларда ята идек, – дип сөйләде ул, – фашистны һич урыныннан кузгатып булмый бит, тәмам интектек. Инде җиңеләселәре дә әллә кайчан билгеле, ә бөтен көчләренә каршы торалар, каһәр суккырылар! Күпме җанны кыялар, үзләре дә гел юкка дөмегәләр. Шуннан соң көтмәгәндә уналтынчы штурмовой батальон килеп чыкты да тегеләрне окопларыннан себереп чыгаргандай итте. Китте куып, китте куып, кая басканнарын белми сыпыртты фашистлар...

Мин бер сүз әйтә алмыйм, бәйләнгән күзләремнән яшь ага. Менә нинди хәбәр килде бит миңа сугышчан дусларымнан!

Шунда сестра килеп керде дә мине шелтәләргә кереште: «Бу ни хәл, нишләп бәйләвегезне чылаттыгыз, алай ярамаганны белмисезмени! Мин сезгә әйттем бит инде, сөенечле хәлләр турында гына сөйләшегез, җиңүне уйлагыз дип», – ди. Ә мин әйтәм: «Шатлыктан елыйм мин, Иринушка, – дим, – ә сөенечле күз яшьләре шифалы алар».

Ул минем янга утырды да күземнең бәйләвечен алыштыра башлады. Башкалар да гел мактап тора иде бу сестраны, ләкин, минем ышануымча, ул бары тик миңа гына шулай назлы, иркә итеп орына иде шикелле. Аның бармакларыннан минем тәнемә йөрәк җылысы агыла иде кебек. Кеше кулларының шундый күпне сөйли алганын, хәтта тел белән әйтеп булмасны да белдерергә сәләтле икәнен мин шул чакта гына белдем. Дөрес, миңа эндәшкәндә, Иринаның тавышы үзгәреп, күңел түреннән агылгандай киңәеп, тирәнәеп киткәндәй була иде. Яралылар, кайчак шаярып: «Ирочка, сез Степанга дәшкән чакта тавышыгызга салган балдан безгә дә өлеш чыгарыгызчы», – ди торганнар иде. Бераздан бу шаярулар бетте. Иринаның минем янда озаграк утыруын, миңа килгән хатларны иң беренче итеп укуын, минем әтиләргә, улыма җавап хатын иң алдан язуын табигый дип саный башладылар. «Синең Ирочкаң» дигән сүзләр дә ычкынгалый иде. Без әле тел белән аңлашмасак та, ике арада сузылган ефәк җепләрнең йөрәкләрне торган саен бер-берсенә ныграк бәйләгәнен сизә идек.

Мин инде хәзер күзем ачылганын тагын да түземсезләнебрәк көтәм. Якты дөньяны, Иринаның йөзен күрәсе килә. Дөрес, куллары назына, тавышына карап, мин аның төс-битен, буй-сынын бик яхшы күз алдына китерә идем... Ләкин бер күрүгә ни җитә! Күзләрем ачылуга, йөрәгемдә кайнаган хисләремне телем белән әйтеп бирермен, без аңлашырбыз дип уйлый идем. Һәм аның да минем сүземне түземсезлек белән көткәнен белеп тора идем.

Кыйпылчыклар кара металл булып чыкты, аларны магнит белән шундый оста итеп алдылар, күземә бер зыян килмәде. Килде бер көн, минем күземнән бәйләвечне алдылар.

Көн яктысын күргәч, ничек сөенгәнемне сөйләп тормыйм. Ул гүр караңгылыгыннан кире кайту белән бер. Шул сөенечле карашымны мин янымда басып торган ак халатлы кешегә төбәдем. Минем каршымда ят бер кыз басып тора иде. Ул минем карашымнан оялды, кызарынып чыкты, калтыранган бармаклары белән халат сәдәпләрен каптыргандай итте. «Күрәсезме?» – Тавышы калтыранып чыкса да, Ирина тавышы иде бу, ләкин үзе бөтенләй чит булып тоелды. Гаҗәп, без, ике сабый шикелле, бер-беребезне ятсына башладык, һәм бу ятсыну тора-бара бетмәде генә түгел, киресенчә, көчәя генә барды. Ул инде минем койкага утырырга кыенсына, палатага кергән чакта минем белән читкә карап кына сөйләшә, хәтта кулындагы әйберен төшереп җибәрә иде. Яралыларның «Синең Ирочкаң» дип әйтүе дә безне җир тишегенә керердәй итә. Менә ничек бит ул: күрмәгәндә, без бер-беребезгә бик якын идек, күзләр ачылгач, кинәт читләштек тә куйдык. Икебез дә бу читләшүне бетерергә тырышабыз, ләкин ятсынуны бетереп кенә булмый бит!

Менә мин инде тәмам терелдем диярлек, китәр вакыт җитте. Без, ашыгып, бер-беребезгә бармак очлары белән генә орынып хушлаштык. Икебез дә күзгә килгән яшьне яшереп, йөзләребезне читкә бордык. Башка очрашмабыз дип уйлаган идек.

Ләкин язмыш безне аерыр өчен генә очраштырмаган икән...

Ике елдан мин күзләремне ныгытып дәваларга Одессага, Филатов институтына килдем. Шунда тагын Ирина белән очраштым. Ул институтта машинистка булып эшли иде.

Без кыенсынып кына күрештек. Сүз югында сүз булсын дип кенә мин зарымны аңа әйтеп салдым. Ул чакта мин Герценның «Үткәннәр һәм уйлар» исемле китабын украин теленә тәрҗемә итеп йөри идем. Хәрби званием кире кайтарылса да, армия хезмәтеннән китәргә туры килде, мин инде тәрҗемә эшенә керешкән идем. Нәшрият бик ашыктыра, ике ай эчендә китапны илтеп тапшырырга кирәк. Ә андый калын китапны ике ай эчендә нинди машинистка басып бетерә алсын? «Мин тотынып карыйм әле, ялга чыгарга тора идем, вакытым да бар», – диде Ирина.

Эшкә утырдык, һәр көн иртән аның бүлмәсендә очрашабыз, мин әйтеп торам, ул баса. Көненә тугызар сәгать шулай мавыгып эшлибез, көндез чәй эчәргә генә туктап алабыз. Китаптагы рухның зурлыгы, уйларның колачы, хисләрнең киеренкелеге безне дә зирәк итте, офыкларны киңәйтеп җибәрде. Без әйтерсең лә бөтенләй үзгә, чиста һәм саф, киеренке тормыш белән яши башладык. Вак-төяк мәшәкатьләр, үткәннәр һәм хәзерге, хәтта безнең бер-беребездән ятсынуыбыз кайдадыр артта калды, һәр сүзне йөрәк аша үткәрәбез, кайчак хисләр ташуыннан мин сүз таба алмый торам, Ирина миңа ярдәмгә килә, тәрҗемә өчен иң уңышлы, иң төгәл, иң йөрәккә үтә торган сүзне ул табып бирә.

Алсыз-ялсыз, баш күтәрми, дөньяда ни барын белми шулай бер ай эшләдек. Китапның яртысына җиткәч, Иринаның ялы бетте. Ләкин эшкә чыгасы көнне дә ул машинкасы янына утырды. «Мин бер айга үз хисабыма ял сорап алдым», – диде. Кичкә таба безнең башлар арый, җеп өзәр хәл калмый, кеше сүзен аңламас хәлгә килә идек, ләкин шул ук вакытта бөтен барлыгыбызны бер нәрсә, хәтта мәхәббәт белән дә алыштырып булмый торган бер рәхәтлек биләп ала иде.

Ниһаять, беркөнне, төш вакытында, тәрәзә челтәрләре аша бүлмәгә кояш төшкәне хәтердә калган, мин әйтеп килгән көй белән: «Бетте!» – дидем. Ул, бар көченә чабып килгән ат шикелле, кинәт кенә туктый алмады, бу сүзне дә басып куйды. Аннары, минем дәвам иткәнемне көткәндәй, кулларын клавишлар өстендә тотып, тынып торды да күтәрелеп карады. Һичбер тартынусыз, оялусыз, якын итеп карады ул һәм мин шунда аның йөзе әниемнең йөзе кебек күңелемә якынлыгын аңладым.

– Ирина, – дидем, – әйдә барыйк урманга. Мин яраткан агачлар ни хәлдә икән?

– Без йөргән бакчалардан да матуррак урын бармыни? – ди ул, ә үзенең күзеннән мөлдерәп яшь ага.

– Күзләрне чылатырга ярамый, – дидем мин, госпитальне искә төшереп. – Елау күзгә зыянлы. Күңелне күтәрә торган нәрсәләр хакында гына сөйләшик.

– Ә мин сөенечтән елыйм, – дип җавап бирә ул. – Шатлыклы күз яшьләре шифалы ул.

Соңыннан без бик күп китапларны бергә эшләдек, ләкин «Үткәннәр һәм уйлар» онытылмады, без аны һаман искә алып тора идек. Кызык булып чыкты: безне якынайту өчен юри шулай ашыктырганнар диярсең. Кульязманы вакытында эшләп бирсәк тә, китап тиз генә дөнья күрмәде, берничә ел нәшрият киштәсендә тузан җыеп ятты. Ул арада гонорарлар да артты. Берзаман китапны чыгарырга уйладылар. Акчасын без көткәннән күбрәк җибәрделәр. «Бәхет артыннан бәхет китерә бу китап безгә!» – дигән иде Ирина.

Степан Петровичның үзалдына елмаеп сөйләгәне тавышыннан ук сизелеп тора. Аста, агачлар арасында, яңа җыр башлап җибәрделәр.

– Без шундый итеп яшәдек: әле дә күңелдә, эх, тегене тегеләй итәсе, моны болай итәсе калган дигән үкенеч туганы юк. Минем хәтергә һаман күңелле нәрсәләр генә килеп тора. Ул, мәсәлән, «ашарга кил» дими, «Степану, синең рухың ризык кабул итәргә әзерме?» дип, шаян тавыш белән дәшә. «Бар, юынып чык!» дими, «Степану, гөнаһлы тәнеңне юасыңмы?» дип әйтә. Төннәрен элекке яраларым сызлап, ыңгырашып куйсам, «әйләнеп ят!» дип кабыргага төртми, сак кына иңемә орынып: «Степану, мине югалттыңмы әллә? Мин монда...» – дип пышылдап, бөтен сызлауларымны бетергәндәй итә иде. Хәзер дә төннәрен уянып китәм дә аның пышылдавын көтәм, һаман янымдадыр кебек тоела.

Степан Петрович агачлыктан яңгыраган җырны тыңлап тынып торды.

– Мәңге яшел кипарис кебек иде минем Иринам, ул беркайчан да ямен югалтмый иде. Ләкин һәрнәрсәнең чиге була икән. Берзаман тавышының көрлеге кимегән сыман булды, шаярып дәшүләре дә сирәгәйде. Өйдә яктылык, җылылык кимегән кебегрәк булды. «Ни булды сиңа, Ирина?» – «Ә нәрсә, берни булмады...» – дип җавап бирә иде ул. Ул хатларны бик матур, гадәтенчә, шаян итеп яза иде. Берзаман танышларыбызга бик озак җавап бирми йөрде бу. Мин кат-кат исенә төшерәм, ә ул, ярар-ярар, ди дә тагын оныта. Ниһаять, язды бу беркөнне. Карыйм, гел генә дә аның хатына охшамаган. Сәламнәрдән соң һава хәлләрен язган да, хәл-әхвәлләрен сорашып, нокта куйган. Шунда белдем инде мин аның авырганын. Ах, әгәр газраилнең юлын кисә торган берәр чара булса, мин аны тапкан булыр идем, бернәрсәне дә кызганмас идем! Ләкин андый чара юк икән шул. Иң зур профессорлар «Соң!» дигәч тә мин олы начальниклар янына бардым, операция ясарга

мәҗбүр иттем. Операция алдыннан мине профессор үзенә чакырып кертте дә: «Әйе, миллион кешедән берсен, бәлки, бу очракта коткарып буладыр, бәлки, шул миллионынчы кеше – хатыныгыздыр», – диде. Әмма мин барыбер өметемне өзәргә теләмәдем. Операциядән соң аның хәле ярты ел чамасы яхшырып торды торуын, ләкин инде якты, шаян, дәртле Ирина кире кайтмады. Шулай да без беркайчан да үлем турында сөйләшмәдек. Мин, билгеле, аңа бу хакта сөйләшү авырдыр дип курыктым, ә ул мине бу дөньяда ялгызымны калдырырга курка иде. Ул белә иде минем аннан башка ямь тапмасымны. Шуңа күрә ул үзенең васыятен дә әйтмәде, соңгы минутына кадәр мине уйлап, мине кызганып яшәде. Без газраилнең якынайганын күреп тордык, ләкин күрмәмешкә салыштык, ахыр көнгәчә элеккечә яшәргә тырыштык. Әгәр шулай итмәсәк, мин кайгыдан сынган булыр идем, мөгаен. Аның ныклыгы миңа көч бирде.

Соңгы кичтә дә ул аңында чакта минем белән һаман яшәр кебек сөйләште, шунда да миңа сыгылып төшәргә ирек бирмәде. Төн уртасына таба ул һушыннан язды һәм бүтән айнымады. Мин өч тапкыр «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырдым, алар килеп уколлар ясап киттеләр, соңгысында: «Бүтән безне чакырмагыз, өмет юк», – диделәр. Ул таң алдыннан тынып калды. Мин аның янында ничек төн уздырганымны сөйли дә, аңлата да алмыйм. Газраил белән очрашуны һәркем ялгызы кичерә. Иртә белән Иринаның институтына шалтыраттым. Алар трубканы алдылар, ә мин берни әйтә алмыйм, тамагыма төер тыгылды...

Менә шул төннән картаеп калдым да инде мин. Хәзер мин үлемнән курыкмыйм. Иң куркынычы үлем түгел, картаю, картлык...

Мин Степан Петровичны юатырлык сүзләр табарга теләдем, сез күп яшьләрдән яшьрәк әле, күңелегез һич картаймаган диясем килде. Ләкин аның ерактан яңгыраган җырны тыңлаганын сизеп, комачауларга кыенсындым. Ә аста, диңгез ярында, һаман җыр яңгырый, аңа яңадан-яңа яшь тавышлар кушыла иде:

Цвіте терен, цвіте терен,
Білым опадае;
Кто с коханням не знаецца
Це горя не знае...*

Без генә түгел, диңгез дә, йолдызлар да бу яшьлек җырын, хәсрәтнең юри-марые, үтә торганы турындагы җырны тыңлыйлар иде шикелле. Җыр көенә җемелдәшеп, йолдызлар диңгезгә карый, диңгез йолдызларны күзәтә. Нәрсә эзли икән мәңгелек йолдызлар мәңгелек диңгез төбеннән, нәрсә табарга тели икән диңгез йолдызлар нурыннан? Кая китә икән ул җырларда яңгыраган шашкын хисләр, мәхәббәт ялкыны, гомер үзе? Йолдызларга ашамы, диңгез төбенә төшәме? Югалырга тиеш түгел бит ул, югала алмый бит ул! Әллә соң йолдызлар җемелдәвендә Иринаның олы җаны бар микән, әллә ул якты нур булып Степанның тормышын яктыртырга тырыша микән? Ә бәлки, ул барлык кешеләрне, шул исәптән шаян кайгыру турында җырлап йөргән яшьләрне кисәтәдер: «Күңелләрегездә моңлы җыр уянырлык чакта матур итеп яшәп калыгыз, – ди торгандыр ул. – Хәсрәтләрнең үтмәс төн кебекләре, җырга сыймаслыклары була, шулар килгәнче бер-берегезгә бәхет бирерлек итеп яшәп калыгыз!» – ди торгандыр.

Ә җыр дәвам итә:

Кто с коханням не знаецца
Це горя не знае...

* * *

Степан Петрович Мариянең дә, Иринаның да ниндилеген әйтмәде. Мин үзем дә аларның тышкы кыяфәтен сорамадым. Шуңа күрәме, әллә башка сәбәптәнме, минем күңелемдә алар бер кеше сыманрак булып калдылар. Ирина Мариянең дәвамы булып тоела башлады. Соңгы очрашуда, катальпа ышыгындагы эскәмиядә утырып торганда, мин Степан Петровичка болай дидем:

– Сезнең ике хатыныгыз булган: Мария белән Ирина. Ләкин алар миңа икесе бер булып тоела. Шулай булгач, сез бер генә тапкыр өйләнгәнсез булып чыга. Мин теге вакытта бабай турындагы җырны сезгә шаярып кына җырлаган идем бит. Дөньяда явыз кешеләр һәм усал этләр һаман бар бит әле, Степан Петрович, һәм шул явызлыклардан яклаучысы булуын теләгән кешеләр дә бар. Сез шундыйларның берсенә генә булса да бәхет бирә алыр идегез. Сез аны ялгызлык дигән явызлыктан гына булса да коткара алыр идегез.

– Мин тырышам анысы, – диде Степан Петрович көр тавыш белән. – Ләкин, Зәйтүнә ханум, олыгаюның үз законнары бар аның. – Ул миңа, сез яшьләр белән өлкәннәр арасындагы аерманы аңлап бетермисез шул, дигән сыманрак итеп карады. – Олыгайгач күпмедер дәрәҗәдә үсмер чакка кире кайткандай буласың икән. Минем бала чактан диярлек аралашып килгән дустым бар. Ул да тол яши. Бер-беребезнең хәлен белеп, ярдәмләшеп, аралашып торабыз һәм, әлбәттә, мин аны бер эттән

дә тешләтмәячәкмен. Әле менә машинка алып бирдем, ул да баса белә. Ләкин өйләнү кадәресенә барып җитеп булмый инде. Мин үз бүлмәмдә, үз урынымда йокларга яратам.

Мин аңа каршы әйтер сүз таба алмадым.

*** * ***

Без хат язышырга вәгъдә куешмаган идек. Ләкин мин аны оныта алмадым. Мине коты алынган чыпчык баласына әйләндерерлек хәлләр һаман булгалап торды, шундый чакларда мине тавис кошына әйләндерерлек кешеләр һаман очрап тора дип һич тә мактана алмас идем. Без, бик еш булмаса да, ара-тирә хат алыша башладык. Хатларымның берсендә мин аңа теге бабай турындагы җырны язып җибәрдем. *«Дөрес, ноталарын бик үк төгәл язганыма ышанмыйм,* – дидем ахырдан, – *хәтердән генә яздым. Танышларым миннән көләләр, син башка милләт көйләрен татарчага тәрҗемә итеп җырлыйсың, диләр. Сез гаепкә алмый гына төзәтеп җырлагыз инде, зинһар»*.

Бераздан аның машинкада басылган җавабы килеп төште. *«Җырыгызны үзалдыма көйләп йөрим,* – дип язган иде Степан Петрович. – *Сез аңа чыннан да татар моңы кушып язгансыз. Мин моны сезгә теге чакта ук әйтмәкче идем дә, әллә ничек җае туры килмәде.* («Анда да минем хәтерне саклаган», – дип уйладым мин.) *Ә ноталарны мин яхшы беләм. Бәләкәй чагымда музыка өйрәнеп, хорда җырлап йөргән идем. Миңа әле хәтта, җырчы булырсың, консерваториядә укырсың, ди торганнар иде. Тик Беренче бөтендөнья сугышы комачаулады».*

«Беренче бөтендөнья сугышы!» Чал тарихны хәтерләткән бу сүзләр минем күңелемә шом салды. Ни хәлләрдә икән минем яклаучым, үсендерүчем, элекке романнардан килеп кергән зыялы кавалерым? Ишек каксалар, сискәнеп китәм, хат ташучы миңа кайгылы телеграмма китергәнме әллә дип котым алына. «Узма, гомер!» – дим мин андый чакларда. Диңгезнең текә ярына ук барып тоташкан куе бакчада, Джанни Родари әкиятеннән чыккан төсле сөйкемле агай янында гына булса да ашыкмый тор, Вакыт. Йөрсен ул шул бакчаны ямьләндереп, коты алынган чыпчык балаларын тавис кошларына әйләндерсен, аларны явыз адәмнәрдән һәм усал этләрдән сакласын. Узма, гомер!

*1979*

## Сары тюльпаннар

Язның да болытлы, ямансу, шактый күңелсез көннәре була. Шундый бер көннең кичке эңгер-меңгер сәгатендә, кеше тулы троллейбуста күзлек кигән пенсия яшендәге бер апа миңа каршы утыргычка килеп утырды. Кулында бер кочак сары тюльпаннар. Күп иде, эре, матур иде тюльпаннар, эчләрендә кечкенә лампочкалар янган кебек, тирә-юньгә нур сибә иде алар. Бөтен кешенең карашы ихтыярсыздан шул чәчәкләргә төбәлде.

Менә троллейбуска кулына зур сумка тоткан урта яшьләрдәге бер хатын килеп керде, тыгызланып баскан халык арасыннан күптән күнегелгән хәрәкәт белән, балыктай шуышып, эчкәрәк, безнең янгарак узды. Аның кыяфәте талчыккан, йөзе уйчан иде. Арыгандыр, өйгә кайтуына тагын күп эшләре көтеп торганын уйлыйдыр, ә бәлки, берәр моңы бардыр. Яшең олыгаеп килгәндә, тәнне авырайта, күңелне сүрелдерә торган сәбәпләр аз буламыни!

Аның бәхетенә, чәчкә тоткан апа янындагы урын бушады, сумкалы хатын, җиңел сулап, иркенәеп утырды. Биге ябылмыйча, авызыннан кәгазь төргәкләр, полиэтилен капчыклар күренеп торган сумкасын тезенә куйды да, йөзен күршесенә таба борып, күзләрен чәчкәләргә текәде. Кем белә, бәлки, бу чәчкәләр аның күңелендә матур хатирәләр кузгаткандыр, ә бәлки, кара-соры-күк пальто-плащлар һәм арыган чырайлар белән тулы троллейбуска яктылык сирпеп, янып торган тюльпаннар аның күзенә ял биргәндер. Кем белә...

Ул шулай керфеген дә какмый карап баргач, чәчкә хуҗасы нидер әйтергә тиеш тапты булса кирәк:

– Бакчабыздан кайтып килүем, – диде. – Башка алып кайтыр әйбер юк бит әле, шушы чәчкәләр генә.

– Иллә дә матур икән чәчкәләрегез! – диде хатын әкрен тавыш белән, ләкин шулкадәр хисләнеп, йөрәк түреннән чыгарып әйтте, тюльпаннар аның күңелен кузгатканы көн кебек ачык иде. Мөгаен, эш-мәшәкать белән ул бу язның узып барганын да сизми калган булгандыр, шушы тюльпаннарны күргәч кенә, «Бәй, яз килгән бит, яз!» дигән уй аңына килгәндер.

– Чынлап әйтәсезме? Сезгә ошыймы? – дип сорады чәчкәле апа, җанланып. Аның күзлек пыялаларында чәчкәләрдән төшкән алтынсу нурлар уйнап алды. Сумкалы хатын тураебрак утырды.

– Ничек ошамасын инде! Эре үзләре, теп-тере үзләре, төсләре дә бигрәк ачык, матур!

– Сез шулай дисез дә бит, күпләр сары чәчкәләрне яратмый. Сары төс – аерылу төсе, сагыш төсе, диләр. Шуңа күрә мондый чәчкәләрне бүләк итү дә кыен. Ә мин үстерәм менә, тамырларын корытасым килми, яратам.

– Аерылу-сагышлар чәчкә төсле буламыни! – диде сумкалы хатын. – Сары төс – яз төсе, яңа чыккан нәни чебешләр төсе, кояш нуры төсе ул. Галимнәр әйтә, сары төс кешенең күңелен күтәрә, нервысын тынычландыра, ди.

– Бала чүпрәгендәге таплар да сары, – дип көлемсерәп, ике өлкән хатынны үчекләгәндәй әйтеп куйды минем янда сабыен кочаклап утырган яшь хатын.

– Әйе шул, – диде сумкалы хатын, тагын да ачылып. – Сәламәт сабыйның ак чүпрәгендәге таплар да сары була. Тик аларның матурлыгын еллар үткәч кенә аңлый башлыйсың икән шул.

– Сары төс быел модада, – дип сүзгә кушылды утыргыч аркасына тотынып барган түгәрәк битле бер кыз. – Мәскәү белән Ленинградта быел хатын-кызларның бар кигәне шәмәхә дә сары икән.

Күзлекле апа кочагындагы тюльпаннарның берничәсен озын сабагы буена суырып алды да күршесенә сузды:

– Менә болары сезгә булсын.

Хатын каушап китте:

– Минме? Миңамы? Юк, рәхмәт, мин сездән андый зур бүләк ала алмыйм!

– Нишләп алмыйсыз? Әле генә ошый дигән идегез бит! Безнең бакчада күп алар. Куяр урын юк. Ялгызым яшим бит мин. Боларын да күрше карчыкларына өләшермен дип кенә алып кайтуым.

Сумкалы хатын озын сабаклы, эре, тере чәчкәләрне, ватудан курыккандай, сак кына хәрәкәт белән кулына алды. Яшь кызлардай оялчан елмайган иде ул, бит очлары алланып чыккан, керфекләре дерелди иде.

– Быел миңа чәчкә биргән кеше юк иде әле. Ничек шулай эре, матур итеп үстерә алгансыздыр үзләрен!

– И, аның берние юк! Суганнарын җиргә тыгып куйсаң, үзе үсә ул. Шәһәр өенең баскыч төбендә дә үстереп була аларны. Көзгә таба мин аларның суганнарын да бирә алам сезгә. Тик онытмагыз, адресымны гына истә калдырыгыз...

Ике хатын, бер-берсенә елышып, чын ахирәтләр шикелле сөйләшеп киттеләр.

Ә минем күз алдыма, аларны каплап, аларның сүзләрен ерагайтып, зиһенемне көйдереп, яшьлек дустым Люция килеп басты. Аның язмышы, өметләре киселүе дә шушындый ук сары чәчкәләр белән бәйле булган иде бит. Тик аның тарихы юлда барганда җиңел генә сөйләп ташлый торганнардан түгел, авыр, ах авыр ул хәлләрне искә алуы!

Сары – көз төсе, диләр. Ләкин язын иң беренче булып үскән гөлләрнең дә чәчәкләре сары бит! Тугай күрке – үги ана яфраклары, бакча күрке – тюльпаннар. Әллә соң алар өчен яз белән көз бергә буталамы?

Люциянең яшьлеге – язы – узган иде бит инде. Ул, әллә ничек шунда, гомеренең җәен бөтенләй әле кичермәгән килеш, тормыш языннан туп-туры көзгә кереп бара иде шикелле.

Ничек соң әле аның язмышы сары чәчкәләргә барып тоташты?

Моның сәбәпләрен гөлләр чәчәк аткан чактан түгел, гөл орлыкларының туфракка төшкән чагыннан эзләргә кирәктер. Ә бәлки, аннан да иртәрәк, туфракның гөл орлыгын кабул итәргә әзер булуыннандыр. Чөнки орлык тишелсен өчен, туфракның әзер булуы кирәк.

Ә Люциянең күңелендә мәхәббәт гөлләре үссен өчен шартлар әзер иде, күптән әзер иде... Тик ул буш торды, артык озак буш торды...

Мин моны көзге кичләрнең берсендә бигрәк тә ачык итеп сиздем.

Дәресләремне бетереп, өйгә кайтырга чыксам, мәктәп капка төбендә мине Люция көтеп тора. Бераз гаҗәп тоелды бу миңа: башка чакта, йомышы булса, Люция туры безнең өйгә килә торган иде, мине урамнарда сагалап йөрми иде. Димәк, аның миңа гадәттән тыш йомышы бар иде!

Җилле, яңгырлы, күшектергеч, шыксыз бер кич иде бу. Урам кырыйларындагы агачлар соңгы яфракларын коя иде. Люциянең тавышыннан исә кәефе шушы кичтән дә төшенке икәне сизелеп тора иде.

Ләкин ул миңа үзенең йомышын әйтергә ашыкмады. Безгә хәтле җәяү генә кайттык, юлда гадәти сүзләр сөйләштек: ул – эшли торган институт хәлләрен, мин – укыта торган балаларны, элекке группадашларны искә алдык, кем кемне күргән дә кем хакында нәрсә ишеткән...

Безгә илтә торган туры юл кечкенә бакча аркылы үтә. Бакчадагы бер эскәмия турына җиткәч, Люция:

– Утырып торыйк әле бераз, – диде.

Сумкасыннан газета алып юеш эскәмиягә җәйде. Утырдык.

– Кичә тагын театрга бардым, «Сүнгән йолдызлар»ны тагын бер кат карадым әле, – диде ул. – Тагын Мәхдүмгә гашыйк булып кайттым.

– Ни өчен Мәхдүмгә? Нигә егет солтаны Исмәгыйльгә түгел?

– Исмәгыйльгә гашыйк кызлар болай да җитәрлек. Ә Мәхдүмгә кызлар каз канаты сатмыйлар. Бөтен башка егетләргә саталар, аңа – юк. Миңа охшаган ул. Яратучысы юк аның.

– Нишләп яратмасыннар сине, Люция! Сине яратмый буламыни! Күрмисең генәдер, игътибар бирмисеңдер!

– Ә кем? Кемне күрим мин?

Мин телемне аркылы тешләдем. Люциягә күзе кызып йөргән егетләрне белә идем мин, белмим түгел, бар иде андыйлар. Ләкин бит Люция кебек кешегә алай күз кыздырып йөрүчеләр генә лаек яр була алмый. Гадәттән тыш кыз иде безнең Люциябез, һәм аның мәхәббәте дә гадәттән тыш булырга тиеш иде, ул үзе дә язмыштан зурны – Галиябану белән Хәлил, Ромео һәм Джульетта, Йосыф-Зөләйха мәхәббәте кебек олы, изге, кабатланмас тугры хис килгәнен көтә, үзенә шундый бөек дәрәҗәдәге хис белән җавап бирерлек пар эзли иде. Моңа аның хакы да бар иде.

Институтта укыганда, ул безнең группабызның күрке һәм мактанычы булды. Биш ел укып, бер генә дүртле дә алмады, гел бишлегә генә укыды, кайбер семинарларда укытучылар белән бәхәскә керерлек гыйлеме бар иде инде аның. Биш ел буе группабызның комсоргы итеп сайланды ул. Ниләр генә кыланмый идек без: гөрләп торган кичәләр, ярышлар, диспутлар үткәрү кирәкме, каникулда Ленинградка бару, атна саен чаңгы шуарга чыгу, ансамбльләр оештыру, спектакльләр кую... Без институтны тәмамлаганга инде җиде ел узды, ләкин әле андый группаның бүтән булганы юк дип сөйлиләр укытучылар, һәм бөтен шул кичәләрнең, походларның, спектакльләрнең башында Люция була иде. Бөтен кешегә, хәтта армия хезмәтеннән кайткан егетләребезгә дә үз сүзен үткәрә белә иде ул.

Группада аны исеме белән атамыйча, «Луциус» дип йөртәләр иде. Луциус Корнелиус Суллага – Борынгы Римның атаклы гаскәр һәм дәүләт башлыгына тиңләп көлемсерәү катыш яратып шулай дәшәләр иде аңа: «Луциус!»

Люция үзе дә бу кушаматка үпкәләми, «Луциус!» диюгә, озын, төз муенын борып, яшь егетләрчә кыска итеп кистерелгән тыгыз бөдрәләре астыннан акыллы яшел күзләре белән туп-туры кешенең күзләренә текәлә, аның түгәрәк мөлаем йөзендә җитди дикъкать һәм таләпчәнлек чагыла иде. Кайгыртучан һәм таләпчән гаскәр башлыгы яисә яшьтән кече туганнарын тәрбияләргә күнегеп, иртә акылга утырган өлкән кыз бала карашы иде бу.

Һичшиксез, без барыбыз да, шул исәптән егетләр дә, аны ихтирам итә идек, ләкин шул ук вакытта егетләрнең аңа булган мөнәсәбәтендә артык югары күтәреп кую, шунлыктан үзләреннән читләштерү дә сизелә иде. Дөрес, Люция биш ел буе ялгыз торна булып йөрмәде. Икенче курста укыганда, физматта укучы чибәр бер егет белән әйбәт кенә дуслашып киткәннәр иде алар, кичәләргә, киноларга бергә йөриләр иде. Люция бу егеткә бик зур өметләр һәм ышаныч баглаган иде. Ләкин егет укуны бездән алда тәмамлады да, һич көтмәгәндә мединститутта укыган бер кызга өйләнеп, башка шәһәргә китеп барды.

Люция зарланмады, еламады, хәсрәтен күз карашында да сиздермәде. «Луциусның андыйларга гына исе китми лә, тыштан гына ялтырый иде бит ул егет, ә чынында Луциусның кисеп ташлаган тырнагына да тормый», – дип сөйләштек без группадаш кызлар белән.

Луциус – башка кызлардан бер башка калкып торган, нечкә сынына корыч үзәк яшеренгәндәй нык ихтыярлы Луциус – гадәти кыз түгел иде, билгеле. Аның язмышы да гадәттән тыш, күренекле, бәхетле булырга тиеш иде шикелле.

Бер яктан караганда, ул шулай булып килеп чыкты да. Институтны тәмамлауга, Люцияне аспирантурага алдылар, егерме биш яшендә ул фәннәр кандидаты булды, хәзер менә инде докторлык диссертациясе дә әзер.

Тик менә мәхәббәтнең генә аңа лаегы килмәде. Безнең группадагы иң йомыкый кызлар да күптән инде кияүгә чыгып беттеләр, балалар үстерәләр, бер-ике өлгере хәтта икенче тапкыр барып өлгерде инде. Ә Луциус һаман ялгыз.

– Әгәр теләсәң, син әллә кемнәрне очраткан булыр идең инде, – дидем мин, нихәтле уйлап та, үзем белгәннәр арасыннан аңа тиң кешене таба алмагач.

Бакчада агачлар җанны өшеткеч тавыш чыгарып шаулый иде, кинәт искән дымлы җил минем битемә юеш яфрак ябыштырып китте. Люциянең сүзләре исә шул җилдән сагышлырак иде.

– Әгәр мине яратучы булса, гел Мәхдүм төсле бөкре булсын, Квазимодо кебек ямьсез булсын, анысына карамас та идем. Яратсын гына иде. Бары шул гына. Минеке генә булсын иде. Янымда гына торсын иде...

Аңлый идем мин аның хәлен, белә идем, билгеле!

Менә шушындый иртә караңгы төшә торган, җилле, яңгырлы көзге кичләрдә ялгызлык кеше күңеленә аеруча авыр итеп сарыла, аны сагыш белән, ялгыз тормышның мәгънәсезлеге турындагы уйлар белән урап ала. Ах, Люция, Люция, ничек кенә ярдәм итим соң мин сиңа! Әгәр үзем егет булсам һәм әгәр дә Әсгать кебекне очратмасам, мин, әлбәттә, үземә синнән башка ярлар эзләмәгән булыр идем!

Кадерен белер идем мин Люциянең! Чөнки мин әле аның беркем белмәгән якларын да белә идем. Группадагы иптәшләр арасында ул бераз кырысрак төсле күренә, ә тулай торак бүлмәсенә кайтып, халатын киеп куйгач, бөтенләй башка кешегә – йомшак, сизгер күңелле, кайгыртучан, дусты өчен бөтен нәрсәне эшләргә әзер мөлаем кызга әверелә иде. Тик бер нәрсәне – үзен әз генә булса да кимсетүне яисә үзеннән чак кына булса да көлүне һич кичерә алмый иде ул. Шуңа күрә мин аның белән сөйләшкәндә, сүзләрне сайлап кына әйтергә тырыша идем. Бәлки, шул хәтер калучанлыгы аркасында ул үзен корырак, егетләрчә кырысрак итеп күрсәтергә тырышкандыр да әле. Бәлки, шуңа күрә ул үзенең күңелендәге җәүһәрләрне каты кабырчык астына яшергәндер дә.

Бу юлы да мин аның күңелен рәнҗетмәслек, шул ук вакытта катырак сүзләр эзләдем. Эзләдем, табалмадым. Бакча юлыннан узып барган ике ир кеше безгә таба борылдылар. Караңгыда аларның йөзләре ак тап булып кына шәйләнә иде.

– Сез безне көтәсезме, кызлар?

– Әйдә китик, – дип, минем җиңнән тартты Люция.

Мин аны үзебезгә алып бармакчы идем.

– Рәхмәт, – диде Люция. – Мине өйдә ялгызлыгым көтә. Эшкә киткәндә мин аны калдырып китәм, кайтуыма ул мине кочак җәеп каршы ала. Аның кочагына күнегергә вакыт инде миңа. Әйтәләр бит әле, кеше һәрнәрсәгә күнегә, диләр. Әгәр кешегә көн саен бер үк вакытта энә белән китереп чәнчи торган итсәләр, ул шуны да көтеп алырга күнегә икән. Ялгызлыкка күнегергә кирәк миңа. Ә сезгә барсам, күнегүем бозыла...

Ул бакча коймасы буйлап ашыгып китеп барды. Караңгыда кечерәйгәннән-кечерәеп, сирәк кенә үткән-сүткәннәр арасында күздән югалды.

Кичен мин Люция белән очрашуыбыз турында Әсгатькә сөйләдем.

– Ялгызлыктан интегә, – дидем. – Ичмасам, Мәхдүм кебек берәр гарип егет гашыйк булсын иде миңа, ди. Үзенә тиңнәрне театр сәхнәсеннән эзли. Артистка бит ул безнең Луциусыбыз!

– Артистка түгел, антиартистка ул сезнең Люциягез, – дип каршы төште миңа Әсгать. – Һәрнәрсәне артык җитди кабул итә. Берәр егетнең үзенә күңеле төшкәнен сизде исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип, тикшеренә башлый, егетне микроскоп астына салгандай итә. Кемгә ошасын микроскоп астына керү! Мәхәббәттә бераз ихи-михи дә кирәк, ансыз булмый!

Мин ирем фикере белән килештем: әйе, Люция җитди, мәхәббәткә дә таләпчән карый. Ләкин бу аның җаваплылыгы, күңел сафлыгы турында сөйли ләбаса. Әгәр инде ул берәрсен яр итсә, мәңге аңа тугрылыклы булачак, аңа ярар өчен бөтенесен эшләячәк. Ничек егетләр шуны аңламый! Әгәр алар аның таләпчән һәм артык җитди сыман күренгән кабыгы эчендә нинди күңел яшеренеп ятканын белсәләр, гашыйк булмый түзә алмаслар иде. Әмма Люция үзе ышанмаган кешегә күңелен ачмаячак иде шул.

Әллә нинди ерып чыга алмаслык хәл иде бу, еллар узган саен, Люциянең бәхетле гаилә коруга өмете кими бара иде.

Ләкин, көзге яңгырлар үтеп, карлар яуганнан соң, Люция миңа телефоннан шалтыратты һәм аның яшь чактагыча күтәренке дәртле яңгыраган тавышын ишеткәч, минем күңелем сөенеч белән тулды. Әллә инде минем дускаем берәр яхшы кешегә юлыкканмы?

– Сөенечең бар, ахрысы, – дидем мин, турыдан-туры сорарга яхшысынмыйча.

– Сизеләмени?

– Мин сизми каламмы?

– Бер чакырып таныштырам әле мин сезне!

Дускаемны бәхетле иткән ул кешене, хәтта ул Мәхдүм кебек бөкре һәм Квазимодо төсле ямьсез булса да, күргәнче үк якын итәргә, яратырга әзер идем мин.

Ул безне 8 Март бәйрәменә үзләренә кунакка чакырды. Мин бу очрашу алдыннан шактый дулкынландым. Ни дисәң дә, Мәхдүм яки Квазимодоны Люция белән янәшә күреп, кәефең кырылмыйча калу ансат булмаячак иде.

Без аңарчы да Люциядә кунакта еш була торган идек. Аның бер бүлмәле квартирасы оҗмахның почмагы кебек ямьле, аш-суга да кулы ята, шуның өстенә Әсгать пианино уйнаганда, хисле итеп җырлый да ала, ләкин, барысыннан да бигрәк, аның белән сөйләшкәч, дөнья хәлләре һәм фән турында бик күп яңалыклар белеп була иде. Кыскасы, аңа барган саен без рәхәтләнеп ял итеп кайта торган идек.

Мин яңа кеше шушы рәхәтлекне бозмас микән дип тә шикләндем.

Ләкин егетне күрүгә, бөтен шикләрем юкка чыкты. Гәүдәсе дә туры, буе да Люциядән тәбәнәк түгел, йөзе дә төзек, ак иде аның. Елмаеп кына сөйләшә, Люциянең авызына гына карап тора: «Люция Кадыйровна, чәй кайнады, хәзер пешереп алып киләм!»; «Люция Кадыйровна, кунакларның тезенә шушы салфетканы салырга ярыймы?»; «Люция Кадыйровна, кузгалмагыз,

хәзер үзем!» Хуҗа булып та йөри шикелле, шул ук вакытта бик үк азынып та китмәгән, үз урынын белә, кечелекле кылана, һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә Люцияне олылау сизелеп тора.

Бер генә кимчелеге бар иде егетнең – ул да булса, Люциядән шактый – сигез яшькә яшьрәк булуы. Хәер, яшьлек дигән кимчелек елдан-ел бетә бара ул, дип күптән әйтелгән бит инде.

Күрәсең, Люциягә бу нәрсә комачау булып тоелмагандыр, югыйсә ул егетне якын да җибәрмәс иде, инде башка сыймаган рәвешле хаталанып куйган булса да, безне парлап аның янына кунакка чакырмас иде. Безгә күрсәтәсе иткән икән, димәк, зурдан иде аның өмете, җитди иде аның нияте. Хәер, нигә өметләнмәскә: егетнең яшьлеге бәрабәренә үлчәүнең үз ягына салырлык өстенлекләре җитәрлек иде лә аның!

Кыскасы, Люция өчен сөенергә кирәк иде. Мин сөенергә тырыштым да. Ләкин чын күңелдән шатланырга бернәрсә комачаулык итте: ул да булса, егетнең текә маңгае астыннан сөзеп карап куюы. Сирәк кенә карый иде ул, ләкин шул бер карашы белән сине аркылыга-буйга үлчәгәндәй итә дә куя иде. Караганын сиздермәскә тырыша үзе, син сискәнеп борылуга, елмая башлый, ләкин бер мизгелдә тоелып калган ул караш сине сагайта, күңелне шомландыра иде. Шуның өстенә Әсгать тә минем шатлыгым балына кашык кына түгел, чүмеч белән чумырып дегет салгандай итте. Флүн белән – егетнең исеме Флүн иде – бер авыз сүз алышмады, Люция белән аны-моны гына сөйләшкәләде дә, бер-ике чынаяк чәй эчкәч һәм баскычка чыгып берүзе – Флүн тартмый иде, билгеле – сигарет тартып кергәч, мине кайтырга ашыктыра башлады.

Юл буе, башын чайкап:

– Ну артист! Ну артист! – дип кайтты. Ә өйдә: – Люциягә әйт: ул малайны пропискага кертә күрмәсен тагын, – диде. – Аңа ышанып, квартирын пыран-заран китермәгәе!

Горур Люциянең күңелен рәнҗетеп андый сүз әйтеп буламыни! Моны Әсгать үзе дә яхшы белә ләбаса. Өстәвенә Люциянең ялгышканына һич кенә дә ышанасым килми иде. Шуңа күрә, иремнән дә бигрәк үз күңелемне ышандырырга тырышып, Люция кешеләрне таный ул, малай-шалайдан алдана алмый дип, чын-чынлап әрепләшергә керештем. Ләкин күңелем бер генә дә тыныч түгел иде, ай, тыныч түгел иде!

Үзебез укыган чакта шулай үзләреннән күпкә өлкән хатыннар белән бәйләнгән бер-ике студент искә төште. Алар, безнең башка егетләр кебек, тулай торакта коры-сары белән ничек туры килде шулай тукланып, майка-ыштаннарын кулъюгыч краны астында юып интекмәделәр – үзләренә әзер оя таба белделәр. Өсләре чиста, тамаклары тук, күңелләре хуш була иде. Хәтерлим, Рәниф исемле бер егетебез үзенең шундый кешесен «хатыным» дип йөрткән була иде, бию кичәләренә дә алып килгәли иде. Яше егермедән яңа узган егет янында гәүдәсе шактый тулыланган, утызга җиткән хатын безгә бик көлке булып тоела иде. Бичара хатын белде микән почмак саен авыз ерып үзеннән көлеп торганнарын. Ни хикмәттер, бу хәлгә күпләр Рәнифнең бик оста корган хәйләсе итеп кенә карыйлар, дөрес эшли, ә нигә мөмкин булганда рәхәт күрмәскә дип, аны хуплаучылар да табыла иде. Кыскасы, болай яшәү егет кешенең дәрәҗәсен артык төшерми, әмма хатынны бөтенләй юкка чыгара, аны чүтсыз арзанайта шикелле иде.

Белмим, андый хатыннар ни уйлап, нәрсәгә өметләнеп асраганнардыр ул студентларны. Бәлки, аларның тасма телләренә ышанып, киләчәктә бергә булуларына өмет саклаганнардыр. Егетне үз яннарында тоту өчен, аларга бар көчләренә ярарга тырышалар иде алар.

Әмма мондый «кавышулар»ның ахыры һаман бертөрле тәмамлана иде: егетләр шул рәвешле өч-дүрт ел бал-май эчендә йөзеп яшиләр дә, диплом алгач, канат җәеп, юллама күрсәтелгән юнәлештә очып китәләр иде. Яңа урында, үзләренә тиң яшь пар табып, оя коралар. Ә анда, иске ояда, еллар буе күзен аңа төбәп яшәгән хатын нишли, ниләр кайный аның эчендә – анысында егетнең хәбәре юк, әйтерсең ул кеше белән бөтенләй танышлыгы да булмаган.

Эт кадере дә булмый иде ул студент асраган хатыннарга!

Люция дә шундый кадерсез булыр микәнни, ул да шулай адәм көлкесенә калыр микәнни? Булмас, булмас, Люция акыллы, зирәк, кешеләрне таный белә, үз дәрәҗәсен төшерүгә юл куя алмый, чөнки ул үз кадерен яхшы белә бит!

– Әйе, акыллы, зирәк, анысына сүзем юк, – диде Әсгать. – Ә менә йөрәге сукыр, чөнки мәхәббәт мәсьәләсендә бер тәҗрибәсе дә юк аның, унбиш-уналты яшьлек кызлар кебек ахмак, беркатлы әле ул. Утызга җиткәч андый булып калу куркыныч, аны һәркем килеп алдый ала!

Нишләп алдый алсын! Күрә иде бит ул теге хатыннар өстендә туенып яткан студентларны, белә иде бит алардан яшьләрнең ничек көлгәнен! Дөньяда бөтен хаталарны үзең ясап акыл җыярга димәгән, акыллы адәм кеше ялгышларын күреп үзенә сабак ала!

Мин бу хакта бар булган шикләремне Люциягә әйтеп, ничек булса да үз хәленә аеграк карарга мәҗбүр итәрмен дип, бик нык күңелемә киртләп куйган идем.

Ләкин аннан соңгы очрашуларда бөтен уйларымны ачып салырга һич кенә дә җай табылмады. Люция кешеләрнең ачы сабакларын оныткан һәм минем сүзләремне дә тыңларлык хәлдә түгел иде. Ул гадәттән тыш мәхәббәт көтеп яшәгән иде һәм, ниһаять, килгән бу бәйләнешне мәхәббәтнең

зурысы дип үз-үзен ышандырырга тырыша иде. Ул студент асрап адәм көлкесенә калган хатыннар турында искә алырга да, ишетергә дә теләми, үзенә әдәбияттан, театр сәхнәсеннән мисаллар, үрнәкләр эзли иде.

– Айседора Дункан Есениннан унҗиде яшькә өлкән булган әле, ә безнең аерма сигез генә яшь.

Бәхәсләшмим, Люция үз урынында Айседорадан бер генә дә ким түгел, ләкин Флүнне Есенин белән ничек чагыштырмак кирәк! Аннары бит шунысын да онытырга ярамый: ничек тәмамланган бит ул Дункан белән Есенин мәхәббәте!

– Яшь мәхәббәт яшәртә ул, – ди иде Люция. – Йосыф гашыйк булгач, Зөләйха өр-яңадан яшәргән бит әнә!

Люциянең теленнән Флүн исеме төшми иде: «Флүнгә кирәк», «Флүн ярата», «Флүн әйтте». Шуннан гына да аның күңеле бик үк тыныч түгеллеген сизеп була иде. Тигез мәхәббәт белән кавышып, тату гомер иткән кешеләр бер-берсенең исемен кирәк-кирәкмәскә талкып кадерсезләмиләр, ул, синең кулың яки аягың булган кебек, яшәвеңнең табигый бер шартына әверелә. Сызламаган әгъза турында күп сөйләмисең, сызлый башласа гына һаман телгә килеп тора ул.

Люция бернәрсәне дә яшерә белми иде, аның Флүн белән булган мөнәсәбәтләрен институтта да яхшы беләләр иде, күрәсең. Болай фаш булу Флүнгә файдага гына иде, ник дисәң, укытучылар, Люциягә ихтирам йөзеннән, аңа билге куйганда, аркылысын-буен кат-кат үлчиләр иде. Кыскасы, көнкүрештә генә түгел, укуда да Люциянең ярдәмен күп күрде егет.

Ул соңгы курсларга җиткәч, Люция аңа шәһәрдәге әйбәт мәктәпләрнең берәрсеннән урын да эзли башлаган иде инде. Күрәсең, киләчәктә бергә тормыш итү турында алар арасында күп сүз булгандыр. Миңа барысын да белү кыен иде, чөнки әлеге 8 Март кичәсеннән соң минем Әсгатем аларга барып «шома егет» белән очрашудан баш тартты, без, гомумән, сирәк очраша торган булдык. Хәер, Люциянең бөтен тормышы Флүн белән мөлдерәмә тулган, аның күңелендә безнең ише дусишләргә урын азайган иде.

Ничек килеп кергән соң ул шома егет Люциянең тормышына, ничек анда шулай иркенләп урнаша алган?

Мин моны соңыннан, берничә еллар узгач кына белдем. Люция аны миңа өзеп-өзеп кенә сөйләде. Алай да, аның һәм теге егетнең холкын белгәнгә күрә, мин бу хәлләрне шактый ачык итеп күз алдына китерә алам.

Флүн китап өстендә күз талдырып, ми черетеп утыра торганнардан түгел, үзе утырган тормыш арбасын такыр юлдан шома гына тәгәрәтү җаен белә, үргә менгән чакта, башкалардан этттерү чарасын табарга да оста иде. Андыйларны очратканым бар минем, бу талант аларга тумыштан бирелә бугай, минемчә, аңа өйрәнү мөмкин түгел. Тик алардан ераграк булсаң иде, алар арбасын этәргә язмасын иде дип теләргә генә кала.

Табигый ки, таләпчән Луциус аңа зачет куймаган. Ике кергән егет, өч кергән – Луциус аны борып чыгара торган: «Укыгыз әле тагын бер кат!» Ниһаять, көтәр көннәр калмаган, деканат студентка шундый шарт куйган: яки син иртәгә зачетыңны тапшыру турында зачеткаңа тамга салдырып киләсең, яисә имтиханнарга кермисең, димәк, институт белән хушлашасың дигән сүз.

Менә шунда инде Флүн беренче тапкыр укытучысының өенә юнәлгән дә. Мөгаен, ул юл буе Луциусның җиде бабасын эттән алып эткә салып сүгеп, каһәрләп баргандыр.

Мин аның ишектән ничек килеп кергәнен бик яхшы күз алдыма китерәм. Оҗмахның бер почмагы кебек ямьле йортны, ул йортта бары бер генә нәрсә – шушы ямьле, якты урында рәхәт чигеп, кадер-хөрмәт эчендә яшәргә бер ир кеше генә җитмәгәнлеген бер караудa чамалап алгандыр ул, мөгаен. Ах, аның астан сөзеп кистереп карап куюлары! Шул карашы белән квартираны гына түгел, өстенә ефәк халат, аягына йомшак башмак кигән, бизәкле келәмнәрдә тавышсыз басып йөргән, ялгызлык кочагында сагышланганы бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан, назга сусап олыгаеп килгән кызны да үз бизмәненә салып үлчәгәндер һәм аның бәһасен шунда ук чамалагандыр ул... Өенә кайткач, Луциус, яудан кайтып, бөтен калкан-кылычларын, тимер күлмәкләрен салган сугышчыга охшап калган. Аның хатын-кыз икәнлеген дә, бәлки, егет шунда, өендә генә күргәндер.

Ул кичне егет күптән зарыккан тамгасы зачеткасына куйдырып чыгып китә.

Китә, ләкин икенче көнне шул ук сәгатьтә тагын килә.

– Гафу итегез, Люция Кадыйровна, мин тагын сезне борчыйм әле. Көн буе вөҗданым тынгы бирмәде. Кичә мин сезгә өчлелек тә җавап бирә алмаган идем. Бүген көн буе китап өстендә утырдым, ул теманы ныгытып укыдым. Рөхсәт итегезче, мин сезгә зачетны яңадан тапшырам. Билге өчен түгел, вөҗданымны тынычландыру өчен...

Луциус бу салам торхан алдында ишекне шартлатып ябып куярга тиеш иде. Әмма ул югалып калган. Бер генә мизгелгә, күз ачып йомарлык бер вакытка гына. Ләкин сугышчан маневрны бөтен нечкәлекләренә кадәр алдан ук уйлап килгән шома егет – ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр фронтында Луциустан чагыштыргысыз зирәгрәк һәм талантлырак Флүн – кызга

аңына килергә ирек бирмәгән. Аны этеп диярлек ишектән кергән, керә-керүгә кочагына алып, иреннәренә үрелгән, ә аннары тезләнеп, аның аякларыннан кочып алган:

– Теләсәгез нишләтегез, тик куып кына чыгармагыз...

Күп спектакльләрдә кабатланган шушы арзанлы кыланыш безнең Луциус дигән кыябызны җимергән дә ташлаган.

Хәер, гаҗәпмени, ул кыя тыштан караганда гына шулай мәгърур күренә, эчтән күптән инде сагыш сулары юган, ялгызлык хәсрәтләре көйдергән иде аны.

Ләкин Луциусның горурлыгы, мин, җимерелгән кыя шикелле, юк җилдән дә ишелеп төштем дип, үзенең көчсезлеген танырга ирек бирми иде. Киресенчә, бу егет үзе минем яулап алган сугышчан хәзинәм дип, үзен дә, башкаларны да ышандырырга кирәк иде аңа. Ул гына да түгел, бу хәзинә минем яулап алуыма лаек иде дип тә исбат итәргә кирәк иде.

Мәгълүм булганча, Луциус Корнелиус Сулла вак-төяк белән булышмаган, Римның үзен яулап алып, анда үз законнарын урнаштырган.

Флүн-шома егет тә бу уенны күтәреп алды. Алар икесе дә спектакль уйныйлар һәм ул спектакль тамашачыларга: «Әйе, болар икесе бергә тигез гомер итеп, бер көнне үләргә һәм бер кабергә ятарга дип кенә дөньяга килгәннәр», – дигән фикерне сеңдерергә тиеш иде. Уйнаучыларның берсе моңа чын күңелдән ышанган иде. Шулхәтле ышанган иде – ул үзе белән уйнаган кешенең гариплеге барын да сизми иде. Дөрес, ул гариплек Квазимододагы яки Мәхдүмдәге кебек тышта түгел, ләкин игътибар беләнрәк караганда, кеше аның эчендә, күңелендә гариплек барын сизәргә тиеш иде. Луциус моны күрмәде, ә бәлки, күрсә дә, төзәтермен әле дип өметләнгәндер.

Ләкин һәр уенның бер чиге була.

Бу тамашаның да ахыры җитеп килә иде.

Мин Яңа елны каршыларга әзерләнеп ятканда, ялгызы безгә килеп керде Люция. Кулында зур гына төргәк, йөнтәс бүреге астыннан бөселеп чыккан бөдрәләрен бәс сарган.

– Син Яңа ел, яңа бәхет көтәсеңдер, ә монда иске дус, иске ваем килде әле, – диде ул.

– Уз, Люция! Ваемнарны бүләрбез – кечерәер, бәхетләрне уртак итәрбез – зураер. Бик дөрес иткәнсең килеп, Яңа елны бергә каршы алырбыз.

– Сез өйдә каршы алмакчымыни?

Әйе, ул кичне без Әсгать белән икәүдән-икәү генә утырмакчы идек. Әни, кызыбызны алып, өлкән апаларга киткән иде – алар анда балалар өчен бәйрәм оештырганнар. Күптән инде бәйрәмнәрне икәүдән-икәү каршы алган юк, яшь чакларны искә төшерик әле, яныбыздагы матур шәһәр чыршысы янына чыгып, бозлы таудан шуарбыз, таган атынырбыз, боз лабиринтында адашып йөрербез, күңел ачып, шау-гөр килгән халык арасында бер тулганырбыз дигән идек. Алай да үзебезгә бер табын әзерләргә кирәк дип, Әсгать кибеткә чыгып киткән иде.

Безнең бу бәйрәмебезгә Люция сыячак иде. Тик теге Флүне генә килә күрмәсен. Кая икән соң әле үзе?

Мин моны сорарга ашыкмадым. Люцияне чишендереп, кухняга кердем, кофе куйдым. Дускаемның йөзе элек ялгызлык сагышларыннан интеккән чакларындагыдан да караңгырак иде, ул суырылган, картаеп киткән иде.

«Егет койрыкны бора башлаган, ахрысы!» – дип уйладым мин, пошаманга төшеп.

Люция Яңа елга күлмәк тектергән икән, шуны күрсәтергә килгән булып чыкты. Кофены юньләп эчеп тормады, залга чыгып, көзге каршына басып, күлмәген киде. Көрәнсу тукымага эре сары тюльпаннар чигелгән иде. Итәк очына да, җиңенә дә. Тегүчесе тәкъдим иткән, быел сары модада, дигән.

Бу күлмәкне тегәргә биргәндә, мөгаен, Люциянең йөзе көләч булгандыр. Ә хәзер аның ямансулыгын көчәйтә генә иде бу сары чәчкәле көрәнсу күлмәк.

– Бөтенләй тегә белми башлады Флера, – диде Люция. – Мин дигәнчә килеп чыкмаган. Картайта.

Хикмәт күлмәктә түгел, Люциянең үзендә иде. Картлык-яшьлек аршынын Флүнгә һәм аның яшьтәш кызларына чамалап үлчәргә кирәк иде аңа. Минем өчен ул һаман яшь, зифа иде, студент чактагыдан бөтенләй үзгәрмәгән дә шикелле иде. Буе-сыны төз, нечкә, муены озын. Тик бөдрәләрендә көмеш җепләр чагылып китә, тик муенында нечкә сырлар хасил булган, елмайганда, күз төпләрендә җыерчыклар пәйда була. Үзе аерым торганда, болар әллә ни сизелми дә, ләкин ул Флүненең күз алдында студентлар белән янәшә тора бит. Янәшә куеп чагыштырып караганда, яшь чамасы бик ачык күренә, аның аңлатып та бетереп булмый торган билгеләре әллә каян үзен белдереп кычкырып тора бит.

Ләкин боларны Люциягә турыдан-туры әйтеп булмый иде. Ул, күлмәген салып, тегүчедән зарлана-зарлана, бил турын сүтә дә башлады. Аннары, эшен ташлап, кинәт башын күтәреп:

– Элек син минем өчен утка керергә әзер идең, Зәйтүнә, хәзер дә шулаймы? – дип сорады.

– Әгәр ул утларда син булсаң, сине алып чыгарга тәмугка да керәм, Люция.

– Юк, бу юлы үзең үк кермәсәң дә була. Кулыңны гына суз миңа.

– Кая, кайсы төшеңнән тотып тартыйм соң?

– Юк, син миңа сузма кулыңны. Телефон трубкасына суз. Шуны ал да менә шушы номер белән шалтырат әле.

– Флүнне сорыйммы?

– Әйе, 45 нче бүлмәдән чакырып китерсеннәр.

«Ә ник үзең шалтыратмыйсың?» дип әйтүдән чак кына тыелып калдым. Билгеле инде ник икәне. Күрәсең, ул анда еш шалтырата торгандыр, студентлар тулай торагында аның тавышын таныйлардыр! Йа Хода, нинди хәлгә төшкән бит безнең мәгърур Луциусыбыз. Улмы бу – бер томана студент артыннан ялынып, кимсенеп йөрүче? Улмы бу – мине дә кимсенергә мәҗбүр итүче?

Мин: «Ташла син шуны, шалтыратма, ялынма!» – дип әйтергә башымны күтәрдем, ләкин аның йөзен күргәч, тел очыма килгән сүзләрне туктаттым: ул миңа күсәк күтәргән хуҗасына караган көчек шикелле куркып, ялварып һәм чарасызлыгын белдереп мөлдерәп карап тора иде. Сугасыларын да белә, тайпыла да алмый... Беркайчан да аның миңа болай караганы юк иде, аның күзләре шулай карарга сәләтле дисәләр, ышанмас идем, билләһи!

– Ярый, – дидем. – Ни әйтим соң?

– Син чакыр гына. Килгәч, үзем сөйләшермен.

45 нче бүлмә өченче катта ук икән. Шактый озак көтәргә туры килде. Люциянең түземсезлеге кайнар сулышыннан ук сизелә иде. Йа Хода, килсен иде бу Флүн телефонга, ни әйтсә дә әйтсен, тик килсен генә иде, болай интектермәсен генә иде Люцияне!

Ниһаять, тек-тек аяк тавышлары ишетелде.

– Флүн өйдә юк, – диде бер кыз тавышы.

Люция бөтен гәүдәсе белән өстәл аша миңа таба сузылды, аның хәленә кереп, мин дә аңа таба үрелдем, телефон трубкасының артын аның колагына терәдем.

– Ә кайда соң ул, кайчан кайта? – дип сорадым.

– Без каян белик. Бер... карчыгы бар бит аның, шунда ятадыр, шунда шалтыратып карагыз.

Тавыш, «карчыгы» сүзенә басым ясап, ничектер мыскыллы сызгыртып әйтте, кемнәрнеңдер хихылдаганы колакка чалынып китте. Мин корт чаккандай артка тайпылдым. Нәрсә дип соң әле бу мыскыллы сүзләрне, көлүне Люциягә тыңлатып торам! Аның җәрәхәтле йөрәгенә тоз сибеп!

Ләкин соң иде инде, Люция барысын да ишеткән иде. Аның йөзе киндердәй агарган, күзләре зур ачылган иде. Ләкин аны тораташка әверелдергән нәрсә аннан көлүләре түгел – кем көлә диген бит әле, Люциянең үз шәкертләре, студентлар көлә! – әйе, үзенең адәм көлкесенә калуы түгел, бөтенләй башка нәрсә булып чыкты.

– Ишеттеңме? Ул анда да юк икән бит! – диде ул, саташкан шикелле. – Әллә берәр нәрсә булды микән? Мин бит аны шунда ята дип уйлыйм, ә иптәшләре миндә дип беләләр. Кешенең кайдалыгын белүче дә юк. Ә бәлки, ул берәр бәхетсезлеккә дучар булып, больницага эләккәндер! Һушсыз ятадыр, авызына су салучы да юктыр! «Скорая помощь»ка шалтыратыйк!

– Ташла, зинһар, – дидем мин. – Ни булсын ул дуңгыз баласына! Берәр компания белән Яңа ел каршыларга йөри торгандыр әле!

– Юк, ул алай итә алмый... – Люция телефонга үрелде.

Минем ачуым чыкты. Диңгездә һаман-һаман косып интеккән кешеләрне каеш белән яралар икән, алар шуннан аякка басалар дип ишеткән бар иде. Ә бәлки, гыйшык бизгәгеннән тилмергәннәргә дә шундыйрак чаралар кирәктер? Учым белән трубканы капладым:

– Шалтыратмыйсың да, нитмисең дә.

Ул калтыранган куллары белән ян җөйләре сүтелгән күлмәген кире киеп куйды. Җиң очларында, итәгендә эре сары чәчкәләр янып тора, йөзендә сары сагыш. Хисләре, хәсрәте бөтен кыяфәтенә шулхәтле аермачык бәреп чыккан иде ки, бу кыяфәтендә аны бәхетсезлекнең образы итеп Академия театры сәхнәсенә менгезеп бастырырга була иде.

– Туктале, нишләп саташып йөрим соң әле мин, – диде ул. – Ул, мөгаен, кайткандыр. Кайткандыр, әлбәттә, мине Яңа ел белән котламыйча кала алмый бит инде ул. Ә мин монда тулганам.

– Килсен, көтсен бераз! Артыңнан ялынып йөрсен, кадерлерәк булырсың, утыр монда гына, – дип үгетләргә тырышсам да, ул минем әйткәннәрне ишетмәде дә шикелле.

Ишектән чыгып киткәндә, миңа таба борылды да:

– Бик бәхетсез килә бу ел минем өчен, – диде.

Кайтып китте Люция, элекке ялгызлык сагышы өстенә тапталган кешелек горурлыгы, кимсетелгән саф хисләре өчен йөрәген көйдерә торган гарьлек утлары өстәлгән квартирасына кайтып китте.

Мәхәббәт җәрәхәтләреннән озак төзәлә йөрәк, ай-һай, озак төзәлә. Ә кайчак ул гомер буе да төзәлеп җитми, һаман сызлап тора. Әгәр дә аны өсте-өстенә җәрәхәтләп торсалар, бигрәк тә. Люция

ул шома егет белән көн саен институтта очрашып тора иде бит, ул аны күрә иде, күргән саен йөрәгендәге ярасы тирәнәя бара иде. Аның ниләр кичергәнен мин күзаллап та бетерә алмыйм.

Бөтен өмет Флүннең тизрәк диплом алып кая да булса эшкә китеп баруында иде.

Ләкин бу өметләр дә акланмады. Ул Казанда, бик яхшы урынга урнашып калды. Бу очракта да ул үзенә җирлекне шул ук өлкәдә – мәхәббәт өлкәсендә тапкан булып чыкты.

Студентларның дәүләт имтиханнары башланыр алдыннан Люция миңа шалтыратты.

– Иртәгә сәгать уникегә загс янына кил әле, – диде.

– Ни бар анда? Әллә кәләшнең иң якын дусты итеп чакырасыңмы мине?

– Килгәч күрерсең.

– Туктале, алай булмый бит, ул-бу булса, матур итеп киенергә, чәчәкләр алырга кирәк...

– Киенмә дә, әзерләнмә дә. Карап кына торырсың.

– Тамашачы булыпмы?

– Әйе, шул чама.

Шулай диде дә, мине тәмам аптырашта калдырып, чылт итеп трубканы куйды бу.

Люциянең сүзен аяк астына салып булмый – мин нәкъ билгеләнгән сәгатькә загс каршындагы киоск янында басып тора идем инде. Кояшлы җәй башы, шимбә көн, загс тирәсендә бизәлгән машиналар тора, ак күлмәкле кәләшләр белән кара костюмлы кияүләр тирәсендә төркем-төркем булып киенешкән-ясанышкан шат күңелле кешеләр йөри.

Күңелне дулкынландыра торган булса да, загс янында гадәти күренеш. Нигә дип чакырды икән мине Люция?

Әһә, менә ник икән. Бер-бер артлы дүрт-биш машина килеп туктады, алдагысыннан безнең танышыбыз Флүн төште. Кара костюм, ак күлмәктән. Менә ул, билен бөгеп, машинадан чыгып килгән озын ак күлмәкле кәләшкә кулын сузды. Тулып пешкән иреннәрен чак кына ачып, дулкынланып елмая иде кәләш, яшь иде ул, чибәр иде, аның Флүнгә төбәлгән йөзендә ярату гына түгел, Аллага табынгандай олылау балкый иде.

Аларны шунда ук башка машиналардан төшкән кешеләр әйләндереп алдылар. Матур киенгәнлеге, ирләрнең башларын горур тотуы белән бу төркем хәтта загс янында да аерылып тора иде. Күрәсең, чибәрлеге, яшьлеге өстенә кәләшкәйнең башка өстенлекләре дә бар иде.

Мин киоск артыннан алгарак чыктым. Нишләр икән шома егет таныш кешене күргәч?

Ул мине күрде, ак йөзеннән күләгә узгандай булды. Ләкин ул күләгәне мин генә сизеп калдым, кәләш йөзеннән балкыган кояш яктысында күләгә шунда ук юкка чыкты. Ул кәләшенең җирдән сөйрәлеп барган челтәр бөркәнчеген төзәтеп куйды, аның кулындагы ак гладиолусларга кагылмаска тырышып, култыклап алды. Алар загсның биек ишегеннән кереп киттеләр. Тантаналы марш көенә бизәкле келәмнәрдән атларга, үзләрен котларга махсус киенеп килгән могтәбәр кешеләрнең изге теләкләрен тыңларга, кадер-хөрмәт күрергә, балдак алышырга, үбешергә, мәңге бергә булырбыз дип ант итәргә кереп киттеләр.

Шунда миндә бер теләк туды: йөгереп керәсе иде дә, бөтен кеше каршына басып, туктагыз, сез нишлисез, кемне тәбриклисез, кемне котлыйсыз, ул бит хыянәтче, алдакчы, ул үз йөрәген сатучы, башкаларның хисләрен аяк астына салып таптаучы дип әйтәсе иде. Ни булыр иде икән? Хәер, андагылар, Флүнгә ияреп тантана залына кереп китүчеләр, аның кемлеген моңарчы белмиләр идемени? Нишләп белмәсеннәр! Бөтен институтка фаш иде бит ул хәл! Аннары төркем арасында да бер-ике таныш чырай чалынып китте әле. Люциянең танышлары... Яшь парны котларга килгәннәр...

Менә мин олыгаеп килəм инде, әмма бер нәрсәне һич кенә дә башыма сыйдыра алмыйм – ул да булса мәхәббәт өлкәсендә хыянәтнең, ялганның, мәрхәмәтсезлекнең, шәфкатьсезлекнең бернинди җәзасыз калуын.

Әйтик, әгәр син берәрсенең тәнен җәрәхәтләсәң яисә йөзенә төкерсәң, яки яман сүз әйтсәң, йөз сум акчасын алсаң – сине хөкем итәчәкләр, суд каршына бастырачаклар, прокурор гаепләячәк, адвокат яклау чарасын эзләячәк, аннары гадел дип табылган җәзаны бирәчәкләр. Анысы бер хәл, әгәр дә син алда санап кителгәннәрнең берсен генә эшләсәң дә, башкалар сине начар кеше, җинаятьче дип саначаклар.

Ә менә берәүнең иң изге йөрәк хисләрен, иң якты өметләрен, хыялларын, ышанычын урлаган, аны алдаган, күңеленә төкергән, газап утларында янган йөрәген аяк астына салып таптаган өчен бернинди суд та, җәза да юк. Киресенчә, мәхәббәттә шул рәвешле җинаять кылып йөрүчеләр үзләрен хаклы, хәтта башкалардан өстен саныйлар, саф хисләргә, тугрылыкка ышанганнарга көлеп кенә карыйлар. Күпме саф йөрәкләр, шундыйларның итеге астында таптавып, әкренләп ташка әверелә!

Саф сөю дөньясында мәхәббәт алласына табынган кешеләр хаксызга җәзалана, бернинди яклаусыз, чарасыз һәлак ителә. Закон да, суд та, прокурор да, яклаучы да, гадел хөкем дә юк анда! Җинаятьчеләр, таш бәгырьләр хөкем сөрә анда!

Әнә аларның берсе – шат чырайлы кешеләр төркеме уртасында, мәхәббәт алласының изгелегенә инанган кешеләр генә атлап керергә тиешле ишектән яшь, чибәр, гөнаһсыз, ышанучан, үзенә гашыйк бер җанны кулына күтәреп чыгып килә. Ниләр язган икән мескен кыз балага ул кеше кулларыннан күрергә? Ә кыз әнә ничек ышанган аңа, ак перчатка кигән куллары белән хыянәтче муенына ничек елмаеп сарылган, нурлы йөзе шатлыктан ничек балкый! Белми шул ул, белми язмышын кемгә тапшырганын!

Тукта, нинди күләгә төште соң әле аның йөзенә? Күзләре ни өчен болай куркынып ачылды, йөзе нигә болай агарынды? Шома егет тә аптырап калды, кәләшен кулыннан ук төшерде...

Мин артыма борылып карадым. Тротуар кырыена тасмасыз, шарсыз һәм бизәлгән машиналар арасында шәп-шәрә булып тоелган кап-кара «Волга» килеп туктаган иде. Машина ишеге ачылып китте дә... аннан бер хатын... хатын түгел, тере күләгә килеп чыкты. Аның елтыр-елтыр килеп торган кара күлмәк итәге җирдән сөйрәлә, башындагы кара эшләпәсеннән төшкән кара челтәр, битен каплап, артыннан җилфердәп килә, кара перчатка кигән озын бармаклы кулларында кара тасма белән бәйләнгән сап-сары янып торган тюльпаннар... Загс янында түгел иде бу күләгәнең урыны, зиратта булырга тиеш ул, ничек ялгышып, саташып монда килеп чыккан, нигә ул тораташ булып биек ишек янында катып калган төркемгә таба бара? Атлап та бармый, шуыша кебек, тере кеше түгел, фаҗиганең, бәхетсезлекнең, үлемнең бер символы иде ул.

Беркем бернишләргә, ни булганын аңларга өлгермәде. Тере күләгә яшь пар каршына килеп җитте дә кулындагы бәйләмен кәләшнең аяк астына ташлады. Сары чәчәкләр, сары ялкын кебек, ак күлмәктән шуышып җиргә яттылар, күмер төсле кара ефәк тасма җилфердәде. Кәләш, ах итеп, Флүннең кочагына ауды.

Флүн кәләшен тоткан, үзе ялтыравык кара ботинкасы белән тюльпаннарга тибә, аларны читкә этәрергә азаплана, ә чәчкәләр типкән саен авыртудан сискәнгәндәй тетрәнәләр, алтын кыңгыраулар шикелле сыкранып зыңгылдау авазы бирәләр иде шикелле...

Күләгә кебек сын, ашыкмыйча шуышып, кире машинага таба китте.

Ни гаҗәпләнгән булсам да, мин аның күлмәге бик кыйбат тукымадан, искиткеч оста тегелгән икәнен күрми кала алмадым. Шаккатырлык матур, төз иде бу сын, шул ук вакытта өнсез калдырырлык шомлы иде. Әгәр мәхәббәт дөньясында фаҗигане һәм җинаятьне билгеләүче фәрештә булса, ул шундый булырга тиеш иде.

Менә ул салмак хәрәкәт белән машинага кереп утырды. Хәзер инде кара «Волга», зур тизлек белән урыныннан кузгалып, кешеләр аңына килгәнче, күздән югалырга, ә кара фәрештәнең биредә булганын раслап, бары тик сары тюльпаннар гына калырга тиеш иде.

Ләкин барысы да син теләгәнчә килеп чыкмый шул. Чаттагы светофор, кызыл күзен кабызып, машинаның юлын кисте, ул арада ишек төбендәге төркемнән берничә ир аңнарына килеп машинага таба йөгерделәр, ишегенә үк барып тотындылар.

Мин, ашыгып, алар артыннан киттем. Каты кычкырып:

– Рөхсәт итегез! – дидем.

Алар көтелмәгән тавышка борылып карадылар. Мин аларны аралап, машина ишеген ачып кереп тә утырдым, шоферга «Кузгал!» дидем, светофор ягымлы итеп яшел күзе белән карап тора иде инде.

Мин кара күлмәк итәгендә калтыранып яткан кулдан кара перчатканы салдырып, нечкә салкын бармакларны кайнар учымда җылытырга тырышып кыстым.

Ах, Люция, Люция, Луциус Корнелиус! «Юкка гына ясадың син бу театрны» дидем мин аңа эчемнән генә. «Синең бу театрың шулкадәр шаккатырлык булды ки, аны күпләр гыйбрәт итеп сөйләрләр, студентлар арасында курстан курска, авыздан авызга күчеп сүз йөрер: «Ә-ә, бу шулмыни? Кара киенеп, кәләш аяк астына сары чәчкәләр ыргыткан хатынмыни?»

Кәләш аяк астына салмадың син ул чәчкәләрне, яхшы исемең күмелгән кабергә салдың! Шулай ук ярата идеңмени соң син аны, Люциякәй, аны югалту намуслы исемеңне югалтудан да ачыракмыни соң?

Без шактый вакыт сөйләшмәдек. Люция битендәге челтәрен күтәрмәде, хәтта минем алда да ачылырга теләмәде. Авызын ачып сүз әйтсә, елап җибәрәчәк иде ул. Бу нәрсә аның роленә сыймый иде – кабер фәрештәсе елый димени?

Ниһаять, ул, бар көчен җыеп, сөйли алыр хәлгә килде бугай:

– Ә син кая барасың? – дип сорады.

– Синең белән, Люция. Зиратка чәчәкләр салып кайткач, искә алу мәҗлесе булырга тиеш бит инде. Беләсеңме, искә алу мәҗлесе ничек дип атала? Атау дип атала ул. Без синең белән атау уздырырбыз. Аннары шунда ук өчесен дә, җидесен дә, кырыгын да, еллыгын да берьюлы үткәрербез. Бүген, менә хәзер. Шундый итеп үткәрербез, бүген син чәчәк салган каберне җиде кышның карлары каплап, җиде язның сулары югандай булсын.

...Кемдер минем кулыма орынды. Троллейбуста миңа каршы утырган күзлекле апа икән.

– Алыгыз сез дә бераз, – дип, миңа тюльпаннар сузды ул. – Алыгыз, матур бит.

– Юк, юк, рәхмәт, – дидем мин. – Гафу итегез, сары тюльпаннар бик авыр хәлләрне исемә төшерә минем...

*1980*

## Көндәшләр

Мин матурлыкның һәм яратуның ниндилеген унике яшемнән беләм.

Матурлык – Әкълимә апа төсле була.

Ярату – Заһир абый кебек була.

Заһир абый безнең Тарагыш авылында мәгълүм егет иде. Ул атка менеп урам буйлап чабып узганда, кем генә сокланып карап калмады икән! Ак тулпар, озын ялын җилпеп, муенын алга сузып, борын тишекләрен киңәйтеп очып бара, тоякларын такыр юлга тупырдау авазлары чыгару өчен генә бәреп ала сыман тоела иде. Ак күлмәк кигән җайдак аяклары белән тулпарга береккән, аның белән бер көйгә талпына... Мәктәп дәреслекләрендә кентавр сурәтен күргәч, мин Заһир абыйны искә төшердем: ул да бит аты белән бер җан, бер тән булып тоела иде.

Аның кебек ак айгырга атланып, Тарагыш урамнарын дер селкетеп чабып узу турында кайсы гына малай хыялланмады икән? Төшләргә керә иде ул тулпар, саташтыра иде.

Табигый инде, без, малайлар, тоз суы сипкәндәй, янгын сарае тирәсендә чуала торган идек. Тын алырга да куркып, хәлебез китеп, Заһир абыйның берсе ак, икенчесе алмачуар ике айгырны ашатканын, тазартканын, иярләгәнен ачык капкадан карап торабыз, бер-беребезгә ул атлар турында өлкәннәрдән ишеткәннәребезне сөйлибез. Имеш, узган кышны ак айгыр чанасы-ние, чанадагы председателе белән бергә тимер юл шлагбаумы аркылы сикереп чыккан. Имеш, язын ул җимерелеп барган күпер аша очып үткән... Җиргә карап йөри белми иде ул тулпар, йолдыз санап кына йөри иде. Озын, сөякчел башын бары тик Заһир абыйның иңенә аның шыпырт тавыш белән назлап дәшкәнен ишетер өчен генә ия иде ул.

Без атларга читтән генә карап торуны да зур бәхеткә саныйбыз, ләкин анысы да күп эләкми.

Заһир абый:

– Барыгыд, бар, өйләрегедгә кайтыгыд, аналарыгыдны аптыратмагыд, – дип, сарайның агач сырлар белән бизәлгән капкасын ябып куя торган иде.

Безгә, борын тишекләребезне киңәйтеп, һәр егет өчен алыштыргысыз татлы исне – ат тире һәм тирес исен, башак исен иснәргә генә кала иде.

Шулай ук сарай янындагы келәткә дә кертми иде ул безне – ә анда агач эшкәртү өчен киң озын өстәл тора һәм әллә нинди хикмәтле эш кораллары саклана иде. Заһир абый келәттә сбруйлар рәтли, челтәрле кәрнизләр, рамнар ясый – ул тирә-юньдә дан тоткан балта остасы иде. Эшкә тотынса, безнең барлыгыбызны да онытa, Фидан Гаффаров тавышына охшаган аһәң белән әкрен генә җыр суза:

Агыйдел сулары кебек
Тар сулар булмас инде.
Минем йөрәккәем кебек
Ярсулар булмас инде, –

дип җырлый ул. Һәм карашын безнең баш өстеннән әллә кая, еракка төби. Шундый кызыксынып, озаклап карый, әйтерсең лә бик кирәк, бик кадерле нәрсә күрә. Мин түзмим, ул караган тарафка күз салам, ләкин саргаеп килгән урман-тугайдан башка нәрсә күрмим. Тугаеның – юасы, урманының җиләге-чикләвеге күптән беткән, Агыйделдә коеныр чак үткән... Ни күрә иде икән анда Заһир абый?

Шулай берзаман аптырап, Агыйдел аръягына карап торганда, Заһир абыйның дәшкәнен ишетеп сискәнеп киттем мин.

– Давыт, син дә мондамыни? Кер әле, – диде ул.

Мин кыюсыз гына келәт эченә атладым. Башка малайлар да минем арттан иярмәкчеләр иде, Заһир абый аларны:

– Ә седне кем чакырды? – дип тиз туктатты. Миңа исә: – Әнә теге пычакны алып бир әле, – диде.

Шул көннән мин Заһир абый янында үз кеше булып киттем. Келәттә аңа такта башы тотышам, сарайда атларга башак болгатышам. Кайчак Алмачуарга атланып йөрим. Билгеле инде, үземнең дә Заһир абыйга яхшылык эшлисем килә.

Әз генә булса да аның күңелен күрим дип, мин беркөнне клубта ишеткән сүзләрне аңа җиткердем.

Ә клубта Әкълимә апа аның турында бик матур сүз әйтте. Анда гадәттәге күңел ачу бара иде. Билгеле инде, безнең ише мәктәп балаларына клубка керергә рөхсәт ителми. Укытучылар күреп калса, икенче көнне бөтен фәннәрдән сорап үзәгеңә үтәчәкләр, җавабыңны аз гына ялгышсаң да: «Уку кайгысы качкан шул инде синнән, клубта кызлар күзләү кайгысы гына калган», – дип, бөтен

класс алдында көлкегә калдырачаклар. Алай да без, өлкән егетләрнең бот араларына кысылып булса да, анда үтәргә тырышабыз, авыз суыбызны корытып, яшьләрнең бишле-сигезле, түгәрәк уен уйнаганнарын карап торабыз.

Ул көзне мин укытучылардан бик шүрләми башладым. Ни өчен дисәгез, бездә фатирда Әкълимә исемле укытучы тора, ул миңа клубка чыккан өчен сүз әйтми, киресенчә, уеннар беткәч, үзе белән алып кайта иде. Клубта да мин аның янынарак елышам. Шулай бер кичне ул кызлар белән сөйләшеп тора иде, ишектән Заһир абый килеп керде. Кызлар көлешеп алдылар: «Ут кечерәйдеме әллә дип торам, кара-чутыр кереп караңгылаган икән!», «Ну хәзер кәкре аягы белән тып итеп бер басса, идән сайгаклары бөгелеп төшә инде!» Авыл кызлары Заһир абыйга үч саклыйлар, чөнки ул аларның берсенә дә карамый иде. Кызлар көлгән булдылар, әмма Әкълимә апа көлмәде: «Заһир – чын егет ул! – диде. – Аяклары да чын егетләрчә – атта йөрергә күнеккән баһадир аягы!» «Кара-кара, яклаган була, әллә кара-чутыр синең йөрәгеңә утлы кисәү салдымы?» – дип телләште кызларның берсе. Тик моңа әһәмият бирүче булмады, чөнки һәркемгә мәгълүм: Әкълимә апа артыннан Богады авылының Әхнәф исемле арык гәүдәле, караңгы чырайлы егет йөри, әнә ул сәхнә кырыена таянып утырган да йөзен гел Әкълимә апа артыннан борып йөртә – озын борынын аңа бәйләп куйганнармыни! Юкка карый акай күзләре белән ашардай итеп, барыбер мин аннан Әкълимә апаны озаттырмыйм, барыбер араларына керәм! Төрткәләсә дә, чеметкәләсә дә: «Бар-бар, балаларга күптән йокларга вакыт!» – дип куса да, яннарыннан китмим. Үземнең дә китәсем килми, Әкълимә апа да кушмый.

Икенче көнне мин Заһир абыйга Әкълимә апаның аны ничек яклаганын сөйләп бирдем.

Заһир абый мине сулыш та алмыйча, тынып, башын иеп тыңлады. Ә иртәгесен минем кулыма нарат сагызы төсле куе, сары җилем белән ябыштырылган конверт тоттырды.

– Әкълимә апаңа бирерсең, – диде, читкә карап.

Мин конвертны теләр-теләмәс кенә алдым. Дөресен генә әйткәндә, бездә фатирда торган ике ай эчендә мин Әкълимә апаны тәмам үземнеке итеп бетергән идем һәм аның егетләр белән, хәтта Заһир абый белән дә йөрүен теләми идем. Армиядәге егетеннән атнасына ике-өч хат килә бит! Килә! Шул бик җиткән.

Хәзергә хәтле Әкълимә апа минем күңелемдә дөньядагы кызларның иң чибәре булып саклана. Дөрес, мин аның төс-битен, кыяфәтен тасвирлап бирә алмыйм, бары тик түгәрәк йөзле, озын коңгырт толымлы икәнен генә әйтә алам. Тәнәфестә өлкән класс кызларының: «Шундый толым буламыни, ялгаган ул аны, ялгаган!» – дип гайбәт сатып торганнарын ишеткән бар иде. Көнләшкәннәрдер инде, Әкълимә апа алардан нибары ике-өч яшькә өлкән булып, безгә педучилище тәмамлап кына килгән иде бит. Кызларның гайбәте аның колагына да барып ирешкән булса кирәк, шуннан соң ул, толымнарын тыгызлап үрмичә, аннан-моннан чалыштырып кына аркасына сала торган итте. Карагыз, күрегез, бер генә ялгаган җире дә юк!

Ләкин Әкълимә апаның матурлыгы толымында түгел, йөзендә, якты күз карашында, йомшак тавышында, ягымлы сүзендә иде. Ул, бер тутырып карап: «Җиткән егет бит инде син!» – дисә, үсеп-зураеп, гайрәтләнеп киткәндәй буласың, үзеңне яхшы кеше итеп сизәсең. Каядыр барасы, кемгәдер яхшылык эшлисе килә башлый.

Менә шул Әкълимә апага тапшырырга тиеш идем инде мин Заһир абыйның хатын.

Мин кайтып кергәндә, ул дәфтәр тикшереп утыра иде. Кулымдагы конвертны күрүгә, урыныннан сикереп торды, ләкин хатны кулына алгач һәм тышында язу-фәлән юклыгын күргәч, хатның армиядәге егетеннән түгеллеген белеп, йөзе сүрелде, гаҗәпләнеп, миннән:

– Кем бирде моны? – дип сорады.

– Кем булсын... Заһир абый...

Әкълимә апа конвертны миңа сузды да, җитди итеп:

– Кире үзенә илтеп бир, – диде. – Йомышы булса, мәктәпкә килсен, шунда сөйләшербез, дип әйтеп әйтте Әкълимә апа, диген.

Мин хатны алдым да ишегалдына чыгып киттем. Иң беренче хисем – канәгатьлек булды. Менә шундый ул безнең Әкълимә апа, егетләр хат язган дип бер дә исе китеп тормый!

Ләкин шунда ук күңелемә пошаман төште: ни йөзем белән бу хатны ачылмаган да килеш Заһир абыйга кире илтеп бирермен дип уйлый башладым. Тирләгән кулым белән кесәдәге конвертны әвәлим дә әвәлим, нишләргә дә белгән юк. Янып торган мичтән идәнгә утлы күмер чәчрәп төшсә дә шулай була бит: идәндә яткырырга ярамый – яндыра, тотарга тиз генә соскысы йә кыскычы табылмый, кул белән дә тотып булмый... Минем өчен шундый утлы күмергә әйләнде бит бу нарат сагызы белән ябыштырылган конверт!

Шулай да ни язды икән аңа Заһир абый?

Гөнаһым зур – сабыр итә алмадым, болдыр артына чыктым да конвертны шартлатып ерттым. Аның эченнән шакмаклы дәфтәр бите килеп чыкты. Почмакларына истәлек дәфтәрендәге төсле иттереп чәчкәләр төшерелгән, уртасына җыру язылган:

Агыйделнең пароходы,
Еракка җитә уты.
Сине уйламый үтә микән
Сәгатьнең бер минуты.

Атларымны дагаладым,
Дагалары каралтын.
Их, дускаем, син белмисең,
Эчләрем тулы ялкын.

Ахырдан «Сине чиксез хөрмәт итүче З.» дип куелган. Укып та чыктым мин бу хатны, шаркылдап көлеп тә җибәрдем. Җә, ни дип язган инде бу җыруларны Заһир абый? Әкълимә апа шуларны да белми дип уйлады микән әллә?

Ләкин хатны тагын бер тапкыр укып чыккач, авызым җыелды, мин, кара күмер өемен актарып, аның астындагы утны күргәндәй булдым. Тикмәгә генә язмаган иде Заһир абый боларны!

Кире өйгә кердем дә хатны Әкълимә апаның каршына, дәфтәрләр өстенә илтеп салдым. Нишләр микән, минем шикелле шаркылдап көләрме-юкмы?

Ул көлмәде, язуны бик җитди кыяфәт белән укып чыкты, иң ахырдагы «З» хәрефен калын итеп кызыл кара белән «Д»га төзәтте дә, миңа карап:

– Нишләдең син, Давыт? – диде. – Синең исемең «Завыт» түгел бит, ул язганда да «Д» белән, «Давыт» дип языла, – диде.

Хикмәт шунда, безнең якта, «З» авазын саңгыраулатып, «бед бадарга барабыд» дип сөйләшәләр. Мәктәптә исә сүзләрне әдәбиләштереп, кагыйдә буенча язарга кушалар иде. Шуның аркасында төрле буталчыклыклар килеп чыга, кайда «З», кайда «Д» куярга белми аптырап бетәсең.

«З» кушып сөйләшү безнең авылда кыланчыклык булып санала, арттырып җибәргәннәр исә бөтенләй адәм көлкесенә кала иде.

Ләкин бу юлы мин Әкълимә апага мине наданлыкта һәм кыланчыклыкта гаепләгәне өчен түгел, Заһир абый өчен рәнҗедем. Әле генә аңа хатның кемнән икәнен әйттем бит, инде онытып та куйган!

Кызарынып-бүртенеп:

– «Д» түгел ул «З» – «Заһир», – дидем.

Әкълимә апаның каләме хәрәкәтсез калды, ул хатка бер үрелде, бер кулын кире алды. Почмакларына чәчкәләр төшерелгән шакмаклы дәфтәр бите аңа да утлы күмер булып тоелды, ахрысы.

– Син, Давыт, моннан ары болай итмә, – диде ул, ниһаять, миңа борылып. – Почтальон китергән хатларны гына бир миңа, ә мондыйларны берәүдән дә алма, апа кушмый, диген! Җиткән егет бит инде син, аңларга тиеш!

Иртәгесен Заһир абый мине кара күз төпләрендә көйрәгән ут белән бәгыремне көйдергәндәй итеп каршы алды. Мин тизрәк Алмачуар артына постым.

– Әкълимә апаң бер-бер сүд әйтмәдеме? – дигән кыюсыз гына тавыш ишеттем мин.

– Әйтмәде...

– Хатка җавап та бирмәдемени?

– Җавап кирәк иемени?

Заһир абый тынып калды.

Без, аның белән янәшә утырып, чи тиредән унике чатлап икебезгә ике камчы үрдек. Борынгыча иттереп, бөтен шартын туры китереп.

– Салават батырның камчысы шушындый булган, – диде Заһир абый. – Уфадагы Салават Юлаев һәйкәлен беләсеңме? Аның кулында кылыч түгел, камчы бит! Яхшы камчы үткен кылыч кебек көчле корал ул, чын егет аны кулыннан төшерми, үлгәндә дә дошманына бирми.

Бу сүзләрне мин күңел түремә салып куйдым, камчымны гел үзем белән йөртергә тырыша идем. Заһир абый сөян агачыннан сырлап-бизәп рам ясады, аңа көзге куйды.

– Моны өегедгә алып кайт, яратсалар, түргә элсеннәр, – диде.

«Яратсалар» дип күплектә әйтсә дә, бүләкнең Әкълимә апага икәнлеге көн кебек ачык иде. Ләкин көзгене Әкълимә ападан алда минем әнкәй күтәреп алды:

– И-и, оста да инде шул Даһир! – диде. – Кулы алтын, күңеле җәүһәр шул егетнең! Карале, улым, җайлап кына әйт әле, тәрәдә яңаклары какшаган, бер килеп рәтләп китмәс микән?

Шуннан соң Заһир абый, сирәк кенә булса да, безгә килеп ишек-тәрәзәләрне, абзар-кура тирәләрен рәтли торган булды. Ирсез йортта какшаган җир һаман табылып тора – әткәй вафат булганга дүрт ел иде бит инде...

Әнкәй Заһир абыйны кояш чыккандай балкып каршы ала, ул килеп керүгә, мине Нәфикъ чишмәсенә суга җибәрә иде. Заһир абый исә әрсезләнми, бәясен төшерми, Әкълимә апа кайтып керсә, самоварны көтеп тормый, чиләктән чумырып салкын су эчә дә чыгып китә иде.

– Бигрәк кыюсыд инде бу Даһир! – дип карап кала иде әнкәй аның артыннан. – Син дә, Әкълимә, шунда кыстамадың, әйдә, бергәләп чәй эчик дип әйтергә телеңне жәлләдең. Синең бер сүдеңне генә көткән ие ул!

– Әй, Мәрхәбә апа, бер сүз әйтсәң, әллә нигә өметләнер кеше!

– Өметләнсә ни! Седнең икегеднең дә яхшыдан-яхшыга өметләнер чагыгыд!

– Минем яраткан кешем бар бит, Мәрхәбә апа, вәгъдә биргән ярым бар!

– Яшь чакта вәгъдә бирешү дә, ташлашу да гаеп түгел, яшь чак – яр сайлар чак, – дип, Әкълимә апага каршы төшә әнкәй. – Янәшә куеп сайлый башласаң, шул Даһирдан яхшысы булмас ие әле!

– Яхшы кешеләр күп ул дөньяда, җан сөйгән яр бер генә! – дип, аның авызын каплый Әкълимә апа. Шаярып-көлеп җырлап та бирә:

Агыйделнең пароходы
Җиталмый Кызыл Ярга.
Җиталмый, дуслар, җиталмый
Яратып сөйгән ярга.

– Кара аны, егетнең асылына кул селтәп, Богады Әхнәфенә барып каба күрмә тагы! – дип куркыта аны әнкәй.

– Ничек башыңа килә, Мәрхәбә апа! Мескен ул Әхнәф, гел чәүкә баласы төсле инде, борыныннан тотсаң, җаны чыгар! – дип көлә Әкълимә апа.

– Одын борынлы егетләр усал була алар, беднең Даһир ише түгел! – ди әнкәй.

Аның сүзе хакка чыкты, озакламый Әхнәф үзенең кемлеген күрсәтте.

Ләкин аңа хәтле безгә аның үзе белән түгел, Богадыдан хатын алып, Әхнәфкә кода булган Вәкил белән бәрелешергә туры килде.

Яз җитәрәк булды бу хәл, Әкълимә апа, барлык укытучылар кебек үк, фермада, ындыр табагында агитатор булып йөри иде. Беркөнне әнкәй мине ындыр табагына, Әкълимә апаны төшке ашка чакырырга җибәрде. Мин, гадәтемчә, камчымны калдырмадым.

Кояшлы көннән рига күләгәсенә кереп, күзем бераз күнегүгә, сулышым кысылып, баскан урынымда катып калдым. Богады кияве Вәкил Әкълимә апаның толымын беләгенә урап тоткан да:

– Абыем-җаныем, дип әйт, бер суырып үбәм, дип ант ит! Вәкил җаный, диген! – дип кабатлый.

Башы җайсыз каерылган, йөзе кызарынган Әкълимә апа, еларга җитешеп:

– Вәкил абый, зинһар, азаплама! – дип ялына.

Минем беркайчан да Әкълимә апаны мондый кызганыч хәлдә күргәнем юк иде әле. Ә ялга туктаган хатыннар көшел өстенә утырганнар да бу хәлне авыз ерып тамаша кылалар. Безнең авылда яңа өйләнгән яшь иргә кызлар белән шаяргалап алу гөнаһ саналмый. Башка берәү булса, минем дә ис китмәс иде, ләкин бу юлы йөрәгем күкрәк читлеген тишеп чыгардай булып ярсыды, нишләгәнемне белмичә:

– Җибәр хәзер үк! – дип кычкырганымны сизми дә калдым.

Вәкил исә Әкълимә апаның чәчен тагын да ныграк тартты:

– Яле, җаныем, диген әле бер генә!

– Җибәр, диләр сиңа! – дидем мин, якын ук килеп.

– Хәзер, көчек, сиңа да өлеш чыгар! – дип ысылдады Вәкил, миңа башын да бормыйча гына.

Мин, Заһир абыйдан өйрәнгән кискен хәрәкәт белән селтәнеп, кистереп, камчым белән аның беләгенә сыдырдым. Вәкил, яман тавыш белән акырып, миңа ташланды. Ләкин кая, аны җиткереп тораммы соң! Ригадан чыгып сыпырганда, мин хатыннарның көшелдән сикерешеп торганын, Әкълимә апаның чәч төзәткәнен күреп алдым.

Өйгә кайткач, Әкълимә апа:

– Давыт, олы кешегә кул күтәрергә ярамый алай! —диде. – Җиткән егет бит инде син, тәртипле булырга кирәк!

– Ә ул миңа көчек дип акырса да ярыймы? Кешене мыскыл итсә дә ярыймы?

Әкълимә апа, иренен тешләп, башын түбән иде:

– Рәхмәт инде сиңа... – диде. – Ләкин бүтән алай итмә!

Мин аның сүзен тыңларга тырыштым: Вәкилне күрүгә, урамның икенче ягына чыга торган иттем. Үзем аны күрмәгән булып кыланам, сызгырынам, камчы шартлатам. Ачудан күзләре ялт та йолт итә тегенең, тик килеп якадан алырга батырлыгы җитми.

Әмма бер кичке эңгер-меңгердә чамаламыйрак калдым, тыкрыктан борылуыма каршыма килеп тә чыкты, уң беләгемнән эләктереп тә алды ул мине.

– Каптың бит, малай актыгы!

Тик мин камчымны сул кулга күчереп өлгергән идем инде. Заһир абыйның «Егет кеше үлгәндә дә коралны кулыннан төшерми!» дигән сүзе истә иде шул, истә иде! Шулай кара-каршы басып калдык без: Вәкил минем беләктән умырып тоткан, мин, артка каерылып, сул кулымда камчы

уйнаткалыйм. Әллә шул камчыдан шүрләде бу, әллә кәефе шәп чакка туры килдем, мине кыйнарга тотынмады, йөземә иелеп, мыскыллап көлде дә:

– Кайда синең тәти апаң, ә? – диде. Аның авызыннан сасы аракы исе аңкый иде. – Тү-тү бит тәти апаң! Толымнары белән кулларын урап озаттык без аны! Кияү куенына керә бүген тәти апаң! Ха-ха!.. – Ул шаркылдап көлеп җибәрде, мин бар көчемә тартылып аннан ычкындым да өйгә таба йөгердем.

– Әкълимә апа кайда? – дип кычкырдым, ишекне ачуга.

– Ни булды? – дип, кече яктан башын сузды әнкәй. – Кайтмады әле Әкълимә апаң, мәктәптә берәр эше чыккандыр.

Мин, ут чыккандай ашыгып, янгын сараена чаптым. Заһир абый китеп өлгермәгән, сарай капкасын бикләп азаплана иде.

– Әкълимә апа... Богады Әхнәфе... Урлаганнар... – дидем, сулышыма кабып.

Ул сарай капкасын ачып җибәрде дә ак айгырга барып ябышты, миңа:

– Ни карап торасың, иярлә Алмачуарны! – дип кычкырды.

Бер минуттан без, авыл урамын дер селкетеп, Агыйделгә таба оча идек инде.

Елга аша турыдан барганда, Богады бездән өч кенә чакрым. Ләкин хәзер юл өзек чак, ташу вакыты, анда, алты чакрымнан әйләнеп, Әрҗәндәге таш күпер аркылы йөриләр. Баштарак мин кая чапканыбызны чамаламыйчарак калдым, бар теләгем: ак айгырдан калышмау иде. Караңгыда каралып, күңелне шомландырып җәелеп яткан елга ярына килеп баскач кына, Заһир абыйның турыдан барганын аңладым. Әнә ул атына камчы белән сукты, әнә ак айгыр, пошкырып, кара упкынга ташланды, әнә күздән юк булды. Баттылар, харап булдылар... Минем йөрәгемә ташу суының салкыны үтеп кергәндәй булды. Ләкин, юк, батмаганнар, әнә әчтәрәк ак тап күренде, ат пошкырганы ишетелде. Алар аргы якка таба йөзеп киттеләр. Ә миңа хәзер нишләргә? Бозлы суга чумаргамы? Әгәр калкып чыга алмасам? Алмачуар ак айгыр түгел, мин Заһир абый түгел... Харап кына булырбыз... Алмачуар яр читендә таптанды, аның да суга сикерәсе килми иде...

«Борылырга кирәк, – дигән уй үтте баштан. – Анда барып мин нишли алам? Заһир абый баргач бик җиткән...» Кире китү теләге шундый көчле иде, хәтта ниндидер бер гайрәт иясе күлмәк чабуымнан артка таба тарта иде шикелле. Әгәр шул көчкә буйсынып кире киткән булсам, мин, мөгаен, бөтенләй бүтән кешегә әйләнер идем, язмышым да башкача булыр иде. Бәхеткә каршы, бер хис мине коткарды, ул хис оялу иде. Иртәгә Заһир абый күзенә ни йөзем белән күренермен? Шушы уй миңа тәвәккәллек бирде. Күзләремне чытырдатып йомдым да, бар көчемә селтәнеп, камчым белән Алмачуарның янтыгына сыптырдым. Шунда ук каядыр очканымны сиздем, сулышым буылды, бөтен тәнемне ялкын теле өтеп алгандай булды. Беренче уем «Нишләп болай тәнне яндыра, су салкын бит!» булды. Икенчесе – «Беттем!» иде. Ләкин шунда ук өскә калыкканымны сиздем, әйтерсең лә су анасы мине мәрхәмәтле учы белән югарыга этә иде. Башым судан чыккач, йотылып сулыш алдым да, аякларымны өзәңгеләрдән ычкындырып, Алмачуарның ялына тотындым.

Башта куркуымнан, аннары тырышып йөзгәнгә күрә, мин туңып өлгермәдем. Аргы якта Заһир абый мине көтеп тора иде. Мин җиргә аяк басуга, ул, борылып, ерак та түгел утларын җемелдәтеп утырган Богадыга таба чапты.

Шунда күңелемне берни белән дә алыштырып булмый торган тантана – көрәш һәм җиңү тантанасы биләп алды. Тарагыш авылының гади малае Давыт түгел идем мин ул төндә, гүзәл кызны гыйфрит тозагыннан коткарырга чапкан баһадир идем, кешеләргә ирек яулап күтәрелгән Салават батыр идем.

Әхнәфләр йортын тиз таптык – капка түбәсенә лампочка асылган, ачык ишектән кешеләр кереп-чыгып йөри иде.

Заһир абый читтә, караңгыда туктады да:

– Бар, апа кайда, дип сора, – диде.

Мин капканы Алмачуарның күкрәге белән бәрдереп ачтым да, атны арт аякларына күтәреп:

– Апа кайда? Апа чыксын! – дип кычкырдым.

Ишегалдындагы хатыннар кайсы кая сибелделәр.

– Әстәгъфирулла, кем бу?

– Әкълимәнең энеседер инде! Апасын сорый бит!

– Котны алдың, җүнсед, – диде берсе, тынычланып. – Күрше өйдә апаң, әнә урам аркылы. Кияүгә хәтле күреп чык!

Әһә, Чәүкә Әхнәф кыз куенына керер алдыннан хәл җыеп, киенеп-ясанып йөри икән әле. Бик вакытлы килеп җиткәнбез! Сикереп төштек атлардан, йөгереп мендек болдырга. Күрсеннәр иде шунда Заһир абыйны кәкре аяк дип авыз ерып көлгән кызлар! Бер генә типте ул ишеккә, бер генә, йозак әллә кая очты, келәләр чылтырап төште. Мин ишекне каерып ачып җибәрдем.

Әкълимә апада булган үзгәрешләрне мәңге онытасым юк. Ян кырыйдагы урындыкта башын учларына салып бөгелеп төшкән иде ул, нечкә ак беләкләрендә күгәргән эзләр ярылып ята иде –

чәче белән генә түгел, аркан белән бәйләгәннәр иде аның кулларын! Аның тезләрендә яткан толымнарыннан ук гарьләнү, чарасызлык, хәсрәт бөркелә иде. Менә ул башын күтәрде, йөзендә чиксез нәфрәт чагылды, иреннәре ачы сүзләр әйтер өчен тетрәнеп ачылды. Ул, бичара, бу йортка Әхнәфтән башка берәрсе керер дип өмет тә итми иде. Безне күргәч, әйтәсе сүзләре тел очына эленеп калды, ул зур һәлакәттән котылган кешенең бәхетен тасвирлаган гүзәл сын булып торып басты, кулларын безгә таба сузды.

Мин аның кочагына атылдым һәм Заһир абый белән икесе арасында калдым. Әкълимә апа тетрәнгән куллары белән мине кочаклады, мин аның иягенә маңгаемны terәдем, аның тәненнән берни белән чагыштырып булмый торган исерткеч хуш ис килгәнен тойдым, башым әйләнеп китте...

Без Әрҗән күпере аша әйләнеп кайттык. Әкълимә апа минем аркама терәлеп, кочаклап утырган, мин, ак айгырдан калышмаска тырышып, Алмачуарны куалыйм...

Авылга кергәндә, Заһир абый ындыр артлап китте, без урамнан кайттык. Клуб тирәсенә җыелган яшьләр безгә гаҗәпләнеп карап калдылар. Капка төбендә безне әнкәй белән Заһир абый көтеп торалар иде. Заһир абый Әкълимә апага аттан төшәргә булышты. Мин борылып карадым һәм аның Әкълимә апаны кочакларга омтылыш ясаганын күреп алдым. Әкълимә апа исә, аның күкрәгенә учларын терәп, артка каерылды. Әйе, ул читләште, мин аны тәрәзәдән төшкән ут яктысында аермачык күрдем.

– Рәхмәт яусын инде сиңа, – диде үзе, гаепле кеше сыман. – Мин синең яхшылыгыңны кайтара алмам инде, әҗерен башкалардан күрергә язсын.

Заһир абый атның тезгенен рәтләгән булып азапланды:

– Күңелең кушканны эшлә, Әкълимә, күңелең кушканны...

– Әйдәгед, тидрәк өйгә керегед, самовар кайнаган! Аллаһыма, өстегеддә коры җеп әсәре калмаган! – диде әнкәй, минем күлмәкне капшап.

– Рәхмәт, Мәрхәбәтти, атларны карыйсы бар, – диде Заһир абый һәм атын җитәкләп китеп барды.

Ул төнне без бик вакытлы өлгердек. Әлбәттә, Әкълимә апа Әхнәфне барыбер кабул итмәс иде. Ләкин егет аның янында әз генә утырып чыкса да, аларның исеме ил теленә керер, кемдә гаеп булган да ник килешмәгәннәр дип, имеш-мимеш сүз таралыр, кыз намусына күләгә төшәр иде.

Ә болай Әкълимә апа хакында бер генә кеше дә яман сүз әйтә алмады. Соңыннан авыл халкы арасында: «Давыт кыз урлаган егетләрне юлда ук куып тоткан да, Әхнәфне камчысы белән ярып, Әкълимәне тартып алган», – дигән хәбәр таралды. «Булыр, булыр, – дип, бу сүзне ныгытканнар авыл хатыннары. – Теге чакта ындыр табагында, Әкълимәне яклап, Вәкилне дә эт урынына кискән ие бит ул. Ай-яй, башкисәр ул Мәрхәбәнең малае!»

Нишләптер Заһир абыйның исеме бөтенләй телгә кермәде, әллә аны күрми калганнар, әллә кыз артыннан чабуына ышанмаганнар...

Бу хәлләрдән соң да ул безгә сирәк-мирәк кенә килеп, аны-моны рәтләштерүдән туктамады. Ул эшләгән арада, мин Нәфикъ чишмәсеннән су алып кайтам, әнкәй самовар куя иде.

Шулай беркөнне, көянтә күтәреп, судан кайтып килә идем, каршыма велосипедка атланган солдат киемле ят бер егет очрады.

– Укытучы Әкълимәнең фатиры кайсы? – дип сорады миннән.

Мин иягем белән үзебезнең капкага ымладым, үзем дә шунда борылдым. Ул велосипедыннан төште дә, күңел түреннән чыккан шат тавыш белән ягымлы итеп:

– Бәхетем миннән алда керсен әле, – диде.

Мин борылып аңа карадым: әллә монда булган хәлләрне ишеткән дәме инде? Ул, минем гаҗәпләнгәнемне күреп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

– Тулы чиләк күтәргән кеше очраса, юлың уң була, әллә ишеткәнең юкмы? – диде. – Димәк, син минем бәхетне күтәргәнсең.

– Әкълимә апа мәктәптә, – дидем мин төксе генә.

– Бигрәк әйбәт, ул кайтканчы, юл тузанын кагып, адәм рәтенә кереп торырбыз, – диде солдат. – Син миңа бер-ике чүмеч су бирерсең бит?

Мин, өйалдыннан чүмеч алып чыгып, Нәфикъ чишмәсенең саф суын аның кулына салып тордым. Аның җыйнак, тыгыз тәненнән, кояшта янган нык муеныннан, һәрнәрсәне җайлы тота торган кулларыннан гайрәт, көч бөркелә, кыска аксыл чәчләреннән, шат йөзеннән, Агыйдел суы төсле якты күзләреннән, ягымлы тавышыннан җанны эретә торган җылылык агыла иде. Уңган булса да, килешле гимнастеркасын, түшендә зыңгылдап торган значокларын да искә алсаң, кайсы гына малайның йөрәге туң калыр икән? Аның учыннан чәчрәгән тамчылар белән бергә гүяки минем күңелдәге салкынлык та түгелеп, җылы дулкын бәреп керде.

– Рәхмәт яусын, җиткән егет икәнсең! – диде ул, нәкъ Әкълимә апа төсле иттереп.

Без өйгә кердек. Бусагадан атлауга, солдатның якты күзләре Заһир абыйның эчтән янып торган карашы белән кисеште. Ул, әлбәттә, бу каратут йөзле егетнең монда хуҗа түгеллеген, аның ник килгәнен бер карауда аңлады. Тыенкы тавыш белән сәлам бирде, әнкәйнең чакыруына рәхмәт әйтеп, түргә узды. Әнкәй, кая басканын белмичә, самовар тирәсендә бөтерелергә кереште.

Менә алар – ике егет – янәшә утырдылар да армия хәлләрен сөйләшә башладылар. Заһир абый да Себердә хезмәт иткән булган икән, уртак сүз табылды. Мин мич артындагы чөйдән камчымны алып чалбар балагына суккаладым... Авыл егетләре арасында мондый очрашуларның ничек тәмамланганын ишеткән дә, күргән дә бар иде. Алай-болай сугыш купса, кемне якларга, кайсына камчы белән сыдырырга? Заһир абыйга каршы бару мөмкин түгел, ләкин солдатны да рәнҗетәсе килми...

Ә егетләр карашларын өстәл япмасына төбәп сөйләшәләр, тавышлары тыныч, әкрен, ләкин бу тынычлыкта бик көчле эчке киеренкелек сизелә. Әйтерсең лә алар арасында күзгә күренмәс кыл сузылган, ул кыл торган саен ныграк тартыла, менә-менә ул шартлап өзеләчәк, һәм өйдә баш китәрлек берәр хәл булачак...

Бу тартылу, киеренкелек, соң дәрәҗәгә җитеп, куркыныч шартлауны көтүдән колаклар чыңлый башлагач, өйалды ишеге ачылганы, җиңел аяк тавышлары ишетелде, бусагада Әкълимә апа күренде.

Аңа каршы өстәл артыннан ике егет торып бастылар, дүрт пар күз аңа төбәлде. Ләкин Әкълимә апа ул күзләрнең бары бер генә парын – Агыйдел суы кебек яктысын гына күрде. Мин аның бер генә тапкыр булса да Заһир абый тарафына керфек сирпүен көттем, көттем генә түгел, теләдем, бөтен йөрәгем белән эчтән ялвардым: «Ул синең өчен салкын дәрья суларына ташланды, җанын фида кыла язды, син дә кара инде бер генә!» – дидем. Ләкин ул Заһир абыйның күзеннән сирпелгән ялкынны да, минем күңелемнән түгелгән ялваруны да тоймады. Ул, гомумән, безнең дөньяда барлыгыбызны оныткан иде...

Менә Заһир абый, өстәл артыннан чыгып: «Сау булып торыгыз», – дип, ишеккә юнәлде. Әнкәй мине дә, җиңемнән тотып, аның артыннан тышка таба тартты. Шунда мин Әкълимә апа белән солдатның йөзләрендә кабынган елмаюны күреп алдым. Гомеремдә бер генә тапкыр булса да мин дә берәү белән шулай елмаешсам иде!

Кичкә таба солдат Әкълимә апаны үзалдына, велосипед рамына утыртып, авылыбыздан алып китте. Капка төбендә әнкәй: «И-и, бигрәк пар килгәннәр икән шул!» – дип сокланып аларга карап калды.

Без кыштан ук бик тырышып атларны Сабан туена әзерли башлаган идек. Көне җитәрәк кенә Заһир абый:

– Алмачуарны чыгарып тормабыз инде, – диде. – Ак айгырга син атланырсың, син җиңелрәк.

Ул елны Әрҗән Сабан туенда булган кешеләр хәтерлиләрдер: без икенче булып килдек. Беренчегә мотоцикл бирделәр, безнең ак айгыр сыртына тере тәкә китереп салдылар. Халык тарала төшкәч, безнең янга Әкълимә апа килде һәм, серле елмаеп, ат муенына чүпләмле сөлге бәйләде.

Мин сөлгенең кемгә тиешле икәнен аңлар дәрәҗәгә җиткән идем инде. Аны, ат муеныннан алмыйча, сарайга алып кайттым. Заһир абый, бер ат ялын, бер сөлгене сыйпаштырып, озак тынып торды, аннары, миңа карамый гына:

– Гелләр үдгәрмәгән Әкълимә, иеме? – диде. – Ябыкмаган, боекмаган, бәхетледер, мөгаен. – Аннары соклану һәм сагыш катыш тавыш белән өстәп куйды: – Шундый булмаса, Әкълимә булырыемыни ул!

Заһир абый белән безнең дуслык мин армиягә киткәнче дә, аннан кайткач та дәвам итте. Мин аның атлар белән сөйләшкәнен, җырлаганын тыңларга ярата идем. Аның шыпырт тавышында ярсу атларны буйсындырырлык көч һәм җан сөйгән ярлар белән колактан-колакка аңлашырлык хис сизелә иде. «Әллә соң безнең бабаларыбыз телне Агыйдел дулкыннары кагуыннан, урман тавышыннан, кошлар сайравыннан, тамчылар тыпырдавыннан өйрәнделәр микән? Әллә шуңа шыпырт, шул ук вакытта көчле, хисле микән ул?» – дип уйлый идем мин.

Басу капкасын чыккач та,
Сулга каерылгач та,
Их, дускаем, рәхәт яшә,
Беддән аерылгач та, –

дип җырлый иде Заһир абый, һәм аның җырында, Әкълимә апаның елмаюында, ул бүләк иткән сөлге бизәгендә, аларның үзара мөнәсәбәтендә борынгыдан килгән һәм мәңгелеккә барачак сафлык, ныклык, ышаныч барлыгын тоя идем. Мин Агыйделгә, аның арьягындагы тугайга, урманга карыйм, караган саен карыйсым килә, торган саен дөнья яктыра, төсмерләргә байый бара. Аларны яктырткан нур минем күңелемдә бары тик үзем өчен генә күтәрелеп килгән кояштан бөркелә. Ул нур миндәге ышанычны ныгытканнан-ныгыта бара.

Әйе, матурлык – Әкълимә апа төсле була, ярату – Заһир абый кебек була...

*1980*

## Бер күрүдә яраттым

Танкка ут капты. Бакый, ачы төтеннән буылып, авырлык белән люкны ачты, кызган тимердә кулларын пешереп, әүмәкләнеп, көч-хәл белән тышка чыкты. Кызгылт-сары ялкын телләре, зәһәр еланнардай ялманып, соргылт-комсу туфрак чәчрәгән броня өстендә биешә, алар шуышып узган урында металл кызып, күкселләнеп кала иде. Бакый, кулларын җилпеп, утны сүндерергә азапланды. Ләкин ул селтәнгән саен, елгыр еланнар зурая, ишәя бардылар, сикерешеп, аның бармакларын яладылар, алар тигән төштә тән, кара күмергә әверелеп, өздереп сызлады. Кызгылт-сары еланнар, аның саен тузынып, биткә үрелделәр, күз алмаларын өттеләр...

Шул урында Бакый аңына килде, тирән упкыннан күтәрелгәндәй, әкренләп зиһене ачылганын тойды, авырлык белән чынбарлыкка кире кайтты. Җайсыз яткан икән, элекке яралар үтереп сызлый, тагын яман төш кергән. Ул борылып ятты, сызлануны киметергә, куркыныч төш тәэсиреннән арынырга тырышып, еш-еш тирән итеп сулыш алды. Кирәк бит, аңа һаман төсле төшләр керә. Ялкын нинди ачык кызгылт-сары, броня – күгелҗем, ә үзенең пешкән бармаклары күмердәй кара иде. Төсле төшләр хисле кешеләргә керә, диләр. Бакыйга ул кадәр хисләнергә һич тә ярамый бит югыйсә. Кара инде син аның уң кул бармаклары сызлавын, күз алмаларының пешеп әрнүен... Никадәр генә хисле булмасын, боларны Бакый өнендә берничек тә тоя алмый бит инде... Нишләп мондый куркыныч төш керде соң әле бүген?

Ә-ә, кичә телевизордан сугыш турында, дөресрәге, танкистлар турында кино күрсәткәннәр иде бит. Дөрес, Бакый читтәрәк утыра иде, нәкъ шул сәгатьтә ул, наушник киеп, радио тыңлый иде. Ә шулай да телевизорга да колак салды, Т-34 танкысының җанга якын гөрелтесен, сискәндергеч шартлау тавышларын ишетеп торды, аларга радиодан моңлы җыр килеп кушылды. Бу авазлар, бергә уралып, аның күз алдында төсле күренешләр булып җанландылар. Чөнки җыр да шул ук дәһшәтле вакыйгалар хакында сөйли, солдат-шагыйрь Мостай Кәримнең әрнүле уйланулары аша сөйли иде:

Тимер ярчык яра төбендә,
Тимер ярчык йөри тәнемдә...
Руда көе аны еракта
Җир куйныннан эзләп таптылар,
Туплар патшасына саттылар,
Рурда аннан мина койдылар
Һәм Днепрода миңа аттылар.
Кандай кызыл иде таң нуры,
Таң кызартты үләннең чыгын,
Икебезгә тиде берьюлы
Бер минаның ике ярчыгы...

Бу сагышлы җыр, сугыш авазларына кушылып, бәгырьне телгәләде. Куркыныч төш тә шулар тәэсиреннән кергәндер, ахрысы.

Бер уйласаң, дөньяда булмас нәрсәләр кереп куя кайчак төшләргә. Йә, кем инде янган танкны кулы белән җилпенеп сүндерсен? Алай кыланырга, Бакый тәҗрибәле танкист иде бит. Аның башыннан бөтенләй башка хәлләр узды, бөтенләй башка. Танкка ут капмады, юк, янмады танк. Чынбарлык төсләргә дә алай бай түгел иде. Ләкин аның кичергәннәре яман төш кебек үк куркыныч булды. Т-34 танкысы, чит җирнең соргылт-комсу туфрагын чылбыр табаны белән изеп, төтен-сөрем ерып, зур тизлек белән бара иде. Кинәт ул бер урында кисәк борылды да туктап калды: чылбыры өзелгән иде. Бакый җиргә төшкәндә, старшина Фоменко белән сержант Матвеев танк артына ышыкланганнар иде инде. Фоменко яраланган, гимнастеркасы лычма кан булган.

– Яралыны бәйләгез, сержант! – диде Бакый Матвеевка. – Мин сезне ышыклап торам!

Үзе, пистолетын алып, каршыдагы җимерек йорт артыннан калкына башлаган дошман солдатларына каршы атарга кереште. Хәвефсезрәк төшкә китәргә иде дә, төзәп аталар, баш калкытырлык та түгел. Ул арада немецлар автоматлардан гына тигезә алмасларын аңладылар, граната томырдылар. Беренчесе читкәрәк төште. Җиргә сыенганда, Бакый сержантның Фоменконы үз гәүдәсе белән каплаганын күреп калды. Икенче граната, броняга бәрелеп, читкә чәчрәде. Өченчесе туры төбәлгән, анысыннан котылу чарасы юк иде. Дусларын ышыкларга тиешле Бакый, аны һавада ук тукtатырга теләгәндәй, кулын сузып, каршысына омтылды...

Менә шулар керергә тиеш иде аның төшенә. Күз алмаларының һәм уң кул бармакларының үтереп сызлавы түгел. Юк бит инде алар, ничек сызласыннар...

Уйламаска кирәк бу хакта, уйламаска. Төннәрен йокы качканда тән сызлавы белән бергә килгән мондый авыр хатирәләр күңелне бигрәк нык изә. Тизрәк көн килсен иде, яшәешнең күнегелгән мәшәкатьләре башлансын иде. Ләкин иртәдер шул әле, алты да юктыр, сәгать шалтыраганы

ишетелмәде. Бакый йөзен тәрәзә ягына борды, һәм шундук уйлары җиңеләеп китте – аның иреннәре, күз кабаклары күтәрелеп килгән кояшның беренче нурларын тоеп алды. Бакый биек йортлар артыннан зур кызыл шарның кырые ничек балкып чыкканын күз алдына китерде. Җирдә яңа көн яралып килә, аяз, тыныч көн. Бүген Бакыйның бик мөһим һәм шактый четерекле эш башкарасы бар. Кичә берәү аның янына гозер белән килгән иде.

– Әниемнең күзләре томаланды, врачлар да ярдәм итә алмый, – диде ул кеше. – Ашамый-эчми, мендәреннән баш күтәрми, әҗәлен көтеп ята. Безнең сүз генә үтмәде инде, зинһар, сез барып үгетләп карагыз. Булдыра алганча кеше төсле итеп яшәргә тырышсын. Андыйларга сезнең сүз үтә икән, дип ишеттек. Башка чара калмагач, аптыраганнан килдем.

Әйе, көн яктысын күрүдән мәхрүм калып, төшенкелеккә бирелгән кешеләр янына чакыргалыйлар шул кайчакта Бакыйны. Соңыннан килеп, үлеп барган җанны тергездегез дип, рәхмәт укып киткәннәре дә бар. Югыйсә гади генә нәрсәләр хакында сөйләшә алар белән Бакый. Хәлләрен сораша, үзенең үткәннәрен исенә төшерә. Гадәттә сугыш турында, аннан соңгы тормышы турында сөйли. Хәер, бүген хатын-кыз – ана кеше белән сүзне күңеллерәк хатирәләрдән башлау яхшырак булыр, мөгаен. Мәсәлән:

– Без бер-беребезне бер күрүдә яраттык, – дип башларга була.

* * *

Кырык өченче елның ахырында лейтенант Тимершинны хәрби часть кирәк-яраклар алырга Казанга командировкага җибәргән иде. Өч көнгә. Өченче көннең кичендә, кинога билет алганда очраштырды аларны язмыш. Кыз заманча киенгән иде: кара юбка, телогрейка, олтанлы итекләр. Ак береты астыннан чәч бөтеркәләре чыгып тора – кыз аларны төнгә каршы юеш чүпрәккә урап куя торган булгандыр, күрәсең. Шунда ике яшүсмер малай әтәчләнеп аңа бәйләнә, кинаяле сүзләр әйтә башладылар, берсе хәтта, чиратсыз кермәкче булып, иңбашы белән аны төртеп тә җибәргәндәй итте. Кызның түгәрәк йөзе алланды, нечкә кашлары җыерылып, алар арасында, сабый тәнендәге төсле, йомшак сыр хасил булды, күзләре караңгыланды.

– Барыгыз әле, таегыз моннан! – диде Бакый егетләргә.

Тегеләр лейтенантка текәлеп карадылар, аның шинеленнән аңкыган дары исен сизделәр һәм:

– Без тартып керәбез әле, – диеп, ишеккә юнәлделәр.

Билетлар беренче рәткә генә калган иде. Хәер, Бакый экранга рәтләп карамады да, ул янәшәсендәге ак беретлы кызны күзәтеп утырды. Кыз исә шулкадәр мавыккан, үзе экранга сикереп менәрдәй булып талпына, әле көлә, куана, әле кечкенә кулъяулыгы белән күзләрен сөртергә керешә. Гаҗәп кызык булды әле бу Бакый өчен. Кызык һәм күңелле, чөнки ике ел ярым фронтта булып, аның күптән инде кызлар белән кино караганы юк иде. Ә киноны аны фронтовикларга да күрсәтү җаен тапкалыйлар.

* * *

Әйтергә кирәк, Бакый бер дә кызлар карамаслык егет түгел иде. Ул үзенең яшь чагын сугышка хәтле төшкән фоторәсемендәгечә итеп хәтеренә китерә. Бакый – авыл малае, әмма яшьли ятим калып, Сарытау каласындагы ФЗӨ мәктәбенә китте, аннары заводта эшләде. Кырык беренче елның җәй башында, отпускы алгач авылына кайтырга, әти-әнисе каберен күреп, туган-тумачасын барлап килергә ниятләде, һушларын алыйм әле дип, кыек якалы ак күлмәк белән яңа чалбар алып киде, аягында шыгырдап торган хром итек иде. Шуларны киеп, карточкага төште. Сары бөдрәсе маңгаеның яртысын каплаган, зәңгәр күзләр куе керфекләр арасыннан мут елтырый. Хәер, карточкада күз-керфекләрнең төсе ачык күренми иде, аларны соңыннан Бакыйның хәтере буяп куйды. Кеше хәтере ифрат оста буяучы бит ул. Ә карточкада, аягын аякка чалыштырып, гитарага таянып, кәттә егет басып тора иде. Күрсеннәр, белсеннәр иртә дөнья куйган тимерче Тимерша малаеның кем булганын! Ятим калсак та, әрәм булмадык, юкка гына Тимерша нәселе дип аталмыйбыз! Әмма бу кәпрәю астында бер яшерен өмет чаткысы да яна иде. Туган авыл бит ул, туган авыл! Бу сүзләрне әйтүгә, Бакыйның хәтерендә, авылның үзеннән дә бигрәк, нурлы күзләр, назлы пышылдау, җан эреткеч рәхәт биреп иркәли торган йомшак кулларның җылысы җанлана иде. Әнисенең карашы-назы иде бу. Туган авылында Бакый шул яктылыкның чаткысын гына булса да табарга тели иде.

Кардәшләре аны кочак җәеп, якты чырай белән каршы алдылар, әмма ул көткән җылылык, якынлык сизелмәде. Зиратта ул чирәм үскән ике калкулык янында озак басып торды. Калкулыкларның башына ак ташлар куелып, аларга урак ай һәм гарәпчә сүзләр уелган иде. Вак ромашкалар, үлән сабаклары талгын җилдә тибрәлә, баш очында тургай сайрый, чикерткәләр сикерешә, иң газиз кешеләрнең шушы калкулык астында ятуына күңел ышанмый иде.

Бакый сагышын җыр-бию, күңел ачу белән басарга тырышты. Кичке уеннарда – болында, тузан туздырып, итек кунычларына шап-шоп сугып биеде, гитара чиртеп, кызларны шаккатырды, егетләр белән кочаклашып җырлап урам әйләнде:

...Сау булыгыз, дуслар, инде мин китәм!
Онытмагыз безнең изге эшебезне,
Әкрен искән җилдән сәламнәр көтәм!

Кичке уеннарда кызлар арасыннан берсе – озын толымлы, ак кофта белән кара юбка кигән Һәдия исемлесе – күзләрен гел Бакыйдан алмый кебек тоела иде. Әлбәттә инде, кыз егеткә сиздереп карап тора икән, ул чакта егет аны озата барырга тиеш. Ләкин ни сәбәптәндер Бакый аның янына барырга кыймады, батырлыгы җитмәде.

Бер кичне яшьләр, Һәдияне түгәрәк уртасына бастырып, җырларга куштылар. Бакый сизмәмешкә салышканны егетләр сизеп торган, күрәсең, аны да төрткәләп түгәрәккә керттеләр: «Уйна гитараңны, Һәдия сиңа кушылып җырласын!» Гитара кылларыннан көмеш тамчылар булып дәртле моң сибелде, ләкин кыз кыска, шаян көйгә кушылмады, тирәннән чыккан йомшак тавыш белән сагышлы җыр сузып җибәрде:

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары коела җилләргә шул;
Үзе дә юк, әйтер сүзе дә юк,
Калды инде сагынып сөйләргә...

Бу җырны Бакый соңыннан фронт юлларында күп тапкырлар ишетте. Аны дошман тылында Муса Җәлил оештырган һәвәскәрләр труппасы да җырлаган, дип сөйләделәр. Бик ихтимал, янып сөюне дә, ярсып сагынуны да сыйдырган көй бит ул. Һәдияне тыңлаганда, Бакыйның да күңеле тулып ташыган иде. Кызның тавышы тулган ай нурына күмелгән иркен болын буйлап еракка таралды, сагыш-моң күкләргә ашып, сары ай тетрәнә башлады кебек. Менә кызның тавышы кинәт өзелде, ул түгәрәктән читкә, каралып күренгән куаклар күләгәсенә атылды.

Нindидер аңлашылмас тарту көче Бакыйны да ул йөгергән тарафка алып китте. Ул тал чыбыгына тотынып иңрәп елый, чыбык бөгелеп китәр дә Һәдия җиргә авар шикелле иде. Бакый, егылудан саклап калырга теләп, аның беләгеннән тотты. Кыз борылды, кулларын егетнең күкрәгенә куйды, йомшак учлары белән йөрәкне пешергәндәй итте, үксүен тыярга тырышып, ләкин тыя алмыйча: «Мин дә синең кебек ятим бит, безнең язмышлар уртак», – дип пышылдады. Бик сагынылган, бик тансык җылылык, иркәләү бар иде аның кулларында, сүзләрендә. Бакый кинәт кенә туган авылында күрергә теләгән яктылыкны, якын итүне, ниһаять, тапканын аңлады. Кайчандыр, балачакта, Бакыйны әнисе шушылай күңел назы белән иркәли иде.

Шул ук вакытта ул үзе дә кызның йөрәгендәге яраларны күргәндәй, аларның сызлавын үз күңелендә тойгандай булды. Ул Һәдияне йомшак итеп күкрәгенә кысты, аның белән уртак хис кичереп сагышлануы гына да кызга җиңеллек биргәнен аңлады. Аларның кайгысы үтә торган түгел иде, ләкин бергәләп кичергәч, андыйлар да җиңеләя икән.

Кинәт якында гына куак кыштырдады, Һәдия читкә атылды, аның кофтасы гына ак күбәләк булып сызылып үтте.

Соңрак, кардәшләреннән читләтеп кенә сораштыргач, Бакый күптән түгел генә кызның әнисе үлгәнен белде.

Алар шуннан соң очраша алмадылар. Бакыйның авылдан китәр чагы җиткән иде инде, аннары сугыш башланды. Ләкин бу очрашу бик еш искә төшә иде. Уйлана торгач, Бакый, әллә соң Һәдиянең бу кадәр сагышлануы ятимлегеннән генә түгел иде микән, әллә аның сизгер күңеле киләчәктә күрәчәкләрне дә сизде микән, дип куя иде.

Сугыш бетеп, күп еллар узгач, Бакый Һәдия турында сорашып карады. Кыз үзе теләп фронтка киткән, зенит частьларында хезмәт иткән, кырык бишенче елны һәлак булган, туганнар кабере өстендәге мәрмәр ташка аның да исеме уелган, дип сөйләделәр. Алай икән, Һәдия дә чит җирнең комсу туфрагына ятып калган икән, дип уйлады Бакый.

Фронт юлларында зенитчыларны шактый күп очратты ул. Күктә гүләү ишетелүгә, һәр җирдә «Ят!» дигән команда яңгырый. Ә зенитчыларга команданың капма-каршысы: «Орудиеләр янына!» Алар сугышчан постка басып, карашларын хәвефле күк йөзенә төбиләр.

Исеме бер сулыш белән, йөрәк түреннән чыккан наз белән әйтелә торган, якты карашлы, ачык холыклы, моңлы һәм хисчән авыл кызы явызлыкка каршы беренчеләрдән булып күтәрелгән икән һәм һәлакәтен дә башын югары тотып каршы алган икән – бу аның табигатенә шулкадәр туры килә!

* * *

«Туктале, тагын сугыш хәтерне бутады, – дип, уйларының агышын үзгәртергә тырышты Бакый. – Мин бүген сүзне иң элек мәхәббәт турында сөйләүдән башлармын дигән идем бит. Кара күзле Һәдия белән бер-беребезне яратышырга өлгерә алмадык шул». Ул чакта унсигезе яңа тулган Бакыйның рухы да, акылы да, йөрәге дә чын мәхәббәт кебек зур хисне кичерер өчен җитлегеп өлгермәгән иде әле. Бакый яшендәгеләргә табигать кушканча әкренләп акыл утыртырга, хисләр тирәнлеген әкренлек белән аңлап җитлегергә мөмкинлек булмады, язмыш аларны сугыш утында чыныктырып ир итте.

Шулай итеп, кинода, беркатлы кыз янында, күпне кичереп җитлеккән, ныгыган егет утыра иде инде.

Кино тәмамланып, халык төркеменнән чыккач, Бакый:

– Ягез, безнең частьлар хәзер кайсы юнәлештә хәрәкәт итәчәк? – дип сорады.

– Кемнәр ул «безнең частьлар»?

– Сезнең белән миннән торган хәрби берләшмә.

– Һәркем үз юлы белән китәр инде.

– Алай ярамый. Сезгә сугышчан озатучы кирәк.

– Нишләп әле?

– Сезнең дошман засадасына эләгүегез ихтимал, – диде Бакый, теге бәйләнчек егетләргә кинаяләп.

Алар барча утлары сүндерелгән шәһәр урамнары буйлап, ай яктысында җемелдәп яткан карлы юллардан шактый озак бардылар. Кыз Казан елгасы буендагы иске урамда яши икән.

– Мин гаскәри кеше, – диде Бакый, – ә хәрби закон шундый: бер юнәлештә хәрәкәт итүче частьлар даими элемтәдә торырга тиешләр. Моның өчен алар бер-берсенең позывнойларын белешәләр. Мин – Боря, ә сез?

– Хадя, – диде кыз, бераз икеләнеп торганнан соң.

Аңарчы алар русча сөйләшәләр иде. Русларга хас булмаган бу исем Бакыйның күңеленнән аҗаган кебек яктырып узды.

– Һәдия?! – диде ул.

Йөрәк түреннән чыккан бер сулыш белән, йомшак, мәгънәле, серле итеп әйтте.

– Нигә аңа гаҗәпләнәсез? – диде кыз, аптырап. – Гап-гади татар исеме.

– Һәдия... Ә мин – Бакый.

Алар җитди сөйләшүгә күчтеләр. Кыз унынчыда укый икән. «Мәктәпне тәмамлауга, фронтка китәргә тырышачакмын», – диде.

Алар ике катлы агач йортның капкасы янында тукталып басып тордылар. Капканың нәкъ уртасыннан бер тактасы каерылган, аннан өздереп ачы җил исә иде. Шул капка ук йорт хуҗасының фронтта икәнен күрсәтеп тора иде. Саубуллашканда кызны бер үпсәң дә гөнаһ булмас иде, фронтовикка ул гына фарыздыр. Ләкин исеме комачаулады, ул исемне йөрткән кызны кинәт кенә, шаярып кына кочаклап алу мөмкин түгел кебек тоелды.

– Безгә элемтәне дәвам итәргә кирәк, сугышчан стратегия шуны таләп итә, – диде Бакый, янәдән шаян тонга күчеп.

– Ничек?

– Почта аша, хат белән.

– Сез шулай очраган бер кыз белән хат алышасызмы?

Минем хат алышкан кызым юк, дип, дөресен әйтергә тиеш тапмады Бакый, дәрәҗәсен төшерәсе, сер бирәсе килмәде.

– Фронтовикка, бигрәк тә танкистларга, кызлардан хатларның күбрәк килүе хәерле, – диде.

– Оста икәнсез, һәркайсына, сине генә яратам, дип алдап-йолдап хат язып ятасызмы?

– Хикмәт анда түгел.

– Ә нәрсәдә соң?

– Әгәр беләсегез килсә, кызларның сугышчыга язган һәр сөю хаты дошманга атылган снарядка тиң.

– Барып тияме соң ул снарядлар? – Кыз көлеп куйды.

– Тимәгән кая! Безнең сугышчан экипаж, мәсәлән, кызларның «өзелеп сөям, сагынып көтәм» дигән һәр хатына җавап итеп, фашистларның бер «Тигр»ын яисә «Фердинанд»ын шартлатырга йөкләмә алды. Сезнең хатка да шулай җавап бирерләр. Тиешле дәрәҗәдә язылган булса, әлбәттә!

– Фашистларның танклары җитәрме соң бөтен кызларның хатына?

– Сынап карыйбыз инде: фашистларның заводлары җиңәрме, безнең кызларның мәхәббәтеме.

Ныгытып ук вәгъдә бирмәде кызкай, ләкин кул биреп саубуллашканда, елмаеп, күзләрен балкытып карады. Хәер, аның карашы ай нурыннан шулай якты булып күренгәндер, бәлки.

Фронттан язган хатлар җавапсыз калмады. Минем хатны алгач, фашист танкын яндырдыңмы, дип сорамады кыз соравын, ләкин сүзләрендә беркатлылык тулып ята иде. «Озакламый мин дә фронтка китәм, бәлки әле, шунда очрашырбыз», – дип яза иде ул сабый.

Ә канлы бәрелешләр дәвам итә, сугышчан дусларның әле берсе, әле икенчесе мәңгелеккә ятып кала, аларга соңгы сәламеңне биргәндә, үзеңнең дә һәлак булуың мөмкинлеген уйлыйсың, ләкин яшь күңел моңа ышанмый, яшь күңел, туган җиргә кайтып, маңгай тирәсендә чәчләре бөтеркәләнеп торган түгәрәк йөзне күрү, хулиган малайлар бәйләнгәндә кара булып тоелган, ә ай нуры төшкәндә бик якты күренгән күзләрнең чын төсен белү өмете белән яши иде.

Кулда шартлаган граната ул өметләрне кисте, дөньяны караңгылык пәрдәсе белән каплады.

* * *

Докторның: «Үлем тырнагыннан тартып алдык без сине, егет, болай булгач, картайганчы яшәячәксең инде», – дигән сүзләре аңа кара түшәк аша гына ишетелгәндәй булдылар һәм хәсрәтне генә көчәйттеләр. Картайганчы яшәргәме? Шушы гүр караңгылыгындамы? Кемнең дә булса сиңа ризык каптырганын, җитешеп йомышка алып чыкканын көтеп яту – ул яшәүмени? Кемгә кирәк андый тормыш?

Шәфкать туташы аның янына кат-кат килеп, берәрсенә хат язарга үгетләде. Бакый аңа аркасы белән генә борылып ята иде. Кардәшләренә язар иде – кулсыз, күзсез егетне алар нишләтсеннәр? Нигә дип кешеләрне четерекле хәлгә куярга? Ә Һәдия исә... аны үлгән дип санасын. «Тигр» яки «Фердинанд» белән бәрелешкәндә һәлак булган дип күз алдына китерсен. Бәлки, теге чакта кино геройларын кызганып елаган кебек, елап та алыр әле. Тик яшь кызның күз яшьләре иртәнге чык кебек тиз кибәр. Озакламый илгә күкрәкләрен орден-медальләр белән бизәгән җиңүче егетләр кайтыр, алар арасыннан Һәдия дә үзенә тиңне табар...

Ләкин тәкъдир дәфтәренә аларның киләчәге бөтенләй башкача язылган булып чыкты. Көннәрнең берендә Бакыйны фронт госпиталеннән тылга алып киттеләр. Кая илтәсез, дип сорамады Бакый, аңа барыбер иде.

Күпмедер көннәр поездда тирбәләп барганнан соң, аякка басып, тышка чыктылар. Салкын һава тынны куырды, тән калтыранды, кире әйләнеп, җылы, тынчу вагонга керәсе килде. «Казанга җиттек, Казан бу, Казан!» дигән тавышлар ишетелде. Бу сүздән йөрәк кузгалып куйгандай булды, ләкин Бакый аның талпынуын басарга тырышты: ул үзен фәкать караңгылыкны гына күрергә, бары тик битарафлыкны гына тоярга тиеш дип исәпли иде.

Казан госпиталендәге матрасның уртасы юкарып, карават тимерләре янбашны тырнап тора иде. Күрәсең, күп егетләр сызланып аунаган булгандыр инде анда. Әмма шәфкать туташының: «Урыныгыз җайлымы, яралы?» – дигән соравына ул берни дәшмәде: барыбер түгелмени?

Күпмедер вакыт тынып торганнан соң, коридорда аяк тавышлары ешайды, хәрәкәт купты – димәк, иртә җитте, смена алышына, дип уйлады Бакый. Менә ишек ачылды, йомшак кына басып берәү керде. «Хәерле иртә, яралылар!» Бу тавыштан сулыш киселеп, йөрәк какканы аермачык ишетелә башлады. Булмас, мөмкин түгел, бу госпитальгә, бу палатага ничек килеп керсен ул? Ләкин тавыш таныш иде, бик таныш иде. Әнә ул Бакыйга таба якынлаша! «Яралы, алыгыз градусникны! Уяныгыз, градусник куябыз!» Адымнар бик якын килде һәм тынды, Бакый колакларын шаулаткан йөрәк тибеше аша шәфкать туташының хәрәкәтен, сулышын тояргa тырышты, ләкин берни ишетелмәде, әйтерсең лә кыз кинәт эреп юкка чыкты...

Чигәләргә сугып күпме секундлар үткәндер, алар Бакыйга озак, бик озак булып тоелды. Менә, ниһаять, ерактан, үткәннәрдә калган якты бер кичтән килгәндәй, тавыш ишетелде:

– Бакый, синме бу, Бакый?

Һәдия аны мамык, марля астыннан чыгып торган иягеннән таныды. Шулчак егет аның ике каш арасында беленер-беленмәс сыр хасил булган түгәрәк йөзен, ай нуры тулган якты күзләрен күргәндәй булды. Егерме ике яшьлек егетнең кайнар каны кинәт кузгалды, ул урынының катылыгын тойды, суларга һава җитмәс булды, аның сикереп торасы, каядыр барасы, нидер эшлисе килде.

– Торыйм әле, – диде ул карлыккан тавыш белән. – Саф һавага чыгасы килә.

Аның иңнәренә одеял салганда, кызның куллары күкрәген сыйпап узды, һәм бу аналарча наз, кадерләү, кызгану белән тулы хәрәкәт кара күзле авыл кызының иркәләвен искә төшерде. Һәдия нечкә, ләкин көчле бармаклары белән аның кулыннан тотып алды да ишеккә таба алып китте.

Ә тышның салкын һавасы әчкелтем татлы һәм исерткеч куәтле икән. Яз исе, яз тәме иде бу.

Шул иртәдән соң аның күз алдына төсле күренешләр килә торган булды. Ул миен томалаган кара томанны куып, үткәннәре һәм хәзергесе хакында фикер йөртергә үзендә көч тапты.

Айлы кичләр, гитара чыңнары, кызларның елмаеп каравы, заводта күңел биреп, мавыгып ясалган детальләр, өлкән мастерның хуплавы – болар барысы да үткәннәрдә калган иде инде.

Аларның барысын да дошман гранатасы юк итте. Бакыйның хәтерендә ул соңгы граната инде хәзер очып килгән тукмак рәвешендә түгел, ә бәлки канатлары белән кояшны каплаган куркыныч кош рәвешенә кереп күзаллана иде. Кеше хәтере вакыт агышын да үзгәртә бит ул. Бакый аны җибәргән кулны да күргән сыман хәтерли башлады. Ул адәм кулына да охшамаган, корым сарган җимерек кирпеч өеме артыннан гүяки кара йон баскан ерткыч тәпие үрелеп чыга, аның һәр бармагы, аждаһа башына әверелеп, авызыннан ут чәчә, агу чәчә. Ут-башлар торган саен зураеп, ыжгырып, Бакый өстенә ыргылалар... Алар үткәннәрдә генә калырга теләмиләр, бүгенгене, киләчәкне йотарга омтылалар... Менә-менә алар Бакыйны тере килеш гүр караңгылыгында һәм битарафлыкта яшәргә дучар итәчәкләр...

Ләкин шунда егет янына Һәдия килеп баса, аның аяк тавышлары ишетелүгә, аждаһа куркып кача. Хатларында, фронтта очрашырбыз, бәлки, дип язгач, Бакый Һәдиянең беркатлылыгыннан көлгән иде. Ләкин кызның күңеле очрашасыларын сизгән икән бит! Шәфкать туташлары курсын тәмамлагач, аны фронтка җибәрмәгәннәр, госпитальдә калдырганнар. Аның адымнарын, тавышын ишетү, аның кулыннан ризык кабу, күздәге һәм кулдагы бәйләвечне алыштырганда аның бармаклары җылысын тою үлеп барган җанга, әкияттәге тереклек суы кебек, шифа бирә иде. Фәкать гүр караңгылыгыннан кире кайткан кеше генә яшәешнең һәр ваклыгын шушылай, Бакый кебек кинәнеп, кадерен белеп кичерә ала.

Киләчәк тә бераз ачыклана төште. Юк-юк, Һәдия белән бергә булырбыз диган уйны башына да китермәде ул, әлбәттә. Кыз муенына гомерлек таш булып бәйләнәләрме соң!.. Бергә сугышкан иптәштән хат килеп төште. «Инвалидлар йортына урнаштым, монда бик әйбәт карыйлар, йортыбыз зур авыл янында, бакча уртасында», – дип язган иде. Һәдия, Бакый янына утырып, хатка җавап язды: «Чакыруыңа рәхмәт, тиздән мине моннан чыгаралар, озакламый барып җитәрмен».

Элегрәк аның, иреннәрен кыймылдатып, бер сүз әйтәсе дә килми иде. Хәзер күңелендә моң уянды, ул, үзе дә сизмәстән, үзалдына әкрен генә җырлап ята торган булды.

...Сау булыгыз, дуслар, инде мин китәм...
Әкрен искән җилдән сәламнәр көтәм...

Яндагылар ишетеп яткан икән, аны берзаман госпитальнең һәвәскәрләре концертында катнашырга үгетли башладылар һәм күндерделәр дә. «Сау булыгыз, дуслар, инде мин китәм», – дип җырлады Бакый. Барлык дусларга түгел, бер генә кешегә атап җырлады ул бу җырын, аерылышу ачысын салып, үзәге өзелеп җырлады. Китәр көн килеп җиткән иде шул инде.

Әмма баш кына исән булсын, бер килә башлагач килә дә тора икән бәхет адәм баласына! Яралы Тимершинны инвалидлар йортына илтеп кую вазифасы шәфкать туташы Һәдиягә йөкләнде.

Ә анда, инвалидлар йортында, терелмәс сырхауларны, ярдәмчесе булмаган һәм үз-үзләрен карый алмаган яралыларны иренмичә, ялыкмыйча, җан җылысын биреп карый ала торган шәфкать туташлары бик тә кирәк икән. Һәдия беразга шунда гына эшләп торырга ниятләде. Шулай итеп, аерылышу минутлары тагын чигерелде.

Алар урнашкан йорт чыннан да зур бакча уртасында иде, ә бакчаларга яз аерата юмартлык белән килә, кошлар моңы ераккарак яңгырый, чәчәкләрнең хуш исе көчлерәк аңкый, җирнең җылынып, иркенләп сулыш алуы да, сукмакларда борын төрткән үлән дә монда үзен ныграк сиздерә. Күңелләр нәкъ табигать кебек үк яңара, ашкынып талпына.

Кичләрен алар, шушы яшәрүне тоеп, хуш исләргә һәм сандугач моңнарына коенып, бакчада йөри торган булдылар. Ерак та түгел авыл яшьләре кичке уенга чыгалар иде булса кирәк, гармун тавышы, чыр-чу, дәртле җыр ишетелә. Шундый кичләрнең берсендә, Бакыйның беләгенә тотынып атлаган Һәдия:

– Бүген ай яктысы бигрәк якты, – диде. – Алмагачлар да ап-ак. Ә күләгәләр аермачык каралып ята.

Бакыйның күз алдында туган авылының болыны, андагы түгәрәк уен, ай нурына коенган чирәмлек һәм аның кырындагы куаклардан төшкән кара күләгә пәйда булды. Әгәр бер күзе генә исән булса да, ул Һәдияне кичке уенга алып чыгар иде, уң кулы терсәктән юклыкка кыенсынып тормас иде. Фронтовикка аның ояты юк.

– Һәдия, – диде Бакый җиңел бер сагыш белән. – Синең дә кичке уенга барасың киләдер бит. Берәү дә көне-төне эшләми, синең дә ял итәргә хакың бар. Чык син кичке уенга.

– Ә син? – дип сорады Һәдия, сагаеп.

– Ә мин, беләсеңме, ни өчен сугыштым? Синдәй кызлар яшьлегендә рәхәтләнеп күңел ачсын, җырласын, биесен өчен. Әгәр мин үзем сине шул рәхәттән мәхрүм итәм икән, болай имгәнә-имгәнә сугышып йөрүемнән ни мәгънә кала?

– Нишләп әле син мине күңел ачмый дип уйлыйсың? – диде Һәдия кинәт, ниндидер бер карарга килгәндәй. – Мин монда да җырлый, бии алам бит. Күңелем тарткан кеше белән бии алам.

Һәм ул кулларын Бакыйның иңнәренә салды. Алар болын ягыннан килгән көйгә биеп киттеләр. Биегәндә аларга бер-берсенең аягына басудан куркып, сагаеп, жайлашып торасы булмады. Һәдия белән бию бик рәхәт, җиңел икән. Кыз егетне үзенчә боргаларга тырышмады, тулысынча аның ихтыярына буйсынды, ә шулай да Бакый сөртенмәде, агачларга бәрелмәде. Хәер, ул кичтә аның күзләре күпмедер минутларга ачылып торды шикелле. Хәзер искә төшергәндә, ул ак чәчәккә күмелгән алмагачларны, тулган айны, сандугачларны күргән кебек хәтерли. Сандугач та, ай нурыннан тугандай, ак, нурлы иде...

– Кайтыйк без өйгә, Бакый, Казанга кайтыйк, – диде Һәдия, биеп туктагач та егетнең күкрәгеннән кулларын алырга ашыкмыйча. – Әти дә госпитальдән чыгып өйгә кайткан, чакырып язалар.

Бакый үзенең хәлен онытып җибәргән иде, ахры, юк, бу мөмкин түгел дип, Һәдияне читкә этеп җибәрмәде, гади генә итеп:

– Кайтыйк, – дип җавап бирде.

* * *

Поезддан төшкәч барган урамнарны, ике катлы йорт каршындагы биек рус капканы аермачык күз алдына китереп барды Бакый. Ләкин өйгә кергәч югалып калды, чөнки монда кайда нәрсә һәм кем барын чамалап булмый иде. Кемнәр бар анда һәм алар күзләре бәйле, ә уң җиңе кесәгә тыгылган солдатка ничек карыйлар? Өй эчендә тынлык, тик бала-чага пышылдаша да кемдер, үксегәнен ишеттермәскә тырышып, тыелып кына борынын мышкылдата.

Кинәт яңгыраган командирларча кискен, катгый тавыш Бакыйны сынын турайтып басарга мәҗбүр итте:

– Нинди частьтан, лейтенант?

– Танкист, иптәш майор, генерал-майор Белобородовның тугызынчы гвардияче дивизиясеннән!

Бакый үкчәләрен бер-берсенә шап итеп бәрде, уң кулын чигәсенә күтәрергә омтылыш ясады. Һәдиянең сөйләвеннән ул бу кешенең саперлар частенда хезмәт иткәнен, майор икәнен белә иде инде.

– Кайттыгыз, димәк, – диде майор, тирән көрсенеп. – Кияүне дә күрер көн бар икән, шөкер. Әйдәгез, түргә узыгыз, – диде аннары, командирларча түгел, аталарча йомшак тавыш белән.

Һәдия күнегелгән өлгерлек белән Бакыйга өстеннән салырга ярдәм итте, әйдәп барган кебек түгел, җитәкләшеп атлаган шикелле генә итеп, өстәл янына илтеп утыртты. Яңа гамьнәр өстәлде Бакыйга: табын янында бик ипле утырырга, сул кул белән чынаяк-кашыкны төгәл тотарга, бүген беренче күргән кешеләрдә үзеңә карата кызгану хисен бетерергә, һич булмаса, киметергә кирәк иде. Бакый каушаганын сиздермәскә, сынын туры, башын югары тотарга тырышты. Ә майор сүзне бик тирәннән башлады:

– Кызга сүз әйтеп булмый, – диде ул. – Кызларның берсе дә фронтта яраланган сугышчыдан йөз чөерергә тиеш түгел. Әгәр исән-сау чакта яраткан икән, хәзер дә яратсын.

Әйе, шулай, дип, эченнән генә раслап кабул итте Бакый аның бу сүзләрен. Һәдия аны туганнан бирле белә һәм гомер буе ярата иде кебек, һәрхәлдә, егет үзе кайчан да булса Һәдияне белми яшәгәненә ышанмый да иде инде.

– Әмма бер шартым бар, – дип ничектер бик тирән мәгънә белән дәвам итте сүзен майор. – Бик олы шартым бар минем сезгә. – Ул уйланыпмы, көч җыепмы, бераз тынып торды. Аннары, тирән сулап: – Шартым шул, – диде. – Шартым шул: миңа оныклар булдырып, адәм рәтле итеп үстерә алырлык булсагыз гына фатихамны бирәм. Әгәр андый ышанычыгыз булмаса, яратышабыз, кызганышабыз, дип кенә уртак тормыш кормагыз. Безгә бу җирдә чын кеше булырлык уллар, кызлар кирәк хәзер. Шунсыз без үзебезне чын җиңүчеләр дип саный алмабыз. Моны ныгытып уйладыгызмы?

Балалар үстерергә? Адәм рәтле итеп? Бу хәлендә Бакый ничек бала тәрбияли алыр икән? Ул, сөюенә мавыгып, Һәдия белән бергә Казанга кайтуны, якын киләчәкне генә уйлаган, ата булуны фаразламаган да иде. Дөресрәге, ул хакта уйларга да курка иде Бакый. Анысы кая, алар әле өйләнешәбез дип тә ачыктан-ачык сөйләшмәгәннәр иде бит. Ә менә Һәдиянең әтисе алар сөйләшергә курыкканны ярып әйтте дә салды.

Бакыйның авызы кайнар чәйгә пеште, алай гына түгел, бөтен үзәге өтелде. Һәдия дә алай тирәннән уйламагандыр әле, хәзер, әтисе әйткәч, кинәт аңына килер дә кылганына үкенер, араны кинәт үк өзмәсә дә, шиккә калыр, икеләнер...

Бакыйның аяк астында кинәт җир убыла башлагандай булды, терәк югалды... Шулчак аның сул ягыннан Һәдиянең бик йомшак, оялчан тавышы ишетелде:

– Кешедән ким яшәмәс идек әле. Әгәр ышанып фатихаңны бирсәң, бөтенесе кешечә булыр иде.

Тыйнак кына әйтелгән шушы сүзләр Бакый баскан җирне какшамаслык ныгытып куйгандай иттеләр.

Гомерлек терәк, какшамаслык ныклы терәк иде бу.

Ләкин кешегә гомер кичү өчен терәк кенә дә аз икән. Кешегә шул терәктә нык тору өчен үзендә көч кирәк икән. Ә Бакый хәлендә нык булу ай-һай зур көч сорый иде шул.

Баштарак ул моны аңламады, теге чакта майор әйткән шик тулы сүзләрнең мәгънәсенә тора торып кына бөтен тирәнлеге белән төшенде.

Дөрес, төннәр аның кешедән кимлеген бөтенләй оныттыра иде. Әгәр сине берәү өзелеп сөя икән, аның өчен син дөньядагы бөтен асыл егетләрдән артык икән, күңелдә ничек кимсенү хисе калсын? Төннәрен Бакыйдан да камил, аннан да сәламәт, аннан да чибәр кеше юк иде.

– Син янымда чакта, мин үземне чыннан да Бакый итеп, үлемсез итеп, мәңгелек итеп тоям, – ди Бакый хатынына. – Ә син минем язмыш биргән иң зур бүләгем, Һәдиям.

– Бергә чакта без икебез дә мәңгелек, – дип ышаныч белән җавап бирә аңа Һәдия.

Әйе, чыннан да, аерым-аерым алар, барлык адәм балалары кебек үк, фани кешеләр, мәңге яши алмаслар. Ләкин өзелеп сөя белгән кеше үз яры белән кавышканда үзен мәңгелек дип хис итә һәм ул хаклы да. Чөнки нәкъ шул минутларда без үз тәнебездә ата-бабаның буыннан буынга килгән таза, сәламәт кайнар каны уйнавын, бу изге агымның беркайчан да туктамаячагын, бездән киләчәк буыннарга күчәчәген, шул рәвешле мәхәббәт ялкынының мәңгелеккә барачагын тоябыз.

Төннәр бәхет бирә иде Бакыйга, аны кодрәтле, үлемсез итә иде.

Әмма көннәр... Аның өчен төннәр – якты, көннәр – караңгы иде.

Иртән Һәдия эшкә китә, үзе белән бергә иренең бөтен ышанычын, ныклыгын алып чыгып китә иде. Биредә, сәламәт кешеләр арасында, ул үзенең кешедән кимлеген госпитальдәгедән һәм инвалидлар йортындагыдан да ныграк тоя иде. Анда бар да бериш, ә монда ул бүтәннәр төсле түгел...

Бакый бик әкрен, бик сакланып кына өйдә йөрергә өйрәнә башлады. Күзе күргән кеше уйлап та карамый, ә өйләрдә очлы почмаклар ифрат та күп бит безнең, Бакый атлаган саен бәрелә иде.

Ләкин аны иң нык изгәне – артык кашык булу, эшкә ярамау иде. Көч-гайрәтен, күңел кайнарлыгын саклаган яшь егетнең, бер урында кузгалырга куркып тик утырганда, ниләр кичергәнен сәламәт кешеләрнең кайсы гына күз алдына китерә ала икән? Көннең сәгате түгел, минуты үтми йөдәтә. Күңелгә сары сагыш тула, тула, тула. ...Ул бәгырьне талый, мине көйдерә, моңа чыдап булмый башлый, сикереп торып нидер эшлисе, караңгылык дөньясыннан ничек тә бәреп чыгасы, башны орып ватасы килә. Һәм бу гаҗизлекнең, көчсезлекнең очы-кырые күренми, кап-кара дөньяда бер генә өмет йолдызы да җемелдәми. Исәннәрнең бар мәшәкате, ыгы-зыгысы чүп кенә булып тоела, аларның һәр сүзе хәсрәт ачысын гына арттыра.

Гарипләрнең, хасталарның көйсезлеген, тора торып холыксызлана баруын Бакыйдан да яхшырак аңлаган кеше бар микән?

Аның күңелендә дошман һаман да каты һөҗүмен алып бара иде әле. Ул Бакыйның үзәген яндырып юкка чыгарырга омтыла иде. Аны көйсез-холыксыз гарипкә әверелдереп, Һәдияне чын бәхетсез итәргә тырыша иде дошман. Әйтерсең лә ул ыргыткан гранатаның ярчыклары чир булып Бакыйны эчтән ашый иде.

Бәхеткә каршы, Бакыйга бу чирдән дару эчерделәр. Ачы иде ул дару...

Кичләрнең берендә, Һәдия ишектән керүгә, атасының кырыс тавышы ишетелде:

– Нишләп син, кызым, йөкле башың белән авыр әйбер күтәреп йөрисең? Ул нинди гадәт тагын?

– Юл уңаенда бәрәңге очраган иде шул, – диде Һәдиянең талчыгудан хәлсез тавышы.

– Ир хатыны лабаса син, авыр әйбер ташырга ирең бар!

– Ул бит... – дип киселеп калды Һәдиянең тавышы.

– Нәрсә ул? Өрлектәй егет ул. Белмим, нишләп оешып утыра торгандыр!

Бакый яңакларының ут булып кызганын тойды, үзе дә сизмәстән сикереп торды да сынын турайтып басты. Моңарчы бу йортта аңа авыр сүз әйткән кеше юк иде әле. Артык каты бәрелә түгелме ата кеше? Аны эшсезлектә, ялкаулыкта гаепли түгелме? Ничек оялмый ул?

Бу гаделсезлеккә каршы эчендә җыелган бөтен ачуны берьюлы чыгарып салырга һәм шартларга җитешкән күңелен шуның белән бушатырга дип авыз ачкан иде инде Бакый. Соңгы мизгелдә колагына кагылган сызланулы, ялварулы бер аваз аның сүзләрен тел очында килеш туктатып калды. Нинди аваз ул, нинди сыкрану? Бакый кулын хатынына таба сузды, ләкин учы бушлыкта эленеп калды. Бу ни хәл? Һәдия шунда, күптәннән килгән гадәте буенча, аның сул ягында тора бит, тигезсез сулышы да ишетелә. Бакый учын чак кына аскарак төшерде – тагын бушлык, аннан да астарак – янә берни юк. Һәдия дә аннан тайчана, ахрысы, бу йортта аннан көлә башлаганнармы әллә? Бу уй эчкә кайнар су булып коелды. Бакый кулын ташлады һәм шунда аның учы тупас, авыр итеп хатынының иңенә шапылдап килеп төште, Һәдия сыгылып киткәндәй булды. Тар, юка икән

аның иңнәре, кечкенә икән буе. Ничек соң әле Бакый моны оныткан, теге чакта, кинода очрашкач ук, кызның нәфис буй-сынлы икәнен күргән иде бит!

Хатынның иңбашы калтырана иде, Бакый аның тавышсыз үксегәнен аңлады һәм учы – кулы аша аның җан газапларын күргәндәй булды. Эштә арыган-талган ул, аннары озаклап чиратта торган, авыр әйбер күтәреп кайткан. Ә өендә ни көтә аны? Бакый кинәт Һәдиянең күзләре белән үзенең кыяфәтен, үзенең йөзен күргәндәй булды. Хикмәт күзләрнең йомык булуында гынамыни? Анысына, бәлки, күнегеп тә буладыр. Ә менә иренең җыерылган кашларын, кысылган иреннәрен, кара төннән караңгы чыраен күргәч, нишли икән Һәдиянең йөрәге? Кайчан елмайды соң әле аңа Бакый, кайчан күңелен күтәрергә тырышты? Гәүдәсе генә түгел, җаны көчсезләнә икән бит аның, теге чакта, кичке уенда, болында ак кофталы Һәдия тотынган тал чыбыгы кебек сыгылып бара икән бит ул! Шундый кешене күпме яратып була?

Әллә соң Һәдиянең күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь тамчылары түгел, иренә булган мәхәббәте түгелә микән? Бөтенләй түгелеп бетсә нишләрсең?

Һәм шунда Бакый үзен елмаерга мәҗбүр итте.

– Ник елыйсың, Һәдия, елама, – диде. – Күз яше ямьсезли бит ул, ә безнең улыбызга матур әни кирәк булыр. Әти дөрес әйтә, мин тик утырып, барысын да син эшләү килешми. Син миңа әйт кенә, мин бөтенесен эшләрмен.

Ул учы белән хатынының күзләрен сөртте һәм аның да яшь аралаш елмайганын тойды.

Менә шулай, әгәр бик теләсәң, дөнья яктысын сөйгәнеңнең күзләре аша күреп була икән. Улларыңның күзләре аша күреп була икән. Менә ничә еллар инде Бакый үзен ике улының күзләре белән күреп яши.

Марат туар алдыннан аларга аерым бүлмә бирделәр. Заманына күрә авыр яшәмәделәр; Бакый пенсия ала, аның Кызыл Йолдыз ордены белән икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденына да бераз акча килә иде. Һәдия эшен ташламады, балаларны Бакый карады.

Алар кечкенә чакта әтиләренең кешедән кимлеген аңламыйлар иде. Бакый, алар моны мөмкин кадәр соңрак белсеннәр өчен, бөтенесен эшләде.

Үз газапларыңны сиздермәскә, башкаларның борчуларын йөрәгеңә якын алырга... Үзеңне чолгап алган караңгылыкны уйламаска, бүтәннәр күреп торган якты дөньяны күз алдыңа китерергә.

Җиңел түгел иде моны эшләү. Шулай да Бакыйның күңелендә нинди көрәш барганын беркем белмәде. Өметсезлекнең һәм гаҗизлекнең көчле һөҗүмнәрен ул берүзе кире кайтарырга тырышты. Бу көрәштә җиңү аның тормышына балаларының көр күңеле, шат көлүе, Һәдиянең җан тынычлыгы һәм ышанычы булып килде: «Әтисе, синең белән киңәшәсе бар бит әле»; «Синең ярдәм кирәк бит әле, әтисе».

Күзе күрмәгәннәрнең колагы никадәр сак икәнен күпләр чамалап бетерми, янәшә бүлмәдә күрше хатыны белән Һәдиянең пышылдашып кына сөйләшкәнен ишетеп торган иде Бакый берзаман.

– Өйдән беркая чыгып булмый, балага күз-колак булыр кешем юк. Синеке янына кертеп куярдай булам кайчакта.

– И-и, ни сөйлисең син! – ди Һәдия. – Күз-колак бул дигәндә, юкка гына иң элек күз димәгәннәр бит инде. Фаязың соң, Фаязың, ул әйбәт күрә ләбаса!

– Фаяз кибет юлыннан кайтып керәмени, кайтса, анда бала кайгысымыни! Сугышта яралангач, күңеле сукырайды бит аның, күңеле! И-и, Һәдия, уңдың да инде син ирдән, иеме!

Чыннан да, фронтларда курку белмәгән егетләрнең дә кайсылары тыныч тормышта биреште шул, үз күңелендә барган көрәштә җиңеп чыга алмады.

Бакыйның да чигенеп куя язган чаклары булмады түгел, булды. Менә берзаман алар алты яшьлек Марат белән керосинкада чәй кайнаталар иде. Маратның кисәк: «Әти, яна, яна!» – дип чырылдап кычкыруы һәм көчле гөжләү авазы өнне алды. Баланы тотарга да чыгып качарга кирәк иде тизрәк. Ә соң сәламәт ата, көчле ата шулай итәр идемени?

Бакый, бөтен ихтыярын җыеп, тыныч тавыш белән:

– Хәзер туктатабыз без аны, улым, – диде һәм ятактан одеялны тартып алды. – Әйдәле, шушы одеялны ябындырыйк та йоклатыйк без ул утны. Тот әле бер кырыеннан. – Һәм үзе эссе гөжләүгә бик якын барып басты. – Әйдә ябындырыйк. Менә шулай. Ә хәзер өстенә су да сибик.

Дөрләп янган керосинкадан курыкмыйча, утны бик оста сүндергәнен шуннан соң Марат ифрат зур горурлык белән сөйләп йөрде.

Маратның кулы кечкенәдән эшкә ятып тора иде, үз юлын бик ансат тапты: мәктәп, армия, завод. Ә Ринат иркәрәк, шаянрак булып үсте. Бик шукланган чакларында да ачуланып булмый иде үзен, чөнки ул атасына малай чагын исенә төшерә иде. Әнә күрше бүлмәдән җиңелчә генә гырлаган тавыш ишетелеп куйды. Ринаттыр, мөгаен. Әллә аңа да яман төш керде микән? Булыр, бик мөмкин. Бакый төпчек улы белән үзе арасында зур уртаклык барлыгын тоя. Бәлки, төшләрнең дә бертөслесе керәдер аларга. Сугыш турындагы киноны кичә ул да карады бит. Әнисе әле улларына сукранып та алды:

– Әтиегезнең йөрәгенә тоз салып, һаман-һаман сугышны исенә төшереп утырмасагыз да ярар иде инде, – диде.

– Карасыннар әйдә, – дип улларын яклады Бакый. – Мин аңа борчылмыйм, радио тыңлыйм.

Карасыннар, сугыш афәтенең нindилеген белеп үссеннәр. Әтиләренең нинди дәһшәтләрне кичкәнен уйласыннар, киләчәктә явызлык белән йөзгә-йөз очрашырга туры килсә, гаделлек өчен көрәшергә әзер булсыннар.

Ә шулай да куркыныч төштән араларга иде баланы. Янына чыгып, өстен карарга, җайлабрак яткырырга кирәк иде. Ләкин Бакый Һәдияне уятудан курыкты. Юктан да сискәнеп сикереп тора торган гадәте бар, иртәнге тәмле йокысы бүленмәсен инде...

Әйе, яшьләрнең барысын да белеп, аңлап үсүен тели дә күңел, тик алар кайчак җиңелрәк уйлыйлар шул.

Ринатның башы яхшы эшли, тик менә дәресләргә күңел биреп җиткермәгән чаклары булгалады. Малай алтынчы класска җиткәч, әтисе аңа:

– Моннан соң укырга бергәләшеп йөрербез инде, – диде.

– Ә ник бергәләшеп?

– Шулай. Мин дә бит урта мәктәпне тәмамламаган әле. Укыган хәтлесе дә баштан очкан инде. Яңадан алтынчыдан башларга булдым менә.

Дәресләргә йөри башлагач, бармак белән укырга, язарга да өйрәнгәч, Бакыйның күңеленә дөньяның тагын бер нуры үтеп керде.

Аһ, әгәр дә безнең күз күремебез киңәйгән саен күңелдә якты, куанычлы уйлар гына арта барса икән лә! Юк шул, юк, алай булмый икән. Иске яра төпләрендә тимер ярчыклар кузгалып, төн йокыларын качырганда, хәвефле уйлар җанны талый. Киләчәк хакында ул уйлар, Маратның һәм Ринатның, бөтен кешелекнең киләчәге турында.

Теге чакта, дусларын дошман утыннан аралап торганда, корымланган кирпеч өеме артыннан ун башлы аждаһа килеп чыкмаганын, үлем-граната ыргыткан нәрсәнең гап-гади кеше кулы булганлыгын бик яхшы аңлый Бакый. Чит җирнең соргылт-комсу туфрагында яралган, үскән ул кул, бәлки, Бакый кулы кебек үк матур, сизгер, көчле – кыскасы, табигатьнең могҗизасына тиң булгандыр. Йортлар салыр өчен, иген үстерер өчен, чәчәкләр тотар өчен, кызлар кочар өчен, сабыйлар назлар өчен яратылган булгандыр ул. Нинди аяусыз көч ул кулны, аждаһага әверелдереп, тыныч шәһәр-авыллар, аналар һәм балалар өстенә үлем, дәһшәт чәчәргә мәҗбүр иткән?

Сугыш беткәч, аждаһа юк ителде дип уйлаганнар иде. Җиңү залплары җирдә тынычлыкның, иминлекнең мәңгелеккә барырлык тантанасы булып яңгыраган иде. Ләкин аждаһа тагын баш күтәрә, кара көчләр аны янә үстерә, куәт бирә. «Җир куеныннан аны алдылар, туплар патшасына саттылар...» Җир куеныннан алынган тимерне әле хәзер дә туплар патшасына саталар, аннан миналар, гранаталар коялар. Иген чәчәр өчен тракторлар, илләрне, кешеләрне бер-берсенә якынайта торган машиналар, самолетлар, яңа шәһәрләр торгызыр өчен куәтле краннар ясалырга тиешле тимердән үлем кораллары коялар. Монысын да аждаһага әверелгән кеше куллары башкара. Нинди законнар нигезендә мөмкин бу эш?

Бүген Ринат Тимершин беренче тапкыр университетка дәрес тыңларга бара. Ул укыр, белем туплар, акыл җыяр. Һәм кара көчләрне фаш итү, аларны җиңү юлларын эзләр. Җир йөзен гөлбакчага әверелдерергә тиешле адәм кулларының гөлбакчаларны кара көл итә торган аждаһага әверелүен мәңгегә туктату өчен тырышыр.

...Өметсезлеккә, күңел төшенкелегенә бирелгән өлкән апа белән бу хакта да сөйләшер бүген Бакый. Без бүтәннәр күргәнне тоя белергә тиеш, бары шул гына безне мескенлектән коткарып калачак, дияр ул. Бу хакыйкатьне белү, якты дөньяны башкалар күргәнчә күз алдына китерә алу көн яктысын күрүдән мәхрүм ителгәннәр өчен генә түгел, күзләре бик җете кешеләр өчен дә бик кирәк, чөнки ул – һәммә намуслы кешеләр өчен яшәешнең уртак законы.

* * *

Иртән-иртүк Марат эшкә чыгып китте. Аның артыннан Ринат җыена башлады. Кибеткә керүне сылтау итеп, әнисе аны озата чыкмакчы булды. Бакый аларны ишек төбендә озатып калды. Дулкынлануын яшерергә тырышып, улына:

– Хәерле сәгатьтә, – диде. Ә хатынынннан: – Матур киендеңме? – дип сорады.

– И-и, миңа кем карый? Ярамаган тагын!

– Сиңа бөтен кеше карый, Һәдия!

Бер уйлаганда, Һәдия – хатыннарның иң бәхетлесе: ире күңелендә ул картаймый, һаман унҗидедәге төсле булып саклана. Бакый аны беренче кинода күргәндәгечә итеп, түгәрәк алсу йөзле, нәфис гәүдәле итеп күз алдына китерә. Еллар узган саен, кешенең үзгәргәнен дә, ике бала анасының

гәүдәсе калынайганын да аңлый ул, Һәдиянең күптән инде маңгай чәчләрен юеш чүпрәккә урамаганын да белә. Ләкин хәтер моның белән исәпләшми, ул матурлыкны саклый.

Бакый улыннан:

– Әниең матур киенгәнме? – дип сорый.

– Әни, сал әле шул яулыгыңны, беретыңны ки, – ди Ринат.

Ә бераздан Бакый, тәрәзәдән башын сузып, аларның адымнарына колак сала. Менә алар тышкы ишектән чыктылар, Һәдия нидер әйтте, сүзләре аңлашылып бетмәде. Аннары икесе ике тарафка юнәлделәр: Һәдия – сулга, Ринат – уңга, трамвай тукталышына. Улының аяк тавышлары тәмам тынгач та, Бакый тәрәзә янында шактый уйланып торды.

Ә Ринат күптән инде өй почмагыннан борылган, ул эре, үрчемле адымнар белән җиргә нык басып бара, аның алтынсу куе керфекләр белән уратылган зәңгәр күзләрендә ак йортлар, агачлар, кешеләр, аяз күк йөзе, кояш нуры – барлык төсмерләре һәм муллыгы белән якты дөнья чагыла иде.

*1984*

## Сөюләрне үлчи торган бизмән бар микән?

Ул ишекне каерып ачты да каты басып килеп керде. Безнең башлар дәррәү аның тарафына борылды. Менә ул ян өстәл артында утырган Әнисә каршына барып басты һәм ачы тавыш белән кычкырырга тотынды:

– Ни йөзең белән утырасың син монда? Ничек оялмыйсың? Кеше ирен тартып алган хәсиснең монда утырырга ни хакы бар? Кабахәт син! Җир бит! Гөл кебек семьяны җимердең! Балаларны атасыз иттең! Ничек җир йотмый үзеңне!

Һәм ул, иелә төшеп, Әнисәнең битенә төкерде. Тагын ниләрдер кычкырды, кызарынып-ярсып таптанды да, ниһаять, борылып чыгып китте. Бүлмә тынып калды. Әнисә башын игән, күзен дә күтәрми, бер сүз дәшми. Без, бүлмәдәге тагын биш кеше – аның хезмәттәшләре, дуслары – телсез, өнсез калганбыз.

Әйе, дәшмәдек без, шым калып утырдык, башларда исә уй өермәсе бөтерелә иде. Әле чыгып киткән хатынны безнең беренче күрүебез, әмма аның кемлеген аңладык: яше утыздан узган Әнисәнең кияүгә чыгарга йөрүе турында хәбәрләр колакка килеп ирешкән иде инде. Булачак ире семьясыннан киткән, диләр иде. Димәк, бу шул Әнисәнең көндәше.

Әйткәнемчә, бу хатын безгә чит-ят иде. Әнисә исә ничә еллар бергә эшләгән хезмәттәшебез, якын кешебез. Нигә соң без аны бу рәвешле рисвай иткәнне тын калып карап утырдык?! Ник җәберләүдән аралап сүз әйтмәдек? Бер ым да какмадык? Чыгырыннан чыккан ул хатынны тәртипкә чакыру кирәк булгандыр бит!

Әгәр ул шунда көндәшен өстәл артыннан тартып чыгарып, аяк астына салып таптаса да, берәребез урыныннан кубар иде микән?!

Хикмәт шунда ки, ул хатынның болай кыланырга хокукы бар кебек тоелды безгә. Әнисә аның ирен тартып алмакчы булган. Ә ир бирмәк – җан бирмәк. Җанын көнчелек ялкыны көйдергән хатынның чамасыз ярсып китүе гаҗәпмени?

Шундый уйлар айкалды безнең башта. Һәрхәлдә, мин үзем шулай уйладым. Төкереген чәчеп тузынган хатын миңа хаклы, ә башын иеп утырган Әнисә исә хаксыз, аның кылганнары әхлаксызлык булып тоелды. Кеше ирен тартып алган хатынны кем мактасын да кем яклasын? Маңгаена хурлык мөһере суккандай иттеләр аны ул чакта! Һәм бу гадел җәза иде шикелле...

Һәркемнең күңелендә гаделлек бизмәне бар бит инде, ул чакта минем бизмәнем бу кешеләрнең гамәлләрен менә шулай үлчәде.

Аһ, бер мин генә булсам икән лә! Совет заманнары иде бит әле бу. Ул чактагы җитәкчеләр гаилә сагында калкан кебек нык торалар, аерылышуны загсларда рәсмиләштерү озак елларга сузыла. Ә инде тормыш иптәшеңә хыянәт иткәнеңне сизсәләр, эш бөтенләй харап. Җыелышларда тикшерәләр, тиргиләр, кисәтүләр чәпиләр, эштән куалар. Югары оешмаларга зарланып хат язучы гына булсын!

Әнисәнең көндәше мондый мөмкинлекне ычкындырмады, хатларны кат-кат язды, әлбәттә. «Унтугыз ел бергә яшәгән иремне тартып алды. Минем белән санашмаса, балалардан оялсыннар иде, ичмасам!»

Рәнҗетелгән хатынның бу сүзләре астына мин дә үз мөһеремне сугарга әзер идем. Мин гүяки күңелемдәге үлчәүнең бер тәлинкәсенә – Әнисә белән Сәгыйтьнең яратышуын, икенче тәлинкәсенә Сәгыйтьнең хатынын һәм буй җиткән ике баласын, аларның кичерешләрен салам. Мондый очракта йөрәк хисләреңне йөгәнләү тиеш дигән нәтиҗә чыгарып куям.

Миннән югарыракларның да бизмәне шулай тарта иде булса кирәк. Яхшы гына урында тырышып һәм макталып эшләп килгән Сәгыйтьне эшеннән чыгардылар. Кара данын койрык итеп тактылар, авылдан шәһәргә, Әнисә янына күчеп килгәч тә эшкә урнаша алмаслык иттеләр.

Әнисәне дә тынычлыкта калдырмадылар, билгеле. Аны да эшеннән кудылар. Шулай итеп, хурлык тамгасы сугылу өстенә алар ач калдылар.

Әнисә, кире үз эшенә кайтаруларын таләп итеп, судка бирергә мәҗбүр булды. Баксаң, ул йөкле икән, ә закон андыйларны эштән чыгаруны тыя. Кире кайтты ул, әмма инде элекке урынына түгел, түбәнрәк дәрәҗәле эшкә.

Ә Сәгыйть, югары белемле белгеч, тәҗрибәле һөнәр иясе була торып, биш ел буе вокзалда грузчик булып эшләде. Әйе, еллар буе капчык ташыды, әмма элекке гаиләсенә кире кайтып баш имәде. Әнисә янында калды.

Алар гомерләренең ахырына кадәр бергә яшәделәр. Ике балалары туды, аларны үстереп, кеше иттеләр. Бар иде бу парның сокланырлык яклары, бар иде җитеп бетмәгән җирләре. Өстән караганда, гадәти бер гаилә кебек күренә иде алар.

Әмма минем хәтеремдә теге хатынның тузынганы, Әнисәнең баш иеп тын гына утырганы әледән-әле яңарып тора. Нигә бер сүз дәшмәде ул чакта Әнисә, нигә сикереп торып аның якасына ябышмады?

Еллар узгач кына мин моның сәбәбен аңладым.

Сәгыйть белән Әнисә бер-берсен яшьли сөйгән булганнар икән. Мәктәптә укыганда ук яратышканнар, йөрешкәннәр. Тик өйләнешергә ашыкмаганнар, башта укырга, белем алырга, ныклап аякка басарга кирәк дип уйлаганнар. Институтны тәмамлагач, тагын бераз сабыр итәргә кирәк булган: зиһенле, уңган, иптәшләре арасында дәрәҗәле Әнисәне җитәкчелек эшенә әзерләргә ниятләгәннәр, янә ике елга укырга җибәргәннәр.

Ул киткән. Сәгыйть авылда калган. Табигатьнең үз кануннары бар бит әле, канның кайнавы бар... Кемнең күңел бизмәне төгәл – үлчәсен! Өйләнер чагы җиткән егетнең хис-тойгыларын үлчәү тәлинкәсенә салсын! Ничек-ничек булгандыр, анысы безгә караңгы, күптән үзенә кызыгып йөргән икенче бер кыз белән якынаеп куйган ул. Кешенең башы әйләнеп китеп, абынган чаклары була шул, ни хәл итәсең!

Шуннан соң... Шуннан соң шул: намуслы егет Сәгыйть ул кызга өйләнергә тиеш була. Аннары шактый еллар бергә яшәргә туры килә. Чөнки бер-бер артлы ике бала дөньяга килә, димәк, үлчәү тәлинкәсенә аларның язмышы да салына. Һәм җаваплылык, гаилә каршындагы бурыч йөрәк хисләреннән өстенрәк дип санала. Сәгыйть шулай, балалары мәктәпне тәмамлап, аякка басканчы, алар янында яши.

Беренче мәхәббәте сүнмәгән-сүрелмәгән кеше өчен озын гомер бу, ай-һай озын! Ә Сәгыйтьнең хисләре сүрелми. Әнисәнең башканы яр итә алмаганын, ялгыз яшәгәнен белеп торганга күрә, күңел күгендә балкыган өмет йолдызын узган гомер җилләре алып килгән болытлар каплый алмый. Вакыт узган саен, яктырак яна ул.

Инде килеп балаларның канат ярып очарга, үз ояларын корырга вакыты җиткәч, алар, ниһаять, аңлашалар. Яшәүнең мәгънәсе, бәхетнең зурысы сөйгәнең белән бергә булуда икән бит! Алларында нинди генә киртәләр торса да, бирешмәскә вәгъдә итәләр.

...Эчендә нинди утлар янганын кеше үзе генә белә. Әнисәнең намусындагы гаделлек бизмәненә ниләр салынганын мин еллар узгач кына аңладым. Үлчәүдә сөю хисе генә түгел, туачак балаларның да язмышы булган икән. Йә бу якты дөньяга киләчәк алар, йә юк... Шуларның барысын да уйлаган, үлчәгән ул һәм... яшьлегендә башка хатынның, ул хатыннан туган балаларның хакын үзенекеннән өстен бәяли белгән. Ә бәлки, вакыт йөрәк хисләрен сүрелдерер дип тә өметләнгәндер. Әмма чын мәхәббәт сүнми-сүрелми диләр бит. Инде теге балалар аякка баскач, Әнисә белән Сәгыйть үзләренең бәхетен якларга хаклары бар дип санаганнар. Моның өчен аларга, әйткәнемчә, бик күп сабырлыклар кирәк булды.

*2004*

## Серле сурәткә гыйшык

Үзеңә тиң парны, гомерлек ярны ничек табарга?

Бу сорауга төпле җавап биргән кеше юк бугай әле. Кызганыч, әгәр дә үз парыңны табуның ысулларын, шулпалы бәлеш яисә кыстыбый пешерергә өйрәткән кебек, бәйнә-бәйнә язып, китап итеп бастырып чыгарсалар, кемне сайларга белми аптырап йөргән яшь-җилкенчәккә нинди җиңеллек булыр иде бит, әй! Алдагы көндә күпме борчу-йончудан, хәтта бәхетсезлекләрдән сакланып калыр иде алар!

«Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта», – дигән шагыйрь. Әйе, бер күрүдә күзе тонып, гашыйк булучылар бар. Хәер, монысына яхшы гына дәва бар икән үзе, икенче тапкыр караганда, игътибарлырак булырга кушалар икән. Бергә укыганда яисә бергә эшләгәндә әкренләп бер-берсенә ияләшеп китүчеләр бар... Кемнәрдер кемнәрнеңдер туенда очраша...

Ә менә мин фоторәсемгә гашыйк булган берәүне беләм. Хәйдәр исемле бу егетнең Алабуга милиция мәктәбендә укыган чагы. Криминалистика буенча практика үткәндә, аларны шәһәр фотолабораториясенә алып баралар. Укучылар әзер негативлардан фото ясарга тиеш була. Карточкалар ясаганда, бер кәгазьдә өч кызның сурәте килеп чыга. Белмим инде, булачак милиционер ул кызларга нинди күз белән карагандыр да ни өчен шуларның берсен, аерып алып, зур итеп ясагандыр? Укучының бу «криминалистик эше»н, иң шәп ясалган карточкалар белән бергә, мәктәп стенасындагы тактага – күргәзмәгә ябыштырып та куялар.

Портреттагы кыз гүяки Хәйдәрне иртәләрен каршы ала, кичләрен озатып кала. Ләкин кем соң ул? Ничек үзен табарга, кайда очратырга? Әмма кыз ул йөргән юллардан ерак, Идел аръягында ук икән шул...

Күпләр кочаклашып сөешкән, мәңге ташлашмаска вәгъдә бирешкән ярларын да, аралар ерагайса, озак күрешми торсалар да, онытып җибәрә. Ә менә Хәйдәрнең теге серле сурәткә гыйшкы шулхәтле көчле була, айлар үтә, ул көтә, очрашуны өмет итә. Берәүләр моны белсә, саташкан бу, дияр иде. Бик яшь тә түгел бит инде үзе, армиядә хезмәт иткән, егерме биш яшен тутырган.

Теләгән морадына ирешер, өзелеп көткән барыбер очрашыр. Сентябрьдә Буа районы кызы Зөбәрҗәт Алабугага үзе килеп чыга. Ул культура-агарту училищесында читтән торып укый икән. Бу юлы көзге лекцияләр тыңларга килүе була аның. Бер шимбәдә аны дус кызы милиция мәктәбенә, бию кичәсенә алып бара. Кереп баса кызлар стена буена, музыка уйный башлый, сары чәчле, зәңгәр күзле, бөтерчек кебек хәрәкәтчән Зөбәрҗәтне милиция киемендәге бер егет биергә чакыра һәм:

– Ә миндә апагызның карточкасы бар, – ди.

– Нинди карточка ул? Апам юк ич мине-е-ем, – дип җавап бирә Зөбәрҗәт. Аның шулай сүзнең ахырын сузыбрак әйтә торган гадәте бар.

– Әнә бит, – ди Хәйдәр, – стенада эленеп тора. Әйдә күрсәтәм. – Бәй, мин бит бу-у-у! – ди Зөбәрҗәт. – Чәчемне кистергән чагым, шуңа олы күренәм. Мин үзем аерым карточкага төшмәгән идем би-и-ит!

– Өчәү төшкәнсез.

– Язын имтиханнар бирергә килгәч төшкән идек шу-у-ул!

Әйе, кыз Хәйдәр уйлаганнан шактый яшь булып чыга. Берничә тапкыр гына очрашып кала алар, аннары кыз Буа районына, Югары Лашчы авылына кайтып китә.

Ә мәхәббәт һич кимеми, яндыра да көйдерә егетнең йөрәген. Түзә алмый, ул кышкы каникул вакытында, үзәк өзгеч суыкта, алдан хәбәр итми-нитми генә, Зөбәрҗәтнең авылына барырга ниятли. Китә поездга утырып, барып җитә Лашчы дигән станциягә. Лашчымы? Лашчы. Төшеп кала бу. Ләкин, баксаң, аңа кирәк авылга – Югары Лашчыга бару өчен поездан Буада ук төшеп калырга кирәк булган икән. Төнгә каршы, суыкта тагын унбиш чакрым барасы. Нишләргә? Акыл белән эш итүче берәү булса, кулын селтәр иде дә, каршы килгән җылы поездга утырып, кире китеп барыр иде.

Әмма Хәйдәр бүтән камырдан әвәләнгән шул. Аптырап калмый, китә бу бригадирны эзләп. Шулай-шулай, ди, Югары Лашчыга милиция эше белән баруым, ярдәм кирәк. Бригадир аның өстендәге шинеленә карый да ат җиктерергә чыгып йөгерә. Шулай итеп, Зөбәрҗәтнең өенә ат белән илтеп куялар Хәйдәрне. Шуннан, әллә сез аны авылда көтеп торганнардыр, дисезме? Дөрес, кышкы суыкта катып-туңып кергән юлчыны куып чыгармыйлар, табынга утырталар, тугыз яшьлек улларына ияртеп, әзер мунчага җибәрәләр.

Тора-бара егетнең ни йомыш белән килеп төшкәне беленгәч, әти кеше кызы белән бик җитди сөйләшә: милиция белән башыңны бәйләсәң, бәхиллегем юк, ди. Чөнки репрессия заманында җәбер күргән гаилә була бу, форма кигән кеше күрсәләр, йөрәк түрләрендә ачы хатирәләр уяна икән.

Шуның өстенә Зөбәрҗәтнең йөргән егете дә бар икән бит әле! Авылда хәбәр тиз таралучан. Егетләр җыелышып, килмешәк милиционерны караңгы урамда тотып алып кыйнап ук ташлыйлар.

Инде, шулай булгач, ни өмете кала иде соң бу «сурәткә гашыйк» тинтәкнең? Әмма чын сөю өчен киртә була димени?! Хәйдәр дә, тырыша торгач, Зөбәрҗәтне үзенә карата. Яз, җәй аңлашалар, көзен – туй.

...Мин дә булдым аларның туенда. Көмеш туйга чакырдылар алар мине. Инде егерме биш ел бергә гомер иткәннәр. Карточкага кабынган мәхәббәтнең дәвамы булып, тирәләрендә консерватория тәмамлаган уллары Эдуард, институт тәмамлап килүче кызлары Эльвира, нәни оныклары Камилә бөтерелеп йөри. Зөбәрҗәтнең тынгысыз эшләренә – фәкыйрьләргә ярдәм өләшкәндә, Кызыл Ай җәмгыятенең кичәләрен үткәргәндә, гуманитар колонналарны оештырып ерак юлга озатканда – Хәйдәрнең армый-талмый булышып йөргәнен күрсәң, исләрең китә! Әйе, бу пар бер-берсенең күңелен, теләк-омтылышларын аңлый белә. Хикмәт ничек гашыйк булуда түгел, ничек яши белүдәдер, күрәсең.

*2005*

## Әти күрше фатирда яши...

Бервакыт шулай безне туган районыбызга очрашулар үткәрергә чакырып алдылар. Арада без ике хатын-кыз булып чыктык: республикада танылган профессор, нейрохирург, күрше авыл кызы Асия белән шунда таныштык. Ул да минем кебек бишенче дистәне ваклаган кеше иде, серләр килеште, дуслашып киттек.

Безнең авылга кайткач, табигый инде, кунарга мин Асияне үзебезгә чакырдым. Ерак шәһәрдән туган ягына кунакка олы абыебыз, әнинең бертуган энесе дә кайтып төшкән икән. Кунакларны таныштырдык. Шунда Асия гаҗәпләнеп, хәтта аптырап калды. «Ничек? Әниегезнең бертуганы дисезме?» – дип кабатлап сорады ул. Без дәррәү көлешеп куйдык. Чөнки абыем белән әниемне беренче тапкыр янәшә күреп, бертуганнар икәнен ишеткән күпләр шулай гаҗәпләнә. Ник, дисәгез, алар бер-берсенә бөтенләй охшамаганнар, хәтта капма-каршы дип әйтергә була: әнием кара чәчле, коңгырт күзле, каратут озынчарак йөзле, абыйның исә күзләре зәп-зәңгәр, чәче сап-сары, йөзе ап-ак.

– Алдамыйбыз, шаяртмыйбыз, – дидем, – икесе дә Сабировлар, Шакир балалары.

Ләкин Асия бик җитди калды, бу икәүнең язмышы гади түгеллеген, ниндидер хикмәт барлыгын сизенде булса кирәк.

Соңыннан, кич җитеп, йокы бүлмәсендә икәүдән-икәү генә калгач һәм өске утны сүндереп, сары абажурлы өстәл лампасын кабызгач, мин Асиянең әнием белән абыем турында сораячагын аңладым. Тик ни өчен бу икәүнең язмышы аны уйландыра, ник борчый? Анысын мин белми идем һәм сорарга вакыты да җитмәгән иде әле.

Ләкин алтынсу лампаның серле яктылыгы, авылда гына була торган рәхәт тынлык, үзебезнең дә инде, матур киемнәребезне салып, төнге күлмәкләрне киеп, кара-каршы бик якын утыруыбыз серләрне чишәргә юл ачып куйган иде.

Без язмышларның төрле, катлаулы, кайчакта аяныч булуы хакында сөйләшә башладык. Халыкта «туасы җан» дигән сүз бар. Менә шул туасы җан кайда, нинди ояда дөньяга килә? Кем көтеп ала аны, кем назлап үстерә? Әгәр туган оясы китек булса, ул кемнәрнеңдер бәхетсезлегенә туса, сабыйның монда ни гаебе бар?

Менә безнең Алтын абыебыз. Мин аңа шулай дип дәшәргә яратам. Ул да бит шул туасы җан булган, китек ояда дөньяга киләсе җан...

Ватан сугышы алдыннан безнең бабабызны күрше райондагы ерак бер авылга трактористлар өйрәтергә җибәргәннәр. Бик яхшы тракторист булган ул. Әбием исә, сабыен – минем әниемне карап, өйдә калган. Өчме-дүртме ай читтә яшәп кайткан бабабызның артыннан кара сөрем булып гайбәт килеп төшкән: ул андагы авыл советы секретаре белән бәйләнгән, имеш. Хәзер безгә сөйләве рәхәт, ә ул чакта итәгендә имчәк баласы утырган яшь хатынныңниләр кичергәнен кем әйтеп бирә алыр?

Ни булса, шул булган, ул чакта авыл җирендә аерылышу хәлләре юк. Өйдәге чүпне читкә чыгармый гына яшәп яталар икән болар. Тагын ярты ел узгач, әбинең колагына яңа хәбәр китереп ирештерәләр: теге авылда бабайның улы дөньяга килгән, имеш, туу турында таныклыгына да Шакир улы Сабиров дип язып куйганнар. Әйткәнемчә, малайның әнисе авыл советы секретаре булган бит.

Озакламый сугыш башлана, ул инде бөтен язмышларны пыран-заран китереп бутап бетерә. Бабабыз сугышта һәлак була. Бер атаның ике баласы төрле якта ярым ятим үсәләр шулай. Әни сөйли, әтисез дә калгач, бердәнбер бала булып үсү миңа бик читен булды, башка йортларда балалар күп иде, мин аларга бик кызыга идем, туганым барын белсәм, җиңелрәк булыр иде, ди. Әмма әбиебез аңа серне чишмәгән.

Абыебыз ниләр кичергәндер, сораштырганыбыз юк. Алар әнисе белән Урал якларына китеп барганнар, шунда урнашып калганнар. Күп еллар узгач, без үсеп килгәндә, инде әбием вафат булганнан соң, Урал якларыннан хат килеп төште безгә. Шакир улы Сабировтан. Әниемнең куанычын әйтеп бетерерлек булмады. «Әниемне күмгәч, берьялгызым калдым дигән идем, минем дә туганым бар икән бит!» – ди.

Гаиләбез түгәрәк, әнинең ире, өч баласы янында иде бит югыйсә. Тик тормышта һәр якын кешенең йөрәк түрендә үз урыны бар, берәүне берәү алыштыра алмый, күрәсең. Менә шулай итеп, безнең Алтын абыебыз булды!

Кыйссамны тәмамлаганда, Асиянең миңа кушылып елмайганын көткән идем. Әмма ул башын иеп утыра бирде, күтәрелеп карамады, сары яктылыкта йөзе ничектер сүрелеп, караңгыланып киткән кебек иде хәтта.

– Нинди туган табыла бит, – диде ул шактый коры, хәтта каты итеп. – Зинадан туганның кем булып үсәсен каян беләсең? Ярый ла сез Алтын абыйлы булгансыз! Әгәр төрмәдә утыручы бандит булып чыкса? Ни дияр идегез ул чакта?

Мин аптырап киттем: абыем турында «зинадан туган» дигән сүзне ишеткән дә юк, үзебезнең дә башыбызга килми иде. Гомер буе намуслы яшәгән кеше, алтын куллы слесарь ул безнең. Ләкин юкка гына әйтелмәгән иде бу сүзләр, бер-бер хикмәте, Асиянең бәгырен талаган сере булырга тиеш иде моның.

Без шактый вакыт сүзсез утырдык, бүлмәнең бер почмагында сайраган чикерткә генә тынлыкны боза иде. Мин сорамадым. Асия үзе, ниһаять, тәвәккәлләгәндәй тирән сулыш алганнан соң, сөйли башлады: авыр уйлар белән күңеле мөлдерәмә тулы, бушатырга кирәк иде, күрәсең.

– Сез минем иремне беләсез, Казанда гына түгел, республикада мәгълүм кеше, чөнки ул җитәкли торган завод бик зур. Кая гына барса да, халык арасыннан бер башка калкып, әллә каян күренеп тора, үзе хәрәкәтчән, үткен зиһенле, шат күңелле, башкаларны буйсындыра торган нык ихтыярлы. Зур заводларны көчле шәхесләр генә кулына ала да. Андыйларның дәрте ташып тора. Без танышканда, мин студент идем, ә ул заводта цех начальнигы иде инде. Миңа уңга-сулга карарга мөмкинлек калдырмады, бер ярты ел очрашып йөргәннән соң, өйләнде дә өенә алып кайтып куйды. Мин «өйләнештек» дип тә әйтә алмыйм, чөнки бу аның ихтыяры белән эшләнде, мин үзем, диплом алмыйча, кияүгә чыкмам, дигән идем.

Гомерем буе абыем кебек булды ул, мин һәрвакыт аның өстенлеген тоеп яшәдем. Бер адым атлаганчы, ул моны ничек кабул итәр дип уйларга күнектем. Аңа тиң булыйм, аның каршында горурланырлык эшләрем булсын дип тырыштым. Бәлки, шуңадыр, институтны бик яхшы тәмамладым, мине кафедрада калдырдылар, бик тиз кандидатлык диссертациясен якладым һәм зур тырышлык белән докторлык диссертациясе язарга керештем. Клиникада эшләп кайткач, фәнни хезмәтләр язарга кирәк, кызыма да игътибарны киметмәскә тырыша идем. Кыскасы, як-ягыма карарга, иремнең кайда йөргәнлеген тикшереп торырга вакытым да, көчем дә калмый иде. Иремнең дә эше баштан ашкан дип белә идем.

Ләкин шунысы бар: уңган кеше һәммәсенә җитешә. Аның башка берәү белән очрашуы турында сүз ирештергәннәре булгалады. Ә мин ишеткәннәремне иремә кайтып сөйлим, ул аларны шундук юкка чыгара, икәүләшеп көлә идек тә шуның белән бетерә идек.

Тик бөтенләй онытып булмый икән шул, андый ямьсез хәбәрләрнең агулы орлыклары күңел түренә коелып кала икән дә, җае туры килгәндә тамырланып, үсеп-зураеп синең бәгыреңне талый башлый икән.

Берзаман безгә җитәкчеләр өчен махсус төзелгән яңа йорттан фатир бирделәр. Без башкалардан соңрак күчендек. Әгәр белгән булсам, бөтенләй дә күченмәгән булыр идем дә бит, алга килми белеп булмый башның ни күрәчәген. Көннәрнең берендә эшкә ашыгып чыгып бара идем, өске каттан сигез-тугыз яшьләр тирәсендәге бер малай йөгереп төшеп килә. Аркасында сумка, мәктәпкә баруы. Күрүгә тынсыз калдым: иремнең малай чагы йөгерә иде миңа таба. Үзем дә белештермичә: «Син кем?» – дип сорадым. Ул исемен әйтте. «Кем малае син?» Ул заводның профсоюз җитәкчесе булып эшләүче хатынның исемен атады... Электән килеп ирешкәләп торган теге яман хәбәрләр дә шул хатын турында иде...

Мине алырга машина килгән иде. Мин малайдан кайсы якка баруын сорадым. Мәктәбе шактый ерак икән. Аны машинага утыртып алып киттем. Ник утырттым, нәрсә сорашырга теләдем? Хәзергә хәтле аңламыйм. Минем аңа тагын, тагын, тагын карыйсым килә, үземне-үзем, юк, бу очраклы охшашлык кына дип ышандырасым килә иде. Азмыни дөньяда кара кашлы, коңгырт күзле, туры борынлы, чокыр иякле кешеләр! Ул арткы утыргычта, мин алда, каршымдагы кечкенә көзгегә карап барам, малайның йөзеннән ят чалымнар табарга тырышам. Аның урынына танышлыкны гына табам. Башын борганда ияген чөеп җибәрүенә кадәр иремнеке. Ә мин беренче очрашкач ук аның шушы сөйкемле ымына игътибар иткән идем, шуның өчен ярата идем...

Кичергәннәр мине аңлар, тик берәүгә дә язмасын. Машинада утырып барган берничә минут эчендә мине тәмам кешелектән чыгарды бу малай...

Клиникага барып керүемә, табиблар миңа ярдәмгә ташландылар. Укол ясадылар, каты чәй бирделәр. Тешләрем стакан читенә шыкы-шыкы бәрелде. Ул көнне мин бик җаваплы, катлаулы операция ясарга тиеш идем. Озак әзерләнгән идем мин аңа. Ләкин ясый алмадым.

Хәзергә хәтле аңлый алмыйм: ярый, кеше ире белән йөриләрдер, андый хәлләр буладыр, ләкин нигә ул фатирны безнең белән бер йорттан, хәтта бер подъезддан алды икән? Ахырда үз-үземә болай аңлаттым: бу хатынның максаты – ничек тә булса минем иремне тартып алу. Аны үзенә өйләндерү. Кызымны әтисеннән мәхрүм итеп, үз баласын әтиле итү.

Монда минем гауга куптаруым, иремне туктаусыз талавым, аның тормышын җәһәннәмгә әйләндерүем ул хатын өчен бик кулай булачак иде. Ни ярсысам да, ни газаплансам да, йөрәгемнең чамасыз сызлавы акылымны басып китәргә тиеш түгеллеген аңладым.

Бер көнгә түзим, дидем, иремә авырып китүемнең чын сәбәбен әйтмәдем. Аннары тагын бер көн түздем, тагын, тагын... Ышаныгыз, мондый хәлләрдә иң якын сердәшләрең белән киңәшү дә файда китерми, чөнки, көндәшеңне фатирыннан кудыр, ireңә, икенең берсен сайла дип, катгый шарт куй,

сымаграк киңәш бирүчеләр күп булыр. Монда фәкать үзеңне генә тыңларга кирәк, анда да салкын акыл белән уйларга. Кызган баштан ни дә булса эшләү һич ярамый. Чөнки сүз ахыр чиктә үз язмышың гына түгел, балаң язмышы турында бара.

Белмим, ун елдан артык бергә яшәгән ире өчен минем кебек газапланган, шундый авыр көрәш алып барган берәү бар микән тагын?

Гаиләмә каты, аяусыз һөҗүм барганын аңладым мин. Җиңелсәм, ул – ирле, малае этиле була. Ә мин – ирсез, кызым этисез калачак. Алда әйткән идем инде, мин һәр эштә иремнең таза беләгенә таянырга, һәр авырлыкны аның киң җилкәсенә аударырга күнеккән идем. Хәзер исә бөтенесен үз өстемә алырга, хәсрәтне эчемә йотарга туры килде.

Гаиләбезгә килгән һөҗүмне үз күкрәгем белән капларга тиеш булдым мин.

Теге хатын үз максатына ирешү өчен зинадан туган баласын көчле корал итеп файдаланырга тырышты. Малай минем кызымнан бер генә яшькә кече, йә китап, йә дәфтәр, йә берәр киңәш сорап ишегебезне еш кага торган булып китте. Ләкин мин аны беркайчан да бусагадан кертмәдем. Кызымны да бик каты кисәттем: малайны кертмәскә, үзенә дә аларның ишегенә якын бармаска, китап-дәфтәрләрне баскыч мәйданчыгында алышырга һәм кирәк сүзне дә фәкать шунда гына сөйләшергә куштым. Ә теге хатынның иң зур максаты – балаларны аралаштыру, дуслаштыру, улын безнең өебездә үз кеше итү иде!..

Мин эчемә ут йотып, тыштан көлеп яшәгән артисткага әйләндем. Менә ул – иремнең уйнаштан, миңа хыянәтеннән туган баласы, минем күз алдымда йөри; менә ул – минем көндәшем – иремне тартып алырга ашкына, ә мин берни белмәгәнгә, берни күрмәгәнгә салышам, бәхетле хатын ролен уйныйм! Элегрәк журналда укыган идем, бер танылган артисткабыз сугышта ире үлгән хәбәрне алган көнне комедия уйнаган, дип. Мин ул комедияне меңнәрчә көннәр буе уйнадым.

Кешелегемне югалтуым, акылдан шашуым бар иде. Бала коткарды. Әйе, тәвәккәлләдем, диссертациямне куеп тордым, бала таптым. Үз күңелемә дәва булсынга да, кызымны ялгыз калдырмас өчен дә кирәк иде ул. Язмыш бу юлы миңа мәрхәмәтле булды – улыбыз туды.

Ир бала теге хатынның өметен сүндерә язды, әлбәттә. Аның тамырын кисү өчен мин үзем дә нык тырыштым.

Нинди генә кимчелеген күрсәм дә, кемнән генә аның хакында начар сүз ишетсәм дә, иремә ирештерә килдем. Ачу белән, үчләнеп түгел, бер мәзәк итеп кенә сөйли идем мин аларны. Баштарак ул моңа кашын җыергалый иде. Ләкин тора-бара тыныч тыңлый башлады. Тамчы таш ярды. Бәлки, башка сәбәпләре дә булгандыр, әкренләп иремнең ул хатыннан тәмам гайрәте чиккәне сизелде. Рухы, җаны өйгә кайтты.

Миңа соңыннан сөйләделәр, теге хатынны каядыр югары урынга сайламакчы булганнар икән. Ирем җыелышта аның турында зур эшләргә лаек түгел дип чыгыш ясаган, теге исә, һуштан язган, диделәр. Шуннан соң озак та үтми, ул, фатирын алыштырып, безнең йорттан күчеп китте...

Узган елны институтта минем кырык яшемне бәйрәм иттек. Иремнең анда минем хакта сөйләгәнен үзем дә хәйран калып тыңладым. Аныңча әйтеп бирә алмам, чөнки без икебез дә нык дулкынланган идек. Ул эшендә зур дәрәҗәгә ирешкән өчен дә, гаиләбезнең тигез, имин булганы өчен дә бөтен халык каршында миңа мең-мең рәхмәтләр укыды...

Асия шунда тынып калды. Мин дә ни дияргә белмәдем, нәрсәдәндер зиһенем таралган иде. Тукта, нигә моңсу соң әле ул һаман? Нигә җиңү куанычыннан, бәхетеннән тураеп утырмый, ник күзләрен аска терәгән? Ә-ә, теге бала...

– Ә... ул кайда соң? – дип сорадым, балаларыгызның туганы дип әйтүдән чак тыелып.

– Белмим... Беләсем дә килми. Балаларымның да белүен теләмим...

Аның бая әйткән: «Әгәр ул бандит булса?» – дигәне искә төште. Авызымны ачкан идем инде, тик Асиянең йөзенә карадым да дәшмәдем.

Ул төнне мин бик озак йоклый алмадым. Теге малайның хәлен күзалларга тырыштым. Аның урынына үземне куярга тырышып карадым. Әти күрше фатирда яши... Аңа бүтән бер кыз, бүтән бер малай «әтием!» диләр... Ә миңа алай дәшәргә, аңа якын барырга ярамый...

Нинди булып, кем булып үсәр идем мин шуннан соң?!

Юк, мин мондый хәлне күз алдыма китерә алмадым...

*2005*

## Саф мәхәббәт турында бер кыйсса

Зәйтүнә бакча йортының өске кат тәрәзәсен ачты да ах итте: сиреньнәр чәчкә атып килә икән ләбаса! Өй түрендә биегәеп, куерып үскән ике куакның сабаклары берсе – ап-ак, икенчесе алсу-шәмәхә тәлгәшләр авырлыгыннан юлга таба авышканнар. Башны әйләндереп, хуш ис бөркелә. Бер-ике көннән бөреләр тәмам ачылыр, агачлар яшәү, яшьлек тантанасы булып ерактан балкыр. Үткән-

сүткән һәркем тукталып калыр, сынын турайтып, башын күтәреп, берсе акка, икенчесе алсу-шәмәхәгә төренгән ике агачка хәйран калып басып торыр. Күзләр җетеләнер, күкрәкләргә хуш исле, шифалы дулкын бөркелеп керер дә, моң-зар юшкыннарын юып алып, күңелләрне сәбәпсез куаныч, яшәү дәрте белән мөлдерәмә тутырыр. Андый минутларда адәм баласының йөзе күкрәп чәчәк аткан гөлләрдәй гүзәл була.

...Бакчада гөлләрнең төрлесе бар, ләкин менә үзе утыртып үстергән сиреньнәрне аерата ярата Зәйтүнә. Менә хәзер берәрсе килеп чыксын иде дә бу гүзәллекне күрсен иде.

Ул, тәрәзәдән үрелеп, уңга-сулга карады. Әнә бит берәү килә. Таныш сын... Зәйтүнә, кабаланып, тар баскычтан аскы катка томырылды. Илледән узган хатынның болай җитез хәрәкәтләнгәнен берәрсе күрсә, гаҗәпләнеп куяр иде... Менә ул атылып аллеяга чыкты, сирень куагына карап, чирәмгә басты. Аргы баштан килүченең адымнары якынлашты... Аның турына килеп тә җитте, шул ук көй белән атлап узып та китте. Зәйтүнә түзмәде, борылды.

– Фоат!

– Исәнмесез, Зәйтүнә Мәҗитовна...

– Саумы, егет! Нишләп дәшми генә узып китәсең әле? Кыш буе очрашкан булмады. Күрешик, хәлләрне белешик!

Уналты яшьлек малай, кыска кара чәчле түгәрәк башын иеп, карашын чирәмле сукмакка текәп басып тора, кыска балаклы күксел чалбар кесәсендә бармакларының тынгысыз тыпырчынганы сизелә.

Ай-һай, бу бала да егет булып килә икән ләбаса! Бер кыш эчендә, күр, ничек биегәеп куйган. Олы апасына өстән карарга читенсенә үзе, ак футболкасын тарттырып торган киң иңбашларын салындырырга тырышып, тезләрен бөгебрәк баскан. Әнә бит борын асты ничек матураеп каралган – мыек чыгып килә!

– Сиреньнәрне күрмисең дә инде әллә?

– Ничек инде күрмәскә?! – ди Фоат үсмерләргә хас тотрыксыз тавыш белән. – Хуш исе әллә каян аңкып тора...

– Чәчкәләре ачылып беткәч күрерсең әле! Син онытмагансыңдыр бит?

– Нәрсәне?

– Үзеңә йөкләнгән бурычны хәтерлисеңме?

– Бурычны?!

Малай, иелгән башын сөйкемле янтайтып, туры кашлары астыннан түгәрәк коңгырт күзләрен елтыратып карап алды.

– Узган елны әйткән идем ич! Тәлгәшләр куакта килеш шиңмәсен – шуны кайгыртырга тиеш син! Югыйсә киләсе елда чәчкәсе күп булмас. Бер-ике атна эчендә өзеп бетер син аларны!

– Шушы хәтлене ме?

Аның гаҗәпләнүе кызык тоелды, Зәйтүнә көлеп җибәрде:

– Чәчкә күп була димени! Өегезгә алып кайт, күршеләрегезгә бир.

– Квартира саен өләшеп йөрергәме?

– Син беләсеңме, күпме кеше бу гүзәллектән мәхрүм? Ишегалдыгыздагы карчыкларны сөендер! Аннары... – Зәйтүнә чак кына тынып торды, – кызларга бүләк ит!

Соңгысын ишеткәч, малай башын тагын да түбәнрәк иде, аның җыйнак, түгәрәк колак яфраклары алланып чыкты.

– Килештекме? – диде Зәйтүнә.

– Ярар... Сау булыгыз...

Малай, җиңел сулап, китү ягына борылды.

– Әти-әниеңә сәлам әйт. Исән-саулардыр бит?

– Саулар...

Ах, аның, тезләрен аера төшеп, җилкәләрен артка таба киереп, башын югары күтәреп, очынып атлаулары! Фоат, Фоат! Күптән узган, бик еракта калган язлардан әйләнеп килдеңме әллә син?

Малайның сыны юл борылышындагы агачлар артына кереп югалгач кына аңына килгәндәй булды Зәйтүнә. Тирән итеп көрсенде дә зәңгәр өйгә кереп китте.

Ул бүген ялгыз иде. Ире икенче шәһәрдә, табибларның белемен күтәрү курслары үткәреп йөри. Улларының да, кызларының үз гаиләләре, бу бакчага су коенып чыгарга гына килгәлиләр. Сиреньнәрнең чакыруын тоймый-сизми шул алар. Ә бәлки, ул чакыру Зәйтүнәнең йөрәгенә генә килеп тоташадыр, аны гына тәкатьсез итәдер... Кил, диләр чәчкәләр, яшьлегең гөлләре белән очраш... Без сиңа беренче мәхәббәтең турында сөйләрбез, диләр...

Ә менә бүген сөйләп кенә дә калмадылар, үзе белән очраштыргандай иттеләр!..

Кич буе, нишләгәнен белештермичә, үзалдына көлемсерәп, әкрен тавыш белән һаман бер җыр көйләп йөрде ул:

Гөлбакчага керәм мин,

Гөл чәчәген өзәм мин...

Караңгы төшкәч, өске каттагы бүлмәгә менде ул. Утны кабызмады. Ачык тәрәзәдән аяз күктәге йолдызларга карап, сандугачлар сайравыннан, тыштан бөркелгән җиләс, хуш исле һавадан сихерләнгәндәй, кымшанмыйча басып торды. Ә күңелдә, кошлар тавышына кушылып, һаман бер җыр тибрәлде:

Гөлбакчага керәмсең,
Гөл чәчәген өзәмсең...

Дөнья шулкадәр гүзәл һәм нилектәндер үзәкне өзәрлек ямансу иде!.. Ниндидер бушлык бар иде җиһанда, нидер җитми иде җанга...

Кинәт каяндыр көлгән тавыш ишетелде. Яшь бер кызның дәртле очыну белән мөлдерәмә тулган күңеленнән тыелгысыз бөркелеп чыккан бәхет авазлары иде бу. Шунда дөнья түгәрәкләнеп киткәндәй булды. Менә нәрсә җитмәгән икән лә йолдызларның серле нуры белән бизәлгән, гөлләр хуш исенә туенган, сандугачлар моңына күмелгән бу бакчада! Яшьлек бәхетен игълан иткән тыенкы, саф көлү кирәк булган икән!

Аллея борылышында ике шәүлә шәйләнде. Менә алар якынайдылар, чылтырап көлү авазына кайнар пышылдашу кушылды. Менә алар өй турында туктап калдылар. Зәйтүнә пәрдә артына яшеренде. Агач ботакларының чыштырдаганы, сынганы ишетелде.

– Кирәкми лә ул хәтле, кирәкми... – диде кыз тавышы. Ул кирелләнгән дә кебек, ләкин шул ук вакытта һәр өзелгән тәлгәш аның бәхетен арттыра, күңелендәге көлү күлен ярларыннан тагын да ныграк ташыта иде сыман.

– Агын да алыйк инде...

Йөрәккә май булып ята торган, бераз тотрыксызрак, ләкин киләчәктә калын, ягымлы булачак тавыш иде бу. Фоат тавышы.

Менә алар кузгалып киттеләр. Зәйтүнә тәрәзәдән үрелеп карап калды. Йолдызларның алдавыч яктысында чәчәкләр кочаклаган кызның сандугачлар сайраган көйгә бөтерелгәне күренде.

Ах, шул кыз урынында буласы иде дә, җанга якын ярың биргән гөлләрне кочаклап, йолдызлар нурына коенган тын бакча юлында онытылып биисе иде!

Бар иде бит Зәйтүнәнең дә шундый чаклары. Бар иде!..

* * *

Әйе, ул да шулай, җәйнең тылсымлы кичендә, сирень чәчәкләрен кочаклап, куе ябалдашлы агачлар ышыгында бөтерелә-бөтерелә биегән иде... Фоат бүләк иткән ак һәм алсу-шәмәхә сиреньнәрнең исеннән канат яргандай очынып...

...Унҗидесе тулып кына килгән чагы иде аның. Күңелне әле сәбәпсез куаныч, әле билгесез сагыш биләп ала, алгысыта, ашкындыра, тик ни теләгәнен, туар көннән нәрсә көткәнен аңлап җиткерми әле ул. Ә аның бөтен барлыгы, вөҗүде сөю көткән икән. Вакыт җиткән иде һәм алар очраштылар!

Зәйтүнә Минзәләнең медицина училищесында үзе белән бергә укучы кызлар белән шәһәр үзәгендәге паркның күләгәле юлыннан узып бара иде. Ян эскәмиядә тезелешеп утырган берничә егеткә юлыктылар. Тегеләрнең кулларында сирень бәйләмнәре...

Дәшми генә үтеп китәргә кирәк иде. Ләкин яшькә өлкәнрәк Римма түзмәде:

– Ах! Нинди матур сиреньнәр! – дип кыюланып әйтеп куйды.

Арадан бер егет сикереп торды да:

– Рәхим итегез! – дип, кулындагы чәчкәләрнең бөтенесен Зәйтүнәгә сузды. Акларын да, алсу-шәмәхәләрен дә.

Ни өчен аңа? Ул читтәрәк иде бит. Зәйтүнә аны таныды. Бию кичәләрендә бу егетнең күзгә чалынганы бар иде. Буйга бүтәннәрдән әллә ни калку булмаса да, арада югалып кала торганнардан түгел. Куе кара чәчләре, түгәрәк йөзе, бәлки, кемгәдер гадәти тоелгандыр, ә менә коңгырт күзләрендә биешкән очкыннар карашны ихтыярсыздан үзенә тарта иде.

Рәхмәт әйтә алдымы Зәйтүнә? Анысы хәтердә калмаган, кинәт башы әйләнеп, зиһене таралып китте бугай.

Ул битен чәчкәләргә яшерде. Караңгыда күреп булмый иде: биш таҗлылары – бәхет вәгъдә иткәннәре бар микән? Булырга тиеш иде, булырга! Агында да, зәңгәрсу-шәмәхәсендә дә!

Ул кызлардан арттарак калды. Бәхете белән ялгыз калырга кирәк иде аңа. Хәер, нигә ялгыз дияргә? Кочагында мондый чәчкәләр барында кыз ялгыз буламыни?

Парк уртасындагы бию мәйданчыгыннан оркестрның уйнаганы еракка ишетелә. Зәйтүнә, чәчкәләрне кочаклап, куе ябалдашлы агачлар арасында, аулакта онытылып биеде. Аның белән бергә күктәге йолдызлар, юл читендәге юкәләр, тирәкләр бөтерелде...

Сиреньнәр чыннан да аңа бәхет вәгъдә иттеләр: иртән вазаның суын алыштырганда, Зәйтүнә биш таҗлыларын шактый тапты. Өзеп, тел өстенә салды – тәме балдан татлы тоелды.

Ә кичен алар тагын паркка – бию мәйданчыгына бардылар. Анда, гадәттәгечә, татарча уеннар уздырыла иде. Чират җитеп, Зәйтүнәне дә уртага чыгарып биеттеләр, ә ул тып итеп очкын күзле егет каршына барып басты, аны чакырды. Аннары алар вальсны да, тангоны да бергә биеделәр. Әйтергә кирәк, ул заманда танго катлаулы, оркестр андый көйне уйный башлауга, биючеләр азая иде.

Фоат исә бик оста булып чыкты. Ә үзе:

– Сез бик җиңел биисез, – диде. – Сәхнәдә дә шундый сез...

Ул концертларда Зәйтүнәнең татар, башкорт, украин биюләрен башкарганын күргән икән...

Егет Фоат исемле, институт тәмамлаган, авыл хуҗалыгы техникумында укыта икән.

Зәйтүнәнең училищеда тагын бер ел укыйсы бар иде әле. Яшьлекнең бу чоры аның өчен сөю кояшының нурларына коенып узды. Унҗиде яшьтә сөйгән ярың булу – бәхетнең иң зурысы.

Һәр очрашкан саен сөйләшеп сүзләр бетми иде. Берәр-се яңа китап укыган яки икесе бергә яңа фильм карап чыкканнар. Яки менә көз җитеп, яфраклар саргайды, аннары кыш килде. Елның һәр фасылында дөнья бөтенләй үзгәрә, күрә-тоя, уйлана белгән кеше алдына мең төрле табышмак куя бит ул.

Фоат андый үзгәрешләргә гадәттән тыш сизгер, күптән балигъ булса да, сабыйларча гаҗәпләнү сыйфатын югалтмаган иде.

Менә язгы бер кичтә алар парк юлыннан баралар. Фоат сирень куагы янында туктады да, бер ботакны сак кына үзенә таба тартып, бармагы белән сусыл, күгелҗем бөрене сыйпады.

– Могҗизаларның иң зурысы менә шушы инде, – диде.

– Бөреме? Шул кечкенә бөреме?

– Кечкенә, дисең? Әйдә, бер айдан килеп карыйк, нинди булыр икән ул, ә?

– Ә син белмисеңмени нинди булырын? Чәчкә булыр! Тәлгәш! Тик менә ак микән, әллә алсу-шәмәхәме? Анысын мин бөресеннән танымыйм.

– Чәчәк ничек сыйган бөре эченә? Кем шулай тыгызлап тутырган?

– И Фоат, әйтеп тә куясың инде. Ә үзең агроном тагын!

– Ә сиңа, медик кешегә, бу гаҗәп түгелмени? Беренче тапкыр мин моңа биш яшемдә чакта хәйран калган идем. Әни мине бакчага алып чыкты да куе бөдрә яфракларга күрсәтте. Тарт әле шуны, улым, ди. Мин тарттым. Һәм, беләсеңме, нәрсә килеп чыкты?

– Тамырдыр инде, ни булсын!

– Яшел яфракка ияреп җирдән кызгылт-сары, озынча...

– Кишер йолкыгансың, димәк.

– Әйе шул, кишер чыкты! Ләкин каян килгән ул анда? Җир астыннан килеп, яфракка кем кишер ябыштырып куйган?

– Кишер яфрагына чөгендер ябышмас ла инде!

– Ә нишләп ябышмас?

– Чөнки чөгендернең үз яфрагы бар!

– Ә сине бу гаҗәпләндермиме? – Фоат кулындагы бөреләргә карап куйды. – Таш кыйпылчыгы хәтле орлык эченә зур агачлар ничек сыя?

– Ничек сыя? Ничә ел әкренләп үскән бит ул!

– Ә нишләп нәкъ шушындый булып үскән? Ник әнә теге шомырт төсле булып түгел?

– Син һаман сабый икәнсең.

Фоатның йөзендә ниндидер илаһи уйланумы, әллә күңелнең иң нечкә кылларын тибрәндерә торган моңмы чагыла. Зәйтүнәгә калса, табигатьнең иң гүзәл, иң камил җимеше – ул үзе!

– Күз алдыңа китер әле, – ди ул. – Әгәр син яңа бертөрле агач ясарга теләсәң...

– Селекционерларны әйтәсеңме?

– Алар бит табигатьтә булганны буташтырып, болгатып кына эш итәләр. Өр-яңаны, моңарчы дөньяда булмаганны ясарга уйласаң... Сызымын сызып, һәр яфракның өлгесен булдырып, бер кечерәк куак кына ясарга алынсаң да... Агачта бертөрле ике яфрак юк бит, һәркайсы үзенчә. Кешеләр әллә ниткән машиналар ясап мактаналар. Алар бар да бертөсле килеп чыга. Бер гөл ясап карасыннар менә!

Фоат барган җиреннән туктап кала һәм сукмак уртасында, яргаланып каткан туфрактагы бака яфрагына иелә.

– Дөнья бәясе үсемлек бит бу, беләсеңдер инде, – ди. – Әйтеп бетергесез шифалы. Шешкән җиргә, сыдырылган, тырналган урынга ябып куйсаң, сулкылдатып тора да шундук сызлавын баса, шешен бетерә, икенче көнгә төзәтеп тә куя.

– Тәнгә кадалган кылчыкны да суырып чыгара ул! – дип өстәде Зәйтүнә. – Минем әни әйтә, шул бака яфрагының шифасын беренче булып ачкан кешенең кемлеген белсәм, барып үбәр идем, ди. Үбәрсең дә! Элегрәк авылларда күпме хатын-кыз бармагы-кулы шешүдән интеккән! Бака яфрагының шифасын белмәгәннәр шул мескеннәр!

– Һәр тереклек иясе үзенә яшәр өчен кирәкле сыйфатларга ия, ди фән. Менә син шуны әйт әле: бака яфрагына адәм балаларын дәвалау ни файда китерә? Ник кирәк ул аңа? Кешеләр аны таптап кына узып китәләр! Сезнең укытучылар бу хакта сөйлидер бит?

– Безнең фармакология укытучысы Камал Вәзировна бака яфрагының шифасын бик түбән бәяли. Вишневский мае күпкә яхшырак, ди.

– Сезнең ул Камал Вәзировнагыз табигатьтән оста булалмас. Ә Табигать галәйһиссәламнең серләрен өйрәнергә дә өйрәнергә әле безгә!

Ә Зәйтүнә югалып кала, башын ия. Фоатның бу сүзләрендә үзенә ниндидер киная барлыгын тоя. Ул да хисләренә артык бирелгән түгелме? Гыйшкы йөзенә-күзенә генә түгел, йөреш-торышына да бәреп чыккан түгелме? Һәм моны күптән инде дус кызлар, бөтен курсташлар гына түгел, укытучылар да белә! Шул ук Камал Вәзировна – аларның класс җитәкчесе – беркөнне дәрестән соң алып калып, кырыс кына сөйләште дә инде.

– Синең монда атаң-анаң юк, бөтен тәртибегез, язмышыгыз өчен без җавап бирәбез, – диде. – Кичә син Фоат Нәҗиповның велосипедына атланып, аның кочагына кереп утыргансың, шул рәвешле урам буйлап узгансыз да Минзәлә буендагы әрәмәлеккә кереп киткәнсез. Күргән кешеләр артыгыздан төкеренеп калган! Кояш баегач кына кайткансыз, дип әйттеләр. Караңгы төшкәнче әрәмәдә егет белән кызның нишләп йөргәнен белмиләр дип уйлыйсыңмы әллә?

Зәйтүнәнең йөзенә генә түгел, бөтен тәненә ут капкандай булды.

– Без... без... шомырт чәчкәләренә дип барган идек...

– Әле өченчекөн генә сезнең тәрәзәдән Фоат китереп ыргыткан чәчәкләр җитмәдемени? Әрәмәдәге бер генә шомырт куагы да исән калмагандыр инде... Агач чыдар анысы, киләсе елга тагын чәчкә атар. Ә менә кызлар бер чәчкәсен койса, аларга бүтән яз килмәс! Шуны күңелеңә бик каты уеп куй! Әгәр инде соң булмаса!

Аннары өстәле артына барып утырды да, тәрәзәгә карап:

– Син моннан китәрсең дә котылырсың, ә менә безнең укучыларның әрәмәләрдә йөргәне турында сүз калыр. Медицина училищесында әнә нинди тәрбия бирәләр, дип, безгә бармак төбәп күрсәтерләр. Кара гайбәт ул сиңа капкага сылаган дегет кенә дә түгел, пычак белән дә юнып ала алмыйсың!

Квартирасына кайткач, Зәйтүнә тыела алмый ярсып елады. Бүлмәдәше Римма ничек юатырга белми гаҗиз булды.

– Нәрсә син истерикага биреләсең? – диде ахырда. Ул мәктәпне тәмамлаганнан соң ике ел эшләп килгән, өч яшькә өлкәнрәк һәм күпкә тәҗрибәлерәк иде. – Камал синнән көнләшә ул.

Зәйтүнә үксүеннән туктап шаккатып Риммага төбәлде. Яше кырыктан узган, авыр бәдәнле, елмая белмәгән симез чырайлы Камалның укучысыннан көнләшүе башка сыярлык түгел иде!

– Карт кыз бит ул, – диде Римма. – Фоат кебек егет тәтемәгән аңа. Тәрәзәсенә шомырт бәйләмнәре ыргытучы да булмаган. Велосипедка утыртып та йөрмәгәннәр. Менә өйләнешерсез дә шуның белән бөтенесенең авызы капланыр. Сезнең мәхәббәтне матур кыйсса итеп сөйләячәкләр әле, әйткән иде, диярсең. Туегыз кайчан була соң сезнең? Без таралышып беткәнче ясагыз инде!

Барыннан да бигрәк, менә соңгысы, туй турындагысы сискәндерде, салкын суга чумдыргандай итте.

Күп нәрсә турында сөйләшә иде алар Фоат белән. Һәм – ник яшереп торырга! – кочаклашып үбешәләр дә иде. Әмма... әмма егетнең туй турында сүз кузгату гына түгел, «яратам» дигәне дә юк иде бит әле! Ник? Нишләп алай? Ярата бит ул аны, ярата! Күз карашыннан, һәр сүзеннән сизелеп тора! Нигә инде аны турыдан әйтмәскә!

Инде хәзер, болайга киткәч, мөнәсәбәтләрне һич кичектерми ачыклау тиеш иде. Аннары бит Зәйтүнәнең чыгарылыш имтиханнарын биреп йөрүе. Ул гел бишлегә генә укыды, кызыл диплом алачак. Укытучылар, Камал Вәзировнадан башкалары, аны һәркайсы үз ягына тарта: берсе, балалар табибы булырсың, ди, икенчесе хирург булырга үгетли.

Ә соң Фоат ни уйлый?! Зәйтүнә китәр, ә ул монда, Минзәләдә калырмы?

Бу мөмкин түгел! Зәйтүнә аны күрмичә бер көн дә яши алмаячак. Аннары тагын шунысы, сукыр түгел, күрә бит ул: егеткә күз атучы кызлар җитәрлек. Училищеның иң танылган җырчысы «көмеш тамак» Зәмзәмия моны яшереп тә тормый. Җае туры килгән саен, янына барып сүз куша, кичәләрдә,

Зәйтүнә мыштырдабрак калса, ак биюгә аны чакыра. Ә Фоат кире борып җибәрми, соңыннан: «Кыз кешене бөтен зал алдында уңайсыз хәлгә куярга яхшысынмадым», – дип аклана.

Юк, Зәйтүнә китә алмый! Дөресрәге, Фоатны калдыра алмый...

Димәк, аларга өйләнешергә кирәк. Калганын икесе бергә хәл итәрләр. Ничек? Моңа Зәйтүнәнең башы җитми, ләкин егет, әлбәттә, бер чарасын табачак иде. Тик ачыктан-ачык сөйләшергә генә кирәк. Ул нидер уйлыйдыр бит бу хакта!

Һәм Зәйтүнә, кыюланып, сүзне үзе башларга карар кылды. Дөрес, «яратам» дип егетнең муенына асылыну кыз кешене бизәми. Ләкин китапларда укыганы бар бит: кайбер очракларда кызлар кыюрак була, сүзнең иң мөһимен тәвәккәлләп алар әйтә. Һәм бу бер дә ямьсез, әдәпсез итеп тасвирланмый.

Кояш баер алдыннан аларның квартирасы турына, велосипедына атланып, Фоат килеп туктагач, Зәйтүнә көттереп тормады, атылып каршысына чыкты. Һәм күнегелгән хәрәкәт белән егетнең алдына утырып, кочагына керде.

Алар урам чатыннан борылганда, кибет ягыннан каршыларына Камал килеп чыкты һәм каккан казыктай тукталып калды.

Зәйтүнәнең чигенү юлы киселгән иде. Йә туй көне билгеләнә, яисә йөзе кара булып кала.

Ул укытучысына әйтеп бетермәде: хикмәт әрәмәдәге чәчкәләрдә генә түгел, Фоат аны велосипедта йөрергә өйрәтә иде. Аны бит инде кеше күп йөри торган урында эшләп тә булмый. Син велосипедка атланган, егет янәшәңнән йөгереп бара. Алар шул рәвешле әрәмәлек сукмакларын шактый таптадылар. Бу юлы Фоат аны үргә таба, шәһәр читендәге калкулыктагы иске паркка алып китте. Бусы да аулак урын иде. Чөнки яшьләр кичләрен шәһәр уртасындагы яңа паркка җыелалар, бию кичәләре, уеннар шунда үткәрелә.

Зәйтүнә велосипедка утырды да, йомры тезләрен капларга тырышып, вак бизәкле аклы күлмәгенең бил турыннан бөреп тегелгән киң итәген тарткалап куйды. Фоат аны арттан этеп җибәрде. Ләкин башка күп нәрсәгә уңган Зәйтүнә нәкъ менә шушы шөгыльгә шактый ук сәләтсез булып чыкты. Әллә тар юлларны карт агачларның юан тамырлары кантарландырып бетергәнгәме, әллә уе бөтенләй башкада булгангамы, әле бер якка, әле икенчесенә янтайды, ара-тирә егылып та алды. Фоат аның артыннан чаба-чаба тирләп чыкты.

– Мин су эчеп килим әле, – диде ул, алланган, шуңа күрә тагын да чибәрләнгән түгәрәк битен сөртеп. – Ә син әкренләп йөри тор.

Һәм капка ягындагы киоскка таба китте.

Зәйтүнә аның артыннан карап калды. Шундый газиз, шундый кадерле иде аның аяк атлаулары! Бу хистән хәтта сулыш кысылды. Тик моны ничек белдерергә?!

Ул велосипедка карады. Ак, елтыр тимерләр шактый тузанланган иде. Зәйтүнә кыска җиң бөрмәсеннән кульъяулыгын алды да велосипедны елтыратып сөртергә керешә. Фоат моны күрергә тиеш иде. Һәм хикмәтен аңларга... Зәйтүнә аны гомере буе менә шушылай кадерләргә тели...

Ләкин Фоат велосипедындагы үзгәрешне күрмәде, аның күзләрендәге очкыннар сүрелеп киткәндәй иде. Уйлар баскан иде аның башкаен...

Тагын бераз велосипедта йөрделәр, аннары, аулак урын табып, чәчәккә күмелгән карт юкә ышыгына, ауган агач кәүсәсенә утырдылар. Көн сүрелеп, җиргә эңгер-меңгер төшкән, юкәдән үзенә бер йомшак җылы һәм татлы ис бөркелә иде.

Моннан соң алар, мөгаен, велосипедта йөри алмаячаклар иде инде. Иртәгә соңгы имтихан, аннары чыгарылыш кичәсе... Иң мөһим сүзләрне әйтер минутлар җиткән, әмма егет тынып калган иде.

– Фоат, – диде Зәйтүнә, башын иеп. – Минем сиңа... әйтәсем килә...

Егет, сүзсез генә аңа таба авышып, иңен кызның иңенә терәде.

– Мин сине яратам, Фоат...

Бу сүзләрдән соң дөнья кинәт үзгәрергә тиеш иде. Аяз көнне күк күкрәп яңгыр коя башлагандай, һич булмаса, кинәт көчле җил чыгып, аларны очырып алып киткәндәй нидер булырга тиеш иде.

Ләкин, ни гаҗәп, бар да үз урынында калды. Куе ябалдашын чыбылдык итеп, аларны сирәк-мирәк узгынчыларның күзеннән генә түгел, бер-бер артлы кабынган йолдызлардан яшергән юкә дә, Фоат үзе дә кымшанмады.

Зәйтүнәнең сыны тагын да ныграк бөгелде.

– Кыю кеше син, – диде, ниһаять, телгә килеп Фоат. Аның тавышында дулкынлану, куанычтан очыну түгел, моңсу уйлану чагылды. Гашыйк егет башка сүзләр әйтергә, үзен бөтенләй бүтәнчә тотарга тиеш иде!..

Хәер, берничә мизгел тын торганнан соң, ул үзе дә моны аңлады булса кирәк:

– Әйдә өйләнешик, – дип куйды.

Әйе, Зәйтүнәнең күптән көткән сүзләрен ул, ниһаять, әйтте. «Мин риза!» – дип кочагына берегергә, битен, күзен шашынып үбәргә дә, аннары шушында ук барысын ныгытып беркетеп куярга – кайчан загска барырга, туйны кайда уздырырга, кемнәрне чакырырга икәнен билгеләргә.

Ләкин бу очракта тиешле сүзләр никтер әйтелмәде, уйлар-ниятләр куерып килгән караңгылыкта әкренләп эреп тарала башлагандай булды. Күңелгә кичке салкын саркыган кебек иде. Фоатның тавышындагы ышанычсызлык, хәтта ниндидер битарафлык хыялларның кояшын болыт белән каплады.

Зәйтүнә аның сызганган җиңеннән чыгып торган беләгенә чатлап ябышты. Йомшак-нәфис төк белән капланган, назлы-җылы кулы нык иде егетнең, әмма ул буйсынды. Зәйтүнә аны күтәрде дә иреннәренә китерде һәм, нишләгәнен үзе дә аңламыйча, тешләрен аның тыгыз тиресенә батырды.

Гомерлеккә, мәңгелеккә үзенең тамгасын салырга теләде ул аңа! Үзенеке итәргә! Ә бәлки аның сискәнүен, сызлануын теләгәндер! Зәйтүнәнең генә йөрәге сыкранырга димәгән!

Ләкин Фоат кымшанмады, «эһ» дигән тавыш та чыгармады.

Ниһаять, күңелдә купкан давыл сүрелеп, аның урынына тын бушлык кереп урнашкандай булды. Зәйтүнә тешләрен егетнең кулыннан алды да торып басты.

Фоат аяк очында яткан велосипедны күтәрде. Дугаланып бормаланган тимерләр йолдызлар яктысын тотып җемелдәштеләр. Чип-чиста иде шул алар... Тик егет моның хикмәтен аңламады.

Капка төбендә ул Зәйтүнәне ничектер кискен хәрәкәт белән үзенә тартып суырып үпте. Бу юлы аның иреннәреннән сөю балының гына түгел, аерылышу ачысының да тәме килгәндәй булды...

Ул төнен йокысыз үткәрде Зәйтүнә. Бәгырен үпкәләү, хәтта рәнҗеш талкыды аның. «Өйләнешик» дигән сүзне алай әйтәләрмени? Киного гына чакырганда да йөзе яктырак, тавышы дәртлерәк, сүзләре татлырак була бит!.. Яратуы шулхәтле генә микәнни?»

Күз яшьләре белән мендәрен чылатып, сәгатьләр буе боргаланды ул шулай. Тулган ай күк гөмбәзенә биегрәк күтәрелгән саен, ян тәрәзә аша нур тасмасын киңрәк итеп сузды. Аның яктысы, салкын су бөркегәндәй, йөрәк сызлануын басып, уйларны ачып җибәргәндәй итте.

Туктале, «өйләнешик» дигән сүзне битараф тавыш белән түгел, уйлангандай итеп әйтте бит ул дигән уй килде башка. Ә нәрсә уйлый икән?.. Алдагыны, киләчәкне, билгеле.

Зәйтүнә, алданиләр буласын күрергә теләгәндәй, күзләрен шар ачып, тәрәзәдән сузылган нур тасмасына текәлде.

Фоатның тәкъдименә җавап бирмәде бит әле ул. Егет аны чынлап ярата, югыйсә шулхәтле каты тешләгәнгә кымшанмыйча түзеп тора алмас иде. Димәк, иртәгә очрашкач, «мин риза» дип әйтсәң, шул җитә. Фоат велосипедына утыртыр да үзләренә, әти-әнисе белән таныштырырга алып китәр.

Иркен ихатаның капкасы ачылыр, алар керүгә, кире ябылыр... Ләкин бу капка урам якны гына түгел, алда көтеп торган олы юлны да ябып куяр түгелме?..

Практика үткәндә, иртә кияүгә чыккан кызларны шактый күрергә туры килде Зәйтүнәгә. Балага узалар да, күңелләре болганып, хәлләре китеп җәфаланалар. Коридордан лап-лап, лаштор-лоштыр атлап узалар. Бераздан өсләренә бала мәшәкатьләре өелә. Баш күтәргәнче еллар уза, күпләре, сәләте, омтылышы булуга карамастан, вакытында белем ала алмый кала. Ә Зәйтүнә сөеп-сөелеп яшәү турында гына түгел, югары белем алып, киң мәйданга чыгып, үзен зур эшләрдә сынап карау турында да хыяллана иде.

Тулган айның нуры айнытты, иртәгесен очрашкач, кичәге сүз кузгалмады...

...Чыгарылыш кичәсе алдыннан Зәйтүнәнең кулына, кызыл дипломга өстәп, институтка юллама да бирделәр.

Характеристиканы соңрак, директорга кереп алырга туры килде. Ә анда «актив, яхшы укый» дигән мактау сүзләреннән соң: «Коллектив фикере белән санашмый, өлкәннәрнең контроленә мохтаҗ», – дигән сүзләр күзне ертып тора иде. Моны, әлбәттә, группаның җитәкчесе Камал Вәзировна язган, директор исә укып та тормыйча кул куеп, секретарь мөһер чәпәгән иде.

Мондый кәгазь белән институт бусагасыннан кертмиләр генә түгел, рәтле авылга фельдшер-акушер итеп тә куймаячаклар иде...

Фоат директор янына кереп сөйләшкәннән соң гына, бу җөмләне сызып аттылар.

Зәйтүнә китәсе көнне Фоат иртүк аны квартирасыннан чакырып чыгарды. Авыл хуҗалыгы училищесында көн буе имтиханнар кабул итәсе бар, димәк, ул озата алмаячак икән. Көн яктысында, урам уртасында үбешергә оялдылар, кул кысышып кына саубуллаштылар.

Хәер, бу бөтенләйгә хушлашу түгел иде әле. Зәйтүнәнең җәйге стипендияне алырга киләсе бар иде... Бер кулына фанер чемодан, икенчесенә матрас-юрган, кышкы пальто тутырган капчык тотып, тузанлы урам чатында басып торганда, аның күңелен авыр сагыш басты. Ямансу, ямансу, бик ямансу иде аңа. Кая барыр ул, кемнәргә сыеныр? Ниләр көтә аны чит-ят җирләрдә?

Ниһаять, юл кырыена тузанга баткан калтырча йөк машинасы килеп туктады, яшь шофер кабина ишеген ачты да елмаеп башын сузды:

– Чаллыга барасыңмы? Әйдә утыр! Кая, төргәкләреңне әрҗәгә ыргытыйк!

Һәм ул, җавап та көтмичә, җиргә сикереп төште. Шоферлар өчен яшь кызлардан да яхшырак юлдаш юк бит инде...

Август башында, институтка документлар бирергә барганда, юл уңаеннан Зәйтүнә Минзәләгә сугылды. Авыл хуҗалыгы училищесына кергән иде, анда Фоатны Казанга семинарга китте диделәр.

Казанга килгәч, иң элек институтка барып, документларын тапшырды ул. Имтихан бирәсе юк, кабул ителүе турында кәгазьне кулына шундук тоттырдылар. Аннары, бер авылдашы биргән адрес буенча Киров урамын эзләп табып, квартирага урнашты. Анда чәй эчеп тә тормыйча, Кремльгә, Авыл хуҗалыгы министрлыгына йөгерде. Аныңча, Фоат шунда булырга тиеш иде. Әмма семинарны каядыр шәһәрдән читтә, «Ферма-2» дигән җирдә үткәрәләр икән. Аның бәхетенә, министрлыктан бер яшь кенә хатын шунда барырга җыенган иде, юлдаш та булды.

Эссе, аяз көн иде. Ленин урамы буйлап барганда, Зәйтүнә туңдырма сатып алды. Шәһәр аңа бик матур, чиста булып күренде, эрегән туңдырмадан асфальтка төшкән ак тапларны сандали табаны белән сөрткәләде ул. Моны күреп, юлдашы шаккатты:

– Карале, урамны чистарта!

Әйе, дөнья искиткеч якты, чиста иде ул көнне. Каршына килеп баскан Зәйтүнәне күргәч, Фоатның йөзендә чагылган хисләрне әйтеп бетерерлек булмады. Сөенүдән дә бигрәк каушады кебек ул. Ничектер югалып калгандай булды.

Алар кичен «Татарстан» кинотеатрына бардылар. Нинди кино караганнары онытылган, бары тик сөйгәнең янәшә булудан туган җан тынычлыгы, рәхәтлек кенә хәтердә.

Кинодан соң Фоат аны озатып куйды. Зәйтүнәнең аннан һич кенә дә аерыласы килмәде. Күрешми торган бер ай эчендә шулхәтле күп кичерелгән, сөйләп бетерерлек түгел иде. Такылдады да такылдады ул. Ниһаять, Фоат:

– «Ферма-2» автобуслар ярты төннән соң йөрми. Соңга калам... Иртәгә килермен! – диде. Үбешеп саубуллаштылар.

Мәңгелеккә хушлашабыз дип ул чакта кем уйлаган!

...Утыз елдан соң гына Зәйтүнә шуны белде: икенче көнне кичке якта Фоат аны эзләп теге квартирага килгән булган.

– Бездән китте ул, кайда икәнен белмибез, – дигәннәр аңа.

Чөнки иртән йокыдан торуга хуҗа хатын, кашын-күзен җимереп:

– Казанга килеп җитүгә егетләр белән чуала башлаган кызлар кирәкми монда! – дип, Зәйтүнәне куып чыгарган иде.

...Зәйтүнә бөтен көчен, тырышлыгын укуга бирде. Үзе һаман Фоатны көтте. Сөюе чын булса, эзләп табар дип өметләнде. Диплом алгач, янына үзем барырмын, дип, күңеленә беркетеп куйды. Кайбер кызлар, очраклы мавыгу чытырманлыкларында адашып, ялгышып, җаннарын яралап, бәгъзеләре тәннәрен керләндереп йөргәндә, аның җаны тыныч, намусы саф булды. Ни генә димәсеннәр, саф кызга уку да, яшәү дә күпкә җиңелрәк бит ул. Бигрәк тә күңел түрендәге урын буш булмаса...

...Ул эзләп килмәде, Зәйтүнә үзе аның янына бара алмады. Еллар узгач, аңлады: бу нәкъ шулай булырга тиеш икән.

Бер үк тереклек иясе булса да, орлык бөредән, бөре гөлдән нык аерыла. Алар бөтенләй охшаш түгел. Адәм баласы да гомер кичкәндә шундый үзгәрешләр кичерә түгелмени? Яшәешнең тирән серләрен аңларга тырышкан, сирень чәчәгенең дә, бака яфрагының да асылын ачыкларга омтылган очкын күзле егет моны яхшы белгән икән. Чәчкәне бөре чагында өзәргә теләмәгән.

Зәйтүнә аспирантурада укыганда кияүгә чыкты. Анысы инде бөтенләй башка, әмма шундый ук матур кыйсса. Зәйтүнә Мәҗитовна Ильясова хәзерге вакытта – танылган табибә, абруйлы галимә, остаз, профессор. Ләкин аның өчен бар мактаулардан, исем-дәрәҗәләрдән кыйммәте – аяз кичтә ул үстергән сиреньнәрнең чәчәген яшь бер кызга бүләк иткән Фоат.

Үз вакытында бу егетнең инде олыгаеп килгән әнисенә буйга узарга Зәйтүнә ярдәм итте. Башка табибларның кулыннан килмәстәйне эшләде. Кулына баласын алгач, ана, куанычыннан нишләргә белмичә:

– Исемен сез кушыгыз! – дигән иде. – Зинһар!

– Фоат, – диде Зәйтүнә.

...Яшьлегендә ул Фоат урынында башка берәүгә юлыккан булса, бу бала дөньяга килер иде микән?

Кайчандыр Фоат Зәйтүнәгә сирень чәчкәләре бүләк иткән иде. Бүген Зәйтүнә Фоатка – яшь егеткә чәчкәләр бүләк итте. Яшьлегендә егет кулыннан чәчкә алган кич бик бәхетле мизгелләр булып хәтеренә сеңеп калган иде. Бүген дә ул шундый ук хисләр кичерде.

*2009*

## Яшь егеткә ир-егеттән бер киңәш

Бервакыт миңа мәдәният өлкәсендә җитәкче булып эшләүче шәп бер кеше белән машинада шактый ерак юл узарга туры килде. Чибәр ул, ачык, сүзчән. Куен дәфтәремә мин аның хакында: «Утыз дүрт яшьтә, гаиләсе, ике баласы бар. Эшен дуылдатып башкара, аның районы һәртөрле ярышларда, узышларда җиңеп чыга», – дип язып куйганмын.

Шактый күп, кызыклы, мәзәк хәлләр турында сөйләде ул җәйге матур көнне озын юлны узганда. Арадан берсе хәтергә аеруча нык уелып калды. Күптән күңелемдә йөри, эчемне бушатасым килә, язарга булдым мин аның кыйссасын.

– Егет кешегә армиядә хезмәт итү бик кирәкле эш, – дип башлады ул. – Мин үзем, мәсәлән, чыныгуны шунда алдым. Чын тормышның асылын шунда аңлый башладым. Дөрес, хәзерге вакытта Рәсәй армиясенең начар даны таралды, «дедовщина» белән куркыталар. Ә миңа калса, солдат өчен иң яманы «дед»лар түгел. Алар белән ботка пешереп була!.. Иң куркынычы, ышанасызмы-юкмы, хатын-кыз. Аңа юлыгудан сак булырга кирәк. Ләкин сакланып бетеп тә булмый икән шул. Күпме солдатларның башын ашый шул афәт! Ул бит сорап та тормый, һич көтмәгәндә каршыңа килеп баса. Ярый ла басып кына торса! Мин менә, бәхетсезлегемә каршы, җәелеп ятканына тап булдым. Янәшәмдә «дед»ларның берсе булмаса, генерал йомшаклык күрсәтмәсә, беткән иде баш... Төрмә баландасы чөмерергә туры киләчәк иде!

Ә «дед»лар белән араларны җайлауның чарасы бик гади: армиягә ныгып-чыныгып барырга кирәк. Әйтик, солдатка килгән малай турникта бер тапкыр да күтәрелә алмаса, марш-бросок вакытында маңкасын агызып арттан сөйрәлсә, өйрәнүләр чорында миңгерәп торса, аңа китереп бәрүләре бик табигый! Шундый җебегәннәр, аңгыралар казарма идәнен себерә, бәрәңге әрчи дә инде. Гади тормышта да шулай бит ул: көчлеләр өскә күтәрелә, хәлсезләр аста кала. Яшәеш законы! Башкача мөмкин дә түгел!

Мин үзем, тиешле частька барып урнашуга, «дед»ларның берсе белән дуслашып киттем. Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, ул мине яхшы волейболчы, футболчы булганым өчен ихтирам итте. Себердән иде ул, фамилиясе – Алиментьев. Ул да спортны бик ярата, бер командада идек. Бер ай үттеме-юкмы – гел бергә без моның белән: казармада да, сакта торганда да.

Әйтергә кирәк, Ерак Көнчыгышта хезмәт иттем мин. Чик сагында. Сиксәненче елларның ахыры иде бу. Коммунистик тәртипләрнең бик нык чагы әле. Ул тирәгә солдатларны сайлап кына җыялар иде. Руслар, украиннар, татарлар, белоруслар – башка милләт юк. Ышаныч безгә генә.

Бер нарядка алты сәгать бирелә. Шул вакыт эчендә ил чигенең мөһим бер кисәген карап-тикшереп торырга тиешсең. Һичкемне үткәрмәскә. Елга яры буйлап бер кишәрлек киңлектә җир сөрелгән, тез тиңентен биеклектә чәнечкеле тимерчыбык сузылган, аның аша сигнализация җибәрелгән. Шул тимерчыбык буйлап билгеләнгән араны бирелгән вакыт эчендә ары-бире узып торырга кирәк. Ә ул ара аз да түгел, күп тә түгел, җиде чакрым! Анда-санда куаклыклар, агачлыклар белән бүлгәләнгән – күз күреме чикле урыннар бар. Хозурлыкның чиге юк, ә без әле теге тарафка, әле бу якка тыз-быз йөреп торабыз. Салкынча булганда ярый, ә менә җәйге чилләдә, кирза итек эчендә ыштыр уралган аяклар күпереп канап чыга! Юләр түгел диген, ник шулай тырышканбыздыр. Хәзерге акылым булса, чаптырырсың мине алай, бар!

Аның әле тагын шунысы: син бер төштән чабып узып кына китәсең, сигнализация эшли башлый – артта чик сызыгы бозылган. Кире йөгерәсең. Ә анда йә куян сикереп чыккан, йә тычкан борын төрткән... Инде анысыннан котылып, юлыңны дәвам итим дисәң, тагын сигнализация зыңгылдый...

Шулай итеп, бик интеккән чаклар була иде. Сигнализация үзәгендә дус кешең кизү торганда ярый – ул, сине кызганып, сигнал төймәсен өзеп куя. Ник шунда Кытай ягыннан СССРга «КамАЗ» килеп кермәсен дә ник безнекеләрнең «уазиг»ы теге якка чыкмасын. Һәркайсының үз йомышы: тегеләр безгә товар ташый, безнең КГБ алар ягыннан үзенә кирәкле мәгълүматны җыя...

Әлбәттә инде, чик бозуда тотылучылар да аз түгел иде. Без дә шундыйларның берсен эләктердек. Ул мескен адәм берничә ел элек безнең якка чыгып рөхсәтсез генә сөлге, чынаяк сатып йөргән. Ахырда, тотылып, үз иленә куып чыгарылган. Ә безнең якта марҗа хатыны белән баласы калган. Бу юлы, аркасына биштәр асып, шуларны күрергә килүе икән. Безнең аргы башка киткәнне чамалап, тимерчыбыкны атлап узган бу. Кире килгәндә күрәбез, эзләре ярылып ята. Бездән алдарак ул төштән этле солдат та узып китте, күзе күрми, эте ис сизми моның. Артыннан чабып, кире борып китердек без бу мокытны эте белән бергә. Менә бит, дибез, чикне бозганнар! Әйдә артыннан куып тотыйк! Борынын китереп терәгәч, эт тә эзне алды. Чаба торгач, эләктердек без теге кытай мәхлугын, тиешле урынга илтеп тапшырдык. Шуннан соң шактый вакыт безне чакырып рәхмәт әйтерләр, отпускы бирерләр, өйгә кайтып килербез дип өметләнеп йөрдек. Тик бу уяулыкның, өлгерлекнең бөтен әҗере теге маңка малай белән ахмак этә булды. Ул хайванга чүт кенә медаль такмадылар, иясен ун көнгә өенә кайтарып җибәрделәр. Ә Алиментьев белән безне телгә алучы да булмады.

Ну, солдат нишли ала? Аның батырлыгын, кыюлыгын командир күрсә күрә, күрмәсә – юк. Ну инде, алай-болай гаебең табылса, чыда гына: әҗерен арттырып бирәләр.

Шулай бер җәйге көнне безгә чик буендагы манараларның берсендә сакта торырга фәрман бирелде. Бардык, манарага мендек, тирә-якны күздән кичердек. Аста гына елга, яры комлы, арырак агачлык та куаклык – табигать кочагында без. Тик бер ягы начар – эсселек кырык градустан артык. Кояш пешерә, тиргә төшерә. Күп тә үтмәде, Алиментьев та, мин дә пешеп чыктык, кыздырырга куйган шашлык калҗасымыни! Сулыш алырлык түгел, бөтен җирдән тир ага.

Башта салып куйдык без итекләрне, аннары чалбар-күлмәкләрне. Барыбер чыдар чама юк. Манарадан төшеп суга чумасы гына да бит, постны калдырып булмый!

Шунда куаклыктан бер пар килеп чыкмасынмы! Күренеп тора: ял итеп, сәйран кылып йөрүчеләр иде болар, ир белән хатын. Аннан алдарак та күзгә чалынганнары бар иде. Су буендагы комлыкка төштеләр, чишенеп аттылар. Тотындылар чумарга, йөзәргә, су чәчрәтешергә! Без, маңгайдан агып төшкән тир тамчыларын ялап, ялманып карап торабыз. Ниһаять, чыктылар, комга тастымалларын җәйделәр дә сузылып яттылар. Ире, корсагына ятып, китап укырга кереште, ә хатыны... Анысы иркенәеп, ике кулын баш астына салып, җәелеп чалкан ятты бит, малай...

Безнең икебезгә бер бинокль иде, икебез ике пыяла күзенә чатлап ябыштык. Ул хатынның чибәрлеген күрсәгез! Ул күкрәкләр, бил, ул шома, тигез, сыгылмалы аяклар... Минем гомеремдә андый чибәрне күргәнем юк иде һәм аннан соң да булмады. Карыйбыз, карап туймыйбыз. Ә ире, мокыт, китабына дөмеккән... Эх, мин аның урынында булсаммы!.. Яңагыма Алиментьевның кызган бите килеп терәлгән, этешәбез, төртешәбез, үзебез шуны сизмибез. Бөтен күңелебез тегендә, яр буенда чалкан яткан хатында...

Шуннан берзаман манара астыннан акырган тавышка биноклебез төшеп китмәсенме... Ни күрик, аска бер төркем офицер килеп туктаган, без машина тавышын да ишетми калганбыз. Арада бик зурысы да бар – генерал! Ә без шәрә тән аларның баш очыннан карап торабыз.

– Шушылармы чик сакчылары? Сез монда ни белән шөгыльләнәсез? – дип акырды генерал.

Ә без кылтыр-пылтыр чалбарларны тарткалыйбыз. Киеп кенә булмый бит, каһәр суккыры!..

Ниһаять, без итекләребезне киеп манарадан төшкәндә, генералның чыраена карарлык түгел иде. Ул инспекция беләнме шунда, башка берәр эш беләнме килгән булган да, нәкъ шул вакыт сигнализация зыңлый башлаган икән. Теге хатын тәмам зиһенебезне чуалтып ташлаган бит, каһәр суккыры, сизми калганбыз. Чикне бозганнар бит болар, тимерчыбык аша атлап, Кытай ягына чыкканнар! Ә без шул вакыт тик утырганбыз!

– Хәзер үк сак астына алырга! Гауптвахтага! – дип акырды генерал һәм минем гимнастеркадан комсомол значогын йолкып алды. Аннары Алиментьевның түшенә ябышты. Тик аныкы алынмый гына бит. Тарткалый генерал, йолыккалый, Алиментьевның гәүдәсе селкенә, значок купмый! Ул безнең комсомол секретаре иде, значокның шәбе икән анда, астан боргычлап беркетеп куя торганы. Тәки ала алмады егетнең значогын генерал, бармагын гына канатты. Аның саен котырынды, билгеле.

Ул арада теге ир белән хатын, киенеп-җыенып, безнең янга килеп басканнар иде инде.

– Сез бу солдатларны кичерегез инде, зинһар!.. – дип ялваралар. – Бөтен гаеп бездә. Аны-моны уйламаганбыз... Аннары, ни булган соң әле? Без беркая да китмәдек бит, су кереп кенә чыктык...

Тик аларның сүзенә кем колак салсын!

Сак астына алдылар безне, бер куышка кертеп яптылар.

Шунда без хәлебезнең үтә дә мөшкел икәнен аңладык. Башка җирләрдә гауптвахтаның әллә ни куркынычы да юктыр, бәлки, мондый эссе көннәрдә күләгәдә хәл алып, ял итеп кенә ятасыдыр. Ә безнең заставада гауптвахта дигән нәрсә гомумән юк. Гаеплеләрне Благовещенскийга илтеп ябалар. Ә анда гауптвахта – чып-чын төрмә. Алла сакласын!

Бездән шәһәргә исә такыр юл юк, вертолет белән генә барып була. Көтәбез без, көтәбез ботак-чатаклардан корыштырган куышта, ә үзебез вертолет килә алмасын иде дип телибез. Ул арада Кытай белән СССРның арасы бозылды, безнең частьның сугышка әзерлеген тикшерү өчен Мәскәүдән махсус комиссия киләчәге турында хәбәр алынды. Һәр җирне тазартырга, һәрнәрсәне рәтләргә кирәк булды, кеше җитми башлады. Стройдагы барча солдатларны чик буйлап йөрергә чыгарып җибәрделәр, штабта кизү торырга безнең ишеләр дә ярап торыр дип табылды. Шуның алдыннан гына безгә яңа форма биргәннәр иде. Мин инде аны яхшылап үтүкләп, ялт итеп киеп куйдым.

Фырт иткән кыяфәттә йөрим шулай казарма буйлап. Күрәм: бер төркем офицерлар килеп кермәсенме! Төркемнең уртасында ул – таныш генерал! Мин ялт итеп «смирно» бастым, шартлатып рапорт бирдем. Солдатлар чик сагында, казармада тәртип ягъни.

Генерал миңа текәлеп карап-карап торды да:

– Туктале, син теге каравылда ыштансыз утырган солдат түгелме соң? – диде. – Нишләп гауптвахтада түгел?

– Вертолет килмәде әле, иптәш генерал, – дип җавап бирде майор. – Килүгә, утыртып җибәрәчәкбез.

– Отставить! – диде генерал. – Кыяфәте егетләрчә, сүзе чын хәрбиләрчә. Күренеп тора: гаебен аңлаган. Төзәлгән.

Аннары миңа елмаеп карады да:

– Бәхетең, шундый вакытка туры килдең, – диде. – Кара аны, бүтән вакыт күзгә чүп кертмә!

– Есть, товарищ генерал!

Шуннан соң озак та үтмәде, Алиментьевны демобилизацияләделәр. Әйткәнемчә, нәкъ шуның алдыннан гына безгә яңа форма биргәннәр иде бит. Кайтып китәсе кешегә исә андыйны бирмиләр, минем дустым иске киеме белән калган иде. Без формаларны алыштык. Ул кызлар күзен кыздырырга яңа гимнастерка, чалбар, итек киеп кайтып китте. Ә миңа тимерчыбык тарттырылган чик буйлап чабарга искеләре дә ярый иде. «Бер елдан, минем кайтыр чак җиткәч, үзенең яңа формасын миңа бирерлек яңа дус табылмасмыни?» – Шулай дип уйладым мин. Һәм шулай булды да.

Солдатта булган елларымны сагынып искә алам. Миңа «дед» тиешле Алиментьевны да, кырыс, әмма гадел генералны да.

Алар яшь солдатны бер сәбәпсез рәнҗетмәс! Ә менә хатын-кызның нишләсен, сине ни хәлгә төшерәсен һич чамалап булмый. Сак булырга кирәк алардан.

Юлдашым шунда туктап калды да, үзалдына серле елмаеп, башын чайкап куйды, аннары, миңа карап:

– Кешегә киңәш бирү җиңел шул ул! – дип куйды. – Ә менә үзем тагын шундый хәлгә тарысам нишләр идем икән. Елтырап яткан елганы, ярдагы сары комлыкны, кояш нурлары астында кулларын баш артына куеп чалкан яткан гүзәлкәйне күз алдына китерәм дә тәннәрем чымырдап куя. Шундыйга юлыксам, аннан күземне алып, башкага карый алыр идеммени мин? Ник шунда каршыма генерал түгел, өч башлы аждаһа килеп басмый!

Юлдашымның бу кыйссасын тыңлаганнан соң, башыма төрле уйлар килде. Хатын-кызларга да ир-егетләрнең хәлен аңларга, һич кирәкмәгәнгә аларны авыр хәлгә куймаска кирәк шул дип нәтиҗә ясап куйдым.

*2009*

# ПОВЕСТЬЛАР

## Казан каласы – таш кала

### Беренче бүлек

***Яңалык***

Казан урамнарында күз ачкысыз буран купкан. Каршы җил тын алырга ирек бирми, вак кар бөртекләре битне чәнчеп-чәнчеп ала. Урамда кеше бик аз, җил уңаена барганнары ирексездән йөгерәләр, ә аларга каршы килүчеләр, башларын иеп, әкрен атлыйлар, әледән-әле борылып тын алалар. Көн уртасы булуга карамастан, эңгер-меңгер чактагы кебек күз бәйләнә.

Мондый көннәрдә самолетлар очмый. Мәрьям Түбән Камадан мең бәла белән, әйләнеч юллардан көчкә кайтып җитте. Поездддан төшүгә, кечкенә чемоданын селкеп, трамвай тукталышына йөгерде. Кием-салымын кар сырган, күшеккән халыкның этешә-төртешә трамвайга утырганын читтән генә күзәтте. Инде кузгалып китәм дигәндә генә, трамвай баскычына басып, уң кулы белән ишек яңагына тотынды. Аннары кысыла-кысыла эчкәрәк үтте.

Трамвайда тагын да караңгырак иде. Тәрәзәләргә калын бәс сарган. Кешеләрнең йөзләре соры, кәефсез күренә.

Ә Мәрьямнең күзләре дулкынланудан елтырый, җилдә бераз ярылган битләре уттай яна.

Трамвайдан төште дә, каршы искән җилдән битен дә капламыйча, проект институтына йөгерде ул.

Ерак юлдан әйләнеп кайткач, үз өеңне дә өр-яңадан күргәндәй буласың. Таныш коридорлар, моңа чаклы күреп туйган бүлмәләр үзгәргәндәй, сиңа билгесез серләр яшергәндәй тоела.

Проект институтының биек коридорларында иртәсен-кичен электр янып тора. Тәрәзәләр юк биредә, һәр ике якта – бүлмә ишекләре.

Тыштан килеп керүгә, яктылыкның саранлыгына ияләшә алмый торасың. Мәрьям, өс-башын каккалап, гардеробта чишенде дә мастерскойга юнәлде. Менә хәзер ул ишекне ачып җибәрер дә барысы белән берьюлы кычкырып исәнләшер. Хезмәттәшләре Мәрьямнең исән-сау кайтуына сөенеп елмаерлар, сикереп торып янына килерләр.

Мәрьям мастерской ишегенә җитәрәк, таза гәүдәле, шадра битле, илле яшьләрдәге апа килеп чыкты...

– И-и, Мәрьям, синме бу, әллә күземә күренәсеңме? – диде ул ягымлы тавыш белән һәм аны кочаклап йомшак күкрәгенә кысты. – Бу буранда ничек адашмый кайттың?

Үзе, Мәрьямнең җавабын да көтмичә, ишектән читкәрәк алып китте:

– Юкка монда килеп йөргәнсең. Мин ачкычны күршедә калдырган идем. Хәер, кызлар да мәктәптән кайтканнардыр инде. Өйгә кайтып рәхәтләнеп ял гына итәсең калган.

Саҗидә апа читкә карап быдыр-быдыр сөйләнде. Аның күп сөйләшүеннән, мастерскойдан читкәрәк китәргә тырышуыннан Мәрьямнең күңеле нидер сизенгәндәй булды.

– Әллә бер-бер хәл булдымы, Саҗидә апа?

– Юк ла, берни булмады... Бар син, Мәрьям, нәчәлство күзенә күренеп торма, кайт та ял ит. Барыбер рәхмәт әйтмәсләр...

Болай булгач, кайтып китә алмады Мәрьям. Эшнең асылын белми җан тынмый инде.

– Килгәч, күрешеп чыгыйм инде, Саҗидә апа.

– Ярый, үз җаеңны үзең беләсеңдер... Мине директор чакыра әле... – дип, Саҗидә апа ашыгып китеп барды.

Мәсьәлә ачык: ниндидер күңелсезлек булган, ләкин Саҗидә апа бу турыда беренче булып әйтергә кыймый. Мәрьямнең шатлыклы дулкынлануы юкка чыкты. Талчыгып киткәндәй булды ул. Поездддан төшкәч тә монда йөгерүнең кемгә кирәге бар иде соң? Кеме сагынып көтә шулчаклы?

Ул, ишекне каты япмаска тырышып, киез итекләре белән тавыш-тынсыз гына басып, мастерскойга керде һәм сак кына үз өстәле янына узды. Берничә кеше, өстәлләреннән баш күтәреп, аның белән исәнләштеләр. Ә эчтәрәк, кульманнар артыннан, чалбар балаклары яки биек үкчәле ыспай туфлиләр генә күренә иде, андагылар кергән-чыкканга бик игътибар да бирмиләр. Хәер, әнә тәрәзә турындагы кульманның авыш тактасы артыннан пеләш баш сузылды. Шәфикъ абый ишек тавышын ишетү генә түгел, бүлмәдән җил узганын да тоеп тора. Мәрьям, киез итекләрен салып, өстәл тартмасыннан туфлиен алып кигән арада, каршына килеп тә басты.

– Кәефләрең ничек, Мәрьям?

– Яхшы, рәхмәт.

Шәфикъ абый пеләшен ике куллап сыпыргалады да кечкенә зәңгәр күзләрен Мәрьямгә сынаулы төбәп сорады:

– Соңгы хәбәрләрне ишеттеңме әле?
– Юк. Әле генә поездан төштем. Әллә сез шәһәр үзәген миннән башка гына проектлап бетердегезме?
– Проект бетмәс, башың исән булсын. Әйдә коридорга чыгыйк әле, монда комачаулыйбыз.
Коридорны тарайтып, зур теннис өстәле тора. Алар стена кырыена бастылар. Биек үкчәле туфли кигән, пөхтә кара костюмлы Мәрьям Шәфикъ абыйдан шактый калкурак күренә, абзыйның пеләшенә өстән карый.
– Ни булды, Шәфикъ абый?
– Бу миссияне үз өстемә алып мин, бәлки, ялгышамдыр. Алай да белеп торуың яхшырак дип саныйм.
– Йә инде, Шәфикъ абый!
– Әйе, җитәкчеләр каршына барып басканчы әзерләнебрәк торырсың. Тагын бер кат уйланып, тикшереп, дим.
– Әлбәттә, әлбәттә. Тик нәрсәгә әзерләним соң?
– Кешегә яман хәбәрне беренче булып әйтүе рәхәт түгел. Тик син акыллы хатын, яхшы ният белән эшләгәнемне аңларсың... Үпкәләмәссең.
Мәрьям, авыр көрсенеп, карашын түшәмгә төбәде.
– Микрорайон проектын яклауны кичектерергә дигән фикерләр бар...
– Кайсы микрорайон?
– Синдә ике микрорайон түгел бит инде...
– Ташлыярдагымы?
– Ташлыярдагы, 3 нче микрорайон.
Мәрьямнең йөзе агарды. Микрорайонның эшен, нигездә, төгәлләдем дип исәпли иде ул. Кирәкле эскизлар төзелеп, смежникларга тапшырылган... Барысы белән дә күптән сөйләшенеп чыгылган... Ни гомер интегеп макетын гына ясап утырды. Алар, Морат белән икесе, әллә ничә эксперт комиссиясе белән бәхәсләштеләр. Инде, ниһаять, Ташлыярда проектны яклау көне, сәгате билгеләнгән, бер атна гына көтәсе калган иде. Димәк, кичектерәләр... Хәерлегә түгел иде бу.
Шәфикъ, Мәрьям дәшмәгәч, түзмәде:
– Директор өстәлендә синең өстән язган докладной ята анда, – диде.
– Кем язган?
– Сантехник Гаделшина.
– Сантехниклар белән бер түгел, ун тапкыр сөйләштек бит инде. Гомуми фикергә килдек ләбаса.
– Синең эскизлар экспертиза үткәндә ул ялда иде бит. Микрорайон, инженер күзлегеннән караганда, квалификацияле планлаштырылмаган, төрле системаларны үткәрү буталчык булу аркасында, артык кыйммәткә төшә, диелгән. Сметага сыймагансыз ич сез...
Шәфикъ абзый күңелсез хәбәр җиткерергә ярата. Кара карга кебек. Шундый итеп сөйли, үпкәләп тә булмый үзенә. Чынлап та, башыңа китереп органчы, күсәк күтәргәннәрен белеп тору яхшырак бит.
– Микрорайонны ансамбль буларак та тәнкыйтьләгәннәр булса кирәк. Художество ягын, диюем... Шәхси тормышыңны да телгә алганнар. Кайгылы чагы Закированың, зур иҗади мәсьәләләрне хәл итәрлек көче юк, рухы сынган, дигәннәр. Шәүкәтне дә...
Бу исемне ишетүгә, Мәрьямнең йөзе кызарды, керфекләре дерелдәп китте. Ул, кулларының калтыравын сиздермәс өчен, учлары белән терсәкләрен кысты.
– Шаяртмый торгансыздыр, Шәфикъ абый? Бүген беренче апрель түгел, бишенче февраль бит.
– Шаяртудан узды эшләр, җаным. Итәгеңне җыебрак йөр.
Шәфикъ абый, көлемсерәп, Мәрьямгә карап тора. Юри үрти диярсең. Юри генә үртәсә ярар иде дә, кызганычка каршы, аның ялган сөйли торган гадәте юк.
Мәрьям местком председателе Ирина Сергеевна янына кереп китте. Мәсьәләнең асылын аннан гына белеп булачак, чөнки ул туры сүзле, кыек-мыекны яратмый.
Конструктор Ирина Сергеевна икенче мастерскойның ишек турысында утыра. Олы гәүдәле, төеп тутыргандай тыгыз тәнле, иллегә якынлашып килсә дә, искиткеч энергияле хатын.
– Ә, Мәрьям, уз әйдә, утыр.
Мәрьям як-ягына каранды. Утырыр урын юк, басып торырга туры килә. Төшке аш сәгате булганга, мастерской буш. Кеше-кара ишетүдән курыкмыйча, рәхәтләнеп сөйләшергә була.
– Син юкта ниләр булганын ишеткәнсеңдер инде, Мәрьямкәй.
– Минем эскизларны тәнкыйтьләгәннәр икән...
– Тәнкыйтьләп кенә калмаганнар шул. – Ирина Сергеевна моны, алтын тешләрен елтыратып, басым ясап әйтте. – Үзең беләсең, мондый гауга безнең коллективны бизәми. Бергә-бергә тату яшәп, кулга-кул тотынып эшләүгә ни җитә!.. Кырмыска оясына таяк тыккандай итеп, коллективны пыран-

заран китерергә яратучылар бар шул. Син дә менә, алдыңны-артыңны карамыйча, кирәкмәгән сүзләр әйтеп ташлыйсың.

– Минем сүздә түгел бит хикмәт, Ирина Сергеевна! Эштә...

– Сүзеңдә дә, эшеңдә дә! Син, Мәрьям, минем мөнәсәбәтемне бик яхшы беләсең бит. Утыр әле, утыр... Ал әнә Семенов урындыгын.

Утыруга Мәрьям бөтен тәненең арыганлыгын, аякларының сулкылдавын тойды, башы әйләнеп киткәндәй булды. Ирина Сергеевна әйткәннәрнең мәгънәсе аңына барып җитми кебек иде. Ә местком председателе кайда ни дияргә, үзеңне ничек тотарга кирәклеген аңлата иде.

– ...Үзгәртәм, диген, төзәтәм, диген... Беребез дә Корбюзье түгел, һәр сызыгыңа теш-тырнагың белән ябышып ятмасаң да ярар. Әгәр бу проектыңны яраксызга чыгарып, заданиене икенче кешегә тапшырсалар, абруеңа бик каты сугачак. Аннан соң кайчан баш күтәрәсең бит әле.

– Проектны үзгәртү бер миннән генә тормый шул, Ирина Сергеевна. Морат белән без ахыргача көрәшергә сүз куештык.

– Морат көрәшер! Урынында нык утыра. Бер проект уңышсыз чыккан өчен генә аның даны кимемәс. Ә сиңа уңыңны-сулыңны чамалап эш итәргә кирәк.

Ирина Сергеевна шулкадәр ачынып, борчылып сөйли, әйтерсең проект заданиесен аның үзеннән тартып алалар.

– Аннары, Мәрьям, өлкән иптәшең буларак әйтәм, авырга алма: үз-үзеңне тотышың кайчакларда үрнәк булырлык түгел... Кара инде ниләр язганнар?

Ул каршында аунап яткан кәгазьләрне туздырып ташлады, өстәл тартмаларын шалт-шолт ачып япты, кирәк кәгазен алдында яткан газета астыннан тартып чыгарды да бераз иелебрәк укый башлады:

– «Инженер Закирова, үзен архитектор дип атап, соңгы вакытта тәмам бәйдән ычкынды. Төзү мәйданнарында тәртип бозуга кадәр барып җитте. Мәсәлән, «Чулпан» кинотеатрында». – Бу урында ул, башын күтәреп, Мәрьямгә текәлде. – Йә инде, шунда барып малярлар белән ызгышып йөрү ник кирәк булды сиңа, ә?

– Җан түзмәде.

– И Мәрьям, кемнең генә күңеле таш икән? Бөтен кешенең җаны әрни, күпләрнең күңеле тулы моң. Тик сер генә бирмиләр. Ә синең эшең генә түгел, уйларың да халыкка билгеле. Менә монда шәхси тормышың турында да язганнар...

– Шәхси тормышымның ни катнашы бар?

Ирина Сергеевна башын чайкап куйды:

– Чүп өстенә чүмәлә өяләр инде. Коллектив алдында дәрәҗәң төшү – иҗат кешесе өчен бик начар нәрсә... Гомумән, андый мәсьәләдә бик сак булырга кирәк... Аеруча хатын-кызга. Аитовка берни булмас, хатыны гына аңа үпкәләр... Ә сиңа гомерлек тап төшеп калыр.

Мәрьям ачы көлемсерәде:

– Киңәшегез өчен рәхмәт.

Ирина Сергеевна аның сүзенә илтифат итмәде.

– Хәзер кайтып, барын да ныгытып уйла. Проектны коткарырга кирәк. Мин дә монда сөйләшермен. Күрдеңме, кешеләр нишли, ә? Бернидән тартынмыйлар. Ә син җебеп йөрисең. Аңла: тормыш – көрәш ул. Көрәшә белергә кирәк бу дөньяда.

Аның яныннан Мәрьям бик кәефсезләнеп, гарьләнеп чыкты. Хак сөйли местком председателе, һич каршы әйтерлек түгел. Их, хак сүзләргә туры килерлек итеп, дөрес итеп кенә яшәп булса иде лә! Ә соң ул үзе, Ирина Сергеевна, шулай ук бу яшенә чаклы шома гына яшәде микәнни? Беркайчан хаталанмады, абынмады-сөртенмәде, егылып, төз борынын канатмады микәнни? Әллә язмыш аңа тиешле афәтләрне дә, үзенә дигәннәргә өстәп, Мәрьямгә бирә микән? Ирина Сергеевнаның тормышы шушы кадәр көйле, җайлы баруын ничек аңламак кирәк югыйсә? Кайсы яктан гына карама, Мәрьям кебекләргә үрнәк ул, күргәзмәгә куярлык. Эшендә мактала, өендә сөелә. Ире – профессор, ике баласы – фән кандидатларымы, әллә менә-менә диссертация яклаячакларммы. Өч бүлмәле квартирасы затлы җиһаз белән тулган, дип сөйлиләр.

Аңа – уңышлар да муллык, Мәрьямгә – ялгышлар да көйсезлек. Өйрәтерлек урыны да бар шул!

Мәрьям, үз мастерскойларына чыккач, туп-туры мөдир Морат янына барып басты. Баштук шуның белән сөйләшәсе иде аңа. Проектның баш инженеры ул лабаса! Ләкин Морат Ташлыярдагы районны әллә ни зур эшкә санамый. Башында зур идеяләр кайнаганда, нәрсә ул кечкенә шәһәрчектәге микрорайон! Өстәлдәге эскизларга күләгә төшкәч, Морат башын күтәрде. Калын пыялалы күзлеген салып, сабый бала кебек, кызарган күзләрен йодрыгы белән ышкыды да, күзлеген кире киеп, Мәрьямгә текәлде:

– Нәрсә?

– Кайттым менә.

– Ну?

– Шуны әйтергә килдем.
– Бик әйбәт. Бүгеннән үк эшкә тотын.
– Микрорайон эскизларын юкка чыгарырга торасыз диме?..
Морат үз уйларыннан арына алмый иде әле.
– Аяк өсте сөйли торган сүзмени ул?! Җыелышып уйлашырбыз. Син, мин, смежниклар. Ә хәзергә башка эшләреңне карый тор.
Морат алдында яткан, өстенә гөмбәз сурәте ясалган кәгазь кисәгенә төртелде. Цирк! Индивидуаль проект төзергә рөхсәт алгач, Моратның дөньядан хәбәре бетте, ул гел цирк белән хыяллана. Мастерскойдагы барча инженерларны, конструкторларны эшкә җиккән. Проекты катлаулы: мондый конструкциянең ныклыгын исәпләп чыгару бик кыен. Кара-каршы капланган ике җамаяк формасында булачак ул. Бина җимерелмәсен, нык булсын, үз-үзен тотсын өчен, аның формасын да, арматураның ныклыгын да бик төгәл исәпләү кирәк. Шуңа күрә микрорайонда хәбәре юк Моратның. Аның өчен Мәрьямнең шәхси тормышында килеп чыккан буталчыклыклар да игътибарга лаек түгел, билгеле.
Эшлә, имеш! Мондый хәлдә ничек эшкә тотынасың! Мәрьям, хәтере калып, урынына барып утырды. Әйе, монда да үзгәрешләр бар: элек аңа яны белән утырган Камәрия Гаделшина өстәлен борып куйган да Мәрьямгә аркасы белән утыра торган иткән. Борылып карамады, әмма Мәрьямнең карашын сизә – көлсу, сирәк чәче арасыннан тырпайган колак яфраклары алсуланган, сөякчел, тар иңбашлары тартышкан. Ниһаять, түзмәде, башын борды... Арттан караганда, Камәрияне үсмер кыз дип белерсең, үзе юка гына, чәче кыска итеп киселгән. Өстендә мәктәп формасына охшаган ак якалы күлмәк. Менә ул борыла, аның кечкенә груша сыман борыны һәм җыерчык баскан йөзе күренә. Сәер кеше шул ул, бичара!
Моңарчы Мәрьям Камәрияне кызгана иде. Яше кырыкка җиткән карт кыз ул. Хәер, сугыштан соңгы чорда аз булдымыни андыйлар? Кызгана аны Мәрьям.
Ә менә Камәрия кызганып тормаган. Шәхси тормышында да казынган... Ярый әле, Мәрьям, хәзерге заманда тугансың. Үткән гасырларда яшәгән булсаң, Шәүкәткә тиң берәүне сөйгәнең өчен сине, муеныңнан җиргә күмеп, башыңа таш бәреп үтергән булырлар иде. Беренче ташны Камәрия атар иде.
Бу заманда кешегә таш ату тыела, әмма каләм алып докладной язу хуп күрелә. Мәрьям Камәрия язган кайбер җөмләләрне укымаса да әйтә ала: «Без шәһәребезне чиста куллар белән төзергә тиешбез, ә менә Закирова кебек әхлаксыз кешеләр архитектор исеменә тап төшерәләр...» Камәрия үз бәхетсезлеге өчен кешеләрдән шул рәвешле үч ала...
Берәрсенең тормышы чуалса, исеме пычранса, җиңел сулап куя: «Дөньяның бәхетсезе бер мин генә түгел. Әнә бик бәхетле дигәннәренең дә тормышы түгәрәк түгел». Шул рәвешле янындагы кешеләрне кимсетеп, пычратып, ул үзен күренеклерәк, чистарак кеше итеп күрсәтә.
Их, юкка гына килде бүген Мәрьям! Башта әллә нинди ямьсез, күңелсез уйлар чуала... Хәер, эш урынына килмичә, кая барсын соң ул? Торыр почмагы да юк бит аның. Тагын Саҗидә апаларына бара инде, нишләмәк кирәк?..

### *Күңелгә кыршау юк*

Кайгы-хәсрәт килсә, күпләр, башыма таш төшкәндәй булды, диләр. Ә менә Мәрьямгә алар бөтәнчә тәэсир итә, көенечләр аның күңеленә гүяки боз кисәге булып төшә иде. Баштарак аның салкыны әллә ни сизелми дә кебек, ләкин ул тора торып үсә, зурая, үзәкне ныграк өшетә, бәгырьне катырак сызландыра. Ләкин бу өшү-сызлану тыштан караганда күренми, шунлыктан мастерскойда Мәрьямнең көенечләре хакында җиңелчә көлемсерәп сөйлиләр: «Безнең Мәрьям бирешми, тиресе калын аның», – диләр. Күрәсең, тыштан караганда, архитектура сызымнары кебек, корырак, шактый кырыс күренәдер ул, сызымнарга текәлгән күз карашыннан да эчке хисләре түгелми.
Менә хәзер дә, проект институты урнашкан мәһабәт бинадан чыкканда, танышлары очраган булса, андагы үзгәрешне сизмәсләр иде, мөгаен. Ә бит аның бәгыренә төшкән боз кисәге зурая башлаган иде инде.
Ә урамда буран тынган. Табигать, зур мәшәкатьләрдән арынган кешедәй, ял итә. Караңгы төшүгә карамастан, урам себерүчеләр тротуардан кар көриләр, аларга зур-зур агач көрәкләр тоткан бала-чага булыша. Көрт ерып бата-чума кайту бик рәхәт. Юкка алай ашыгып көриләр бу карны.
Эштән кайтып килүче кешеләр башка вакыттагыча ашыгып-кабаланып узмыйлар, үз көйләренә генә атлыйлар. Карның аклыгыннан, дөньяның пакьлегеннән, һаваның чисталыгыннан күңелләр ачылып китә, үткән гомернең рәхәт минутлары искә төшә. Әнә кардай ак башлык кигән яшь хатын коляскадагы сабыен тротуарга чыгарган да авыз эченнән көйли:
– Ай, лә-лә-лә-лә!

Авыр йөк машинасы урам уртасында туктап калган. Аның янына ике яктан ике трамвай туктап, әледән-әле кыңгырауларын зыңгылдаталар. Менә аларның ишекләре ачылды, алардан ир-егетләр төште. «Җәяү китәләр инде», – дип уйлады Мәрьям. Юк ла, ирләр машинага ябышып, һай-һулап этә башладылар: «Раз-два, взяли!» Машина үз юлы белән китеп баргач, ирләр, кар сырган пальто итәкләрен каккалап, трамвайга кире утырдылар.

Мәрьям Кольцога җәяү барырга булды.

Бутлеров урамы аңа Казанның иң матур урамнарыннан берсе кебек тоела. Элеккедән калган агач өйләр дә, күптән түгел салынган таш пулатлар да бар биредә. Яшел бакчалар, аны аркылыга кискән тын урамнар, серле тыкрыклар Мәрьямнең яшьлек истәлекләрен саклый. Ә ул истәлекләр Шәүкәт Аитов белән бәйле.

Аның исемен ишеткәндә, йөзе алланып чыга, йөрәге дөп-дөп тибә Мәрьямнең. И-их, ник чәнчелеп китми шунда гайбәтләре! Иң бәхетле минутлар Шәүкәт белән узды. Һәм Мәрьям моңа тамчы да үкенми.

Тик үз вакытында очрашуларның кадерен белеп җиткермәгәндер кебек...

...Шушындый кышкы кичләрнең берсендә, цирктан кайткач, шактый вакыт җитәкләшеп йөргәннәр иде алар. Ул чакта әле Казанның иске циркы эшли иде. Ә хәзер архитектор Морат Шәехзадин гаҗәеп гөмбәзле яңа цирк проектын сыза. Бик матур булыр ул, әмма Мәрьям күңеленә элеккесе кебек якын тоелмас. Анда башка гашыйклар йөрер, ул башкаларга истәлекле булып калыр.

Шәүкәт билетларны беренче рәткә алган иде. Мәрьям Шәүкәткә таба авышыбрак, дулкынланып, рәхәтләнеп көлеп утырды. Хәзер нәрсә караганы истә калмаган. Мәрьям бик бәхетле иде ул кичне, шунысы гына хәтердә. Тамаша беткәч, аллы-гөлле ыштан кигән, бит очларына иннек яккан клоун кызыл шар бүләк иткән иде Мәрьямгә. Мең кеше арасыннан ничек нәкъ менә аны күреп алды икән?

Кайтканда, Мәрьям, бәйрәмдәге кебек, юл буе шар болгады. Аннары шактый вакыт капка төбендә басып тордылар. Әнә ул капка – тау өстендә, финанс институты белән янәшә. Ә ишегалдында – ике катлы агач йорт. Мәрьям шул йортта яшәүче ялгыз карчык Дуся түтәйдә квартирада яши иде.

Алар дәшми озак тордылар. Дулкынланудан һава эсселәнгәндәй булды. Мәрьям шарны Шәүкәт белән ике арада тотарга тырышты. Кинәт Шәүкәт шарны җиңелчә генә сугып читкә этте дә, кайнар учлары белән Мәрьямнең ике яңагыннан тотып, иреннәннән үбеп алды.

Мәрьям оялуыннан бер сүз әйтә алмыйча йөгереп капкадан кереп китте. Беренче үбешүләре иде бу аларның...

Урамнар шул ук, тик Шәүкәт кенә юк, тик Мәрьям генә үзгәргән...

Ул Кольцога килеп җиткән иде инде. Чират торып, беренче троллейбуска утырды. Алга узып, троллейбус йөртүче кабинасының тәрәзәләре аша карап барды. Бауман урамында халык гадәттәгедән күбрәк. Халык арасыннан әкрен генә юл ерып барган троллейбус, Ленин күперен үтеп дамбага чыккач, бик кызу элдертә башлады. Тәрәзә артында, электр фонарьларыннан төшкән яктылыкның теге ягында, караңгылыкта, тынлыкта, калын кар-боз катлавы астында Казансу йоклый.

Казансу! Назлы дулкыннарында Шәүкәт белән Мәрьямнең көймәсен тибрәткән елга. Аларның бәхетле минутларын күргән, эч серләрен, канатлы хыялларын тыңлаган бердәнбер шаһит...

Җәй уртасында, аяз, эссе көннәрнең берсендә, Максим Горький паркы янындагы причалдан көймә алып, авыр, җайсыз ишкәкләр белән ишеп, шушы дамба янына кадәр килеп җиткәннәр иде алар. Диңгездәй җәелгән елга өсте тулы көймә, пляжда халык мыж килә.

Шәүкәт ишүдән туктаган. Мәрьям, үрә басып, тирә-яктагы хозурлыкка соклана. Кремль яныннан югарыга узып барган «Москвич»ка чуар косынкасын болгый: «Ә-әй, хәерле юл!»

Ак пароход биек күпер астына кереп китә. Ул калдырган дулкыннар көймәне тирбәтәләр. Шәүкәт елганың уң як ярына таба ишә. Анда берәү дә юк. Көймәне икәүләшеп ярга сөйриләр. Шәүкәтнең суга чумган минутыннан файдаланып, Мәрьям, чуар сарафанын салып, коену костюмын киеп ала. Ул эчкәрәк йөзә, зәңгәр күккә карап, су өстендә чалкан ята, күзләрен йомып елмая.

Бераздан алар, судан чыгып, яшел чирәмгә утыралар. Мәрьям уйга чума. Шәүкәт яткан килеш кузгалак яфрагы чәйни.

– Шәүкәт, әгәр дә синең кулыңда тылсымлы таягың булса, бу минутта нишләр идең? – дип сорый Мәрьям, шаяртып.

– Миңа тылсымлы таякның кирәге юк. Үземә кирәкне мин болай да булдырам, – дип җитди җавап бирә Шәүкәт.

– Ә шулай да нинди теләгең бар?

– Рәссам Аитовның үз «Джоконда»сы булуын телим мин.

– Нәрсәгә ул икенче «Джоконда»? – дип гаҗәпләнә Мәрьям. – Берсе җитмимени?

– Әһәмияте, зурлыгы белән шундый картина турында сөйлим мин, – ди Шәүкәт, сабыйга аңлаткандай. – Чын талант учак булып янарга һәм дөньяны башкаларга үз яктылыгында күрсәтә

белергә тиеш. Хәзерге вакытта Леонардо да Винчи заманнары узды инде, халык чутсыз ишәйде. Даһи әсәр иҗат итү бер хәл, аның даһи икәнлеген исбат итә белергә кирәк. Пәйгамбәрнең кем икәнен беләсеңме син?

– Пәйгамбәр? Ул үз заманы өчен хак сүз әйтүче, ниндидер яңа тәгълимат тудыручыдыр инде...

– Хак сүз? Ә аның хаклыгы ни белән исбатлана? Пәйгамбәр ул, беләсең килсә, минем менә шушы сүзем – чын хакыйкать дип, башкаларны ышандыра белгән кеше. Чын рәссам да шулай: чын сәнгать әсәре менә мондый була, матурлык менә шушындый ул, дип, барча халыкны ышандыра алырга тиеш. Менә шундый югарылыкка күтәрелергә кирәк. Пыскып яшәмәскә! Берничә елдан син минем хакта ишетерсең әле!

Шәүкәтнең бераз саңгыраурак тавыш белән сөйләнгән бу сүзләреннән шундый кайнарлык бөркелде ки, Мәрьямнең тыны кысылды. Ләкин шул ук вакытта күңел түренә боз кисәге төшкәндәй булды һәм йөрәкне шомландырып өшетә башлады. Мәрьям аны тизрәк эретергә, бетерергә теләп, егетнең кайнар сулышына якынрак елышты.

– Бирсен Ходай, синең бөтен теләкләрең чынга ашсын, – диде. – Ләкин... әгәр дә... син зур шөһрәт казана алмасаң, ул чакта да... син минем өчен бердәнбер Шәүкәт булып калачаксың.

– Менә монысы өчен рәхмәт.

Шәүкәт әле һаман зәңгәр күккә карап ята, ләкин бу сүзләрне әйткәндә, аның тавышы башкачарак, йомшаграк булып чыга.

– Ә минем тылсымлы таягым булса, бер кала салыр идем. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән гүзәл кала булыр иде ул. Анда һәр йорт, һәр бина үзе бер көй кебек яңгырап торыр, һәм алар, бергә кушылып, зур симфониягә әверелер иде. Ул шәһәрдә кысан тыкрыклар, җимерек, ямьсез йортлар бөтенләй булмас иде. Матур биналар, гүзәл калалар кеше күңелен дә сафландыра бит алар, Шәүкәт. Мин торгызган калада саф күңелле, бәхетле кешеләр яшәр иде!

– Хыялый син, – диде Шәүкәт бик әкрен генә. – Синең кебекләргә проект төзергә ирек куйсалар, яңа калалар чутсыз кыйбатка төшәр иде. Хәзер экономия заманы, биналарны типовой проектлар буенча гына салалар шул, аларның авторлары да билгесез. Зур шәһәр салдырырмын да, анда керер юл читенә минем исемне уеп язган мәрмәр такта куярлар дип өметләнә күрмә тагын!

– Кирәк тә түгел, – дип көлде Мәрьям. – Архитекторлар рәссам түгел, аларга дан сирәк эләгә. Менә моны кем салган, беләсеңме?

Мәрьям кулы белән елганың аръягына, Кремльнең ак стеналарына һәм түбәсе белән зәңгәр күккә үрелгән Сөембикә манарасына ишарәләде.

– Кем белсен инде аны.

– Менә шул шул. Ничә гасыр тора инде бу стеналар, бу манара, ничә буын кешеләр аларга соклана. Менә бит адәм баласының таланты, кодрәте нинди зур, диләр алар. Һәм шушы матурлыкны булдырган илһам иясен хөрмәт белән искә алалар. Аның исеме Әхмәт яисә Ибраһим икәнен белү кирәкмени? Безнең хәтерләрдә ул барыбер Сөембикә манарасын торгызган оста булып саклана бит.

Шәүкәт, борылып, Мәрьямнең йөзенә текәлеп карады:

– Димәк, сине дан кызыктырмый?

– Син әйткән рәвештә булса, кызыктырмый.

– Алайса... син үз гомереңне бер изге максатка... иҗади максатка багышлый алыр идеңме?

– Нинди... максатка?

Нилектәндер Мәрьямнең йөрәге сулкылдап тибә башлады.

– Бер йорт торгызырга. Иң матурын, иң мәһабәтен, берәүнең таланты ачылырга мөмкинлек бирерлеген...

– Синең талантың ачылыргамы? – диде аның сүз сөрешен аңлый башлап Мәрьям. – Синең өченме?

– Икебез өчен дә. – Шәүкәт моны басым ясап әйтте.

Мәрьямгә ничектер бик уңайсыз булып китте, ул кабаланып сарафанын киеп куйды.

– Димәк, син анда үз «Джоконда»ңны, мин үземнең «Бәхет шәһәре»мне тудырсын өченме?

Бу сүзләрдән Шәүкәтнең йөзе сүрелеп киткәндәй булды.

– Бер казанга ике тәкә башы сыймый, дигәнне ишеткәнең бармы синең? Әгәр син миңа таяныч булсаң, мин ике кеше өчен эшләячәкмен! Хәзерге вакытта архитектура өлкәсендә рәтле эш майтару мөмкин түгел, анда гайрәтле ирләр дә берни кыла алмый.

– Ә мин менә эшләячәкмен! Зур кала сала алмам да, бәлки, әмма минем проект буенча йортлар төзеләчәк!

...Шулай дигән иде Мәрьям, әмма үз сүзенә үзе дә ышанып җитмәгән иде. Чөнки ул елларны чыннан да бөтен төзелешләр типовой проект буенча алып барыла иде. Үзең төзегән проект буенча йортлар салдыру «Джоконда»га тиң картина иҗат итүгә караганда да мөмкин булмаслык эш кебек

тоела иде. Картина язу өчен кешегә талант белән тырышлык җитә. Ә архитектор өчен ул гына аз, аның хыялын тормышка ашыру өчен башка бик күпләрнең тырышлыгы, уңай шартлар булу зарур.

Әллә чыннан да буш хыяллар белән артык мавыкмаскамы? Ә бәлки, Шәүкәт хаклыдыр, ике тормышны бер максатка юнәлтеп, бер талантның тулысынча ачылуы өчен тырышу дөресрәк булыр? Бу сөйләшү башында күңелгә төшкән боз кисәге эреп юкка чыккан иде инде, һәм бары тик шаян бер киреләнү, оялу гына Мәрьямгә, әйдә, синеңчә булсын, дип, егет белән ризалашырга ирек бирмәде. Һәрхәлдә, ул чакта Мәрьям рәссам Аитовның булачак казанышлары хакына үзенең иҗади хыялларыннан ваз кичәргә әзер кебек иде.

Ул көнне алар караңгы төшкәч кенә кайттылар. Көймә биреп торучы агай сукранып алды:

– Тугызда өйгә кайтып җитәргә тиеш мин, әлегә хәтле бер сезне көтеп утырдым.

Алар паркның асфальт җәелгән, кеше мыжлап торган аллеялары буйлап түгел, куе ябалдашлы өрәңгеләр, топольләр белән капланган, текә ярлы, тирән, караңгы чокыр буйлап киттеләр. Мәрьям, юри иркәләнеп: «Уф, арыдым», – диюгә, Шәүкәт аны күтәреп алды. Кыз, аны муеныннан кочып, колагына пышылдады:

– Җибәр, син дә арыгансыңдыр...

– Юк, җибәрмим... Жир читенә алып китәм мин сине.

Алай ук ерак алып китмәде тагын, чокырдан чыгып, якты сукмакка аяк баскач, кулыннан төшерде. Кольцога кадәр җитәкләшеп җәяү кайттылар. Электр лампочкаларыннан багана тирәләренә якты түгәрәкләр таралган. Багана турыннан узгач та, күләгәләр алга төшә: түгәрәк башлы, кыска муенлы, киң җилкәле Шәүкәт шәүләсе, аннан шактый тәбәнәк, нечкә билле, озын муенлы, тар җилкәле Мәрьям. Шәүкәт, аякларын аерып, бераз киерелебрәк атлый, һәр адымыннан яшьлек, сәламәтлек, көч һәм үз-үзенә ышаныч аңкып тора...

...Аннан соң Казансу ничә кат боз белән капланды бит инде. Менә троллейбус, бер чакрымга сузылган дамбаны узып, урамга керде. Шушы юл буйлап биш ел эшкә йөри Мәрьям, әмма бу урам аңа һаман да чит булып калды. Бу йортлар, бу тыкрыклар, бу топольләр Мәрьямгә бернинди истәлек тә хәтерләтмиләр.

### *Өйдән кире якка*

Балалар бакчасында Мәрьям Фәйрүзәсен үбә. Кызчык кечкенә гәүдәсе белән әнисенә сыенган, йомшак битен аның яңагына терәгән.

– Сагындыңмы мине, бәбием?

Кызчык башын ия. Ләкин дәшми. Әллә инде атна-ун көн эчендә ятсына да башлаган?

Ана белән кыз, әкрен генә атлап, урамнан кайталар. Ана күңеле тыныч. Барлык истәлекләр, уйланулар әллә кайда, еракта калган, онытылган кебек. Бала гына исән булсын, ул янында булганда башка берни кирәкми. Менә бит ул, уйларны читкә җибәрми, туктаусыз сорау бирә:

– Әни, кая алып барасың мине?

– Өйгә, бәбием.

– Безнең өй ә-ә-нә тегендә бит. – Фәйрүзә ак йөнтәс бияләе белән урамның теге ягына төртә. Йә, ни дисең, барын да ничек итеп аңлатасың сабыйга?

– Әйдә, кызым, апаларга барыйк бүген...

Фәйрүзә туктап кала, нәрсәнедер аңларга тырышкандай уйланып тора.

– Әйдә, кызым...

Мәрьям артында карның йомшак кына шыгырдаганы ишетелә. Алар турына җиткәч, аяк тавышлары тына. Мәрьям башын күтәрмәсә дә, ул кешене күрмәсә дә, белә, таный, бу – Вилдан.

– Әти! – дип, Фәйрүзә аңа ташлана.

...Вилдан, кызын кулына алып, битараф тавыш белән Мәрьямгә дәште:

– Кайтуың белән!

– Рәхмәт.

Мәрьям күтәрелеп карады. Әллә якындагы электр яктысыннан инде, Вилданның күзләре салкын ялтырыйлар. Йөзе җитди. Йөнтәс бүрегенең колакчыннарын төшергән, пальто якасын күтәргән.

– Тагын өйдән кире якка китүеңме? – Аның калын тавышында көлемсерәү дә, әрнү дә чагыла.

– Мин үземнең кайда икәнен белмим әле.

– Ярый, син белмисең ди. Ә Фәйрүзә?! Ни өчен ул, үз өен ташлап, кеше почмагында аунарга тиеш?

– Мин арыдым, Вилдан. Башка вакытта сөйләшербез, яме?

Вилдан тирән көрсенде дә кызын җиргә төшерде. Фәйрүзә бер кулы белән әтисен, икенче кулы белән әнисен җитәкләп алды. Алар, җитәкләшеп, светофорда яшел ут кабынганын көттеләр.

Тынычрак, аулаграк урамга кергәч, Вилдан тагын бер көрсенеп куйды.

– Гафу үтенер идең, ичмасам. Неужели намусың йоклый синең, ә?
– Гафу ит, мин гаепле, – диде Мәрьям.
– Һе, үзем сорап алгач аны.
Бераз сүзсез бардылар, шунда Фәйрүзәнең такылдавы ишетелде:
– Бүген без өчебез дә апаларда йоклыйбыз. Шулай бит?
– Юк, кызым, мин апаларда йокламыйм, үзебезгә кайтам, – диде Вилдан. Аннары, эченнән генә уйлагандай, әкрен тавыш белән әйтеп куйды: – Синең кебекләргә гел контроль кирәктер, күрәсең. Теге чакта китеп бармаган булсам, болай адәм көлкесенә калмаган булыр идек, бәлки. Иң кирәк вакытта синең яныңда булмаганмын шул!
Бу – яңалык. Вилдан моңарчы гел Мәрьямне гаепли иде, гаиләнең пыран-заран килүен аңардан күрә иде. Хәзер аның нык уйланганы, хәтта хатынын аңларга тырышуы сизелә.
Аңа элекке тынычлыгын кайтарып бирү өчен күп нәрсәдән баш тартырга әзер Мәрьям. Тик бүген үк Вилдан янына кире кайта алмый, моңа үзен мәҗбүр итә алмый.
Алар биш катлы йортның караңгы подъезды янына килеп туктадылар.
– Әллә кире кайтабызмы? – диде Вилдан карлыккан тавыш белән, үз сүзенә үзе ышанмагандай.
Мәрьям газаплы сөйләшүдән тизрәк котылырга ашыга.
– Ярый, хәерле төн.
Ул Фәйрүзәне кулына күтәреп алды да ишекне берничә кат тартканнан соң көчкә ачып кереп китте.
Вилдан:
– Баладан оялыр идең, ичмасам! – дип сөйләнеп калды.

### *Гомер язында*

Сәҗидә апа кофта бәйли. Мәрьям күчеп килгәч кенә ике кызына, үзенә бәйләп киде инде. Хәзер ак ефәктән бәйли. Кулы күнегеп беткән, энәсе үзе биеп тора кебек. Алга иелебрәк диванга җәйлап утырган, өстендә жылы йомшак халат. Аның каршындагы кәнәфигә урнашкан Мәрьямнең арыган гәүдәсе дә, талчыккан күңеле дә ял итә кебек. Уяу килеш тә төш күрә сыман, Сәҗидә апаның сүзләре бик ерактан ишетелгәндәй тоела. Бүлмә ярым караңгы, яшел абажурлы торшердан Сәҗидә апага гына яктылык сибелә. Балалар күрше бүлмәдә йоклыйлар.
– И-и, Мәрьям, гомер иткәндә әллә ниләр күрәсең икән. Минем беренче иптәшем Арыслан чын егет иде. И-и, яратыштык та инде! Сугыш башлангач, бер көн булса да бергә торып калыйк дип, юри өйләнештек. Ансыз яши алмас кебек идем.
Сәҗидә апа бәйләмен диванның аргы башына ыргытты. Аның тормыш кыйссасын Мәрьям күптәннән белә, шулай да кызыксынып тыңлый, чөнки апа бик хисле итеп, һәрвакыт яңача сөйли. Арысланның сугышта һәлак булуы, Сәҗидә апаның шул кайгыдан юләрләнә язуы, уйларга вакыт калмасын дип, көне-төне эшкә җигелүе, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча сигез ел тол яшәве, ахырда тормыш үзенекен итүе, димләгән кешеләргә ышанып, күрмәгән-белмәгән Гамирга ияреп, Казанга чыгып китүе – барысын да беренче тапкыр ишетәсең кебек.
– Гомерем буе Арысланны оныта алмадым, шулай да Гамирга чыкканыма тамчы да үкенмәдем. Берьялгызым, ирсез-баласыз ничек яшәр идем бу дөньяда? Хәзер менә, Гамир үлгәч, үткәннәрем турында кат-кат уйлыйм да, ирем барда бер кайгым да булмаган икән, дип куям. Ир – алтын багана, дигәннәре чын икән. Иртәгә ничек яшәрмен, ни булыр, дип уйлаганым да юк иде. Хәзер берүземә шулхәтле авыр...
Сәҗидә апаның күзләренә яшь тула.
– Синең дә күңелең бер утырыр әле, – ди ул, сүзне борып. – Бу болганулар тынар. Тормыш үз җаена салыныр. Әгәр Вилдан җәй көне әллә кайларга китеп йөрмәгән булса, мөгаен, һаман шулай тыныч кына яшәр идегез әле.
Бу сүзләрдән Мәрьям кинәт уянып киткәндәй булды.
– Әллә сез Вилдан белән сөйләштегезме?
Сәҗидә апа, кыенсынып, әле күзләрендә кибеп тә бетмәгән яшь аралаш елмая.
– Күрешкән идек шул. Фәйрүзәнең хәлен белергә барган идем. Ир-ат бала карый беләмени ул. Шуны әйтәм әле, бу рәвешле пыран-заран килмәгән булсагыз, синең тормышыңа тел тигезеп, башыңны тинтерәтмәсләр иде. Вилдан барып, өстәл сугып, ник минем семьяга катышасыз, дип бер әйтсә, шып булырлар иде. Кая барсаң, нишләсәң дә ир кирәк шул. Ирсез хатынга сан юк инде, юк.
Мәрьям тагын изрәде, Сәҗидә апа сүзләре янә төш күргән кебек:
– И-и, тыңламыйсың ла син! Әйдә ятыйк инде алайса, тәмам күзләрең йомылган. Мин дә, юләр, юлдан арып кайткан кешегә акыл сатып утырам. Әйдә, әйдә, ят!

Сәҗидә апа, диваннан кузгалып, Мәрьям өчен урын салды. Үзе каршы стена буендагы караватка ятты да торшерны сүндерде.

Мәрьямнең күзеннән йокы качты. Тегеләй дә, болай да ятып карады ул, һаман урынның җаен тапмады. Диван каты, юрган эссе кебек, аяклар сулкылдый.

Караңгыда ялгызың калгач, төрле уйлар килә күңелгә.

«Уйла, – диде Ирина Сергеевна... – Уйла, Мәрьям, уйла».

Проектны юкка чыгармакчы булалар, диген, ә? Тиешенчә, белеп төзелмәгән, диген... Ни гаепләрен таптылар икән? Хәер, тырышып-тырмашып эзләсәң, гаеп табыла инде ул.

Әле менә ул Түбән Кама шәһәрендә яңа кварталда булып кайтты. Проект бер-ике ел элек эшләнгән иде, ә төзелеш күптән түгел генә тәмамланган. Бишәр катлы унбиш йорт, бер балалар бакчасы, бер кечкенә генә кафе... Барысы да типовой проект буенча... Заманында Мәрьям шактый тир түккән иде ул квартал өчен. Йортларны әле тегеләй борып куя иде, әле болай. Юлларны, бакчаларны, гөл түтәлләрен әле болай планлаштыра, әле икенче төрле... Йорт стеналарын бизәү өчен мең төрле панно уйлап чыгара... Җиде төн уртасында уятсалар да, нинди йортның кайда торасын, юлларның ничек салыначагын чатлатып әйтә алыр иде.

Баксаң, чынбарлыкта, кала булып калыккач, бөтенләй башкача була икән ул. Мәрьям биналар арасында бик озак тулганды. Күңелле дә, ямансу да булды аңа.

Кәгазьгә сызган сызык буенча таш стеналар күтәрелгән, шакмаклап билгеләнгән урынга зур-зур йортлар килеп баскан... «Минме бу? Мин, шушындый кечкенә, зәгыйфь, бер бетон плитәне дә кузгата алмаслык көчсез кеше, мин шундый зур кодрәткә ияме? Бу йортлар минем хыялым, минем иҗатым, үткән гомеремнең бер кисәге бит! Чын-чынлап көчле икәнмен! Акыллы икәнмен! Талантлы икәнмен!» Шактый вакыт әсәренеп йөргәч, чиксез горурлык, хәтта кәпрәю хисе кимеп, әз-әзләп канәгатьсезлек хисе туа башлады. Әнә теге эре панельле йорт урынсызрак утыртылган. Олы урам узачак якка кабыргасы белән төртеп тырпаеп чыгып тора. Квартал эченәрәк урнаштырасы калган... Дөрес, ул тәрәзәсез-нисез стена сграффито белән бизәлергә тиеш иде. Мәрьям эскизы буенча анда кулына колба тоткан егет сурәте булып, биредә химиклар яшәгәнен күрсәтеп торырга тиеш иде. Ашыкканнармы, шәһәр хуҗаларының акчасы җитмәгәнме, төсле штукатурка тапмаганнармы – ни сәбәптер, әмма юк сграффито! Соры шакмаклардан оештырылган стена күзне ертып тора, җекләре кап-кара.

Бер урында бакча сукмакларын дөрес планлаштырмаган архитектор. Дөрес, түтәлләр кар астында, әмма кар өстендә күкселләнеп яткан сукмаклар нәкъ шул түтәлләр булырга тиеш урыннан үтә. Димәк, гөл тамырлары таптала дигән сүз. Ә бер йорт янында, проект буенча тип-тигез асфальт җәелергә тиеш урында, нечкә кәүсәле, нәфис тармаклы яшь каеннар утыра. Көртне тишеп, корыган георгин сабаклары тырпайган... Мәрьямнең өстенә кайнар су коелгандай булды... Ул, үз күзләренә ышанмыйча, сумка күтәреп узып баручы бер бабайны туктатып сорады:

– Бу агачларны күптән утырттылармы, абзый?

Бабай, гаҗәпләнеп:

– Ник, ярамыймыни? – дип, сорауга сорау белән җавап бирде.

– Нишләп ярамасын. Каеннар тамыр җәя алды микән, дип кенә соравым.

Карт йомшарды:

– Белгән юк әле, кызым. Агачларын көз генә утырттык... Соңгарак калынды... Төзүчеләр, ахмаклар, шушы төшкә таш ташып, асфальт җәеп куйганнар... Яз көне халыкны җыеп, көч-хәл белән асфальтны каезлап, ташын җыеп тилмердек. Агачын гына үстерәбез инде аның. Быел гөлләр үсте дә инде.

Мәрьям, картка рәхмәт әйтеп, тизрәк китү ягын карады. Менә шулай, архитектор иптәш, кодрәтлесен кодрәтле син, тик шуны бел: ялгыш сызылган һәр сызыгың кешеләргә ай-һай кыйммәткә төшә!

Әгәр соңгы проектыңда шундыйрак, уйлап җиткермичәрәк үткәрелгән сызыкларың булса, мәрхәмәт көтмә! Берәү дә сине кызганып, хәтер саклап тормаячак, һәм бу шулай булырга тиеш тә. Бу очракта үпкәләп булмый.

Әйе, җаваплылык көчле... Кайчакта шикләнеп куя Мәрьям: хатын-кыз башы белән шундый зур һөнәр иясе булып, өстенә зур җаваплылык алып дөрес эшләгәнме ул? Бәлки, көче җитмәскә кизәнүе булгандыр бу? Дөрес, аның беренче проектларын хуплап, яратып каршы алдылар. Ул бу эшне, авыр булса да, бик ярата. Шулай да, бәлки, акылы, белеме, тырышлыгы җитмидер? Сәләте чамалыдыр? Дөресен генә әйткәндә, Мәрьям үзен зур талант иясенә санамый да...

Ә менә Шәүкәттә бар иде ул талант дигән нәрсә, бар иде. Тумыштан рәссам иде ул. Мәрьямдә исә балачактан ук хәзерге һөнәренә – архитекторлыкка омтылу булмады. Хәер, дөньяда архитектор дигән кешеләрнең барлыгын да унынчы классны тәмамлагач кына, институтка укырга кергәч кенә белде. Аңарчы ул үзен ак халат кигән, горур кыяфәтле табиб итеп күз алдына китерә; имеш, үлем түшәгенә егылган хасталарны аякка бастыра, һәркем аңа рәхмәт укый: берәүләр үзен дәвалаган

өчен, икенчеләр әти-әнисен йә баласын терелткән өчен. Әле зур пароходның капитаны булу турында хыяллана: имеш, өстенә кара китель, башына ак фуражка киеп, күпердә басып тора һәм рупор белән катгый команда бирә: «Право руля! Полный вперед!» Кызык булыр иде ул нечкә тавыш белән пәһлевандай моряkларга бирелгән командалар... Хыялый диген. Чит тел өйрәнеп, Берләшкән Милләтләр Оешмасында эшләү турында да уйлады, инде анысы бөтенләй барып чыкмастай икәнен аңлап, Мәскәүгә, чит илләр белән сәүдә итү институтына кабул итү шартларын сорап хат язды. Сәламәт иде Мәрьям, башы эшли, яхшы укый иде, Мәскәүгә дә барып җитәр иде, кесә сайлыгы гына тотып калды.

Ахырда ул һич истә юк һөнәргә тап булды – төзүче-инженерлар институтына укырга керде. Сәбәбе шул: математиканы ул су кебек эчә, дөньяда аннан да матур һәм мавыктыргыч фән юктыр дип исәпли, шул ук вакытта сызарга, рәсем ясарга бик хирыс иде. Һәрхәлдә бишенче класска күчкәннән бирле мәктәпнең стена газеталарын гел ул бизәде. Ә институт аның математикага һәм рәсемгә булган мәхәббәтен берләштерде. Шулай да, күп кызларны яратып та, очраклы рәвештә өйләнгән егет сыман, баштарак һаман күңеле утыра алмый йөрде. Хыялларыннан тиз генә аерыла алмады, институтны тәмамлаганнан соң һөнәремне алыштырмагаем әле дип уйлаган чаклары да булмады түгел. Тик ул яшь йөрәкнең ашкынуы гына булып чыкты.

Ә Шәүкәт андый түгел. Ул рәссам. Әгәр дә рәссам була алмаса, беркем дә була алачак түгел. Бер карасаң, гаҗәп: күзгә бәрелеп торырлык талантка ия булмаган яшь кеше алдында мең юл ята: ул тегүче дә була ала, пешекче дә, игенче дә, төзүче дә, укытучы... табиб та... Ә инде менә табигать кешегә кызганмыйча талант бирсә – аның юлы бер генә: ул шул юлдан барып, таланты йөкләгән бурычны үтәргә тиеш, юкса... һәлак булачак.

Аның хыялы, омтылышы – сәнгатьтә үз сүзен әйтү, алай гына да түгел, исемен мәңгелеккә калдыру.

Ул Мәрьямне дә дөньяның матурлыгын күрә белергә өйрәтте, рәссам хезмәтенең гүзәллеген һәм авырлыгын ачып бирде.

Кызның чемодан төбендә акварель белән ясалган кечкенә генә рәсем саклана... Уйлары бу ноктага җиткәч, аның шул рәсемне тагын алып карыйсы килде. Тик коридорга чыгып, чемодан актару мәшәкатьле, Саҗидә апаны уятуың бар...

...Шәүкәт урманда вакытта, кояш баеп барганда акварель белән ясаган иде. Ул күренеш хәзер дә аермачык күз алдына килде: иңкүлек уртасындагы тар ерганактан, куе үлән арасында сай гына саф су ага. Ерганакның ярларында төз кәүсәле бөдрә каеннар тезелеп үскән.

Шәүкәт пумаласы белән кәгазьгә ашыга-ашыга сызгалый. Тик ул каеннарны бер яктан сурәтләгән арада, икенче яктагыларның төсе үзгәреп куя. Башта яфраклар ачык яшел иде, аннары саргылт төс инде. Тора-бара ак кәүсәләрдә, яфракларда кызгылт нурлар уйный башлады. Куе үләннең, талгын җилдә әкрен генә шыбырдашкан сабакларның төсе куерды. Үтә күренмәле су каралып киткәндәй булды. Ак ромашкалар, су кырыенда үскән ак күбәләктәй тукранбаш чәчәге мондый фонда ныграк күзгә ташлана торган булдылар.

– Әнә кара, – ди Шәүкәт, – төсләр ничек үзгәрә. Тотып ал син аларны менә! Хәтергә төшереп ясасаң гына инде.

Аңа кадәр Мәрьям табигатьтәге үзгәрешләр бик әкрен була һәм аларны сизү бик зур түземлелек таләп итә дип уйлый иде. Үләннең үскәнен, агачның яфрак ярганын, гөлнең чәчәк атканын күреп булмый бит. Баксаң, табигать бик тиз, бик кинәт үзгәрә икән.

Ул кичне искә төшергәч, Мәрьям хәзер дә юеш үлән исен тойгандай, кичке дымсу-салкынча һавадан тәне калтырап куйгандай була.

Шәүкәт рәсемнәрендә сызыклар йомшак, нечкә гөл сабаклары кебек хәрәкәтчән иде. Ул буяуларның тонықгракларын сайлый, шуңа, ахры, аның рәсемнәре бераз ямансу тәэсир калдыра. Мәрьям егетнең үзен берәү белән дә бутамаган шикелле, рәсемнәрен дә беркем сурәте белән бутый алмас кебек.

Кызганычка каршы, табигать кенә түгел, кешеләр дә бик тиз, бик нык үзгәрә икән шул.

Чын күңелдән ярата иде ул Шәүкәтне. Егет тә аны ярата иде. Инде аерылышып, бер кичкә хушлашып киттек дигәч тә, икесе ике якка күпмедер адымнар атлагач та, берүк мизгелдә кинәт борылып, бер-берсенең кочагына ташланган чаклары була иде. Әйтерсең лә алар үз ихтыярларында түгел, икесен бер өермә бөтереп ала иде. Күңелләрнең бер-берсенә тартылуын тоеп, шул ук вакытта мөнәсәбәтләрдә сафлыкны саклап, матур дус булу бик рәхәт иде.

Шәүкәт укулар тәмамлангач тиз генә кайтып китмәде, аннан-моннан заказлар алгалап, шактый вакытка Казанда калды.

Август аенда Мәрьям, ял алып, авылга кайтып китте. Шәүкәт тә, ниһаять, әнисе янына кайтырга, бер үк вакытта киләчәк турында ныклап уйларга булды. Алар икесе бер пароходта Чаллыга кадәр кайттылар.

Пароход Чаллы пристанена килеп туктагач, Каманың биек ярыннан текә баскыч буйлап янәшә менделәр. Үр өстендә, мыжлап торган халыкның күз алдында, Шәүкәт Мәрьямне кинәт кочаклап алды да, беркемнән оялмыйча, үзенеке итеп үпте... Аннары, басма саен диярлек борылып карый-карый, әкрен генә аска төшеп китте.

Әгәр шунда, шул биек яр башыннан карап калмыйча, Шәүкәткә ияреп кире төшсә, ак пароходка утырып, аның белән бергә Кама буйлап арырак, Башкортстанга таба киткән булса, ничек булыр иде икән аларның язмышы?

Ә бит йөрәк талпынган иде, күңел якты елга өстендә салмак кына чайкалып торган ак пароходка таба очынган иде. Мәрьям йөрәген тыярга тырышты, Шәүкәтнең баскычтан төшеп җиткәнен карап торырга сабырлыгы җитмәсен, аның артыннан үзенең дә томырылып төшәчәген аңлап, читкә борылырга ашыкты, җиңел чемоданын селкеп, тузанлы юлдан автовокзалга таба китте. - Пароходтагы сәяхәттән соң шундый күңелсез, ямьсез булып тоелган иде ул юл! Мәрьямнең күңелен шундый сагыш баскан иде ул чакта! Белеп сызлаган икән күңел, көенечләргә алып бара торган юл булган икән ул.

Бер ай буе Шәүкәтне күрми түзә алмас кебек булган иде Мәрьям. Ах, бер генә ай булса! Ахмак диген, гомерлеккә аерылуның башы шушы икәнен күңеле сизгән, акылы аңлап җиткермәгән. Хәзер менә ай түгел, еллар, бөтен гомер аерым уза, башны ташка орып булмый, сабыр итми чараң юк.

Мәрьям авылдан Шәүкәткә озын-озын хатлар язып торды. Аларның берсендә: *«Аерылышуыбыз хәерлегә булды әле, мөнәсәбәтләребезгә читтән торып, аеграк карарбыз, дуслыгыбызны сынарбыз»,* – дип тә язган иде ул. Хәзер искә төшкәндә дә шул сүзләре өчен оялып, кыенсынып куя. Егет, ул хатны укыгач, аның беркатлылыгыннан көлгәндер шикелле.

Шәүкәтнең нибары бер хаты килде. Ул иптәшләрчә коры гына язылган иде. Бу нәрсә Мәрьямне һич тә борчымады. «Кара син аны, хат язарга яратмый икән», – дип кенә уйлады ул.

Авылдан Мәрьям Шәүкәткә кучтәнәчкә бер банка шикәр комына буталган карлыган алып килде.

### *Бер генә аваздан торган көй*

Хәзер, еллар ераклыгыннан караганда, ул чакта ук Шәүкәтнең күңелендә кара тап бар иде кебек тоела. Шәһәрнең баш рәссамы Газиз Лотфуллин белән танышкан көнне беренче тапкыр сизде моны Мәрьям.

Газиз институтка Морат янына еш килә иде. Мастерскойда кеше шактый күп булганга, баштарак ул Мәрьямгә бөтенләй игътибар итмәде.

Алар 8 Март көнне таныштылар. Гадәттәге тәртипне бераз бозып, группа җитәкчесе Морат Шәехзадин эшне иртәрәк бетерергә рөхсәт итте. Мастерской ишегенең тоткасына урындык аягы тыгып куйдылар. Чит кешеләрдән Газиз белән Шәүкәтне генә керттеләр.

Өч өстәлне тоташтырып, өстенә ак кәгазь җәйделәр, шампанский ачтылар, кыйммәтле конфетлар, тортлар куйдылар. Камәрия, парлап утырмагыз әле, дигән булып, Шәүкәтне үз янына чакырды. Мәрьям Газиз белән Морат арасына туры килде. Мораттның бик кәефсез чагы иде: нәкъ шул көннәрдә яңа институт бинасына ул төзегән проектны кире кактылар. Бинаны Мәскәүдән җибәрелгән типовой проект буенча салачаклар иде. Морат, эчендәге утны сүндерергә тырышкандай, стаканына салган шәрабны йотып кына торды. Мәрьямнең күңелен күрү вазифасы ирексездән Газизгә йөкләнде. Бу – урта буйлы, түгәрәк йөзле, зур авызлы, калын иренле һәм дулкынланып торган куе коңгырт чәчле кеше иде. Атсыз бармагында киң алтын балдак ялтырый. Күзләрендә тирән акыл чагыла.

– Гафу итегез, сез Мәскәүдән яки Ленинградтан килгән вәкилме әллә? – диде ул, шаярып.

– Ник алай уйлыйсыз?

– Чөнки мин биредәгеләрнең һәммәсе белән таныш, сезне генә беренче күрәм.

– Мин начальник түгел бит, шуңа белмисездер, – диде Мәрьям, көлеп.

– Кем соң сез?

– Гап-гади инженер.

Газиз, җитди кыяфәткә кереп, сорау артыннан сорау яудырырга тотынды: нинди проектлар төзүдә катнаштың, алган заданиең бармы, планнарың нинди?

– Кая инде ул план, – дип кул селтәде Мәрьям. – Миңа түгел, тәҗрибәле архитекторларга да эш юк.

Аның сул ягында утырган Морат бу сүзләрдән соң борылып карады, ләкин дәшмәде.

Газиз Мәрьямгә җитдирәк эш белән шөгыльләнергә кирәклеген әйткәч, бу турыда институт җитәкчеләре белән сөйләшергә вәгъдә биргәч, Мәрьямнең, вакыт табып, үзенә позировать итүен сорый башлады.

– Мин позировать итә белмим, – диде Мәрьям.

– Зарар юк. Килегез генә.

– Әллә сез минем портретны мозаика итеп ясап, берәр кибет стенасына элмәкче буласызмы?

– Анысын да ясарбыз. Ләкин башта киндергә төшерергә кирәк.

– Вакытым юк шул минем.

– Шулай да бөтенләй үк өметсезләндермәгез. Югыйсә мольбертымны бирегә алып килеп эшлим.

– Юк-юк, – диде Мәрьям, куркып. Ул бу егетнең үзсүзле икәнен сизеп алган иде инде. Бернәрсә белән дә исәпләшеп тормас, бөтен кеше алдында портретыңны ясарга тотыныр. Шул ук вакытта вәгъдә итү дә яхшы түгел: Шәүкәт ни әйтер бит әле. Мәрьям өстәлнең аргы башында Камәрия белән кызып-кызып сөйләшеп утырган Шәүкәткә күз салды да: «Ай Алла, серләре килешкән икән!» – дип, канәгатьсезлек хисе белән уйлап куйды.

– Вакытым булгач, үзем әйтермен, – диде ул Газизгә.

Көтмәгәндә Морат телгә килеп, аларның дикъкатен үзенә тартты.

– Мин, әлбәттә, Мәрьямне берәр проект заданиесен эшләгәндә өлкән инженер итеп куярмын. – Аның тавышы карлыккан иде. – Ул аны очлап та чыгар, мөгаен. Тик шуны бел, кызый, кая барганыңны, үзеңнең нинди язмышка дучар булачагыңны алдан чамаларга кирәк. Кара инде менә мин тилегә. Архитектор исеме күтәреп йөргән булам. Асылда, хыяллары чынга ашмаган, теләкләре үтәлмәгән, эшләре юкка чыккан кызганыч адәм бит мин! Институтта безгә бар тукыганнары «классика, готика, барокко» булды. «Һәр йорт сәнгать әсәре булырга тиеш!», имеш. Бик шәп. Тик без җиң сызганып эшкә тотынуга, готиканы да, барокконы да себереп түктеләр. Архитектурада «излишество»ны бетерү максат итеп куелды. Баксаң, йортның сәнгать әсәре булуы артык нәрсә икән! Кеше торырлык тишекләр булса, шул җиткән, имеш. Хәзер архитекторның беркемгә дә кирәге юк. Артык кеше ул! Бөтен биналарны заводларда ясап чыгаралар. Сызымнары Мәскәүдән әзер килеш килә. Без архитектор түгел, «ахры тик тор»лар, ягъни эшләмәскә тиеш кешеләр, җәмгыятьтә артык адәмнәр...

– Тынычлан, Морат, – диде Газиз, аның кулына учын куеп. – Синең кәеф начар бүген...

Морат кулын тартып алды:

– Бүген генә түгел. Мин кыйналырга өйрәнгән инде. Син Мәрьямне проектлар төзергә өндисең. Кемгә кирәк безнең проектлар, нәрсәгә кирәк? Минем сабакташларымның күбесе һөнәрен үзгәртте яки яңа калаларга төзүче-инженер булып китте. Ә мин, ахмак, калдым. Казанны бөтенләй архитекторларсыз калдырып булмый, янәсе... Үземне корбан иттем, ә өч тиенлек тә файда китерә алмадым.

Газиз тагын аны туктатырга тырышып карады:

– Юкка кимсенәсең. Эшләгән эшләрең аз түгел.

– Эшмени ул! – диде Морат, рәнҗеп. – Типовой проектлар өчен нигез салу! Оскар Нимейер кебек бер талантка карандаш очлап кына торсам да, бәхетлерәк булыр идем. Архитектураны музыка белән чагыштыралар. Әгәр бу хак икән, безнең шәһәрләрнең яңа районнары, бозылган камертон авазы кебек, бар да бер генә, ул да булса, ялган нота уйныйлар – до-до-до-до... – дип, иренен бөрештереп, пышылдап диярлек сузып көйләде Морат. – Ә безнең күңелләрдәге моңнар тумый кала. Дөрес, мин Чайковский кебек талант түгелмендер дә, әмма Алябьевның «Сандугач»ы кебек бер көем булса да калыр иде. Мин үз көемне җырлый алмадым, авызымны томаладылар.

Ул, шакмаклы кулъяулыгы белән күзлек пыяласын сөрткән булып, күз яшьләрен сыпырып алды.

– Шулай, Мәрьям, Газиз сүзен тыңлама, иҗади һәлакәткә өстери ул сине. Кулыңда менә дигән һөнәрең бар, инженер син. Кит шул юлдан, билләһи, миннән бәхетлерәк булырсың. Әгәр төзелештә эшләргә дәртең юк икән, Газизнең икенче киңәшен тыңласаң да ярый. Натурщица булып эшлә: буй-сының, килеш-килбәтең ярыйсы.

Моратның ачынып сөйләгән сүзләрен өстәл тирәсендә-ге халык ишетмәде бугай: кешеләр шаулаша-көлешә иде. Морат янына аккордеон күтәреп, Шәфикъ абый килде:

– Әллә җырлый да башладың инде, моңлы тавышың ишетелгәндәй булды. Җырласаң, елатырсың, лутчы гармун уйнап биет әле безне.

– Менә тагын бер юкка чыккан адәм, – диде Морат, ачы көлемсерәп. – Бер ун ел бугай инде эшләгән эше юк, кайчандыр Бохарада искиткеч биналар салдым дип мактанып, дәрәҗәсен күтәреп йөри...

Шәфикъ абыйның исе китмәде:

– Ярый ла минем мактанырлык Бохарам бар, кайберәүләрнең искә алып сөйләрлек чурты да юк бит әле.

– Хак әйтәсең, – диде Морат. – Синнән бәхетсез адәмнәр дә бар дөньяда.

– Юкка аһ орасың. Архитектура начар булганнан берәү дә үлми. Бүген хатын-кыз бәйрәме икәнен онытма. Туташны елар чиккә җиткергәнсең ич!

Морат, аккордеонны сыздырып, «Тукай маршы»н уйнап җибәрде. Шәфикъ абый, штиблет үкчәләрен шакылдатып, Мәрьямгә баш иде.

– Марш ич бу, Шәфикъ абый!

– Фокстрот биеп була бит аңа.

– Шәфикъ абзый, зинһар, үпкәләмәгез. Бу көйне генә уйнап бетерсен инде. Икенчесенә биербез.

Уйнап бетергәч, Морат, аккордеонны куеп, урыныннан сикереп торды, кабаланып, ишек тоткасыннан урындыкны алды да коридорга чыгып китте. Мәрьямнән гафу үтенеп, Газиз дә аңа иярде.

Күңелсез тынлык урнашты. Ләкин озакка түгел. Нык адымнар белән, күкрәген киереп, Шәүкәт килде, аккордеон каешын беләгенә элде дә телләргә басты. «Яшьлек вальсы». Шәфикъ абзый белән Мәрьям өстәлләр арасындагы иркенрәк урынга чыктылар. Шәфикъ абзый, гадәтенчә, Мәрьямгә үрелеп карады, ә кыз исә, биек үкчәләре белән кавалерының аягына басудан куркып, туфлиләрен сак кына шудырды.

– Ниләр сөйләде сиңа теге тәти егет?

Шәфикъ абзыйның күгәргән иреннәре калтырап куйды.

– Моратны әйтәсезме?

– Газизне сорыйм... Кара аны, гашыйк булып куя күрмә тагын. Синнән чибәрләр дә күп йөрде аның артыннан. Тик ул берәүгә дә карамый. Һавадагы торнага ымсынып, кулыңдагы чыпчыкны очыра күрмә. Шәүкәтеңә ныграк ябыш, диюем.

Алар таралышканда, кояш баемаган иде әле. Кичке шәфәкъ тәрәзә пыялаларында кызыл учаклар кабызган. Җылы бүлмәдән чыккач, коры, салкын һава калтыратып куйды. Моратның сөйләгәннәре Мәрьямгә бик нык тәэсир иткән иде, ул барысын да Шәүкәткә сөйләде. Бигрәк тә аны Моратның күзләреннән яшь атылып чыгар хәлдә ачынуы хәйран калдырган иде. Кырыкка җиткән ир кеше елый... Ләкин Шәүкәтнең моңа бер дә исе китмәде:

– Артыграк салып җибәргәндер. Өстәл астыннан гына шампанскийга акны өстәгәне сизелмәдеме? «Ак аю» күздән яшьне тиз чыгара ул.

– Ни сөйлисең син, Шәүкәт? Бүген аның бик кәефсез көне. Проектын кабул итмәгәннәр.

– Проектының ярар җире булмагандыр, юкса кире какмаслар иде. Талантым харап булды, үсәргә шартлар юк, дип елау модага кереп китте. Ә баксаң, андый кешеләрнең тамчы да сәләтләре юк. Талант теләсә нинди шартларда да үзенә юл яра ул. Һәркем үзен талант иясе итеп күрсәтергә тырыша, һәммәсе дан-шөһрәт даулый. Тик Ходай бирмәгәнне елап-сыктап алып булмый шул!

Моңарчы Мәрьям Шәүкәт белән Моратны дуслар дип йөри иде.

– Алай димә! Моратның соңгы эше миңа бик ошаган иде. Аны бит начар булганы өчен түгел, расходны күп сорый дип кире какканнар. Күңеле китек аның...

– Шулай шул. Үзеңне сәләтсез халык массасы арасында итеп сизү кыен...

– Бу ни дигән сүз инде? – дип сорады Мәрьям, чын-чынлап гаҗәпләнеп.

– Дөнья халкы ике өлештән тора: талант ияләреннән – алар санаулы гына була; һәм кара халыктан – андыйлар бихисап.

– Генийларның шул кара халыкның бер кисәге булуын онытма! Халык генийны тудыра, үстерә, аңарга тәҗрибә, акыл бирә, кулына корал тоттыра, аны ашата-эчертә, киендерә. Буш урында гений туа алмый!

– Әлбәттә. Мәк чәчәге үссен өчен туфрак кирәк.

Бусын инде Мәрьям үзен мыскыллау дип кабул итте.

Димәк, барча халык, шул исәптән Мәрьям дә – туфрак, ә Шәүкәт – талант иясе – мәк чәчәге икән.

– Синең бу чагыштыруың һич дөрес түгел. Туфрак бөтен тереклек ияләре өчен зарури нәрсә. Әмма мәк туфрак өчен чәчәк атмый, ә генийлар кешелеккә хезмәт итәләр.

– Алай бик акыллы булсаң, икенче чагыштыру тап.

– Кешелекне бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Чөнки ул һәммәсен беренче тапкыр эшли. Морат та үзенчә, беркемгә охшатмыйча иҗат итәргә тели. Мөмкинлек кенә юк. Шартлар булса, ул үзен күрсәтер иде. Алай да башкалар кебек һөнәрен алыштырмаган бит әле, үзе сайлаган юлга тугрылыклы булып калган. Андый шартларда тугрылыклы булып калу – үзе зур батырлык!

Бәхәс зурга китте.

Ахырда Шәүкәт үзен-үзе кимсетә башлады:

– Ярый инде, мин синең кебек үк күп укымаган, югары белемем юк, үз акылым белән генә фикер йөртәм, ә син китаплардан цитаталарны күп укыган кеше. Кая инде миңа синең белән ярышырга!

Бәхәс мондый юнәлеш алгач, килешү, уртак тел табу мөмкин түгел иде. Мәрьям саубуллашып кереп китәргә ашыкты. Алар кайчан очрашулары турында сүз дә куешмадылар.

***Портрет***

Шул сөйләшүдән соң Шәүкәт шактый вакыт институтта күренмәде. Газиз исә көн саен диярлек килеп йөрде:

– Вәгъдәгезне кайчан үтисез? – дип, Мәрьямнең исенә төшерә торды. Ахырда кыз аның эш урынына барырга риза булды.

Шәһәрнең баш рәссамы Кремль янындагы горисполком бинасының икенче катындагы бүлмәдә эшли иде. Зур, авыр ике ишекне ачып кергәч, тимер баскычтан менәсең. Челтәрләп эшләнгән араталар баскан саен даң-доң килә. Мәрьям рәсем пумаласы, карандаш һәм каләм сурәте төшерелгән ишекне шакыды.

Тәрәзәләре көнчыгышка караган кысан бүлмәдә ике зур өстәл. Стена буйларында, идәндә, өстәлләрдә, шкаф өсләрендә бихисап планшетлар, кәгазь рулоннары, мәрмәр, җиз һәм пластилин фигуралар. Шулар арасында һәр чәч бөртеге урынына яткан, кершәндәй ак күлмәк кигән, чис-та итеп кырынган Газиз басып тора. Ул исәнләшү белән мольбертка күксел киндер тартылган рамны куйды, люстраны кабызды, хәтта, өстәлдәге бра төймәсенә басып, яктылыкны Мәрьямнең битенә юнәлдерде.

– Минем бүлмәдә тиз караңгылана, – диде. – Мин килерсез дип өметләнмәгән дә идем. Ярый, менә бу урындыкка утырыгыз да эшкә тотыныйк. Сезнең вакыт ягы ничек?

– Бераз бар, – диде Мәрьям, уңайсызланып. – Тик мин позировать итәргә күнекмәгән.

– Иркенләп утырыгыз, кыенсынмагыз.

– Сөйләшергә ярыймы соң?

– Ник ярамасын.

Газиз күлмәк җиңнәрен сызганды, буяу банкаларын ачып, палитра әзерләргә керешә. Мәрьям алсу төстәге агач төбеннән кисеп ясый башланган сынга текәлде: бик яшь кыз, башын артка ташлап, сөенеп һәм өметләнеп өскә караган.

– Бу груша төбен каян алдыгыз?

– Урта Азиядән җибәрделәр. Күптән эшли башлаган идем дә, вакыт җитми. – Газиз көрсенеп куйды.

– Бу кыз сыны «Яшьлек» дип аталган инде, әйеме?

– Өстенә бастыгыз диярлек. «Исәнме, кояш!» дип аталачак ул.

Газиз, Мәрьямгә карый-карый, кара буяуга манылган пумала белән киндергә сызгалый. Аның йөзе җитди, күзләре үтәли күрә кебек. Мәрьям беркавым аны беренче тапкыр күргәндәй гаҗәпләнеп утырды. Морат турында сорашасы килә, әмма, сүз башласа, комачаулар кебек тоела иде.

– Ә нигә сез оформитель булып эшлисез? Рәссам яки скульптор эше ошамыймыни? – диде Мәрьям.

– Архитектура, шәһәрләр төзелеше – минем мәхәббәтем.

– Авыр хезмәт бит.

– Эшнең берсе дә җиңел түгел. Яраткач тырышасың инде. Әгәр назлы кызга гашыйк булсаң да, сөйгәнем тәкәббер, миңа баш бирми, гел ялындыра дип, аннан ваз кичеп булмый. Авыр булса да сөясең. Хәер, архитектурага гашыйк кеше калада бер мин генә түгел.

Әллә шаярта, әллә чынлап сөйли шунда. Уйлап сөйләми, теленә килгәнне генә әйтә, ахры, тавышы төссез яңгырый, үзе һаман эше белән мавыккан.

– Сезгә задание бирделәрме соң әле?

– Юк, Морат архитектор булырга киңәш итми. Үзегез дә ишеттегез.

Газиз, пумаласын палитрага куеп, Мәрьямгә карады:

– Башта үзегезне сынап карарга кирәк. Морат ул сүзләрне аптыраган минутында әйтте ич. Ул үзен күрсәтәчәк әле. Аның канатлары сынмаган, чөнки күп эшли, күп белә, күп уйлана... Эзләнә...

– Ул эшләр иде дә, мөмкинлекләр юк бит, – диде Мәрьям.

– Мөмкинлекләр дә булыр. Дөнья үзгәреп тора. – Ул, Мәрьямнең уен сизенгәндәй, сүзне Шәүкәткә күчерде. – Сезнең танышыгызны сәләтле рәссам диләр.

– Әйе, ул талантлы кеше.

– Мин аның эшләрен карар идем.

– Әйтермен аңа.

Бер сәгать чамасы узгач, Мәрьям, урыныннан торып, киндер янына килде. Аңа кара буяу белән генә ясалган, яңак сөякләре бераз калкып торган, чөелгән борынлы түгәрәк йөз, кыйгач каш астыннан озынча күзләр карады. Кара чәч, дулкынланып, күзгә төшкән. Портреттагы кыз дөньяга сабыйларча гаҗәпләнеп карый. Нәкъ менә шул күз карашы бу рәсем белән Мәрьям көзгедә күрергә гадәтләнгән йөз арасындагы охшашлыкны шактый киметә кебек иде.

– Мин мондый түгел ич.

– Ашыкмагыз, бу схема гына әле. Аннары сез үзегезне белмисез ич. Мин сезнең үзегезгә таныш булмаган якларыгызны ачып салырга тиеш.

Газизгә һәрнәрсә анык, аңлаешлы, һәркемнең ни эшләргә тиешлеге мәгълүм. Аның янында син дә үзеңне көчле, акыллы итеп сизәсең – ышанычы сиңа күчә. Шулай да ниндидер корылык бар анда. Көчле хисләр, икеләнү, газапланулар – берсе дә аңа таныш түгел микәнни соң?

Чыннан да, ул әйткән сүзен үтәмичә калмый икән, очраган саен Шәүкәтнең картинасы турында сораша килде.

Ай буе көттергәч, Мәрьямне бик зарыктыргач кына, килде Шәүкәт институтка. Ишектән керде дә Морат янына барып утырды. Берничә авыз сүз алышкач, Мәрьямгә караш ташлады, тик сүз кушмады. Сүз башлау өчен Газизнең үтенече бик яхшы сылтау булды. Дөрес, Шәүкәт чыраен сытып кына ризалык бирде. Шулай да Мәрьям Газизгә шалтыратты, кичкырын эш беткәч, алар өчәүләп художество училищесына киттеләр.

Шәүкәт аларны зур, шыксыз бүлмәгә алып керде. Биек, иркен зал саран гына яктыртылган иде. Стеналарда берничә картина эленеп тора. Мәрьямгә алар артык куе төсләр белән ясалган кебек тоелды, күңелдә ямансу тәэсир калды. Яшь чакта дөньяны җете, ачык төсләр белән тасвирлыйсы килә, җирдәге һәртөрле гаделсезлекне, явызлыкны куе буяулар белән күрсәтеп, бөтен галәмгә фаш итәсе килә, чөнки яшь күңел начарлык белән ризалашмый. Олыгая барган саен, кеше күбрәк төсләрнең дә йомшагракларын, нәфисрәкләрен күңеленә якынрак кабул итә.

Шәүкәт залда барлык утларны кабызды. Мәрьям полотноларга күз йөртеп өлгермәде, Газиз уң як кырыйдагы картинага килеп тотынды:

– Шушымы? – Үзе шунда ук, картинаны карау өчен уңайлы нокта эзләп, уңга-сулга чайкалды.

Чыннан да, башкалар арасында бу әсәр бик нык аерылып тора. Җәйге айлы төн. Әле генә яңгыр явып узган, ахры, һаваның чисталыгы, үтә күренмәле булуы сизелеп тора. Юеш тротуардагы зур күлләвектә саргылт кәрнизле таш йорт чагыла. Йорт почмагына бер кыз сөялгән, аның бөтен кыяфәтеннән бик озак көткәне сизелә. Мөгаен, егетен көтәдер. Йортлар арасыннан күренгән күк йөзенең итәге аллана башлаган...

Бу күренеш күңелдә татлы әрнү, моңлы уйлар уята. Килерме ул бәхет, килмәсме?

Рамгаябыштырылган кәгазь тасмасына «Җиде төн уртасында» дип язылган иде.

Мәрьям егетләргә таба борылды. Газиз күзләрен картинадан алмый. Шәүкәт маңгаена төшкән кыска чәчләре астыннан астыртын гына аны күзәтә, юка иреннәре кысылган. Урындык аркасына ябышкан бармакларының агаруы гына аның дулкынланып Газиз хөкемен көткәнен сиздереп тора.

Ниһаять, Газиз Шәүкәткә кулын сузды.

– Миңа ошый. Настроение яхшы бирелгән. Палитрагыз йомшак, күңелгә ятышлы.

Мәрьямгә бу мактау аз тоелды. Талант иясе бит ул Шәүкәт! Миңа ошый, имеш. Искиткеч әсәр бит бу! Урамга чыгып, Газиз белән хушлашкач, Шәүкәтнең дә шулай уйлаганлыгы мәгълүм булды.

– Аның фикере миңа әллә ни өстәми, – диде ул. – Сәнгатьтә дилетант ул. Талантлы кеше булса, административ эштә утырмас, үз юлын табар иде. Ә ул монументалист та, скульптор да, рәссам да, сәнгать белгече дә. Әйе, белгеч. «Кыргыч, ургыч, чәчкеч» дигәндәге кебек. – Шәүкәт көлеп куйды. – Галим түгел, белдекле булып кылanучы.

Аяк астында март аеның төнге салкыннан бозланып каткан кары шыгырдый иде. Мәрьям дәшмәде. Газизне шул рәвешле юкка чыгарып ташлагач, Шәүкәт пластинканы әйләндерде.

– Ә ул кыз – син ул, – диде тавышын әкренәйтеп, эчке дулкынлану белән. – Мин аны күз алдымда тотып, синең өчен яздым. Әгәр мин ялгышсам, адашсам, килми калсам, көт мине! Күпме көтәргә туры килсә дә көт, яме!

Мәрьям туктап аның йөзенә карады. Шәүкәт әйтми калганнарны ишетергә теләгәндәй сагайды, чөнки сөйгәненең әйткәннәре аны ни өчендер ышандырмый, бу сүзләрдә үзенчә кылану сизелә иде.

– Килмәсеңне белсәм дә көтимме?

– Мин киләчәкмен. Кайчан да булса киләчәкмен.

– Дөньяда төрле хәлләр булуы мөмкин, Шәүкәт. Үзеңне гомерлеккә бурычлы итеп куйма. Килә алмаслык хәлдә калсаң, нишләрмен мин?

– Мин үзем сиңа көтмә дип хәбәр бирермен... Юк, мин сиңа алай дип әйтмәм. Көт, яме!

Күңелләрне җилкетеп, йөрәкләрне ярсытып яз килгән чак иде. Мәрьям күңелендәге шомны куарга, Шәүкәт сөйләгәннәргә үзен-үзе ышандырырга тырышты.

Ике рәссам бер үк вакытта Мәрьямне үзләре аңлаганча, үзләре күргәнчә сурәтләгәннәр иде. Газиз язган портретта – ул эчкерсез, беркатлы, киләчәгенә якты өметләр баглаган шат күңелле яшь кеше булып күз алдына килеп баса. Ә Шәүкәт картинасында – таш каланың зур биналары арасында адашкан моңлы кыз бала...

Кайсы хаклы иде аларның? Кайсы Мәрьямнең күңелен дөресрәк аңлаган, язмышын ачыграк күргән?

Бер караганда, Газиз хаклы кебек, икенчесендә – Шәүкәт.

Хәер, еллар ераклыгыннан караганда, ул әсәрләрдә Мәрьям характерыннан да бигрәк рәссамнарның дөньяга, тормышка мөнәсәбәте, холкы-фигыле чагылганын күрәсең.

## *Бәхетлеләр арасында*

Язмыштан күпне таләп итте, тормышта зур йөк күтәрергә теләде Шәүкәт. Тик үз көчеңне белмичә, чамасыз авыр йөккә җигелү дә ярамый икән шул...

Өстәвенә тәнкыйтьне авыр кичерә, сүз күтәрми иде. Ә иҗат – туктаусыз көрәш. Сәнгатьтә үз сүзен әйтергә теләгән шәхеснең каршылыкка очрамавы мөмкин түгел.

«Җиде төн уртасында» дигән картинага карата әйтелгән һәр тәнкыйть сүзен йөрәгенә энә кадагандай кабул итте Шәүкәт. Диплом эше иде ул аның. Кызганыч, ул диплом яклаганда Мәрьям булмады, чөнки Шәүкәт аңа, бик катгый итеп:

– Килеп йөрмә, кирәкми! – дигән иде.

Алай да Мәрьямнең йөрәге түзмәде, аудиториягә кермәсә дә, училище янына бармый кала алмады. Базарларда гладиолуслар, роза чәчәкләре, канәферләр сата башлаганнар иде инде. Мәрьям бөтен базарны айкап, берәмтекләп сайлап, зур чәчәк бәйләме җыйды. Шул бәйләмне кочаклап, училище бинасыннан төшкән күләгәдә бик озак басып торды. Аяклары талып бетте. Ниһаять, ишектән бер-бер артлы егетләр-кызлар чыга башлады. Куанычтан авызлары ерылган, дулкынланудан битләре алланган. Кайберләре Мәрьямгә сынап карап ала, чаярак егетләр:

– Чибәр кыз, бу букет миңа түгелме? – дип шаярткалый. Аларның дулкынлануы, ташып торган шатлыгы Мәрьямгә дә күчте.

– Юк шул, сезгә түгел! – диде ул, гафу үтенгәндәй елмаеп.

Ниһаять, ишектә Шәүкәт күренде. Аның сөмсере коелган, киеренке иңнәре салынып төшкән кебек иде.

– Исәнме, Шәүкәт! Әллә син якламадыңмы?

– Ә-ә, син мондамыни? Әйдә. – Ул Мәрьямне култыклап алды. – Эш бетте монда.

– Якладыңмыни? Алайса котлыйм!

Мәрьям кыюсыз гына чәчәкләрне аңа сузды.

– Ташла... Котларлык берни дә юк. – Егет чәчкәләрне кулы белән читкә этте. – Дүртле куйдылар. – Аннары, ярсып: – Син үзең күрдең бит, анда минекенә әз генә булса да якын килгән картина юк иде.

Мәрьям, шулай дигәнен белгертеп, башын иде.

– Ә ул пешеп җитмәгәннәрнең күбесе «отлично» алды, – диде Шәүкәт, ярсып.

– Синең эшеңнең кай җире ошамады соң аларга?

– Рәсем ясау техникам начар, имеш. Укыганда да тырышлык җитмәде, дип, укытучысы сайрап тора. Әлбәттә, мин аның кураена биемәдем, шуның өчен үч ала. Ә үзенең өйрәтер бернәрсәсе дә юк. Сәнгатькә кадалган бер сөлек кенә шунда! Кагыйдәләр ятлаган да шуларны тәкрарлап йөри. Үзенең ике тиенлек тә әсәр язганы юк! Шул да сәнгать әсәрләре турында фикер йөрткән була. Күрсәтермен әле мин аларга кемлегемне!

Шәүкәтнең кәефе кырылуы аңлашыла. Тик ник әле шулчаклы үзеңне-үзең ашарга? Дүртле дә начар билге түгел бит! Мәрьям егетне тынычландырырга тырышкан саен, Шәүкәт кыза барды...

Ике-өч көн үткәч кенә башка нәрсәләр турында сөйләшер хәлгә килде ул.

Монда кадеремне белмәячәкләр, китәргә кирәк дигән фикер аның башында ныгыганнан-ныгый гына барды. Иң яхшысы: берәр яңа шәһәргә барып урнашу. Андый җирдә талант кадерен беләләр. Сәнгать әһелләре белән иң олы җитәкчеләр кул биреп исәнләшә. Эшләр өчен шартлар тудыруны кайгырталар: квартира, акча, мастерской, машина – иҗат кешесе өчен алар бернәрсәне дә кызганмыйлар. Уңышыңны күрә беләләр, мактауны да, бүләкләрне дә кызганмыйлар. Чын талантка игътибар кирәк, кайгыртучанлык. Гөлләр дә сусыз үсә алмый.

Ләкин Мәрьямнең карашы башкачарак иде.

– Иҗат әһелләреннән аерылып, мөстәкыйль эшли башлаганчы, иң элек ныклап осталыкка өйрәнергә, укырга кирәк. Берьялгызы калса, кеше үсә алмый.

– Кемнән өйрәнергә? Мондагыларданмы?

– Башта алар булдырганнан уздырырга кирәк бит әле.

– Әллә мин алардан кимрәк беләммe?

– Мин чагыштыра алмыйм. Тик шулай да... Чын талант ияләре хәтта дошманнарын да үзләренең талантлы булуына ышандыралар бит. Син дә башкаларны үз көчеңә ышандырырга тырыш. Канатларың ныгыгач кына, кая барсаң, шунда файда китерә алачаксың. Ә болай... син акча белән файда артыннан киткән кебек буласың. Дан эстәгән шикелле.

– Әллә акча кирәкмиме? Җанга – җылы сүз, яшәргә квартира кирәкмиме? Әгәр дә сәнгать әсәре эт оясында эшләнсә, аннан, гафу ит, эт исе аңкып торачак. Борынгы заманда сәнгатьне аксөякләр үстергән икән, бу бер дә юкка түгел.

– Ә безнең Тукаебыз? Сабый чакта базарда сатылган, гомере буе кеше почмакларында яшәгән шагыйребез? Ә Муса Җәлилнең зинданда язылган шигырьләре? Алар ничек иҗат иткән соң?

– Алар бит ул язмышны үзләре теләп алмаган, – диде Шәүкәт талчыккан тавыш белән. – Яхшырак яшәсәләр, аннан да күбрәк һәм бөегрәк әсәрләр иҗат иткән булырлар иде, бәлки. Китик без, Мәрьям, моннан! Менә күрерсең, мин икебез өчен дә эшләячәкмен. Син минем өчен горурланачаксың әле!

Их, киткән булыр иде лә Мәрьям! Бөтен йөрәк җылысын аңа биргән булыр иде. Ләкин ияреп китү белән генә Шәүкәткә ярдәм итеп булмый иде шул.

### *Зәһәр Камәрия*

Ниһаять, Морат Мәрьямне җитдирәк эштә сынап карарга булды.

– Менә үзәк урамга чыга торган өч йортка проект төзеп кара әле, – диде ул. – Рәттән куелачаклар. Тышкы оформлениесен уйларга кирәк... Бу йортларга беренче проектны Гаделшина эшләгән иде инде, кабул ителмәде. Синең вариант яхшырак булыр, бәлки.

Мәрьям җилнең кайсы яктан искәнен шундук аңлап алды: аңа задание бирүне Газиз үтенгән иде. Морат Мәрьямгә әллә ни өмет багламаса да, өстеннән бурычны төшерә. Менә бит булдыра алмады, төзү институтыннан нинди архитектор чыксын, дип акланырга җай эзли.

Үзәк урамнардагы йортларга сметада күбрәк акча бирелә. Бинаның тышкы күренешенә үзгәрешләр кертергә ярый, әмма эчке төзелешенә кул тидерергә рөхсәт ителми иде.

Мәрьямгә шушындый өч йорт эләкте дә инде. Иң элек ул төзелеш булачак урынны карап кайтты. Урамы киң, трамвай, троллейбус, автобуслар йөри, җәяүлеләр дә, машиналар да агылып тора. Йортларга каршы якта бакча булачак икән.

Әйе, гадәти биш катлы, дүрт подъездлы, алтмыш дүртәр квартиралы йортлар иде болар. Беренче катларында ресторан, китапханә һәм кием-салым кибете булачак. Өч йорт та тышкы яктан юка таш плитәләр белән тышланачак. Өченче каттан башлап һәр квартирада балкон. Аның ни-ен үзгәртәсең?

Хәер, балконнарны парлап-парлап берләштерергә дә була бит. Ул чакта ике гаиләгә бер озын балкон була дигән сүз. Аны плитә белән урталай бүлеп куярга мөмкин. Балкон араларын ике рәт төсле плитәләр белән тоташтырсаң? Ни төсле булырга тиеш ул киң тасмалар? Куе кызыл төстә, билгеле.

Өч йортны бергә тоташтырырга була. Алар бер-берсенә икенче кат биеклегендә тоташалар, беренче кат урыны киң капка кебек була. Һәр йортка алты бүлмә, алты лоджия арта дигән сүз бит бу. Димәк, икешәр бүлмәле урынына өчәр бүлмәле булачак ул квартиралар...

Мәрьям ашыкмады, озак уйланып, төрле яктан үлчәп төзеде бу проектын.

Морат проектны күрү белән урыныннан сикереп торды да директорга йөгерде. Дөнья аны сак булырга, үз фикерен кычкырып әйткәнче, олыраклар сүзенә колак салырга өйрәткән иде.

– Молодец, булдыргансың, безгә ошады бу эшең, – диде ул, директордан чыккач. – Комиссия каршы килмәс дип өмет итик.

Морат сүзләрен алдын-артын уйлап бетермичәрәк әйтеп ташлады. Камәрия төшке аш ашарга дип урыныннан кузгалган иде. Моратның сүзләрен ишетеп алды да:

– Кая, нинди проект ул? – дип килеп тә җитте. Сүзнең әлеге шул 183, 185, 187 нче йортлар турында барганын белгәч, чәчрәп чыкты: – Бәлеш, мин бу йортларга проектны төзеп, документациясен тапшырып бетердем бит инде! Каян килгән ул бер кеше эшен икенчесеннән төзәттерү? Сигез ел инженер булып эшләгән кеше мин! – дип, аңына килә алмый торган Морат кулыннан эскизны тартып алды да, тимерле үкчәләрен шыкылдатып, мастерскойдан чыгып та китте. Директор: «Тукта, булыр-булмас эшкә гауга куптарып йөрмә әле, мәсьәлә хәл ителмәде бит», – дигәндер инде, кире кергәч, гауга куптармады үзе.

Шул көннән Камәрия Мәрьямне кан дошманы итеп күрә башлады, җае туры килсә-килмәсә дә төрттерә, чеметә торган булды.

Атна-ун көннән Мәрьямнең проектын кабул иттеләр. Бу хәбәрне Газиз алып килде. Ул Мәрьямне коридорда очратты да, котлыйм дип, тәмам югалып калган кызның маңгаеннан йомшак кына үбеп алды.

Шәүкәтнең исә бу вакыйгага исе китмәде. Типовой проектка кызыл тасмалар сызу һәм газоннарны ничә метр киңлектә утыртырга кирәклеген исәпләп утыру – иҗади эш тә, хәтта кызыклы шөгыль дә түгел иде, аныңча. Мәрьям эченнән генә рәнҗеде, әмма, бераз уйлагач, егетне аклады. «Шәүкәтнең үз эше генә эш!.. Икенче яктан караганда, дөрес тә инде: «Джоконда» биеклегенә омтылган талант иясе янында пүчтәк эшең белән мактанып буламыни?»

Шул ук җәйне Казанда революция өчен көрәштә һәлак булган геройларга һәйкәл куярга карар чыкты, аның проектына ябык конкурс игълан иттеләр. Конкурсның ябык булуы Мәрьямне кулына

каләм алырга дәртләндерде. Ачыктан-ачык, менә бу минем эш дип, кешегә күрсәтергә кыенсыныр да идең, ә болай ничек кабул итсәләр дә ояты юк.

Авылга кайткач та һаман уйланды, һаман эзләнде ул. Ялдан килгәндә инде нишләячәген күз алдына китерә һәм бу хакта Шәүкәт белән бик тә киңәшәсе килә иде. Ләкин киңәшү дә, рәхәтләнеп сөйләшү дә насыйп булмады.

***Күпердә***

Уф, нишләп бу чаклы эсселәнде соң әле? Җылыткыч батареялар артык кызганмы әллә? Мәрьям, урыныннан торып, яланаяк тәрәзә янына килде. Әйе, батареялар ут кебек, кул тидерерлек түгел.

Мәрьям, пәрдәне ачып, тышка карады. Урамда шыксыз, күңелсез. Бераз җилли икән, иртәгә, мөгаен, көн суытыр. Күрше йортларда бер генә якты тәрәзә дә юк. Ишегалдындагы ике катлы балалар бакчасының бер тәрәзәсеннән генә яктылык сирпелә. Багана башында электр лампочкасы чайкала. Әнә урамнан егет белән кыз узып бара. Әллә ир белән хатын микән? Култыклашмаганнар, бер-берсенә сыенмаганнар, ашыгып атлыйлар...

...Көзге караңгы кичләрнең берсендә Мәрьям белән Шәүкәт тә менә шулай урамнардан бергә үткәннәр иде. Ләкин үзләре янәшә атласалар да, алар арасында упкын хасил булган иде.

Шәүкәт авылыннан үзгәреп килде. Хәер, читтән караган кеше моны сизмәс тә иде. Әмма Мәрьям аның күңелен аңларга өйрәнгән, кәефе үзгәргәнне шундук тоя иде.

Дөрес, шәһәргә кайту белән проект институтына килде ул. Алар төшке ашны ашарга Кольцодагы ашханәгә бардылар. Биредә аш-суны тәмле әзерлиләр, әмма Мәрьямнең тамагыннан ризык үтмәде. Шәүкәтнең дә тәлинкәләре шул килеш калды.

Аннары Болак буена чыгып, күпер рәшәткәсенә таяндылар да яшел мүк белән капланган хәрәкәтсез суга төбәлделәр. Көн җылы, һава тузанлы, урамнар шау-шулы. Мәрьям бер сәбәпсез көлде дә көлде. Шәүкәтнең йөзе җитди, күз карашы сынаулы, кашлары җыерылган иде.

– Ул кадәр кычкырып көлмә, – диде ул, түземе бетеп. – Хәерлегә түгел көлүең.

Бәхетсезлек килгәнен Мәрьям үзе дә сизенде, тик акылы моны сыйдыра алмады.

Алар кич очрашырга сүз куешып аерылыштылар. Әмма эш бетүгә Шәүкәт килмәде. Мәрьям аны баскыч төбендә дә, урамда да көтте. Ахырда, эңгер-меңгер төшә башлагач, аның янына үзе барырга булды. «Без күптәнге якын дуслар лабаса, – дип, бу адымын акларга тырышты ул. – Аның ашыгыч эше килеп чыккандыр, ә бәлки, ташлап чыгып китә алмаслык кеше килгәндер».

Иң яхшысы – газапланып йөргәнче, барып сәбәбен белү. Шәүкәтне күреп, сөйләшеп тә кайтыр. Бик-бик сагынды бит ул аны, хәтта килер сәгатьләрен санап көтте.

Шулай да тора салып егет ишеген кагу яхшы түгел, җитди сәбәп кирәк иде. Юл буе сылтау эзләп барса да, чуалган зиһененә рәтле фикер килмәде. Акылы белән үзен ничек кенә юатмасын, күңеле тыныч түгел иде аның.

Урам чатында чәчкә сатучы очрады. Мәрьям аннан зур йөнтәс, куе кызыл георгин сатып алды. Моңлы уйга чумгандай, башын юан сабагына кыңгыр салган чәчкә.

Мамадыш тракты дип аталган таш юллы киң урамның ике ягында да, бакчаларга күмелеп, агач йортлар утыра. Урамга алма исе таралган. Караңгы төшкән, ләкин баганалардагы лампочкаларны кабызмаганнар. Сирәк-мирәк үткән машиналар, урам өстеннән очкан самолетлар чамадан артык улый кебек. Биек коймалар артында чылбырга бәйләнгән этләр өрә. Куркыта, күңелне шомландыра иде бу урам.

Мәрьям таныш капканы йодрыгы белән дөбердәтте. Ишегалдында шашынып овчарка өрергә тотынды. Шау-шуга Шәүкәтнең фатирдаш иптәше чыкты.

– Исәнмесез! Шәүкәт өйдәме?

– Өйдә, – диде егет. – Әйдәгез, керегез!

– Рәхмәт. Кереп тормыйм инде. Үзе генә чыкмас микән?

Егет кереп киткәч, Мәрьям куркуга төште. Төн җиткәч, егет артыннан килү оят бит инде. Шәүкәт, бәйләнчек булды бу, дип уйламасмы? Дөрес, элегрәк аның башына начар уй килмәс, Мәрьямне күргәч, чын күңеленнән сөенер генә иде... Хәзер исә аның ни уйлаганын белеп булмый. «Китәргә кирәк, – диде Мәрьям үз-үзенә. – Күзенә күренгәч, ни әйтермен?» Ләкин бераз киткәч, тагын борылып килде. Барыбер ул килгәнне Шәүкәт белде бит инде.

Авыр келәләр шалтырады, усал эт чыелдап куйды. Капкадан Шәүкәт килеп чыкты:

– Нишләп биредә торасың? Әйдә керик. Закир сине чакырмадымы әллә?

Мәрьям, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, артык кычкырып һәм ашыгып сөйләргә тотынды:

– Чакырды, кермәдем. Ашыгам. Дуся түтәй мин кайтканны көтеп тормый, ята да йоклый... Вакытсыз килгән булсам, ачуланма инде.

– Вакытсыз түгел... Әле ашарга гына утырган идек. Әйдә керик, бәрәңге белән сыйларбыз...
– Нинди бәрәңге, тәмлеме?
– Әрчеп пешергән... – Шәүкәт бераз уйланып торды. – Юк, гафу ит. Чикмәнле бәрәңге.
Аннары моңсу гына елмайды:
– Ярый әле чикмәнле иде, югыйсә тоз урынына шикәр комы салганмын...
Мәрьям үзен кулга алырга һәм килүенә сылтау табарга өлгергән иде.
– Мин сездә җәй көне зонтигымны калдырган идем. Шуны гына алып чыгып бирсәңче! Көз бит, яңгырлар...
Шәүкәт озак көттермичә зонтикны алып чыкты. Караңгыда аның йөзе ачык күренми иде, шулай да егетнең кашлары җыерылган кебек тоелды.
Инде китәргә кирәк иде. Шулчак Мәрьямнең исенә келт итеп сумкасындагы күчтәнәч килеп төште.
– Бәй, онытa язганмын. Мин сиңа авылдан карлыган алып килгән идем бит. Свежий көе алып килмәкче идем, бозылыр дип курыктым. Шикәр комы белән бутарга туры килде. Мә, шикәрле бәрәңге ашагач, монысын кабып чәй эчәрсең.
Шәүкәт кулларын артка яшерде:
– Юкка мәшәкатьләнгәнсең. Баллы әйбер яратмыйм мин.
Шәүкәт моны шундый итеп әйтте, Мәрьям кыстап торуның мәгънәсез икәнен шундук аңлады. Бу – егетнең аны читкә этәрүе иде. Банканы кире салгач, сумка чамасыз авыраеп киткәндәй булды.
– Сау бул. Мин киттем, – диде Мәрьям, бераз сүзсез торгач, ләкин баскан җиреннән кузгала алмады.
Шәүкәт аның ни көткәнен аңлады.
– Биредә берүзең йөрергә ярамас. Әйдә озатып куям.
Алар урам уртасыннан янәшә киттеләр. Мәрьям аны сынар өчен юри читкәрәк тайпылды, Шәүкәт исә якынлашмады. Баш очыннан әледән-әле яман улап самолетлар уза, аэродром якын гына бирегә. Самолет канатларында яшелле-кызыллы утлар җемелди: «Бәрелә күрмә, сак бул», – ди ул утлар.
Алар сөйләшмиләр. Мәрьямнең бер кулында сумка, икенчесендә – йөнтәс чәчкә. Караңгыда ул кап-кара булып күренә. Күңелендә мең төрле уй булса да, сүз башларга җай тапмый, чөнки ул «яңа» Шәүкәт белән ничек сөйләшергә кирәген белми.
Университетның биш катлы тулай торагы каршында тирән чокыр бар. Аның төбеннән тимер юл үтә. Тулай тораҡтан килгән сукмак белән барсаң, шул чокыр аркылы салынган тар гына такта күпергә килеп керәсең.
Күпер уртасына җиткәч, Мәрьям туктады, култыксага таянып, аска, тонык кына ялтыраган рельсларга карады. Аннары, күтәрелеп, Шәүкәткә борылды:
– Ни булды сиңа?
– Берни булмады...
Мәрьям сораштырырга кирәк түгелен дә бик яхшы белә. Ул ни генә әйтсә дә, Шәүкәтнең күңеленә хуш килмәсен дә сизә, тик тыела алмый, тагын сорый:
– Юк, нидер булган сиңа. Син бик нык үзгәргәнсең, шулай бит?
Шәүкәт бөтен гәүдәсе белән тураеп нидер әйтә башлаган иде, баш очыннан, утларын җемелдәтеп, самолет узып китте, мотор гүләве егетнең тавышын күмде.
– Үзгәрү гаҗәпмени? – диде ул, самолет ерагайгач. – Дөньяда мәңгелек берни дә юк. Әгәр синең миңа мөнәсәбәтең үзгәрә икән, бу бер дә гаҗәп булмаячак.
Мәрьям, аның сүзләреннән йөзен капларга теләгәндәй, кулын күтәрде. Кулында чәчкә икән. Ул шул чәчкәсе белән Шәүкәтнең яңагына сукты. Берне... икене... Егет читкә тайпылмады, хәтта йөзен дә бормады. Мәрьям аның саен үчләнеп, киңрәк селтәнеп, яңаклавын дәвам итте. Үңлап-суллап... Авыр чәчкә шап-шоп килде... Ниһаять, чәчәк өзелеп чокырга очты, Мәрьям кулында сабагы гына калды.
Шәүкәт шәрә сабакны сак кына алды да гаҗәпләнеп карады, тик ләм-мим сүз дәшмәде. Әгәр чыннан да күңеле сүрелгән булса, гаепле кешедәй түзеп тормас иде ул... Мәрьям күкрәге белән күпер култыксасына ятты, шушы култыкса аша сикереп, аска, чокырга ташланасы, ялтырап яткан рельсларга башын бәрәсе килде аның. Ул сумкасыннан банканы алып төшереп җибәрде, пыяла ватылган тавыш тонык кына ишетелде.
Шәүкәт гадәттәгедән басынкырак тавыш белән әкрен генә сөйли башлады:
– Еллар үткәч, син минем хаклы булганымны аңларсың әле...
– Ник «еллар үткәч»? Ник хәзер түгел? Ник син минем белән ачыктан-ачык сөйләшмисең?
– Хәзер син мине аңламаячаксың... Аннары, сөйләшеп торуда ни мәгънә?
– Димәк... барысы да бетте?
Шәүкәт дәшмәде. Дәшмәү ризалык билгесе иде...

Мәрьям, култыксадан аерылып, беренче адымын атлады. Алар күпердән икесе ике якка чыктылар. Бераз киткәч, Мәрьям, үксегәнен ишеттермәс өчен, йодрыгын тешләде. Бетте...

Бу хәлгә акыл күзе белән караганда, ул хәтле өзгәләнүләргә сәбәп юк иде кебек. Шәүкәт белән аларның мөнәсәбәтләре артык тирәнгә кермәгән иде. Кешеләр яшь чакта сөешәләр дә аерылышалар, үпкән-кочкан җилгә очкан...

Юк, алай түгел икән шул. Мәрьям Шәүкәтне чын күңелдән яраткан, аңа ышанган, аныкы булачагына тәмам инанган иде инде. Соңгы елда ул тормышын аңа гына багышлады, барлык дус-ишләреннән, якыннарыннан читләште. Яшәвенең мәгънәсен Шәүкәт белән бергә булуда, аның мәхәббәтендә генә күрә иде ул.

Хәзер егет араны шулхәтле кинәт һәм аяусыз өзгәч, Мәрьямнең киләчәген яктырткан утлар сүнеп киткәндәй булды. Киләчәк караңгы, тирә-юньдә бушлык. Ни өчен җирдә яши ул, беркемгә дә кирәк булмагач?

Табигать хатын-кызга көч-куәтне, күңел ныклыгын ирләргә караганда ким биргән, чөнки ул аларга башка бурычлар йөкләгән. Хатыннарны балалар белән беррәттән җил-давыллардан, авырлыклардан ирләр сакларга тиеш, күрәсең.

Ир күләгәсенә ышыкланырга, кемгәдер кирәк булырга омтылмаган, кеше өчен яшәргә теләмәгән хатын-кыз хатын-кыз түгел. Киресенчә, сөйгәне өчен, кеше өчен олы җаваплылыкны үз җилкәсенә алмаган, хатын-кызны җил-давылдан сакламаган ир-егет ир түгел.

Егетләре ташлаган кызлар, ирләре ташлаган хатыннар үзләрен кимсеткән өчен гарьләнеп яки балаларын ялгыз тәрбияләүдән куркып еламыйлар. Юк, хикмәт анда түгел. Аларга үзләрен яклый, саклый, көч бирә торган кеше кирәк. Шулай ук аларга тормышларын, бөтен барлыкларын багышларга кеше кирәк.

...Шәүкәт белән күпердә саубуллашмыйча да аерылгач, квартирасына кайтып җиткәнче Мәрьямнең күзенә ак-кара күренмәде.

Дуся түтәй аңа ишек ачты да, үзалдына нидер сөйләнә-сөйләнә, текә, тар агач баскычтан икенче катка менеп китте. Аның бизәкле ситсыдан тегелгән итәгенә борыны белән тия язып, арттан Мәрьям иярде.

Сиксәннән узган Дуся түтәй бик таза әле, суын да үзе ташый, кибетенә дә йөгерә. Үз гомерендә ике ир җирләгән, биш бала табып бирсен дә исән үстерә алмаган, картайган көнендә олы йортта ялгыз калган.

Дуся түтәй гомерен Тимоша исемле ата мәчене тәрбияләп үткәрә. Аны иркәли, пенсия акчасына аның өчен ит-сөт сатып ала, кичләрен аның көндез нишләгәнен сөйләп утыра.

Бүген Тимоша өйгә кайтмаган икән, Дуся түтәйнең шуңа кәефе юк.

Ул Мәрьям бүлмәсенең ишегенә аркылы басты да, борынын мышкылдатып (әллә елаган да инде), шул турыда сөйләргә тотынды:

– Бөтен урамны әйләнеп чыктым инде, кайларда гына йөри икән бичаракаем. Бигрәк матур, бигрәк сөйкемле иде шул; мөгаен, урамнан берәрсе тотып алып киткәндер. Ерак алып китсәләр, ни хәл итәрмен! Юлны таба алмавы бар бит!

Мәрьям мәче дигән ялагай һәм астыртын хайванны яратмый. Ә иңгә менеп кунакларга гына торган бәйләнчек, симез һәм иркә Тимошаны бөтенләй җене сөйми. Дөньяда мәче өчен яшәгән карчыкның язмышы аңа коточкыч булып күренде.

Ул бүлмәсенә керде, Дуся түтәй кермәсен дип ишек келәсен элде дә, пальтосын да салмыйча, караватына ауды...

### ***Шәфикъ абый Бохарасы***

Төннәреңне йокысыз үткәргәндә ниләр генә уйлап бетермисең? Үткәннәрне искә төшерү кешегә сөйләү белән бер түгел. Сөйләгәндә кайберсен яшерәсең, күбесен үзгәртәсең. Ә менә намусыңнан бернәрсә дә яшереп булмый, вөҗданың һәммәсенә шаһит.

Мәрьям дөньяда терәген дә, яшәү мәгънәсен дә югалтты. Эше артык катлаулы түгел, гадәтләнгән куллар кирәкне үзләре башкара, ә уйлар һаман бер тирәдә әйләнә.

Мәрьям дигән кеше элеккечә эшли, ашый. Таныш-белешләре белән ачылып сөйләшә. Йоклый алмаса да, кичләрен урынына ята. Ул хәтта үзен иҗат эше белән шөгыльләнергә дә мәҗбүр итеп карады.

Ябык конкурста катнашырга эскизлары әзер иде. Дуся түтәйнең: «Бар икән, хатын-кыз түгелдерсең син, юбка кигән малайдыр, бөтен дөньяны чүплисең!» – дип мыгырдавына колак та салмыйча, төннәр буе катыргы, фанер, пенопласт турап, һәйкәлнең макетын ясады.

Кабер өстендә Ана тора. Аның күзләрендә тирән хәсрәт, үткән гомерендәге зур югалтуларны, авыр фаҗигаләрне, җиңү тантанасын – барысын берьюлы исенә төшергән ул. Әллә Мәрьямнең

кайгы кичергән чагы булганга, образда трагик мотивлар өстенлек алган иде. Мәрьям үзенең проектын беркемгә дә күрсәтеп тормады, Саҗидә апага гына серен ачып, аннан макетны комиссиягә тапшыруын үтенде.

Аның проекты дүртенче урынга чыкты. Конкурста башка шәһәрләрдән дә күп кенә рәссамнарның һәм архитекторларның катнашуын исәпкә алсаң, бу уңыш иде. Жюри членнары заманча итеп эшләнгән обелискларны яхшы дип таптылар, беренче премияне архитектор Морат Шәехзадин һәм рәссам Газиз Фәтхуллинга бирделәр.

Җиңүчеләрнең исемнәре мәгълүм булгач, хезмәттәшләре Мәрьямне мактадылар, әйбәт архитектор булачаксың, дип үсендерделәр. Нәкъ шул айларда яшь архитектор Сухоруков, квартирасы юклыгын, юньле задание бирмәүләрен сәбәп итеп, Алма-Атага китәргә йөри иде. Мондый хәлләр елга берничә тапкыр кабатланып торганга, берәүнең дә исе китмәде. Морат кына үз постыннан качкан «дезертир»га мөнәсәбәтен ачыктан-ачык әйтте: «Әйдә ычкын, Алма-Атада сиңа дип пешерелгән бишбармак суына күрмәсен!»

Сухоруковның китүе Шәфикъ абый өчен зур вакыйга булды: ул тагын Бохараны исенә төшерде. Пенсия яше җитеп килгәнгә, аңа зур эш кушмыйлар, буш вакыты күп иде, соңгы ике атнасын әйлешәйле уздырган Сухоруковка Бохарада салынган биналарны бәйнә-бәйнә тасвирлап бирде, аннары чаяннарның явызлыгына, арык суларының болганчыклыгына, тут җимешенең тәменә, гомумән, экзотикага күчте.

Ул кызып китеп артыграк кычкырып сөйләшә башласа, Морат, башын күтәреп, күзлеген елтыратып куя, андый чакта Шәфикъ абзый пышылдауга күчә.

Ниһаять, Сухоруков китте. Шәфикъ абзыйның күзләре кызарып, пеләше күгәреп калды. Ул берничә көн аптырап үзенә шөгыль таба алмый йөрде.

Бушаган урынга архитектор итеп Мәрьямне күтәрделәр. Моны ул ничектер бик тыныч кабул итте, очынмады, куанмады, чөнки бу үзгәрешнең нинди вакыйгаларга этәргеч бирәсен белми иде. Аның урынына башка икәү моңа зур әһәмият биргәннәрен белдерделәр.

– Котлыйм, Мәрьям! – диде Саҗидә апа, чын күңелдән сөенеп. – Яшь чакта эшләп кал. Әллә зур эшләр башкарырсың әле, күренеп тора.

Ирина Сергеевна хөрмәт йөзеннән Мәрьям янына үзе үк йөгереп керде. Ул, чын күңелдән сөенгән кебек, баскан урынында таптанды:

– Ну, Мәрьям, молодец! Син беренче хатын-кыз архитектор бездә. Ниләргә сәләтле икәнебезне ирләргә күрсәтик әле. Әгәр юл бирми башласалар, миңа гына әйт, кыерсытырга ирек бирмәбез...

Мәрьямне күтәрүгә эчтән кайнап утырган Камәрия Ирина Сергеевнаның сүзен иң кызган җирендә бүлде:

– Бәй, моңарчы да әллә кая китә алмадылар әле ирләр. Берсенең дә миннән артык эшләре юк.

– Әйе, әйе, – диде Ирина Сергеевна, Мәрьямгә күз кысып. Ул Камәрияне надан, сәләтсез кешегә саный һәм хатын-кызларның дәрәҗәсен үстерүдә аңа бернинди дә өмет багламый иде. Шулай да Камәриягә дөресен әйтү хәтәр икәнен истә тотып, майлап-җайлап җибәрүне хуп күрде: – Менә иптәш Гаделшина үрнәгендә эшләрсең. Хатын-кызларны архитектура өлкәсендә дә тиешле югарылыкка күтәрү сезнең кулда хәзер. Бу изге эштә мин сезнең ярдәмчегез, хезмәтчегез! – диде.

### ***Җил уңаена***

Кыш килде. Күксел болытлары, ачы җилләре, озын төннәре белән кыш җитте. Мәрьямнең тәне генә түгел, күңеле дә туңа иде кебек. Чөнки Шәүкәт бер генә тапкыр да проект институтына кермәде.

Алай да кар астында кечкенә генә өмет чаткысы яна – көн саен аны көтә иде Мәрьям. Чөнки аяусыз хакыйкатьне кабул итә алмады, эченнән егетне акларга, үз-үзен юатырга тырышты: «Дөньялар үзгәреп тора, бәлки, ике арадагы аңлашылмаучылык ачыкланыр, ярата бит ул мине!» – дип уйлады ул.

Газиз кереп рәссамнарның «Олы Идел» күргәзмәсе ачылуын сөйләде. Аитов «Җиде төн уртасында» дигән картинасын тәкъдим иткән булган. Юк, теге диплом яклаганын түгел, яңа вариантын. Бусы тагы да яхшырак, ди. Тик кабул итмәгәннәр, идея эчтәлеге сай, дигәннәр. Аитов шул комиссиягә ачу итеп картинасын кискәләгән...

Газиз Мәрьямне коридорга чакырып чыгарды:

– Шәүкәтнең кәефе бик төшенке, – диде ул. – Аңа бик зур таяныч, терәк кирәк хәзер. Берәр кая моннан китеп тору, дөнья гизеп кайту файдалы булыр иде. Бәлки, сез отпускыны хәзер алырсыз?

– Бәй, Шәүкәт ялга барсын дип, мин нишләп отпускы алыйм? Анда ни катнашым бар минем?

– Соң... – Газиз бераз югалып калды. – Мин сезне өйләнештеләр дип ишеткән идем...

– Безнеме? Безнең күрешмәгәнгә ярты ел инде.

– Менә сиңа мә! – дип аптырады Газиз. – Миңа кемдер, Аитовның туенда булдым, дип сөйләгән кебек иде. Башка Аитов булды микәнни? Да-а, хәзерге вакытта синең ярдәмең бик кирәк иде аңа. Ул юкка чыгарга мөмкин. Дуслык менә шундый чакларда сынала да.

Ул Мәрьямнең ни әйтерен көтте, ләкин бертөрле дә җавап ишетмәде, саубуллашып китеп барды.

Мәрьям, озак уйланулардан соң, бөтен горурлыгын артка ташлап, Шәүкәтнең хәлен читләтеп булса да белешергә уйлады...

Шәфикъ абый Мәрьямне янына чакырып, аның инженер булып эшләгән чагындагы сызымга юан бармагы белән төртеп күрсәтте:

– Кара әле, кызыкай, синең мондагы тәрәзә урыннарына рамнарың сыймый бит. Ике сантиметрын кисеп ташларга кирәк.

Мәрьям калька өстенә иелде:

– Кая әле?

Һәм көтмәгәндә колак төбендә зәһәр пышылдау ишетте:

– Аитов өйләнгән бит...

Мәрьям бөтен тәне кызышканны тойды, әмма сер бирмәскә тырышты.

– Шәфикъ абый, бу информациянең проектка ни катнашы бар?

– Бу вакыйга сине кызыксындырыр дип уйлаган идем.

– Бераз гына, – диде Мәрьям, елмаерга тырышып.

Шәфикъ абый аңа текәлеп, газаплануыннан тәм табып утыра иде.

Берничә көннән Шәүкәт нindидер йомыш белән Морат янына керде. Шәфикъ абый аны Мәрьям алдында башлы-күзле булуы белән котлады. Шәүкәт котлауларны рәхмәт әйтеп кабул итте. Димәк, өйләнүе хак.

Мәрьям иртәсен дә, кичен дә шушы минутларда Шәүкәтнең башка берәү белән елмаеп сөйләшүен, урамнарда бергә йөрүен, башка берәүне назлап-иркәләвен уйлап, ут эчендә яна башлады. Көнләшү газапларын дошманыңа да күрсәтмәсен!

Ничек соң ул хисләр тиз туа да тиз үлә икән? Ничек инде күптән түгел яратып, ансыз яши алмастай булып йөргән кешегә бүген бөтенләй битараф буласың, ник ул егылып үлми шунда, исең дә китми. Икенче берәүне кочканда, үпкәндә, элек сөйгәнең исеңә төшеп, ничек үзәгең өзелми икән? Мәрьям моны аңлый алмады.

Теге чакта Мәрьям белән Чаллы үрендә саубуллашып, кире Кама буена төшеп киткәч, пароходта ук бер кыз белән танышкан булган икән ул. Уфага барып җитүгә, культура министры янына кергән. Башкортстанда рәссамнар әзерли торган махсус уку йорты юк иде әле, шунлыктан республика җитәкчеләре читтә укып кайткан яшьләрне ачык чырай белән каршы алалар иде. Шәүкәтнең яңа калада эшләргә теләген белгәч, бик хуплаганнар, хәзер үк барып карап кайт, дип, командировкага җибәргәннәр. Ә ул каладагы зур бер җитәкченең кызы Шәүкәтнең пароходта бергә кайткан танышы булып чыккан...

Кыз бик чибәр, дип сөйләделәр Мәрьямгә аның хакында, үткен, өлгер дә икән үзе. Шәүкәткә бер күрүдә гашыйк булган, имеш. Бу заман өчен бирнәсе дә менә дигән: тормышның – җитеше, ата-ананың – дәрәҗәлесе. Кыскасы, Шәүкәт үзенә иҗат итү өчен кирәкле дип санаган барча шартлар бар икән яңа калада. Сөйләүләренә караганда, егет белән кыз, хисләренә мавыгып китеп, артыграк якынаеп куйганнар, имеш. Ә соңыннан кызны бәхетсез итәргә егетнең намусы кушмаган.

Шәүкәт Казан белән араны тиз генә өзмәде, ара-тирә күзгә чалынгалап торды.

Ә беркөнне алар һич көтмәгәндә троллейбуста очраштылар. Мәрьям сер бирмәскә тырышты, шырык-шырык көлгән, шаярган булды. Сүз иярә сүз китте. Шәүкәт киная белән: «Мин синең каршыңда бурычлы булмадым, ә башка кеше алдында үзем дә көтмәгәндә бурычлы булып куйдым», – диде. «Бәхетеңне тапкан өчен миңа рәхмәт әйт инде алайса», – диде аңа Мәрьям, үчекләп.

Шуннан соң зиһендә кинәт шәм кабынып, аның яктысында үткәннәрнең күләгәсе чигенгәндәй булды. Элек аңлаешсыз тоелган хәлләрнең сәбәпләре ачыкланды. Теге чакта, авылдан килгәч, Шәүкәт Мәрьям белән юри ызгышырга теләгән икән. Ул Мәрьямнең аңа үпкәләп китүен теләгән, аерылышуда аны гаеплисе килгән, яңа танышыннан Мәрьямнең начаррак икәненә үзен-үзе ышандырырга тырышкан икән.

### *Шугалак*

Декабрьнең болытлы тымызык кичендә Мәрьям Вилдан белән очрашты. Хәзер дә әйтүе кыен: бәхетенәме, әллә бәхетсезлегенәме? Бәхеткә дияр идең, аларга яндырып көйдерә торган көчле хисләр килмәде. Бәхетсезлеккә дияр идең... Юк, тукта, барысын да үз тәртибендә искә төшерик әле...

Эштән соң, инде караңгы төшкән иде, Мәрьям «Чишмә» ашханәсенә барып керде. Токмачлы аш ашыйсы килгән иде аның. Ашханәдә җылы, рәхәт. Кеше дә аз. Чаршау артындагы патефон Зифа

Басыйрова тавышы белән «Җырламыйм мин җырларымны» дип җырлый. Кискән чәчләренә чигүле калфак кадаган официанткалар нәзакәтле сөйләшәләр.

Мәрьям буш өстәл янына утырды. Ашны тиз китерделәр. Ул кулына кашык алгач кына күрше өстәлдә ялгыз утыручы чибәр егетнең шоколад төсле күзләре белән очрашты. Һе-е... Кайчан керде соң әле бу егет? Мәрьям кергәндә юк иде түгелме?

Ашагач, Мәрьям тиз генә киенә алмады – гардеробтагы апа каядыр чыгып киткән иде. Менә аның янына теге чибәр егет килеп басты. Гардеробчы юан хатын алпан-тилпән килеп җитте дә Мәрьямнең пальтосын аңа тоттырды:

– Егеткәй, туташка киенергә ярдәм итегез!

Янәсе, ул яшь кешене әдәпкә өйрәтә.

– Юк, юк, рәхмәт, мин үзем дә киенә алам!

Егет эре ак тешләрен күрсәтеп елмайды, аның гарәпләргә охшаган кара-кучкыл озынча йөзе бердәм яктырып, мөлаемланып китте.

– Рөхсәт итегез!

Мәрьям пальтосын тартып алырга җөрьәт итмәде. Егет, ишекне ачып, Мәрьямгә юл бирде; алар, бер-берсенә сүз дәшмичә, Кольцога таба борылдылар.

– Сез дә бу яккамыни? – дип сорады Мәрьям, бераз шикләнеп.

– Әйе, мин тукталышка барам. Сез дә троллейбускамы әллә?

– Юк. Трамвайга.

Бераз дәшми бардылар. Янәшәңдәге кеше белән сөйләшмәү уңайсыз иде, Мәрьям, сүз югыннан сүз булсын дип:

– Ленин районында торасызмы әллә? – дип сорады.

– Әйе.

Егет Мәрьямнең ул тирәләрдә сирәк булганын белеп аптырады. Әгәр теләсә, анда төзелгән яңа кварталларны күрсәтергә әзер икәнлеген әйтте. Анда парк бик яхшы, менә дигән шугалак бар. Әгәр Мәрьям каршы килмәсә, егет аны шунда чакырыр иде. Мәсәлән, иртәгә сәгать алтыда алар биредә, троллейбус тукталышында очраша алалар. Аның тавышында үчекләү, үртәү ишетелде. Килмәсеңне бик беләм, юри генә чакырам дигән сыман иде. Шуңа Мәрьям юри: «Бәлки, килермен дә әле», – дип әйтеп куйды. Алар хушлашканда бер-берсен үртәгәндәй көлемсерәп баш иделәр.

Башта таныш түгел кеше белән беркая барырга теләмәсә дә: «Бу рәвешле җебеп өйдә яту оят, бу нинди көчсезлек, ичмасам, бер һава алыштырып кайтырга кирәк», – дип, үз-үзен тиргәп, билгеләнгән сәгатькә Кольцога китте Мәрьям. Урам буйлап чалбар киеп йөрергә уңайсызланды, куртка белән чалбарын, кәгазьгә төреп, җәтмә сумкага салып тотты.

Киче дә бик матур, әз генә вак кар төшкәли, җылы, рәхәт, һава чиста иде.

Егет Мәрьямне тукталышта көтә иде инде, елмаеп каршы алды.

– Инде танышырга да вакыттыр. Мин – Вилдан, – дип, башын иде ул.

Бу мизгелдә әдәпле кыз үз исемен әйтеп, аңа кул бирергә тиеш иде.

– Мин – Мәрьям.

Ул тимераякта начар шуа. Шулай да Вилдан аны җитәкләп йөрмәде. Мәрьям ике атлады да егылды, өч атлады да утырды. Бүген генә сатып алган яңа коңгырт чалбары белән шугалакның яртысын себереп чыккандыр, мөгаен. Ул егылуга, Вилдан җил кебек очып килеп җитә, тимераяклары астыннан боз кыйпылчыклары чәчрәтеп, кырт борыла, Мәрьямнең култык асларыннан күтәреп аягына бастыра да тагын шуып китә. Аның үзен шулай иркәле тотуы ошады: Мәрьям аңа һич тә комачауламый, димәк, ул Вилдан каршында бурычлы да түгел.

Хәрәкәттә – бәрәкәт дигәндәй, егылсаң да, тезләр күгәрсә дә, саф һавада, яктыда, кеше арасында уралып йөрү күңелне күтәреп, күзне ачып җибәргәндәй итте.

Андый чакта вакыт тиз үтә бит, әнә Вилдан тимераягын салган, биек көрткә баскан да кулын болгый. Мәрьям ул төшкә барып җиткәнче, тагын бер-ике тапкыр утырып алды. Ә Вилдан рәхәтләнеп көлә:

– Их син, аю баласы!

Алар киенү бүлмәсендә өсләрен алыштырдылар, тимераякларын тапшырдылар.

Вилдан Мәрьямне троллейбуска утыртып җибәрде.

...Икенче атна ахырында ул Мәрьямнең эш урынына шалтыратты.

Алар ял саен очраша торган булдылар. Дуслаштылар, әмма күңелләре белән бер-берсенә артык якыная алмадылар. Дөрес, егет янында чакта йөрәкнең әрнүе дә, эштәге гамь-ваемнар да онытылып тора шикелле, гәрчә Мәрьям эч серләрен аңа ачмады, борчулары хакында бер авыз сүз дә сөйләмәде. Сүз укылган китаплар, кинолар, уен-көлке тирәсендә генә әйләнә торган иде.

Әйе, елмаеп искә алырлык вакыйгалар булмаган, хәтергә мәңгегә сеңеп калырлык сүзләр әйтелмәгән, һәрхәлдә, Мәрьям Вилдан өчен янып-көеп йөргәнен, йөрәге җилкенгәнен хәтерләми.

Хәтта парлап нинди кинолар караганнары, нинди спектакльләрдә булганнары да истә калмаган. Шактый озак йөрделәр бит югыйсә.

Бәлки, мәхәббәт дигән олы хис кеше гомерендә чыннан да бер генә тапкыр килә торгандыр? Бәлки, бар хисләрен Шәүкәткә багышлаган Мәрьям, Вилдан белән очрашып, аның белән язмышын бәйләп, дөрес эшләмәгәндер?

Дөрес, ул моңа тамчы да үкенми. Шәүкәт өчен янып-көеп, ялгызы яшәп, гомере заяга узар иде, ә болай, ичмаса, Фәйрүзә бар, тормышка ямь, яшәргә мәгънә бирә торган бала бар.

Әйе, алар икесе дә эч серләрен бикле сандыкларда сакладылар. Вилдан беркайчан да Мәрьямгә үткәннәре турында сөйләмәде. Егерме сигез яшьлек егетнең кемнәре булгандыр да, улниләр кичергәндер, анысы хәзер дә Мәрьям өчен караңгы.

Үтә дә сабыр, тыйнак булып чыкты ул. Аның акылын җуеп кызлар артыннан чабуын күз алдына китерү кыен. Ир-егетнең эчендә иярләгән ат ятар, дип нәкъ шундыйлар турында әйтәләр инде.

Бәлки, ул хаклыдыр да. Бер-берең алдында капчыкны төбеннән тотып селкү зыянгадыр. Борчылмыйча тыныч яшәүгә ни җитә!

Ничек кенә булмасын, ике-өч ай эчендә алар бер-берсенә шактый ияләштеләр. Бер шимбәдә Вилдан аны өенә чакырды. Ул көнне дә алар шугалакка бардылар, шактый салкын булуга карамастан, озак шудылар. Егет Декабристлар урамындагы квартирасына кереп, чәй эчеп, җылынып чыгарга тәкъдим ясады. Кыз күптәнге танышының чакыруын кире кагарга кыймады.

Вилдан яңа йортларның берсендә, дүртенче каттагы бер бүлмәле квартирада тора икән.

Шулай итеп, Мәрьям беренче тапкыр үзе хуҗа булачак өйнең бусагасын атлап керде.

Гөлт итеп ут кабынуга, Мәрьям үзен оҗмахка кергәндәй хис итте. Өй җылы, чиста иде. Яшькелт стеналарда эре-эре көзге яфраклар сурәте. Тәрәзәдә яшелгә ак-кара сызыклар белән каеннар төшерелгән пәрдә. Бер як стенада идәннән түшәмгә чаклы китап шкафлары. Икенче якта секретер, янәшәсендә диван-караватъ. Уртада ялтырап торган өстәл, диванга каршы якта радиола һәм телевизор. Гомумән, хуҗаның белемле, зәвыклы, яшәүнең тәмен белгән шәхес икәнлеге һәрнәсәдән сизелеп тора иде.

Дуся түтәйнең Мәрьям торган кысан, ярым караңгы, шыксыз бүлмәсе бу квартира белән чагыштырганда эт оясы кебек иде. Вилдан кунакка диванга утырырга тәкъдим итте, иңнәренә җылы джемперын элде, өстәлгә электр җылыткычы китереп куйды. Йомшак диванда йөзеңне җылы нурларга куеп утыру искиткеч рәхәт иде.

– Хәзер чәй пешерәм, – диде Вилдан.

– Озак буламы соң ул?

– Унбиш минут. Ә син, теләсәң, китап карый тор.

Мәрьям урыныннан торып шкаф янына килде. Китапларның күбесе букинистлар кулыннан узган, күрәсең, нык таушалганнар. Арада калын-калын томнар күп. Конан Дойльның «Шерлок Холмс маҗаралары», Ефремовның «Андромеда томанлыгы», Лев Шейнинның «Тикшерүче язмалары». Мәрьям киштәдән киштәгә үрелде, ләкин бөтен шкафны саңаклы кешеләр, Марстан килгән коточкыч хәшәрәтләр, мәкерле һәм хәйләкәр җинаятьчеләр, аларны аулаучы акыллы милиционерлар һәм полицейскийлар тутырган иде. Кешене мавыктыра һәм күңелгә шом сала торган хыялый дөнья... Аек килеш төш күрсәтә торган әфьюн, татлы агу. Мәрьям җитди әсәрләр, һич булмаса, квартира хуҗасының эшенә бәйле белешмәләр табарга өметләнеп, аяк очына басып, өске киштәгә үрелгән иде, арттан хуҗаның тавышы ишетелде:

– Шәпме минем китапханә? Танышлар бик кызыга. Китап сорап җаныма тияләр... Ә бирсәң, кайтарып алуны өмет итмә... Ә сиңа биреп тора алам. Теләгәнеңне сайлап ал.

– Сайламадым әле. Ә бусы ни?

Ул Вилдан кулындагы сәер тартмага төртеп күрсәтте. Китапханәләрдә каталогларны шундыйларга тутыралар. Вилдан, шкатулканы өстәлгә куеп, тартмачыкларны берәм-берәм ачып күрсәтергә тотынды.

– Яле, иснәп кара әле!

– Чәй.

– Ә бусы?

– Бусы да чәй ич, – диде Мәрьям, гаҗәпләнеп.

– Ә сорты нинди?

– Чәй булгач, барыбер түгелмени?

Мәрьям чәй сортларын исе белән дә, төсе белән дә аермый иде.

– Һи-и, чәй эчүнең ләззәтен белмисең икән алайса! Йә, кайсын пешерим сиңа?

Кыз, тәвәккәлләп, бер тартмачыкка бармагы белән төртте:

– Менә монысын!

– Һи-и, иң арзаны ич бу, Краснодар чәе! Болай булгач, минем зәвыкка ышанырга туры килә инде сиңа, – диде Вилдан һәм, ялтырап торган очлы башлы ботинкалары белән кәс-кәс басып, кухняга

кереп китте. Ботинкалар аның куе зәңгәр йоннан бәйләнгән спорт костюмына шулкадәр ятышсыз иде, Мәрьям ирексездән көлеп җибәрде. Бала-чага икән бу Вилдан! Киеме дә, кыланышы да, укыган китаплары да яшүсмер малайларныкы кебек! Мәрьямгә күңелле булып китте. Чәйне дә: «Ай-һай, тәмле, мондыйны эчкәнем юк иде», – дип мактады. Вилдан, аның сүзенә чын күңелдән ышанып: «Мин бит берничә сортны бергә кушып пешердем, шуңа тәмле ул», – дип сөенеп утырды.

Егет чәйнең генә түгел, музыканың да тәмен белә икән. Табыннан кузгалгач, шкафның аскы тартмасын ачып күрсәтте, анда шыплап пластинкалар тезелгән иде.

– Ниндиен тыңлыйсың килә? – дип сорады ул. – Операдан арияләрме, симфоник музыкамы, әллә эстрада җырларымы? Әллә, Эдита Пьеханы тыңлыйсың киләдер?

– Мария Калласны, – дип, теленә беренче килгәнне әйтте Мәрьям. Юктыр дип уйлаган иде, ялгышты. Вилдан иелеп карады да арадан бер пластинканы тартып та чыгарды.

– Теләсәң, «Аида» операсын тулысы белән тыңлата алам.

– Юк-юк, бер ария дә бик җиткән.

Үзенең ничәнче тапкыр тыңлавы булгандыр, әмма бу юлы да, башын артка ташлап, күзләрен кысып, хисләнеп утырды.

Мәрьям урыныннан кузгалгач, тагын бераз утыр әле дип кыстамады, тиз генә киенеп, озатырга чыкты.

## *Туйлар*

Ниһаять, 187 нче йорт төзелеп бетте. Эштән соң Мәрьям бинаны тагын бер карап кайтырга булды. Кешеләр күчеп килгәч, эченә җан кергәч, ничек күренә икән...

Караңгы төшкән иде инде. Яңа йортның күп тәрәзәләрендә утлар яна. Ул елларда күпләр торакка кытлык кичерде, шунлыктан кулларына ачкыч керүгә күченәләр дә иде. Монда да әнә ашыкканнар. Абажурлар, люстралар, пәрдәләр эләргә өлгермәгәннәр әле, чекерәеп янган шәрә лампочкалар яктысында хуҗаларның әрле-бирле йөргәне күренә.

Ирексездән шушы ыгы-зыгыга катнашасы, шул бәхетлеләр арасында буласы килә.

Мәрьям якындагы гастрономга йөгерде. Кесәсендәге бар акчасын кырып-себереп, бер тартма торт, бер шешә шампан шәрабы алды. Бу аның да олы бәйрәме – тормышка ашкан беренче проекты, беренче җиңүе ләбаса!

Кире килде, бераз икеләнеп торганнан соң 55 нче квартирага керергә булды. Вилданның ишегенә 55 саны беркетелгәнгәдер, бәлки.

Эчтән тавыш-тын ишетелми иде, әмма, шакыгач, озак көттермәделәр. Ишекне таза гәүдәле, киң җилкәле, ак чырайлы, егерме биш тирәләрендәге кеше ачты.

– Рәхим итегез! – диде ул, ачык елмаеп.

Ят кешене күреп гаҗәпләнмәде, күрәсең, бүген аларга газны, суны, электрны тикшерергә керүчеләр булгандыр.

– Котлыйм сезне! – диде Мәрьям, күчтәнәчләрен сузып.

Егет аптырап калды. Аннары тәвәккәлләп күчтәнәчләрне алды да, тавышын күтәреп:

– Зөлфия! Кунак килде! – дип кычкырды. Кухня ишеге ачылып, ак мамык шәлгә уралган яшь хатын килеп чыкты. Мәрьямне танымавына кыенсынды булса кирәк, кара кашлары дугаланып күтәрелде, каратутлы йөзе алланды.

Квартира нәкъ Вилданныкы шикелле, бер бүлмәле, озынча, кухня ишеге бүлмәгә чыга. Җиһаз-мазар юк, бары бер почмакта матрас, юрган һәм ак тышлы мендәр ята. Алай да кухняда өстәл бар икән, аның янына ике чемоданны яны белән бастырып куйганнар.

– Исәнмесез! Борчыганым өчен гафу итегез, – диде Мәрьям. – Бу йортның проектын төзедем, архитектор мин.

Хуҗалар елмаештылар:

– Менә күрдеңме, Зөлфия, шулай була ул, – диде егет. Аннары Мәрьямгә борылды: – Ул әйтә, әйдә, ди, бүген күчкәнне берәүгә дә әйтмик, ди. Кеше килсә, тегесе-монысы кирәк, әзерлисе-җыясы була... Өй туен бәби туе белән бергә үткәрербез дигән идек.

Зөлфия оялып башын иде, ни сөйлисең инде дигәндәй, куе керфек астыннан иренә үпкәле караш ташлады.

– Әйдә утырыгыз, – диде ир кеше, бер чемоданга ымлап. – Мине Рифкать диярсез. Сездән мондый зур күчтәнәчләр алу яхшы да түгелдер, әмма кире кагып булмый, китап кушмый. Әле үзебез дә нидер җитмәгәндәй аптырашып утыра идек. Шулай бит, Зөлфия? Мин дә, аңа ярамый дип, аны-моны алмаган идем. Ымсынып куяр да, мин әйтәм, зыяны тияр. Нечкә нәрсә бит ул хатын-кыз.

Рифкать җор һәм сүзчән, Зөлфия исә тыйнак, оялчан икән, сүзгә катнашмыйча башын иеп утыра. Бөтен кыяфәтеннән эчке куаныч, җан тынычлыгы бөркелә.

– Ярый әле Зөлфия сумкасына чәйнек белән ике стакан тыгып килде, – диде Рифкать.

Ул шампанский шешәсен шартлатып ачты да шәраб күбеге белән өстәл турындагы стенаны чылатып алды. Аннары стаканнарга салды.

– Башта сез котлагыз өйне, аннары мин җитешермен. Син, Зөлфия, стаканы белән каплый күрмә тагын, миңа да калдыр.

– Күбек кенә ич ул!

– Ничу, ничу! Киләсе ел шушы вакытта шешәсе белән каплап куйсаң да сүзем булмас.

Бер йотып кабып куйгандай иткәч, хатынның теле ачылып киткәндәй булды.

– Үз куышыбыз булганга күңелем һаман ышанып бетми әле. Торып-торып, төш түгел микән бу, уянмасам ярар иде, дип куям. Бала белән кеше өстендә торырга туры килсә, нишләрбез, дип курыккан идек. Бүген Рифкать ачкыч алып кайткач та, әйдә тизрәк кереп утырыйк, дидем. Такси белән килдек. Әйберләрне иртәгә алып килсәк тә ярар. Искиткеч бит! Ваннасы, кухнясы, кайнар суына чаклы торба белән киләчәк.

– Планировкасы бик үк уңайлы түгел инде, – диде Мәрьям, гафу үтенгәндәй. – Безгә анысын үзгәртергә кушмыйлар.

– Болай да бик әйбәт! – Зөлфия кулы белән нәфис хәрәкәт ясады. – Бу төшкә чаршау элсәк, монда Рифкать идәннән түшәмгәчә шкаф ясап куяр, бик оста ул андый эшкә...

– Мебелегез бармы соң?

– Юк әле. Хозяйка караватында йоклый идек... Хәзергә идән ярап тора, – дип сүзгә кушылды Рифкать. – Егылып төшмәскә ару булыр. Мондый чакта бигрәк тә...

Газны ялгамаганнар икән әле, чәйнекне электр плитәсенә куйдылар. Стаканнардан пешә-пешә баллы су эчтеләр – яшьләр шикәр алып килгәннәр, тик чәйне онытканнар иде.

– Безнең йорт үзенә бер матур, – диде Зөлфия. – Балконнары иркен, уңайлы... Сезнең профессиягез бик яхшы, иҗади хезмәт. Аннары беркатлы итеп өстәп куйды: – Сез, би-ик, би-ик бәхетледер?

– Әлбәттә! – диде Мәрьям, елмаеп.

Урамга да үзалдына елмаеп чыкты ул. Тышта кыш шәһәр урамнарын бизәп куйган. Мәрьям бу хозурлыкны моңарчы ничек күрмәгән соң? Аяк астындагы кар асылташлар сибелгән ак келәмгә охшаган. Агачларны сыкы сарган, кардан ясалганнар диярсең, ә өстән, багана башларындагы утлар яктысында җемелдәп, бәс коела. Башны күтәреп күккә карасаң, сирәк йолдызларны күрәсең, җиргә аларның кыйпылчыклары сибелә кебек. Ничек шулай кинәт үзгәрде соң әле бу дөнья?

Кайчак кешеләр дә шулай кинәт үзгәрә бит: карап торышка гап-гади бәндә кебек, ә берчакны йөзе балкып, күзләре шундый нурланып китә, аның тирән хисле, нечкә күңелле, зирәк акыллы шәхес икәнен күрәсең, борыны почык, авызы зур булуына игътибар да итмисең.

Кечкенә шәһәр дә шулай. Аның җитешсез якларын төн пәрдәсе каплый. Ә утлар яктысында тынгысыз тормыш, якты өметләр, уйланулар, сөенечләр күзгә ташлана.

Мондый кичләрдә күңелне гаҗәп бер талпыну биләп ала, үзеңдә таулар кичәрдәй көч сизәсең. Яшисе килә! Ялгызың гына түгел, җанга якын берәү белән акка төренгән урамнарны гизәсе, җырлыйсы, биисе килә!

Әмма Мәрьям ялгыз иде шул. Ул Зөлфияне күз алдына китерде, аның бәхетенә кызыкты. Күңелен ямансу хис биләп алды, башы иелде.

Соңгы көннәрне Вилданның да күзгә күренмәгәнен исенә төшерде. Үзара мөнәсәбәтләр гади, дустанә булса да, ике-өч ай эчендә ул аңа шактый күнеккән иде. Дөрес, аларның танышлыгы шугалакка, кино, театрга бергә йөрүдән узмады. Үзара мөнәсәбәтләр турында авыз ачып бер сүз сөйләшкәннәре юк. Була бит шундый танышлар, аралашу рәхәт үзе, әмма очратмасаң әллә ни юксынмыйсың.

Ә менә бу кичне Мәрьямнең уйлары Вилданга барып тоташты. Бер очрашканда егет аңа эш телефонын биргән иде, шул искә төште... Менә ул кәгазь, сумка төбендә аунап, таушалып беткән.

Иртәгесен Вилданның эшенә – зур заводның конструкторлар бюросына шалтыратты. Аннан: «Инженер Закиров бюллетеньдә», – дигән җавап алды.

Кичен Мәрьям Вилданның хәлен белергә китте. Ул егетне урын өстендә ярдәмсез ята торгандыр дип күз алдына китергән һәм чәй кайнатып эчерүчесе дә юктыр дип кызганган иде.

Әмма Вилдан бер дә алай хәлсез кешегә охшамаган иде, ачык елмаеп каршы алды. Сырхаулаганын фәкать муенына ураган җылы шарф кына белгертә иде. Исәнлек-саулык сорашкач:

– Син кунак бул, утырып кына тор, – дип, кухняга юнәлгән иде, Мәрьям аңа иярде.

Буйдак хуҗалыгында хатын-кыз кулы юклыгы сизелә: чынаяклар чәйдән саргайган, мельхиор калаклар күгәргән, тәрәзә төбендә каткан ипи сыныклары ята. Ярый әле Мәрьям күчтәнәчкә конфет алып килгән иде, егетнең шикәре беткән икән.

Табынга куярга сые мул булмаса да, мәе табылды тагын.

Егет:

– Мин чирле кеше бит, дәваланырга туры килә, син дә грипп йоктырма, чарасын күреп, алдан дезинфекция ясыйк, – дигән булып өстәлгә моңарчы Мәрьям күрмәгән шешә китереп куйды. Кәгазенә «Салхино» дип язылган иде. – Мәскәүдән бик якын танышым алып кайтты, – диде Вилдан. – Синең исәнлеккә, – дип, чынаягын күтәрде аннары.

Рюмка дигән нәрсә аңарда юк икән.

Тәмле шәраб җиңел эчелсә дә, буыннарга нык суга торган булып чыкты... Чәйдән соң диванга янәшә утырып, Вилданның фоторәсемнәрен карадылар. Ул аларны альбомга тезмәгән, пакетларда гына тота икән. Вилдан үзенең төрле шәһәрләрдә командировкага йөргәннәре турында бик кызык итеп сөйләде.

– Диңгездә кыслаларны ничек тотканнарын беләсеңме?

– Ничек?

– Менә шушындый, – дип, кулларын ярты метрлап җәеп күрсәтте ул, – бау аласың да яр буена утырасың. Су астында, ярдагы тишекләрдә менә мондый-мондый кыслалар оя коралар. – Вилдан йодрыгын күрсәтте. – Бауны шундый оя турына төшерәсең. Кысланың ачуы килә бу селкенеп торган бауга. Кыскычлары белән – цап! Нәкъ шул минутта бауны җәһәт кенә тартсаң, кысла шап итеп ярга килеп төшә.

– Бәй, ник соң ул бауны ычкындырмый? – ди Мәрьям, гаҗәпләнеп.

Вилдан андый кызыкларны бик күп белә икән. «Күбесен маҗара китапларыннан укып беләдер инде», – дип уйлады Мәрьям.

Алар янында яшел абажурлы торшер яна. Бүлмә почмакларында серле күләгәләр яшеренгән. Җылы, рәхәт. Мәрьям үз иңбашына Вилдан иңбашының тиеп-тиеп киткәнен тоя.

Вакытның соң икәнен белсә дә, Мәрьям Вилданның сүзен бүләргә җай тапмый утырды. Бу рәхәттән салкын урамга чыгасыңны уйлауга тән сискәнеп китә иде. Урам якка борылуга, битенә усал җил бәрер. Бу сәгатьтә троллейбуслар да сирәк йөри. Тукталышта озак көтәргә туры килер. Туңып бетәрсең. Авыру кешегә озат мине дип әйтеп булмый бит инде. Троллейбус буш булыр. Башына иске шәл ураган кондуктор, аягын электр миченә куеп, бөрешеп утырыр һәм йокымсырап китәр. Андый чакта троллейбус бик әкрен баргандай тоела. Ниһаять, Кольцога җиткәч, Мәрьям троллейбустан төшәр дә, үз күләгәсен үзе куып, үргә каршы йөгерер. Дуся түтәй, аңа ишекне ачкач: «Әле генә ятып, җылынып йокыга киткән идем», – дип сукраныр. Шулай итеп, чолан кебек шыксыз бүлмәсенә кайтып керер Мәрьям.

Биш минуттан чыгам, тагын ун минут кына утырыйм, ди торгач, сәгать бер җитте. Сиңа кирәкмәгәндә сәгать телләре бик җәһәт әйләнә бит ул!

Мәрьям, ниһаять, урыныннан кузгалды.

– Миңа китәргә вакыт. Болай да соңга калып беттем.

Вилдан аңа тутырып карады. Аның ялгыз каласы килмәгәне күренеп тора иде.

Мәрьям, кечкенә, кысан коридорга чыгып, чөйгә үрелгән иде, Вилдан аның пальтосын үзе алды, әмма кидермәде, кире элеп куйды да иңнәреннән кочты, кыенсынып, кызарынып кызның күзләренә карады һәм әкрен генә:

– Бәлки... калырсың? – диде. – Бу салкында кая барасың? Троллейбуслар да сирәк йөри хәзер. Аннары... кем көтә анда сине? Хозяйкаң да ачуланыр. Чирле кешене ялгыз ташлап китү дә яхшы түгел...

Мәрьям җиңел генә уйлап куйды: «Әллә калыргамы? Чыннан да, кем көтә мине, кемгә кирәгем бар?» Ләкин шундук бу уе өчен үзе үк оялды: тормышында мондый җитди адымны ясарга ул әле акылы белән әзер түгел, Вилданга булган хисләре аек акылын җиңәр дәрәҗәдә көчле түгел иде. Ул сак кына хәрәкәт белән Вилданның кулларын иңнәреннән алды һәм, нык итеп:

– Юк, мин өйгә кайтам! – диде.

Шул көннән соң егетнең аңа мөнәсәбәте үзгәрде. Еш килә торган булды, җитди карарга килгәнлеген баштарак киная белән сиздерә иде, аннары гаилә корырга күптән вакыт җиткәнлеге турында сүз кузгатты.

– Безгә бергә яшәү яхшырак булмасмы?

– Ашыкмыйк, бераз уйлыйк әле, – диебрәк җавап бирә килде Мәрьям. Шулай итеп, ризалык бирергә ашыкмаса да, тәкъдимнән катгый рәвештә баш тартмады. Чөнки ул тагын кайчан да булса гашыйк булырга өмет итми, ә Шәүкәтне онытырга, онытырга, онытырга кирәк иде.

Кичләрнең берендә, кинодан чыгып, тауга күтәрелгәч, Дуся түтәй йортының капкасы төбендә Вилдан аның иңнәреннән кысып тотып, үзенә борды:

– Кайчан загска барабыз?

Җавап булмагач, катгый итеп:

– Ни көтәбез инде тагын? – диде. – Миннән башка кешең бармы әллә?

– Юк... – дип кызарынып башын аска иде Мәрьям.

Икенче көнне загска гариза бирделәр, ә Мәрьямнең күңелендә мәсьәлә һаман хәл ителмәгән кебек иде. «Тукта, ун көн котәсе бар бит әле, кире уйларга соң түгел», – дип, үз-үзен юатып килде ул. Ләкин бер адым ясагач, ярты юлда тукталып калып булмады. Көне-сәгате килеп җиткәч, загска бармый калу һич мөмкин түгел кебек тоелды: ак күлмәк тегелгән, кияүгә кара костюм алынган, таныш-белешләр чәчәк күтәреп килгән, туй табыны әзерләнгән, ишек төбенә машина килеп туктаган булып чыкты.

Вилдан тар агач баскычтан Дуся түтәй квартирасына йөгереп менде дә, Мәрьям ак күлмәген кигәнче, өйалдында көтеп торды, аннары, кәләшен бәла-казадан сакларга теләгәндәй иңнәреннән кочып, зәңгәр «Волга»га чыгарып утыртты. Бер сәгатьтән алар законлы ир белән хатын иделәр инде.

Институтта бу вакыйга күпләрне гаҗәпләндерде: Шәүкәттән соң Мәрьямнең башка берәү белән дуслашканын белми дә калганнар икән. Яшьләрнең язылышасын бер генә көн алдан белгән Саҗидә апа:

– Дөрес эшләмисез, – диде.

– Ә нишләргә соң, Саҗидә апа? Үзегез дә бит...

Мәрьям аның икенче тапкыр кияүгә чыкканын исенә төшермәкче иде, әмма апа бөтенләй башканы күз алдында тота икән.

– Туй – бәйрәм дигән сүз бит ул. Аны матур итеп үткәрергә кирәк. Сез кемнән ким?

– Зурдан купмаска дип килешкән идек.

– Сез купмасагыз, без кубарбыз. Кулдан килгәнчә.

Загстан чыккач, кияү белән кәләшне машинага утыртып, шәһәрне әйләнеп килергә җибәрделәр. Алар кайтуга мастерскойда табын әзерләнгән иде. Саҗидә апа «Наполеон» торты пешереп китергән. Ирина Сергеевна местком исеменнән хрусталь графин белән рюмкалар бүләк итте. Калган кунаклар биш данә будильник алып килгәннәр иде. Яз башы гына булуга карамастан, озын аяклы Морат каяндыр сирень чәчәкләре эзләп тапкан. Целлофанга төрелгән күгелҗем тәлгәшләр бик зәгыйфь булып, алардан сизелер-сизелмәс җир исе аңкый иде.

Мәрьямнең бит алмалары уттай янды, үзе шырык-шырык көлде дә көлде. Кайчандыр, болай гасабиланган чагында, Шәүкәт аңа:

– Хәерлегә түгел синең бу көлүең, – дигән иде.

Кунаклар аны сөенечтән көлә дип уйладылар, күрәсең. Вилдан да моның чын сәбәбен аңламады шикелле.

Көн аяз, табын күрекле, хезмәттәшләр ачык йөзле иде, әмма нилектәндер тик Мәрьямнең башын сарган томан таралмады.

Ул көнге вакыйгалар куе томанлы араны ерып баргандай хәтердә калган. Машинада шәһәр урамнары буйлап йөргәндә, һичкайчан булмаганча, күңеле болганды аның. Табында авызы ризык тәмен сизмәде. Табындашлар: «Ачы! Ачы!» – дип кычкырганда, аягүрә басып Вилдан белән үбешү бик тә оят булып тоелды, тик карышып булмый, түзәргә кирәк иде. Гомер иткәндә юлларның шундыйларын узарга туры килә икән: бер адым атлагач, барырга да барырга туры килә, борылып булмый.

Вилданның квартирасына кайтканда да ул томан эчендәге кебек иде. Бик озак кара-каршы чәй табыны янында утырдылар, Мария Калласның да, Эдита Пьеханың да җырлаганын тыңладылар. Кич җиткәнне көттеләр.

Караңгылык Мәрьямнең зиһенен сарган томанны отыры куертып җибәргәндәй итте. Ул эченнән үз-үзенә ике генә сүзне тәкрарлады: «Карышмаска... Буйсынырга... Карышмаска...»

Вилдан да нык каушаган иде, яшел абажурлы торшер яктысында йөзе каралып киткән кебек тоелды, күзләре очкынланып янды. Ул әкрен генә ак күлмәген, майкасын салды, аннары диванда утырган кәләшенә таба ике адым атлады. Иелеп кулларыннан тотты һәм кайнар, йомшак иреннәрен аның бармакларына тидерде. Авырттырудан курыккандай, сак хәрәкәт белән аны терсәкләреннән тотып торгызды... Диванны җәеп җибәрде. Шакылдаган тавыштан Мәрьям сискәнеп калтыранып куйды.

Вилдан аны кочып алды һәм туй күлмәгенең аркасы буйлап сузылган чылбырның элмәген аска таба шудырып, бушап калган җиңнәрен кулбашлардан түбән сыдырды. Ә Мәрьямнең башында бер генә уй: «Буйсынырга... Һәммәсен аның ихтыярына куярга...»

Ир-хатын мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен ул бик аз белә, бу хакта кем белән булса да ачылып сөйләшкәне дә, китаптан укыганы да юк иде. Борынгыча әйткәндә, сазаган кыз яшендә иде ул, әмма күңеле белән үсмерлектән узмаган иде. Андыйлар ирне назлый да белми, аңа ярый да алмый. Әлбәттә инде, өзелеп сөйгән ярың кочагына керсәң, тән акылдан сорап тормас, табигать кушканны кылыр иде. Мәхәббәт бар җирдә оят юк, диләр... Сөйгәне кочагында эрегән тән акылдан сорап тормый, үзенә кирәкне эшли ул. Ә Мәрьям оялды, тартынды, читләшергә теләде. Аек акылы белән, ихтыярын җигеп, үзен буйсынырга мәҗбүр итте ул. Хәзер искә төшкәндә кияүнең хәленә кереп карарга тырыша, аның кочагында чүпрәк курчак булдым бугай, дип, үзен гаепләп тә куя.

Ул кичтә кичергән тойгылар ләззәттән бигрәк тән авыртуына кушылган җан сыкрануы булып хәтергә сеңеп калган.

Китапларда зөфаф киченең ләззәте турында бик тәфсилләп язалар. Әмма, хатыннарны тыңлаганда, бөтенләй башканы ишетәсең. Шактыйларының күңелендә кияүләренә рәнҗеш саклана: гыйффәтле кыз баланың кичерешләрен аңламаган, тупас кыланган, түземсезләнеп, үз рәхәтен күрергә ашкынган... Бергә гомер кичергән ирләре турында кайбер хатыннардан мондыйны ишеткәч, Мәрьям Вилданның башкалардан аермалы буларак нәзакәтле, сак кыланганын аңлады. Ул кәләшенең саф кыз булганына сөенгән иде. Соңыннан ireннәреннән суырып үпте дә:

– Бөтен рәхәтлекләр безне алда көтә, – диде. Һәм хатынының иңбашына борынын терәп, тынып калды, озакламый тигез сулап, йокыга талды.

Ә Мәрьям йокылы-уяулы хәлендә чалкан ятуында булды. «Башкалар бергә яши-яши ияләшкән, ярашкан бит әле, мин дә ияләшермен, – дип юатты ул үзен. – Ияләшермен».

Ул кыска гына вакытка әллә йоклаган, әллә онытылган иде, сискәнеп айнып китте дә, күңеле нилектән шомланганны аңларга тырышып, күзләрен зур ачкан хәлдә шактый вакыт хәрәкәтсез ятты. Аның янында, ак тышлы юрган астыннан борынын чыгарып, Вилдан изрәп йоклый иде... Мәрьям үзенең хәзерге хәле турында уйларга курыкты, нинди булса тавыш ишетергә теләп сагайды, ләкин колаклары чыңлаудан башка бернинди аваз ишетмәде.

Көн яктырып килә иде, күрәсең, тәрәзә пәрдәләре аша йомшак яктылык саркый. Бүлмә күңелсез һәм ят тоелды. Ләкин иң гаҗәбе – бернинди тавыш ишетелми иде, әйтерсең лә бөтен нәрсә хәрәкәттән туктаган.

Мәрьям, Вилданны уятмаска тырышып, сак кына урыныннан кузгалды һәм, пәрдәләрне ачып, тышка карады. Соры, күңелсез иртә икән, урамнан бер ир кешенең ашыгып узганы күренде, ул мамыкка баскандай шыпырт атлый иде.

Мәрьям тәрәзәгә җентекләп карады һәм... өч кат пыяла күрде. Әйе, әйе, биредә тәрәзәләр гадәттәгечә ике генә катлы түгел, өч катлы иде...

Диван пружиналары шыгырдап куйды. Вилданның бераз карлыккан, ягымлы тавышы:

– Нишлисең син анда? – дип сорады. – Тәрәзә янында торма, салкын тидерерсең.

– Тидерер инде өч кат пыяла белән... Йортның бар тәрәзәләрендә дә шулаймы ул?

– Булыр инде. Үзем куйдырдым мин аны. Югыйсә бик әшәке тавыш бит. ТЭЦ бер уфылдап куйса, котыңны ала. Ә болай ныгыткач, тыныч... Йә, торма анда, кил бире, нәрсәгә сиңа дөнья шау-шуы?

Мәрьям борылды да аңа сәерсенеп, ятсынып карады. «Минме бу? Ә бу минем иремме? Минем гомер юлдашыммы?»

## Икенче бүлек

### *Апрель*

Шуннан соң гомер ничек узды? Мактанырлык, горурланырлык яисә үкенерлек, йөзе кызарырлык нинди гамәлләр кылды Мәрьям?

Хәзер менә, төн караңгылыгына күзне төбәп, үзеңә-үзең сөйләгәндә, узган биш ел эчендә андый хәлләр булмаганын күрәсең. Әйе, булмаган, чөнки ул бер дә искитәрлек эш кырмаган. Кызганычка каршы, күп очракларда гаиләдә тыныч тормыш – кызыксыз тормыш икән ул.

Хәер, ул елларны әллә ни эш кырмавына Мәрьямнең акланырлык сәбәбе бар: ул әни булды, Фәйрүзәсен үстерде. Эшен ташламады, әмма вазифасы-шөгыле гел бертөрле, кызыксыз булды: типовой биналарга нигез проекты сызу. Җаена төшенсәң, тыныч, гаугасыз, җиңел эш.

Әллә ялгыш саныймы, әллә соң яшәлмәгәнме узган айлар-еллар? Биш ел гомер, кесәдән төшеп калган акча кебек, юкка чыккан. Алар истәлеге булып бары тик дүрт яшьлек Фәйрүзә генә калган.

...Җанны тетрәндергән вакыйгалар узган яз башында, апрель аенда булды...

«Чулпан» кинотеатрына Мәрьям проекты буенча реконструкция ясала иде. Проект бер хәл, төзүчеләрнең эшне җиренә җиткереп башкаруы бик мөһим бит әле. Мәрьям шактыйдан инде кинотеатрга барып килергә җыена, вакыт таба алмый иде: иртән эшкә ашыгыла, «Чулпан» троллейбус тукталышыннан ерак, төшеп йөрисе килми, кичен Фәйрүзә янына омтыласың. Ә эш сине көтми, төзүчеләрнең проектлар белән бик исәпләшми торган гадәте бар. Кереп карамый һич ярамый иде.

Мәрьям, эштән бераз иртәрәк китеп, «Чулпан»га кереп чыгарга булды.

Көн болытлы, күңелсез. Өстән, яңгыр дисәң яңгыр түгел, кар дисәң кар түгел, салкын дым ява. Мәрьямнең юка күксел пальтосы каралып киткәндәй булды, әллә ни салкын булмаса да, күшектерде.

Бинаның вестибюленә барып кергәч, Мәрьям пальтосын каккалап караган иде дә, кулы гына чыланды. Эчтә төзелештә була торган тәртипсезлек хөкем сөрә иде – стеналар сыланмаган, идән җимерек хәлдә. Борынны ярып, юеш акбур исе, буяу исе аңкый.

Эчтән, тамаша залыннан кычкырган һәм шакылдаган тавышлар ишетелде. Мәрьям ярым караңгы фойе аша шунда узды.

Тамаша залы куе зәңгәр түшәмдәге сөт төсле плафоннарга тезелгән сирәк лампочкалар белән яктыртылган. Мәрьям килеп кергәндә, ике ир кеше стеналарга чаршау элеп маташалар иде. Берсе биек баскычка баскан да чаршауларны түшәм астына беркетә, икенчесе чүпрәкне астан тартып, рәтләштереп йөри. Чаршаулар ямьсез сары төстә, ә түшәмне куе зәңгәргә буяганнар. Моны күргәч, Мәрьям, исәнмесез диясен дә онытып:

– Нишлисез сез? – дип кычкырды.

Аста торучы, яңа гына мыек чыга башлаган егет, бит урталарын чокырайтып, елмаеп карады:

– Ничек, нишлибез? Күрмисезмени, ремонт ясыйбыз лабаса!

– Реконструкция проект буенча эшләнергә тиештер бит. Түшәмне күксел төскә, стеналарны алсуга буярга кирәк иде. Ә сез горчица төсле чүпрәк эләсез.

– Безгә проект ни дә, ни ни. Начальство ни кушса, шул закон. Директор белән сөйләшегез.

Әңгәмәне баскычның югары аратасына утырып тыңлаган җирән чәчле егет, авызындагы кадакларын чыгарып, иптәшенә дәште:

– Ташла әле, Юра, шул телгә салынуыңны. Әйдә, тизрәк бетерик тә кайтып китик.

– Юк, – диде кычкырып Мәрьям. – Хәзер үк төшегез аннан! Мин рөхсәт бирмим!

– Кем әле сез ул хәтле? – диде җирән чәч, аның катгый тавышыннан шикләнә төшеп.

– Архитектор мин.

– Подумаешь! Каян килгән командир! Бар әнә, директорга кычкыр! Ә безне тоткарлама. Без сдельно эшлибез.

Аның чүкече шакылдый башлагач, Мәрьям чаршауның бер иңен шытырдатып тартып төшерде. Җирән чәч әздән генә егылмый калды. Залга тәбәнәк буйлы, юан гәүдәле хатын йөгереп керде.

– Ни булды?

– Теләсә кем керә дә эшне тоткарлый, – диде җирән чәч. – Ишекне бикләп куярга кирәк.

Хатын Мәрьямгә таба борылды.

– Сез кем?

– Ә сез кем?

– Кинотеатрның директоры мин.

– Ә мин архитектор. Проект буенча стеналар алсу плиткалардан торырга тиеш. Ә сез сары чүпрәк асасыз.

– Аның ни аермасы бар? Материаллар әллә кайчан алынган, хәзер аларны чыгарып ташлап булмый лабаса.

– Бу – зәвыксызлык! Үзегез проектны яхшы дип кабул иттегез...

– Сеңлем, нишләп йөрисез сез монда, ә? Без заказ бирдек – сез үтәдегез, акчасын алдыгыз. Шуның белән аралар өзелде! Барыгыз, юлыгызда булыгыз. Эшем бик тыгыз чак. Зинһар, башымны катырмагыз.

– Юк, чыгып китмим. Сез барысын да проектта күрсәтелгәнчә эшләтергә тиеш!

Директор Мәрьям белән сүз көрәштереп тормады, кулыннан тотты да ишектән чыгарып җибәрде. Мәрьямнең төрле оешмаларга баруы белән өркетергә маташуына:

– Әйдә бар-бар, синең хулиганлыгың турында мин дә язып җибәрермен! – дип мыскыллап калды.

«Тырыш менә, эшлә, җелегеңне суыр» дип уйлады Мәрьям. Матурлыкның нәрсә икәнен белмәгән, интерьер турында хәбәре дә булмаган хатын тота да кинотеатр залын теләсә нинди чүпрәккә төреп куя! Ә ул залда көненә меңнәрчә кеше булачак.

Мәрьям, гарьлегеннән, ачуыннан кая барып сугылырга белмичә, урам уртасында туктап калды. Тизрәк Газизне табарга кирәк. Ул чарасын күрсен, бу вәхшилекне туктатсын!

Әмма эш сәгате беткән, Фәйрүзәне бакчадан алырга вакыт җиткән иде инде. Ул, биек үкчәле кызыл туфлиләре белән күлдәвекләрнең уртасына баса-баса, троллейбус тукталышына йөгерде. Тукталышта – халык. Шыгрым тулы троллейбус, тәгәрмәчләреннән пычрак су чәчрәтеп, кызулыгын киметмичә узып китте. Яшь-җилкенчәк, арырак тукталмасмы дип, ярты квартал буенча аның артыннан чапты.

Гел шулай: көн начарландымы, троллейбуска утыру кыенлаша. Бераздан юеш туфли аякны туңдыра башлады, дымланып авырайган пальто иңбашларны аска тартты. Мәрьям тәмам аптыраган иде инде, янына автобус килеп туктады да алгы ишеген ачты. Бала-чагалы хатыннар, әбиләр кереп беткәч, Мәрьям дә ишек баскычына басты һәм кысылып калды. Автобус кузгалды, кемнеңдер көчле кулы аны беләгеннән тотып өскә тартып менгерде.

– Каты кыстымы? – дип сорады таныш тавыш. Каршында терәлеп, Шәүкәт басып тора иде.

– Аягыма әллә нинди тимере бәрде шунда...

– Бик авырттырдымы? – Ул үз аягы авырткандай кашларын җыерды.

– Авырттырды шул, – диде Мәрьям зарланулы тавыш белән.

Ниндидер усал карчык очлы терсәге белән Мәрьямнең аркасына китереп төртте:

– Киләсесендә чыгасызмы? Соң нишләп юл өстендә торасыз? Ну бу яшьләрне!

– Бирерәк кил! – диде Шәүкәт, үзалдыннан, тимер касса янышнан урын биреп.

Аларны шунда ук төрле яктан этә-төртә башладылар һәм бер-берсенә тәмам беркетеп куйдылар. Мәрьям сумка тоткан уң кул аркасы белән Шәүкәтнең сул кулына орынып китте. Кулның кайнарлыгы аның бөтен тәнен көйдереп алгандай итте.

– Исәнме, хәлең ничек, с приездом, диген...

Бу сүзләрне Шәүкәт шаяргандай итеп әйтте әйтүен, әмма тавышы калтырабрак чыкты. Мәрьям аныңча булып шаяруга кушылырга тырышты:

– С приездом! Кәефең ничек? Ни кырып йөрисең?

Карашлары кисешкән иде, Мәрьям керфекләрен төшерде. Чөнки күзе күргәнне аңлаудан курыкты. Аның яшькелт күзләре үзгәрмәгән, аларда элеккечә якын итү дә, соклану да бар, шуларга өстәп ялвару да чагылып узды шикелле. Аерым узган еллар бик күп нәрсәләрне үзгәрткән, әмма күңелләрдәге якынлыкны бетерә алмаган. Халык белән төеп тутырылган автобуста алар үзләрен икәүдән-икәү калгандай тойдылар. Мәрьям иңбашы белән егетнең күкрәгенә терәлгән, сулышлар кушыла, кыйммәтле тәмәке исе башны әйләндерә.

Дөрес, болар күңелдән кичерелде, сүзләрнең исә мондый очракта тиешлеләре әйтелде.

Шәүкәт Рәссамнар союзына килгән икән. Ул үзләрендәге художество мәктәбендә укыта икән, көзгә Мәскәүдәге сәнгать институтына укырга керергә теләге бар. Моның өчен Казандагы укытучыларына яңа картинасын күрсәтеп, аларның фикерен ишетәсе, киңәшләрен тыңлыйсы килә икән. Мәскәүгә аларның фатихасын, рекомендациясен алып бару хәерле.

Берничә җөмлә белән шуларны сөйләп бирде Шәүкәт. Мәрьямнең проектлар төзегәнен белгәч, ничектер кыюсыз гына:

– Мөмкин булса, сызымнарын гына булса да карар идем, – дип куйды. – Макетлары да бардыр бит?

Әгәр Мәрьям аны институтка чакырса, бу читләтеп булса да, аның үпкә сакламавын аңлатачак иде. Шәүкәт өчен, аның үз-үзен ихтирам итүе өчен Мәрьямнең аңа мөнәсәбәте бик тә мөһим иде, күрәсең.

Мәрьямнең рәнҗү-үпкәләре онытылып бетмәсә дә, кичерәйгән, кимегән иде инде. Ул йөзен бозмады, икеләнеп тормады, җиңел генә:

– Безнең институтка керсәң, күреп чыгарсың, – дип куйды. Бу әле чакыру да, гафу итү дә түгел, шулай да Шәүкәтнең йөзендәге киеренкелек югалды. Ул иркенәеп елмайды.

Мәрьямнең тукталышы алдарак иде.

– Сау бул! Мин кайтып җиттем...

Автобус кузгалып киткәндә, тәрәзәдә Шәүкәтнең елмайган йөзе чалынып узды. Кулын чигәсе турына күтәргән: «Сау бул!» Гел үзгәрмәгән, элек тә шулай елмаеп, кулын шулай күтәрә торган иде.

Ә автобус әллә нишләп алсу төскә буялган. Алсу автобус буламыни? Ни булган бу дөньяга? Биш катлы типовой йортлар алсу, урам асфальты алсу! Мәрьям, гаҗәпләнеп, як-ягына каранды. Ә-ә, көнбатышта соры болыт пәрдәсен кояш нурлары тишеп чыккан икән.

Күп үтмәде, болыттагы тишек ямалды, дөнья янә соры төскә керде. Шулай да Шәүкәтнең елмаюы да, очлы нурларның төсе дә зур бер шатлык булып күңелгә кереп калды.

Өенә ул елмаеп кайтып керде. Башка көннәрне, кухня белән ванна бүлмәсе арасында йөргәндә, телевизор каршында йә приемник янында утырган Вилданның кыяфәте аның ачуын китерә: «Ник мин генә болай бөтереләм әле, ник ул кыл да кыймылдатмый, мин дә эштән кайттым лабаса», – дигән гаделсезлек рәнҗетә иде. Бүген ул иренә күз генә салып алды. Кызына май ягып ипи сыныгы тоттырды да, бәрәңге пешкәнче, ялт итеп идәннәрне юып чыгарды. Табын янында, авызына ни капканын сизмичә, калын китапка кадалып утырган иренә кызганып карады, дәшмәде. Ул, бичара, Сименонның яңа әсәрен каяндыр тапкан, укып бетермичә йокларга ятмас, ахры.

Менә, ниһаять, бала кечкенә караватында ята. «Фәйрүзәкәйнең тәмле әйбер ашыйсы килгән. Шулай бит?» Кызчык «шулай» дип башын селки. «Ә татлыдан татлы, тәмледән тәмле нәрсә ул?» Фәйрүзә, әтисенекенә охшаган шоколад төсле күзләрен зур ачып, кашларын маңгаена күтәрә. «Йокы ул, бәбием. Менә йоклап кара әле, ай-яй татлы йокы».

Вилдан, салкын чәенә шикәр салырга да онытып, бер кабуда йотып җибәрде дә, диван-карават янына килеп, чишенергә тотынды. Ә күзе һаман китап битендә. Урын җәю өчен Мәрьям аны читкәрәк этте.

Вилдан чалкан ятып китап укый. Бүлмә ярым караңгы, люстра сүндерелгән, төнге лампадан төшкән яктылык китап битләрен, Вилданның куе кара чәчен яктырта. Мәрьям диван кырыена утырган да, карашын китап катыргысына терәп, үз уйларына чумган.

Вилдан китапның яңа битен ачарга әзерләнде, Мәрьямнең карашы ирексездән лампа яктысына кергән бармакларга төште. Озынча тырнаклы, буын араларына кара төк үскән ак бармакларда көч артык йомшак булып күренде. Төзүченең дә, сугышчының да, башка берәр гайрәт иясенең дә кулы мондый булмас... Мәрьям ирексездән икенче берәүнең, йомарланып, ихтыяр төене булып, чигә турысына күтәрелгән кулын хәтерләде.

Вилдан, күтәрелеп, хатынына карады:

– Ни бар?

Аның әле генә капитан Мэгре белән җинаятьчеләр аулап йөргән миендә борчылу туган иде.

– Ник болай карыйсың миңа?

– Болай гына, – диде Мәрьям, сәбәпсез елмаеп.

– Син миннән гаеп эзләп утырасың ич.

Аннары, нидер исенә төшкәндәй, китабыннан аерылып, башын күтәрде. Абажур күләгәсендә калганга, Мәрьямнең йөзе начар күренә иде.

– Сиңа нидер булган бүген.

– Берни булмады.

– Һи-и, ни булганын әйтәсеңме соң...

Мәрьям ванна бүлмәсенә кереп китте – баланың күлмәкләрен юып эләргә кирәк иде. Вилдан, көрсенеп, китабын алды. Биш минуттан ул бөтен барлыгы белән капитан Мэгре янында иде инде.

### *Чатнау*

Уйла, Мәрьям, уйла, бүген шундый төнең синең. Бернәрсәне дә онытмыйча, барын искә төшереп, һәммәсенә дөрес бәя бир. Бары да үтте, хәзер аек акыл белән фикер йөртеп була...

Апрель аендагы очрашудан соң әле ел да узмады, ә күпме вакыйгалар баштан кичте, күпме үзгәрешләр булды!

Башта сиздермичәрәк, әмма котылгысыз үзгәрде тормыш. Әйе, алар икесе дә эштән кайткач, гадәти сүзләр әйтеп очрашалар иде.

– Ә-ә, син кайткансың икән, – ди Мәрьям. – Ә мин ашарга да өлгертә алмадым әле.

– Арттан куып килгән кеше юк, – ди Вилдан. – Көтәрмен, ашыгыч түгел.

Вилдан өс-башын алыштыра, юына, кызын күтәреп алып иркәли, тезендә биетә. Аннары радиоалгыч янындагы креслога барып утыра. Арыган-талчыккан кыяфәттә, бәлки, эшендә борчулары булгандыр, анысы Мәрьямгә караңгы. Вилдан эше турында сорашканны яратмый. Гаиләне ул беренче чиратта хезмәт мәшәкатьләреннән, дөнья ыгы-зыгысыннан ял итү өчен кирәк дип саный.

Менә ул радио тыңлый.

Дөнья тыныч түгел, дөнья афәт белән тулы. Кайдадыр зилзилә җилләре кубып, океаннарны ярларыннан чыгара, шәһәр-авылларны җимерә. Кайдадыр җир тетри, кайдадыр янар таулар ут чәчә. Көн саен меңнәрчә кешеләр һәлак була.

Хәвефле хәбәрләр йөри эфирда. Алар төрле дулкыннарда, төрле телләрдә киләләр һәм, радиоалгыч аша үтеп, тын йортларны шом белән тутыралар. Вилдан аларны тыңлый да эченнән генә шөкрана итә: «Ярый әле без торган җирләр тыныч, ярый әле без афәтләрдән ерак». Һәм шалт итеп радиоалгычның икенче төймәсенә баса.

Башка дулкыннан да шомлы хәбәрләр килә: кайдадыр канлы сугышлар бара, кайдадыр патшаларны бәреп төшерәләр, һавадан самолетлар мәтәлә, канлы көрәшләрдә ил батырлары җан бирә. Фаҗигаләрне кешеләр үз башларына үзләре ясый. Барысына бер сәбәп: йөгәнсез хисләр, чамасыз теләкләр, дан эстәү. Ни җитми кешегә, нишләп тыныч яши алмый ул?

Вилдан үзе шалт та шолт радиоалгыч төймәләренә баса, уйларының очына чыга алмый.

Ул тыныч яшәргә тели. Эшкә баргач, үзенә тапшырылганның һәммәсен тырышып үтиме ул? Үти. Тормышының калган сәгатьләрен тату гаиләдә тыныч үткәрергә хакы бармы? Өйгә кайткач, иркенләп ял итәргә хокукы бармы? Бар, әлбәттә.

Ләкин аңа – әздән канәгать кешегә дә – тынгы бирми дөнья. Аларның өенә афәт бәреп керде. Дөрес, аермачык күренми әле, әмма сизелә, бик сизелә. Моңа кадәр дә үзен шактый салкын тоткан Мәрьям соңгы вакытта иреннән көннән-көн ерагая бара шикелле.

Йә инде, аңа ни җитми? Тормышлары түгәрәк. Ир кешенең бөтен игътибары гаиләдә. Ә хатын канәгать түгел, әллә ни тели, әллә кая омтыла. Төннәр буе проект төзим дип утыра, юньләп йокы күрми – ябыгып бетте. Өй эшләрен карарга җитешә алмый, чисталык-тәртип яклары йомшарды.

«Мәрьям әллә берәрсе белән бәйләнде микән?» дигән шик тә туды, билгеле, әмма әлегә, Аллага шөкер, аны расларлык дәлилләр юк иде.

Мәрьям иренең борчуларын бөтенләй үк белми түгел, сизә иде. Кичләрен кайчак аның бер ноктага текәлеп, моңаеп калганын күргәндә яисә үзенә төбәлгән сораулы моңсу карашын тойганда, хатын кинәт айнып киткәндәй була һәм, бу кешенең күңел төшенкелегенә мин гаепле бит, дип уйлап куйгалый иде. Ләкин бу уйны башкалары, Мәрьям карашынча, зурраклары, мөһимрәкләре күмеп китә торды.

Төннәрен, Вилдан стенага борылып, тыныч сулап йокыга талгач, Мәрьямнең күзеннән йокы кача иде. Менә шул сәгатьләрдә, караңгылыкта, әйтерсең лә галәм белән, мәңгелек белән кара-каршы берүзе очрашкандай була иде ул. Үткәннәр һәм киләчәк хакында кинәт кенә бик зурдан, моңарчы башына килмәгәнчә уйлана иде. Төн караңгылыгында, тынлыкта, ялгызың бу хакта уйлана башласаң, вакыт агышының котылгысыз кодрәтен, аяусызлыгын тоя башлыйсың икән. Хәтта Җирнең ничек итеп сиздерми генә, шул ук вакытта шомландырырлык дәһшәт белән әйләнгәнен йөрәгең белән сизәсең кебек. Кайсыдыр әйләнештә син якты дөньяга килгәнсең. Бу инде әллә кайчан булгандыр сыман. Ләкин син булганчы да Җир шушылай әйләнеп торган, кешеләр яшәгән, көн төн белән алышынган, шәһәрләр салынган, икмәк пешкән, тимер коелган. Ә соң мин, мин кайда булганмын? Ничек инде мин булмыйча мөмкин булган? Бу һич аңлашылмый, моңа берничек тә баш җитми...

Кайчандыр мин булмаганмын һәм кайчандыр... мин булмаячакмын. Ә Җир һаман шулай әйләнер, тормыш һаман шушылай шаулап барыр. Ничек инде мин булмам? Кая китәр соң минем уйларым, хыялларым, йөрәкнең талпынулары? Алар... юкка чыга аламыни?

Бу уйдан шундый куркыныч булып китә, бәгырьгә ут каба, сулыш кысыла, ишекне каерып ачасы, тәрәзәләрне бәреп ватасы, янында гамьсез мышнап яткан кешене сикертеп торгызып, аңа: «Коткар мине!» – дип ялварасы килә... Ләкин Мәрьям торып утырган җиреннән кымшанмый кала. Аны уятуда ни мәгънә, ул да синең кебек, ул да элек булмаган... Мәңге-мәңге булмаган һәм мәңге-мәңге булмаячак... Мәңгелек каршында без барыбыз да ялгызлар...

Мәрьям кухняга чыгып салкын су эчә, тәрәзә төбенә таянып, озаклап тышка карап тора. Җилдә тибрәнгән агачларга карагач, җанга бераз ял була. Ләкин башка яңа уй килә: гомер заяга уза. Әрәм үтә гомер, буш үтә, кулдан килгән эшне дә башкарып булмый ичмаса. Күпме еллар аккан су кебек үткән дә киткән, ә Мәрьям менә моны булдырдым мин дип әйтерлек бер эш тә кыра алмаган!..

Бу куркыныч уйлардан, бу үкенечләрдән котылу чарасы юк иде шикелле. Ләкин бар икән ул чара, бәхеткә каршы, бар икән.

Институтка унике мең кешелек микрорайонның проектын төзү эшен тапшырдылар. Ул Ташлыярда корылачак иде. Мәрьямне аның өлкән инженеры итеп билгеләделәр, бу, асылда, архитектор хезмәте иде. Анда егерме торак йорт, бер мәктәп, өч балалар бакчасы, спорт мәйданы, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты, кибетләр булырга тиеш иде.

Менә шушы микрорайон Мәрьямне бернинди кодрәт иясе дә коткара алмаслык афәттән – мәңгелек белән ялгызы калып, куркыныч уйлар уйлаудан коткарды. Проект аның бөтен уйларын, хисләрен үзенә тартты.

Аның эше өенә ияреп кайта торган булды. Моның тискәре ягы да булды: эш урынында яхшы гына белгеч булып саналган шәхес гаиләсендә уңмаган, булдыксыз хатынга әйләнеп кала иде. Кухня өстәлендә кәгазь бите аунап ята, бәрәңге әрчегәндә дә, башына уй төшеп, нидер сызгаларга тотына ул. Төннәрен кулына китап ала: күп укырга, өйрәнергә, санарга-исәпләргә кирәк. Иң әһәмиятлесе – яңа фикер, идея. Ансыз юньле проект эшләп булмый. Яңа фикер тусын өчен башны бер юнәлештә уйлатырга, хисләреңне бер ноктага тупларга кирәк. Бүлгәләнсәң – бала карауга, өй эшләренә бирелсәң – таркалу-вакылануыңны күр дә тор.

Буйдак чагында Вилданның йорт эшләрен бер апа башкара торган булган. Өйләнгәч, Вилдан аның белән араны өзде: «Өемә чит кешенең килеп йөрүен яратмый идем, котылдым», – диде. Өч кешелек гаилә өчен квартира бик тар – анда Мәрьямнең сызымнарына урын да юк. Бүлмәдә дә, кухняда да аунап яткан кәгазьләр, хатынының таркаулыгы, тәртипсезлек Вилданның эчен пошыра иде. «Эш кешегә ияреп өенә кайтырга тиеш түгел, – ди иде ул. – Яхшы белгеч үз вазифасын эш сәгатьләрендә башкарырга җитешә. Ә өендә тәнен дә, миен дә ял иттереп, яңа эш көне өчен көч җыя. Политэкономия өйрәтмәделәрме әллә сезнең институтта? Ә инде эшеңнән өеңә кәгазь сөйрәп йөрү ул, мин бүтәннәрдән ныграк тырышам, күбрәк эшлим, дип масаю өчен генә кирәк. Медаль бирерләр дип өметләнәсеңдер инде, җыелышта күтәреп мактарлар дип көтәсеңдер».

Башка берәр хатын булса, аның бу сүзләренә чәчрәп чыгып, пәрмә-пәр ызгышыр иде, бәлки. Мәрьям аңа сәер җәнлеккә караган кебек кенә күз ташлады да бер сүз әйтмичә кухняга, ташып чыккан аш кастрюле янына кереп китте. Мәңгелек һәм кеше гомере турында уйлануларын, төннәрен күңелен баскан кара шомнан бөтен тәне тирләп чыккан чакларны, бу уйлардан шушы проект кына коткарганын иренә сөйләп тормады. Хәер, сөйләсә, Вилдан тыңлар иде микән, тыңласа,

аңлар иде микән? Анысын Мәрьям уйламады да, ул башканы бик яхшы белә иде; ир кешенең тамагын фәлсәфә белән туйдырып булмый, аңа итле кайнар аш кирәк. Шуңа күрә ул тизрәк аш өлгертергә ашыкты. Табын янында чит кешеләрдәй тын утырдылар, хәтта Фәйрүзә дә боегып киткәндәй булды. Мәрьямнең иренә ничә тапкыр талпынып та әйтә алмаган сүзе бар. Сәҗидә апаның ире үлгән. Вилдан андый күңелсез хәбәрләрне яратмый, нервыларны сакларга кирәк, ди. Шуңа күрә Мәрьям аңа бу турыда әйтми йөргән иде.

Ул гына да түгел, бүген Мәрьям Сәҗидә апа янына куна барырга тиеш. Бичара апа елый да елый, ә янында ике кыз бала. Алай-болай әниләре чирләп китсә, сабыйлар нишли ала? Шуңа күрә көн саен берәр танышы аның янында куна. Ире өстәл яныннан кузгалгач, Мәрьям сүз башлады:

– Беләсеңме, мин Сәҗидә апа янына барып кунарга вәгъдә биргән идем.

Вилдан тиз генә аңлый алмады. Бераз торгач кына телгә килде:

– Ник?

– Аның ире үлде бит.

– Кызганыч... Тик син нишли аласың анда?

Вилданның тавышында ризасызлык, канәгатьсезлек яңгырады.

– Янында кеше булгач, аңа җиңелрәк.

– Син барып кына аның кайгысын киметә алмассың. Әни кешегә мәет киткән өйдә йөрү гомумән ярамый. Чир ияртеп кайтып, балага йоктыруың бар.

– Аңла, мин вәгъдә бирдем, бармый кала алмыйм!

– Әгәр минем белән аз гына исәпләшәсең икән, аягыңны да атламыйсың. Туган-тумачалары бардыр, шулар юатсын.

Вилданның түгәрәк ияге сизелер-сизелмәс калтырый башлады.

Мәрьям, үзен-үзе кулга алырга тырышып:

– Мин барыбер барам! – диде.

– Мине санга сукмыйсың икән, рәхим ит!

Вилданның йөзе каралып чыкты, иреннәре юкарып киткәндәй булды.

Мәрьям чөйдән пальтосын алды да чыгып йөгерде.

### *Калалар һәм кешеләр*

Йортлар язмышы кешеләр язмышына охшаган: яңа чакта бөтен тирә-якны бизәп торалар, аннары әкренләп картаялар, таушалалар. Йортлар язмышы кешеләр язмышы белән уртак: сугышларда яралананалар, җимереләләр, афәт килсә, вакытсыз искерәләр, тузалар. Тыныч, мул елларда ишәяләр, матурланалар.

Калалардагы таш йортларның гомере озын. Аларны салган кешеләр күптән юк инде, әмма шушы биналарда аларның матур хисләре, якты хыяллары саклана. Калалар үзләрендә кешелек тарихын саклыйлар. Кешелек тарихының иң борынгы чорлары, ташларга уелган тамгаларны, папирусларны, кәгазьдә язылганнарны гына түгел, адәм балаларының кулы белән корылган йортлар-биналарны, шәһәр-авылларны тикшереп тә өйрәнелә.

Җир йөзенә яңадан-яңа буыннар килә, һәрберсе үзенчә йортлар сала, һәрберсе шәһәрне үзенчә яхшырта, үзенчә бизи.

Калада бер-берсенә охшамаган төрле йортлар барлыкка килә. Һәр каланың үз йөзе, үзенә бербөтенлеге бар.

Гаҗәеп кала Казан! Нинди генә йортлар, нинди генә биналар юк биредә. Ак стеналы Кремль, камиллеге белән сокландыра торган Сөембикә манарасы, университет колонналары, Петропавловский соборының бизәкле манаралары һәм челтәрле тәрәзәләре... Шулар янында типовой кварталлар, тимер-бетоннан һәм пыяладан корылган биналар.

Казанны башка калалардан аерып торган, аны күңелгә якын иткән үзенчәлеге шунда: биредә кеше үзенең табигать баласы икәнен онытмый. Күп шәһәрләрдә урамнар коридор кебек, кая карама күз таш стенага терәлә. Ә Казанда алай түгел. Кайда гына булма, урам башында йә чаттан борылгач, Идел яки Казансуның комлы ярын яисә шәһәр тирәсендәге урманнарны, йә булмаса урман кебек яшел иркен бакчаларны күрәсең. Көндез күге-кояшы, кичен ай-йолдызы күз алдында, аларны биек стеналар кешедән ерагайтмый.

Мәрьям «Бәхет каласы»ның Казан янында булуын теләр иде.

Ничә еллар онытылып торганнан соң, «Бәхет каласы» салу хыялы Мәрьямнең күңел түрендә янә уянды.

Әмма бу хыялга һәрьяктан киртә куелган иде шул: заказ бирүче нинди биналарны ничегрәк салырга теләвен бәйнә-бәйнә әйтеп куйган. Өстәвенә аны «Төзү нормалары һәм кагыйдәләре» дигән нәрсә чикли. Барлык биналар, архитектор аны телиме-юкмы, типовой проект буенча салыначак. «Эх, индивидуаль проектлар төзергә мөмкинлек булса, мин бирегә мондыйрак биналар, ә менә

монда тегендирәкләрне салыр идем!» – дип, кәгазьгә сызгалый торгач, заказ алынмаган, планга кертелмәгән микрорайонның эскизы ясалды. Андый проектны беркем кирәксенмәсә дә, Мәрьям өчен ул бик кадерле иде. Эскизны Казанның баш рәссамы Газиз Лотфуллинга күрсәтеп карарга булды ул.

Ләкин аңарчы сызымнарны Шәүкәт күрде.

Эш бетәр алдыннан мастерскойга килеп керде ул.

Апрель аенда троллейбуста очрашканнан бирле аларның күрешкәннәре юк иде. Ул һәммәсенә берьюлы баш иеп исәнләште дә туп-туры Морат янына узды. Элеккечә, күкрәген киереп, хуҗаларча атлый, дулкынланганы сизелми. Куе чәче кашларына төшкән, әфлисун төсендә кыска җиңле ефәк күлмәге һәм яшел чалбары яшәртеп күрсәтә.

Мәрьям ул утырган якка күз салмаска тырышты, әмма Шәүкәтнең карашы аны ут кебек көйдерә, бераз саңгыраурак тавышыннан йөрәк әрнеп тибә иде. Аның кичерешләрен һәммәсе сизәдер, йөрәге шашып типкәнен барысы да ишетәдер кебек тоелды. Ул урыныннан кузгалды, планшетын кулына алды һәм, үзендә Шәүкәтнең күз карашын тоеп, мастерскойдан чыгып китте.

Коридорда аның тез буыннары йомшап китте. Ул стенага сөялде. Ничә минут узгандыр, белми, әмма Шәүкәтнең озак көттермәячәген сизә иде. Менә ул ишектән чыкты һәм янәшәсенә килеп туктады. Дустанә елмаеп, планшетка ымлады.

– Бу ни?

– Проектка эскизлар. Газизгә күрсәтермен дип әзерләгән идем.

– Мин күз салсам, рөхсәтме? Син вәгъдә биргән идең бит!

– Кайда күрсәтим соң? – диде Мәрьям, аптырап. – Биредә караңгы.

– Әйдә урамга чыгыйк!..

Алар, Чехов базары аша үтеп, бакчага керделәр. Мәрьям планшетын сукмак кырыендагы утыргычка куйды. Шәүкәт, кашларын җыерып, беренче биттәге сызымга текәлде. Шактый вакыт дәшмәде.

Эскәмия янындагы яшь каеннарның чиста, яшел яфраклы тармаклары җилдә тирбәлә, аларның озын күләгәләре Шәүкәт өстенә төшә иде. Каеннар артындагы хәтфә чирәмлектә кыргый алмагачлар чәчәккә күмелеп утыра. Мәрьям озак кына аларга карады, аннары, керфекләрен кыса төшеп, сызымнарга. Аның күңелендә чын шәһәр, моңарчы күрелмәгән гаҗәеп кала манзарасы пәйда булды...

Биналар арасындагы иркен мәйдан уртасында ак таштан салынган мәктәп. Аның ишегалдында спорт мәйданы, бассейн. Алар һәммәсе агачлык белән уратып алынган. Мәйдан тирәсендәге йортлар төрле биеклектә: өч, биш, тугыз, унике катлылар. Алар бер-берсенә бөтенләй охшамаганнар. Барлык тәрәзәләр агачлыкка ачыла, берсе дә күршесенең стенасына төбәлми. Бер өч катлы йорт түбәсендә – җәйге кафе. Һәр йортның балконнары аерым фасонда эшләнгән, рәшәткәләре төрлечә. Балкон араларына һәм кәрнизләргә гранит вагы кушылган штукатуркага төрле төсләр белән милли бизәкләр төшерелгән.

Биек йортлар янында көнкүреш хезмәте күрсәтү биналары, кафе. Микрорайон кырыендагы киң бульварлар урманга тоташа.

– Кызганыч, бу кала кәгазьдә генә калачак, – диде Шәүкәт.

– Алай димә. Монда тормышка ашыра алмаслык бернәрсә дә юк. Мин фантазиямне бәйдән ычкындырмадым. Хәзерге заман өчен бу искитәрлек проект түгел. Монда фәкать биек йортлар өчен лифтлар, төсле штукатурка өчен гранит вагы кирәк булачак.

– Синең һәр бинаң индивидуаль проект сорый. Алар бер-берсенә охшамаган!

Шәүкәтнең тавышында кызгану ишетелде.

– Ул әллә ни кыйбатка төшмәячәк. Алар бер үк детальләрдән салына. Монда зур мәйдан алынмый, урынны төзелешкә әзерләүдән шактый экономия булачак. Хәзер дөньялар үзгәреп килә бит, төзелешкә караш та җылына. Көрәшергә кирәк.

Шәүкәт иңбашларын сикертеп куйды:

– Җил тегермәннәре беләнме?

Испан язучысы Сервантесның тилемсә герое Дон Кихотка ишарә иде бу, юк артыннан куасың дигән сүз иде. Шәүкәт моны үртәп йә кимсетеп түгел, кызганып әйтте, шуңа күрә үпкәләү урынсыз иде.

– Җил тегермәне белән сугышмаса, Дон Кихот тарихка кереп калмас иде, – диде Мәрьям.

– Тарихка керүне өмет итәсең инде, димәк!

– Һәр төзелгән шәһәр кешелек тарихына эз сала!

Шәүкәт, и-и, әйтеп тә куясың инде дигәндәй, башын селкеде, аннары кесәсеннән авторучка чыгарды, эскәмия-гә утырды да, планшетын әйләндереп, аннары фанерга сызгаларга кереште.

– Йортларың шәп. Композициясе уңышлы. Казан халкының төшендә дә күргәне юк мондый районны. Ләкин бер-ике кисәтү ясыйм, үпкәләмә.

Мәрьям елмайды:

– Яса, яса!

– Мин районны тагын да матурлар идем. Булгач-булгач, булуы җитсен. Синең «яшел тапларың» яссы. Урыны тигезмени? – Мәрьям, әйе дип, ым какты. – Яса калкулыклар. Котлованнардан алган җирне өйсеннәр шунда. Үлән чәчәргә кирәк. Балалар җәен качыш уйнарлар, кышын чана шуарлар. Балконнарның кайберләре матур түгел. Стиле ятышмый...

Ул әйткәннәр Мәрьям күз алдында төсле күренешләр булып җанланды, күңелен очындырды. Менә ул рәсемнәрен аркылы-торкылы сызды да башын күтәрде:

– Болар башка кинәт килгәне генә. Ныгытып уйларга кирәк.

– Син уйлашасыңмы соң? Бипаларның ничек урнашуын сызып биримме әллә? – диде Мәрьям, сөенеп.

– Кирәкми. Күрдем ич инде. Аны гына истә тотарлык.

Алар тагын бераз сөйләшеп утырдылар.

Шәүкәт шушы арада ачылачак күргәзмәгә үзенең картинасын куйдыру артыннан йөри икән. Димәк, тиз генә китеп бармаячак, бу сөенечле хәбәр җанны тәмам эретте.

### *Хыялый калада*

– Мин иртәгә китәм.

– Кая?

– Таганрогка, командировкага.

Июнь уртасы, көн чалт аяз. Ачык тәрәзәләрдән кичке кояш нурына чумган шәһәр күренә. Каршыдагы «Пампушки» кафесының пыяла стеналарында шәфәкъ яктысы чагыла. Вилдан идән уртасындагы кечкенә чемоданына йомарланган күлмәкләрен ыргыта.

– Алай салма инде, – ди Мәрьям, шактый дәшми торгач. – Кая, үтүкләп бирим.

Вилдан, борылып карамыйча, теш аралаш кына:

– Мәшәкатьләнмә, зинһар. Чит ирнең күлмәкләрен үтүкләү күңелле эш түгел, – ди.

– Китәреңне әйтмәдең ич...

– Кайчан әйтим әле. Башка берәүне җибәрмәкчеләр иде, үзем үтенеп сорадым. Чит кешеләр кебек яшибез ич, миннән тәмам туйдың, ахры. Фәйрүзә киткәнгә ун көн, шуннан бирле ун авыз сүз сөйләшкәнең юк.

Мәрьям кызын авылдагы туганнарына кайтарып куйган иде.

Ләкин Вилданны җибәрергә ярамый, һич ярамый иде! Мәрьямнең күңелен үзе дә сәбәбен аңламаган шом басты.

– Китмә, Вилдан, үтенеп сорыйм, зинһар, китмә!

– Хәзер соң инде, кире уйлап булмый. Беразга миннән котылып торырсың. Кайтуыма бөтенесен төптән уйлап, алга таба ничек яшәвеңне хәл итеп куярсың.

Ир ирлеген итте, сүзеннән кире кайтмады, ишекне каты ябып чыгып китте. Ялгызы калган хатынга читен булырга тиеш иде. Әмма Мәрьям юкка шомланган икән, Вилдан үзе белән аның җанын кысып торган кыршауны алып киткәндәй булды: күңел тынычлангандай булды, эшкә дәрт артты, хәтта тәүлек тә озайды шикелле.

Ташлыярдагы микрорайон эскизлары берсе артыннан берсе сызыла торды. Институтта урамнар перспективасын ясаса, өйдә, идән уртасына җәеп, рәхәтләнеп, иркенләп, яшелләндерү планын сыза архитектор Закирова. Аннары районның өстән караганда күренешен... Әле фасадларны бизәү эскизларын эшлисе бар... Макетын ясарга кирәк... Сызып-сызып арыгач, пенопласт, катыргы турыйсы...

Мавыгып, дәртләнеп эшләде Мәрьям. Бик бәхетле хис итте ул үзен бу көннәрдә.

Баш инженер Морат Шәехзадинның чираттагы идея белән мавыккан чагы иде. Ташлыярда типовой биналардан салыначак микрорайонны үзе өчен әһәмиятле эшкә санамый иде, шунлыктан җаваплылыкны тулысынча өлкән инженер Закировага йөкләде, һәр сызыгына бәйләнеп, теңкәсенә тимәде. Мәрьямгә шул гына кирәк тә иде инде.

Эш үз иркенә куелгач, баш әйбәт эшли бит ул. Хыялый шәһәрдә булырга тиешле дип күзалланган шактый табышлар Ташлыяр микрорайоны өчен ярап куйды.

Ә Моратның үз хәле хәл иде. Дөрес, аны богаулап торган чылбырлар чишелә кебек – архитекторларга индивидуаль проектлар төзергә рөхсәт ителә башлады. Шунда тагын бер фаҗига ачылды: озак елларга сузылган иҗат ачлыгы фикер торгынлыгына китергән икән. Заманалар үзгәргән, таләпләр үскән, ә искелектә тәрбияләнгән иҗат әһелләре яңалыкны тудыруга сәләтләрен югалтканнар. Яңа стильгә, яңа төзү ысулларына, матурлык дигән нәрсәнең үзенә яңача карарга тырышу – аяныч, хәтта көлке хәлләр китереп чыгара иде. «Шәфәкъ» ресторанының Шәехзадин

проекты буенча эшләнгән интерьеры яңа стильгә пародия булып чыкты: аның кара түшәмендәге аркылы-торкылы итеп беркеткән тимер араталар башка төшәр кебек. Стеналар буй-буй саргылт-кара. Түр стенага смальтадан ясалган мозаика – Сөембикә манарасы гомуми тәэсирне йомшартмый иде. Иң аянычлысы – интерьер революциягә кадәр үк сырлап-бизәп салынган бинаның тышкы күренешенә, зур көзгеле, сырлы кәрнизле, мәрмәр баскычлы вестибюленә һич туры килми иде.

Хәер, Шәехзадинның моңа көенеп, кайгырып утырырга вакыты юк әле. Ул яңа проект – цирк белән мавыккан. Бар да Мәрьям бәхетенә. Яшәсен мөстәкыйльлек!

Ул инде, чикләрне онытып, микрорайонны киңәйтте. Ташлыяр мәңге кечкенә шәһәр булып калмас, киләчәктә яшәү өчен бик тә уңайлы, гүзәл калага әверелер. Әйе, ул хыялда көннән-көн үсте, зурайды. Кәгазь битләренә караган саен, күңелне күтәрә торган сурәтләре арта барды. Анда инде миллион кеше яши. Завод-фабрикалар, комбинатлар, кибет-рестораннары җир астында. Юллар да җир астыннан үтә. Ә җир өсте – торак йортлар, мәктәпләр һәм бакчалар өчен генә. Бернинди шау-шу, тузан-төтен юк. Ямь-яшел бакчалар, саф сулы елгалар, күлләр, йөгерек инешләр һәм алар арасында төрле биеклектәге, төрле формадагы матур биналар. Урыны-урыны белән пыяла түбә асларында мәңге яшел бакчалар үстерелгән.

Архитектор биналарны салу һәм бизәү өчен иң матур, иң яхшы материалларны файдаланган: мәрмәр, гранит, алюминий, пыяла, синтетика... Бу проект Шәүкәтне дә мавыктырды. Ул көн саен кич Морат янына дигән булып институтка килә. Алар өчәү бергә кайтырга чыгалар; Морат, Мәрьям һәм Шәүкәт. Морат Кремль янында өенә кереп кала, ә алар икесе дамба буйлап юлны дәвам итәләр. Баштарак, бу очрашуларны очраклы дип, Мәрьям үз-үзен алдап маташты. Ләкин институттагылар мәхәббәттән исермәгән, барын да күреп-белеп торалар. Тик Мәрьям моны аңламады, абруен саклау турында кайгыртмады.

Алар дамбаның аргы башына чыгалар да, ком өстенә планшет салып, хыялый йортлардагы хыялый квартираларны җиһазлыйлар: төймәгә басып ачыла торган тәрәзәләр... Шлангтан су сиптереп юыла торган идәннәр... стеналар эчендә – шкафлар...

– Менә бу – кыйммәтле эчемлекләр саклый торган бар.

– Бусы – күчереп йөртелә торган стена: кунаклар килгәч алып куясың, киткәч, үз урынына урнаштырасың, бер якта зал, икенчесендә – минем будуар...

– Ишек эчкә дә, тышка да ачылмый, стена эченә генә шуып кереп китә...

– Бу бакчада тиеннәр үрчетербез. Алар нарат күркәсе яраталар. Ә безнең шәһәрдә чыршы-нарат яхшы үсәчәк, чөнки анда тавыш та, зарарлы газ да булмаячак...

Хыялый каланы күз алдына китереп, алар үзара шулай сөйләшергә күнегеп киттеләр.

Алар ул каланы чынлап салынган дип хис иттеләр. Аһ, ул комда салынган кала! Саташтырды ла ул, адаштырды!

## *Тирән күл*

Бәндә хатадан хали түгел. Кайчак ялгыш адым ясаганыңны сизми дә каласың. Вакыт үтә, хатаңны күрәсең, терсәгеңне тешләрдәй буласың, әмма соң була... Алай да азмыни абынып егылганнан соң аякка басып, тормышын өр-яңадан, дөрес юлдан башлап җибәргән кешеләр?!

Шәүкәт тә кайчандыр хата ясады. Ләкин егет булды, авырлыкны башка кеше җилкәсенә салмады, җаваплылыкны үз өстенә алды... Тик шунысы: аның хатасы Мәрьямнең язмышын башка берәү белән бәйләүгә сәбәп булды.

Мәрьям үзенең төссез үткән елларын искә төшереп хәйран калды. «Бер генә килә торган гомеребезнең кадерен белмибез бит, белмибез! Үткән гомернең бер генә сәгате дә кире кайтмый. Ә без сәгатьләрне генә түгел, айларны, елларны суга салгандай итәбез. Моңа хакыбыз бармы безнең? Кем биргән безгә андый хокукны?»

Әгәр Мәрьям тормыш юлында Шәүкәтне очратмаса, ул талпынуның бар икәнен дә белмәс һәм дәртләнеп, илһамланып иҗат итә дә алмас иде кебек тоелды.

Ул киләчәктә ни буласын белми. Бу турыда уйларга башы да җитми, әмма кире чигенү мөмкин түгел. Һәрхәлдә, яратмаган кеше белән яшәү үзе үк әхлаксызлык бит, андый тормыш беркемгә дә бәхет китерми.

Җылы, җилсез төннәрнең берендә алар, инде Мәрьямнең өенә кайтып җиткәч, хушлашмадылар, кире борылдылар. Тимер юлга килеп чыккач, шпаллар буйлап көнбатышка юнәлделәр. Тоныкк кына ялтыраган рельслар еракка, күз күрмәгән, колак ишетмәгән сихри урыннарга илтәләр иде кебек.

Мәрьям, Шәүкәтнең иңенә таянып, рельс өстеннән бара. Бала-чага кебек кылана, иркәләнә ул. Менә алар Тирән күлгә килеп җиттеләр. Текә яр астында тыныч су тонык кына ялтырый. Тулган ай күл суында үзен күреп сокланудан хәйран калган. Бер ярда үскән наратлар ай нурында коеналар, икенче яр астында – кара күләгә.

Алар, ярдан төшеп, күләгәгә яшеренделәр. Су янында шактый салкынча. Юка жакет кигән Мәрьям әллә туңудан, әллә дулкынланудан калтыранып куйды. Шәүкәт, канатын җәйгән бөркет кебек, пинжәген ачып, аны чакырды. Мәрьям бер атлады, ике... Яр читендә ике урынына бер генә шәүлә калды. Мәрьям ир-егет иреннәренең татлы балын да, исерткеч шәрабын да, ачы агуын да берьюлы эчте. Аның башы әйләнде, йөрәгеннән бәреп чыккан кайнар дулкын бар тамырларын көйдерде. Ялтырап яткан күл, тыныч наратлар, түгәрәк ай – бөтен дөнья чайкалды, авышты, ауды...

Алар комда утыралар. Мәрьям, яңагын Шәүкәтнең күкрәгенә куеп, йөрәгенең тигезсез тибүен тыңлый. Шәүкәт тетрәнгән бармаклары белән аның чәчен сыйпый.

– Кара әле миңа!

Мәрьям, башын артка ташлап, аның йөзенә карый: искиткеч матур, акыллы, серле тоела ул йөз!

– Ирен сызыкларың матур синең, – ди Шәүкәт. – Йөзең, тавышың көләр өчен яратылган. Беләсеңме, сине оныта алмаячагымны кайчан аңладым?

– Кайчан?

– Хәтерлисеңме? Сез коридорда теннис уйный идегез. Мин килеп стенага сөялдем. Син ул көнне гадәттәгедән җитез, сизгер идең. Син барысын да җиңгәч, көлдең дә көлдең. – Шәүкәтнең назлы пышылдавына якын куактан сандугач моңы кушылды. – Минем күз алдыма Казансу, парк, тын урамнар килде. Мин сине элегрәк, артык кычкырып көләсең дип, гел тыеп килә идем. Ә менә шул көнне генә синең көлүеңнең кадерен белдем.

Мәрьям дә ул көнне яхшы хәтерли. Шәүкәт өйләнгәннән соң берничә ай узгач булды ул вакыйга. Ул күреп торганга көлгән иде, аның карашы астында очынып һәммәсен җиңгән иде ул.

– Аһ, Шәүкәт, ярый әле син бар дөньяда, ярый әле без очрашканбыз! Юкса мин күп нәрсәдән мәхрүм калган булыр идем. Бик матур син, Шәүкәт!

Ул тын гына елмая:

– Булыр инде. Күнеккәнгә генә шулай күренә.

Урманны яңгыратып, сандугачлар сайрый. Күк гөмбәзен очлы башлары белән терәгән наратлар, сакчылар кебек, хәрәкәтсез тора. Якындагы тимер юлдан, күңелле тыкылдап, поездлар үтеп китә.

Куе үлән арасыннан зәңгәрсу яктылык сипкән кортка күрсәтте Мәрьям:

– Үзе кечкенә генә, ә шундый нурлы! Шулхәтле нур каян килә икән аңа?

– Алып биримме?

– Кирәкми, тимә! Кулга тотсаң, сүнә ул. Болай да күп янасы калмаган инде, әнә таң атып килә.

Әйе, таң ата. Кабат Мәрьямнең көлүе яңгырады. Иртәнге томан белән өртелгән күлдә су чәчрәтә-чәчрәтә, куыша-куыша су коенды алар.

Чыклы аланда каралып ике эз калды...

Алар шәһәргә җәяү кайттылар – автобуслар йөрми иде әле.

Тимер юл буенда ике карт каен үсеп утыра: берсе ямь-яшел, икенчесе корыган.

– Кара син боларны, – диде Шәүкәт. – Тегесе яшь кызлар күлмәге кигән әбигә охшаган. Ә корыганы табигый, үзенчә матур. Шулай бит?

Мәрьямгә агачларның яфраклысы чагыштыргысыз матуррак тоела иде. Аның җиргә кадәр салынган бөдрә тармакларыннан, юан, ак кәүсәсеннән тереклек көче бөркелеп тора. Ә корыганы, үле ботакларын күккә сузып, шәфкать сорагандай...

Кояш үрелеп шәһәр урамнарына беренче нурларын сузганда, алар саубуллаштылар.

### *Күргәзмәдә*

Бишәр катлы таш йортлар белән әйләндереп алынган зур ишегалдының уртасында бөдрә өрәңгеләр үсә. Алар яшь әле, көндез күләгә бирми, кичен ят күзләрдән сакламый. Шул сирәк агачлар арасына эскәмияләр куелган. Урамнарда йөреп арыгач, аерылыша алмый йөдәгән Шәүкәт белән Мәрьям шуларның берсендә утырып торалар. Күз бәйләнгән чак. Урак ай – үтә күренмәле кәгазьдән ясалып, сыек зәңгәрсу күк гөмбәзенә ябыштырып куелган кебек. Каршыдагы тротуардан да, уңдагы сукмактан да кеше өзелми. Шәүкәт, үзалдына карап, әкрен тавыш белән сөйли, ә бармак араларына кысылган сигареты сүнә бара...

– Мин соңгы елларда бик нык уйлана башладым әле. Ярый, менә без үзебезне табигатьнең хуҗасы дигән булабыз. Ә чынлабрак карасаң, бер бөҗәктән, чебеннән, кырмыскадан ни аермабыз бар? Бөҗәк тә үлә, кеше дә үлә. Бары да бетә, юкка чыга. Кая китә кешенең хисләре, мәхәббәте, хыяллары? Ни мәгънә талпынуында, янып-көюендә, иҗат итәм дип тырмашуында? Галәм чиксез. Мин шул чиксезлекне һич күз алдына китерә алмыйм. Әйтик, ракетага утырып, яктылык тизлеге белән очасың, очасың... Үлгәнче очасың... Аннары синең балаларың, оныкларың оча... Уйлап карасаң, шулчаклы куркыныч. Кеше генә түгел, Җир шары үзе дә ул чиксез галәмдә бер ком бөртеге кебек кенә. Кеше дә аңа ябышкан, бөҗәк тә. Аерма юк...

Менә ничек... Мәрьямне газаплаган уйлар Шәүкәтнең дә җанын талкый икән. Галәмнең мәңгелек караңгылыгы һәм суыгы аның да бәгырен өшетә икән. Бу шом күңелне янә басты. Әмма шунда ук аны теләктәшлекнең, кызгануның җылы дулкыны юа башлады.

– Аерма бар, ник булмасын, – диде Мәрьям. – Бөҗәкләр үлем турында уйлый алмый, ә кеше уйлый, үләчәген белә.

– Уйланудан ни файда?.. Уйламаган, белмәгән җан иясе бәхетлерәк түгелме? Адәм баласы һәрнәрсәнең асылын аңларга, серенә төшенергә тырыша, төпченә, казына, ачышлар ясый. Миллион ел тырыша, баш вата торгач, атом бомбасы иҗат итте кешелек! Аның үсешенең нәтиҗәсе, акыл җимеше – бомба! Җир йөзендә тормыш әсәрен юк итү чарасы! Йә, уйлап кара, шуннан да искитәрлек, шуннан да куәтле тагын берәр нәрсә уйлап тапканмы кешелек? Юк. Аның иң бөек ачышы – үзен-үзе үтерү коралы. Ул бомба безнең башыбызга һәр минутта килеп төшәргә мөмкин һәм безнең үзебездән дә, иҗатыбыздан да тузан бөртеге дә калмаячак. Ә Җир һаман шулай Кояш тирәсендә әйләнер, Галәм һаман чиксез булыр, вакыт шул ук тизлектә уза торыр. Тик без генә булмабыз.

Шәүкәт сүнгән сигаретын комсызланып суырды, аннары кесәләреннән шырпы эзләргә тотынды, тапмагач, төпчеген чирәмгә ыргытты.

– Үзем үлгәч, дөньяда, галәмдә ни эшем бар минем? Джоконданың елмаюыннан Леонардо да Винчига ни файда? Ул үлгән, берни белми, сизми, елмаямы-юкмы Джоконда – аңа барыбер! Мәңгелек материя күзлегеннән караганда, Мона Лиза – чүпрәккә сыланган бер-ике кашык буяу гына бит!

Шәүкәт Мәрьямгә текәп карады:

– Йә, ник дәшмисең? Синең бу турыда уйланганың юкмы әллә? Әгәр уйланмыйсың икән, син – бәхетле.

Күктәге ай яктырды, җанлана төште, күк йөзе тирәнәйде, караңгыланды, чекерәеп йолдызлар калыкты. Мәрьям кинәт үзен салкын, чиксез галәм белән япа-ялгызы күзгә-күз калгандай хис итте. Бәгыренә төн караңгылыгы, галәм суыгы үтә башлагандай булды. Ләкин ул бу шомны, караңгылыкны куарга тырышты, һәм Шәүкәтнең иңбашына таба авыша төшеп пышылдап кына сөйли башлады:

– Әгәр Леонардо да Винчи бер генә минутка терелсә һәм аннан: «Кешелекнең бөек рәссамы һәм галиме Леонардо да Винчи! Синең дөньядан киткәнеңә дүрт йөз кырык җиде ел. Ләкин синең әсәрләрең яши, алар исән, «Джоконда»ның елмаюы бөтен дөнья халкын сокландыра. Әйт әле, Леонардо да Винчи, Мона Лизаның яшәве-яшәмәве синең өчен барыберме, юкмы?» – дип сорасалар, ни дип җавап бирер иде ул, синеңчә? «Мин Мона Лизага гомеремне бирдем. Ул исән чакта мин дә үлмәм», – дияр иде. Шулай бит? Адәм балаларын бөҗәккә тиң кую дөрес түгел, минемчә. Әгәр алар, син әйткәнчә, бөҗәкләр кебек мәгънәсез яшәсәләр, без кыргый хайван хәлендә булыр идек. Моңарчы җирдә яшәгән кешеләр безнең өчен калалар салганнар, киемнәр теккәннәр, китаплар язганнар, дарулар ясаганнар... Без бу хакта бөтенләй уйламыйбыз. Ә бит безгә искиткеч күп нәрсәләр бирелгән! Алдагы буыннар мәгънәсез яшәп, мәгънәсез үлсә, без бөтенләй мондый булмас идек. Әгәр беләсең килсә, кешелекнең иң бөек казанышы атом бомбасы түгел, ә хәзерге заман кешесе. Егерменче гасырның акыллы, белемле, куәтле кешесе. Кеше тудырган иң зур могҗиза ул – «Джоконда»ның елмаюы, гаделлек, изгелек, матурлык. Дөрес, бөтен кеше дә «Джоконда» тудыра алмый, ләкин менә мин үз проектымны төзегәндә, «Бәхет каласы»ннан күбрәк нәрсәләр кертергә тырышам.

Мәрьям шулай мавыгып сөйләде, сөйләгән саен үз-үзенә юаныч, таяныч тапкандай булды.

Шәүкәт кашларын җыерды:

– Тагын проект! Аңла син шуны: без үләчәкбез, юкка чыгачакбыз, мәңгелек белән чагыштырганда безнең проектларның гомере – бер мизгел!

– Шулай шул, алар мәңгелек түгел, – дип ризалашты аның белән Мәрьям. – Ләкин галәм турында, мәңгелек турында уйлаганда, үзеңне җилдә очкан ком бөртеге кебек кенә итеп күз алдына китерү дөрес түгелдер ул. Без яшәешнең өзлексез чылбырындагы бер буын бит, үткән буыннарның тормышын дәвам итәбез, безнең тормышны киләчәк кешеләре дәвам итәчәк. Моны аңларга кирәк, егерменче гасырда яшибез ич инде!

– Бигрәк китапча сөйлисең инде. Егерменче гасыр кешесе, имеш. Ә мин менә үземнең шушындый булуымнан һич тә канәгать түгел, һич тә. Җирдә аяк терәп торырлык урын таба алмыйм.

Мәрьям аның иңенә кулын салды:

– Шәүкәт! Талантлы кеше ич син. Юлың бер генә – иҗат. Бәлки... бәлки, сиңа аркылы төшәләрдер? Бәлки, аңламыйлардыр?

Шәүкәт авыр көрсенде дә, күңелсез уйларын селкеп ташлагандай, җәһәт урыныннан кузгалды.

– Мин үземә алкышлар таләп итмим... Кирәкми! Әйдә әле башка нәрсәләр турында сөйләшик!

Ләкин сүз ялганмады. Алар иңнәренә йөк баскандай иелеп утырдылар.

Шәүкәтнең бу газаплы уйларын таратырга, ничек булса да юатырга, күңелен күтәрергә кирәк иде. Ләкин Мәрьям шуны да ачык белә: мондый чакларда кешегә ярдәм итү бик тә, бик тә читен. Галәм һәм мәңгелек белән йөзгә-йөз очрашып, тирән һәм сагышлы уйлар кочагында ялгызы калган чакта кеше үзе, фәкать үзе генә ничек яшәргә һәм кая барырга икәнен ачыклый ала.

Дөньяга яратылганнан бирле кешелек хакыйкатьне аңларга, мәңгелекнең серләрен ачарга омтылып яши. Бу авыр һәм озын юлның очы-кырые күренми әле. Һәм бары тик мин-минлегеннән, үз гамьнәреннән югары күтәрелә алган, җирдә яшәүче башкалар белән бердәмлеген тоеп, мәңгелек хакыйкатьне аңлау юлында кешелеккә бераз гына булса да алгарак китәргә ярдәм итә алган шәхес кенә – фәкать шундыйлар гына бу дөньяда җан тынычлыгы һәм киләчәккә ышаныч белән яши ала.

Күп уйланды инде Мәрьям бу хакта, һәм бер нәрсәне генә – безнең гомердә бу сорауларга җавап табылмаячагын гына аңлый алды. Кайчан да булса кешеләр мәңгелекнең серен ачарлар һәм үлемсезлеккә ирешерләр, һәм моңа алар үткән буыннарның гыйлемлегенә һәм гүзәллеккә таянып кына ирешә алачаклар. Әгәр дә Мәрьям бу юлда аларга әз генә булса да ярдәм итә алса, димәк, аның гомере киләчәк буыннарда дәвам итәр. Хәзергедән матуррак һәм уңайлырак калаларда, бездән акыллырак һәм камилрәк кешеләрнең канында дәвам итәр ул...

Шуларны әйтергә теләде Мәрьям, ләкин Шәүкәтнең салкынлыгы, анда сизелгән каршылык тагын да ныграк ачылып китәргә мөмкинлек бирмәде. Ә бит мондый сүзләрне, мәхәббәт сүзләре кебек үк, ике йөрәк бер булып типкәндә генә сөйләп була.

Алар, сөйләшмичә генә, әкрен атлап, урамга чыктылар. Берсе дә сүз башларга базмады. «Сиңа авыр булды инде, бәлки, яныңда кул бирерлек, ярдәм итәрлек дусларың да булмагандыр. Ләкин болар барысы да олы максат, иҗат белән чагыштырганда ул кадәрле үк әһәмиятле түгел бит. Син бирешмә, нык тор, күңелең сынмасын, синең тормышта үз сүзеңне әйтерлек көчең-куәтең бар бит», – дип әйтергә теләде Мәрьям. Тик мондый сүзләрне Шәүкәт ясалма дип кабул итәр кебек тоелды, шунлыктан алар әйтелми калды.

Әйе, алар бер-берсен ахыргача аңлый алмадылар. Хәзер инде Шәүкәт кичергәннәрне фараз итәргә генә кала. Үз-үзеннән, шәхси тормышыннан, бигрәк тә иҗатыннан канәгатьсезлек хисе газаплый иде аны. Ул яшьтән үк зурга омтылды, бөтен кешене шаккатырырлык картиналар иҗат итәргә, шөһрәт казанырга теләде. Ләкин максатына тиз генә ирешә алмады. Бәлки, таланты үзе уйлаганча олы булмагандыр. Бәлки, тырышлыгы, эшчәнлеге, белеме җитмәгәндер. Бәлки, күңеле бик сизгер, бик нечкә булганга, һәр тәнкыйть сүзен артык авыр кабул иткәнгә, күңеле төшеп, кулы эшкә бармагандыр...

Һәрхәлдә, Шәүкәт, рәссам буларак, үзе сайлап алган, үзенең табигатенә, сәләтенә, каләменә туры килгән юнәлештә бара алмады, читкә тайпылды. Ә иҗат кешесе өчен андый тайпылыш фаҗигагә тиң.

Моны Мәрьям «Зур Идел» күргәзмәсенә барып, Шәүкәтнең картинасын карагач аермачык аңлады.

Аның картинасын әллә каян таныячагына ышанган иде ул. Юри зал уртасына басты да дүрт стенадагы рамнарны ерактан карап чыкты. Юк, тапмады. Бер әйләнде үз тирәсендә, ике – юк, күрмәде Шәүкәтне. Әллә аның картинасын куймадылар микән? Тагын хаксызга рәнҗеттеләр микән? Меңнәр арасыннан бер күрүдә танырлык гаҗәеп талантлы Шәүкәтне тагын хурладылар микәнни?

Мәрьям зал буйлап әкрен генә йөреп чыкты. Юк Шәүкәт... Рамнардагы язуларны укырга башына килмәде, почмактагы өстәл артыннан тамашачыларны ялкау гына күзәтеп утырган, мода белән киенгән кызга мөрәҗәгать итте:

– Рәссам Аитов эше юкмыни биредә?

Кыз белдекле кешедәй елмайды:

– Бар, әлбәттә! Күргәзмәнең кадагы! Әнә теге баштагы зур полотноны күрәсезме?

– Кайсы?

– Әнә! «Көтүче җыры» дип атала...

– Сез ялгышасыз... Мин Аитов турында сораган идем.

Кыз үпкәләгәндәй булды:

– Ничек ялгышыйм инде?! Мин Аитовның үзен дә яхшы беләм. Искиткеч талантлы рәссам. – Кыз илһамланып сөйли башлады: – Төсләр гаммасына игътибар итегез, композициянең төгәллегенә, камиллегенә!

...Күзләрне камаштырырлык җете кызыл җилән, башкорт бүреге кигән кәҗә сакаллы бер карт калкулык башындагы олы ташка утырган да курай уйный. Аның аяк очына, Мәрьямгә йөзе белән, аякларенә таянып, түгәрәк битле малай сузылып яткан. Калкулык астында туры сызыклар ясап үскән агачлыклар белән тигез шакмакларга бүленгән басулар, бакчалар. Офыкта күргәзмә әсбапларда гына була торган авыл: ап-ак йортлар, антенналар...

Мәрьям картинага озак карап торды. Композиция, сурәтләү, төсләр сайлау ягыннан караганда, барысы да үз урынында. Менә бу җире начар дип, тотып хурларлыгы юк кебек, киресенчә,

мактарлык урыннары да шактыйдыр. Ләкин күңел кылларын тибрәндерерлек, дулкынландырырлык көче юк. Картинада курай күренә, ә моңы ишетелми. Гомумән, Шәүкәтнең һәр сызыгы белән йөрәккә тәэсир итә торган палитрасы күренми.

«Яшь бит әле, эшли-эшли осталыгын үстерер. Хәтта генийларның да өйрәнчек әсәрләре шедевр булмаган», – дип, Мәрьям үзен юатырга тырышты. Ләкин ул һәр генийның иң начар рәсемендә дә кешене дулкынландыра торган, үзенә генә хас каләме сизелгәнен белә иде. Ә биредә андый каләм күренми шул.

Мәрьямгә бөтен картина ясалма тоелды. Төсләр артык ачык, күзне ерта. Автор кешеләрне, маңгайларына бәреп, шаккатырырга тырышкан. Мәрьям хәтта Шәүкәтнең картинаны ни кыяфәттә язганын күргәндәй булды: кашларын җыерган, рамга тарткан киндерне сөзәргә җыенгандай башын игән, ә күңеле белән әллә кайларда гизә. «Иҗат эшендә үзеңне мәҗбүр итү уңышка китерми! Илһамсыз күңел, дәртсез кул белән сурәт ясау җелекне суыра... Буталган Шәүкәт, адашкан», – дип уйлады Мәрьям, һәм шунда ук сөйгәне янына йөгереп барасы, аны юатасы, тынычландырасы килде. Ул барын да сак кына, җаен туры китереп аңлатыр. Туңган йөрәген кайнар мәхәббәте белән эретер, олы ышанычы белән аңа җан өрер. Иҗатында аңлаучысы, киңәшчесе, ярдәмчесе булыр.

Шәүкәт күп уйлый, үзе турында гына түгел, бөтен кешелек язмышы турында борчыла. Шундый тынгысыз талант ияләре бөек әсәрләр иҗат итә дә инде! Аның каләме кешеләрне теләсә, җырлата, теләсә, елата алырлык. Үз юлыннан тайпылмасын гына.

Эшен дә, тормышын да корбан итәргә әзер иде Мәрьям Шәүкәт өчен. Тик андый зур корбаннарның кирәге булмады.

### *Өченче кеше артык*

«Родина» кинотеатрының кече залында «Төрле этажлы Америка» дигән документаль фильм бара иде. «Этаж» да, «Америка» да булгач, архитектор кешегә ул фильмны карамый калырга һич ярамый. Беркөнне эштән соң Мәрьям шунда китте һәм барганына мең үкенде...

Аның урыны сигезенче рәттә, ишек янында иде. Инде утлар сүнә башлагач, соңгы тамашачылар, ашыгып-кабаланып, үзләренең урынын эзләп йөргәндә, Мәрьям турыннан Шәүкәт узып китте. Ул үзе генә түгел, аның артыннан җиңсез кара күлмәк кигән чандыр гәүдәле хатын-кыз килә иде. Бер күз салуда Мәрьям барын да аңлады: Шәүкәтнең хатыны иде бу. Менә нилектән берничә көн инде күзгә күренгәне юк...

Ул, иелеп, буш урындыклар арасыннан үз урынын эзләде. Алар җиденче рәткә, Мәрьям турына диярлек утырдылар.

Экранда фильмның титрлары күренүгә, хатын, үрелеп, Шәүкәтнең колагына нидер пышылдады. Әнә ничек үз итеп, якын итеп сыена иренә! Мәрьямнең кулын сузып ят хатынның иреннәрен учы белән каплыйсы килде: сүзләре Шәүкәткә ишетелмәсен, сулышы аңа бәрелмәсен иде.

Ничек түзәр иде Мәрьям, тик тегеләр, икесе дә кузгалып, кешеләргә комачауламас өчен иелеп, алга уздылар һәм буш калган беренче рәткә барып утырдылар. Мәрьям бөтен миен чорнап алган кайнар томан аша: «Хатыны начар күрә, ахрысы», – дип уйлап куйды.

Америка этажларында хәбәре калмады Мәрьямнең. Фильм бетүгә, урыныннан сикереп торды да күзләре белән Шәүкәтне эзләп тапты. Аны башка берәү белән күрү никадәрле газаплы булса да, Мәрьям, сихерләнгәндәй, күзләрен аннан ала алмады. Кешеләргә бәрелә-сугыла, аларны күздән югалтмаска, үзе күренмәскә тырышып, урамга чыкты. Хатыны кояшта каралган шома беләге белән Шәүкәтне култыклаган, көлә-көлә нидер сөйли. Астрономическая урамы чатында аларны светофорның кызыл уты туктатты. Хатын, гәүдәсе белән борылып, Шәүкәтнең каршысына диярлек чыгып басты. Шунда Мәрьям аның йөзен аермачык күрде: буяп җирән төскә керткән, күпертеп тараган кыска чәче маңгаен каплаган. Кечкенә борынлы түгәрәк йөз. Модага туры китереп, кап-кара сөрмә тарткан. Ә күзләре, зур зәңгәр күзләре, нур сибеп, бөтен йөз-кыяфәтен яктыртып тора.

Әйе, бу чыннан да хатыны иде. Кайгыртучан, юатучан, назлы, иркә, иренә һичшиксез ышанган, аны үзенең пәйгамбәре дип санаган, кирәк булса, күз йомып, аның артыннан җир читенә барачак хатын иде бу.

Мәрьям күңеленнән генә үзен аның белән янәшә куеп, чагыштырып карады. Кырыс холыклы, сөю-назын эченә яшерә торган, таләпчән Мәрьям белән бу хатынның арасы – җир белән күк арасы. Бу хатын Шәүкәттән «Джоконда»га тиң картина язуны таләп итмәячәк, киресенчә, иренең каләме салган һәр тапны сокланып кабул итәчәк, күккә күтәреп мактаячак.

Зәңгәр күзләр бер мизгелгә Мәрьямгә текәлделәр. Аларда гаҗәпләнү чагылды. Белә иде микән ул дөньяда Мәрьям барын?

Светофорда яшел ут кабынуга, алар култыклашып урамны кичтеләр. Мәрьям бу якта калды. Шәүкәтнең кулындагы сумканы шунда гына күрде ул... Хатынының кара сумкасын тотып бара...

Шул көннән алып кулыннан эш төште Мәрьямнең. Ундүрт катлы кунакханә проектлаштырырга тиеш иде ул. Иртән эшкә килә, өстәле янына утыра, кәгазьгә тегеләй дә сызгалап карый, болай да, тик юньле әйбер чыкмый...

Ә Морат ял итә. Башына, нервыларына вакыт-вакыт ял биргәләмәсә, ул андый киеренкелек белән эшли дә алмас иде. Әмма, ял итәм дигәндә дә, тик утыра белми, шук малай шикелле, кызык ясарга җай эзли.

Дөньядан хәбәре китеп, уйга чумып утырган Мәрьям аның өчен яхшы табыш булды. Ул озын итеп скрепкалар тезмәсе ясады, аның бер очын, узып киткән арада, сиздерми генә Мәрьямнең итәгенә беркетте. Аннары бик тырышып, линейка, циркуль белән сызып, җилем белән ябыштырып, калькадан очлы калфак ясады. Аны кызылга, яшелгә буяды да, арттан килеп, аны хәсрәт дәрьясына чумып утырган Мәрьямнең куе кара чәчләренә сиздермичә генә кадап куйды. Бүлмәдәгеләр, кайсы стенага борылып, кайсы өстәлгә иелеп, пырх-пырх көлештеләр: шамакай калфагы киеп, моңаеп утырган хатынның кыяфәте чыннан да көлке иде.

– Мәрья-әм! Авызыңны ачып утырма! Вилданың көньякта нишләп йөри дип беләсең?! Җәлләмә, бир йөз тәңкә! Барыйм да компромат җыеп кайтыйм үзеңә!

Мәрьям, шамакай калфаклы башын күтәреп, Моратның сүзен аңлап җиткермичә, төссез тавыш белән:

– Нәрсә ул компромат? – диде.

– Компрометирующий материал. – Морат бөгелә-сыгыла көлә. – Көньяк кояшы тәнне генә түгел, йөрәкне дә кыздыра. Ир түгел, фәрештә дә чыдамас. Пляжда берәр ханым белән терәлешеп кызынып ятканын сиздерми генә рәсемгә төшереп алам да – менә сиңа компромат.

Бүлмәдәгеләр тыела алмый көләләр. Мастерскойга, җил-җил атлап, Ирина Сергеевна килеп керде.

– Ха-ха-ха! – дип рәхәтләнеп көлде ул. – Әллә сез цирк өчен клоунны үзегездә әзерләмәкче булдыгызмы? Ни кидең син, Мәрьям?

Мәрьямнең берни аңламый үзенә карап торганын күргәч, башындагы калфагын салдырып, алдына куйды, үзе мастерскойның аргы башында эшкә чумгандай өстәленә карап утырган Моратка бармак янады:

– Синең эшеңдер әле, юньсез!

Ирина Сергеевнаның күңеле һәрвакыттагыча шат, дәрте ташып чыккан.

– Ну, ничек, Мәрьям, эшләр? Барамы? Минем янга кереп тә чыкмыйсың, ә? Әллә үпкәләдең инде?

– Юк, үпкәләмәдем. Йомышым булмады.

– Йомышың булмаса да кер. Әйдә әле, әйдә!

Коридорга чыккач, местком председателе проект белән кызыксынды. Казанда иң биек бина булачак бит ул. Ничегрәк куелачак? Беренче каттаниләр була? Ундүртенче катында?..

– Белмим әле, – диде Мәрьям. – Задание күптән түгел генә алынган. Уйланып бетмәгән әле. – Ул сизеп тора: Ирина Сергеевнаның әйтәсе килгәне бөтенләй башка, эшләнмәгән проект, сызылмаган эскиз исә сынықка сылтау гына.

– Менә нәрсә, – диде ул ахырда, – әлбәттә, бу минем эш түгел... Шулай да, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган өлкән хезмәттәшең буларак, бер киңәш бирмәкче идем... Дөресрәге, сорамакчы идем: тормышлар ничек бара?

– Зарланырлык түгел.

– Хикмәт шунда... Менә Аитов... Яхшы рәссам, анысына сүзем юк. Шулай да теләсә ни әйт, синең ничек яшәвең, артыңнан нинди сүзләр йөрүе минем өчен барыбер түгел.

– Соң инде, – диде Мәрьям, үзе дә сизмәстән.

– Ничек «соң»? Ни булды?

– Киңәшегез соңга калды.

– Но, Мәрьям, син барын да уйлап эшлә, барын да. Гаиләне төзү җиңел, саклап калу бик авыр. Сакламасаң, бик тиз җимерелә ул. – Ирина Сергеевна бераз сүз сайлап торды. – Ну, что ж, ихтыярың, әлбәттә. Мин синнән шуны гына үтенәм: уйла, Мәрьям, ныклап уйла. Сез хәзер икәү түгел, алтау! Ялгышмасам, Аитовның улы бар бугай?

Мәрьям нидер әйтергә теләде, ирен читләре калтырап куйды, ләкин ул дәшмәде, башын түбән иде.

Уйламаган кая! Тик уйларның очына чыгып кына булмый.

Бер яктан карый да, беркем белән, бернәрсә белән исәпләшмичә, мәхәббәте өчен көрәшергә дигән карарга килә. Теге хатын, ике арага кереп, Шәүкәтне тартып алган иде. Хәзер аның чираты, ул да газаплансын, ди.

Икенче яктан карый да, хатынның нурлы зәңгәр күзләрен исенә төшереп, үзалдына кызарынып куя. Шиксез, ул хатын Шәүкәтне ярата. Аның мәхәббәтен җимереп, кеше бәхетсезлегендә бәхетле

булырга омтылу дөрес эшме? Өстәвенә Шәүкәткә дә ул хатын мәхәббәтсез, күңел кайтаргыч түгелдер, мөгаен; әнә бит алар ничек матур итеп, икесе бер адымнан атлап баралар. Җитмәсә, Шәүкәт аның сумкасын тоткан!

Ирина Сергеевнаның сүзләре болай да әрнегән ярага тоз сибү генә булды.

***Чигенү***

Казансу өстендә вак дулкыннар шаяра. Алар йөгерешеп киләләр дә, бетон ярга бәрелеп, кире чигенәләр.

– Кара әле, кара! – ди Мәрьям Шәүкәткә. – Нидер йөгереп йөри түгелме?

– Юк ла, дулкын шулай сугыла.

Алар бетон ярда офыкка якынаеп килгән кояшка карап утыралар. Кечке йомшак нурлар шаян дулкынчыклар белән уйный. Табигать көндезге эсседән соң иркенәеп тын ала.

Мәрьямнең йөзе уйчан, Шәүкәт тә, нидер сизенгәндәй, җитди чырайлы. Аның учында Мәрьямнең кулы.

– Шәүкәт, мин күргәзмәдә булдым.

Шәүкәтнең тәне сизелер-сизелмәс тетрәнеп куйды. Әллә шулай тоелды гынамы?

– Ну, ничек соң?

Мәрьям дулкыннардан күзен алмый...

– Син андый түгел идең, Шәүкәт...

– Ну, әйт, кай җире ярамаган?

– Барысы да әйбәт, һәммәсе тиешенчә. Тик кураең гына син теләгән көйне уйнамый.

– Нинди көй уйный соң ул?

– Ул гомумән уйнамый. – Мәрьям, гаепле кешедәй, башын аска иде. – Гафу ит, миңа көтүчең таяк кабып утыргандай тоелды.

Шәүкәт кесәсеннән сигарет эзләргә тотынды.

– Акыл сатарга яратасың син, менә нәрсә. Гомумән, бер эше буенча гына кеше турында фикер йөртеп булмый әле. Минем иҗатымда кайбер җитешсезлекләр бардыр, булмый калмас. Шуңа менә укырга керәм дә бит инде. Осталардан сабак алгач, тәҗрибә туплагач, курае да сызгырыр, башкасы да булыр.

Тагын тынлык. Дулкыннар бер-бер артлы бетон ярны ялый. Шәүкәт сигаретын сындырып суга ыргытты. Аннары Мәрьямнең битен учларына кысып, йөзенә туры карады:

– Син бит миңа, гений булмасаң да, гади Шәүкәт булып калсаң да яратырмын, дигән идең...

– Әйе, әйткән идем.

– Хәзер башкача уйлыйсыңмы?

– Юк. Хәзер дә шулай уйлыйм... Шәүкәт булып калсаң... дигән идем шул мин...

Шәүкәт бу сүзләрнең серенә төшенә алмагандай итеп карады, дәшмәде. Назлы дулкын бетон яр кырыеннан, елгыр җәнлектәй, берничә тапкыр уйнаклап узды.

– Тагын акыл сатасың. Ни дип әйтүең инде бу, үзгәргәнсең дисеңме?

– Әйе, син танымаслык булып үзгәргәнсең!

– Сиңа ярап булмас. Җюри картинага яхшы бәя бирде.

Сүз шушылай дәвам итсә, икесенең дә бөтенләй кәефе кырылачагы көн кебек ачык иде.

– Күргәзмә тиздән ябыла. Син китәрсең инде... Ә мин...

Бу Мәрьямнең батырчылык итеп киләчәк турында сүз башлавы иде.

– Ә син изге нияттә бул! – диде Шәүкәт ваемсыз гына. – Институтка гына керим, калганы җайланыр. Ә син минем янга килерсең. Һөнәрең шәп, кайда да эшкә урнашырлык.

Мәрьям Шәүкәтнең бу сүзләрен зарыгып көткән иде, әмма, ишеткәч, нилектәндер сөенә алмады. Һәммәсен артык шау-шу куптармыйча гына хәл кылырга җай чыгып тора бит югыйсә. Шәүкәт укырга керү сылтавы белән Мәскәүгә китә. Мәрьям аның янына бара. Иренең үпкә сүзләрен, тиргәүләрен озаклап тыңлыйсы да, институтта гаилә бозучы данын күтәреп йөрисе дә булмый. Бар хаталар, үпкәләр, үткәннәр, рәнҗегән кешеләр бирсдә кала – яңа урында тормышны өр-яңадан башлап җибәрергә мөмкинлек туа. Башкалар үз якларын үзләре карар.

Әмма Мәрьям куана алмый, ул үзен кеше бәхетенә кул сузган карак кебек хис итте. Өстәвенә күңелгә якын яшәгән урынынны, яраткан эшеңне ташлап кит, имеш. Ә Фәйрүзә? Яңа тормышта аңа нинди урын бирелер?

– Мин килергә вәгъдә итә алмыйм, – диде Мәрьям.

Шунда Шәүкәтнең, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйганы сизелде...

...Мәрьям урыныннан ничек кузгалып, юлга ничек килеп чыкканын хәтерләми. Бар көченә сиренасын улатып чапкан «ашыгыч ярдәм» машинасы астына керә язгач кына аңына килде ул. Ак

халатлы ир табиб ачык ян тәрәзәнең өске рамына чытырдап ябышкан. Машина каты чыелдап туктады да, Мәрьям читкә тайпылуга, кузгалып, күздән югалды. Кемдер авыр хәлдә, кемгәдер ярдәмгә ашыгалар иде...

### *«Мәхәббәт — чир ул»*

Урамнарда газоннар шау чәчәктә, юкәләрдән баллар тамган чак – татлы истән башлар әйләнә. Таш стеналардан эссе бөркелә.

Ә мастерской, гадәттәгечә, күләгәле, салкынча. Бүлмә эче иркенәеп калган – күпләр ялда.

Морат тагын дөньясын оныткан, шәһәр паркын бизәү буенча эскизлар төзи. Ул баш күтәрми эшли, башкаларга да тын алырга ирек бирми. Мәрьям ишектән килеп керү белән янына чакырып алды:

– Син ни белән шөгыльләнәсең әле?

– Ундүрт катлы гостиница миндә. Шуның эскизларын ясыйм.

– Анысын беләм! – Түземсезлектән Моратның йөзенә кызыллык бәреп чыкты, күзлек пыялалары ялтырап куйды. – Хәзер ни хәлдә соң ул?

– Менә Кольцо ягы фасадын эшлим...

Морат, сабырлыгы төкәнгәнен белдереп, урыныннан сикереп торды да, тавышын күтәреп:

– Ни булды безнең архитекторларга? – диде. – Бу ни хәл? Эш муеннан! Әнә тагын бер ресторанга индивидуаль проект төзергә кирәк. Ә бездә безобразие! Эшкә күңел бирү юк, җаваплылык юк! Кайчаннан бирле бер гостиницаның фасады да эшләнмәгән!

Морат, сүзен төгәлләп, кире урынына утырды һәм көлемсерәп торган Мәрьямгә, кит дигәндәй, кул селтәде.

Мастерской җитәкчесе Шәехзадин өчен бар дөнья архитектура белән чикләнгән иде. Ул үз тирәсендә эшләгән кешеләрнең ничек яшәгәнен, ни уйлаганын белми дә, белергә дә теләми. Аныңча, кеше эш турында, шул проектлар турында гына уйларга тиеш. Ул, Мәрьямнең күңел төшенкелеге, боеклыгы белән һич исәпләшмичә, аннан эш таләп итеп торды һәм шуның белән, үзе дә сизмәстән, архитектор Закированың газаплы кичерешләрен җиңеләйтте, аның күңелендәге боз катламын чак кына булса да юкарткандай итте.

Кичке уңайда Газиз кергән иде, Морат белән бер-ике авыз сүз сөйләште дә илтифатсыз гына Мәрьямгә дәште:

– Гостиница вестибюленә оформление эшләдем мин. Сиңа ошармы, юкмы?

– Кайчан алып киләсең соң?

– Әле Жилплощадкадан кайтып килә идем. Юл уңаеннан гына сугылуым. Әйдә, барып карыйсыңмы, машина ишек төбендә тора...

Мәрьям, җибәрәме соң дигәндәй, Морат ягына ишарә ясады.

– Әй, Морат, – диде Газиз, тавышын күтәреп. – Закирова белән объектка барып кайтыйк әле!

Морат, бәйләнмәгез әле дигәндәй, иңбашларын гына сикертеп куйды.

Заманында Шәүкәт Газиз турында «дилетант», ягъни күп нәрсәдән хәбәрдар булса да, иҗатка сәләтсез кеше дигән иде. Газиз бу еллар эчендә иҗади яктан бик нык үсте, ул ясаган сыннар берничә күргәзмәгә куелып яхшы бәя алды. Өстәвенә шәһәрне бизәү өчен шактый паннолар ясады, һәйкәл өчен проект төзеде.

Мастерскоена кергәч, өстәлгә биш-алты эскиз җәеп салды ул: теләсә кайсын сайлап ал. Һәркайсы бик пөхтә итеп, зур төгәллек белән эшләнгән, үзенчәлекле, күңелгә ятышлы. Менә хәзер шуларның берсен проект авторы сайлап ала, ә калганнары ташлана... Мәрьямгә бу әрәм хезмәт булып күренде.

– Ник шулкадәр күп эшләдең? Бер-икесе дә бик җиткән булыр иде.

– Бу бер өлеше генә әле. Калганнары, минемчә, карап торырлык түгел.

Газиз стена буендагы киштәләрнең берсеннән кәгазьләр алып, бер-бер артлы өстәлгә җәйде:

– Бусында формасы матур түгел... Бусында төсләре табылмады... Бусы артык тыгыз бизәкле... бусы сыек. Хәер, үзең кара...

Ул үз эшенә чит күз белән карый белә һәм аек фикер йөртә. Аның шулчаклы күп эшләвенә, үз-үзенә бу кадәр таләпчән булуына хәйран калырлык иде. Мәрьям дә һәр проектның берничә төрлесен ясый, эзләнә, тик болай ук төгәл-пөхтә итеп эшләми.

– Йә, кайсы ошый? – диде Газиз.

– Барысы да ошый... Менә бусы бигрәк тә.

Газиз сурәтләрнең берсен генә калдырып, калганнарын җыеп алды.

– Нәкъ шунысын сайлап алырсың дип уйлаган идем.

– Проектны кире каксалар, күпме хезмәтең әрәм була инде, – диде Мәрьям.

– Минемчә, проект кабул ителәчәк. – Газиз өстәлне әйләнеп чыкты да, Мәрьямгә каршы утырып, сигарет кабызды. – Мин кайбер кешеләр белән сөйләштем. – Ул сынын турайтты, эреләнеп киткәндәй булды.

«Карасана, бу да кыланчык икән», – дип уйлады Мәрьям.

Эш көненең ахыры булуга карамастан, кунакка барырга җыенгандай чиста-пөхтә иде ул, арыганлыгы тамчы да сизелми. Җиңнәре сызганулы ак күлмәгендә кер заты түгел, бер җыерчык та юк. Дулкын-дулкын куе коңгырт чәченең ник бер бөртеге тузгып чыксын. Ул тезен чәнчеп утырган да, калын иреннәрен турсайтып, түшәмгә төтен боҗралары очыра. Мәрьям бүлмәне күздән кичерде: шкаф өстенә планшетлар, киштәләрдә балчыктан, гипстан ясалган, агачтан уелган эреле-ваклы сыннар, бюстлар тезелгән.

Бүлмә җыйнак кына, әйберләр ишле булуга карамастан, тәртип, чисталык. Бусаганы атлауга борынга кергән буяу исе үзе үк күңелне дулкынландыра шикелле. Бу гади эш урыны гына түгел, биредә кеше иҗат итә, аның күңеле гүзәллеккә, матурлыкка омтыла.

– Әллә бераз позировать итәсеңме? – диде Газиз, тынып торганнан соң.

– Син минем портретны тагын да яхшырак итеп ясамакчымы?

– Эшләп бетереп булмады бит. Вакыт тапмадың. Кая соң әле ул?

Газиз сигаретын сүндерде дә шкаф артыннан таныш рамны тартып чыгарды.

– Менә икән!

Ул рамны урындык аркасына терәп куйды да өске утны кабызды. Бүлмә эче шактый караңгыланган икән, Мәрьям ирексездән күзен йомды.

Киндердән аңа калкурак яңак сөякле, тулы ирен читләренә елмаю кунган кыз карады. Аның озынчарак уелган күзләре дөньяга могҗиза көтеп карый. Моннан алты ел элек Мәрьям шушындый булды микәнни?

Ул сумкасыннан көзге чыгарып карады. Аннары янә портретка төбәлде. Әйе, бу ул – Мәрьям, тик аннан соң нык үзгәрде шул инде. Хәзер аның күз карашы моңсу, иннек сөрткән иреннәрендә елмаю галәмәте юк, күз төпләрендә вак җыерчыклар беленә башлаган. Мәрьям, көрсенеп, көзгесен сумкасына яшерде.

– Да-а, – диде Газиз, сузып кына. – Синең особый чагың иде шул ул. Гашыйк идең син. Ләйлә кебек. Әйе, Ләйлә, Зөһрә, Джульетта һәм инженер Закирова. Хәер, ул чакта фамилияң башка иде бугай.

Мәрьям моңсу көлемсерәде.

– Син мине хәзер гашыйк түгелдер дип беләсеңмени?

– Ну... хәзер инде... – Газиз сүз табалмый торды. Портрет янындагы урындыкка утырып, карашын түшәмгә төбәде. Аның һәммәсен дә белгәне, тик бу хакта сүз кузгатырга кыймаганы сизелеп тора иде.

– Йә, әйт инде... нәрсә «хәзер»?

Газиз тирән итеп сулыш алды.

– Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Мәхәббәтнең бигрәк тә. Унҗиде-унсигездә гашыйк була кешеләр. Яшь чакта башны югалтып хисләргә бирелү табигый. Тик инде, әйтик, егерме биштән узгач, акылны югалту килешми шул. Бу инде мәхәббәт түгел, чир дигән сүз. Кырыкка җиткәч, скарлатина белән авырган кебек, кешене көчен-җегәрен ала. Ир белән хатын арасындагы мәхәббәт иҗатка ярдәм итә дигән сүзгә ышанмыйм мин. Гашыйк булгач, хәтта бөек Паганини да скрипкасын ташлаган! Шул булдымы файдалы нәрсә!

Газиз кызып китте, урыныннан торды да, ишек янына басып, сүзен дәвам итте:

– Мөнәсәбәтләрдә акыл өстенлек итәргә тиеш! Акыл! Ә хисләр, мавыгулар сәнгатькә, иҗатка бирелсен. Мондарак кил әле!

Мәрьям, хәйран булудан авызын ачып, урыныннан кузгалды да бер-ике адым ишеккә таба атлады. Газиз, алтын балдаклы кулы белән артистларча ишарә ясап, почмактагы тумбочка өстеннән ак тукыма кисәген алды. Анда груша агачыннан уелган сын килеп чыкты. Мәрьямнең келт итеп исенә төште: «Исәнме, кояш!» дигән сын иде бу.

Кеше тәне төсле алсу йөз тере, җанлы кебек. Чибәр, яшь кыз, кулларын күкрәгенә куеп, сөенеп, дулкынланып карап тора.

Моңарчы Газизнең әсәрләре декоративрак планда була иде. Хиследек, лиризм җитеп бетми кебек аларга. Ә моны күргәч, Мәрьямнең йөрәге сулкылдап куйды: Шәүкәтнең «Җиде төн уртасында» дигән картинасы исенә төште. Үзәккә үтә торган моң, якты сагыш бар иде анда. «Бу син», – дигән иде Шәүкәт, картинадагы кызны күрсәтеп. Газиз белән алар икесе бер үк вакытта диярлек Мәрьямнең портретын ясаганнар иде. Кем хаклы булды икән? Аның Газиз сурәтләгәнчә бәхетле, шат күңелле чаклары да булмады түгел, булды. Ул проектларын дәртләнеп төзегәндә – шундый. Фәйрүзәсен тезләренә алып иркәләгәндә, сөйгәндә – шундый. Шәүкәт белән икәүләп хыялый кала төзегәндә шундый булды.

Ә кайчак ул Шәүкәт тасвирлаганча боек, моңлы, уйчан. Менә хәзер дә адашып калган вакыты аның, башкайларын кая куярга белми аптыраган чагы.

Кем хаклы: тормышка оптимистларча җиңел караучы, эшчән һәм булдыклы Газизме? Күп уйланучан, хискә бирелүчән, сизгер күңелле, үпкәчел Шәүкәтме?

Хәзергә Газиз үзенең иҗаты белән Шәүкәттән өстенрәк икәнен исбат итте. Синең эчеңдә нинди хисләр кайнавында кемнең ни эше бар? Кешеләр иҗатыңа, хезмәтеңә карап бәя бирәләр бит...

Газиз Мәрьямне соклanудан телсез калган дип белде, ахры, бик канәгать кыяфәттә:

– Менә күрдеңме инде, – диде дә сынны бик кадерләп, ак тукымага төрде.

## *Кояш баегач*

Мәрьямнәр тәрәзәсенә кояш төшкә кадәр генә карый, кичен йортның икенче ягына күчә. Кояш баер алдыннан, каршы йортларның тәрәзәләрендә һәм «Пампушки»ның пыяла стеналарында шәфәкъ кызыллыгы чагыла башлагач, бүлмә караңгылана, моңсулана, почмакларга эчпошыргыч күләгәләр кереп оялый.

Мәрьям өенә бик соң кайта, үзен кая да булса барырга, йөрергә, кино карарга мәҗбүр итә. Өйгә кайтып керүгә, ятар вакыт җиткән булсын. Яткач та йокыга китәрлек дәрәҗәдә арылсын.

Бу йорт аңа чит. Ул бернәрсәгә дә үкенми, үзен гаепләми. Әгәр гаебе бар икән, аның өчен җәзасын алырга риза. Ул инде бу йорттан чыгып китәчәген күңеленә беркетеп куйган, бу турыда алдан ук Вилданга хәбәр салмакчы иде, тик аның адресын, кайчан кайтачагын белмәгәнгә, хат яза алмады. Вилданның үзеннән ике ай буена бер хәбәр дә булмады.

Кичләрен авыр Мәрьямгә – эчтә янган хәсрәт утыннан тыны кысыла, күңеле тула, ә елый алмый. Кызын исенә төшереп кенә үзенә юаныч таба. Аны тизрәк авылдан алып килеп, кочагына кысса, иреннәре белән тыгыз битенә орынса, куллары белән йомшак чәчен сыйпаса, җиңелрәк булыр иде... Ләкин авылга кайтып килү өчен өч көн вакыт кирәк, ә Моратның бу турыда ишетәсе дә килми: эшнең шулчаклы күп вакыты, кая ул! Менә теге атнада, менә киләсесендә, дип сузып йөртә.

Өйгә соң кайтса да, Мәрьям тынгы тапмады, кулына шөгыль эзләде. Һәрнәрсәне урынына куйды, тузан сөртеп, идәнне юып чыгарды. Радионы бар көченә кычкыртып сөйләтте. Бөтен утларны кабызды. Телевизорны тоташтырды. Ләкин өйгә ямь кермәде шикелле, почмакларга сагыш кереп оялаган кебек иде. Нигә болай соң?

Чәй кайнатып эчәргә кирәк, булмаса! Соңгы вакытта газ да сирәк кабызыла.

Инде утырып чәй эчим дигәндә генә, сискәндереп ишек кыңгыравы чәрелдәде.

Бусага артында Вилдан басып тора иде. Йөзе гадәттәгедән дә карарак төсле. Кояшта янгангамы, әллә кәефсезлектәнме?

Мәрьям ирексездән артка чигенде:

– Син... кайттың дамыни?

– Күрәсең ич. Көтми идеңме әллә? – Вилданның тавышы карлыккан. Ул чемоданын почмакка атты да, тузанлы ботинкаларын да салмыйча, бүлмәгә керде, һәм, радионы туктатып, телевизорны сүндереп, урындыкка утырды. Күзләрен бер ноктага терәгән килеш, хәрәкәтсез калды. Мәрьям, яулыгын салып, чуар ситсы халатын тарткалап куйды да диванга барып утырды.

Хатынының сүз башлаганын көтә иде булса кирәк Вилдан. Ул бер сүз әйтмәгәч, ниһаять, хәрәкәткә килеп, күкрәк кесәсеннән солдат хаты төсле иттереп өч почмаклап бөкләнгән кәгазь кисәге тартып чыгарды да өстәлгә ыргытты:

– Мә, укы!

Хат яхшы сызым кәгазенә тушь белән язылган, имзасы юк. *«Син анда йөргән арада монда хатының тик кенә тормады...»* Әһә, ирештергәннәр. Иренмәгәннәр, Вилданның кайсы шәһәрдә, нинди заводта икәнен каян белгәннәр диген!

Хат язучы берне биш иткән. Андыйлардан намус саклауны, дөресен генә сөйләүне таләп итеп булмый, билгеле. Баш ватып торасы юк, кем язганы мәгълүм... Камәрия кулы сизелеп тора. Мәрьям елмаюдан чак тыелып калды. Камәриянең дә файдасы тияр икән. Ул бу хаты белән Мәрьямгә ничаклы яхшылык эшләгәнен үзе белмидер әле, бичара. Беренчедән, хәзер Вилданга мин синең белән яши алмыйм, моңа үзем гаепле, дип аңлатып торуның кирәге юк. Икенчедән, бу хатны Вилдан моннан берничә көн элек алган, хәзер инде кызуы сүрелгәндер...

Ул, шоколад төсендәге күзләрен Мәрьямгә төбәп, җавап көтә иде.

– Йә, ни диярсең?

Әгәр Мәрьям: «Юк ла, бер явызы араны бозарга маташа, ышанма», – дисә, Вилдан, әлбәттә, хатынына ышаначак һәм өстеннән тау төшкәндәй хис итәчәк иде. Ләкин Мәрьям, аның күзләренә туры карап, эченнән тартып чыгаргандай авыр итеп:

– Мин аның белән очраштым шул... – диде.

Вилдан чайкалып китте. Хатынының күзгә карап: «Мин гаепле», – дип утыруы аның зиһенен таратып җибәрде.

Мәрьям урыныннан торды да стена эчендәге шкафтан мендәр, матрас, юрган, чиста җәймәләр алды. Кухня идәненә урын җәйде. Ишекне эчке яктан урындык белән терәтеп куйды да, утны сүндереп, йокларга ятты. Өстәлдәге бер чынаяк чәй эчелми калды.

Күктә ялгызы нур чәчеп йөргән тулы ай тәрәзә аркылы Мәрьямнең йөзенә карады да күңелне бушлык, тынлык белән тутырды. Барысы да хәл ителгән, уйлыйсы да кайгырасы юк. Ябык ишекнең теге ягында идәнне шыгырдатып әрле-бирле йөрүче кеше аның өчен чит-ят хәзер...

Ә бәйләнчек ай тәрәзәдән күзгә туры карый. Ялгыз ай, бәхетсез ай! Хәер, ялгызлыгын сизми ул, ахры, ничә карама – чырае якты. Ә менә кеше ялгызлыкка дучар ителсә, аның яшәвеннән ни мәгънә кала? Менә шушы минуттан Мәрьям юк булса, аңа беркем дә офтанмас иде кебек. Вилдан хыянәтче хатыныннан котылыр, кызы Фәйрүзәсе аның янында калганга сөенер генә иде. Фәйрүзәгә дә юньсез әни ник кирәк?

Мәрьямне башка беркайчан да күрмәячәген белгәч, Шәүкәт тә көрсенеп кенә куяр, мөгаен. Сөешкән чакта җанын бирердәй, бер көн дә аерым яши алмас кебек иде, аралар ераклашуга онытa да куя. Бик тә гаҗәп инде бу, баш җитәрлек түгел. Төзелеп беткән, ләкин тормышка ашмаган проектлар кызганыч... һәм Фәйрүзә, Фәйрүзә... Әнисез ул ничек яшәр?..

Кызын күз алдына китергәч, Мәрьямнең күңелен тыелгысыз бер теләк биләп алды: аны кочагына алырга, тәненең хуш исен күкрәк тутырып суларга. Калганы соңыннан...

### *Һәркемнең үз кайгысы*

Урам тулы халык арасында кеше ялгыз. Беркемнең беркемгә кирәге юк кебек. Багананы да, кешене дә бәрелмәс өчен әйләнеп узасың. Мәрьям дә ялгыз бүген. Һәм шушы миллионга якын халкы булган шәһәрдә барып бәрелер кешесе, сыеныр почмагы юк аның.

Ябыгып, сулыгып киткән Вилдан белән сөйләшмиләр, бер квартирада икесе ике почмакта чит кешеләр кебек яшиләр. Тора-бара бу хәлгә күнеккәндәй булдылар хәтта. Мәрьям кичләрен ашарга хәстәрләгән була. Ә бүлмәдә икенче берәү, гәрчә ул чит-ят кеше булса да, ач утырганда, тамагыңнан ничек ризык үтсен?

Мәрьям, кухня ишегеннән башын тыга да, телевизор тавышы аша ишетелер-ишетелмәс итеп:

– Ашыйсың килсә, кер, итле бәрәңге пешердем, – ди.

Сүзләр әкрен әйтелсә дә, Вилдан ишетә. Бераз уйланып торгач керә. Кара-каршы утырып тын гына ашыйлар, аннары Вилдан:

– Рәхмәт яусын!.. – дип, бүлмәгә чыгып китә.

...Мәрьям, утны сүндереп, гадәттәгечә идәндәге матраска яткач, Вилдан кухняга керде.

– Ярар инде, азаплама үзеңне. Бүлмәгә чык.

Мәрьямнең йөрәге чәнчеп куйды. Вилдан да ялгыз бит дөньяда, аның да беркеме юк ич! Ләкин аның кайнар учын иңендә сизгәч, бөтен тәне куырылып китте, һәм ул ихтыярсыз читкә тайпылды.

– Кирәкми!

Хәер, бу сүз артык иде, Вилдан аның тайпылуыннан барысын да аңлаган иде...

Хәзер инде бергә тору мөмкин түгел иде.

...Дөньяда ваемсыз кеше бармы икән? Әнә Саҗидә апа коридор почмагында моңаеп басып тора. Ак чыраендагы шадралары гадәттәгедән ныграк беленә, гадәттә елмаючан күзләре дымлы. Тагын Морат каты бәрелгән. Саҗидә апа менә дигән оста, пөхтә копировщица. Җентекләп, җиренә җиткереп эшләргә ярата. Морат исә ашыктыра, кабынып киткәндә хәтер саклап тормый. Ә Саҗидә апаның күңеле сынык. Ире үлгәч, тәмам боекты. Күңелен курку басты: «Куып чыгармасалар ярар иде, кызларым гына чирләмәсен инде, сугыш кына була күрмәсен...»

– Бераз сулу алырга чыктым әле, – диде ул Мәрьямгә. – Моратның да җене чыкты бу арада. Карале, Мәрьям, җитешә алмый дип куып чыгармас бит, ә?

– И-и, Саҗидә апа, ни сөйлисез сез? Сезнең кебек копировщицаны каян тапсын ул? Юкка хафаланып йөрмәгез. Гариза бирсәгез дә, җибәрми ул сезне.

Саҗидә апа кыска, йомшак бармаклары белән Мәрьямнең иңен сыйпап куйды.

– Гамир хәсрәтеннән айный алмыйм. Ир – алтын багана, бергә чакта кадерен генә белеп бетермибез. Кызларымның үз тормышы, аларга да гел елап утырып булмый. Эчемне бушатканчы рәхәтләнеп сөйләшер кешем дә юк ичмаса.

Аның ачык күзләреннән мөлдерәп яшь бөртекләре тәгәрәде. Яшь аралаш елмаеп:

– Син дә минем зарымны тыңлап туйгансыңдыр инде, – диде. – Һаман үземне генә туглыйм. Син ничек яшисең соң? Вилдан кайттымы инде?

– Кайтты да бит...

Мәрьям, теш арасыннан сыгып кына, гаиләнең бозылып китүен, үзенең квартира эзләвен әйтте. Саҗидә апа күбесен белә, белмәгәнен төпченә торган гадәте юк.

– Әйдә бүген безгә кайтыйк әле, – диде. – Коймак пешереп, чәй эчәрбез, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз. Вилданга шалтыратып әйт тә, эштән туры безгә китик!

Шуннан соң Мәрьям өенә кайтмады. Берничә көннән соң кереп, Фәйрүзәнең әйберләрен җыеп алды, үзенең кирәкле кием-салымнарын да чемоданга салды.

Шкафның өске тартмасында аның бизәнү әйберләре салынган шкатулка тора иде. Мәрьям аны да ачып карады. Фирүзә кашлы йөзекне Вилдан, кызы тугач, бүләк иткән иде. Гәрәбә беләзекләр – 8 Мартка бүләге. Марҗаннарне дә төрле елларда бәйрәмнәргә ул алып бирде. Бизәнү әйберләренең кыйммәтен белә, хатынына нәрсә килешкәнен дә яхшы сизә һәм аны бизәргә тырыша иде ул. Мәрьям бүләкләрнең барысын да, шкатулкага салып, урынына куйды һәм шулчак кечкенә генә ят тартмачык күреп алды. Ачып караса – алка, кыйммәтле кызыл таш кан тамчысы кебек тамып тора. Моны, күрәсең, Вилдан көньяктан алып кайткандыр, тик тапшырырга җай тапмагандыр. Мәрьям, көзге каршына басып, алканы киеп карады. Килешә. Иренгә шундый иннек яксаң, кара күлмәк кисәң, искиткеч буласы. Кара чәч арасыннан күренеп-күренеп китәр, йөзгә затлы, серле төсмер бирер... «Менә юләр, – диде ул үз-үзенә, – бу бүләккә хакың юк бит инде синең». Ул алканы салып кире куйды, бүлмәгә соңгы тапкыр күз йөртеп чыкты, квартира ачкычын өстәлдә калдырды. Аннан әкрен генә ишекне япты. Инглиз йозагы челт итеп бикләнде...

Менә шулай бетте бу тарих. Менә шулай күз башында нокта куелды аңа. Бу хакта кәгазьләр язып та, мәсьәләне җыелышка куеп та, берни дә үзгәртеп тә, төзәтеп тә булмый инде.

...Мәрьям һаман тәрәзә янында басып тора иде әле. Аһ, җитәр инде, җитәр, искә төшергән саен йөрәк өзгәләнә, уйлаган саен буталасың гына. Эштә генә һәммәсе ачык: хыялланасың, газапланасың, тырышасың – ахырда барыбер көн аязган кебек була, зиһен ачылып китә, башка көтелмәгән уйлар килә, йөрәк сөенечтән талпынып тибә. Иҗат куанычын кичерә белгән кеше үзен тома бәхетсез итеп тоя алмый! Ташлыяр проектын эшләгәндә, Мәрьямнең табышлары шактый булды.

Тик менә аның тормышка ашырылуы да шик астында калган бит әле... Ничек аны якларга, каян көч, таяныч табарга?

Мәрьям, авыр сулап, урыныннан кузгалды. И-и, сәгать икенче киткән бит инде. Саҗидә апа ничек тәмле итеп, рәхәтләнеп йоклый: әйләнми дә, кымшанмый да. Ә Фәйрүзә, гадәтенчә, юрганын тибеп очырган. Мәрьям, аның өстен ябып, диван кырыена салынган кулын үпте. Аның бөтен барлыгын җылы дулкын юып узгандай булды. Җебеп төшәргә ярамый, нык булырга кирәк иде. Фәйрүзә хакына, аның киләчәге матур булсын өчен яшәргә, көрәшергә кирәк иде.

### ***Ташлыярда***

Икенче көнне иртәдән кичкә кадәр Ташлыяр микрорайонының баш инженеры Морат Шәехзадин белән өлкән инженеры Мәрьям Закирова өстәл янында, башны башка терәп диярлек, эскизлар, саннар язылган кәгазьләр белән мәшгуль булдылар.

Дөресен әйткәндә, Морат эштә бәхәсләшергә бер дә яратмый, шикле мәсьәләләргә катышмаска тырыша. Ләкин эше шундый: ахыр чиктә ныклы бер карарга килергә, аны җитәкчеләр һәм төрле оешмалар каршында теш-тырнак белән якларга кирәк була.

Бу очракта да шулай: проект җитәкчесе Шәехзадин кул куйган кәгазьләргә нигезләнеп шактый эш эшләнгән, чыгымнар тотылган иде инде. Шул ук вакытта аңа каршы язылган шикаятьтә дә дөреслек бар иде. Иң мөһиме, проект сметага сыймаган, ягъни төзелеш алдан исәпләгәнгә караганда күпкә кыйммәткәрәк төшәчәк. Чөнки анда соңгы елларда хурланган, хәтта тыелган «артыклыклар» күп: йортларның алгы якларын сграфитто, төсле смальтадан ясалган мозаика, витражлар белән бизәү күздә тотыла, өстәвенә заказчы бөтенләй искә алмаган объектлар – бакчалар, фонтаннар, хәтта кышкы бассейн төзү планлаштырылган.

Үз вакытында Мәрьям ничек итсә итте, Моратны бу нәрсәләргә күндерде, хәзер исә баш инженер моңа нык үкенә иде. Шул гына җитмәгән, Ташлыяр өчен канны бозып йөрисе генә калган! Авыртмаган башка тимер тарак!

– Юк белән башымны катырасың, – дип сукранды ул. – Җитмеш санасаң да шул инде, сметага сыймыйбыз. Әле дә аптырыйм: ничек риза булдым мин бу эшкә, ә? Ну проекты да ярыйсы шул! – дип куйды ахырда. – Моңарчы мондыйны үткәрә алганыбыз юк иде әле. Кызыгырлыгы да бар.

Үз һөнәренең остасы буларак, иҗади эшне бәяли белә иде үзе.

– Әзер проектны ботарлау күңелле эш түгел. Мине күндердең, хәзер менә заказчикларга сүзеңне үткәреп кара. Күрербез, сейфларыннан акча чыгарта алырсың микән?!

Һәм ул, учы белән шап итеп, өстәлдәге кәгазьләргә сукты:

– Все. Пан или пропал. Бер атнадан Ташлыярга очабыз.

Вакыты җиткәч кенә Мәрьямгә эскизлары тиешенчә пөхтә-матур эшләнмәгән, макеты яхшы ясалмаган төсле тоелды. Макетны бозарга соң иде инде, ә менә эскизларны төзәткәләргә була.

Аның эшен һаман караштыргалап йөргән Шәфикъ абый килде дә:

– Бусы да заказчик кушуы буенча проектлаштырыламы? – дип, кәкре бармагы белән микрорайон өстендә сурәтләнгән ак болыт кисәгенә төртте.

– Хыялый болытыңны да сметага керттеңме?

– Бөтенесе саналды, Шәфикъ абый! – диде Мәрьям, җорланып. – Безнең хыяллар кыйбат тора, әмма һәммәсе тормышка ашачак!

Шәфикъ абый, башын чайкап, аны кызгангандай көлемсерәп карады.

Ташлыярга китәр алдыннан Вилданга шалтыратырга туры килде. Фәйрүзәне бакчадан алырга кирәк булачак иде.

– Ташлыярга проект якларга барам, – диде ул.

– Уң булсын, – диде Вилдан сүрән генә.

– Рәхмәт!

Ташлыярга кичтән барып кунарга туры килде. Мәрьямнең йокысы йокы булмады. Иртәнге сәгать сигез тулганчы ук шәһәр идарәсендә иде инде. Киңәшмә шунда узачак иде.

Залның түрендә «Т» хәрефенә охшатып яшел постау капланган өстәлләр тезелгән. Макетны, сызымнарны бер көн алдан «уазик»ка салып җибәргәннәр иде, залның почмагына кертеп куйганнар икән. Мәрьям макетны тартмасыннан алып урта өстәлгә куйды. Стеналарга сызымнарны ябыштырырга кереште. Гомуми план, ишегалларының, бакчаларның аерым планнары, аларның өстән, яннан караганда күренеше... Электр, телефон, су үткәрү планнары... Күп иде алар, түр стена тоташ капланды.

Мәрьям Шәүкәтне исенә төшерде: сурәтләрдә, сызымнарда аның да өлеше бар иде бит...

Сәгать ике тулганда залга утызлап кеше җыелды. Барысы диярлек җитди кыяфәтле, салмак хәрәкәтле, гомер уртасын узган ирләр. Арада бердәнбер хатын-кыз булып, ул да шактый өлкән яшьләрдәге тулы гәүдәле ханым иде. «Монысы санитария табибыдыр инде», – дип уйлады Мәрьям. Бары кызыл лацканлы зәңгәр форма кигән янгыннан саклау бүлеге начальнигы гына, маңгай өстендәге чәче шактый коелган булса да, утызлар тирәсендәге төз сынлы кеше иде. Кергән берсе, исәнләшеп, стена кырына тезелгән урындыкларга утыра тордылар.

Менә бөтен кыяфәте, бигрәк тә үткен карашы белән бөркетне хәтерләткән кеше, түргә узып, өстәл артына утырды: бу – Ташлыяр райкомының беренче секретаре. Әнә, ап-ак чәчле булса да, җиңел төз гәүдәле, хәрәкәтчән абзый – «Ташлыярнефть» берләшмәсенең җитәкчесе килеп керде, башын чак кына иеп сәлам бирде дә райком секретаре янына барып урнашты. Боларны Мәрьям элек килгән чакларыннан танып белә иде. Ә калганнарын беренче күрүе – алары төрле төзү оешмаларының җитәкчеләре: сантехниклар, электриклар, телефонистлар...

Мәрьям аларны күздән кичерде дә куркып калды: илнең тоткасы, зур кешеләр болар. Мәрьям алар арасында читтән килгән булуы белән генә түгел, кыяфәт белән аерылып тора: яшь ул, шактый кечкенә, җитмәсә, хатын-кыз үзе тагын. Үзләренә тиң күреп кабул итәрләрме? Үзенең хаклыгыңа ышандырып булырмы аларны?

Дулкынланудан райбашкарма председателенең утырышны ачып җибәргәнен дә, Моратның, аягүрә басып, түр яктагы сызымнарга озын указка белән төртеп күрсәтә-күрсәтә ниләр сөйләгәнен дә юньле-башлы аңламады ул. Баш инженер урынның тотрыклылыгына, калку, түбән урыннарына, электр чыбыклары, су торбалары сузуның кыенлыклары, шуларга бәйле рәвештә җир эшләренең күләме турында сөйләде. Шуннан соң гына биналарга, аларның яшәү өчен заманча уңайлы, карап торышка үзенчәлекле, җанга ятышлы булуына күчте.

Баштарак залдагылар тыныч тыңладылар, торган саен кызыксыну арта барды. Ниһаять, чыгымнарның алда күз алдында тотканнан күбрәк булачагын ишеткәч, җитдиләнеп, бер-берсенә карашып алдылар. Хәтта йокымсырап утырган янгын сүндерүче дә, күзләрен зур ачып, Мәрьямгә текәлде.

Морат утыргач, бер мәлгә колакларны чыңлатырлык тынлык урнашты.

– Йә, кемнәрдә нинди фикерләр бар? – диде райком секретаре.

– Сурәтләр матур, анысына сүз әйтеп булмый, – диде нефть берләшмәсе җитәкчесе, утырган җирендә алга иелебрәк. – Заказ биргәнче, без үзебезнең мөмкинлекләр-не кат-кат санаган-исәпләгән идек бит инде. Бәлки, архитектор иптәшләр җитмәгән акчаны табу юлларын да планлаштырганнардыр?

Беразга тынлык урнашты. Берәү дә дәшмәгәч, райком секретаре сүзне архитектор Закировага бирде.

Мәрьям тынычланып киткәндәй булды. Өстәлдән указка алып, бүлмә уртасына, макеты янына чыгып басты. Ул зәңгәр йон костюмнан, ак кофта кигән... Биек үкчәле кара туфлиенең шакылдавы мондый шартларда бераз сәер тоелды.

Аның йөзе агарынып киткән, күзләре кырыс карый иде.

– Ташлыяр тирәсендә урманнар юк, кая карама басулар җәелгән. Урталарында нефть скважиналары гына тирбәлеп утыра, – дип башлады ул сүзен. Баштарак аның тавышы калтыраныбрак чыкты кебек, әмма ул шундук үзен кулга алырга тырышты. Ни әйтәсен кат-кат уйлаган, хәтта ятлап килгән иде ул. – Мондагы халык, минем белүемчә, урманнарның ерак булуыннан зарлана. Елгаларга күп еллар нефть агызылганга, су коену түгел, казларны да якын китереп булмый, дип зарланалар. – Бусын ул нефтьчеләр җитәкчесенең йөзенә төбәп әйтте. – Яңа кала тирәсендә нефть чистарту, тимер-бетон заводлары урнашкан, факеллар дөрли, әледән-әле чокырларга җыелган нефтькә ут төртеп яндыралар. Әгәр яңа каланы агачлык белән уратып алмасагыз, ничек сулыш алырсыз икән? Балаларның сәламәтлеге нинди булыр? – Монысын ишеткәч, тыңлаучыларның карашы үзгәреп киткәндәй булды. – Ташлыярда киң елга юк. Инешләр пычранып беткән. Яшьләр йөзә белми торган булып үссен дисезме әллә? Мәктәптә һичшиксез бассейн булырга тиеш ул. – Мәрьям таякчыгы белән түгәрәк бинага төртеп күрсәтте.

Аннары ул урам-мәйданнарны, биналарны тасвирлап чыкты.

– Әгәр без рәт-рәт итеп бишәр катлы типовой йортлар тезеп чыксак, халык үзен казармага кертеп тутырылгандай хис итәчәк. Шәһәрләрнең гомере озын, анда әллә ничә буын яши. Без төзеп калдырган биналар алар киләчәк буыннарга иң зур мирасыбыз. Аларны килделе-киттеле салырга хакыбыз юк! Матур калада яшәгән кешеләр зыялы, аларның күңеле бай. Кешеләрнең яхшы булуын теләсәк, без матур калалар төзергә тиеш. Чордашларыбыз рәхмәт укырлык, ул-кызларыбыз безне хөрмәт белән искә алырлык булсын.

Мәрьям сүзен тәмамлап, тып-тып басып, урынына барып утырды.

Беразга тынлык урнашты. Һәммәсе, башларын иеп, уйга калгандай утыралар иде. Башларын күтәргәч ни әйтер алар? Мәрьямнең хезмәтенә, алай гына түгел, үзенә нинди хөкем чыгарыр?..

Менә нефтьче тураеп утырды, карашын райком секретарена төбәде. Асылда, шушы ике кешенең сүзе сүз булачак, хөкемне алар чыгарачак...

– Бөтен халыкка хан сарае төзеп бирер идек... Кулдан килсә... – диде нефтьче уйлангандай.

Мәрьямнең сулышы иркенәеп китте. Бу әле хуплау да, проектка аяк терәп каршы чыгу да түгел иде!

– Мин монда түбәләрнең нинди рәк буласын күрмәдем, – диде секретарь, Мәрьямгә карап. – Аларга һаман шулай сумала сылап куелырмы?

Мәрьям аягына торып басты.

– Безнең илдә түбәләр белән шөгыльләнүче юк, чөнки аларны бизәү архитектурада артыклык дип санала, – диде ул. – Шунлыктан кирәкле материаллар да эшләп чыгарылмый.

– Түбәсе рәтле булмаса, йортның коты булмый инде аның, – дип куйды кемдер әкрен тавыш белән.

– Шөгыльләнергә кирәк! – диде секретарь, тавышын күтәрә төшеп. – Авылларда да рәтле хуҗалар түбәсен матур итеп яба. Борынгы затлы калаларда түбәләр сокланып туймаслык.

– Эшлибез, эшлибез! – диде Морат. Аның йөзе куанычтан балкый, күзлек пыялалары да күңелле елтырый иде. – Безнең архитекторлардан эш тормас! Нинди материал таба аласыз, шуннан эшлибез.

Мәрьямгә бүлмә яктырып киткәндәй, һава сафлангандай тоелды.

Әлбәттә инде, берсе дә сикереп торып, аны мактарга керешмәде. Сызымнарга, макетка кызыксынып карадылар, сораулар яудыра башладылар, тегесен болайрак, бусын тегеләйрәк итәргә кирәк иде, дип, теләкләр әйттеләр. Бу сызымнарда тасвирланган йортларны алар үзләренеке, балаларыныкы итеп тоя башлаган иде инде. Архитектор өчен мактауның иң зурысы шушы иде инде.

– Без бер фикергә килдек булса кирәк, – диде райбашкарма председателе. – Проектны биредә әйтелгән киңәшләрне искә алып эшләп бетерү шарты белән, нигездә, кабул итәргә дигән тәкъдим бар. Кем дә кем шушы фикерне хуплый, кулларыгызны күтәрегез!

Мәрьям, башын күтәреп, залга карарга куркып калды.

– Бертавыштан, – диде председатель.

Үзара сөйләшә-сөйләшә таралыштылар. Күбесе тәмәке кабызды. Берәү дә килеп архитекторны котламады, мактау сүзләре әйтмәде, кулын кысмады. Кеше үзенә тапшырылган эшне намус белән башкарып чыккан – алар өчен бу табигый иде. Үзләренең эше башланырга тора, аны ничек ерып чыгарлар – шул хакта уйлый иде алар.

Фәкать Морат кына килеп, урыныннан кузгала алмыйча утырган Мәрьямнең җилкәсеннән кагып куйды.

***Соңгы очрашу***

Җәй, көз үтте, кыш җитте. Мәрьям көннең-көн буе кульман янында басып тора, һәр йортның, корылманың төгәл сызымнарын ясый, аларны күчермәләр ясау өчен Саҗидә апага биреп бара. Берничә атна диярлек инде микрорайонның төгәл сызымнарын сыза. Көннәр буе аягөсте булганга, тез буыннары катып китә. Тик күңеле күтәренке: хыялындагы бәхет каласы күз алдында калка диярсең!

Бик мавыккан чагы иде, артына Саҗидә апаның килеп басканын сизми калган. Йөзе нилектәндер борчулы кебек.

– Шәүкәт килгән бит! – диде ул, пышылдап.

– Кая? – дип, кульман артыннан башын сузып, ишек ягына карады Мәрьям.

– Кереп тормады, мине коридорга чакырып, колагыма гына әйтте. «Мир» кинотеатры янына килсен әле, ди... Очрашырга теләгең булмаса, үзем генә барып әйтермен, көтеп тормасын.

– Нигә сезне мәшәкатьләргә... – диде Мәрьям. – Татарга тылмач кирәкми, диләр, сүземне үзем әйтермен...

Гардеробтан пальтосын, бүреген алып, киенеп урамга чыккач, бер мәлгә баскычта туктап калды ул. Битен талгын җилгә каршы куеп, болытлы күккә карады, күкрәк тутырып, дымсу һаваны сулады. Салкын диярлек түгел үзе, әмма күшектергеч көн иде бу.

Бәлки, кире керергәдер?.. Ләкин юк, борылу мөмкин түгел. Аяклар үзләреннән-үзе тротуарга – кантарланып каткан кар өстенә атлады. Йөрәк тигезсез типте, күзләр әллә каян кинотеатрның ак колонналары яныннан үтеп-сүтеп йөргән халык арасыннан таныш сынны эзләде.

Ерактан ук күреп алды: ул, гадәтенчә, күкрәген киереп, аякларын аерыбрак баскан. Кыска кара кайры тун, козыреклы кара күн бүрек кигән... Менә ул да күреп алды, борылып басты, әмма каршыга ашыкмады, шактый якынлашкач кына берничә адым атлады.

– Исәнме, Мәрьям.

– Саумы, Шәүкәт.

Кулны шактый авырттырып кысты, бармаклары каты, салкын, никтер перчаткасын кимәгән.

– Ник мастерскойга кермәдең?

– Кеше-кара күзенә чалынып йөрисем килмәде. Телгә керүең бар...

Мәрьям көлемсерәп куйды: телгә керү-кермәү турында элегрәк уйлыйсы бар иде.

– Эшеңнән аерган булсам, гафу ит, – диде Шәүкәт.

Мәрьям сәгатенә карап алды:

– Төш вакыты җитеп килә бит, – диде, дулкынлануын яшерергә тырышып, шаярып елмайгандай итте. – Егет бул, кафега чакыр.

Кинотеатр тирәсендә ашап алыр урын юк, алар каршыдагы базар аша үтеп, Шмидт урамына чыктылар. Андагы кечкенә кафега кереп, ике подноска салат, дөге белән кәтлит, компот алдылар. Буш өстәл юк иде, ак шәл бәйләгән апа белән күгелҗем бүрекле кыз янына утырырга туры килде.

Шәүкәт сәнгать мәктәбендә укыта икән, укучыларын мондагы училищега таныштыру нияте белән алып килгән. Шул хакта сөйләшергә булган.

– Ә институт? Син институтка кермәкче идең бит?

Шәүкәт, башын иеп, чәнечкесен тәлинкәсендәге кәтлиткә төрткәләде.

– Институт калып торды әле. Өйдән чыгып китеп булмады. Кызыбыз туды...

Мәрьям йөрәгенә пычак кадалгандай булды. Әмма моны чыраена чыгармаска, елмаерга тырышты. Мондый очракта гадәти сорауны бирде:

– Исеме нинди?

– Аурика.

– Нишләп алай?..

– Ошады...

– Ә-ә, кинодан мыни...

Әле күптән түгел генә кинотеатрларда «Аурика» дигән фильм шаулап узган иде.

– Сәнгатьчә булган икән, – дип чеметтереп алды Мәрьям, үзе дә сизмәстән. Күңелен исә һич көтмәгән уй телеп узды: «Баласына исемне кинодан алып кушкан... Уенчыкка кызыккан малай кебек... Үзәге нык, акылы төпле эти кеше алай итәр идемени?» Элегрәк башка мондый уйлар килгәне юк иде. Мәрьям, бик үк сиздермәскә тырышып, әледән-әле аңа сынап карап алды. Тискәре кара чәчләре һаман шулай маңгаена төшеп йөдәтә, Шәүкәт аны элеккечә кискен хәрәкәт белән төзәтә. Бөтен кыланмышлары җанга якын, тик йөзе, күз карашы... Нур сирпелми, күңелне өтеп ала торган очкыннар сибелми аннан. Берничә ай эчендә сүрелде микәнни?

Каршыда утырган апа белән кыз быдыр-быдыр кайсыдыр авыл турында сөйләшәләр, ара-тирә күршеләренә күз ташлап алалар. Сүзләрнең иң кирәген монда әйтү мөмкин түгел иде.

Кафедан чыккач, тукталып калдылар. Саубуллашырга иртә, әйтәсе килгәннәр тел очында, ләкин әрле-бирле базар халкы чуалган урында әйтә торган түгел иде. Шәүкәт тимер рәшәткә артындагы бакчага карады. Әнә анда, эчтәрәк, таныш эскәмия. Кайчан гына әле алар шунда Бәхет каласының сурәтләрен ясаганнар иде. Каеннарның толымнары ачык яшел, кыргый алмагачлар, Оренбур шәленә төренгән кебек, шау чәчәктә иде... Кая китте икән ул көннәр?

– Әйдә бераз йөреп киләбез...

Алар, ачык капка аша кереп, аллея буйлап киттеләр. Бакчада кар керләнмәгән, ак, ян-ягына көрт өелгән сукмак кына күкселләнеп тора.

– Йә, ни эш кыру? – диде Шәүкәт. – Микрорайон төзеләме әле?

– Проектны хупладылар. Хәтта яхшыртырга куштылар.

Шәүкәт тукталып, аңа борылып карады.

– Шуннан да яхшыны төземәкчеләрме?

– Хәтерлисеңдер, без биналарның түбәләре турында бөтенләй уйламаган идек. Типовой проектларда ничек булса, шулай калган иде.

– Шул җитмәгәнмени?

– Кеше камиллеккә омтыла.

– Кайчан экскурсия оештырып булыр инде ул шәһәргә?

– Эш башлауны бу елның планына керттек, диләр.

– Очы-кырые күренми икән әле! – Шәүкәтнең тавышында усал кинәнү ишетелде. – Ә Бәхет шәһәренең сызымнары кайчан әзер булыр икән?

– Хәзер индивидуаль проектлар шактый эшләнә. Морат яңа цирк проектын эшли. Бик оригиналь идея тапкан ул. Бөтен бер калаларны өр-яңача салырга да вакыт җитәр.

Шәүкәт, ышанмаганын белдереп, иреннәрен кысты, әрепләшәсе килмәгәнен сиздереп, карашын читкә юнәлтте.

Бакча аклык эчендә утыра. Агачларның шәрә ботаклары тырпаешып тора. Җан әсәре сизелми аларда. Бервакыт Шәүкәт нәкъ шундый корыган агачны яшеленнән матуррак итеп күргән иде. Хәзер исә шәрә бакча күренешенә сокланганы сизелмәде, киресенчә, йөзендә канәгатьсезлек ярылып ята.

Кайчан да булса яз килүенә, шәрә чыбыкларның терелүенә, яшеллеккә төренүенә ышанасы килми, алар үле кебек.

– Син ник мине чакырдың? – дип сорады Мәрьям.

– Хәлеңне беләсем килде. Өеңдә хәлләр ничек?..

– Бер килеш.

Шәүкәт моны ир белән хатын арасы җайланган дип аңлады булса кирәк. Ләкин Мәрьям һаман әле кызы белән бергә Саҗидә апада яшәп ятканын әйтүне кирәк тапмады. Ачылып китсә, ник кире кайтмавын да аңлатырга тиеш булачак иде. Ә анысы тагын да эчкәрәк алып кереп китәчәк: ире кочагына гафу сорап керергә үзен мәҗбүр итә алмый иде ул. Әйе, мондый очракта үзеңне мәҗбүр итми булмый, чөнки күңел башка берәүне сагыну белән тулы...

– Мин сине укырга кергәнсеңдер дип уйлый идем, – дип, сүзне икенчегә борды Мәрьям. – Хәбәр дә бирмәдең.

– Нинди хәбәр бирергә кирәк иде? Керә алмадым, дипме? Мөмкинлегем булмады, дипме?

– Ничек булса, шулай.

– Институт бер генә... ә минем кебекләр... буа буарлык. Ярый әле вакытында аңладым. Гомер буе алданып яшәсәм, начаррак булыр иде.

– Димәк, «Джоконда»...

– Син һәрвакыт хыялый идең. Күзеңне ачыбрак кара! Дөнья бу! Хыялланып кына яшәп булмый!

– Мин, киресенчә, торган саен күбрәк хыялланырга кирәгенә ышанам. Дөрес, төрле вакытлар була. Кайчак бик авырга туры килә. Теләгеңә ирешә алмассың кебек. Ләкин тырышсаң, һәммәсен үзгәртеп, яхшыга борып була. – Мәрьям, үрелеп, якындагы каенның салынган тармагын тотып, үзенә тартты. – Менә кара, шәп-шәрә чыбык бу. Яз килер, аны да яшел яфрак сарыр. Һәммәсе үзгәрә. Безнең өчен дә язлар килер...

– Син мине корыган агачка санамыйсыңдыр бит? – Шәүкәт рәнҗүле көлемсерәде. – Артык эре кыланасың түгелме? Мин югалып кала торганнардан түгел! Менә партиягә керәм. Озакламый мәктәп директоры булырмын... Аннары күз күрер...

Кем авызыннан чыкты бу сүзләр? Мәрьям аңа беренче күргәндәй гаҗәпләнеп текәлде. Кем басып тора аның каршысында? Аны тотып селкисе килде. Ә бәлки, яңакларгадыр? Теге чакта күпердә чәчәк белән яңаклаган шикелле... Түбән уйларыннан айнытырга, ярсытырга кирәк аны! Үз хәленә күзе ачылсын, йөрәге кузгалсын, яшьлек хыялларын исенә төшерсен иде.

Әмма куллар күтәрелмәде, чөнки мондый очракта кешегә каты бәрелергә, ә бәлки, китереп орырга фәкать уртак мәхәббәт кенә хокук бирәдер.

Мәрьямнең андый хокукы юк иде шул инде. Ул, Шәүкәтне әйләнеп узам дигәндә, сукмактан читкә тайпылып, тездән карга батты.

– Их, син! – диде Шәүкәт, аны терсәгеннән тотып. – Орынасың килмәгәч, юл бир, дияр идең. Аннары кистереп карады да: – Бергә булмавыбызны миннән күрәсең. Ә бит һәммәсе синең аркада булды, – дип өстәп куйды. – Коры кул белән күктән торна аулыйсың, мине дә шуңа мәҗбүр итәргә тырыштың.

Алар бакчадан чыгып базар аша институт бинасына кадәр дәшми генә бардылар. Кул бирешми, күзгә-күз карамый гына хушлаштылар.

Шәүкәт сөзәк урамнан аска, трамвайга таба төшеп китте. Ерагая төшкәч, күксел бетон койма фонында кара шәүлә булып күренде ул. Мәрьям, йөрәге сызлаудан ыңгырашмас өчен, тешләрен кысты. Бу шәүлә аның матур хыяллар, якты өметләр белән тулы, сөенечле минутлар белән бизәлгән яшьлеген алып киткән кебек тоелды.

*1967*

## Егетлеккә бер адым

### Беренче бүлек

Кичке кояш пыяла заводы поселогын алсу нурга коендырган. Завод өстендә эленеп торган җиңел болыт кисәгенә кызгылт буяу сеңгән төсле, икешәр катлы таш йортларның стеналары сабын белән югандай чиста күренә. Урман ягына караган тәрәзәләр, учак яккандай, күзләрне чагылдыра.

Олы урамдагы йортлар күләгәсеннән тыкрык турына чыккач, Ләң-ләң Васьканың сары чәчле башы да, велосипед руле дә яктырып киткәндәй булды.

Малайның исә кояшта хәбәре юк. Ул, ялан аягын рам арасына тыккан да, әле уңга, әле сулга янтаеп, педальләргә баса; ул авышкан көйгә, рульдәге ятьмәдә бер бөтен калач чайкала. Әтисе велосипедына менеп атланган малай ямьшек борынын харап югары чөйгән, каршына килгән Бикташны күрмәгән булып кылана.

Ә менә Бикташ аңа выжт итеп үтеп китәргә ирек бирмәде, велосипед руленнән эләктереп алды:

– Туктале... Бер сүз әйтәм...

Васька янтаеп җиргә басты:

– Ну?

– Чишмә яныннан гына әйләнеп килим әле, ә?

Бикташның тавышы ничектер нечкәреп, мескенләнеп чыкты, ә бот буе Васька, кашын-күзен җыерып, кәпрәеп чәрелдәде:

– Булмый. Мама тиз кайтырга кушты. Аш өлгерүгә, ипи өстәлдә булсын, диде.

– Тиз киләм мин... Сизми дә кала ул аны...

Васька рульне Бикташ кулыннан тартып алырга талпынды.

– Җибәр! Ну!

Алар шулай тарткалашып торганда сизми дә калдылар, тыкрык башына тузанлы йөк машинасы килеп туктады. Машина арбасында чүмәшеп утырган кеше тураеп басты, Олы урамдагы яңа таш йортларны гаҗәпсенеп күзеннән кичерде. Аннары, урман ягына ишарәләп, малайлардан:

– Яшел урам шул яктамы? – дип сорады.

– Шунда, шунда! – дип җавап бирде Васька, гадәтенчә кабаланып. – Сулга борыласы!

Менә ир кеше, тәгәрмәчкә басып, җиргә төште, шоферга нидер әйтте дә тыкрыкка кереп китте. Малайлар аның артыннан сәерсенеп карап калдылар. Алар икесе дә Яшел урамда яшиләр, ләкин бу кешене беренче күрүләре. Өстендәге күк костюмы да, салам кепкасы да өр-яңа күренә, ялтыравык соры портфеле кабарып тора иде. Кунакка кайта булса кирәк. Кемнәргә икән?

Ул арада машина үз юлы белән китеп барды. Васька да, җаен туры китереп, рульне Бикташ кулыннан тартып алды, бераз ара велосипедын этеп, йөгереп барды, аннары, Бикташның куа килмәгәнен күреп, уң аягын рам арасына тыкты да үртәп кычкырды:

– Сиңа тагын велосипед! Йөри белмәгән башың белән!

Уңга-сулга янтаеп педальләргә баса-баса, теге абыйны куып та җитте, узып та китте. Бикташ та, башын иеп, алар артыннан өенә таба атлады.

Ул урам чатыннан борылганда, әлеге абый Бикташлар турына җиткән иде инде. Менә ул адымнарын әкренәйтте, як-ягына каранды һәм, ничектер кыенсынгандай атлап, ишеккә юнәлде.

Бикташлар пыяла заводының бер катлы, өч квартиралы агач өендә яшиләр. Урам яктан аларның болдырын куерып үскән сирень куаклары ышыклап тора. Теге абый, тәбәнәк коймага уелган тар капкадан кереп, өч басмалы баскычтан әкрен генә менде, нидер тыңланып торгандай булды, аннары сирень куаклары артында күздән югалды – өйгә керде булса кирәк.

Бикташның күңеле кузгалды. Кем булыр бу? Ник килгән? Малай ирексездән адымнарын кызулатты.

Ишекне ачып, әнисен күрүгә, ул ниндидер гадәттән тыш хәл булганын аңлады. Салиха апа, кулларын кушырып, тимер караватның биек аркасына сөялеп баскан, хәрәкәтсез карашын килгән кешегә түгел, ян тәрәзәдән ак мичкә төшкән кояш нурына төбәгән иде. Ул, ишек тавышына сискәнеп, Бикташка карады. Бусага төбендә торган теге абый да, малайны күргәч, каушап киткәндәй булды, кызарынды, кыюсыз гына, үз уен расларга теләгәндәй итеп:

– Бикташ... – диде. – Бикташ, улым!..

Аннары портфелен идәнгә куеп, иелә төшеп, кулларын сузды:

– Исәнме, улым!

Малай аны-моны аңлап җиткергәнче, аның куллары абыйның дымлы учына чумган иде инде.

Салиха апа, аларның арасына төшәргә теләгәндәй, алга омтылды һәм:

– Ник кайттың инде? Ник кайттың? – диде. – Кайтма, борчып йөрмә, дип язган идем бит мин сиңа!

Аның бу сүзләрендә шулхәтле ачы рәнҗеш, сызлану яңгырады, Бикташ кулларын әтисенең учыннан тартып алганын сизми дә калды. Сәетҗан абый исә, үпкә сүзләрен тыңларга күптән әзер кешедәй, сабыр гына башын иде, тирән итеп көрсенде:

– Мин дә сиңа әллә ничә яздым бит. Кайтам, дидем. Ник дисәң, үз балам ул минем. Үз каным. Закон да, шәригать тә минем хокукымны раслый.

Бу сүзләр Бикташ күңеленә ялкын бөркелгәндәй тәэсир итте. Ни ди ул? Хатлар яздым, диме? Ә нишләп Бикташ аларны күрмәде, укымады? Димәк... әнисе белгертмәгән? Әтисенең хәбәрен улыннан яшергән? Ә монда Бикташ атасыз бала исемен күтәреп йөри! Күпме кимсенде, күпме хурланды, малай-шалайдан күпме әр-хур ишетте, күпме кыйналды ул шуның аркасында!

– Нишләп алай кинәт кенә исеңә төшерәсе иттең соң әле син аны? – диде Салиха апа. – Моңарчы кайда идең? Үз каның булгач, унөч ел буе бер хәбәр бирми ни уйлап йөрдең?

Шулай диде дә малайның йөрәгенә бозлы су сипкәндәй итте. Әһә, алай икән, быел гына язган икән ул хатларын. Чыннан да, моңарчы нишләп язмаган? Нишләп онытып йөргән?

– Кайткан булырыем да бит, – диде Сәетҗан абый, йомшак кына итеп, – кайтып керер җир калмады. Әллә кемнәрне йортка кертеп, мин ачып керәсе ишекләрне шартлатып бикләп куйган идең бит!

Ана белән малай бер мәлгә өнсез-тынсыз калдылар. Әкрен тавыш белән әйтелгән бу дәлил малайның күңелен кара төндә атылган яшен кебек сискәндерде.

Әйе шул, Салиха апаның икенче ире, Бикташның үги әтисе Әгъзам дигән кеше бар иде бит әле дөньяда. Бар иде, хәзер юк инде. Моннан өч ел элек машинага тапталып үлде. Әнисе Бикташка, әтиең безне ташлап китте, ди торган иде. Димәк, ул сүз дөрес булмаган? Әтисенең бик кайтасы килсә дә кайта алмаган, чөнки әнисе аны көтәргә теләмәгән, Әгъзамны йортка керткән булып чыга?

Үсмер малай башына бу аяусыз фикер тиз генә сыя алмады. Салиха апа, телгә килеп, нидер сөйли, рәнҗүле тавыш белән нәрсәдер исбатларга маташа, ләкин инде Бикташ аны ишетсә дә аңламый, ул әтисенең нәкъ үзенеке төсле күк күзләренә текәлеп карап тора иде.

Сәетҗан абый улына якын итеп елмайды, аяк очындагы портфеленә үрелде:

– Улым, сиңа күчтәнәч бар бит әле монда... – дип, бер төргәк алып бирде.

– Мә, улым! Мондый нәрсәне күргәнең юктыр әле синең, ә? Читтән кайткан күчтәнәч бу. Капкач та йотып җибәрмә, озак итеп чәйнә.

Бикташ нишләргә, ни дияргә белмәде. Өйдә һава җитмәгәндәй тоелды, сулышы кысылды. Ул ялт борылды да чыгып китте. Баскыч төбендә туктап, көмеш кәгазьгә язылган сүзләрне укырга тырышып карады, булдыра алмады.

Капка төбенә, мыш-мыш сулап, велосипеды белән Васька килеп туктады.

– Атаң кайттымы әллә?

– Әйе... кайтты... – дип җавап бирде Бикташ. Аннары, мактанган төсле: – Кайтты шул! – диде. – Күр, миңа ни апкайткан!

Васька, велосипедын коймага сөяп, болдырга күтәрелде, ямьшек борынын күчтәнәчкә тери язып:

– Ни ул? – дип сорады.

– Син күргән әйбер түгел.

Бикташ, үзе мондый нәрсәне көн саен күреп торган кешедәй кыланып, көмеш кәгазьне шытырдатып сүтте, бер кисәк сындырып алып авызына капты, татлы икәнен белдереп, күзләрен йомды.

– Миңа да бир әле! – дип ялынды Васька.

Бикташ ишетмәмешкә салышты.

– Велосипедны биреп торам! Чишмә буеннан биш тапкыр әйләнерсең!

Бикташ җавап бирмәде, конфетны чут-чут суыруында булды. Урам буйлап велосипед белән куыша-куыша килгән малайларны күреп, Васька бәяне арттырды:

– Ун тапкыр әйләнерсең! Бир инде әз генә!

Ул кичне Бикташ аяклары талганчы, башы әйләнгәнче велосипедта йөрде. Васьканыкында да, Рәмзинекендә дә, Садрыйныкында да...

Караңгы төшкәч, тиргә батып өенә кайтып керде ул. Ут та кабызмыйча, өстәл янында башын иеп тавышсыз-тынсыз утырган әнисеннән:

– Кайда... ул? – дип сорады.

Салиха апа башын күтәрмәде.

– Китте дәмени?

Бикташның тавышындагы шомлану, курку ананы айнытып җибәрде.

– Белмим... – диде Салиха апа. – Каян белим... Әйтмәде...

Бикташ ишектән кире атылды, Олы урамга таба йөгерде. Урам буш, тын, юлда машина утлары да күренми иде.

Малай, күңеле сизепме, әллә акылы җитепме, пыяла заводының кунак йорты турыннан узасы итте.

Юан, төз бүрәнәләрдән салынган бу өйнең бер ягында – хатын-кызлар, икенче ягында ир-ат куна.

Хатын-кызлар бүлмәсенең пәрдәләре корылган, эче күренми иде. Икенче якның ачык тәрәзәсенә күз салуга, Бикташ, аякларының җегәре беткәндәй, кинәт туктап калды. Бүлмә уртасындагы зур өстәл янында тәрәзәгә яны белән Сәетҗан абый утыра иде.

Бикташ, стена буендагы биек кычытканнарга шәрә беләкләрен чактырып, тәрәзәгә якынайды.

Өстәлдәге ертык газета өстендә колбаса телемнәре, йомыркалар таралып ята, тик Сәетҗан абый аларның берсенә дә орынмый, кулындагы кара ипи сыныгын тешләштереп, кырлы стаканнан чәй генә капкалый. Пинжәге белән кепкасын караватка ыргыткан, зәңгәр буйлы күлмәгенең изүен чишеп, җиңнәрен сызганып куйган. Сирәк, йомшак чәче маңгае өстендә чуалып, күпереп тора, какча йөзе түшәмгә асылган шәрә лампочка яктысында талчыккан төсле күренә иде. Уйчан иде аның кыяфәте. Менә ул, нидер сизенгәндәй, тәрәзәгә борылып карады – Бикташ яктыдан башын чак алып өлгерде. Малайның йөрәге кабыргалары арасыннан сикереп чыгардай булып типте, тәненә тир бәреп чыкты, ләкин ул тәрәзә яныннан китә алмады: аяклары, җиргә береккәндәй, кузгалырга теләмәде, күзләре зур бүлмәдә берьялгызы уйланып утырган моңсу йөзле кешене күреп туймады.

*** * ***

Алар урам уртасында очраштылар. Бикташ аргы очтагы биек тупыл башларына караган да дәшми тик тора. Ни дисен? Бүген шимбә көн. Салиха апа эшенә китте, Бикташка, өйдән чыгып йөрмә, диде, дөнья кадәр эш кушып калдырды: утын ярырга, идән палаçларын кагарга, каникулга чыккач та ясый башлаган китап киштәсен рәтләп бетерергә. Эше күп иде Бикташның, ләкин берсенә дә кулы бармады. Иртән күзен ачуга, әтисен исенә төшерде ул, әнисе чыгып киткәч, әрле-бирле йөренде дә кунак йорты тирәсеннән әйләнеп кайтмакчы булды.

– Урманны карап кайтасы килгән ие бер, – диде Сәетҗан абый. Чалбар кесәсеннән таушалган «Беломор» пачкасы алып, шырпы сызды. Папиросына ут кабызганда, кулы калтыраганы сизелде.

Урамда кеше-кара булмаса да, алар үзләрен мең күз астында хис иттеләр. Әнә каршы тәрәзәдән Анна түтәй карап тора. Әнә Бикташларның күршесе Шәмсия апа, юл уртасына ук чыгып, идән паласы селкергә кереште. Менә, велосипедын сөйрәп, Васька килеп чыкты. Бикташ яныннан выжт кына узып китәргә ашыкмады, янтаеп, бер аягы белән җиргә басты да, авызын ачып, керфеген дә какмыйча, Сәетҗан абыйга карап торды. Ниһаять, ул кузгалып киткәч, Сәетҗан абый, күзләрен кыса төшеп, улына дәште:

– Әйдә, бераз йөреп килик!

– Ярар, – диде көттеребрәк Бикташ.

Алар урманга илтә торган юл буйлап киттеләр. Икесе буйга бер чама, адымнары, йөрешләре, кул селтәүләре дә бертөсле, тик Бикташның сыны нечкә, иңнәре тар, ә Сәетҗан абыйның җилкәләре иңә башлаган, биленә шактый май үскән иде.

Алар поселоктан чыгып киткәнче аркалары белән үзләрен күзәткәнне тоеп бардылар, урман ышыгына кергәч кенә иркен сулыш алдылар.

Һәр кырмыска түмгәгенә чаклы таныш урман бу юлы Бикташка башкача, яңача булып күренде. Сары, зәңгәр, шәмәхә чәчәкләр куе үлән арасыннан бигрәк чекерәешеп карыйлар, күкеләр кычкыруында да, тукран тукылдавында да үзенә бер дәртле аваз бар кебек тоелды. Агач башларын шаулатып җил искән саен, аяк астында кояш шәүләләре биеште.

– Су башы корымаганмы әле, улым?

Су башы дип поселокны әйләнеп уза торган инешнең башланган урынын атыйлар иде. Бикташ чирәм үскән сукмактан читкә, яшь имәннәр арасына борылды. Анда үлән сирәк, сусыл, черегән ботаклар гына аяк астында шыртлап сына иде. Бераздан алар каен, усак агачлары белән әйләндереп алынган уйсулыкка килеп чыктылар.

Сәетҗан абый кепкасын салды да ятып су эчте. Чишмәнең агышы җентекләп, озаклап караганда гына сизелә, чокырчыкка җыелган су төбендә нечкә үлән сабаклары чайкала, нәни коңгызлар йөгерешә иде.

– Мин куйган бураны алыштырганнар икән, – диде Сәетҗан абый.

– Черегәние инде ул, кыйшайганые, – диде Бикташ. – Әни алыштырырга кушты.

– Кемгә?

– Миңа.

– Әниең кушты дисеңме? – дип кабатлап сорады Сәетҗан абый.

– Ие. Бурасына имән агачларын үзебезнең утын арасыннан сайлап алдык.

Сәетҗан абый, кесәсеннән бөгәрләнгән кульяулык алып, битен, тирләгән маңгаен сөртте, тетрәнгән тавыш белән:

– Кулың эшкә ята икән, маладис, – диде.

Беравык алар чишмәнең сизелер-сизелмәс агышын күзәтеп тордылар.

– Түбәнгәрәк куясың калган икән, – диде, ниһаять, Сәетҗан абый. – Күрәсеңме, менә монда су кайнабрак чыга.

– Элекке урынына куйдым инде.

– Су юлын үзгәрткән, димәк.

Алар икәүләшеп бураны күчереп куйдылар, кулларын кызартып, туңдырып, чишмә юлын тазарттылар. Сәетҗан абыйның күк чалбар балаклары, күлмәк җиңнәре ләмгә буялды, Бикташның кедыларына су тулды, ләкин алар берсе дә моңа игътибар бирмәде. Чөнки үз күңелләрендә чишмә булып бөркеп чыккан якынлык хисе алар өчен дөньяның бөтен көйсезлекләрен юып алган иде.

– Синсез килсәм, су башын таба аласым булмаган, – диде Сәетҗан абый. – Ник дисәң, теге төштә элек каенлык ие, хәзер әнә имән утыртканнар.

Кире урман юлына чыкканда, баш очларыннан, киң канатлары белән имән ябалдашларына тия язып, зур бер кош очып үтте.

– Урман тавыклары һаман бармыни әле? – дип гаҗәпләнеп һәм сөенеп сорады Сәетҗан абый.

– Монда күп алар. Пошилар да, куян да күп. Бүре дә бар, диләр.

Бикташ, үз байлыгы белән мактангандай, әтисенә иң гөмбәле урыннарны, иң җиләкле аланнарны күрсәтеп йөрде. Алар юа, кузгалак, балтырган авыз иттеләр, йөреп арыгач, дымлы чокырчык төбенә кечкенә генә учак тергезеп җибәрделәр. Сәетҗан абый, терсәкләренә таянып, йомшак чирәмгә сузылып ятты.

– Үтә гомер, урман да танымаслык булып үзгәргән, – диде ул, үзалдына уйланып. – Әле кичә генә чыгып киткән кебек югыйсә.

Бикташ көн яктысында тонык кына янган учакка карап утырды, озын таяк белән кисәүләрне рәтләштерде. Ул әтисенең йөзенә, кыяфәтенә күнегеп җитмәгән иде әле. Сәетҗан абый күп яклары – иягенең сул ягындагы түгәрәк миңе, туры аксыл кашлары, юка иреннәре, тагын әллә нинди, әйтеп бетереп булмый торган йөз сызыклары, йөреш-торышлары белән Бикташка бик нык охшаган булса да, малайга ул ничектер чит, ят тоела иде. Ләкин барыбер дә аның үзалдына уйлангандай сөйләвен тыңлау, «улым» дип йомшак тавыш белән дәшкәнен ишетү рәхәт иде.

– Яшь чакта ахмак буласың икән шул, – дип дәвам итте Сәетҗан абый сүзен. – Күңел әллә кая ашкына. Чит җирләрдә рәхәттер сыман тоела. Әзрәк дөнья күрим, бераз акча җыйыйм дип кенә киткәнием мин дә. Бераз хәлләнгәч, кире кайтыргае исәп. Йә булмаса әниең белән икегезне үз яныма алыргае. Әллә ничек булды шунда, кайтыр юллар өзелде дә куйды.

Бикташ кулындагы таяк, учак эчендә калып, очыннан яна башлады. Малай сагайды, менә-менә китереп сугасыларын көткәндәй, бөтен тәне киеренкеләнде. Ул әтисенең өйдән ничек чыгып киткәнен хәтерләми иде.

Үсә төшеп, башкаларның әтиләре барлыгын белгәч, минем әти кая, дип сорый башласа, әнисе:

– Әтиең түүт китте! – дип җавап бирә иде.

Малай әтисен шофер йә очучы итеп күз алдына китерә иде.

Тагын да бераз исәйгәч, әнисенең күрше хатыннарына:

– Атасы чыгып китте дә юк булды бит әле менә, ничә ел инде бер сәлам хаты да җибәргәне юк, – дигәнен ишетә иде дә уйга кала иде малай.

Соңрак, Әгъзам абый белән яши башлагач, Салиха апа улын:

– Менә син дә әтиле булдың, – дип юатырга тырышты.

Ләкин Бикташ Әгъзам абыйны үз этисе урынына куя алмады. Әнисе икенче тапкыр кияүгә чыкканда, малайга алты яшь тулган, ул үзенең ятим икәнлеген күңеленә сеңдерергә өлгергән иде шул инде.

Үги ата аны какмады, сукмады, әмма үз баласыдай сөеп, иркәли дә белмәде. Фәния тугач, аларның арасы тагын да суына төште. Әгъзам абый кызын шапылдата-шапылдата, түшәмгә чөя-чөя сөйгәндә, Бикташ аларга чиксез кызыгып, көнләшеп карап тора иде, ләкин анда үги этисенә сыену теләге беркайчан да тумады.

Үскән саен малай үзен өйдә артык җан кебегрәк тоя башлады. Әгъзам абый еш кына эчеп кайта, әнисе тиргәп авыз ачса:

– Сиңа ни җитмәгән тагын! Яхшылыкның кадерен белмисең! – дип кырт кисә иде. – Инде мин дә ярамагач! Ирең ташлап җир читенә качкан димәдем, колга буе малаең бар димәдем, алдым! Яшим, сүз әйткәнем юк!

Шулай диюгә, Салиха апа, тамагына таш утыргандай, тынсыз кала иде. Андый чакларда Бикташ үги этисен өзгәләп ташлардай була, әнисенең аны өйгә кертүен дә, чыдап яшәвен дә һич аңламый иде.

Хәзер менә, этисе сүзне аның өчен газаплы кичерешләр белән бәйле хәлләргә китереп бәйләгәч, малайның бөтен тәне кылдай тартылды. Ул әнисе турында гаепләү-хурлау сүзләре ишетүдән курыкты.

Сәетҗан абыйның бу турыда сүзне озайтмаска акылы җитте. Әллә улының эчке халәтен сиздеме? Ул тирән итеп көрсенде дә аркасына әйләнеп ятты, агач башларына эләгә-эләгә әкрен генә шуышкан ак болыт мендәрләренә карап, сүзне икенчегә борды.

– Син дә үскәнсең инде, – диде. – Егет булып киләсең. Ни генә булса да, ата белән бала бер-берсен онытырга тиеш түгел. Энең белән дә танышырга кирәк. Дөнья көткәндә туганнарсыз булмый.

Бикташның туры кашлары җыерылып куйды. Ул калада этисенең яшь хатыны, Фәниядән кечерәк тагын бер улы барын әнисеннән ишетеп белә, әмма алар турында уйламаска тырыша иде.

Сәетҗан абый улының йөзенә чыккан ризасызлык билгеләрен күрмәде. Ул сүзенең сөрешен, күптән әйтергә тырышып та, һаман әйтә алмый азапланган бер фикергә китереп җиткерергә маташа иде. Ул Бикташка тормыш юлын сайлау, һөнәр алу турында ныклап уйларга вакыт җиткәнен әйтте. Уен-муен түгел, көзен сигезенче класска барачак бит инде. Бер ел бик тиз үтә ул, сизми дә калырсың, язмышны хәл итәр көн килеп җитәр: тугызынчы класска барамы ул, әллә берәр һөнәр алу ягын карыймы? Сәетҗан абыйның менә шул мәсьәләдә улына ярдәм итәсе килә. Шәһәрдә аның танышлары җитәрлек, киңәш-табыш итәргә дә, кирәк икән, ярдәм кулы сузарга да әзер торучылар бар. Менә, мәсәлән, электротехника училищесына керсәң, бик әйбәт булыр, телевизор мастерлары чыгара, сирәк һөнәр, андый осталар бүгенге көндә авылда да, шәһәрдә дә кадерле, диде.

– Мин сиңа бу турыда әйтеп берничә тапкыр хат та язганыем, – дип йомгаклады сүзен Сәетҗан абый. – Ул хатлар сиңа килеп ирешмәгән икән. Ә мин синнән җавап көтеп ятам тагын. Хәбәр-хәтер булмагач, үзем кайттым менә. Ник дисәң, сине үз яныма чакырмакчыем...

Зәңгәр күккә карап ятса да, ул малайның тып-тын утыруыннан, тигезле-тигезсез сулыш алуыннан кызыксынганын сизде.

Кирәкми, дип туктатмады малай, мин синең белән беркая да бармыйм, дип кырт кисмәде, аркасы белән борылып утырмады. Шулай сабыр гына тыңлап утыруы өчен дә бик рәхмәт. Сәетҗан абый торып басты, астыртын гына улын күзәтеп, учак тирәли әйләнеп чыкты.

– Мин сине алырга дип кайтканыем, – диде ул. – Барырсың, карарсың, дигәнием. Ошаса, кала мәктәбенә керерсең, ошамый икән, ирексезләмәм. Ничек уйлыйсың?

Ул, әлбәттә, улының «Әйдә соң киттек!» дип сикереп торуын өмет итми иде. Малай пыскып яткан кисәүләргә төбәлеп утыра, күзен күтәреп карамый, авызын ачып сүз әйтми, ләкин бөтен кыяфәтеннән этисенең сүзләренә каршылыгы юклыгы сизелеп тора иде. Ата өчен шунысы да зур җиңү иде. Инде бу җиңүне ныгытырга, яулап алган мәйданны киңәйтергә, Салиха апа тарафыннан булачак һөҗүмне икәүләшеп кире кагу чарасын табарга кирәк иде.

Ниһаять, Бикташ башын күтәрде.

– Пәкең бармы?

– Ә?.. Нәрсә?..

– Пәке кирәк ие...

Сәетҗан абый кабаланып чалбар кесәләрен капшады. Пәкесе бар аның, бар, тик кунак өендә, пинжәк кесәсендә калмаганмы? Әйтерсең лә шушы минутта аның бөтен язмышын кесәсендә пәкесе булу-булмау хәл итә иде. Уф, менә бит ул! Ничек акылы җитеп чалбар кесәсенә салган!

Бикташ майланып, керләнеп беткән тимер саплы җыелмалы пәкене бик кадерле нәрсә сыман сакланып кына кулына алды. Алан кырына барды да яшь, бөдрә каенның кәүсәсен кулы белән сыпыргалады. Аннары нәфис кәүсәгә, тузын гына телеп, нечкә сызыклар уя башлады. Бу яраларның

агачка зыяны тимәячәк иде, каен үскән саен Бикташның тамгалары гына тирәнәячәк иде. Малай сак булырга тырышты – ул каенның озак яшәвен тели иде, агач исән чакта аның язуы да яшәячәк иде. «Мансуровлар. Сәетҗан, Бикташ» дип телеп язды ул каенга.

* * *

Төшкелеккә кайтып килгән Салиха апа Бикташ белән Сәетҗан абыйны ерактан ук күреп алды һәм тигез җирдә абынды. Ата белән малай кояшлы юлдан, икесе дә нәкъ бертөсле алгарак омтылып, уң кулларын сулыннан ныграк селтәп, иңгә-иң атлап киләләр иде. Аларның шулай тигез, бертөсле атлавыннан ук серләре килешкәне күренеп тора. Әнисенә күзе төшкәч, Бикташ әтисеннән чак кына читләште, бераз ара калдырып атлый башлады.

Салиха апа аларны көтеп тормады, тыкрыктан борылды да йөгерә-атлый өенә таба китте. Әмма эчендә янган уттан ишек артына яшеренеп кенә котылып буламы соң? Ул, тәрәзә пәрдәсенә ышыкланып, урам якны күзәтте.

Сәетҗан өйгә үк бәреп кермәс дип өметләнгән иде. Ялгышкан икән. Бу юлы ул, нык-нык басып, ишекне каерып ачып килеп керде. Өйалдында нишләргә, кая карарга белми аптырап торган Бикташка, башы белән генә ымлап:

– Малай белән сөйләштек без, киңәшләштек, – диде. – Үзең беләсең, ул зур инде, син дә көчләп тота алмыйсың, мин дә. Минем белән барсын, карасын, үз күңеленә ошаганны сайласын. Каршы килмә.

Тыныч әйтте бу сүзләрне Сәетҗан абый, ничектер елмайган сыманрак итеп тә куйды. Салиха апа исә: «Җибәрмим! Ике аягының берсен дә атлатмыйм!» – дип кычкырудан чак кына тыелды.

Гауга куптарырга ярамый иде. Ярсып бәргәләнә башласаң, эшне бөтенләй бозып куюың бар. Чөнки малайның эчендәгесен белеп булмый. Ни уйлап тора ул анда, әтисе артында, күләгәдә? Алла сакласын, чынлап ниятләсә, әйтми дә китеп барыр, берни эшли алмассың!

Бикташ белән икәүдән-икәү калгач сөйләшергә булды Салиха апа. Ләкин Сәетҗан абый аларга андый мөмкинлекне бирмәде. Әйтәсе сүзен әйтте дә болдырга чыгып утырды, тәмәке кабызды, төш узганчы урыныннан кузгалмады. Урам яңгыратып, ызгышып-талашып, аны куып йөрү Салиха апа кулыннан килә торган эш түгел иде.

Ана белән бала ачылып сөйләшү түгел, рәтләп тамакларына да ашый алмадылар. Өйдән күренмәсә дә, Сәетҗан абыйны яннарында утыргандай хис иттеләр. Әйтерсең лә стеналар пыялага әверелгән дә болдырдагы кеше аларның ни сөйләшкәнен генә түгел, ни уйлаганын да белеп тора!

Төшке ял вакыты үтте, Салиха апа чак кына читкәрәк тайпылган Сәетҗан яныннан ашыгып узды да, кая басканын да белмичә, заводка китеп барды.

Ул кичен кайтканда, Бикташ тагын өйдә юк иде. Әгәр ялгызы озаграк торса, Салиха апаны хәсрәте басып үтерер шикелле тоелды. Уң як күршеләренә сугылып карады – Шәмсия апа өйдә юк иде. Каршы йортка, Анналарга керергә туры килде.

Һәрвакыт авызы ерык, күңеле шат, тавышы күтәренке Анна тәлинкәләргә аш бүлеп тора иде. Аның ире Борис өстәл янына тагын бер урындык китереп куйды, Салиха апаны табынга чакырдылар.

– Бикташны күрмәдеңме? – дип сорады Салиха апа Васькадан.

– Күрдем. Мүкле күлдә су кереп ятадырые.

– Берүземе?

– Түгел. Әтисе белән.

Тәлинкәдәге ашка мөлдерәп күз яше тамды. Суыткычтан каймак алырга кузгалган Анна, шөкер, моны күрмәде, Борис күрсә дә күрмәмешкә салышты.

– Ник кайткан Сәетҗан? Әллә акылга утырганмы, яңадан кавышырга уйлыймы? – дип сораша башлады ул.

Салиха апа сулкылдавын сиздермәскә тырышты.

– Юк... Бикташны алып китәргә кайткан.

– Ә? Алып китәргә, дисеңме?

– Ие, алып китмәкче.

Аннаның кашыгы чупылдап шулпага төште.

– Бөтенләйгәме әллә?.. Кара син аны! Акылы алтын икән. Тапкан йомшак кеше, ә? Күрсәтерием мин аңа малайны! Каласына ракета кебек барып төшәрие!

– Шуның белән ни кырган булыриең инде? – дип каршы төште аңа ире. – Әйттең сүз! Ата белән баланы аеру булдымы эш!

– Салиха аермады ич аларны! Үзе ташлап качты! Күз алдыбызда!

– Кем кемне ташлаганны үзләре беләләрдер. Ир белән хатын арасын без тикшерергә калмаган. Бала турында уйларга кирәк. Ул малайны кеше иткәнче күзең күгәрер әле. Иң куркыныч вакыты аның хәзер, әтинең иң кирәк чагы. Шуны аңлап кайткан икән, молодец, дим мин Сәетҗанга!

Анна иренә чүмеч белән янаган булып кыланды:

– Җыен качкынны яклап утырма монда! Барыгыз да бер чыбыктан куылган!

Аннары, өлкәннәрнең һәр сүзен йотардай булып тыңлап утырган улына күзе төшеп:

– Ә син нәрсә күзеңне тасрайттың? – диде. – Тамагың туйдымы? Марш өстәл яныннан!

Салиха апа аларда җанына ял ала алмады, шунлыктан озак утырмады, чыгып китте. Бикташ һаман кайтмаган иде әле. «Калага ук алып киткәнме әллә?.. Юк-юк, булмас. Әйбер-караларын алырларые...» Салиха, үзен-үзе тынычландырырга тырышып, як-ягына каранды. Бар да үз урынында икән. Улының укый башлаган китабы ачык килеш өстәлдә ята, курткасы белән береты да чөйдә эленеп тора. Ни борчылган булса да, Салиха апа: «Ярый әле өс-башлары сүз әйтерлек түгел, бөтенесе гөл кебек», – дип бераз юанып куйды. «Кинога-фәләнгә керделәр микән әллә?» Алар керерләр, эшләре беткән. Салиха апаның гына балалары белән иркенләп, күңел ачып йөрергә вакыт таба алганы юк. Ике баланы тәмле ашатып, матур киендерү ансат түгел аңа. Ә бала-чага аның кадерен беләме? Уен кирәк аларга, күңел ачу кирәк. Ә ни сөйләшә ул үзенең улы белән? «Өстеңә киеп чык!», «Аша, суытма!», «Дәресләреңне карадыңмы?», «Бар, сеңлеңне алып кер!» – Аның сүзе шуннан артмый бит!

Юк, болай үз-үзеңне әрепләп утырып булмый, Шәмсиягә кереп чыгыйм, булмаса, дип уйлады ул.

Күрше хатын, кухня уртасына артсыз урындык куеп, кер уып азаплана иде. Салиха апа почмактагы өч аяклы утыргычка утырды.

Түгәрәк мөлаем йөзле Шәмсия апа йомшак тавышы, төпле сүзе белән кешене юата, тынычландыра белә. Салиха апа аннан яшьрәк булганы, аның янында үсмер кыз шикелле кечкенә күренгәне өчен түгел, үзенә җитмәгән акылны, ныклыкны эзләп аңа киңәшкә керә иде.

– Ике малай үстердем, – диде Шәмсия апа, кулларын терсәгенәчә күбеккә батырып, – бик яхшы беләм: ир балага дөрес тәрбия бирү уен эш түгел. Аңа ата бә-әк кирәк. Дөньяда барлыгын гына белеп торса да ярый. Аталы булуның берәүгә дә зыяны тигәне юк әле, атасызлык читен!

– Ничекләр итеп ирекле баштан газиз баламны үги ана янына җибәрим соң? – диде Салиха апа.

– Бәхете шуннан, күрәсең, ул баланың. Үги ата белән яшәде, үги ананы да күрергә насыйптыр. – Үзе шунда ук, Салиха апаның күңел җәрәхәтенә саксыз кагылганын аңлап, сүзен йомшартырга ашыкты. – Нигә ул хәтле хәсрәтләнәсең әле? – диде. – Барсын. Күрсен. Ул хатынга үги бала кирәк микән әле, анысы да бар бит. Үз улы була торып, үги бала асрыйсы килмәстер, мөгаен. Бәлки әле, озак тормас, әйләнер дә кайтыр. Бала-чага, тыя башласаң, отыры котыра ул.

– Тегесе дә ата ялганчы бит аның, – диде Салиха апа, сызланып. – Тамчы да ышаныч юк. Бер сынаганны мең сынама, дигәннәр.

– Сезнең арада ни булса, шул булган, үткән – беткән инде. Малаен ник алдасын икән соң ул? Аны алдап кына ни рәхәт күрер икән? Акылга утыргандыр инде Сәетҗан да. Аннан хәтәррәкләрне дә акылга утырта бу дөнья. Синең дә ике кулыңа ике бала, җиңел түгел бит, күреп торабыз. Үскән саен мәшәкатьләре арта бара, кая да булса урнаштырырга кирәк булыр. Атасының ярдәме артык булмас. Бәлки, әйбәт урынга укырга урнаштырыр. Монда яшәп, без ни беләбез...

Шәмсия апа улының ак күлмәген чиста суда чайкады да, сыгып, шартлатып селекте. Салиха апаның битенә вак, салкын тамчылар бөркелде.

– Фәния әбиләреннән кайтмыйммы соң әле? – дип, сүзне икенчегә күчерде Шәмсия апа.

– Укуы башланганчы торсын, дигәние эни. Үзләренең сыеры, тавыклары, бакчасы...

– Анысы шулай да бит. Хәзер менә янында бер юанычың булырые.

...Салиха апа тышкы кыяфәте белән генә түгел, холкы-фигыле белән дә үсмер кызларга охшаган иде. Гаҗәп дәрәҗәдә эчкерсез, беркатлы, ышанучан. Үз тормышындагы бик мөһим адымнарны кеше биргән киңәш белән ясады ул. Кыз булып җиткәч, пыяла заводының грузчигы Сәетҗанга димләделәр. Азып-тузып йөрми, тәмсез сүз белән авыз пычрата белми, кушканны эшли, кулыңда тота алсаң, менә дигән ир булыр, диделәр. Ышанды Салиха, егетне озак сынап тормады, чәчен чәчкә бәйләргә ризалыгын бирде. Ике ел бергә яшәгәч, Сәетҗан акча эшләргә читкә чыгып китте. Озак йөрмәм, кайтырмын да үзегезне чакырып алырмын, диде. Ышанды Салиха, ирен тоткарламады. Еллар буе хаты килмәгәндә дә, менә кайтыр, менә берәр хәбәр бирер, дип көтте, өметен өзмәде. Казахстан ягыннан кайткан бер хатынның: «Сәетҗан анда яшь хатын алган икән», – дип сөйләгәнен ишеткәч тә өметен өзмәде. Ләкин иренең ятлар белән бәйләнүе, туган иленә кайтырга нияте юклыгы турында башка кешеләрдән дә хәбәр килгәч, ышанмый булдыра алмады.

Каяндыр читтән килеп, пыяла заводына эшкә кергән Әгъзамга Салиха апа үзе игътибар да итмәгән булыр иде, бәлки. Аларның арасын шушы күршесе Шәмсия апа җайлап бирде. «Син яшь әле, гомерең буе ялгыз тормассың, Әгъзам хатыны белән арасын өзгән кеше, күзенә бик үк

мәхәббәтсез күренмәсә, читкә тибәрмә», – диде. Тыңлады Салиха апа, артык нечкәләп уйлап тормыйча гына Әгъзамны йортка кертте.

Анысы үкенерлек булмаган иде булуын. Әгъзам белән алар кеше көлдереп яшәмәделәр, ирсез торган ише түгел иде. Гомере генә кыска булды мәрхүмнең. Шәмсия апаның соңыннан үкенерлек киңәш биргәне юк. Шуңа күрә бу юлы да Салиха апа аның һәр сүзен күңеленә сеңдереп утырды.

Ләкин әйткәннәре белән бөтенләй үк килешә алмады. Хәлгә керергә бик тырыша да бит Шәмсия апа, тик күршесенең эчендә нинди утлар янганын беләме соң ул?! Яшьли тол калып, ике ирдән тапкан ике баласын җир тырмашып үстергән, киләчәккә бөтен өметен олы улына баглаган ананың хәлен аңлыймы? Каян белсен, ничек аңлап бетерсен! Үзеңнеке үзәктә, кешенеке кештәктә, диләр, кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә, диләр. Шуңа шулай җиңел сөйли ул! Шома сөйли үзе, каршы әйтерлек тә түгел. Әйе шул, ата белән бала арасына төшү ярап та бетми торгандыр. Ләкин нинди ата бит! Сәетҗан үзе ана белән бала арасына чөй кагудан тайчанып торамы соң? Бер генә көн йөрде аның белән бала, нибары бер көн, ә ничек үзгәрде, урманда шүрәле алыштырып җибәргәнмени! Күтәрелеп тә карамый, теш агартып сүз дә әйтми. Калага алып китеп, әнисеннән күңелен тәмам суытып җибәрмәгәйләре!

«Ник кайттың, ни кирәк сиңа тагын? – диде Салиха апа эченнән генә, Сәетҗан абыйга мөрәҗәгать итеп. – Ни үчең бар миндә? Шул гомер үткәч ник болай газаплыйсың? Йөрәгең ташмы әллә?»

Ул бу сүзләрне аның үзенә әйтә алмаячагын, әйтсә дә йөрәгенә үткәзеп булмасын аңлый иде. Ананың бердәнбер өмете – улы йөрәгенә сукмак табу, аның күңелендә миһербан уяту иде.

Салиха апа улының өйдәлеген тыштан ук белеп керде – тәрәзәдә ут бар иде. Ишек тавышына Бикташ борылып карамады, үз эшендә – урын җәюендә булды.

Салиха апа, тыныч күренергә тырышып:

– Хәзер чәй куям, улым, ашап алырбыз, – диде.

– Минем ашыйсым килми.

Гади генә бу сүзләр ананың бөтен ихтыярын сындырдылар.

– Нишләп алай? Ашамадык бит әле.

– Мин ашадым инде.

Салиха апа теленнән ычкынырга торган: «Кайда?» – дигән сорауны көчкә йотып калды. Кайда булсын, этисе янында, билгеле! Ә Бикташ аңа карамый гына чишенә башлады. Аның әле кыш ахырында гына алган сары сатин күлмәге, джинсы чалбарлары кечерәеп тә киткән иде инде. Шул ике-өч ай эчендә генә дә шактый үсеп куйган малай. Егет булып килә ич аның Бикташы! Ә ир-егетнең эчендә иярләгән ат ята, ди. Кайларга алып китәр ул ат бу егетне?

Бикташ ак тышлы юрганга башыннан ук төренеп ятты. Күренеп тора, сөйләшәсе килми иде малайның. Алай да Салиха апа:

– Улым, атаң белән китәргә булдыңмыни инде? – дип сорамый булдыра алмады. Җавап урынына Бикташның янбашлары турында ак юрган гына тибрәнеп куйды. Белмим әле, янәсе. Ә күзләре йомык иде инде.

...Бикташ төн уртасында ниндидер ят, сәер тавыштан уянып китте. Йөрәге дөпелдәве, колагы шаулавы һәм мич артында сайрап яткан өч чикерткәнең чарелдәве аркылы аның аңына ыңгырашкан аваз барып җиткәндәй булды. Әйе, кемдер ыңгыраша, алай гына да түгел, сулкылдап үкси иде. Бикташның беркайчан да әнисенең үксеп-тавышланып елаганын күргәне юк иде әле. Хәтта ире Әгъзам үлгәч тә аның күз яшьләре тавыш-тынсыз гына тамдылар. Бикташ, үз колакларына үзе ышанмыйча, бераз вакыт кымшанырга куркып ятты. Ниһаять, түзмәде:

– Әни... – диде. – Әни, ни булды?..

Аның тавышы караңгы өйдә тынлыкны ярды, чикерткәләр тынып калдылар.

– Әни, берәр җирең авыртамы әллә?

Бикташ караватын шыгырдатып торып утырды, чаршау аркылы әнисен күрергә тырышкандай, күзләрен зур ачты.

– Юк, улым... Яман төш күрдем. Җайсыз ятканмын... Бастырылдым...

– Әйләнеп ят алайса.

Нишләптер әнисенең сүзләре Бикташны ышандырып җиткермәде.

– Йокла, улым, борчылма. Бүтән алай бастырылмам инде.

Ләкин берсенең дә күзенә йокы кермәде. Икесе дә кыймылдамаска, тигез сулыш алырга тырышып, чикерткәләр җырын тыңлап, беркадәр тын гына яттылар. Ахырда Бикташ түзмәде, караватын шыгырдатып, стенага таба борылып ятты. Салиха апа, шуны гына көткәндәй:

– Улым, йокламыйсыңмы әле? – дип сорады.

– Юк.

Бикташның йөрәге кысылып куйды, ул әнисенең көн яктысында әйтергә кыймаган сүзен җиткерәчәген аңлады.

Улым... Синең атаң... – ялганчы димәкче иде Салиха апа. Ләкин теле әйләнмәде. Бу сүзнең улы йөрәгенә ничек барып кадаласын сизеп, тыелды.

– Атаңа ияреп китәсең бик киләмени соң?

– Юк... – диде Бикташ.

– Барма, улым, йөрмә. Сигезенчене монда әйбәт кенә тәмамласаң, берәр юлы табылыр әле.

Бикташның бик тә әнисен юатасы килә иде. Ул, һич икеләнеп тормыйча:

– Минем барам дигәнем юк әле, – диде. – Бармыйм да.

Бу сүзләр Салиха апаның янган йөрәгенә салкын су сипкәндәй тәэсир итте, ана белән бала арасындагы киртәләрне җимереп үтте, икесенә дә җан тынычлыгы бирде. Инде рәхәтләнеп йоклагыз дигәндәй, мич артындагы чикерткәләр дә үзләренең бишек җырларын өч аваздан берьюлы башлап җибәрделәр.

* * *

Ял көнне Бөрлегәнледә Сабан туе булырга тиеш иде. Салиха апа улына, без дә әбиеңнәргә барырбыз, иркенләп кунак булырбыз, Фәнияне дә күреп кайтырбыз, дип, әллә кайчаннан әйтеп килә иде инде. Аның тормышында бәйрәмнәр сирәк була, бу бәйрәмне ул көннәрне генә түгел, сәгатьләрне санап дигәндәй, зарыгып көтеп алды.

Кояш чыкканчы ук торып, электр самоварын тоташтырды. Бикташны да гадәттәгедән иртә кузгатты. Алай-болай Сәетҗан абый күренгәләгәнче, улын алып китәргә иде аның исәбе.

Ләкин өлгерә алмады. Чәй янына утырганнар гына иде, тәрәзәгә чиерттеләр. Бикташ, урыныннан калкып, тышка карады.

– Килеп җиткән дәмени инде? – дип сорады Салиха апа, агарынып.

Бикташ, «әйе» дигәнне аңлатып, башын иде.

– Бар, чыгып әйт, без авылга китәбез, диген! Кеше көлдереп тормасын анда!

Малай әнисенең шул сүзен генә көткәндәй атылып чыгып китте, минут эчендә әйләнеп тә керде.

– Киттеме?

– Мине чакыра. Әз генә йөреп килик әле, ди...

– Нинди йөрү инде ул? Китәбез, дип әйтмәдеңмени?

Бикташ иңбашларын сикертеп куйды. Икесе дә нишләргә белми тынып калдылар. Сәетҗан абый тагын тәрәзәне чиертте.

– Бар, чыгып әйт, хәзер үк китәбез, диген. Ныгытып әйт!

Малай тагын әйләнеп керде.

– Ул әйтә, азаккы тапкыр әйләнеп килик инде, ди. Тыкрык башыннан гына, ди. Минем дә китәсе бар, ди.

«Юк» димәкче булды Салиха апа. Ләкин малайның әтисе янына чыгасы килгәне әллә каян күренеп тора иде. Тегесе дә әйтәсен әйтми китмәс. Хушлашсыннар әйдә... Каты кылансаң, отыры киреләнүе бар малайның. Көянтәне дә кисәк кенә түгел, әкренләп кенә бөгәләр...

– Ун минут вакыт сиңа, – диде Салиха апа. – Ишетсен колагың, ун минут. Мин өсне алыштыруга, өйдә бул.

Малайның йөзе балкыды, күзләре нурланды.

Салиха апа чемоданнан Бикташның өр-яңа ак күлмәген, шакмаклы чалбарын тартып чыгарды. Үзенең, бер-ике киелсә дә, төсен җуймаган чуар ефәк күлмәген алды. «Кичтән карап, үтүкләп куйган булсам, ак сакаллы карт булырыем. Әллә нишләп миңгерәеп йөрдем шунда. Әнә бит, бөкләгән сырлары ничек беленә...» Ул киемнәрне үтүкләде, күлмәген алыштыргач, мич уентыгындагы кечкенә көзге каршына басып, маңгае өстендә бөтеркәләнеп торган кара чәчен тарап үрде, яңак сөякләре калкыбрак торган түгәрәк йөзен җентекләп карады. Дулкынланудан аның бит алмалары яшь вакыттагы кебек алланып чыккан иде. Кыяфәтеннән канәгать калды Салиха апа. Үзе дә сизмәстән, Сәетҗан абыйга матур киенеп, көязләнеп күренеп калырга тели иде ул. Төшеп калганнардан түгел, кешедән ким җире юк! Хәсрәтне күп күрсә дә, вакытсыз картаймады, Аллага шөкер!

Шуның белән аның эше бетте, Бикташны көтәсе генә калды. Башта ул тәрәзәдән карап торды, аннары болдырга чыкты, тыкрык янына ннан әйләнеп килде. Бикташ белән Сәетҗан абый беркайда да күренмиләр иде. Киенгән-ясанган кешеләр, төркем-төркем булып, урман юлыннан киттеләр.

– Салиха, нишләп торасың, әйдә безнең белән!

– Бара торыгыз, куып җитәрбез..

Урман аша Бөрлегәнлегә дүрт кенә чакрым, иртәнге саф һавада сөйләшә-сөйләшә бару үзе бер җан рәхәте.

Бераздан, тузан куптарып, машиналар кузгалды. Аларның әрҗәләренә шыплап яшь-җилкенчәк тулган, җырлыйлар, чыркылдашалар, гармун уйныйлар иде.

Поселок тынды. Урам уртасында бәйрәм күлмәген кигән Салиха апа берүзе басып калды.

Сәетҗан абый аны тагын алдады. Ул малаена: «Бөрлегәнлегә барган чакларың булыр әле, әйдә, менә шушы машинага утырып, бүген ераккарак барып кайтыйк, кайткач, әниеңә җавабын үзем бирермен», – дип көйләп-чөйләп, ашыктырып, Алантау Сабан туена алып киткән иде.

Ниһаять, Салиха апа баласын кулыннан ычкындырганын аңлады. Өйгә керде дә караватка, Бикташның ак күлмәгенә йөзтүбән капланды.

Үзе бер гомер булып тоелган озын көн үтеп, кич җиткәч, Бикташ белән Сәетҗан абый кайтып кергәндә, Салиха апаның ихтыяры тәмам сынган иде инде. Улы кайтудан өмете өзелгән иде, аларны күргәч, коелып төште.

Бикташ, эченнән үзенең гаебен таныса да, үсмер кирелеге белән гафу үтенергә дә теләми, Салиха апаның күзенә күренергә дә курка, шуңа күрә әтисенең аркасына ышыкланыбрак тора иде.

– Хәзер станцага машина китә, безне алырга ризалык бирделәр, – диде Сәетҗан абый. – Кая, Бикташның берәр әйберсен бирәсеңме, юкмы? Поездга өлгерергә кирәк, иртәгә иртән эшкә барасы. Адресны беләсең, баруга үзе дә хат язар. Теләсә – калыр, теләмәсә – бераз кунак булыр да кире кайтыр.

Малай һаман әтисе артыннан күренмәскә тырышты. Салиха апа, карышса, ызгышса, улының гайрәтен генә чигерәсен аңлады. Авырлык белән урыныннан кузгалып, Бикташның ак күлмәген кулына алды.

*** * ***

Бикташның шәһәргә икенче тапкыр килүе иде. Бишенче классны тәмамлагач, укытучы Флера апалары аларны анда экскурсиягә алып барган иде. Ул чакта күргәннәре балалар күңелендә татлы төш шикелле бизәкле-матур, шул ук вакытта шактый буталчык та истәлекләр булып саклана иде. Таш урамнар, киң мәйданнар, аларда айкалган бихисап халык. Кремль сарайлары, музейдагы җәнлекләр, мылтыклар, хәтта самолет. Түшәме күккә ашкан театр, аның затлы заллары, басарга куркыныч ялтыравык идәннәре. Алардан да бигрәк сәхнәдәге серле урманнар, күл төпләре... Андагы агач араларында, су асларында очынып-очынып биеп йөргән сылу кызлар, батыр егетләр, Су анасы... «Су анасы» балетын караганнар иде алар.

Укытучы апалары аларны биш катлы йортның өске катында яшәүче бер танышларында йоклатып чыгарды. Бикташның уенча, шәһәр кешеләре бар да шундый квартираларда яшиләр иде.

Ул баруда малайлар, кызлар көне буе таш урамнарда чабып, арып-әлсерәп беткәннәр иде, әмма күрергә өлгермәгән кызыклар тагын да күбрәк калды шикелле.

Флера апалары:

– Бөтенесен берьюлы күреп бетерә алмассыз, үскәч үзегез килеп карарга да калсын, – дип юатырга тырышты. Ләкин бала күңеле моның белән ризалашамыни? Кайчан үсәсең дә кайчан киләсең бит әле!

Вакыт узган саен, шәһәрдә күргән-кичергәннәр кызыграк, могҗизалырак булып искә төште һәм һаман үзенә чакырып, ымсындырып торды.

Табигый ки, шәһәргә якынлашкан саен, Бикташ ныграк дулкынланды, бу килүендә ул элеккедән дә зуррак могҗизалар көтә иде.

Иртән поезддан төшкәч, алар трамвайга утырып киттеләр, шактый баргач, троллейбуска күчеп утырдылар. Иске кыршылган өйләрдән торган тар урамнарны да, яңа йортлар тезелеп баскан киң урамнарны да үттеләр. Тукталыш саен троллейбуска яңа кешеләр керде, элек утырганнары төшеп кала барды. Чыжлап ишек ачылган саен, Бикташ урыныннан калкынды, әтисенең һаман кымшанмавын күреп, тәмам аптырады.

Менә троллейбус биек таш күпернең астыннан чыкты да, як-ягына тупыл, өрәңге, каеннар утыртылган киң юлдан бик кызу чабып китте. Уңда, агач арасында, тәбәнәк корылмалар күзгә чалынып кала, ә сулда, тау өстендә, биек, озын йортларның бихисап тәрәзәләре кояшка каршы балкып тора иде.

Бикташ үзләренең шәһәрдән үк чыгып китеп барганнарын аңлады. Моның сәбәбен сорарга теләп, авызын ачкан иде, әтисе: «Төшәбез!» – дип, ниһаять, урыныннан кузгалды.

Алар асфальт юл буйлап үргә, яңа йортларга таба менеп киттеләр. Бикташ кайсы йортка барып керәселәрен алдан ук чамаларга тырышты.

Ләкин, үргә менеп җиткәч кенә, Сәетҗан абый яңа йортларга түгел, бөтенләй икенче якка, тау кырыендагы тирән чокырга таба борылды. Чокыр тирәли үскән куе агач ябалдашлары арасында кечкенә өйләрнең шифер түбәләре ялтырап күренә иде.

Алар буялмаган такта капка янына килделәр. Капканың урта бер җиренә ак калай кисәге кагылган, аңа кара хәрефләр белән «Сак булыгыз! Усал эт бар!» дигән сүзләр язылган иде.

Сәетҗан абый, кулын такта ярыгына тыгып, кече капканың биген ычкындырды. Ишегалдыннан һау-һаулап ак түшле, ак муенына кара каеш муенчак кигезелгән, җирән сыртлы йөнтәс көчек чабып чыкты.

– Уйнак! Уйнак! Син нәрсә! Мин бит бу! – диде Сәетҗан абый. – Кунак алып кайттым менә. Ах, шаян, сагындыңмыни!

Көчек, кызыл телен чыгарып, тәпиләрен хуҗасының тезенә куйды, Сәетҗан абый аның колак артын кашыды.

– Карале, Бикташ, нинди сөйкемле этебез бар безнең!

Ләкин Бикташ аларга карамады. Ул, күзләрен ишегалдына текәп, гаҗәпләнүдән хәрәкәтсез катып калган иде. Аның исен китәргән нәрсә – резин көпчәкле, кырыйсыз такта арба белән аңа бәйләп куелган җирән бия иде. Ат бит ул! Ат! Машина булса ни әйтер идең!

Бикташ поселокта гына түгел, Бөрлегәнледә дә ат тоткан кешене белми иде. Шәһәрдә яшәүчегә ат ник кирәк икән? Әтисе аны ни дип асрый? Ә Бикташ аны әле шофер, әле очучы итеп күз алдына китерә иде бит.

– Кер, улым, кер, тарсынып торма! Өйдә кеше юктыр әле. Бәһиҗә апаң эштә, Илдар энең бакчададыр.

Болдырның бер як култыксасы сынып, ямьсез тырпаеп тора, идән такталары баскан саен селкенә иде. Үз өендә бөтен какшаганны каккалап, рәтләп торырга күнеккән Бикташ боларга игътибар итми уза алмады. Өй эче дә аңа ошамады, үз квартираларыннан кечерәк тоелды. Монда кара-каршы килгән ике кеше бер-берсенә ышкылмыйча үтәрлек тә түгел иде. Хәер, бу – әйбер күплектән туган кысанлык иде, ахрысы: бер якта диван белән зур суыткыч тора, икенче якта – савыт-саба тулы шкаф; түрдә телевизор, уртада чуклы ашъяулык җәелгән озынча өстәл. Тәрәзә арасындагы көзгедә ак күлмәкле, моңсу карашлы малай – Бикташ үзе күренде.

– Кулыңны чайкап кер дә тамак ялгап алыйк, – диде Сәетҗан абый.

*** * ***

Бикташның әтисе балалар бакчасында йөк ташучы булып эшли икән. Ерак түгел, янәшәдәге яңа йортлар арасында гына. Тау сыртлары кебек озын биналар янында ике катлы балалар бакчасы бик кечкенә булып күренсә дә, ак стенасына кызыл кирпеч тезеп ясалган әтәч-тавыклары, ишегалдындагы яшь агачлары, гөл түтәлләре, төрле төстәге гөмбәчек-өйчекләре белән тирә-юньдәге таш, асфальт һәм ком дөньясына җан өреп, үзенә бер ямь биреп тора иде.

Алар ачык капкадан бик күңелле итеп барып керделәр: алдан койрыгын боҗраландырып Уйнак, аның артыннан, таш юлга чак-чок басып, Кашкарый атлады. Ишек төбендә чандыр гына бер апа кулларын халат кесәсенә тыгып басып тора иде.

– Эх, Сәет! – диде ул, биргән сәламне дә алмыйча. – Ике кулсыз иттең син безне, ә! Сөт китерелмәгән, бәрәңге бетте, макарон җитмәде! Җомга эштә булырга тиеш идең бит син! Бу кадәр дә гамьсез, ваемсыз булырсың икән! Кайчан гына мотороллер бирерләр икән, синең белән сөйләшеп тә тормас идем!

Апаның озынча йөзе ачудан агарып калганга, борын астындагы мыегы каралып, әллә каян күзгә ташланып тора иде. Сәетҗан абый арба кырыенда ык-мык итеп таптана, мин уйлаганча килеп чыкмады, дип, нәрсәдер мыгырдана иде. Бикташка әтисен мондый мескен хәлдә күрү кыен иде, шуңа күрә ул арткарак чигенде.

Ул арада бина артыннан куыша-куыша, бер төркем бала-чага йөгерешеп чыкты, кайсы авызын ачып Кашкарыйга текәлде, кайсы, кулын сузып, Уйнакны эзәрлекли башлады.

– Пшал! Пшал! – дип кычкырды мыеклы апа. – Эт ияртеп килмә, дип ничә әйттем бит инде!

– Уйнак! Марш капка төбенә!

Уйнак урам якка чапты, балалар, чыр-чу килеп, аның артыннан йөгерештеләр, ак халатлы тәрбиячеләр, кыткылдап чебиләрен җыярга маташкан тавыклар кебек, алар арасында чуалдылар.

Бикташ каршында бия белән көчекнең дәрәҗәсе бермә-бер үсеп китте. Машина нәрсә ул! Хәзерге заманда машинага борылып караучы да юк! Әнә күпме йөреп торалар, ник бер бала бар дип белсен!

– На, әйдә, нишләп оеп каттың! – дип кычкырды Сәетҗан абый Кашкарыйга. – Өйрәнгән ялкаулыкка!

Урамга чыккач, Сәетҗан абый улы алдында акланырга, һич булмаса, үзенең теге апага дәшми торуы сәбәбен аңлатырга тиеш тапты:

– Гадәтсез марҗа! Кашын-күзен җимереп кычкырудан бүтәнне белмәс шул! Мин бер-ике сәгатькә соңарганнан детсад җимерелгән диярсең! Кычкыр әйдә, кычкыр! Бик исебез китеп тормый әле! Ник дисәң, эше рәхәт. Таңнан торып, күз ертып, заводка чабасы юк, көннәр буе тузан йотып станок янында бил бөгәсе юк. Үз көебезгә генә йөрибез.

Эше чыннан да күңелле булып чыкты Сәетҗан абыйның, һәрхәлдә Бикташка ошады. Сөт тулы бидоннарны, макарон тартмаларын төяү-бушатулар, йортларның таш стеналарын яңгыратып, чак-чок юырткан Кашкарый җигелгән, резин көпчәкле арбага утырып, җирән сыртлы, йөнтәс койрыклы Уйнакны ияртеп, узган-барганның күзен кыздырып йөрүләр хәтәр кызык икән.

Кичен өйгә әйләнеп кайтканда, малайның күңеле бик хуш иде. Уйнак алдан чапты. «Без кайттык!» дигәнне белгертеп, капка төбендә һау-һаулап куйды. Шуны гына көткәндәй, кече капкадан кыска балаклы кара ыштан кигән, түгәрәк кара башлы биш-алты яшьлек малай йөгереп килеп чыкты. Аны күргәч, Сәетҗан абый атны туктатты, малайны күтеп алды, күтәреп янына утыртты.

– Абыең килде бит, Илдар улым. Исәнләш абыең белән!

Илдар, арбага үрә басып, дилбегәне әтисе кулыннан тартып алды:

– На-на-на!

– Әкрен, улым! Чү! Егыла күрмә!

Алар килеп җитүгә, сим-сим тылсымы белән ачылгандай, олы капка да ачылып китте. Кашкарый, арт аякларына чүгә төшеп, чокыр ягына авыш ишегалдына керде. Юан гәүдәле, шома коңгырт чәчле апа аларны елмаеп каршы алды:

– Шушымыни инде ул Бикташ! – дип, кочакларга теләгәндәй, кыска халат җиңнәреннән тулышып чыккан ак беләкләрен җәеп җибәрде. – Исәнме, наныем, саумы! Карасана, нинди зур егет икәнсең! Күр, бәбием, нинди матур абыең бар синең!

Аның кочагына кереп чуммас өчен, Бикташка, шактый ук кискен хәрәкәт ясап, артка чигенергә туры килде. Апа моңа үпкәләмәде, һаман шулай ачык елмаеп:

– Әйдә, наныем, өйгә кер, – диде. – Арыгансыңдыр.

– Хәзер керербез! – диде Сәетҗан абый. – Атны тугарыйк инде.

– Юлдан килү белән эшкә җигәсе түгелие баланы! Бер дыңгырдыктан икенчесенә утыртып иләгәнсең! Ятсыние, ял итсение! Тизрәк булыгыз, аш суына анда! Сезнең бәхеткәдер инде, бүген сталавайга бик әйбәт тавыклар бирделәр... Менә бит килгән, ә син килмәс дигәниең!

Соңгысы Бикташ хакында иде булса кирәк. Сәетҗан абый туры кашларын җыерды:

– Көч-хәл инде... Ни чарадан бичара гына дигәндәй...

Бәһиҗә:

– Кая соң, әзерли торыйм! – дип, җәһәт кенә өйгә кереп китте.

Бикташ Кашкарыйның җирән ялын сыйпады. Куе, озын койрыклы, сул яңагы ак, уңы кызгылт, уң як корсагында кыйгач ак тасма сузылып төшкән, ак бәкәлле мондый ат булса да, шушы Кашкарый гына булгандыр. Шундый ягымлы үзе, кулыңны сузсаң, йомшак иреннәре белән учыңны кытыклый.

– Үзебезнең атмы бу, әти?

– Үзебезнеке, улым, башы-аягы белән үзебезнеке. Кәгазьдә детсадныкы булып исәпләнә исәпләнүен, ләкин фактически аңа мин хуҗа.

– Атланып буламы соң аңа?

– Нишләп булмасын. Улым, Илдар, кил әле!

Сәетҗан абый кече улын күтәреп, ат өстенә утыртты. Илдар сандали үкчәләре белән биянең корсагын ышкыштырды:

– На!

Кашкарый, чебен кугандай, колакларын гына селкетеп куйды. Бикташ энесенә кызыгып һәм көнләшеп карап тора иде.

* * *

Сәетҗан абыйларның ихатасы сирәк койма белән аннан-моннан гына әйләндереп алынган. Ишегалдында да әллә ни искитәрлек нәрсә юк: уң якта Уйнакның куышы да, түрдә бер иске сарай кисәге генә. Сарай артындагы чокырның үрен киртләп ясаган өч-дүрт түтәлдә, алабута, песи тарысы арасында, кишер, суган, кыяр үсеп яткан була.

Әтисе белән балалар бакчасына кирәк-яракны ташып кайтканнан соң, кичләрен Бикташ шул түтәлләргә су сибә. Суны күрше урамда төзелеп яткан бер йорт стенасындагы торбадан арбадагы мичкәгә резин шланг белән генә тутырып ала. Берочтан Кашкарыйны да коендыра. Ат пошкырып таптана, бөтен тәне белән калтырана, әмма китәргә омтылыш ясамый – суны ярата. Соңыннан Бикташ аның ялтырап торган шома тиресен ике учы белән сыпыргалап куя.

Кашкарый тулы мичкәне юыртып кына алып кайта. Бикташ суны бакчага да шлангтан гына агыза.

Аларның уң ягындагы ихатада шундый ук киртләч түтәлләргә кызыл майка кигән бер малай су сибеп йөри. Күршеләрнең бакчалары шәбрәк күренә: гөлләре, помидорлары, карлыган куаклары

бар. Тик кызыл майкалы малайның эше Бикташныкы кебек ансатка көйләнмәгән. Ике кулына ике чиләк асып, суны чокыр төбендәге кәкре-бөкре өрәңгеләр янында казылган коедан ташый ул. Тулы чиләкләрне күтәреп, үргә каршы менә.

Малай яшькә Бикташ чамасы булыр, тик гәүдәсе базыграк та, җилкәләре киңрәк күренә. Йөзе түгәрәк, кара-тутлы, туры чәчләре маңгаен каплап тора. Ул күршесенә борылып та карамый, Бикташ исә башлап сүз кушарга кыймый.

Аларның урамда да очрашканнары бар. Кичләрен көн сүрелгәч, малайлар югары очтагы такыр урынга җыелалар, кызыл балчык кантарларыннан «капка» ясап, пыр тузып футбол тибәләр. Кайчак Бикташ та, Кашкарыйга атланып, Уйнакны ияртеп, алар янына бара, атыннан төшми генә уенны күзәтә.

Кызыл майкалы малай аңа беренче тапкыр шунда эндәште. Уйный торган туплары читкә тәгәрәгәч, тузанлы битен кул аркасы белән сөртте дә:

– Әй, пацан! – дип кычкырды. – Нәрсә анда кукраеп утырасың? Уйный белсәң, төш әйдә бия сыртыннан!

Атылып төшәргә әзер иде Бикташ, уйнавын да башкалардан ким уйнамас иде, ләкин атны караусыз калдырырга курыкты. Ят малайларның гадәтен белеп булмый, берәр кая олактырсалар, эзләп тә таба алмассың Кашкарыеңны!

Бер кичне, эңгер-меңгердә күрше малае урамга велосипед сөйрәп килеп чыкты. Аны күреп, Бикташ та Кашкарыйны түбән очка таба борды. Алар тигезле-тигезсез, бормалы урам юлыннан куышып киттеләр. Әле велосипед алга чыга, әле башын югары чөеп юырткан Кашкарый. Биткә тыгыз җил бәрә, күңел ашкына, йөрәк җилкенә. Малайларның дәртен тагын да арттырып, урам яңгыратып, Уйнак өрә! Кем кемне узар иде, белгән юк, тик урам очында такыр юл өзелде, алда текә үрдән төшеп киткән сукмак кына калды. Кашкарый тезләрен чүгеп туктады, күрше малае, берничә карамый, килгән шәпкә аска томырылды. Егет икән, егылмады, «эһ» дигәнче тигез җиргә төшеп, каядыр үз юлы белән китеп барды.

Мондый хәлләрдән соң танышмый калу мөмкин түгел иде шикелле. Ләкин икенче көнне су сипкәндә теге малай тагын Бикташны күрмәмешкә салышты. Борылып бер карамый да ичмаса, суны чиләге белән селтәнеп кенә сибеп җибәрә дә, салмак атлап, тагын коега төшеп китә. Бикташ дымлы җирдә уелып калган яланаяк эзләренә аптырап карап кала. Ник сөйләшми икән ул? Ниһаять, түзмәде Бикташ, үзе сүз башлады:

– Кая, сезгә дә суны шлангтан гына сибәбез!

Буш чиләкләрен тотып китәргә җыенган малай гаҗәпләнеп аңа борылды:

– Ә үзеңә җитмәсә?

– Тагын алып килербез. Озакмыни!

Бикташ, аның ризалыгын да көтеп тормыйча, су агымын күрше помидорларына таба юнәлтте. Күрше малае Юныс исемле икән.

– Ничәнче класска күчтең? – дип сорады ул. – Сигезенчегәмени? Ә мин тугызынчыга... Хәзер бу түтәлләргә су сибеп тормасаң да була инде. Помидорларны әллә ашап була, әллә юк. Әни сүзен тыңлап кына йөрим.

– Нишләп алай?

– Озакламый күчәбез бит инде.

– Кая?

– Бәй, син белмисеңмени? Әнә теге йортка.

Юныс агач ябалдашлары аша күренеп торган тугыз катлы йортка ишарәләде.

– Безнең квартира билгеле инде. Йөз дә кырык беренче. Ә сез кая күчәсез?

– Ник, без дә күчәсемени?

Сәетҗан абый белән Бәһиҗә түтәйнең квартира турында кызып-кызып нидер сөйләшкәне аның колагына чалынгалаган иде чалынуын, ләкин Бикташ ул сүзләргә әһәмият бирмәде, өлкәннәр дә ничектер аның алдында ачылып сөйләшмиләр иде.

– Көзгә монда беркем дә калмый, – дип дәвам итте Юныс сүзен. – Чокырны күмәчәкләр, аның өстенә яңа йорт салачаклар. Самосвал килә дә – тр-р-р! – җиде тонна балчыкны берьюлы ишә дә төшерә. Эзләп кара аннары кишерләреңне!

Аларның сүзен сарай яныннан яңгыраган тавыш бүлде:

– Бикташ, наныем, эшең беттеме әле?

Бакча башында Бәһиҗә түтәй басып тора иде. Астан караганда аның кыяфәте бигрәк иләмсез юан булып күренә икән. Хәер, юан булмый хәле юк: Бикташ озакламый тагын бер энесеме, сеңлесеме буласын сизенгән иде инде.

– Азапланма, наныем, интекмә, – диде Бәһиҗә түтәй татлы тавыш белән. – Кер әйдә, карының ачкандыр.

– Хәзер, хәзер.

Бикташ, сүзен матур гына түгәрәкләргә ниятләп, күршесенә борылган иде, телсез калды. Юнысны җен алыштырганмыни! Аның әле генә гаҗәп ягымлы күренгән чырае каралып чыккан, арты белән борылып, түтәлдән алабута йолкыган булып маташа.

– Ал шлангыңны, хәзер үк ал! – диде ул, ярым пышылдап.

– Җый, наныем, шлангны, – диде Бәһиҗә түтәй дә.

Бикташ үги әнкәсенең әйткән сүзен өзми-куймый үтәтә торган гадәтен белеп өлгергән иде инде, шлангны тартырга керешге.

Алар өйгә кергәндә, Сәетҗан абый, диванга кырын ятып, телевизор карый иде. Хатынын күргәч, тураеп, җыелыбрак утырды.

– Сәхрәгә чыккансың син! – диде Бәһиҗә түтәй бусагадан атлауга. – Дөньядан хәбәрең киткән! Малаеңның нишләп йөргәнен дә карамыйсың!

Бәһиҗә түтәйнең теле гаҗәп татлы: улына «бәбием» дип, «бәгырь парәм» дип, Бикташка «наныем» дип дәшә, чит кешеләр белән сөйләшкәндә, сүз аралаш «җаныем» дип кыстырып җибәрә. Тик иренә эндәшкәндә генә тавышында бал кими, тәмле сүз дә табылмый.

– Ни булган тагын? – дип сорады Сәетҗан абый канәгатьсез тавыш белән.

– Теге башкисәр, Сәйдәнең хулиганы, эләктереп алган бит малаеңны! Акча түләп яллаганмыни, түшен киереп баскан да Бикташтан бакчаларына безнең мичкәдән шабыр-шобыр су сиптертә!

– Соң үзе риза икән, сибә бирсен!

Бикташ та:

– Мин үзем... – дип башлаган иде, үги ана аны тыңлап тормады.

– И-и, наныем! Мондагы халыкны белмисең шул әле син! Кара елан кебек эчеңә кереп, бөтен сереңне алып чыгалар, сизми дә каласың!

Бәһиҗә түтәй күз иярмәс тизлек белән бәрәңге әрчеде, ризык тулы сумкасын бушатып, табын әзерләде. Үзе туктаусыз Бикташка үгет-нәсихәт укыды. Бигрәк уңган шул Бикташның үги әнкәсе, бөтенесенә җитешә.

Аның сүзеннән малай шуны аңлады: Юныс хәтәр әшәке, эчкерле малай икән. Тыштан гына ялтырый, эче тулы мәкер икән. Ата-анасы да күршеләрен чагарга җай чыкканны гына көтеп йөриләр. Алардан ерак йөрүең хәерле...

– Тыштан сиздермиләр! – диде Бәһиҗә түтәй. – Сәйдәсе очраган саен миңа, кибеттә ит юк бит әле, тавык юк, сез каян аласыз, дип төрттереп куя. Безне сталавайдан ташып ашаган итеп күрсәтмәкче була. Бусының да теле тик тормыйдыр, бөтенесен энәсеннән җебенә сорашадыр. Шулаймы? Квартира турында сорашкандыр әле, ие бит?

Бикташ шаккатты: каян белгән ул малайларның ни сөйләшкәнен, каян ишеткән?

– Ие шул, сорады...

Бәһиҗә түтәй, ипи кискән җиреннән пычагы белән иренә ишарәләп:

– Ишеттеңме? – диде. – Әйттем мин сиңа! Шул маңканы да шпионлыкка өйрәтеп куйганнар инде. Башкача булдыра алмагач, малайлар аркылы чакмакчылар!

Бикташ берни аңламый аптырап калган иде: нинди шпион? Кем шпион? Юнысмы? Кем куйган аны шпион итеп? Ник куйган? Малай, сорауларына җавап эзләп, әтисенә борылды. Ләкин Сәетҗан абый, мәсьәләгә ачыклык кертәсе урында, хатынының сүзен җөпләде:

– Шулай шул, улым, бик астыртын монда халык, – диде. – Сереңне бик оста алалар. Бар белгәнеңне чыгарып селкергә ярамый, авызны бик чамалап кына ачарга кирәк. Ник дисәң, берәү дә сине кайгыртмый, үз файдасын гына карый. Туры килгәндә, этлек эшләүдән дә тартынып тормыйлар. Алай-болай сораша башласалар, сак бул, әти янында торып укырга килдем, диген дә бетте-китте.

Бу күңелсез һәм Бикташ өчен бөтенләй аңлаешсыз сөйләшүдән соң ашау-эчүнең дә рәте булмады. Хәер, табын янында малай үзен болай да бик уңайсыз хис итә торган иде. Үги ана, аша-аша, тегесен кап та монысын авыз ит, дип кыстап кына утыра утыруын да, Бикташ үрелгән саен ялт итеп карап алгалый, чәйгә ничә шакмак шикәр салганына чаклы саный иде шикелле.

Шуның өстенә энесенең дә бик начар гадәте бар тагын: әле өстәл астыннан өлкәннәргә сиздерми генә тезгә тибә, әле кашык сабы белән янтыкка китереп төртә. Бикташ әләкче түгел, түзә, чыраена да чыгармаска тырыша. Малай исә аның саен аза бара иде.

Бу юлы да Бикташ шулай чыдап-чыдап утырган иде, кинәт корт чаккандай сикереп торганын үзе дә сизми калды, өстәл кырына бәрелә-сугыла, аркасын күрергә тырышкандай, боргалана башлады.

– Алла! Ни булды? Нишлисең? – диде Бәһиҗә түтәй, күзләрен шар итеп.

Бикташ кабаланып күлмәк итәген чалбар бөрмәсеннән тартып чыгарды, аркасыннан бер уч кайнар бәрәңге боламыгы сыпырып алды. Ә Илдар сикергәли-сикергәли көлә иде.

– Разбойник! Тик утыра белмәсәң, мин сине! – дип, кашык белән янады аңа әтисе.

– Ярар-ярар, котын алма сабыйның, – дип каршы төште аңа Бәһиҗә түтәй. – Бала-чага алай гына да шаярмый тормас инде.

Ул кичне Бикташ Кашкарыйга атланып йөрмәде, малайларның футбол уйнаганын карарга да бармады. Болдырда ямансулап, уйланып утырды. Якты Тәрәзә поселогының урманнарын, түр башында әнисе пешергән ярмалы бәрәңге ашап утырган чакларын, сеңлесе Фәниянең «абыем» дип өзелеп әйткән сүзләрен, коңгырт күзләренең нурлы карашын сагына иде ул. Һәр сүзне кирегә сукалый торган Васьканы, дөрләп кабынырга гына торган сугыш чукмары Буран Рәмзине, бер иярсә, артыңнан калмас Садрыйны сагына иде. Хәзерге минутларда урамда шулар белән әвәрә килеп йөрүгә ни җитә! Үзенең велосипеды булмаса булмасын, малайлар биреп тора бит!

Ишегалдында Илдар Уйнак белән шаяра. Көчек малай алдына килә дә, тәпиләрен бөгеп, җиргә иелә, үзе, телен чыгарып, тәмле әйбер сорый. Көчек кенә түгел, арбадан печән чемченеп торган Кашкарый да, аклы-кызыллы башын борып, алар ягына караштыргалап ала, ул да сый өмет итә. Илдарның аларны шикәр, конфет, җимеш белән сыйламый калган көне юк. Бәһиҗә түтәйнең кунак табынына дип җыеп куйган тәм-томнарының бер өлеше ат белән эт авызына кереп тора. Ул гына җитмәсә, Илдар урам очындагы такта ларекка йөгереп барып кайта, аннан бия белән көчеккә тагын да затлырак күчтәнәчләр эләгә: шоколадтыр, зефирдыр, кайчак морожный да. Аларына акчаны Илдар әнисенең кесәсеннән чәлдерә. Бәһиҗә түтәй белә микән боларны? Юктыр, белсә, шкафын актарганда һәм кесәсендәге тиеннәрен барлаган чакларда, аптырап калмас иде. Тик ул шикле карашын Илдарга түгел, күбрәк Бикташка төби. Каравын карый, әмма телен әйләндереп сорамый. Ул сорамагач, Бикташ та серне чишми...

Бүген Илдар ларектан тышына «Имбирь» һәм «Ванильле шикәр» дип язылган кечкенә кәгазь каплар алып кайткан. Кашкарый белән Уйнакны ят ризык белән сыйламакчы. Ат, малайның учын бер генә иснәп карады да, пошкырып, ак порошокны өреп төшерде. Илдар аның ак аяклары тирәсендә күпме генә чуалса да, башка алдый алмассың дигәндәй, башын аска имәде. Ә Уйнак алданды, сыйны ерактан гына иснәп карамакчы булган иде, малай, җаен туры китереп, бер кап «Имбирь»не аның битенә сылап куймасынмы! Уйнак кызык кына итеп төчкереп җибәрде, йөнтәс битен койма янындагы үләнгә сөртте. «Ах, юләр маэмай, юләр маэмай, белер-белмәс өмсенсәң, менә шулай була ул. Мин дә монда менә шулай өмсенеп килгән идем. Ник шулхәтле ашкынып килдем соң әле мин монда? Нишләп бу хәтле озак торам?»

Бигрәк катлаулы, аңлаешсыз булып чыкты бу шәһәрнең кешеләре дә, Бикташның әтисе дә, үги әнисе дә, күрше малае Юныс та, хәтта шушы җирдән нибары бер карыш үскән Илдар да кәбестә кебек мең катлы – аңлап-белеп бетерерлек кенә түгел. Ә Якты Тәрәзәдә һәммәсе гап-гади, аңлаешлы иде. Әнисенең һәр сүзе, сеңлесенең бар уе, малайларның бөтен кыланышлары көн кебек ачык иде анда, Бикташның шул эчкерсез, күңелгә якын кешеләр арасына кайтып китәсе килде.

Мөгаен, кайтып киткән булыр иде ул. Ләкин Бәһиҗә түтәй аның эчендә ни барын әллә каян күреп торган икән, йокларга ятар алдыннан мондыйрак сүз башлады:

– Сәетҗан, карале! Бикташ, наныем, син дә тыңла, – диде. Бу юлы иренә дәшкәндә аның тавышы чит кеше белән сөйләшкәндәй ягымлы яңгырады. – Әллә соң берәр җиргә эшкә урнаштырыйкмы сине? Балаларны каникулда күп җиргә эшкә алалар бит хәзер. Әнә безнең савыт-саба юучы Вәлия сөйләп торды әле, сигезенчене бетергән игезәкләрем заводка урнашканнарые, ди, ике атна үтүгә кулыма алтмышар тәңкә акчаны шыгырдатып кайтарып тоттырдылар, ди. Аена йөздән артык төшә икән. Без синнән акча җәлләмибез, ни кирәк, шуны алып бирербез, сора гына. Алай да үзең тапкан акчаны тоту күңеллерәк бит ул...

Башта Бикташ, юк, мин кайтып китәм, дип кырт кисмәкче иде. Ләкин аңа сүз кыстырырга җай булмады: Бәһиҗә түтәйнең сүз тегермәне бер тарта башласа, туктауны белми иде. Аңа Сәетҗан абый да куәт өстәде тагын:

– Эш безнең детсадта ук та бар барын. Әле төнге каравылчыбыз отпускыга чыкканые, ул кайтуга икенчесе китәм дип тора. Безнең хуҗа кеше таба алмый ах итә. Малайның яше җитми дип каршы төшмәсәләр... Җаваплы эш бит.

Бәһиҗә түтәй өчен андый гына киртәләр чүп тә түгел.

– Ә син каравылчы булып үзең күч, – диде ул. – Йөк ташырга Бикташны куйсыннар.

Бикташ муллыкта үсмәде. Йөзәрләгән акчаны аның үз кулына алу түгел, кеше кулында да күргәне юк әле. Әгәр дә менә хәзер ул, бер-ике йөз сум акча эшләп, әнисенә кайтарып бирсә, ә? Түбәсе күккә тияр иде әнисенең, рәхмәтләр укып туймас иде. Ә бәлки, акчалата алып кайтмаска, бүләк алыргадыр. Әнисе белән сеңлесенең икесенә пардан матур күлмәкләр, тәмле конфетлар... Бер чемодан күчтәнәч... Йөз тәңкә һәммәсенә җитә: бүләк-күчтәнәченә дә, чемодан алырга да. Ә бәлки, велосипед алырга да артып калыр әле!

Малай күз алдыннан әллә нинди матур күренешләр йөгереп узды...

...Бакчада эшләү Бикташка бик ошады. Кичләрен ул килгәндә, ике катлы бинада пешекче Фая түтәй генә калып, икенче көнгә бәрәңге әрчи. Бикташны ул, җыерчык баскан йөзен тагын да ныграк җыерып, ягымлы елмаеп каршы ала, әрчи торган бәрәңгесен өч чиләк сыешлы алюмин кастрюльгә ыргыта да, суда бүртенгән кулларын халат итәгенә сөртеп, малайны сыйларга керешә. Тәбәнәк

өстәлгә нәни тәлинкә белән манный боткасы, котлетлар, җимеш суы куя. «Аша, балам, аша, синең яшьтә ризык тәмле була, – ди. – Иң үсә торган чагың. Минем нәкъ синең хәтле оныгым бар, сиңа охшаган да бераз. Сирәк күрәм, ерак торалар. Күргән саен көчкә таныйм, бер карыш үсеп куйган була... Нык аша, балам, үсәргә кирәк сиңа». Ни хикмәттер, Фая түтәй биргән ботка Бәһиҗә түтәй ашаткан майлы тавык ботларыннан тәмлерәк тоела.

Тамак ялгагач, ата белән малай чүкеч, келәшчә алалар, уенчык шикелле кечкенә өстәл-урындыкларның сынган аякларын, какшаган аркаларын кагып-сугып куялар. Ул эш өчен теге апа аерым хак түли икән.

Шул шөгыль аркасында Бикташ бакчада тулы бер хәзинә барлыгын белде. Ул хәзинә – бер чоландагы шомартып ялтыратылган такта, фанер, борыс кисәкләре, җилем, лак, буяулар иде. Агач эшен яраткан кешегә җаны ни тели – шул бар.

Ватылган өстәлләрне рәтләгәндә, Бикташның күз алдына гел сеңлесе Фәния килеп баса. Күптән инде ул кыз: «Курчагыма караваt ясап бир әле», – дип, абыйсына ялынып йөри иде. Әле агачы, әле теләге, әле вакыты булмады. Хәзер менә агач та, вакыт та җитәрлек, теләк тә бар иде. Малай аның өчен иң шома такта кисәкләрен, иң матур буяуларны сайлап алды.

Шул караватны ясый-ясый, әтисе белән иркенләп сөйләшеп, кич утырулары рәхәт иде.

Тик Сәетҗан абый гына кайчак улының кәефен төшергәләп куйгалый иде. Әтисенең «чумара каеруын» яратып бетерми иде малай.

Бакчага кирәк-яракны кайтарып бетергәч, алар Кашкарый белән хуҗалык товарлары кибете янына китәләр. Кибет биш катлы йортның беренче катын буеннан-буена алып тора, тоташ тәрәзәдән торган стенасы аркылы эче үтәли күренә. Арбада утырып калган Бикташ әтисенең халык арасында чуалганын ничектер кыенсынып, оялып күзәтә. Ярый әле озак йөрми Сәетҗан абый, берәрсен ияртеп килеп тә чыга. Арбага өстәл, урындыклар, зур-зур буяу савытлары салалар йә булмаса буш тартмалар төйиләр – кемгә нәрсә кирәк. Йөкне тиешле урынына илткәч, бишенче йә дүртенче катка менгереп тә биргәлиләр. Сәетҗан абыйның чалбар кесәсенә акча акмаса да тама.

Шулай өч-дүрт тапкыр әйләнгәч, ул акчаны тиененә кадәр саный да, нәкъ урталай бүлеп, яртысын Бикташка суза:

– Өлешеңә тигән көмешең!

Башта Бикташ ул акчаны алырга кыймыйча, кызарынып, каушап төшкән иде.

– Ал, ал, – диде әтисе. – Миндә барыбер тормый ул. Тутаң кулына эләксә, күзеңә дә чалындырмас. Тик кара аны, юк-барга әрәм итмә!

Улына акыллы киңәш бирә Сәетҗан абый, тик үзе генә аны тотып бетерми. Бикташны тагын урамда калдырып, ашыгып азык-төлек кибетенең арткы ишегеннән кереп китә дә озак та тормый, кызарынып, күзләрен, май урлаган мәче шикелле, елтыратып килеп тә чыга. Бикташ өчен иң кыены шул инде: әтисенең битенә тимгелләнеп чыккан таплар да, аның авызыннан аңкыган сасы ис тә, гаепле карашы да малайның күңелен рәнҗетә. Аңа әтисенең ямьсезләнгәнен күрү читен. Эх, шул эчү дигән нәрсә булмаса! Эх, әтиләр сирәк кенә булса да улларының сүзләренә колак салсалар! Кайбер әтиләргә үсмер улларыннан акыл алу файдадан башканы бирмәс иде дә бит, аларның фикерен сорарга, тыңларга теләмиләр шул!

Хәер, Сәетҗан абый бу эшенең улы күңеленә хуш килмәгәнен сизә, төшереп алган кичләрне аеруча ягымлы, сүзчән була.

Бакчаны саклау эшен тулысынча Уйнакка ышанып тапшыралар. Маэмай, кечкенә булса да, үз бурычын яхшы белә, ят кеше килгәнен сизсә, дөнья куптарып өрә, буе җитсә, тешләп алырга да күп сорамый!

Шуңа күрә Сәетҗан абый диванга җәелеп утыра, папиросын кабызып җибәрә дә идәндә агач кырып азапланган улына башыннан кичкәннәрне сөйләргә керешә. Аның гомерендә иң рәхәт, иң истәлекле чагы – казах далаларында йөрүе булган, шуннан соң ул бер кызык та күрмәгән, ахрысы. Чөнки сүзне нәрсәдән генә башламасын, һаман шул дала турындагы кыйсса белән очлап куя.

– Һәркемгә үз баласы газиз, һәр кешегә үз сабые матур, һиммәт күренә, – ди ул. – Менә син казахларны гына кара: дегеткә чумып чыккандай кара-чутыр балаларын «ак ботам» дип сөяләр. Ник дисәң, «ботам»ы дөя бозавы дигән сүз, ә дөянең бозавы бәләкәй чакта илла да сөйкемле була инде. Ак та булып туса, казахның аңа тәмам һушы китә. Дөя бозавын күргәнең бармы соң әле синең? Юкмыни? Мондагы зоопаркта дөяләр бар, бер алып барып күрсәтермен әле. Дөрес, ул дөяләр чын дөянең шәүләсе генә инде, бикләнеп ятып күләгәгә калганнар. Ә дала дөяләре карарга куркыныч була. Ник дисәң, абзарда бикләнеп ятмыйлар, иркенләп сахрада йөриләр. Көтүчесе дә юк аның, караучысы да, үз көенә йөри шунда. Кыш җиткәч кенә хуҗалары тотып ала, чөнки кышын даланы кар баса, машина юлы өзелә, дөягә атланып кына йөреп була. Яз җиткәч, тагын сахрага чыгаралар аларны. Казах даласы өчен менә дигән хайван инде, әйтәсе дә юк. Ләкин бер куркыныч ягы да бар. Яз җиткәч, ата дөяләр котыра башлый. Күзе акая, авызыннан күбек ага, ни-нәрсә күзенә чалынса, шуңа ташлана. Ат белән дә котыла алмыйсың, шундый каты чаба. Куып та җитә, күкрәге белән

бәреп егып, таптап та китә. Шуңа күрә яз көне кеше далага коралсыз чыкмый да. Артыңнан ата дөя куа башласа, коралсыз ни кылмак кирәк? Бетте баш, дияргә генә кала!

– Ә корал белән нишлисең? – дип сорый дөньясын онытып тыңлап утырган Бикташ.

– Нишлисең! Үләсең килмәсә, маңгаена төбисең дә атасың инде, шул гына!

– Аны үтерергә ярыймыни?

– Ярамый нишләсен! Башкача котылу чарасы юк бит!

Бикташ бу күренешне бөтен төсмерләре белән аермачык күз алдына китерә. Менә офыклары күксел рәшә белән томаланган такыр, соры дала. Юлсыз җирдән бер җайдак бара, ул, ияреннән күтәрелә төшеп, алга иелеп, бар көченә атын куалый. Атның җирән ялын, озын, куе койрыгын каршы искән ачы җил тарый. Атның бәкәлләре ак, сул яңагы да ак, корсагының уң ягында кыйгачлап сузылган киң ак тасма бар, үзе җирән, нәкъ Кашкарый шикелле. Ул, башын югары чөеп, күкрәге белән тыгыз һаваны ерып, ярсып чаба, аның артыннан күк күкрәгәндәй дөпелдәп, кар тавы кебек, биек ак дөя килә. Күзләрен кан баскан, авызыннан ак күбек чәчри. Менә ул җайдакны куып җитә, тоякларын югары чөеп, Кашкарый өстенә ыргыла. Шул чакны җайдак күн бушлат кесәсеннән ялтырап торган кара пистолет тартып чыгара. Менә, күзләрен кыса төшеп, артына борыла, аның йөзендә тәвәккәллек. Бу – Бикташның әтисе Сәетҗан. Менә ул, пистолетны дөянең маңгаена төбәп, чакмага баса. Шартлау авазы яңгырый, дөя, ишелгән тау кебек, гөрселдәп җиргә ава.

– Ә синең андый дөяне очратканың булдымы? – дип сорады Бикташ.

– Ник булмасын! Мин далада күп йөрдем бит!

– Үтердең дәме? – Бикташның тәне чымырдап куйды.

– Булгалады инде... Берсендә җиде пуляны бер-бер артлы терәп атып бетердем.

– Хәзер дә бармы соң әле ул синдә?

– Нәрсә?

– Пистолет!

– Хәзер юк. Алып калдылар. Корал йөртергә рөхсәт юк бит монда.

Бу кичләрнең рәхәте, яме Бикташ ясый торган уенчык караватка да күчте. Бик тә пөхтә, җыйнак килеп чыкты ул. Малай аның баш-башына чәчкәләр уеп ясады, аякларына кечкенә тәгәрмәчләр беркетте. Ниһаять, буяулары кипкәч, уенчыкны идәнгә куеп, сак кына этеп җибәрде. Курчак караваты, ал чәчкәләре, кызыл тәгәрмәчләре белән җемелдәп, идәндә күңелле тәгәрәп китте.

– Ни ул? Нәрсә ясадың? – дип сорады Сәетҗан абый, дала турындагы хыялларыннан арынып.

– Бүләккә... – диде Бикташ. – Авылга алып кайтырга.

Әтисенең күңелен китәсе килмәгәнгә, сеңлемә дип атап әйтмәде.

Иртән өйләренә кайтканда ул уенчыкны арбага куймады, юка пыяла савытны саклагандай, тезе өстендә тотып кына утырды.

Ләкин саклап бетерә алмады. Ишектән керүгә Илдар аның кулындагы уенчыкны күреп тә алды, килеп тә ябышты:

– Бир, бир, бир!

– Карале, минем бәгырь пәрәмә абыйсы нинди матур уенчык алып кайткан! – диде Бәһиҗә түтәй, шаккатып.

Ярый әле үги ананың эшкә ашыккан чагы иде, ул малаен ашык-пошык киендерде дә акырта-бакырта җилтерәтеп алып чыгып китте. Уенчыкны алырга рөхсәт итмәде.

– Андагы мир баласына барып эләксә, кичкә хәтле сыңар тәгәрмәче дә исән калмас! – диде.

Энесе белән үги әнисенә күренмәслек итеп кая яшерергә аны? Бикташ як-ягына каранды. Җиһаз тулы өйдә андый урын юк иде. Малай уенчыкны ишек катындагы почмакка, авылдан алып килгән чемоданы артына куйды. Илдар кичкә хәтле онытыр, кайткач эзләп азапланмас дип өметләнде.

Ләкин ялгышты. Бикташ кич кайтып кергәндә, уенчыкның кызыл тәгәрмәчләре бер якта, ал чәчәкле такталары икенче якта таралып ята, алар өстендә бер күзсез, бер аяксыз соры аю баласы ауный, ә Илдар үзе, уенчыкның кызыгын күптән югалтып, ишегалдында Уйнакны каражимеш белән сыйлап маташа иде.

– Әти! – диде Бикташ, ватык уенчыкны күргәч үзәге өзелеп. – Әти! Карале!

Чөйдәге пинжәге кесәсеннән папирос эзләп маташкан Сәетҗан абый «ә» димәде, «җә» димәде, ишек өстенә башын бәрмәс өчен иелә төшеп, өйдән чыгып ук китте.

Әтисенең дәшмәвеннән дә бигрәк, йөзендәге битарафлык, гамьсезлек авыр тоелды малайга. Ник әз генә булса да хәлгә керми, ичмаса бер җылы сүз әйтми ул? Күрде бит ул Бикташның уенчыгын нинди зур көч куеп, ничек тырышып ясаганын, бүләккә икәнен дә белде. Икәүдән-икәү чакта, эштә, бакчада ягымлы, үз тоелган әтисе өйгә кайткач кына ник болай үзгәрә икән? Бу нәрсә малайның бәгырен уенчык ватылу хәсрәтеннән дә ныграк телгәләде.

Бикташ сеңлесенә бүләккә өр-яңа уенчык ясады, ләкин анысын энесе белән үги әнисе күзенә чалындырмады, алар өйдә юкта гына алып кайтты да, кәгазьгә урап, такта кисәкләре белән каплап, Уйнак куышының почмагына яшереп куйды.

Әтисе биреп килгән чумара өлешен дә, шакмаклы дәфтәр битенә төреп, шул ук куышның төбәсендә, такта ярыгында саклый торган итте.

Укырга керер чак җитте, ә Бикташ һаман авылга кайтып китә алмады.

– Озакламый яңа йортка күченәбез, әтиеңә әйбер-кара ташырга булышырсың, – дип үгетләп килде үги әнисе.

– Электротехник училищега әзерлек курслары октябрьдә ачыла икән, шуңынчы түз инде, – дип ымсындырып һәм юатып торды әтисе.

Бакчада эшләгән өчен Бикташка йөзләп үк булмаса да, туксан сумга якын акча тиде. Киңәш-табыш итешеп, ул акчага малайның үзенә коңгырт шакмаклы костюм, береты-ние белән зәңгәр болонья куртка, ботинка, мәктәптә кияргә сандали, кедалар алдылар.

– Үзең эшләгән акчага алган кием бик кадерле була ул! Эссе тәнеңдә тузсын, наныем! – диде Бәһиҗә түтәй, Бикташның иңнәреннән сыпыргалап. «Ярый әле теге акчам тотылмый кала!» – дип уйлады Бикташ, эт куышы төбәсенә яшергән уналты сум да утыз җиде тиен акчасын күз алдына китереп.

Бәһиҗә түтәй аңа тагын портфель, китап-дәфтәр, ручкалар да алып бирде:

– Кем баласы, дигәндә, аның баласы дип әйтерлек булсын, йөз кызарырлык булмасын, – диде.

Сентябрь башында Чокыр буе урамында күченү ыгы-зыгысы башланды. Әледән-әле шкаф-өстәлләр төялгән, зур-зур савытлы гөлләр куелган машиналар үтеп тора, йортлар бушап кала, ихаталарга ташландык төс керә, капкалардан «Сак булыгыз! Усал эт бар!» дигән калайлар алынып, эре, тигезсез хәрефләр белән «Ашыгыч рәвештә сүтеп алу өчен сатыла!» дигән сүзләр языла.

Беренчеләрдән булып Юныслар күчеп китте. Бикташ аларның бөтен семьялары белән шау-гөр килеп машинага әйбер-кара төягәннәрен капка төбеннән моңаеп карап торды. Юныс аңа күз дә салмады. Күрше малаеннан сәлам биргәндәй, машинадагы роза гөленең сабаклары гына шактый вакыт күздән югалмыйча, җилдә җилпенеп барды.

Җир тетрәүдән калгандай җимерек, шыксыз урамда бер Сәетҗан абыйлар гына һаман яшәп яталар иде әле. Бәһиҗә түтәй, кешеләр яллап, өр-яңа квартирасына күчкәнче үк ремонт ясатырга кереште.

Бакчага әтисе белән бергәләп эшкә йөрүләр, икәүдән-икәү генә әңгәмә корып, озак итеп кич утырулар бетте. Бикташ өчен бердәнбер юаныч булып Уйнак белән Кашкарый калды.

Маэмай малайның мәктәптән кайтканын капка төбенә үк чыгып көтеп ала. Бикташ портфелен генә кертеп куя да сәгатьләр буе аның белән булаша: әйберне китереп бирергә, арт аякларында йөрергә, «кил», «тот», «чиген» дигәннәрне үтәргә, кыскасы, эт белергә тиеш дип санаган бөтен һөнәрләргә өйрәтә.

Кичкә таба, күңелле теркелдәп, Кашкарый кайтып керә, Бикташны күрүгә, кәефең ничек дигәндәй пошкырып, туры колакларын селкетеп куя. Сәетҗан абый дилбегәне арбага ташлый, атны тулысынча улы карамагына тапшыра. Бикташ, арбага мичкә салып, суга бара – инде түтәлләр бушаган, ләкин хуҗалыкта су беркайчан да артмый. Кран янында Кашкарыйны эчерә, коендыра, учлары белән аның ялтырап торган шома, тыгыз тиресен сыйпый. Янында сикергәләгән Уйнакка да бер-ике кат сиптереп ала. Аннары аларның чокыр ярыннан печән чабып кайтасы була, шуннан соң Бикташ Кашкарыйга атланып йөреп килергә чыга. Алар өчәүләп бушап калган футбол мәйданчыгына баралар, яңа йортлар тирәсеннән урыйлар.

Кашкарый белән Уйнак Бикташның әтисе өендәге шактый күңелсез тормышын яктыртып, җылытып торган учак иде. Кайчак ул, Кашкарыйга атланып, тау итәгенә килә дә сын шикелле озак кына хәрәкәтсез басып тора. Аның аяк астында тынгысыз олы юл сузылып үтә, шаулап-гөрләп торган зур кала күренә. Бикташның күңел түрендә могҗизалы истәлек булып саклана торган музейлар, театрлар кай турыдарак икән?

Кашкарый белән очып кына барсаң иде дә шунда, Флера апалары белән бергәләп карап йөргән җирләрне тагын бер тапкыр күреп кайтсаң иде...

Ял көнне әтидән сорарга да, иртәрәк чыгып китәргә дип уйлады Бикташ.

Якшәмбе көнне әтисе Бикташны иртүк уятты:

– Тор әле, әйләнеп кайтасы җир барые.

Бикташ Кашкарыйга атланып бару турында хыялланган юлдан алар арбага утырып киттеләр. Көн салкын, болытлы, каршы җил биткә машина сөреме катыш тузан бөрки.

Олы юл буйлап арбада бару бер дә рәхәт түгел икән. Арттан килгән зур машинаның каты үкерүен ишеткән саен, ирексездән Бикташның муены җыерыла, аркасы чымырдап куя. Кашкарыйның гына бернәрсәгә дә исе китми, өстенә менәрдәй булып ажгырып килгән үзбушаткычларны да, тормозларын каты чинаткан «Жигули»ларны да бар дип тә белми ул, башын чайкап, чак-чок басып юыртуын гына белә.

Бикташ әтисенең бөкрәя башлаган аркасына, кепка белән керләнгән яка арасында күренеп торган җыерчыклы, кызыл муенына карап бара. Сәетҗан абый кымшанмый, дәшми. Кая баралар алар?

Олы урамга кергәч, Бикташ сүз башларга омтылып карады:

– Бу ни, әти? – дип, ак колонналы зур бинага күрсәтте.

– Сарай, культура сарае, – диде Сәетҗан абый, башын бормый гына. – Клуб ягъни.

– Дүрт каты да клубмыни?

– Шулайдыр инде. Эченә кереп карамагач, әйтү кыен.

Тагын бераз машиналар шавын һәм тояклар тыкылдавын тыңлап бардылар.

– Ә бусы ни? Тагын клубмы?

– Шул инде. Кинотеатр.

Әтисенең сөйләшәсе килмәгәнен сизеп, малай бүтән сорау бирмәде. Ул күңелендә авыр бушлык тойды, зур калада адашып калгандай, эче пошты.

Озак барды алар. Урамнарның киңнәрен, яңаларын да, тарларын, искеләрен дә шактый үттеләр. Ниһаять, уртасына ике рәт булып лареклар тезелгән бихисап халык айкалган киң тыкрыкка килеп керделәр.

Базар иде бу. Сәетҗан абый, арбага үрә басып: «Әй, чиген! Үткәреп җибәр!» – дип кычкыра-кычкыра халыкны ерып бераз барды да Кашкарыйны уңга, шар ачык капкага таба борды. Ат, өч яктан икешәр катлы ямьсез иске йортлар белән, дүртенче яктан, түрдән, акбурга буялган вак-төяк корылмалар белән уратып алынган шәрә, күңелсез ишегалдына барып керде. Урта бер җирдә хәрәкәтсез басып торган алмачуар ат арык янбашларын сәер генә сикертеп читләште.

Өй буендагы тар такта эскәмиядән өч агай торып бастылар. Шома чырайлы, очлы иякле берсе, кулларын плащ кесәләренә батырып, баскан урынында калды, кашларына ук төшереп кигән эшләпәсе астыннан күзләрен елтыратып, башкаларны читтән генә күзәтеп торды. Ак чүпрәк куртка белән ак кәпәч кигән кызыл чырайлы абый һәм кәләпүшле, очлы сакаллы ябык кына бер бабай Сәетҗан абый белән илтифатсыз гына исәнләштеләр дә, тамакларын кыргалап, Кашкарыйга якынлаштылар. Кызыл чырайлы тезгенгә ябышкан гына иде, Кашкарый чыбыркы белән корсак астына сыдыргандай сискәнде, башын югары чөйде, бөтен гәүдәсе белән калтыранып, таптанып артка чигенде, арба артында торган Бикташны бәреп ега язды.

– Но-но! – дип җикерде кызыл чырай, җирән төк баскан зур куллары белән атның авызлыгына үрелеп.

Ни булыр иде, белгән юк, кызыл чырайлыны кәләпүшле бабай туктатты:

– Нишлисең син? Ат күргәнең юкмы әллә? Сыерга ябышкандай кыланасың! Сабыр, җирәнкәй, сабыр! Ярсыма юкка! Мәле, кап, мәле!

Карт, бишмәт кесәсеннән конфет алып, кәгазен сүтте дә атка сузды:

– Ал, ал! Курыкма!

Үзе, ат капкан арада, җәһәт кенә аның иренен каерып, тешләрен карарга өлгерде.

– Һиммәт, һиммәт! – диде карт, тик нигәдер чырае караңгыланды, нәрсәнедер ошатмагандай, кәләпүшен бер алга, бер артка шудырды. Кызыл чырайлыга: – Син, Мәрдән, читтәрәк тор, – диде. – Ярсытма малны. Ит исе килә синнән. Читтән дә күренеп тора бит инде малның нindилеге. Тел-теш тидерер җире юк. – Ул Кашкарыйны берничә тапкыр әйләнеп чыкты, тоякларын күтәртеп карады, ялын сыпыргалады. Мактады, ә үзенең йөзендә канәгатьсезлек ярылып ята иде. – Шәп! Асыл мал бу! – диде.

– Син нәрсә, Кыям абзый, кемлегеңне оныттыңмы әллә? – дип тавыш бирде, ниһаять, эшләпәле. Аның тавышы куе, ышанычлы, әлеге адәмнең кешеләр белән өстән карап сөйләшергә күнеккәнлеге әллә каян сизелеп тора иде. – Ник шулчаклы мактыйсың? Иясе күбрәк сорасын, дипме? Акчаң җитмәсә, нишләрсең?

– Ат күрсә, чут-чаманы оныта бит ул, – диде кызыл чырай.

– Мал таный белгән кешегә моннан да яхшысы юк инде, – дип сүзгә кушылды Сәетҗан абый. – Яшь, көр, яхшы нәселдән...

– Сыер нәселеннән булса, безнең өчен әйбәтрәк тә булыры, – дип көлде кызыл чырай. – Без бит аны Сабан туенда чабышырга алмыйбыз.

– Чабыш аты түгел бу, – диде карт кырыс кына. – Эш аты бу, крәстияннең терәге. Мондый атың булса, элекке заманда бөтен тормышыңны гөл итеп була иде. Соңгарак калып тугансың шул, җирәнкәй. Эх, мин яшь чакта кулга эләккән булсаң!

Карт тамырлары бүрткән, буыннары бүлтәйгән, кәкре бармаклы куллары белән Кашкарыйның сыртыннан сөеп куйды, Бикташ ул кулларның йомшак назын үз тәнендә тойгандай булды.

– Эләкмәде шул миңа синдәй атлар! Үтте гомерләр! Хәзер менә сезнең өчен дә дөньялар тарайды! Чын бәягезне дә белүче калмады!

– Алай бик ошаса, үзеңә ал син аны, Кыям абзый, – диде эшләпәле, көлемсерәп. – Ал да асра Аллага тапшырып. Без каршы төшмәбез.

– Шушы малкай сыярлык кына ишегалдым булса да, сездән сорап тормас идем, алыр идем дә китәр идем, – диде карт, көрсенеп. – Сатма син аны, туган, – диде аннары, Сәетҗан абыйга борылып. – Яшәсен бераз, ә? Бер колынласын, ичмаса, нәселе калсын! Күр син, нинди сөйкемле!

– Соң, аласыгыз килми икән, ялынучы без түгел!

– Тукта әле, тукта, – диде эшләпәле, якынрак килеп. – Бар әле, Кыям абзый, китебрәк тор, буталма.

Карт, тезләренә таянып, эскәмиягә утырды, эшләпәле белән Сәетҗан абый сатулаша башладылар. «Ике йөз...» – «Йөз илле... Тояк урынына тояк бирәбез бит...» – «Уен эш түгел, тәвәккәллим инде...» дигән сүзләр колакка чалынып китте. Аларга кызыл чырайлы барып кушылды.

Бикташ күңеленнән генә кәләпүшле бабайга ялварып карады. Ләкин карт дәшми, куллары белән ике яктан эскәмиягә таянып, башын иеп, үзенә генә мәгълүм сагышлы уйларына чумып утыра иде.

Ул арада тегеләр килешеп тә куйдылар. Эшләпәленең куен кесәсеннән яшел кәгазьле шешә белән пластик стаканнар чыкты. Башта Сәетҗан абыйга, аннан кызыл чырайлыга салып бирделәр. Теш араларына кыстырыр нәрсә юк икән, Сәетҗан абый тамагын кырып, юеш иреннәрен пинжәк җиңе белән сөртеп куйды, ә кызыл чырайлы, авызын зур ачып, симез кулы белән һава җилпеде.

– Кыям абзый, кил якынрак, – диде эшләпәле.

Карт кулын гына селтәле.

– Ә син үзең? – дип сорады Сәетҗан абый эшләпәледән.

– Мин эчмим, ярамый.

– Бөтен авырлык безнең өскә төшә шул, Сәетҗан. Ни хәл итәсең, күтәрергә туры килә, – дип, кызыл чырайлы тагын стаканнарны тутырды.

Шуның белән Кашкарыйның язмышы хәл ителде. Аның гына микән? Бу көнне Сәетҗан абый, үзе дә белмәстән, юк кына бәягә улының олы юанычын сатып җибәрде.

– Бикташ! Ишетмисеңме әллә! Кил әле, булыш!

Сәетҗан абый калтыранган куллары белән чөелдерек бавын чишә алмый азаплана иде. Чишелмәсен, мәңге шулай төйнәлгән килеш калсын ул чөелдерек! Ник әтисе көннәр буе иза чикми шунда, Бикташ бу эштә аңа булышчы түгел.

Ләкин язмышны андый төеннәр генә үзгәртә аламы соң? Тәртәләр таралып җиргә төште, камыт, дугалар арбага ятты. Кашкарый, тезгененә тотынган кызыл чырайлыдан йөз чөереп, арт аякларына басты.

– Ни карап утырасың, Кыям абзый! Таптап үтерә бит бу Мәрдәнне!

Сәетҗан абый биянең йөгәнен салдырырга үрелде.

– Калдыр, – диде эшләпәле. – Мәгәрич чутыннан булыр.

Кызыл чырайлы эскәмия астыннан иске, төенле йөгән алып килде:

– Үзең тапкан мал түгел. Кайтканда сак бул, ГАИга юлыга күрмә, правањны алып калмасыннар, хи-хи-хи!

– Дилбегәне малайга тоттырам мин, – дип мактанды Сәетҗан абый. – Малай янда бит, олы таяныч! – Һәм улының аркасыннан кагып куйды.

Арбага арык алмачуарны җиктеләр. Кашкарый, башын болгап, арба артыннан иярде.

– Кыям абзый! Тот инде бияне, тот!

Түзмәде Бикташ, арбадан сикереп төште дә йөгереп барып дустының aклы-кызыллы яңагын кочып алды, сөякчел, әмма бу минутта бик йомшак тоелган маңгаена битен терәде.

– Бик ярата идеңмени соң? – дип, малайның башыннан йомшак итеп сыйпады Кыям бабай. – Рәхмәт яусын, улым. Болай булгач, ахырзаман җитмәгән икән әле. Кеше күңелендә җан иясенә рәхим-шәфкать булганда, дөнья бетми әле, тормыш бара!

* * *

Урамга чыгып бераз баруга, алмачуар алаша тагын да ныграк аксый башлады, Бикташ белән әтисенә арбадан төшәргә туры килде.

– Әти! – диде Бикташ. – Бөтенләй йөри алмый бит бу! Йөк төягәч ничек тартыр?

– Аңа кем йөк ташыта! – диде Сәетҗан абый, кәефле көлеп. – Аны җигүче булмаячак. Безгә кирәкми, ник дисәң, ихата бетте. Яңа квартираның балконында ат асрап булмас!

– Ә балалар бакчасында ни диярләр?

– Хуҗа хатынны әйтәсеңме? Ни дисен! Рәхмәт әйтер! Үзе бер яртыны куярга тиеш әле ул миңа!

Улының берни аңламый, күзләрен зур ачканын күреп, Сәетҗан абый тагын да ныграк кинәнде:

– Шулай, улым, яхшы аттан коткаруым бик әйбәт булачак аның өчен. Премия тиеш әле миңа аннан, медаль тиеш! Ник дисәң, бүген ятып җан тәслим кыла торган хайван гына кирәк аңарга.

«Ә азык-төлекне ни белән ташыр соң алар?» – дип уйлады Бикташ. Әмма соравын кычкырып әйтмәде, чөнки әтисенең сүз тегермәненнән су агызасы килмәде.

– Атлары егылып үлде дисә, алар ике кулсыз калалар, ә бала-чаганы азыксыз тотып булмый, шулай бит? – дип, үз сүзен үзе үрчетергә мәҗбүр булды әтисе.

«Шул да булдымы файда?»

– Шуннан аның юлы бер генә кала: иң олы нәчәлниккә бәреп керә дә ул, шулай-шулай, атыбыз үлде, транспорт бирегез, шунсыз кабинетыгыздан чыкмыйм, ди. Ә нәчәлник нишли? Транспорт тапмый чарасы юк аның да. Ә нәчәлниктә ат юк, бирсә, мотороллер гына бирә ала. Тегеңә шул гына кирәк тә. Әллә кайчаннан мотороллер дип авыз суы корыта инде ул, атыгыз бар, дип, моңарчы бирмәделәр генә. Мотороллерга печән-солы кирәкми, караучы эзләп тә интегәсе юк! Ник дисәң, мотороллерга теләсә нинди малай утыра да чаба аңа. Менә шулай ул, улым, дөньяның җае!

Сәетҗан абый, улына күзен кысып, кашын сикертте.

– Сиңа атны сатарга ул апа үзе куштымыни?

– И сабый-сабый! Нишләп ул кушсын инде! Кешене җинаятькә этәрү була ич ул, казна малын пыран-заран китерү була! Аның өчен судка бирәчәкләр аны, төрмәгә утыртачаклар!

– Ә сине?

– Нәрсә мине?

– Сине судка бирмәсләр микән?

– Кем бирсен? Ул апаң җаваплы кеше бит, аңа таләп зур. Ә мин кем? Гап-гади йөк ташучы. Җаваплы кеше түгел. Мине судка бирсә ул гына бирә алырые да бит, ләкин, әйтеп торам бит, ул минем бу эшемә үзе үк кул куячак! Вакыт уздырып, итеген туздырып, ник йөрсен ул суд юлында? Явыз кеше булса, бер хәлие. Бугазы гына көчле, үте юк, кешенең бәгырен ачыттырырлык эшәкелек эшли белми. Аннары мин кичә, эштән китәм дип, гариза бирдем инде. Бу үләксәнең эченнән җаны чыкканчы абзарга илтеп япсак, шуның белән эш бетә безнең. Алдын-артын уйлап эшли, дөньяның җаен белә синең атаң!

Җил аркан иссә дә, бик озак кайтты алар. Ләкин һәр юлның очы була, ниһаять, үргә менә башладылар. Монда алмачуарның көче генә җитмәде, Бикташ белән Сәетҗан абыйга арбаны этешергә туры килде. Каяндыр Уйнак килеп чыкты, ят атны күргәч, ризасызлыгын белдереп, ярсып-ярсып өрергә кереште. Ләкин алмачуарның маэмайда хәбәре юк, ул атлаган саен, борынын җиргә тигезә язып, сискәндергеч хәрәкәт белән алга иелә, бөтен тәне белән тартышып куя иде. Аның янбашлары май сылагандай булып юешләнгән, авыр, тигезсез сулышы арба артындагы Бикташка бик яхшы ишетелә иде.

Үргә каршы аякларын нык терәп, башын чөеп, ашыгып-ашкынып менәргә яраткан Кашкарый малайның күз алдыннан китмәде.

– Әти! – диде ул. – Тегеләр Кашкарыйны суярлар микәнни?

Сәетҗан абый кызарган битен җиңе белән сөртте дә, мышнап:

– Нишләтсәләр дә үз ирекләре, – дип җавап бирде. – На! Тагын әзрәк тырышсаң, бүтән көчләмәбез. Юл уртасында егылып җан бирмә тагын! Бәладән башаяк!

Бикташ, арба артына ябышып, йөзен ике беләге арасына иде: яшь тулган күзләрен әтисенә күрсәтәсе килми иде аның.

*** * ***

– Этне өйгә кертәсе булмагыз! Иялә шмәсен!

Бу сүзләрне Бәһиҗә түтәй кат-кат тәкрарлады. Димәк, Уйнакка яңа квартирада урын булмаячак, димәк, аның да кирәге бетте дигән сүз иде бу.

Бик иркен иде югыйсә яңа квартира, гаҗәп шәп иде. Беренче тапкыр әтисе белән карап чыгарга дип баргач, Бикташка аның ишекләре хисапсыз, бүлмәләре адашырлык булып күренде. Сәетҗан абый, ботинкаларын салып, кинәтрәк бассаң таеп егылырлык тоелган идәндә сак кына атлап, бүлмәдән бүлмәгә кереп, улы алдында мактанып йөрде:

– Карале кухнясын! Караңгы бүлмәсен кара! Бусы зал дип атала. Ә балконы нинди! Өч бүлмәле бит ул! Өч бүлмәле! Мондый квартираны калада туып картайган кешеләр дә ала алмый. Ә без алдык менә! Ни бирмәскә тырыштылар, ни карышып маташтылар, бугазларыннан каерып алдык! Барыбер үзебезнекен иттек!

Һәммәсенә урын җитәрлек иде монда: Бикташка үги әнисенең очлы күзеннән, энесенең бимазаларыннан котылып торырга да, әйбер-карасын урнаштырырга да, Уйнакка сырма салырга да. Ә ник әле аны монда асрамаска? Ишегалдында әнә кайберәүләр бозау хәтле этләр ияртеп йөриләр, әллә кайда тотмыйлар бит аларны, шушындый ук квартираларда яшәтәләр! Йомгак хәтле Уйнакны асрау нәрсә ул? Ник күпсенәләр аны? Кая куймакчы булалар?

Бикташ бу хакта әтисенең кылын тартып караган иде, Сәетҗан абый сүз күпертеп тормады, чыраен сытып:

– Эт кайгысы юк әле монда, вакыт җиткәч күз күрер, – дип кенә җибәрде.

Чыннан да, эшләренең бик тыгыз чагы иде шул. Бөтен әйбер-караны җыясы, төйнисе, машинага төйисе, яңа йортның дүртенче катына менгерәсе бар.

Бу мәшәкатьләр арасында Сәетҗан абый бер-ике тапкыр Кашкарыйны да исенә төшереп алды.

– Кулда ат бар чакта күченеп калсак, җиңелрәк буласые, – диде. – Җае туры килмәде бит, нишлисең.

Бу сүзләр Бикташның болай да янган йөрәгенә ялкын өстәделәр. Исән идеме икән әле аның ак бәкәлле дускае? Әллә теге кызыл чырайлы адәм җирән төк үскән куллары белән аның муенына пычак салырга өлгерде дә микән инде? Ә Уйнакны нинди язмыш көтә? Бикташ аны коткару чарасын алдан ук күрергә тырышып карады.

– Кил әле, – дип чакырып алды ул энесен, үги әнисе кухняда болганган арада. – Син Уйнакны яратасыңмы, юкмы?

– Яратам.

– Юк, яратмыйсың син аны.

– Юк, яратам мин аны.

– Юк, яратмыйсың!

– Юк, яратам!

– Яраткач, ник соң син аны үзең белән бергә күчермисең?

Илдар, кара төймә төсле күзләрен түгәрәкләндереп, уйга калды. Аның әнисе беркайчан да Уйнакны өйгә кертергә рөхсәт итми иде, шуңа күрә маэмайны үзе белән яңа квартирага күчерү малайның нәни башына кереп тә карамады.

– Ул анда ялгызы кала бит, – дип аңлатты Бикташ энесенә. – Кем карар аны? Кем ашатыр? Син аны ташлап китәргә булдыңмыни?

– Юк, ташламыйм! Яңа өйгә үзем белән алып киләм!

Икенче кичне өйдә олы тавыш купты – Илдар Уйнактан башка өйгә керергә теләмәде, елады, сугышты, ярсып бетте. Аның эт муенчагына чатнап ябышкан бармакларын әнисенә берәм-берәм каерырга туры килде. Ләкин барыбер Бәһиҗә түтәй хәтта «бәбие», «бәгырь парәсе» хакына да Уйнакны өйгә кертергә ризалык бирмәде.

– Абзар түгел бу сиңа! Аннан башка да мәшәкать муеннан! Бәби дә кайтасы бар, өйне сасытып ятар хәлем юк! – диде.

Сәетҗан абый, кече улын кочагына алып:

– Аның үз өе бар бит, шунда йоклый ул, иртәгә күрешерсез, – дип, конфет-җимешләр белән сыйлап, көчкә юатты.

Уйнак буш ихатада ялгызы калды. Хәер, буш идемени ул ихата? Анда Бикташның бар булган байлыгы – сеңлесенә дип ясаган, җан кебек күргән уенчыгы белән уналты сум да утыз җиде тиен акчасы саклана иде әле. Ул гына да түгел, Бикташның күңеле шунда иде, тәне яңа квартирага күчкән булса да, җаны шул Уйнак белән калды. Ул яңа өйгә ашарга, йокларга гына кайта, калган вакытын чокыр буенда үткәрергә тырыша иде.

Ләкин бу хәл дә озак дәвам итмәде. Беркөнне мәктәптән кайткан уңайда, сугылып чыгыйм әле дип, урам очыннан керүгә, ул үз йортлары тарафыннан шакылдаган тавышлар ишетте. Малайның күңеленә шом тулды – үзенең соңарганын аңлады ул.

Капка күгәннәреннән каерып ташланган, ике ир кеше тузан болыты эчендә йортның түбәсен сүтеп азапланалар иде. Бите-муены тимгелләнеп кызарган Сәетҗан абый: «Әрәм булып калмасын, утынга ярый ул», – дип сөйләнә-сөйләнә, кадак суыргыч белән эт оясының такталарын кубарып маташа.

Ишегалдында аны-моны каранып йөргән Бәһиҗә түтәй, Бикташның күз алдында, уңайсыз итеп янтаеп иелде дә шакмаклы дәфтәр битенә төрелгән төргәкне табып алды. Көмеш һәм бакыр тиеннәрне, таушалган берлекләрне җентекләп санады да, астыртын елмаеп:

– Карале, Сәетҗан, табышлы булдык бит! – диде. – Әйтәм аны, кесәдән һаман вак акча югалып тора, Уйнак урлап җыя икән!

Ә үзе сызылып киткән кашлары астыннан Бикташка кистереп карап алды.

– Бик шәп, хатын, бик хуп, – диде Сәетҗан абый көр тавыш белән. – Менә өй нигезеннән дә бер-бер хәзинә килеп чыкмасмы! Баербыз, Алла боерса.

Бикташ бер сүз әйтә алмады. Бәһиҗә түтәй акчаны койма аратасында эленеп торган ак сумкасына салып куйды. Аннары янтаеп, янында сикергәләп йөргән Уйнакның муен каешын салдырып алды. Маэмайның ак муенында күксел эз калды. Тутасы, бер кулында сумкасын, икенче кулында муенчакны болгап:

– Мин ашарга әзерли торам, – дип, таралып яткан койма такталары өстеннән бик сакланып кына атлап үтте. Ул инде эшкә дә йөрми, бәби туганны көтеп, өйдә генә утыра иде.

Ул бераз ераклашкач, әтисе Бикташтан шыпырт кына:

– Синең байлык булдымы инде ул? – дип сорады. – Эх, син! Тапкансың яшерер урын! Ал инде хәзер эт авызыннан сөякне!

Бикташ такталар арасыннан уенчыкны табып алды. Ул пычранган, бер аратасы сынган иде. Бикташ өйгә кайткач, аны ваннага алып кереп юды. Энесе бакчадан кайтып кергәнче, уенчыкны кая да булса яшерергә кирәк иде. Кая? Дала хәтле квартирада энә яшерерлек урын да юк иде.

Ахырда ул аны зал почмагында яткан юрганы арасына тыгып куйды.

Кич караңгы төшкәч, көндезге ыгы-зыгылар иртәнгәчә тынып калгач, ишек ягыннан нindидер сәер авазлар ишетелде. Кемдер тырмана, шакыгандай итә, нечкә тавыш белән сыкрана иде анда. Кухняда шалтыр-шолтыр савыт-саба юган Бәһиҗә түтәй, зал ишегеннән башын тыгып:

– Сәетҗан, ишетәсеңме, теге нәрсә тагын килгән бит! – диде.

Өстенә зәңгәр трико кигән Сәетҗан абый диванда телевизор карап утыра иде. Футбол уенының иң кызган чагы, урыныннан кузгаласы килми иде аның. Авырлык белән торып басты, экраннан күзен алмый гына капшанып, урындык аркасына элеп куелган чалбарыннан бил каешын суырып алды. Аннары, артсыз башмакларын чаштыр-чоштыр сөйрәп, ишеккә юнәлде.

Аңарчы аны-моны абайламыйча, футбол белән мавыгып утырган малайлар, ишек яныннан карганган, ачыргаланып чинаган тавышлар ишетеп, икесе дә дәррәү сикереп тордылар. Сәетҗан абый, бөтен көченә селтәнеп, Уйнакны кыйный иде:

– Килмә бүтән! Килмә! Эзеңне суыт моннан!

Уйнак борыны белән лифт читлегенә терәлгән, үзәкне өзеп чиный, елый, каеш төшкән саен, бөтен тәне белән куырылып килә, ләкин никтер ычкынырга җай эзләми, китми, качмый иде.

Илдар, йөгереп барып, әтисенең кулына ябышты:

– Тимә! Кыйнама!

– Җибәр, әти, җибәр! – диде Бикташ та.

Сәетҗан абый этне аяк очы белән элеп, баскычтан түбән ыргытты, аның артыннан артсыз башмагы да очып, тәрәзәгә барып бәрелде.

– Китегез, аяк астында буталмагыз! – дип җикерде ул улларына.

Ачык ишектә Бәһиҗә түтәй ирен тиргәп тора иде:

– Ничә әйттем мин сиңа, шуны берәр кая олактыр, дип! Бозау!

– Кит әле, син дә эчне пошырып торма, ичмасам!

Сәетҗан абый, гомер булмаганча, хатынын этеп, кире залга узды.

Эт хәсрәте Бикташка төн буе йокы бирмәде. Нишли микән инде ул бичара? Берәр җире имгәнмәде микән, аяклары сынмады микән? Ә бәлки, ул шушы минутларда баскыч төбендә яраларын ялап ятадыр? Эх, әгәр Бикташ иркендә булса, каршысында тезләнеп ялынсалар да, беркемгә бирмәс иде ул аны! Шушы квартирада кадерләп кенә асрар иде. Якты Тәрәзәдә булса... Бикташ аны үзеннән бер адым да калдырмас иде. Ну малайлар кызыгыр иде соң үзенә. Андый эт велосипед түгел ул сиңа! Велосипед хәзер адым саен, ә Уйнак кебек матур эт поселокта юк.

Чыннан да, Якты Тәрәзәгә генә алып китәргә кирәк аны. Әни, мөгаен, ник алып кайттың аны димәс, кирәкми димәс, сөенер генә. Ә Фәния! Кулына бүләк уенчыкны алгач, Уйнакны күргәч, сөенеченнән үрле-кырлы сикерәчәк, билгеле!

Кайтып китәргә кирәк дигән уй Бикташка юаныч бирде, кыйналган күңелен тынычландырып җибәрде.

* * *

Иртән кухняда ашап утырганда, Бикташның бер телем колбасаны җиң эченә шудырганын күреп, Бәһиҗә түтәй:

– Нәрсә, җитмәдемени? – дип сорады. – Каракның урлап ашамаса тамагы туймый диләрие, хак икән.

Аннары йокылы-уяулы көйсезләнеп утырган Илдарга борылды:

– Әнә күрдеңме абыеңны? Кап-кап итте – ярты булканы капты-йотты. Әле тагын йөз грамм колбасаны үзе белән алмакчы. Менә шулай ашарга кирәк сиңа да. Болай мешмелдәп утырсаң, үсми калырсың әле!

Бикташ колбасаны кире тәлинкәгә салды да тизрәк чыгып китү ягын карады. Мәктәпкә барганда, элекке ихаталарыннан әйләнде. «Уйнак! Уйнак!» – дип кычкырып та, сызгырып та карады, әмма маэмай күренмәде.

Малай дәресенә соңга калды, шуның өчен класс җитәкчесе, беренче елын гына укытучы апа, өч өндәү билгесе куеп, аның көндәлегенә кисәтү язды. Бикташның моңа тамчы да исе китмәде – өйдә

аның көндәлеген ачып караган кеше юк иде. Аның уенда гел Уйнак кына булды, эченнән генә звонокка кадәр калган секундларны санап утырды, игътибарсызлыгы аркасында алгебрадан икеле эләктерде.

Дәресләр бетүгә, беренче каттагы элгечкә иң алдан төшеп җитте, бер кулына курткасын, икенче кулына сандали салган кара сатин букча белән портфелен тотып, чокыр буена чапты.

Ул Уйнакны ерактан ук күреп алды: эт күн түбәле кепка кигән бер малай тирәсендә сикергәли иде. Исән! Имгәнмәгән!

Ә янындагы малай Юныс икән.

– Исәнме! – диде Бикташ аңа.

Теге чакта түтәлләргә су сибеп йөргәннән бирле аларның юньләп сөйләшкәне юк иде. Алай да бу юлы Юныс караңгы чырай күрсәтмәде.

– Уйнакны асрамаска булдыгызмы әллә? – дип сорады, исәнләшкәч. – Берүзе йөри, муенчагын да салдыргансыз.

– Юк, мин асрыйм аны, – диде Бикташ.

– Алайса, ник караусыз калдырдыгыз? Монда иясез этләрне тотып алып та китәләр, һичьюгы, муенчак кигезергә иде.

– Кигезәм мин аңа муенчак, – диде Бикташ.

Ул Уйнакның башыннан сыйпады. Маэмай, аның тезләренә ал тәпиләрен куеп, соры күзләрен мөлдерәтеп, койрыгын болгады.

Алар өчәүләп – ике малай һәм бер эт – яңа йортка таба киттеләр.

– Сезгә дә квартираны безнең белән бер мәйданчыктан бирмәкчеләр иде башта, – дип сөйләп барды Юныс. – Нәкъ безнеке кебекне, ике бүлмәлене. Син килгәч, бүтән мәйданчыктан бирергә карар чыгардылар, өч бүлмәлене.

– Нишләп алай?

Бикташ Юнысның болай якын итеп сөйләшүенә бик шат иде. Яңа мәктәптә ул беркем белән дә якынаеп, дуслашып китә алмаган иде әле. Андагы малайлар берничә ел буе бергә укыганнар, каникулдан соң бер-берсен сагынышып күрештеләр, яңа килгән малай белән сөйләшергә, аралашырга теләкләре дә, вакытлары да юк иде шикелле. Ә Бикташ мәктәптә берәр дусты булуны бик тели иде. «Юныс белән күрше квартирага эләксәк ярыйсы буласы икән», – дип уйлады ул.

– Әтиеңнәр өч бүлмәлене алырга җан тырыштылар, – дип аңлатты Юныс теләр-теләмәс кенә. – Үзең беләсең. Шуның өчен сине җәй башыннан ашык-пошык алып килделәр, ди минем әни.

– Ни өчен? – Бикташ юлдашына чиксез гаҗәпләнеп текәлде.

Уйнак, ни булды дигәндәй, тәпиләрен аның тезләренә куйды.

– Синең монда ник килгәнеңне бөтен кеше белә! – Юнысның калын иреннәре мыскыллы кыйшайды. – Өч бүлмәле квартира эләктерү өчен алып килделәр сине! Шуңа күрә, син килгәч, аларны башка квартирага күчереп яздылар. Белмәгән булып кылана тагын! Алдашып маташа!

Шулай диде дә китеп барды. Бикташ, аның әйткәннәрен башына сыйдыра алмыйча, баскан урынында калды.

Менә ничек икән! Шәһәрдә квартираларны кеше санына карап бирәләр икән, димәк. Әтисе белән үги әнисенең ул турыдагы сүзләре колакка чалынганы бар иде барын, тик Бикташ аларга дикъкать итмәде. Андый уй килеп карадымыни соң аның башына? Әгәр белгән булса, килер идемени? Әнисе җибәрер идемени аны? Ике аягының берсен дә атламаган булыр иде. Шуны белеп, әтисе аңа дөресен әйтмәгән дә инде... Әтисе аны алдаган!

Бикташның күз алдында яшен яшьнәп, кинәт бөтен нәрсәне яктыртып үткәндәй булды. Димәк, әтисе аны теге вакытта сагынып кайтмаган, училищега урнаштырырга да уйламаган. Ул зуррак квартира аласы килгәнгә генә исенә төшергән Бикташны. Бары шуның өчен генә ияртеп алып килгән. Бикташ үзе аңа бөтенләй кирәк түгел, аңа тагын бер бүлмә генә кирәк икән. Хәзер аларга Бикташның бөтенләй кирәге бетте. Кашкарый шикелле, Уйнак шикелле.

Ләкин бу хакыйкать артык ачы, аяусыз иде. Ул Бикташның миен уттай көйдерде. Малайның бөтен күңеле, алай гына да түгел, тәненең һәр күзәнәге аларга каршы чыкты. Булмас! Алай түгел! Әтисе Бикташны ярата. Ул аны сагынган иде, шуңа алып килде. Бикташның үз әтисе бит ул. Ялганлый Юныс, күрәләтә кара яла яга.

Әмма шик корты башка кереп оялаган, мине туктаусыз кимерә иде инде. Ә нишләп соң әтисе соңгы вакытта аның белән бер генә дә ачылып сөйләшми? Үги әнисе дә тырт та пырт кына йөри, «наныем» дигән сүзне ялгыш та ычкындырмый? Ни өчен яңа квартирада Илдарга атап аерым бүлмәне билгеләп куйдылар, ә Бикташка бер почмак та юк? Кирәгең бетте, диюләре микәнни?

Булмас, булмас, әтисе ярата аны. Бикташ хәтер сандыгыннан әтисенең үзенә мәхәббәтен расларлык дәлилләр эзләде. Урманда бергә йөргәннәрен, Алантау Сабан туенда бергә күңел ачканнарын, балалар бакчасында кич утырганнарын, чумара акчасын бүлешкәннәрен исенә төшерде. Күп түгел икән һәм шактый күптәнге булып чыкты ул дәлилләр...

Аның шул минутта ук әтисен күрәсе, нәкъ үзенеке төсле аксыл керфекләр белән уратылган күк күзләренә карап, чын дөресен сорыйсы килде.

Ишекне Бәһиҗә түтәй ачты:

– Ник ияртеп кайттың бу җәфаны? Без ничек котылырга белмибез, ә син, үч иткәндәй, үзең алып кайтасың!

Бикташ, Уйнакка игътибар бирмичә һәм үги әнисенә карамыйча, ашыгып эчкә үтте.

– Аягыңны сал! – дип кычкырып калды Бәһиҗә түтәй. – Пшал! Пшал!

Аның соңгы сүзләре дә Бикташка юнәлтелгән сыман яңгырады.

– Әти кая?

– Кайтмады әле. Эш эзләп йөри. Син өйдә буласыңмы соң? Мин ипигә бармакчыем.

Илдар тамагы авыртып бакчага бармаган иде. Зал уртасында бер кибет киштәсен шыплап тутырырлык уенчык машиналарын пыран-заран китереп утыра. Бикташ аның уенчыкларын атлап үтте дә балкон тәрәзәсе янына барып басты.

Аның күз алдында дистәләрчә торбаларын тынгысыз күккә сузган заводлары, эреле-ваклы йортлары, бакчалары, урамнары белән зур шәһәр җәйрәп ята, аяк астыннан диярлек олы юл уза. Ләкин бу күренеш теге чакта, Кашкарыйга атланып тау башыннан күзәткәндәге кебек, малайның күңелен җилкендермәде, киресенчә, аның сагышын көчәйтте генә. Ертык-тишек күгелҗем болытлар арасына кереп адашкан, инде берсеннән котылдым дигәндә генә, икенчесенең тозагына эләгеп торган кызгылт кояш та бу авыр хисне тагын да авырайта иде шикелле. Бикташ аста, тузан өермәсе эчендә кечкенә булып тоелган, әкрен хәрәкәтләнгәндәй күренгән машиналарга йотылып карады. Кайсысыннан төшәр аның әтисе? Кайчан? Әгәр кодрәтеннән килә торган булса, малай аны күз карашы белән суырып кайтарыр иде дә, каршысына басып, йөзенә текәлеп карар иде.

Ул, троллейбус тукталышын яхшырак күрәсе килеп, балкон ишеген ачты. Җил бәрде, челтәр пәрдә суырылып тышка талпынды, балконда җилфердәде.

Бикташ чыгып баскан гына иде, чылтыраган тавыш ишетеп, артына борылды. Илдар савыт-саба шкафы янына урындык куеп баскан да өске киштәдә актарынып маташа икән. Хәзер инде сыйларга Кашкарый да, Уйнак та юк, ләкин малайның, әнисе чыгып китте исә, актарына торган яман гадәте һаман калган иде.

Бикташ энесен күтәреп төшермәкче булды. Ләкин малай шкафка ике куллап чытырдап ябышкан, куптарып алу эт колагыннан талпан суыру белән бер иде. Савыт-саба тулы шкаф чак аумый калды.

Идәнгә бастыргач, Бикташ энесенең артына берне кундырып та алды:

– Әйткәнне тыңлый белмәсәң, мин сине!..

Малай, акырып, чапаланып, идәнгә тәгәрәп китте, Бикташ, кулын селтәп, кире балконга юнәлде. Кинәт каты шартлаган тавыш яңгырады, чылтырап пыяла коелды. Бикташ ирексездән муенын җыерды. Ни булды? Нәрсә ватылды?

Ул, башын сузып, бүлмәгә карады. Илдар, коты очып, абыйсына түгел, почмакка карап тора. Ә анда, кара тоткычлы тумбочка өстендә, телевизор урынында тартма тора, аның эченнән ватык пыяла кырыйлары тырпайган. Идәндә пыяла ватыклары, алар арасында Илдарның уенчык паровозы.

Телевизор ватылган... Аңа уенчык паровоз тигән... Илдар абыйсына ыргытмакчы булып, ялгыш кулыннан ычкынганмы әллә?

Әйе, шулайдыр. Ләкин Бәһиҗә түтәй моны Бикташка сылтаячак! Әтисе да якламас! Ул карамаган, ул сакламаган, ул ваттырган, ә бәлки... үзе ваткан диярләр әле!

Бикташ, ашыгып, чөйдән курткасын алды, аягына ботинкаларын элде. «Абый! Абый!» – дип итәгенә ябышкан Илдарны көч белән этеп җибәрде дә ишекне каты ябып чыгып китте. Эчтән үрсәләнеп елаган тавыш ишетелеп калды.

* * *

Пыяла ватыклары арасында елап утырган улын күргәч, Бәһиҗә түти телсез, өнсез калды. Әкренләп аның чыраендагы гаҗәпләнү, аптырау галәмәтләре зәһәрлек, ярсу белән алышындылар. Ул ипи салган сумкасын кухняга ыргытты да, өермәдәй бөтерелеп, эчке бүлмәгә кереп китте, аннары кире чыгып, ванна, караңгы бүлмә ишекләрен шалт та шолт ачып япты.

– Кая ул? Кая теге мөртәт? – диде, улы өстенә килеп.

– Чыгып китте...

– Ах, иблис токымы! Юри ваткан инде алайса! Юри каза ясап киткән! Әйтәм аны, күз карашларында бер генә дә иман заты юк иде! Бер-бер әшәкелек уйлап йөри торгандыр дигәнием аны! Атасыз үскән балада өмет буламы соң! Ничек әле өйгә ут төртмәгән!

Бәһиҗә түтәйнең бөтен ачуы, бозлы су булып, шактый кәефләнеп кайтып кергән Сәетҗан абыйның баш түбәсенә коелды.

– Кара, күр! Әнә ни кылып киткән теге бандитың!

Сәетҗан абый җимерек телевизорга, идәндә чәчелеп яткан пыяла ватыкларына карап, бераз тын торды.

Ниһаять, колак төбендә чәр-чәр килгән хатынына борылды да:

– Акырма, – диде. – Алып кил дә алып кил дип, син колак итемне ашадың бит! Алып килдем. Рәхәтен күр менә!

– Син аздырдың аны! Ата була белмәдең, муеныңа атландырдың!

Хатыны тиргәгән саен, Сәетҗан абыйның улына ачуы кабара барды. Бикташны, шиксез, кайтып керүенә этисенең каешы көтә иде.

Ләкин кич җитте, караңгы төште, ә ул кайтмады. Сәетҗан абыйның ачуы басылды, Илдар ишеккә караштырып көйсезләнде – икесе тиң аны көттеләр, баскыч ягыннан лифт тавышы ишетелгән саен, сагаеп тыңландылар.

– Көтеп утырасыңмы? – диде Бәһиҗә түтәй, ирен мыскыллап. – Кайтыр дисеңме! Кайтыр сиңа, көт! Әллә кайчан поездда инде ул! Мин аларны менә шулай-шулай мыскыл иттем, дип, әнкәсенә сөйләр әле кайткач. Безнең кесәдән акчаны әз урлаган дисеңме әллә! Бер-бер каза ясап таярга җай гына эзләп йөргән, мөгаен!

Сәетҗан абый дәшмәде. Хатынының сүзләре аңа һәрвакыттагыча төпле, ышандырырлык булып тоелды. Шулай да борчылуы бөтенләй үк бетмәде: әгәр дә Бикташ кайтып китмәгән булса?

* * *

Ә Бикташ алардан ерак та түгел, иске ихаталарында, чокыр ярындагы кәкре өрәңге төбендә ята иде. Караңгы төшә башлагач, ул калдык-постык такталарны җыйгалап, дымлы җиргә түшәде, аннары, өрәңге кәүсәсенә терәп, куыш сыманрак нәрсә әмәлләп куйды. Урман янында үскән малай андый эшләрнең җаен белә иде. Дүрт аяклап куыш эченә кереде, Уйнакны үз янына чакырды, иркәләп, җайлап яткырды. Этнең кайнар сизгер тәне аны җылытып җибәрде. Бикташ Уйнакны борчымаска, әйләнмәскә тырышты, ләкин астан такта кыры янбашны кисеп керә, муенны өрәңгенең кытыршы кәүсәсе тырный иде.

Кинәт Уйнак нәрсәдәндер сискәнеп сикереп торды, нечкә генә итеп чинап куйды. Бикташ та башын калкытты. Ихата ягыннан аяк тавышлары ишетелде. Аннары тынлык урнашты. Бераздан Сәетҗан абыйның: «Улым!.. Бикташ!..» – дигәне ишетелде. Бикташ атылып чыгарга омтылган Уйнакны тотып, учы белән аның авызын томалады, колагына «Ят!» дип пышылдады. «Ят, Уйнак!» Эт, ризасызлыгын белдереп, башын болгады, ләкин буйсынды, калтыранган тәне белән малайга сыенды. Сәетҗан абый тагын берничә тапкыр әкрен генә: «Улым! Улым...» – дип кабатлады да: «Китүе хактыр, ахры...» – дип сөйләнә-сөйләнә китеп барды.

Малайның йөрәге дөп-дөп тибә иде. Әтисенең аяк тавышлары тынган мәлдә аның йөгереп чыгып: «Әти!» – дип кычкырасы килде. Әмма ул үзен тыеп калды. Ни дисен ул аңа? Мин гаепсез, телевизорны Илдар ватты, дисенме? Ышанмаячаклар! Ни генә дисә дә, бу каза аңа сыланып калачак. Их, бер телевизор алып бирсәң иде шуларга! «Ватучысы мин түгел, энем өчен түлим!» – дияр иде. Чырайларына бал сылагандай булыр иде үзләренең дә...

Тик моны ничек эшләргә? Җыйган акчаны да саклап булмады, анысы да үги ана кулына керде шул... Хәзер ул кесәдә булса, аңа күпмедер өстәсәң... Ә ничек өстисең ди аны?

Шунда үги әнисенең җәй көне әйткән сүзләре исенә төште малайның. Ике игезәк заводка эшкә кергәннәр, бер ай эчендә уч тутырып акча алганнар, дигән иде бит ул. Кайда икән ул завод? Эзләгән таба, эзләргә кирәк. Әйе, иртән үк эш эзли башларга...

Әгәр таба алмасаң нишләргә? Кая барырга, кайда кунарга?

Бер мизгелгә аның күз алдына әнисе килеп басты. Күзләре яшьләнгән, рәнҗүле. Җибәрәсе килмәгән иде, үпкәләп калды. Бикташ аның сүзен тыңламады, кызганмады. Хәзер инде, кыйналган көчек кебек, маңкасын агызып кайтып керсенме? Телевизор хакын аннан түләтсенме? Ни йөзең белән кайтып аның каршына басарсың? Аннары кайтып җитәр өчен дә акча кирәк бит әле! Трамваенда ничек тә барырсың, ә поездга утыртмаячаклар...

Башта ничек тә акча эшләргә кирәк. Ансыз бернишли алмыйсың.

Малай киләчәген шулай хәл итеп куйды да тынычланып киткәндәй булды. Такта ярыгыннан аңа күк йөзеннән бер йолдыз чекерәеп карап тора иде. Зәңгәрсу йолдыз, якты йолдыз. Менә аның янында тагын берәү пәйда булды, анысының төсе кызгылтрак. Менә ул, әкрен генә шуышып, зәңгәрсу йолдызга якынлашты, аны узып китте һәм ераклаша башлады. Бәй, бу йолдыз түгел, җир иярчене ләбаса! Ә бәлки, космик корабльдер әле. Нindидер бәхетле кешеләр шул йолдызлар арасындагы корабльдә галәм гизәләр. Бәлки әле, шушы минутларда аларны телевизордан күрсәтәләрдер. Менә шундый корабльгә утырып очасы иде дә телевизордан күренәсе иде. Әйе, тегеләргә Бикташ үзе алып биргән телевизордан күренсәң иде. Ну үкенер иде дә соң аның әтисе!

Мин синең кадереңне белмәгәнмен, дип, җиргә төшүенә янына йөгереп килер иде! Үзе әле, очраган бер кешегә, минем улым бу, дип мактанып йөрер иде.

Бикташ үз уйларына елмаеп, йоклап киткәнен сизми дә калды.

**Икенче бүлек**

Әле генә яңгыр явып үткән иде. Салкынча җил салынкы болытларны көнчыгышка таба куып, завод торбалары артына авышып барган кояшны алар тозагыннан коткарды. Җиргә моңсу нур сибелде, тау өстендәге биек йортларның тәрәзәләрендә меңләгән учак кабынгандай булды.

Юеш асфальт юлдан үргә таба сул кулына авыр сумка күтәргән, уң кулына кәгазь кисәге тоткан бер хатын менеп килә. Җил, аның кара пальто итәкләрен резин итек кунычларына бәреп, каршы исә, ләкин хатын үргә менгән саен адымнарын кызулата. Аның түгәрәк бит алмалары алланып чыккан, ал чәчәкле шәле астыннан бүселеп төшкән кара чәч бөтеркәләре дымлы маңгаена ябышкан.

Менә ул тау өстенә менеп җитте дә уңга, чокырга таба борылды. Шәрәләнгән агач ябалдашлары арасыннан ташландык урам яхшы ук шәйләнә иде инде. Хатын сулышына кабып йөгерә үк башлады. Кайчандыр җыйнак өйләр тезелгән ямьле урамга илткән юл аны ватык кирпеч белән такта катыш кызыл балчык өемнәре, чокыр-чакыр, җимерек койма калдыклары һәм корыган үлән сабаклары арасына китереп кертте.

Хатын барган көйгә туктый алмыйча, шушы хәрабәләр арасыннан атлавында булды. Ниһаять, чокырларның, балчык өемнәренең дә чиге күренгәч, тез буыннарының җегәре беткәнен тоеп, корыган яфракларын кыштырдатып торган юеш тупыл кәүсәсенә аркасы белән сөялде, сумкасын җиргә куйды да, аптырап, бер кулындагы кәгазьгә, бер тирә-юненә карады.

Ташландык нигездән дә шыксыз, котсыз күренеш бар микән бу дөньяда? Әйтерсең лә кешеләр бөтен ямьне, бар матурлыкны үзләре белән алып китәләр, кайчандыр көн иткән төшләрендә күңел керләрен генә калдыралар.

Кем күңеленә дә авыр тәэсир итә бу күренеш. Ә бу хатынга аны күрү бигрәк тә үзәк өзгеч иде. Чөнки улының хәлен белергә дип килгән Салиха апа иде ул, ә аның кулындагы кәгазь кисәге – Сәетҗан абыйның адресы язылган дәфтәр бите иде.

Бу җимерек урамга, бу тупыл астына килеп басканчы да бик күп уйлар уйлаган иде инде Салиха апа. Җәйдән бирле Бикташтан хат килмәде, аңа атап язылган хатларның да соңгылары конвертларына аркылы-торкылы сызыклар сызылып һәм «Андый урам юк» дигән язу язылып, Салиха апаның үзенә кире кайттылар.

Ул барысын да уйлады: көндәше каршына ничек-ничек барып керәсен, нәрсә дип әйтәсен мең тапкыр күз алдына китереп, алдан ук кимсенде, Сәетҗаны белән күзгә-күз килүнең авыр буласын да белде. Ләкин бала борчуы аның үз горурлыгын, кимсенүләрен оныттырды, бөтен көйсезлекләргә алдан ук риза булып, юлга чыгарга мәҗбүр итте. Улыннан хат көткән көннәрдә дә, үзенең хатлары кире кайткач та, ул төрлесен уйлаган иде. «Бала күңеле далада, рәхәт яшидер, шуңа безне оныткандыр», – дип, үзен юатырга тырышты ул. «Атасы миңа хат язарга кушмыйдыр», – дип, гаепне Сәетҗан абыйга ягып та куйгалады. Кире кайткан хатларының адресын кат-кат тикшереп, дөрес язылганына ышангач: «Әллә соң араларны ерагайтыр өчен үги ана юри шулай кайтарганмы боларны», – дип тә шикләнде.

Төрлесен уйлады Салиха апа, тик улының чыннан да юкка чыгуы, үзенең наз, сагыш, сагыну һәм ялвару тулы хатларны шушы бушлыкка, шушы хәрабәләргә юллавы башына килмәгән иде.

Инде кая барырга, баланы кемнән сорарга?

Салиха апа, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды. Урамда кеше заты күренми иде. Чокыр төбеннән җирән сыртлы, ак муенлы эт менеп, ниндирәк кеше син дигәндәй, читтәнрәк карап торды да, андый-мондый начарлык сизмәгәч, төлкенеке төсле йөнтәс койрыгын болгап, якынрак килде, сәлам биргәндәй, ә бәлки, ашарына сораптыр, алгы тәпиләренә чүкте.

Салиха апаның эттә хәбәре юк иде. Ул сумкасын җирдән алды да, авыр атлап, тугыз катлы йортларга таба китеп барды. «Андагы халык бу урамдагы кешеләрнең кая күчкәнен беләдер, белми булмас, – дип уйлады ул. – Күрше генә ләбаса! Без менә поселокның аргы урамында ни булганын белеп торабыз».

Зур йортның эреле-ваклы язулы кәгазьләр белән чуарланган ишекләреннән кереп-чыгып йөргән кешеләр бик җитди күренәләр, ашыгалар шикелле, аларны юлыннан туктату килешмәс кебек иде. Алай да Салиха апа, берничәсен туктатып, русчасы начарлыктан һәм каушавыннан тотлыга-тотлыга, кулындагы кәгазен күрсәтеп һәм чокыр тарафына кулы белән изәп, сорашып карады. Бер кулына бала җитәкләгән, икенче кулындагы сеткасына ипи, сөт һәм кәгазь төргәкләр салган яшь хатын, битараф тавыш белән: «Белмим, без бирегә әле генә күчтек», – дип узып китте. Сумка болгап килгән яшь кыз да аның сүзен кабатлады: «Белмим. Анда да урам бар идемени?» – «Күчерделәр аларны», – диде ир уртасы берәү. «Кая?» – «Кая ордер биргәннәрдер бит. Бәхетләре булса, бәлки,

үзәктән дә эләккәндер». Ир кеше, бәхетлеләр өлешенә кызыккандай, каядыр читкә, еракка карап алды. Салиха апа ул караган тарафта рәт-рәт зур йортлар күреп, тәмам гаҗизлеккә төште: бу йортларның кайсында икән аның улы? Монда аны ничек тапмак кирәк?..

Ишегалды уртасындагы агач эскәмиягә утырып бераз хәл җыйгач, Салиха апа чарасызлыгын тәмам аңлады. Зур калада бу рәвешле урамда болганып, кирәк кешеңне табу мөмкин эш түгел. Кайтырга кирәк... Һәм ул авыр адымнар белән үрдән түбәнгә – троллейбус тукталышына таба юнәлде.

Тукталышта берничә кеше тора, алар тирәсендә, кемнедер түземсезләнеп көткәндәй, теге җирән сыртлы эт тә әйләнгәләп йөри иде. Салиха апаның яшь сарган күзләре аны күрмәде.

Троллейбус аның турына алгы ишеге белән килеп туктады. Салиха апа баскычка атлауга, арткы ишектән Сәетҗан абый сикереп төште. Җирән сыртлы эт, койрыгын кысып, читкә тайпылды, ә Сәетҗан абый, уңга-сулга карамый, үргә таба менеп китте. Салиха апа тәрәзәгә күз салмады, аны күрмәде. Троллейбус төеп тутыргандай тыгыз иде, кергән кешеләрне төрле яктан китереп кыстылар.

– Карале, берәр җирең авыртамы әллә? Бальной штоли?

Башына челтәрле ак шәл бәйләгән бер карчык, Салиха апага урын бирмәкче булып, кузгала башлады.

– Кил монда, утыр.

– Юк, апа, рәхмәт. Басып торсам да ярый... Үзең олы кеше...

Салиха апа, мөлдерәгән күзләрен яшереп, башын читкә борды.

– Берәр хәсрәтең бармы әллә? Йөзеңә чыккан.

Әбинең ак шәленнән, пөхтә габардин пальтосыннан, юка тиреле ябык йөзеннән татар карчыкларына хас пакьлек, сизгерлек бөркелеп тора иде. Бераздан Салиха апа аның янында утыра, иңе белән карчыкның тән эссесен, тавышыннан күңел җылысын тоеп, иркенләп сөйләшеп бара иде инде.

Авылда гомер кичереп тә, картаеп көчләре кими башлагач, шәһәргә балалары янына килеп урнашкан татар карчыкларының гаҗәп бер гадәте бар. Алар кайнап торган шәһәр урамнарының, трамвай-троллейбус тукталышының кайсында гына очрашмасыннар, шундук бер-берсен әллә каян күреп алалар, гомерләрендә беренче күрешүләренә карамастан, сагынышып кавышкан ахирәтләр сыман, хәл-әхвәлләрен, бала-чагаларын сорашырга тотыналар. Ул арада светофорда яшел ут кабына, оныклары, балалары аларның икесен ике якка таба тарта яисә троллейбустан төшәр чак җитә, карчыклар бүтән мәңге очрашмаска аерылышалар, ләкин бу сөйләшүнең җылылыгы, яктылыгы аларның күңелендә дә, йөзендә дә шактый вакыт балкып торачак әле.

Салиха апа белән ак шәлле әби дә тирә-юньдәге битарафлыкны оныттылар, үз дөньяларына чумдылар.

– И-и, монда андый урамнарны атна саен сүтеп торалар, – диде әбекәй, Салиха апаның зарын тыңлагач. – Авылдагы шикелле җиде буын бер нигездә гомер кичерми, кеше бер гомерендә җиде нигез алмаштыра монда. Күченгәндә мәшәкать, ыгы-зыгы күп була, шуңа хат язмавыдыр. Ул-бу булса, шундук хәбәр бирерләр иде. Шулай бит?

Чыннан да, Бикташ бер-бер бәхетсезлеккә тарыса, Алла сакласын, тфү-тфү анысы... андый-мондый хәл булса, анасына әйтми ятмаслар иде бит инде! Ничек бу уй Салиха апаның үз башына килмәгән соң әле?

Әби аналарның тынгысызлыгы, балаларның гамьсезлеге турында кыйссалар сөйләп китте. Берәүнең малае әллә кая Боз диңгезенә балык тотарга ялланып киткән дә өч ел буе өенә бер хат та язмаган, ди. Ата-анасының кайгыдан йөзләре саргайган, диңгезгә батып үлгәндер инде бу дип уйлаганнар, ди. Өч елдан кайтып төшкән, ди, теге. Авызы тулы алтын теш, ди, куены тулы яшел иллелекләр, ди. Кайткан да атасына шыңгырдатып гүрничәдәй йорт салып биргән, ди.

– Һай, бала-бала, ата-анасының бәгырен чага, чакканын үзе дә сизми кала! Син болай ит, – диде әби, ниһаять, Салиха апаның хәленә кире кайтып. – Кунар җирең булмаса, Дом крәстиянгә кереп урнаш. Иртә белән берәр җае табылыр, табылмый калмас. Мин сиңа күрсәтермен Дом крәстияннең кайда икәнен. Үзем дә шул якка барам.

Әллә ни юатырлык сүз дә әйтмәде шикелле әби, әмма Салиха апаның күңел җәрәхәтенә шифалы май сөрткәндәй, сызлануын җиңеләйтеп җибәрде.

* * *

Тәгәрмәчләр тыкылдавы һәм тормозлар ыңгырашуы белән вокзал янындагы моңсулыкны бердән җанландырып, бөтен тәрәзәләреннән җылы нур сибеп, поезд килеп туктады. Әле генә буш торган перрон ыгы-зыгы белән тулды, вагон баскычларыннан чемодан күтәргән кешеләр белән аралаш костюм гына кигән ирләр сикереп төште – көнчыгышка үтеп баручы поезд иде бу.

Күк плащы өстеннән билен киң каеш белән буган, плащы төсле үк беретын маңгаена батырып кигән, елтырап торган зур кара портфель тоткан бер ир кеше вагоннан төште дә, шәһәр ягына турыдан чыгып китәргә ниятләп булса кирәк, як-ягына каранмыйча гына халык тавышыннан гүләп торган биек вокзалга керде, зал аша ашыгып тышкы ишеккә таба узды.

Аның куе җирән сакал-мыек баскан йөзеннән яшен белү кыен иде, ләкин сынының төзлегеннән, хәрәкәтләренең җитезлегеннән, соры күзләренең үткенлегеннән егерме биш яшьләр тирәсендәге егет икәнлеген чамаларга була иде.

Тышкы ишек янында егет эчкә кереп килгән бер малайга бәрелеп, ирексездән күтәрелеп карады һәм кинәт туктап калды. Малай аңа күз дә салмыйча залга узды, ә сакаллы кеше аның зәңгәр курткасыннан күзен ала алмый карап калды. Малай халык арасында кереп югалгач, ул кинәт, портфеле белән кешеләрнең янтыкларына бәрелә-бәрелә, гафу да үтенеп тормыйча, эчкә ташланды, әмма зәңгәр куртканы күреп, тагын адымнарын әкренәйтте. Әйтерсең лә ул күптән югалткан кадерле кешесен тапкан да хәзер аны тагын югалтудан курка, шул ук вакытта килеп сүз кушарга да кыймый, улмы-түгелме дип, икеләнә иде.

Малай үз артыннан күзәткәннәрен сизмәде. Вокзалдан перронга чыгып, пыяла стеналы кечкенә кафега таба китте, ишектән бик кыюсыз гына керде дә сагаеп туктап калды. Ул үзе кемнедер күзәтә иде. Баскан килеш ашау өчен җайланган түгәрәк мәрмәр өстәлләрдән азык калдыкларын, буш стаканнарны җыештырып йөрүче ак халатлы, талчыккан чырайлы апаны күзәтә икән малай.

Сакаллы егет аның янынннан эчкә узды, ашарга җыенгандай, бер өстәл янына басты, һәм беретын тагын да батырыбрак киде дә, сиздермәскә тырышып, шул ук вакытта бик җентекләп малайның ябык йөзенә, иягендәге түгәрәк миңенә текәлде. Караган саен егетнең йөзе яктыра барды, менә-менә ул малайга ташланып, аны кочагына алып кысар иде шикелле. Ә малайның анда кайгысы юк, ул һаман теге ак халатлы апага карап тора иде. Менә апа подносын күтәреп буфет ягына таба китте, малай шуны гына көткән икән, якындагы өстәлдән җәлт кенә бер сынык ипи чәлдереп, чыгу ягына борылды.

Ләкин чыгып китә алмады, теге егет аның юлына аркылы төшәргә өлгерде.

– Туктале! Нишлисең син, ә?

Малайның болай да ак чыраеннан кан качты, ул сакаллы кешегә коты очып карады.

Сакаллының аны куркытырга нияте юк иде, күрәсең, тавышын йомшартты, елмайды:

– Ашыйсың киләме?

Малай ипи сыныгын учына чытырдатып кысып басып тора, сакаллының йөзенә текәлеп караган, аның ниятен чамаларга тырыша иде: нишләтмәкче ул аны? Ник килеп тотты?

Егет аның саен ягымлырак күренергә тырышты:

– Ник дәшмисең? Русча белмисеңме әллә? Татарча аңлыйсыңмы соң? Ә бәлки, син чит телдә генә сөйләшәсеңдер? Йә инде, әйтсәнә бер сүз генә!..

Малай бу кешедән болай гына котылып булмасын аңлады булса кирәк, карлыккан сыманрак тавыш белән саф татарча:

– Ни әйтим? – дип сорады.

Сакаллы кеше, күзләрен кыса төшеп, күңелле итеп көлеп җибәрде:

– Соң, сораганга җавап бир! Ашыйсың киләме, дип сорыйлар бит синнән! Әйдәле!

Ул малайны куртка җиңеннән тоткан килеш прилавка янына алып килде дә симез битле ападан ике стакан кофе, биш пәрәмәч сатып алды.

– Тот стаканнарны! – диде малайга. Тегенең кулындагы ипи сыныгын кая куярга белми аптырап торганын күреп көлде: – Анысын кире куйсаң да ярый.

Алар биек өстәл янына янәшә барып бастылар. Малайның нечкә бармаклары калтырануын, күзләре елтыравын күреп, егет:

– Берәр кая китәргә йөрисеңме әллә? – дип сорады. – Акчаңны, билетыңны-мазар югалтмагансыңдыр бит?

Малай, юк дигәнне аңлатып, башын селекте: авызы тулы ризык булганга, аның яңаклары бүлтәеп чыккан иде.

– Әллә берәрсен каршы алырга төштеңме?

Малай тагын башын селекте.

– Алайса, нишләп вокзалда йөрисең?

Малай ашавыннан туктады, аксыл керфекләре тетрәнеп, иреннәре үпкәләгәндәй турсайды.

Егет, малайның авырткан җиренә кагылганын сизеп, сүзен шаяртуга борды:

– Дөнья күрергә чыккансыңдыр әле. Сәяхәт кылып йөрүеңдер. Яшь чакта андый хәлләр булгалый. Сәяхәтче Синдбад төсле буласы килә. Исемең дә Синдбадмы әллә? Илгизәрме?

– Юк...

– Ә ничек соң?

– Бикташ.

– Кара, хәтәр матур икән исемең. Ә мин Әхсән абыең булам. Аша, Бикташ, аша, кофесын да эч. Ну, романтика каешын күп ашарга туры килдеме инде?

Малай аңа гаҗәпсенеп карады: нинди каеш?

– Романтика каешының ниндилеген белмисеңме әллә? Алайса, син чын сәяхәтче түгел икәнсең әле. Шушылай берәр атна ил гизеп йөргәннән соң, милиция тотып әтиеңә кайтарып биргәч, әтиең, чалбарыңны төшереп, каеш белән сыйласа, романтика каешы менә шул була.

«Милиция» сүзен ишеткәч, Бикташның йөзе тагын күләгәләнде.

– Синең ашыгыч эш юк инде алайса, – диде Әхсән, җитдиләнеп. – Минем шушы портфельне генә илтешмәссең микән?

Бикташ карышып тормады.

Портфель шактый саллы булып чыкты. Җылы кафедан сибәләп яуган салкын яңгыр астына чыккач, Бикташ калтыранып куйды, башын куртка якасына яшерергә тырышкандай, муенын җыерды.

Алар вокзал мәйданын аркылы чыгып, бер-ике квартал бардылар да троллейбуска утырдылар. Кеше аз икән, Бикташ тәрәзә кырына, Әхсән аның янына утырдылар.

Малай троллейбус барган көйгә бик тиз оеп китте, башын юеш тәрәзәгә терәп, күзләрен йомды. Түшәмнән төшкән яктылыкта аның нәфис колагы һәм нечкә муены шактый керле күренде. Троллейбус туктаган саен, малай алгы утыргычның арка тимеренә маңгаен бәрә язып чайкалып куя, ләкин йокысыннан айный алмый, янә күзләрен йома иде. Йокысы бик тирән иде шикелле, әмма иңенә орынуга, дерт итеп сискәнеп, күзләрен ачты.

– Кайтып җиттек! – диде Әхсән.

Троллейбустан төшкәч, Бикташ урамга ян белән тезелеп баскан бишәр катлы йортларга гаҗәпләнеп карады. Аның бу тирәдә булганы юк иде әле.

Алар урам аша чыктылар да, иң якын йортның беренче подъездына кереп, иң югары катка күтәрелделәр. Әхсән портфеленнән ачкыч алып, ачык яшел төскә буялган ишекне ачты, алгы бүлмәдә ут кабызды. Озак вакыт караусыз булган йортлардан гына килә торган тынчу бер ис өйдә кеше юклыгын сиздерде. Бикташ каршысында өч ишек күреп, квартираның шактый зур икәнен чамалады. Әхсән уртадагы ишекне ачты:

– Ваннада коенып чыкмыйсыңмы? Бар, мин чәй кайнатканчы чистарынып чык. Киемнәреңне шунда калдырып торырсың, мин сиңа чиста күлмәк-ыштан бирермен. Ванна күргәнең бармы? Краннарын бора беләсеңме? Бар, алайса!

Сакаллы абыйның вокзалда очраган чит-ят малайга шушы хәтле кадер-хөрмәт күрсәтүе сәер тоелырга тиеш иде. Бу уй Бикташның миендә бер генә минутка чагылып үтте. Бер генә минутка, чөнки ул ахыр чиккә җитеп йончыган, үлеп йоклыйсы килә иде, шуңа күрә ул, аны-моны уйлап тормастан, хуҗа кушканнарга сүзсез буйсынды.

* * *

Алар ике бүлмәле квартираның ике бүлмәсендә йокладылар. Кунак – залда, җәелмә ятакта, хуҗа – кече бүлмәдә, диван-караватта.

Дөресен генә әйткәндә, Әхсән турында йоклый дип әйтү хакыйкатькә бик үк туры килеп бетмәс. Ул төн буе диярлек әрле-бирле йөренеп чыкты. Берничә тапкыр, караңгыда берәр нәрсәгә абынудан куркып, сак кына атлап, сулышын кысып залга керде, ак җәймәсен ачып ташлап, тынгысызланып йоклаган малайга иелеп, караңгыда аның йөз сызыкларын ачыграк күрергә тырышты. Аннары, кече бүлмәгә чыгып, түрдәге өстәл янына баскан килеш ак кәгазь битләренә зәңгәр фломастер белән ашыгыч сызыклар сызгалады. Ул бер-ике сызык үткәргән саен, кәгазь битендә әле уйчан, әле куркынган, әле саран гына елмайган бер йөз хасил була, ул йөз Бикташка гаҗәп охшаган иде. Әхсән, сакалын чеметкәләп, ишекле-түрле йөренә, тәмәке тарта, форточканы ачып, йөзен дымсу җилгә куеп елмая, әледән-әле өстәлдә яткан кул сәгатенә карый. Аның тизрәк таңны аттырасы, көнне җиткерәсе килә иде.

Ниһаять, талчыкканын тоеп, диванга яткач та ул озак йокыга китә алмады. Төшендә Бикташны күрде.

Ул залда җәелмә ятак шыгырдаган тавышка уянып китте. Күзләрен шар ачып, сагаеп тыңланды. Залдан килгән тавышлардан кунагының һәр хәрәкәтен күз алдына китерергә тырышты. Менә малай, ялан аягының очларына гына басып, ванна бүлмәсенә кереп китте, келәне шакылдатмаска тырышып, сак кына элде, суны да әз генә җибәреп агызды. Аннары шактый озакка тынып калды. Әһә, менә чыкты. Тукта, ә бусы нинди тавыш? Тышкы ишекнең йозагы шыгырдый түгелме? Әйе шул, әнә ишек шалт итеп ябылды, инглиз йозагы челт итеп бикләнде.

Әхсән урыныннан ничек сикереп торганын сизми дә калды, үзен-үзе белештермичә ишеккә атылды. Баскыч буенча шак-шак баскан аяк тавышы гына ишетелә иде.

– Бикташ, тукта!

Әхсәннең тавышы таш стеналарга бәргәләнеп яңгырады. Җавап булып аяк тавышлары гына ешайды. Әхсән, өчәр-дүртәр басманы берьюлы атлап, аска томырылды, ялан аяклар ташта чап-чап килделәр. Тизрәк, тизрәк! Урамга чыгып җиткәнче тотарга кирәк малайны, анда куыш-куыш уйнап булмас! Ак майка белән бизәкле сары трусик кигән сакаллы кешенең җан-фәрман бер малай артыннан чапканын күрсәләр, иртән торып сөт кибетләренә чыккан хатын-кызлар ни әйтер дә, урам себерүчеләр ни уйлар? Тотып алып, тиләләр йортына озатмасалармы үзеңне?

Алар бер-бер артлы дөбер-дөбер аска хәтле чабышып төштеләр. Икенче каттагы бер ишектән бала җитәкләп чыгып килгән хатын, боларны күргәч, ялт итеп кире кереп китте. Ахыр борылышның баскычын Әхсән ике генә атлады, ишекне ачып азапланган Бикташның якасыннан эләктереп үзенә тартты һәм каршысына чыгып басты.

– Тукта, дим!

Малай дорфа итеп тартылды, иреннәрен кысып:

– Нәрсә, әйберегез югалганмы әллә? – диде. – Мин алмадым! Менә! Менә!

Ул, курткасының изүен ачып, керләнгән ак күлмәген күрсәтте, кесәләрен актарды. Әхсән аптырап китте – ул һич тә моны көтмәгән иде.

– Юк, хикмәт анда түгел, – генә дия алды. Ә үзе, эшнең нәрсәдә икәнен аңлатырга сүз таба алмагандай, яланаяк боздай салкын таш идәндә таптанды. – Кызык кына син, ә? – диде. – Саубуллашу юк, ни юк, мыштым гына чыгасың да китәсең. Бу ни дигән сүз була инде?

– Йоклыйдырыегыз бит.

– Алай бик ашыккач, уяталар аны.

Кичә кич Бикташ Әхсәнгә, буйга сузылып үскән булса да, акылы белән сабыйлыктан чыкмаган яшүсмер булып күренгән иде. Бүген исә аның каршында байтак нәрсә кичергән, кешеләргә ышанычы какшый башлаган яшь егет басып тора иде. Әхсән аның белән ничегрәк сөйләшергә белми аптырап калгандай булды. Ул елмаеп башын чайкады:

– Ник бу хәтле дорфа кыланасың син? – диде. – Минем сиңа бер үтенечем бар иде. Аны монда сөйләшеп булмый. Аннары егет кеше җитди сүзне ыштансыз килеш сөйләшмәс инде, шулай бит? Әйдә, кереп сөйләшик. Курыкма, мин сине бәйләп тотмам. Алай бик китәсең килә икән, китәрсең.

Бикташ аның аякларына карады, хәлен аңлады, сүз куертып тормады, ярар, диде дә, икешәр баскычны берьюлы атлап, өскә менеп китте. Ишектән кергәч, беретын да салмыйча, хуҗаны тыңларга әзер икәнен белдереп, стенага сөялде.

Әхсән залның ике ягындагы зур тәрәзәләрнең пәрдәләрен шытырдатып ачып җибәрде, бүлмәгә көзге иртәнең саран яктысы сибелде.

Көн яктысында өйнең караусызлыгы, хатын-кыз кулы юклыгы аеруча күзгә ташлана иде. Идәнне әйткән дә юк, сары төскә кара сызыклар сызылган стеналарны да, почмактагы кечкенә телевизор экранын да тузан сарган кебек тоела, урта бер җиргә куелган зур өстәлдә тузгып яткан кәгазь, карандашлар, почмаклардагы рамнар, катыргылар тәртипсезлекне тагын да арттыра иде. Ишеккә каршы стенада сары ырмаулы сәгатьнең коймак кебек түгәрәк сары теле әкрен генә чайкала, аның янындагы рәсемнәрдән төрле кыяфәтле малайлар кайсы елмаеп, кайсы бик җитди кыяфәт белән Бикташка карап торалар иде.

Әхсән кече бүлмәдән шакмаклы күлмәк белән зәңгәрсу джинсы киеп чыкты, куе чәчләрен сыпыргалады, үтешли җыелма ятакны аягы белән читкәрәк шудырды:

– Яткан урыныңны җыярга кирәк иде, ичмаса, – диде. – Хезмәтчеләр юк бездә.

Ә үзе шунда ук урынны җыярга талпынган Бикташны туктатты:

– Ярар инде, сөйләшик әле башта... Хикмәт шунда – мин рәссам. Рәссамның кем икәнен беләсеңме?

Бикташ белә иде, билгеле. Дөрес, мәктәптә стена газеталарын чыгарып йөрүче Садрыйдан башка рәссамны күргәне юк иде моңарчы, ләкин рәссамның кем икәнен белә. Флера апалары белән теге вакытта шәһәргә экскурсиягә килгәч, музейда картиналар да күргән иде. Дөрес, ул чакта музейдагы мылтыклар, туплар аның өчен картиналардан күпкә кызыклырак булып тоелган иде.

Әхсән сүзенең малайга әллә ни тәэсир итмәгәнен күреп көрсенде, алай да дәвам итте.

Әйе, ул рәссам, картиналар яза, китапларга рәсемнәр ясый. Байтактан инде яңа картина язу турында уйланып йөри. Ул малайлар хакында булачак һәм «Әтиләр фронтка киткәч» дип аталачак. Анда сугыш вакытында фронтка киткән әтиләре урынына заводларга эшкә килгән яшүсмерләр сурәтләнәчәк.

Әхсән стена буенда сөялеп торган бер рамны әйләндереп күрсәтте. Менә кара, завод цехы, станоклар, алар янында кечкенә генә булып күренгән малайлар. Аннары өстәлдән рәсемнәр алды. Менә картинаны язу өчен шушындый этюдлар ясала. Әхсән инде әллә ничә заводта булды, сугыш вакытында үсмер булган, заводта эшләгән кешеләрне табып сөйләште. Картинаның эчтәлеге, композициясе, яктылыгы – һәммәсе уйланган.

Шактый сөйләде ул. Ахырда:

– Авыр эш түгел, – диде. – Бүген ял көне, бер-ике сәгать вакытың бардыр. Менә шушында өстәл янында басып кына торырсың, мин сеансларны озын ясамыйм.

Сәер тоелды малайга рәссамның сүзләре. Шул ук вакытта ул бөтенләй үк битараф та кала алмады. Рәссам чыннан да дулкынлана, бу нәрсә аның өчен бик әһәмиятледер, мөгаен. Шуңа күрә Бикташ аның хәленә керергә тырышты, мөмкин кадәр йомшак итеп:

– Бүген минем вакыт югые шул, – диде.

– Нишләп? Ни эшең бар ул хәтле?

– Эшкә барам.

– Нинди эшкә? Кая?

– Ипи заводына грузчик булып.

Әхсән шаркылдап көлеп җибәрде.

– Ипи заводына... – диде ул. – Тамагың бик тук иде шул!

Кафеда ипи урлаганын исенә төшереп, малай башын аска иде.

– Мин бүген генә эшли башлыйм бит әле анда, – диде ул. – Андагы абый әйтте, ял көнне иртүк килерсең, теләсәң күпме эшләрсең, акчасын шундук бирәм, диде.

Әхсән аңа гаҗәпләнеп карады, җитдиләнде.

– Шул шул, – диде. – Сине эшкә алырга хокукы юк аның. Син мәктәптә укырга тиеш. Ә ял көнне укулар юк. Ничә яшь инде сиңа? Уналты тулмагандыр бит әле?

– Юк әле, – диде Бикташ. – Минем даими эшлисем килә.

Әхсән, сакалын чеметкәләп, тәрәзә яныннан әйләнеп килде:

– Нәрсә, бөтенләй укуны ташлап, эшкә керергәме әллә исәбең?

– Ие шул.

– Ипи заводына булмаса да ярыймы соң?

– Ярый. Нинди эш булса да!

– Миңа ялланасыңмы соң?

– Нинди эшкә?

– Натурщикның кем икәнен беләсеңме? Беләсең килсә, рәссамның иң якын ярдәмчесе ул. Ансыз бер картинаны да язып булмый. Бик тә җаваплы хезмәт.

Соңгысы малайны сагайтып җибәрде.

– Булдыра алырмын микән?

– Тырышкан булдыра. Әллә ние юк. Кушкан рәвештә басып яки утырып торасың, ә мин сиңа карап рәсем ясыйм.

Малай көлемсерәп куйды. Булмасны! Тик торган өчен, җитмәсә әле, тик утырган өчен акча кем түләсен?

– Бик кирәк кеше, хезмәт хакын да яхшы гына түлиләр. Йөк ташучылардан ким түгелдер, мөгаен.

– Күпме? – диде малай, үз колакларына үзе ышанмыйча. Ничек инде тик утырып торганга грузчик акчасын бирсеннәр! Тоттырырлар, бар!

Аның ышанмаганын күреп, рәссам саннарны атауны кирәк тапты:

– Безнең художество училищесында, мәсәлән, андыйларга сәгатенә өч сум түләнә.

Бикташ күңеленнән генә көненә күпме төшәсен чамалап карады. Адәм ышанырлык түгел иде бу!

– Ә кем бирә ул акчаны?

– Сиңа үзем түлим. Менә хәзер аванс биреп куям.

Әхсән кече бүлмәдән өч бишлек алып килде.

– Ал! Менә сиңа биш сәгатьлек эш хакы.

– Күп бит бу!

– Ә син позировать итеп кара әле. Күпме-түгелме икәнен шуннан әйтерсең. Ал-ал, авызыңны ачып торма!

Бикташ кыюсыз гына учын сузды. Акчаны пөхтәләп төреп, курткасының куен кесәсенә салып куйды.

* * *

Әмма беренче карашка күңелдәге образга бик туры килгән малай, каршыга бастырып куйгач, бөтенләй башка төсле булып күренә башлады. Дөрес, тыңлаучан үзе: Әхсән әзерләп куйган иске сырма белән йөнтәс бүрек киеп (сугыш вакытында завод цехлары бик салкын булган!), нәкъ рәссам кушканча тәрәзәгә таба башын борыбрак, урындык аркасына тотынып басып тора, кымшанмый, селкенми, керфеген дә сирәк кагарга тырыша үзе. Әмма күз карашы, йөзе! Аларда бер генә хис чагыла – талчыгу. Малайда бер генә теләк – бу эш тизрәк бетсен иде дә кич тизрәк җитсен иде.

Беренче күргәндә рәссамның дикъкатен җәлеп иткән беркатлы курку, чарасызлыкның, гаҗизлекнең эзе дә юк.

Андый чакларда рәссам нишләргә кирәген белә: натурщик белән җиңелчә генә әңгәмә корып җибәрә. Эш арасында бирелгән сорауларга кеше артык уйлап тормыйча җавап бирә, җанланып, иркенәеп китә, кайчак, үзе дә сизмәстән, яшерен серләрен дә ачып ташлый. Әхсән, мольберты артына басып, киндеренә сызгалаган арада, авыз эченнән генә нидер көйләде, сызгыргалады. Бикташка сирәк-мирәк кенә күз салды, бер дә исе китмәгәндәй сораулар биреп, малайның кылларын тарта башлады.

– Син иркенрәк тор, – диде. – Тәнең оер... Вокзалга ничек килеп чыктың соң син? Мондагымы үзең, әллә берәр каян килдеңме?

– Шулай туры килде инде... Юл уңаеннан...

– Детдомнан качтыңмы әллә?

– Юу-ук, аннан түгел...

Малайның ачыласы килмәгәне күренеп тора иде, шунлыктан Әхсән аңа артык басым ясамады. Үз вакыты белән сөйләр әле дип уйлады. Бер сәгать үттеме-юкмы, карандашын кулындагы такта кисәгенә куйды.

– Җитте.

– Мин торам әле, торам, – диде Бикташ.

– Унбиш тәңкәнең әҗерен бер көн эчендә кайтармакчы буласыңмы? Акылың алтын икән. Мин әле сине аның өчен биш көн буе эшләтәчәкмен. Көн саен берәр сәгать.

Бикташ, бүреген салып, тирләгән маңгаен сөртте.

Йөзе моңсу иде аның.

– Акча бик кирәкмени соң? – дип сорады Әхсән.

– Бик.

– Күпме?

– Күп.

– Нәрсәгә?

– Телевизор алырга.

– Сезнең телевизорыгыз юкмыни?

Малай тагын дәшмәс булды.

Әхсәннең ашыгыч эше бар иде. Хәер, әзме-күпме дәрәҗәсе булган рәссамның эше бетеп торамыни? Абдулла Алишның быел басылып чыгачак «Бал корты» исемле китабына рәсемнәр ясарга тиеш иде ул. Китап нәшриятына Мәскәүгә киткәнче эшен бетерәм дигән вәгъдәсе дә бар иде. Ләкин башта бик ансат тоелган эш – аллы-гөлле чәчкәләр арасында биеп йөргән нәфис кызларга охшаш күбәләкләр, бизәкле яулыкларын башы белән чөйгән эшлекле бал кортлары рәссам каләменә ансат кына буйсынып, кәгазьгә төшәргә теләмәделәр.

Шул ук вакытта рәссамның Бикташны да ычкындырасы килми иде. Ул малайга берәр шөгыль табарга тырышты. Кече бүлмәдән тузан суырткыч алып, залда гүләтеп тузан җыйгаларга кереште. Бикташка:

– Карап торуы рәхәтме? – диде. – Ярдәм итәсең килмиме?

Нигә итмәсен! Рәхәтләнеп эшли аны Бикташ. Ә Әхсән тынычланып өстәл янына утырды.

Тузанны җыя-җыя кече бүлмәгә барып кергәч, Бикташ гүләп торган машинаны онытып туктап калды. Бүлмәнең бер стенасы буйдан-буйга киштәләр белән тулы, аларга шыплап китап тутырылган иде. Мәктәп китапханәсендәге шикелле! Әтисенең өендә моның ишене күрмәгән, китап-журналга сусаган малай өчен бу искиткеч байлык булып күренде. Ул аннан-моннан эшен бетерде дә китапларга тотынды. Көннең калган өлешен рәссам Әхсән Гайнуллин рәсемнәре белән чыккан әкиятләр укып уздырды.

Кичкә таба Әхсән бәрәңге пешерде, аны колбаса, май белән кушып ашап чәй эчтеләр. Савыт-саба юарга борылган Әхсән кунагының өстәлдән бер-ике телем колбаса шудырганын сизеп алды.

– Син өстәл янында туйганчы аша, кыенсынып утырма, – диде ул. – Кесәдә колбаса тиз бозыла ул, чалбарны да пычрата.

Әхсән малайның керле киемнәрен салдырып, үзенең ак нейлон күлмәге белән искерәк булса да пөхтә күк чалбарын кигезгән иде. Малай кызарынып кесәсеннән колбаса телемен алды да тын гына кухнядан чыгып китте.

Әхсән эшен бетергәндә, ул алгы бүлмәдә киенеп азаплана иде.

– Тагын чыгып качарга инде әллә исәбең?

– Юк, – диде Бикташ. – Барып киләсе җир барые.

– Тагын вокзалгамы әллә? Өеңәме?

– Юк...

– Эшең беткәч монда кайтасыңмы соң?

– Ярар, – диде Бикташ.
– Кайт, әллә кайда йөрмә.
Әхсән аның троллейбуска утырып киткәнен ян тәрәзәдән карап калды. Урамда һаман шул эчпошыргыч яңгыр сибәли, малайның иңбашлары һәм курткасы чыланып та өлгергән, елтырап тора иде. Менә ул тукталыштагы ир кешедән нидер сорады. «Кая бара икән? – дип уйлады Әхсән. – Начар малайларга ияреп йөрмидер бит? Бер дә андыйга охшамаган үзе».
Рәссам эшкә утырды, мавыгып, вакыт узганын тоймады. Ишек кыңгыравы моңлы аваз биреп, берничә кат чыңлагач кына, урыныннан кузгалды. Өсте манма булган, битендә тамчылар ялтыраган Бикташны күреп елмайды.
– Ну и ну, бу хәтле пычракны каян җыйдың? – Ул малайның кызыл балчыкка буялган тез башларына ишарәләде. – Бар инде, боларын да ванна почмагына тондыр. Иртәгә бөтенесен берьюлы кер юу машинасында әйләндереп алырбыз.
Шулай дип, кыска балаклы яшел чалбар китереп бирде.
– Шуны киеп тор инде.
Малай шул чалбарны киеп, ванна бүлмәсеннән чыккач, рәссам, исе китеп:
– Бу ни тагын? – дип сорады, Бикташның кутыр баскан сөякчел балтырларына ишарәләде.
– Бумы? Бу батарейга пешкән иде.
– Нинди батареяга? Кем илтеп тыкты синең аякларыңны батареяга?
– Үзем... Вокзалда йоклаганда ялгыш терәгәнмен.
– Шулхәтле пешкәнеңне дә сизми йоклап буламыни? Аннары нишләп соң син вокзалда куна-төнә йөрисең, ә?
Малай йомылды, дәшмәде, ләкин шул минутта аның читкә, лампа яктысына борылган йөзендә каршылыклы хисләр чагылды. Рәссам ул йөздә кайнаган рәнҗешне, үпкәне, үҗәтлекне, үз намусын яклап утка ташланырга әзерлекне, мең төрле каршылыклы кичерешләрне күрде. Ул ашыгып өстәл янына килде, кулына карандашын алды. Ак кәгазь битендә ул күптән көткән, күптәннән эзләгән, аны газаплаган йөз калкып чыкты.
Әхсән, рәхәт бер талчыгу сизеп, урындыкка утырды, тәмәке кабызды. Иреннәре сакал-мыек арасыннан канәгать һәм хәлсез елмайдылар.
– Охшаганмы? – дип сорады ул, портретны күрсәтеп.
Кәгазьдәге малай Бикташ көзгедә күрергә күнеккән йөзгә охшаган да, охшамаган да иде шикелле. Тик шунысы бар: нигәдер, бер карагач, аннан тиз генә күзне алып булмый, ул менә-менә борылыр да сиңа тутырып карар, агарынган иреннәрен тибрәндереп нидер әйтер сыман тоела иде.
– Нишләргә соң инде синең белән? – диде Әхсән, уйланып. – Минем белән рәтләп сөйләшәсең килми, сереңне чишмисең. Нурзаһит белән таныштырыйммы соң әллә үзеңне? Шундый бер дус бар минем. Синең ишеләргә тел ачкычын тиз таба ул, профтехучилищеда мастер. Шалтыратыйм шуңа, ә? Әһә, сәгать тугыз тулып килә икән. Кичке институтта уку юк бүген, мөгаен, өйдәдер. Берочтан портретны да карап китәр. Ике тиенлек акчалар бар микән инде...
Шулай дип, кесәсеннән вак акчалар алды да телефон- автоматтан шалтыратырга чыгып китте.

* * *

Язмыш Салиха апага бик үк мәрхәмәтле булмаса да, бөтенләй ярдәмсез дә калдырмый иде. Бу юлы да шулай булды – шәһәрдә адым саен хәленә керердәй, киңәш бирердәй кешеләр очрап торды.
Крестьян йортының алты кешелек бүлмәсенә кереп, андагы ят хатыннарны күргәч, читенсенеп калган иде. Әмма артыннан ук янәшә караватка чак кына шадра төшкән, җилдә янган түгәрәк битле, тыгыз ак тешле, нык гәүдәле, илле яшьләр чамасы бер апа кереп урнашты. Иң элек кыштыр-кыштыр итеп зур-зур дүрт капчык алып керде дә аларны караваты астына урнаштырды, кара бәрхет бишмәтен салып, шома чәчләрен сыпырды да караватында моңаеп утырган Салиха апага:
– Син дә базарга килдеңме әллә? – диде. – Юкмыни? И-и, бергә булсак, әйбәт буласые... Суган сатарга килгәнием...
Апа Җамал исемле икән. Ике минуттан ул, яшь солдатны өйрәткән ефрейтор кебек, Салиха апаны үз кубызына биетә башлаган иде инде. Аның кушуы белән Салиха апа коридордагы титаннан бер чәйнек кайнар су алып кергән арада, яңа танышның сумкасыннан өйдә пешкән пәрәмәчләр, ярты литрлы банка белән авыл каймагы чыгып өстәлгә урнашкан иде инде. Өстәл тирәли алты хатын түгәрәкләнеп утырып, бергәләшеп чәй эчтеләр, һәркайсы үз йомышын сөйләде. Барысы да калага әйбер-кара алырга йә сатарга килгән, гаҗәп хәлгә тарыган бер Салиха апа гына икән. Аның улы югалганны ишеткәч, Җамал апа, бот чабып:
– Үзең дивана икәнсең син, шыр тиле! – дип кычкырып җибәрде. – Аерылган иргә кем инде бала тоттырып җибәрә, җә! И-и, үзем булсам, алырые ул миннән баланы, тотсын! Бала бирү түгел, әгәренки теләсәм, үзен дә җибәрмәсием әле. Әнә минеке, мин кушмаган җиргә аяк та басмый.

Егерме биш ел эчендә бик шәп өйрәттем мин аны! Өйдә генә утыра, күземә мөлдерәп кенә карап тора! Баштук кулдан ычкындырмаскае!

Хатыннар беравыздан аның сүзен хупладылар.

– Милициядән эзләтергә кирәк, – диде озынча ак чырайлы хатын.

Ләкин Җамал апа бу фикерне шундук юкка чыгарды.

– Милиция катыша башласа, малайны отыры котыртып, әнисенә тәмам дошман итүләре бар, – диде. – Ирләр алар бергә яшәп яткан хатыныннан узмый. Яшь хатынның башына ни килмәс!

Җамал апа Салиха апаның кайгысын күтәреште, аңа башын җуяр дәрәҗәдә хәсрәтләнергә ирек бирмәде. Иртәгесен аны караңгыдан кузгатып, үзе белән базарга алып китте, суганны дүрткуллап тиз арада сатып бетергәч, иренә җылы бияләй, балаларына матур шарф, җылы яулык ише әйберләр эзләп йөргәндә дә Салиха апаны үзеннән калдырмады.

Ул кичке поезд белән китәргә тиеш иде, ләкин китмәде, Крестьян йортында тагын бер төн кунды – Салиха апага ярдәмләшергә дип калды.

Дүшәмбе көнне алар горисполком ишеге төбенә эш башланганчы барып бастылар. Ләкин, ялгышып, кирәкмәгән бүлмәләргә сугылып йөрделәр, тиешлесе янына килеп җиткәндә, көндез ут янган тәрәзәсез коридорда әллә нихәтле халык чиратка тезелеп баскан иде инде. Әмма Җамал апа тукталып калмады:

– Безгә иртүк килергә куштылар, сорап кына чыгабыз, – дип, Салиха апаның кулыннан кысып тотып, халыкны этә-төртә ишектән алып кереп китте.

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, ди, аларга кирәк кеше эшкә килеп җитмәгән булып чыкты.

– Бәй, соң башка кеше әйтсен безгә кирәк адресны! – диде Җамал апа. – Ул әллә ай буе килмәс!

Түр өстәл артында утырган пеләш башлы, могтәбәр кыяфәтле ир кеше, каршындагы агай белән сөйләшеп торган җиреннән башын чак кына борып:

– Килер, килер! – диде. – Аннан башка белүче юк ул адресларны, өстәлен бикләп киткән. Төштән соң килегез!

Анысын инде Җамал апа күтәреп тора алмады. Салиха апаны булдыра алганча юатып, сәгать ике җиткәнче үк кабинет ишеге төбенә барып басарга, беркем белән исәпләшеп тормый бәреп керергә, йомышын бик ачык итеп, кычкырып әйтергә өйрәтеп, поездына утырып китте. Салиха апа аны озатып калды, поезд күздән югалуга, терәксез калган колмак сабагыдай сыгылып төште.

Атна буе барган әчпошыргыч яңгырлардан соң көн ачылып киткән, җылытып җибәргән, вокзал янында чыпчыклар чыркылдаша, күгәрченнәр чемченеп йөри иде. Салиха апаның күңелен исә кара болыт саргандай булды, ул башын кая куярга белми, вокзал алдындагы бакчада әрле-бирле йөренде, туктаусыз вокзал кәрнизе астындагы түгәрәк сәгатькә карады. Төшкә хәтле вакыт бик күп, һай күп иде әле.

*** * ***

Әхсәннең дусты Нурзаһит буйга Бикташ чамасы гына егерме өч яшьлек егет булып чыкты. Ул курткасын салганда ук, түгәрәк йөзен бүлмә ишегенә тыгып карады да көр тавыш белән:

– Шушымыни инде синең табылдык малаең? – дип сорады. – Нинди Бикташ булсын бу! Биктаяк бу, Бикмакарон!

Ул, сарык йоныннан бәйләгән җылы свитерын тарткалап, бүлмәгә керде, зәңгәр күзләре белән Бикташка үтәли күргәндәй текәлеп, кулын сузды:

– Йә, Бикташ, тормышлар ничек бара соң? Укулар ничек?

Аның һәр сүзеннән, хәрәкәтеннән төгәллек, икеле-микеле уйларга җай калдырмый торган кискенлек сизелеп тора иде.

– Тормышлар бик бармый шул әле аның, – дип, малай өчен җавап бирде Әхсән. – Тукталып тора.

– Тормыш тукталып тора алмый ул. Андый мәсьәләләрне конкрет сөйләшергә кирәк. Флоттагыча. Кая, документларыңны күрсәт әле! Туу турында таныклыгың яныңдамы? Анысы булмаса, мәктәп көндәлегеңне күрсәтсәң дә ярый.

Үзе һаман каты учыннан Бикташның кулын ычкындырмый, бит очларын чокырайтып, якты күзләре белән малайның күңелендәге бөтен уйларын укыгандай итеп карап тора. Бу хәтле кинәт һөҗүмне һич тә көтмәгән Бикташ кулын көчкә тартып алды. Нурзаһит Әхсәнгә борылды:

– Кая соң, берәр документы бармы аның?

Рәссам, аптырап калгандай, сакалын чеметкәләде:

– Мин сорамадым да тагын.

– Документы булмаса, милициягә тапшырырга кирәк иде, – диде Нурзаһит. – Ул нинди сукбайлыкта йөрү! Җитмәсә, уку елы барышында! Безнең белән сөйләшәсе килмәсә, милиция белән сөйләшер!

Нурзаһит Бикташка борылырга да җай калдырмады. Катгый, төгәл сораулар бирә-бирә, аның калада әтисе һәм үги әнисе белән яшәгәнен, ике атна элек алардан чыгып киткәнен, шуннан бирле мәктәпкә йөрмәгәнен әйттерде.

Малайның теле ачылганын күреп, Нурзаһит бүлмә уртасына урындык китереп куйды да тезләрен киң аерып утырды, Бикташны каршысына утыртты.

– Мәсьәлә бераз ачыкланды, болай булгач, – диде. – Берәр катырак сүз әйтеп ташлаганнардыр инде, ә? Ә синең серкә су күтәрми инде, баш бирәсең килми, үзеңә-үзең хуҗа булып яшисең килә. Шулаймы? Әллә түгелме?

Бикташ дәшмәде.

– Әйдә без болай итик, – диде Нурзаһит, кулын аның иңбашына куеп. – Әтиең белән барып сөйләшик. Ул сине эзли-эзли ах иткәндер инде, кара кайгыга сабышкандыр. Ярамый алай. Өеңә кайтырга кирәк.

– Бармыйм мин анда! – диде Бикташ. – Бармыйм да, йөрмим дә!

– Менә сиңа мә! Сине барыбер эзләп табачаклар. Мөгаен, милициягә дә хәбәр итеп куйгандыр инде!

– Милициягә барсам барам, анда бармыйм! Үтерсәгез дә бармыйм!

– Соң, милиция беренче эш итеп әтиеңне чакырып китерәчәк бит!

– Барыбер бармыйм!

– Карале, бик кире икәнсең син!

Нурзаһит, ике кулы белән тезләренә таянып, башын аска иеп, бераз уйланып утырды.

– Ярый, барма. Әгәр дә без болай итсәк: Әхсән абыең белән барып сөйләшсәк?

– Барабыз, ник бармаска, – диде Әхсән.

Бикташ, аларның бу ниятенә каршы тора алмасын күреп, тәмам каушап төште:

– Алар сезгә әйтерләр... Әйтерләр... – диде башын иеп, тотлыгып. – Акча урлады... диярләр... Телевизор ватты дип әйтерләр... Мин урламадым аны... Мин ватмадым...

Әхсәннең киң якалы нейлон күлмәге малайның муенын бигрәк нечкә, иңбашларын тар итеп күрсәтә иде. Рәссамның күңеле нечкәреп китте, ул якынрак килеп, кулын аның башына куйды.

– Алай борчылма, – диде. – Без хакны нахактан аера беләбез.

– Без конкрет сөйләшербез, – диде Нурзаһит та. – Кая, адресларын әйт әле.

Теле бер ачылгач, Бикташ туктый алмады: Якты Тәрәзә поселогы турында, әнисе турында, әтисенең үзен ничек, ни өчен кайтып алып килүе турында, аның чын ниятен соңыннан гына белүе турында сөйләргә кереште. Әйтерсең лә Нурзаһитның үткен карашы, төгәл сораулары аның күңел чишмәсенә аркылы яткан ташны алып аттылар.

– Тәмам буталып беткәнсең икән син, – диде Нурзаһит, аның кыйссасын тыңлап бетергәч.

*** * ***

Аларның троллейбуска утырып киткәнен Бикташ үзәге өзелеп тәрәзәдән карап калды. Троллейбус йортлар артына кереп китеп күздән югалгач, стенадагы сары ырмаулы сәгатькә карады. Кайчан барып җитәрләр дә ни сөйләшерләр икән? Бикташның әтисе ни әйтер ? Ә бәлки, ул чыннан да Бикташны эзләгәндер? Теге вакытта, алар Уйнак белән куышта йоклап ятканда иске ихатага килгән иде бит! Шулай эзли-эзли тәмам гаҗиз булып беткәндер, бәлки. Хәзер менә, улы табылгач, түбәсе күккә тиеп сөенер, тегеләргә ияреп, атылып килеп тә җитәр әле. Ник килмәсен! Үз әтисе ич ул аның! Бәһиҗә түтәй җибәрмәскә тырышыр. Бикташны да хурлап маташыр, карак, дияр, хулиган, дияр. Сөйләшергә бик оста бит ул, ышандырып куюы да бар...

Их, үзем ияреп барасы калган икән, дип үкенә башлады малай. Ул, үз-үзен кая куярга белми, әрле-бирле йөренде, туктаусыз ырмаулы сәгатькә карады. Сәгатьнең озын тимерчыбыкка эленгән борчак коймагы төсле сары теле уңга-сулга талгын гына чайкалмаса, Бикташ аны йөри дип тә белмәс иде, чөнки уклары, сумала белән ябыштыргандай, хәрәкәтсез булып тоелды.

Ул, вакыт җитмәгәнен белсә дә, һәр троллейбустан төшкән кешеләрне тәрәзәдән күзәтеп торды. Эче пошканга түзә алмыйча, кухняга кереп, өстәлдәге тәлинкәдән алма алып кимерде, суыткычтан кәкре таяк төсле колбаса кисәге алып, аны әрчеми-турамый гына тешләде. Тагын тәрәзә янына барды, тагын әйләнеп кухняга керде. Ниһаять, аның башына бер уй килде: тегеләр кайтуга өйне җыештырып куярга. Кече бүлмәдәге диван артыннан тузан суырткычны чыгарды. Моторның тигез гүләве тынычландырып җибәргәндәй булды. Ни дисәң дә, хәрәкәт. Бик үк пөхтә эшләмәсә дә, аннан-моннан олы бүлмәне дә, кухняны да тазарткалап чыкты, иң соңыннан кече бүлмәгә керде. Суырткычның көпшәсен диван астына сузган иде, нindидер каты нәрсәгә бәрелгәнен тойды. Дүрт

почмаклы зәңгәр калай савыт икән. Эче тулы су – проявительме шунда, закрепительме. Тартып чыгарам дигәндә, суы чайпалып идәнгә түгелде, Бикташ аны суыртканын сизми дә калды. Машина чыш-пыш итте дә гүләвеннән туктады. Бикташ, кабаланып, суырткычның мең буынлы тук еланга охшаган көпшәсенә өрергә кереште. Аннары селкеде, каккалады – машина рәтләнмәде. «Ник кенә тотындым бу нәрсәгә, – дип уйлады Бикташ, ачынып. – Болай булгач, миңа тамчы да ышаныч булмас инде. Телевизорны да мин ваткан дип уйларлар, мөгаен. Тузан суырткычны ватканны, нигә телевизорны ватмаска, дияр Әхсән абый...»

Ул, суырткычны идән уртасында калдырып, зал ягына чыкты, ян тәрәзә янына килде. Күз бәйләнә башлаган, ләкин урамда утлар кабынмаган иде әле. Әңгер-меңгердә, троллейбустан төшкән кешеләр арасында таныш сыннар күзгә чалынгандай булды. Әллә өченчесе дә таныш инде?.. Ничек итеп алар күзенә күренсен хәзер Бикташ? Ул тиз генә курткасын алып, ботинка бауларын да бәйләп тормыйча, ишектән чыгып китте.

* * *

71 нче квартираның акка буялган ишеге уртасында тимер ырмаулы пыяла «күз» акаеп тора. Нурзаһит, эчтән караган кеше яхшы күрсен өчен нәкъ аның турына басып, бармагы белән ишек кырыендагы кыңгырау төймәсенә төртте. Хуҗалар кыңгырауның төзүчеләр куйганын алып ташлаган, матур көй чыгарып чыңгылдый торганын, кыйбатлысын алып куйган икән. Нурзаһит көйне кат-кат уйнатты, ләкин ишек артыннан тавыш-тын ишетелмәде. Өйдә кеше юк иде.

Егетләр баскыч мәйданчыгындагы тузанлы тәрәзә төбенә утырдылар, Әхсән тәмәке кабызып җибәрде.

– Күңелсез монда, – диде Әхсән, лифт читлегенә таба төтен өреп.

– Аның урынына уңайлы, – диде Нурзаһит. – Баскыч буйлап тугызынчы катка хәтле тәпи-тәпи менәсе түгел, чүп чиләге күтәреп, урамга чыгып йөрисе түгел.

– Уңайлылык белән генә булмый бит ул! – дип көрсенде Әхсән. – Җан җылысы кирәк кешегә. Иркенлек кирәк. Табигать белән бәйләнеш кирәк! Ә без уңайлы дигән булып, гомеребезне таш тартма эчендә үткәрәбез. Адәм баласының табигате моңа каршы! Табигать үзенекен итә! Шуңа бит инде күпме кеше эт асрый, кош асрый, кактус үстереп иза чигә! Чөнки табигатьтән аерылып яши алмый. Әнә, карале, теге бала ни кылана!

Ул тәрәзәдән тышка, ишегалдына ымлады. Анда очлы кара башлык кигән бер малай ак муенлы, йөнтәс койрыклы җирән көчек белән әвәрә килә иде. Маэмай малай каршында ал тәпиләрен бөгеп чүгәли, аннары, күтәрелеп, арт аякларына баса да малайның битенә үрелә, ә тегесе аны кочаклый, башыннан сыйпый иде.

Бу күренеш белән мавыккан егетләр, каяндыр, астан ишетелгән чәрелдек хатын-кыз тавышына башта игътибар бирмәделәр. Мондый зур йорт тирәсендә кем кычкырмас! Ләкин тавыш торган саен көчәеп, егетләрнең дә колагына үтеп керде:

– Тизрәк бул инде! Бар инде! Пычратып бетерә бит баланы, дөнья шакшысына батыра! Абау-абау, авызын ялый!

Тавыш иясе үзе күренми, баскыч төбендә, тышкы ишекне өстән ышыклаган бетон плита астында тора иде булса кирәк. Менә аннан кара плащ, соры эшләпә кигән җыйнак кына гәүдәле бер ир кеше килеп чыкты, җил-җил барып, теге малайны кулыннан эләктереп алды да, бар көченә кизәнеп, ботинка башы белән маэмайның корсагына тибеп җибәрде. Эт ачыргаланып чинады, сызлану йомгагы булып читкә тәгәрәде. Менә ул калтыранып, азапланып аякларына басты. Ир кеше, бәргәләнеп елаган малаен кулыннан ычкындырмый гына, таш алгандай итеп, җиргә иелде. Бары шуннан соң гына җирән маэмай, бер якка янтаеп, читкә тайпылды.

– Карале, нишли, ә! Ни кылана! Бу чаклы кансыз булыр икән! – дип сөйләнде Әхсән үзалдына.

– Әйе, конкрет тәрбия бирәләр бу малайга, – диде Нурзаһит.

Астан ишек шакылдаган, елаган, карганган тавышлар ишетелде. Тимер читлек буйлап шуып, өстән аска лифт кабинасы төшеп китте. Бераздан лифт тартмасы Әхсәннәр турына җитеп туктады, аннан әлеге өч кеше чыгып, 71 нче квартира ишегенә килделәр.

– Гафу итегез, – диде Нурзаһит, ярсып елаган малайның тавышын басарга тырышып, – сез Мансуровлармы әллә?

Малай елавыннан туктады, ир кеше борылып карады:

– Әйе, Мансуров.

Аның йөзен күргәч, Әхсән, бармакларын сүнеп барган тәмәке төпчеге пешергәнен дә сизмичә, хәрәкәтсез калды. Менә бу бәхетле ата, ичмасам! Аңа Ходай дөньяда иң зур сөенечне – нәкъ үзенә охшаган ир бала биргән. Нәкъ әтисе төсле икән Бикташ, суйган да каплаган! Шундый ук нечкә, аксыл кашлар, шундый ук күзләр, түгәрәк колак яфраклары, инде булган-булган булсын дигәндәй,

иягенең сул ягындарак түм-түгәрәк коңгырт миң табы. Улы төсле кашларын җыерыбрак карап тора, ни әйтергә белми аптырагандай, юка иреннәре дә нәкъ Бикташныкы төсле итеп тетрәнеп куйды.

Нурзаһит үзенең йомышын сөйли, Бикташның хәлен аңлата, ә Әхсән сүзләрне тыңламый, Сәетҗан абыйның йөзендәге үзгәрешләрне күзәтә иде. Менә ул йөздә чиксез гаҗәпләнү чагылды, менә ул нидәндер куркынып китте, син ни әйтерсең дигәндәй, астан гына хатынына карап алды. Тик Әхсән көткән бер хис – сөенү, куану хисе чагылмады ул йөздә. Чыннан да, нигә соң әле ул баласы табылганга шатланмый, ни өчен болай борчыла? Ник бер сүз әйтми? Аның урынына киң кырлы күксел эшләпә кигән, шакмаклы пальтосына көчкә сыйган корсаклы хатыны сөйли:

– Бәй, нишләп сезгә барып керде әле ул? Анасы янына кайтып киткәние ләбаса, – ди.

Ят абыйларны күргәч әзрәк тынып торган малай тагын тавыш бирде:

– Абый кая? Абый кайтсын!

– Тик кенә тор! – диде хатын. – Әйдәгез, кереп сөйләшик әле.

Бусаганы атлауга, хатын, улын җилтерәтеп, ванна бүлмәсенә алып кереп китте. Аннан шыбырдап су аккан, тиргәнгән, чәрелдәгән тавышлар ишетелде.

Ә Сәетҗан абый ялгыш сүз ычкындырудан курыкты, ахры, алгы бүлмәдә берни дәшми, аска карап тик торды. Түшәмнән салынып төшкән йөзле лампочка яктысында аның йөзе Әхсәнгә башкачарак күренде. Абзыйның улына охшап бетмәгән яклары да шактый икән: күз төпләре җыерчыклы, юка борынында зәңгәрсу челтәр булып кан тамырлары беленеп тора. «Бикташ та картайгач шушындый булыр микәнни? Йа Хода, гомер кешене ничек үзгәртә!»

– Сәетҗан, нишләп кунакларны ишек төбендә тотасың? Керегез, кер, җаныйларым, залга узыгыз, – диде хатын, ванна ишеген ябып. Хатын күбрәк Әхсәнгә карап сөйли, сакаллы булганга, ул аны дәрәҗәлерәк дип белде, ахрысы.

Ләкин залга кереп утырышкач, эш турында күбрәк Нурзаһит сөйләште. Ул Бикташның хәле бик аяныч икәнен, беркая да урнашмаганын, укымаганын аңлатырга тырыша иде.

– Сезгә ничек кенә булса да уртак тел табарга кирәк, – диде ул плащын да салмыйча, үз өендә чит кеше кебек утырган Сәетҗан абыйга. – Конкрет сөйләшергә кирәк. Бу яшьтәге малайларның күбесе салулап ала, ата кешегә сабыр булырга туры килә.

Сәетҗан абый эшләпәсен сыпыргалады.

– Аптыраган инде, нишләргә дә белгән юк, – диде ул, ниһаять.

– Ничек инде белмисез! – дип кинәт кычкырып сүзгә кушылды Әхсән. – Аптырап торыр нәрсә юк! Хәзер үк барып алып кайтырга да кире мәктәбенә илтергә кирәк!

– Безнең янда торасы килми бит аның! – Монысын, кулларын күкрәгенә кушырып, кече бүлмә ишегендә аркылы баскан Бәһиҗә түтәй әйтте. – Аны моннан куып чыгарган кеше булмады. Үзе чыгып китте. Бөтен нәрсәне пыран-заран китереп, телевизорыбызны челпәрәмә ватып качты. Әле менә кичә генә яңа трубка куйдырдык. Йөз тәңкәгә төште, йөз тәңкәгә! Ни үче булгандыр бездә, белгән юк. Какмадык, сукмадык, бернәрсәдән кысмадык, нәрсә кирәк шуны алып бирдек! Үзенең бездә яшисе килми, атасын сөйми! Хайван түгел, адәм баласы бит ул, ябып асрап булмый. Бәләкәйдән рәтле тәрбия алмаган, ипле генә итеп, ата кул астында яши белми!

– Нинди генә булса да, ата үз баласын тәрбияләргә тиеш, – диде каты итеп Әхсән. – Бала өчен ата-ана җаваплы!

– Анасы карасын әнә! Шундый итеп үстергән икән, кыенын да үзе күрсен!

Күренеп тора, Бәһиҗә түтәй артыгын кызмаска, тыелырга тырыша иде, ләкин Әхсәннең кайнарлануы аны ирексездән кыздыра башлады.

– Тарсына да бугай инде, – диде ул. – Чыннан да, иркенлек юк бит монда, авылдагы ише түгел. Кая куясың аны монда? Кая аңа без комачауламаслык итеп, рәхәтләнеп яшәр урын?

Хатын, чыннан да Бикташка урын эзләгәндәй, як-ягына каранып, кыйммәтле җиһаз тулы бүлмәне күздән кичерде.

– Урыны шушында аның, шушы квартираның уртасында, – диде Әхсән. – Ордерга кертелгән бит ул? Шулаймы? Бер бүлмә тулысы белән аныкы дигән сүз.

Нурзаһит, дустына күзләрен кысып, кашларын уйнатып, иреннәрен мимылдатып карады, кызма, артыгын бәйләнмә, эшне генә бозасың, янәсе. Тик кая ул, рәссам аның ишарәләрен күрмәде.

Ул арада Бәһиҗә түтәй Әхсәнгә карашын үзгәртеп өлгергән иде инде. Күренеп тора, сакалы гына бар бу егетнең, дәрәҗәсе әллә кем түгелдер, начальник кеше болай итеп вакланып, ызгышып утырмас иде.

– Син кем әле ул хәтле кеше өенә кереп күрсәтмә биреп йөрергә? – диде ул, зәһәрләнеп. – Алай бик яхшылык эшлисегез килә икән, укырга урнаштырыгыз әнә. Раз безне тыңламый икән, аны көчләп кайтарудан ни мәгънә? Барыбер чыгып качар!!!

Бәһиҗә түтәй кызып китеп, Әхсәннең каршысына ук килеп басты, рәссамнан Сәетҗан абыйны бөтенләй каплады. Ә Әхсәннең Сәетҗан абыйдан ни булса ишетәсе, аның Бикташныкына охшаган

күк күзләренә карыйсы килә иде. Ник дәшми ул? Ник хатыны артына яшеренә? Улының язмышы турында сүз бара лабаса!

Әхсән торып басты, каршысында чәр-чәр кычкырынып торган хатынны читкәрәк этәргә теләгәндәй, кулын сузды. Бәһиҗә түтәй шуны гына көткән икән, чәрелдәп кычкырып җибәрде:

– Син нәрсә миңа кул сузасың, ә?

Нурзаһит дустын җиңеннән тотып артка тартты. Әхсән, Бәһиҗә түтәйнең иңбашы аша үрелеп, бер генә мизгелгә Сәетҗан абыйның йөзен, күз карашын күреп алды. Ул йөздә, ул күзләрдә курку, шомлану чагыла, олыгаеп килгән, тормышында буталып беткән кешенең болганчык җаны ярылып ята иде. Бик кызганыч тоелды ул бу минутта.

Әхсән, кесәсеннән катыргы кисәге алып, хатынның җилкәсе аша бүлмәгә ыргытты:

– Улыңны күрәсең килсә, шушы адрес белән эзлә! – диде ул кычкырып һәм чыгу ягына борылды.

Бәһиҗә түтәй, алар артыннан ишек төбенә басып:

– Училищега урнаштырып, тулай торакка кертергә кирәк аны! – диде.

Әхсән борылып тагын нидер әйтмәкче иде, Нурзаһит авырттырып аның аягына басты.

Әхсән лифтка ничек утырганын да, урамга ничек барып чыкканын да тоймады.

– Судка бирергә кирәк аларны! – дип ярсыды ул. – Баласын алдаган өчен бер бүлмәләрен тартып алырга кирәк!

– Ташла, – диде Нурзаһит. – Суд залында әтисе белән кара-каршы басып тору Бикташка бик күңелле булыр дисеңме әллә? Файдалы булыр дисеңме? Конкрет эш кирәк монда. Флоттагыча. Үзебезнең училищега урнаштырып карарга булыр. Әгәр теләсә.

– Шул хатынның кушканын үтәмәкче инде син дә, ә? – диде Әхсән, ачы көлемсерәп.

– Андыйлар дөньяның җаен белә...

– Шундый җинаять җәзасыз калсынмы?

– Алар үз җәзаларын минут саен алып яши, – диде Нурзаһит. – Бик бәхетледер дип беләсеңме әллә син аларны?

* * *

Егетләр артыннан ишекне япкач, Бәһиҗә түтәй иренә:

– Син дә утырасың шунда, – дип кычкыра башлаган иде, Сәетҗан абыйның нур качкан чыраен күреп, тавышын йомшартты. – Каты тормый да булмый монда, – диде уйлангандай. – Монда кайтарсак, безгә дә тынгы бирмәс, үзенә дә рәхәт булмас. Ерактагы кояш җылы була...

Сәетҗан абый аны тыңлап бетермәде, торды да, эшләпәсен киеп, плащ төймәләрен каптырды.

– Нишлисең? Кая барасың?

– Бир әле бер яртылык.

Бәһиҗә түтәй үз сүзен алга куярга ярата, ләкин кайбер очракларда иренә аяк терәп каршы торуның хәерлегә булмавын яхшы белә иде. Пар казанының да капкачын вакыт-вакыт ачып ябарга кирәк, югыйсә шартлавы бар. Хатын эчке бүлмәдән дүрт тәңкәне чыгарып бирде, ире артыннан:

– Әллә кайларда эчеп йөрмә, өйгә алып кайт! – дип кычкырып калды.

Бәһиҗә түтәй борылырга да өлгермәде, тагын ишек кыңгыравы чыңлады. Тәгаен Сәетҗан абый түгел иде бу – ул төймәсенә кат-кат ике-өч тапкыр төртеп кенә ала. Тагын тегеләр әйләнеп килде микәнни? Хәзер Бәһиҗә түтәй башкачарак сөйләшер алар белән!

Ул каты-каты басып барды да ишекне каерып ачып җибәрде. Ләкин аның каршында егетләр урынына ябык, каушаган чырайлы, үсмер кыз шикелле җыйнак гәүдәле, авылча киенгән бер хатын басып тора иде. Бәһиҗә түтәйне күргәч, аның ак йөзе алланып чыкты.

Алар аңарчы беркайчан да күрешмәгән булсалар да, бер-берсен шундук таныдылар.

Салиха апа нишләптер болай буласын белмәгән, ишекне Сәетҗан ачар дип күз алдына китергән иде. Каршысында кыйгач кара кашлы, түгәрәк битле, йөкле хатынны күргәч, ул тәмам югалып калды. Көндәше каршына шушы рәвешле гаҗизләнеп килеп басу гарьлеге бер генә минутка улы хәсрәтен күмеп китте. Йа Алла, язмыш аны мондый хурлыкка да дучар итте. Менә бит ул нинди, аның ирен, баласын тартып алган кеше, аллы-гөлле халатын киеп, елтыр күзләре белән һич тарсынмыйча туп-туры карап, киерелеп басып тора. Бәхетледер, күрәсең, рәхәт яшидер. Бу хәтле шома чырайлы булмас иде. Салиха апа үзенең чәчәкле шәле белән гади кара пальтосыннан, резин итекләреннән, таушалган сумкасыннан, талчыккан кыяфәтеннән оялып калды. Ул тел тибрәтеп нидер сорамакчы булды, тавышы чыкмады. Каядыр ишек артына, эчкә карарга тырышты, Бикташы күренер сыман тоелды.

Бәһиҗә түтәй аның авыз ачканын көтеп тормады:

– Бикташ бездә тормый бит хәзер, – диде.

Аның сүзләренең мәгънәсе Салиха апаның аңына бераздан гына барып иреште.

– Кая соң ул? – диде ул калтыранган тавыш белән.

Бәһиҗә артына борылып карады, җайсыз иелеп, идән уртасында аунап яткан катыргы кисәген алып сузды.

– Менә адресы шушы, диделәр.

– Кем әйтте?

– Мин каян белим? – диде Бәһиҗә түтәй, карашын читкә алып.

– Сәетҗан беләдер бит?

– Беләдер дә... Өйдә юк шул әле ул...

– Ә кайда?

– Командировкада. Берәр айсыз да кайтмас... Еракка китте. Адрес кулыңда бит, шунда бар! Сау бул! – дип, Бәһиҗә түтәй көтелмәгән кунакның борын төбендә ишекне ябып та куйды.

Салиха апа, тагын шалтыратмакчы булып, кыңгырау төймәсенә үрелде, ләкин ярты юлда тукталып калды. Тәрәзәгә таба борылып, катыргы кисәгенә текәлде. «Әхсән Гайнуллин, рәссам» дип язылган иде анда һәм адрес күрсәтелгән иде.

* * *

Егетләр юл буе Бикташка ни әйтергә дип план корып кайттылар. Малай этисенең аларны ничек каршы алганын, ни әйткәнен, үзен ничек тотканын энәсеннән җебенәчә белергә теләр, әлбәттә.

– Артыгын сөйләргә ярамый, – диде Нурзаһит. – Конкрет мәсьәлә бу. Ни генә булмасын, эти эти ул, аны алыштырып булмый.

– Андый аталарны тотып атарга кирәк, – диде Әхсән. Әмма дусты белән килешми булдыра алмады. Әйе, малайга күргән-ишеткәннәрен чәчми-түкми сөйләп торуның кирәге юк, аның күңелен төшерүдән ни файда? Сине училищега урнаштыру турында килештек, этиең риза, дияргә дә бетте-китте.

Нурзаһит иртәгесен иртүк үзләренең директорлары белән сөйләшергә булды. Бикташка унбиш яшь октябрьдә генә тула икән, өстәвенә белеме дә аз, училищега сигез класс белән генә алалар. Алай да Нурзаһит директорны ризалатырга булды.

Ул институтка кичке лекцияләргә ашыга иде, шунлыктан Бикташ янына Әхсән ялгызы гына кайтып керергә һәм, аның саф күзләренә туры карап, ялганлауның бөтен авырлыгын үз өстенә алырга тиеш булды.

Әйтергә кирәк, ул ишекне курка-курка гына ачып керде. Беркайда да ут югын күреп, аптырап китте. Залда, йокы бүлмәсендә, кухняда бөтен лампаларны кабызды, ваннаның ишеген ачып карады – малай беркайда да юк иде. Әхсән моңа шулхәтле гаҗәпләнде, идәндә таралып яткан тузан суырткычка, өстәлдәге алмаларның, суыткычтагы колбасаның юкка чыгуына бераздан гына игътибар итте. Тузан суырткычны җыеп куяр алдыннан эшләтеп карамакчы булды, ватылганын ачыклагач:

– Аңламассың бу малайны, – дип, башын чайкады. Алай да Бикташ кайтып керсә, аны ачык йөз белән каршы алырга, тузан суырткычны да, башкасын да исенә төшермәскә дип, күңеленә киртләп куйды.

Ләкин Бикташ ул көнне дә, икенчесендә дә күренмәде. Аның урынына ишек төбенә ят бер апа килеп басты.

Кыңгырау зыңгылдагач, ишекне ачкан Әхсәнгә: «Исәнмесез!» – генә диде дә, чакырганны да көтеп тормыйча, бусага аша атлады. Үзенең кемлеген аңлатып, йомышын сөйләп торырлык сабырлыгы калмаган иде инде. Әхсән дә аны тоткарламады, чигенеп, зал ягына узарга юл бирде.

Һәм, ачык ишек янына килүгә, Салиха апа улын күрде. Ул стенага сөяп куелган зур рәсемнән, сагышлы уйларын әнисеннән яшерергә теләгәндәй, каядыр читкә, моңаеп һәм үҗәтләнеп карап тора иде. Бу шул үзе – Салиха апаның бәгырьләрен телгәләгән газиз баласы бит. Шул ук вакытта ул анага ничектер чит булып, бөтенләй күренмәгәнчә, яңача булып күренде. Үскән, тәмам егет булып килә икән инде аның Бикташы. Күңелендә әнисенә билгесез мең уй, мең кичереш кайный икән. Өстенә әллә нинди иске-москы киемнәр кигән, җитмәсә. Әтисе шулай киендерде микәнни?

– Кая соң әле үзе? – дип сорады Салиха апа, Әхсәнгә борылып.

Рәссам сакалын бөтергәләп, күзләрен кыса төшеп, аңа текәлеп карап тора, аның йөзендәге үзгәрешләрне күзәтә иде. Беренче карашка ана белән бала арасында бернинди охшашлык юк икән. Коңгырт чәчләре ак маңгае өстендә бөтеркәләнеп торган түгәрәк йөзле бу апа белән озынча йөзле, йомшак сары чәчле малай арасында бернинди уртаклык та юк кебек. Ләкин менә картина янына басып, сораулы карашын рәссамга төбәгәч, бу хатын белән малай арасында гаҗәп бер охшашлык күренде. Шундый ук эчкерсезлек, сафлык, бар уй-кичерешләрнең йөздә чагылышы. Менә каян килә икән бу малайга күңел пакьлеге, садәлек.

Җирән сакаллы бу кешенең кыяфәте дә, бер сәбәпсезгә елмаеп торуы да Салиха апага сәер тоелды. Ник авызын ера ул? Әгәр ана баласының кайдалыгын сорый икән, аның ни көлкесе бар? Үз акылындамы соң бу кеше, Ходаем? Кая куйган ул Бикташны?

– Кая ул? – дип кабатлады Салиха апа, тәмам каушап.

– Монда ул, монда тора, – диде. – Чыгып кына киткән иде... Кайтыр... Сез өсләрегезне салыгыз. Элгеч менә монда, – дип, алгы бүлмәгә күрсәтте ул. – Монда кул юарга була. Ә мин чәй куям... – диде дә үзе кухняга кереп китте.

Мәсьәләнең шактый катлаулы, четерекле икәнлеге аның аңына шунда гына барып җитте. Бу апа улын күрмичә китмәячәк, ә кайчан монда килер ул малай? Гомумән, килер микән әле? Алай да ананы куркытырга ярамый иде.

Чәй янында ул Бикташ белән ничек очрашканын (урамда трамвайда күрдем дә бик ошады, минем картинама туры килә торган булып күренде, шуңа үзем әйдәкләп алып кайттым, диде), аның бик сөйкемле, яхшы күңелле малай икәнен сөйләде. Салиха апа да ачылып китеп, улын озак эзләгәнен, көч-хәл белән Сәетҗанның квартирасын тапканын, анда шушы адресны биргәннәрен әйтеп, визитканы күрсәтте.

Инде чәй дә эчелде, сөйләшер сүз дә бетте, Әхсән авыл хәлләрен сораштырмакчы иде, Салиха апа, улының аяк тавышларын ишетергә тырышып, ишек ягына колак салып утыра, аның сорауларын кат-кат кабатлагач кына аңлар дәрәҗәгә җитә иде. Апакайны ничек тә тынычландырырга кирәк. Ниндидер хәйлә табарга... аның башы бик кызу эшләргә кереште.

– Училищега керергә теләге бар аның, – диде ул. – Минем бер бик якын дустым һөнәр училищесында укыта... Шул ярдәм итәм дип вәгъдә бирде.

– И-и, әйбәт булырые, – диде Салиха апа, җиңеләеп. – Улымның кулы бик оста, агач эшенә бигрәк тә...

– Ул училищеда мебель ясаучылар әзерли торган бүлек бар, – дип, аның сүзен эләктереп алды Әхсән. – Тулай торакта урын алу турында сөйләшергә дип киткәннәр иде. Мөгаен, хәл иткәннәрдер, бәлки, шунда кунып калырга булгандыр.

Салиха апа аның күзләренә тутырып карады. Ышанырга теләде һәм ышанды.

Аның узган төнне Крестьян йортында кунып чыкканын белгәч, Әхсән дә җиңел сулап куйды.

– Хәзер соң инде, иртәгә мин Бикташны барып алырмын, төштән соң сезне очраштырырмын, – дип, сүз биреп, апакайны тышкы ишеккә хәтле озата чыкты.

Урамга чыкканда, Салиха апага төн караңгысы көн яктысына алышынган кебек тоелды.

* * *

Ул кайтканда, Әхсән җиденче төшен күрә иде инде. Кыңгырау ничә тапкыр зыңгылдагандыр, рәссам аңына килгәч тә кузгала алмый ятты. Күзгә җылы ком булып йокы тулган, керфекләр күтәрә алмаслык авыр иде.

– Кем бар анда?

– Ми-ин... – диде Бикташ.

Ишекне ачуга, кулын сузган малайны күреп, Әхсән:

– Нишлисең? Ни ул? – дип сорады.

Малайның учында пөхтә итеп бөкләнгән бишлекләр ята иде. Әхсән эш хакы итеп биргән өч бишлек.

– Пылесосны төзәтергә бу... – диде малай.

– Кер әле. Нәрсә син минем белән бусага аркылы сату-алу итәсең.

Һәм, Бикташ кергәч, йозакны ике тапкыр борып бикләп куйды.

– Син, малай, ташла бу яман гадәтеңне! – диде. – Әйтми-нитми чыгып качалармыни? Син монда яшисең, мин синең кайда йөргәнеңне белеп торырга тиеш. Югыйсә киләләр дә кычкыртып миннән сорыйлар, ә мин, аңгыра сарык шикелле, карап тик торам.

– Әти килдемени? – Бикташның йөзендә сөенү, үкенү, өмет, шик – мең төрле хис чагылды.

– Әниең килде, – диде Әхсән.

– Әни?!

– Әйе, әниең.

– Каян белгән ул?

– Аналар таба инде, тапмый хәлләре юк. Балалары качып йөргәч, тапканчы эзләми нишләсеннәр. Ә син хат та язмыйсың икән...

– Кая соң ул? Киттемени инде?

– Курыкма, сине күрми китмәс. Ә син, бар, юын, оекбашларыңны да юып куй, үзеңне тәртипкә китер. Иртән торуга, алма кебек томрап торырлык бул. Юкса әниең күзенә күренер чутың юк.

– Әхсән абый, – диде Бикташ. Аның тавышы калтыранып куйды. – Мин эшли башлагач, акча алгач, сезгә бөтенесе өчен дә түләрмен.

– Тагын нәрсә өчен? – дип сорады Әхсән коры гына.

– Тузан суырткыч өчен дә, алмалар өчен дә... Бөтен кылган яхшылыгыгыз өчен дә...

– Акчаң җитәр микән соң? – диде Әхсән, көлемсерәп. – Кешеләрнең яхшылыгын нинди бәя белән үлчәрсең икән? Кем өйрәтте сине һәрнәрсәне акча белән үлчәргә? Әгәр беләсең килсә, кешеләр кылган яхшылык өчен түләп бетерерлек акча бөтен дөньяда юк. Юк! Син аны бары тик үзең яхшы булып кына кайтара аласың. Күңелеңә бик нык итеп киртләп куй син моны!

* * *

Кар очкыннар чәчеп, җем-җем итеп яткан җилсез салкын көндә Бикташ Якты Тәрәзә поселогына каникулга кайтып төште. Ялгызы гына түгел иде ул, тыкрык башында ябык машинадан аннан алда Уйнак сикереп чыкты.

Болдыр кырыенда чаңгыларының карын кагып азапланган Ләң-ләң Васька, эт иярткән Бикташны күргәч, күзләрен челт-челт йомып, ни әйтергә белми аптырап торды, чөнки күрше малаен тиз генә таный алмады.

Бикташның үзенә дә поселок үзгәргән – йортлар тәбәнәкләнгән, тыкрык тарайган, Васька кечерәйгән төсле күренде. Ләкин йортлар да, тыкрык та бер үзгәрешсез калганнар, Ләң-ләң Васька исә ике сантиметрга үсеп тә куйган иде. Бары тик Бикташ үзе үсеп кайтканга, каланың киң урамнарына, биек йортларына күнеккәнгә генә шулай бәләкәй булып күренә иде алар.

...Кичен Бикташны күрергә, Салиха апаның сөенечен уртаклашырга Шәмсия апа белән Анна түтәй керделәр.

– Йа Ходა, кала урамында очрап кыйнап китсә, тәки танымасыем! – диде Анна түтәй. – Малай булып киткәние, егет булып кайткан.

– Әйттем ич мин, ата янында булу ир балага зыян итми ул, – диде Шәмсия апа.

Хикмәт Бикташның буй үстереп, җилкәләрен киңәйтеп, тавышын калынайтып кайтуында түгел, йөз сызыкларының кырыслануында, карашының җитдиләнүендә, әнисенә һәм сеңлесенә булган кайгыртучанлыгында – кыскасы, бер сүз белән генә әйтеп биреп булмый торган рухи бер борылышта иде.

Кайберәүләрдә бу үзгәреш еллар буе дәвам итә, кайчак гомер буе бара һәм тәгәлләнми кала. Ир булып җитлегә алмыйча, гомеренең чигенә җиткән сакаллы сабыйлар азмыни дөньяда? Ә кайберәүләрдән язмыш кинәт җитлегүне таләп итә – көчле җил-давыллар төрле яктан китереп бәргәндә, буыннарны ныгытып өлгермәсәң, сынасың, сыгыласың гына.

Ә Бикташ сынмаган иде, сыгылмаган иде. Бу исә егет булып җитлегүнең беренче билгесе иде.

*1976*

## Янар таулар яктысында

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
Яшьнәү-күкрәүләргә тиң гомер.
Бу дөньяда без яшибез икән
Юкка түгел, юкка түгелдер!
*Н.Нәҗми*

Зуфирә тәрәзә янына килде дә аһ итте: анда-санда куаклар белән чуарланган киң иңкүлекнең нәкъ уртасыннан төрле төсләргә манчылган томан күтәрелә иде. Томан диярлек тә түгел, үтә күренмәле киң пәрдәләр кебек – һәр төс берсе икенчесеннән бик кискен аерылып тора. Бу пәрдәләр яңгырдан соң юылып-чистарынып калган, кичке ямансулык белән өртелгән мохитне әкияттәге тылсымлы дөньяга охшатып куйган иде. Әнә кызыл пәрдә, сарысы, яшеле, зәңгәре, шәмәхәсе. Бәй, бу салават күпере ич! Дөресрәге, салават күперенең туып килгән чагы! Менә нинди булып туа икән ул! Күпер диярлек тә түгел, итәге куак башларына орыныр-орынмас эленгән, аның аша үтәли ерактагы елганың текә ярлары да, урман каплаган калкулыклар һәм алар арасындагы ак биналар да, ачык төсләргә буялып, аермачык күренә.

Зуфирә гомердә бер була торган бу күренештән күзләрен ала алмады. Салават күпере сизеп-тоеп булмый торган, ләкин үрчемле бер хәрәкәт белән үзгәрә барды: торган саен аның итәге ераккарак шуышты, очы, болытлардан арынып килгән күк гөмбәзе уңаена җәйланып, бөгелә барды. Күтәрелгән, ерагайган саен аның төсләре дә тыгызланды, ачыкланды, пәрдәләр тарайды һәм, офык сызыгына барып ирешкәндә, ачык тасмалар рәвешен алды.

Ниһаять, менә ул Зуфирәгә балачактан таныш салават күперенә әверелде – дугаланып, күк гөмбәзе аркылы төсле күпер булып ятты. Зуфирәнең баш очыннан офык артына, кояш чыгышына юл салды ул.

Кайларга барып тоташты икән аның офык артындагы очы? Урал тауларын кичеп, Северне иңләп үтеп океанга барып җитмәдеме икән? Дулкыннарда тибрәлгән ак пароходтагы үткен зәңгәр күзле ир-егетнең баш очыннан Зуфирәгә таба юл салды микән әллә ул?

Юкка гына кабынырга тиеш түгел бит инде мондый гүзәллек, берәр хикмәте булырга тиеш аның, берәр мәгънәсе! Бер-берсен эзләп зарыккан күңелләрне тоташтырырга тиеш ул...

Зуфирә өстәле янына килеп утырды, чәчелеп яткан каләмнәр, буяу тартмалары, кәгазьләр арасыннан пумалачыгын алды, аны банкадагы суга манды да, ашыгып, катыргы кисәгендә буяулар изәргә кереште. Хәтердә тоныклана башлаганчы, кәгазьгә төшереп каласы иде бу күренешне – салават күперенең туып килгәнен.

Ул яшел иңкүлекне, ерак елга ярын, урманлы калкулыкларны сызгалады, алар өстеннән үтә күренмәле төсле пәрдәләр сузды... Бөтенесе әле генә Зуфирә күзәтеп торганча иде кебек, ләкин шул ук вакытта бөтенләй башкача иде. Чөнки кәгазьдәге салават күпере фәкать төсле томан гына, табигатьнең гадәттән тыш матур бер күренеше генә булып кала бирде, әмма бер-берсенә тартылган күңелләрне тоташтырган хыялый юл була алмады. Кәгазьгә сызылган төсле тасмалар беркая да ашкындырмый, чакырмый, күңелне тынгысызлап сызландырмый иде.

Зуфирә эреле-ваклы рамнар, кәгазь төргәкләре тулы шкаф, зур өстәл, карават арасындагы тар мәйданда әрле-бирле йөренде. Аннары стена кырыена сөялеп торган ике рамны үзенә таба борды.

Рамның берсенә акварель белән түгәрәк йөзле хатын портреты ясалган иде. Аның сары чәче кашлары өстеннән киселгән, ә ике яктан иңнәренә таралып төшкән, шунлыктан йөзе рамга алынгандай тоела; соры күзләре нәрсәдер эзләгәндәй борчылып, сынап карый. Зуфирәнең автопортреты бу. Ул, өстәлдән кечкенә көзге алып, бер үзенә, бер рәсемгә карады. Рәсемдә ул олы сымаграк күренә, яше кырыкка җиткәне бик нык сизелә иде. Үзенә карап, аңа берәү дә кырык яшь бирмәс, чөнки чәчен таратып йөргәнгә, башын югары тотканга һәм бигрәк тә буй-сыны кызларча ыспай булганга, күпкә яшь күренә ул. Акыл белән түгел, йөрәк белән яши торган кешеләр тиз картаймый.

Ләкин хикмәт картлык-яшьлектә түгел, хикмәт Зуфирәнең хәтта үз сурәтен дә күңеле теләгәнчә яза алмавында иде. Тыштан караганда, охшаган ул үзенә, әмма шул ук вакытта бөтенләй чит тә, чөнки сурәттәге хатынның күз карашында, йөзендә күңел тирәнлеге сизелми, Зуфирәнең кайнар йөрәге чагылмый иде.

Акварель белән ясалган икенче портреттан үткен зәңгәр күзле, кыйгач кашлы, нык иякле бер ир кеше карап тора иде. «Нилектән болай көчсез мин? – диде Зуфирә, пышылдап, ир кеше сурәтенә. – Беләм бит югыйсә ничек кирәген, сизәм-тоям. Күңелем тулып ташыган. Ник шуны кулларым, каләмем аша, буяулар белән башкалар күңеленә җиткерә алмыйм икән?»

Алгы якта ишек ачылып ябылганы ишетелде.

– Әни! – диде яшь тавыш. – Миңа хат юкмы?

– Юк иде шул, кызым, – дип җавап бирде Зуфирә. Үзе авыр көрсенеп куйды: ул да кызы кебек үк хат көтә, әмма бүген почта тартмасыннан газеталардан гайре нәрсә чыкмады.

Халидә шалт-шолт итеп алгы бүлмәдә туфлиләрен салып ыргытты да, кайнар сулышы, дәрте белән бүлмәне тутырып, әнисе янына килеп керде.

– Кем бу, әни? Космонавтмы әллә?

– Нишләп космонавт дип уйлыйсың?

– Көчле, сәламәт, омтылышлы ир-егет бит. Ничектер безнең буй җитмәслек сыман үзе. Чит. Ерак... Кырыс...

– Ерак ерагын, Тын океанда ук... Әмма кырыс түгел, чит тә түгел...

Зуфирә рамны стенага борып куйды. Сурәттәге кешене буй җитмәслек ерак иткән нәрсә әлеге дә баягы шул каләмнең көчсезлеге иде. Ул кеше Зуфирәнең дөньяда иң якыны, иң газизе бит югыйсә.

– Әйдә чәй эчәбез, – дип, Зуфирә сүзне бүтән нәрсәгә борырга ашыкты.

Кухняда кара-каршы утырганда, Зуфирә сиздерми генә кызын күзәтте. Үсте инде Халидә, тәмам аякка басты, училищеда укып һөнәр алды, хәзер кием кисүче булып эшли. Ә әнисе аны үзе кебек, юк, үзеннән дә оста, талантлы рәссам итү турында хыялланган иде. Ничә еллар художество мәктәбендә укытты. Әмма кыз, пейзажлар, жанровый рәсемнәр, натюрмортлар ясыйсы урында, гел генә хикмәтле итеп киенгән кыз сурәтләре ясый иде. Бишенче класста ук «кием конструкторы булам» дип сөйли башлаган иде, шулай итте дә.

Кызык, Зуфирә шикелле, анда-монда бәргәләнеп, кырыкка җитеп тә үз хыялына ирешә алмаган ана белән җил кайсы якка иссә, шунда авыша торган аумакай атадан ничек туган диген шундый бала! Төсе-бите нәкъ этисенеке: эре дулкын ясап торган йомшак коңгырт чәчләре, яшел күзләре,

озынча йөзе, күбәләк канаты кебек матур уелган иреннәре, яңак уртасындагы чокырлары – бар да әтисенеке. Буйга да әтисе кебек озын булып үсте – Зуфирәгә өстән карый хәзер.

Тик кызның йөзендә ныклык, үҗәтлек ярылып ята, яшел күзләрендә үз бәһасен белү, акыл чагыла – бу аның әтисенә охшашлыгын киметә иде. Холкы белән әтисенең капма-каршысы ул. Алдан үзенә юл сызып куйган да, тайпылмыйча, тайчанмыйча, шул юлдан бара. Андыйлар ышанычлы, нык була, алар белән яшәү җиңелрәк.

Мәхәббәт мәсьәләсендә дә шундый нык һәм тугры булыр, ахры, аның юлы. Художество мәктәбендә үк Айрат исемле бер малай белән дуслашып йөри башлаган иде, моңарчы башка берәүгә күз дә салып караганы юк. Зуфирәгә ошамый малай, йомыкый, хәтта шактый җебегән булып тоела. Ул Халидәгә йомшак кына итеп моны әйтергә тырышып карады. «Мин аны синнән яхшырак беләм, әни, – диде Халидә, ык-мыкка юл куймыйча. – Әйбәт күңелле малай ул. Якыннанрак танышкач, синең фикерең үзгәрәчәк әле». Шуның белән өзде дә куйды, әнисен телсез калдыргандай итте.

Хәзер менә егет армиядә. Халидә аны көтә һәм, һичшиксез, башка бүтәнгә борылып та карамыйча, ак йөз белән сөйгәнен көтеп алачак.

Халидә, тәрәзә аша каядыр еракка карап, үз уйларына чумып утыра иде. Менә ул нәрсәнедер исенә төшереп елмайды, бит очлары батып, йөзе гаҗәп мөлаемланып китте. Мондый чакта ул әнисенә бигрәк газиз була, аны кечкенә чагындагы сыман күкрәккә кысасы килә иде.

– Бүген кара бәрхет күлмәк тектерергә китерделәр, – диде Халидә. – Бәрхетне тегү шулхәтле азаплы, әни, син күз алдына да китерә алмыйсың!

Чәй эчкәч, ул кинога җыена башлады.

– Шундый шәп картина, ди. Безнең кызлар мактап туймый. «Мәхәббәт турында романс». Әйдә син дә!

– Юк, кызым, ашыгыч эшем бар.

– Тагын яңа китап өчен рәсем ясыйсыңмы?

Зуфирә – китаплар, журналлар өчен рәсемнәр ясаучы рәссам.

– Юк, үз эшем, – диде ул. – Беләсеңме, минем күңел түремдә бик зур хәзинәләр тутырылган бер сандык ята. Шуның йозагы бикле, ә ачкычы югалган. Шуңа ачкыч ясыйсым килә, сандыкны ачып, хәзинәсен кешеләргә өләшәсем килә.

Халидә рәхәтләнеп көлде, сеңлесен кочаклагандай итеп, иелеп, әнисен иңнәреннән кочып алды.

– Ну, ясa алайса ачкыч! Байыйсылары бар икән әле халыкның! – диде дә бөтерелеп чыгып китте.

*** * ***

Әмма Зуфирәгә ялгыз уйланырга ирек бирмәделәр – ишек кыңгыравы чыңлады. Ишекне ачкач, ул иң элек берәүнең ак күлмәген күрде, аннары гына, башын артка ташлап югарырак карагач кына, каршында ире, дөресрәге, моннан ике ел элек аерылган ире Эльвир торганлыгын аңлады. Эльвирның кулында зур гына кара портфель, аркасында таныш чехол белән аккордеон асылган иде.

– Ярый әле өйдә икәнсең, – дип җиңел сулады ул. – Үзең генәме әллә?

– Халидә чыгып киткән иде әле.

– Сиңа бер йомыш бар иде, – диде Эльвир, каядыр читкә карап. – Җүләр йомыш... Җүләрлек белән килдем мин сиңа...

Зуфирә, каушавын яшереп, шаярып җавап бирергә тырышты:

– Җүләрлек буенча зур белгеч бит инде мин... Шуны уйлап килгәнсеңдер.

Аның бу сүзләреннән Эльвир иркенәеп киткәндәй булды, ул, күрәсең, ишек төбеннән борып, куып җибәрмәгәйләре дип куркыбрак килгән булгандыр да каты сүз ишетмәгәч, тынычлана төште. Инде сүзне бу рәвешле җиңелчә шаяруга коргач, бусага аркылы гына сөйләшеп булмый иде. Зуфирә, артка чигенебрәк, аңа керергә юл бирде.

Эльвир ишек төбендә үк аркасыннан аккордеон чехолын төшерде, портфелен куйды. Икесе дә ни әйтергә белми тынып калдылар. Эльвир ачык ишек аша залдагы җиһазны күздән кичерде. Ул бу йортта бары бер генә тапкыр, анда да өйнең асты өскә килгән чагында – әнисе мәрхүмәне күмгәндә генә булган иде, шуңа күрә хәзер һәммә нәрсә аңа өр-яңа булып тоелды.

Ә Зуфирә ирен күзәтте. Инде күптән аңа күңеле сүрелгән, йөрәк түрендәге иң кадерле урынны башка берәү – үткен зәңгәр күзле, кыйгач кашлы кеше алган дип уйлый иде ул. Ләкин нигә соң, аны күрүгә, йөрәк кабыргаларга бәреп кага башлады?

Табигать Эльвирны ясаганда вакытын да, тырышлыгын да кызганмаган, ахрысы. Кыз чагында ук Зуфирә аның теләсә нинди төркемдә башкаларның баш өстендә калкып торган йөзенә сокланып туя алмый иде. Аның бөгелеп торган, очы алтынлангандай ялтырап килгән куе керфекләренә, шулар арасыннан нур сирпегән яшел күзләренә караган саен карыйсы килә иде. Аңлатып булмый торган ямансулык, ярдәм сорау, оялчанлык бар иде аның карашында.

Гашыйк булып йөргән чакта да, өйләнешкәч тә, Зуфирә күп тапкырлар аның портретын язды, ләкин бер генә тапкыр да ул карашның серен бирә алмады. Ә ансыз Эльвир Эльвир түгел, ансыз аның сөйдергеч һәм көйдергеч мөлаемлыгы югала, бетә иде.

Була бит шундыйлар ир-ат халкы арасында, сабыйларча саф ямансу караш белән хатын-кызның йөрәгенә ут салалар. Син аларны кызганасың, үзеңнең бар мәшәкатеңне ташлап, алар көен көйлисе килә. Ә инде кызгану, үз көеңне онытып, аның мәшәкате артыннан йөрү теләге кузгалды исә, гашыйк булдың дигән сүз.

Зуфирә хәзер яхшы аңлый моның хикмәтен, әмма барыбер Эльвирның яшькелт күзләреннән сирпелгән тылсымнан котыла алмый икән әле.

– Тормышны әйбәт көйләгәнсең син, – диде Эльвир, кыйммәтле телевизорны, әйбәт җиһазны, тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган яраннарны, тамчы гөлләрне күздән кичереп.

– Комачаулаучы юк бит хәзер, – диде Зуфирә, төрттереп. Ул инде аны бер каршылыксыз өенә кертkәненә үкенә башлаган иде. – Йә, ни йомышың бар?

Эльвир очлары бөгелеп килгән куе керфекләре арасыннан бер карады да:

– Син мине хәзер теләсә нишләтә аласың, Зуфирә, – диде. – Теләсәң – иректә калдырасың, теләсәң – төрмәгә илтеп тыгасың...

– Төрмәгә... дисеңме? Эш шуңа ук барып җиттемени инде?

– Эш... Минем гаеп белән килеп чыккан эш түгел. Әмма кызуында әләктерсәләр, илтеп тыгулары да ихтимал. Суынганнарын көтәргә кирәк.

– Кемнең суынганын? Утырып сөйләшик әле.

Эльвир, җиңеләеп, иркенәеп, диванга таба узды.

Зуфирә өстәл янына урындыкка утырды. Бер-ике авыз сүздән шул аңлашылды: Эльвирның яшь хатыны Румиянең суынганын көтәргә кирәк икән. Ә көтәргә, сабыр итәргә тиешлесе – беренче хатын Зуфирә икән.

– Ачыграк итеп сөйлә әле, зинһар, – диде Зуфирә.

Эльвир ресторяннан кайткач, Румия белән икесе арасында дәгъва купкан, ул хатынын этеп җибәргән дә тегесе йөзе белән өстәл кырыена барып төшкән. Кыскасы, хатын хәзер больницада ята, туганнары Эльвирны таш капчыкка илтеп тыгарга ажгырып йөриләр, ди.

– Синең хатын-кызга кул күтәрә торган гадәтең дә бармыни әле? Ничә ел бергә яшәп белмәгән идем.

– Мин уйламаган да идем... Алай ык та орынмадым югыйсә. Әллә юри кыланып, егылмакчы булып ялгыш бәрелде шунда...

Эчкәч, Эльвирның йөзеннән сөйкемле нур качып, күзләре пыялаланып, шәфкатьсезләнеп калганын белә иде Зуфирә. Андый чакта ул аннан читтәрәк булырга тырыша иде. Бәлки, шуңа күрә генә аның йодрыкларыннан котылып калгандыр да, кем белә.

– Эчкән булгансыңдыр инде, үз-үзеңне белештермәгәнсеңдер.

– Ул хәтле авыз тутырып «эчкән» диярлек түгел идем инде, гадәттәгечә, чама белеп кенә. Алла-а, аның чәрелдәвенә адәм түгел, фәрештә чыдамас...

Эльвир, тагын бер тапкыр гаҗәпләнгәндәй, башын чайкап куйды.

– Ә мин сезне бик бәхетледер дигән идем.

– Соң, бәхет шул инде – өч елдан сигез елга хәтле төрмә баландасы чөмерү күз алдында тора. Минем язмыш кына түгел бит монда. Бала бар – Халидә. Әтисе арестант булса, гарьлеген ул ничек кичерер?

Эльвирның җуләр йомышы менә нәрсәдән гыйбарәт икән: хатыны терелеп чыкканчы, чит күзләрдән югалып тормакчы ул. Ә аның өчен иң җайлы урын – Зуфирә квартирасы. Эшеннән ул берничә көнгә сорап киткән. Берәү дә аны биредән эзләмәячәк, килеп сорасалар да, Зуфирәнең аларны кертмәскә тулы хокукы бар. «Әһә, үзегез минем иремне тартып алдыгыз да, хәзер, мине мыскыл итеп, аны моннан эзләгән булып йөрисезме?» – дип куды чыгарды. Аннары инде, Румия больницадан чыккач, аны бәхилләтү, эшне күпертмәскә ризалату кыен булмаячак. Беренче җил-давылны гына хәвеф-хәтәрсез уздырырга иде.

– Җил-давылдан минем артка ышыкланырга инде, алайса, исәбең? – диде Зуфирә, гаҗәпләнеп.

Үзе шунда ук Эльвирның тел белән әйтелмәгән яшерен хәйләсен аңлап алды: качып ятар өчен генә килмәгән ул монда, Румияне көнләштерер өчен килгән! Эче янсын әле, үзәге өзгәләнсен, тизрәк гафу итәр дип уйлый!

– Иң якын кешем монда бит, бала монда, – диде Эльвир, Зуфирәнең күзләренә сабыйларча туры һәм гөнаһсыз карап.

Зуфирә әйтер сүз тапмады: нәрсә бу, оятсызлыкмы? Әллә чыннан да сабыйларча беркатлылыкмы? Мөлдерәпләр карый бит, юньсез, Зуфирәнең куып чыгармасын белеп тора!

Зуфирә кухня ягына чыгып китте, чәй куйды. Куллары һәр эшне күнегелгән хәрәкәт белән үзеннән-үзе башкарды, ә үзе, бөтен дикъкатен биреп, зал ягыннан килгән авазларны тыңлады.

Менә Эльвир алгы бүлмәгә чыкты, аккордеонын алды булса кирәк. Менә аның бармаклары клавишлар буйлап йөгереп уздылар һәм менә ул, бары тик аңа гына хас йомшак моң белән, яшьлектәге көйне өздереп уйнап җибәрде:

Сагынып килдем, күрми китәм,
Чыкмый калма иртәгә...

Зуфирә өчен, махсус аның күңелен тетрәндереп, ихтыярын сындырып, тәкатьсез итеп, үзенә буйсындырыр өчен уйный иде ул моны. Урынына, җаена, кәефенә карап, көйләрне төрлечә уйный белә бит ул. Кичәләрдә, табыннарда – дәртле, җиңел, кискен итеп; Зуфирә өчен генә булганда – яшерен бер мәгънә салып, башкаларга сиздерергә ярамый торган оялчан, нечкә, тирән хисле итеп уйный ул. Андый чакларда әйтерсең лә аның аккордеоныннан көй түгел, ә бер күңелдән икенче күңелгә, беркая түгелми-чәчелми, беркем колагына чалынмый, икәүгә генә аңлаешлы сер агыла...

Шушы серле моңы белән Зуфирәне баштанаяк үзенә әсир иткән иде бит инде ул... Аның көче һаман бетмәгән икән әле, аның йөрәгеннән агылган хиснең Зуфирә күңеленә үтеп керә торган юллары һаман күмелмәгән икән. Бу көй хәтердә матур күренешләр итеп истәлекләр яктыртты.

...Менә алар училище залында икәүләп бииләр. Кайсы училищеда: Зуфирә укыган художество училищесындамы, әллә Эльвир укыган музыка училищесындамы? Хәер, анысы мөһим түгел, Эльвирның аңа төбәлгән нурлы күзләре, күбәләк канатлары кебек матур уелган иреннәренең кайнар пышылдавы мөһим.

– Сез шундый җиңел биисез, очып йөргән кебек кенә. Ничек мин сезне моңарчы күрмәгәнмен... Кайсы яктан сез?

– Бөгелмәдән...

Менә алар паркта. Зуфирә башына сары яфраклардан такыя үреп кигән дә, фонтан суына иелеп, шәүләсенә карый, үзеннән бигрәк, янында басып торган Эльвирны күрә.

– Такыя сиңа шундый килешә, – ди Эльвир...

Менә алар, парлашып, Эльвирның әнисе Сабира карчык каршында басып торалар, булачак каенананың егетнеке төсле яшькелт күзләре кызны чәнчеп-чәнчеп алгандай итә, ә егет сөйгәненә көч биреп елмая: «Курыкма, без икәү бит!» – ди.

Менә алар парлашып загстан чыгып киләләр... чәчәкләр, котлаулар...

Менә алар мотоциклда урманнан кайтып киләләр. Басу юлында туктап, серкә очырган арыш арасында үбешәләр... Эльвирның иреннәннән әчкелтем тәм килә.

«Сагынып килдем... сагынып килдем...» – дип өзгәләнә аккордеон, узганнарның иң матур күренешләрен күңелдә җанландыра.

* * *

– Әтиең килде.

Халидә ишектән кереп, туфлиен салырга дип иелгән иде, башын тагын да түбәнрәк иде.

– Ә ник килгән? – диде, әнисе шикелле үк пышылдап.

Ну бу Халидәне! Һәрнәрсәнең төбенә төшенеп, барысын да баштан ук ачыклап куя торган гадәтен!

– Күрергә... килгәндер.

– Моңарчы безне күрми яшәде бит әле... Озакка килгәнме инде бу юлы?

– Вакытлыча... Ә бәлки, син рөхсәт итсәң, берничә көн торыр да.

– Ә аннары?

– Аннары яши торган җиренә кире китәр.

Халидә, күтәрелеп, әтисенеке төсле яшькелт күзләре белән әнисенә туры карады.

– Нәрсә килеп сарып йөри ул әрле-бирле...

– Бер җайсызлык килеп чыккан... Бераз... читтәрәк торырга кирәк.

– Әһә, җайсызлык килеп чыкканда, без исенә төшкәнбез икән. Син теләсә ни әйт, мин аны кертмәс идем.

– Авызыңнан җил алсын! Кем турында сөйләгәнеңне беләсеңме? Әтиең турында сөйлисең бит син!

– Әтием булгач, хыянәт итмәсен иде! Башка... кеше янына китеп, ул синнән дә бигрәк миңа хыянәт итте, беләсең килсә!

– Ярый-ярый... Монда бәхәсләшмик... Зинһар, хәзергә телеңне тый, тупасланма...

Залдан шылт иткән тавыш та ишетелми, Эльвир ана белән кызның ни сөйләшкәнен ишетергә тырышып утыра иде булса кирәк. Ата белән кыз чит кешеләр кебек күрештеләр. Эльвирның Зуфирәне сихерли торган нурлы карашы кызының нәкъ үзенеке төсле яшькелт күзләренә тәэсир итми иде. Чәй янында Эльвир аны-моны сораштырырга тырышып карады. Халидә, тәрәзәгә караган килеш, «яхшы», «ярыйсы» дип төксе генә җавап биргәләп торгач, сүзнең очы очка ялганмады.

Өстәл янында авыр тынлык урнашты. Чынаякка балкашыкның бәрелүе һәм Эльвирның чәйне шапырдатып чөмерүе дә сискәндереп җибәрә иде.

Зуфирә, иренең карашы һәм аккордеоннан агылган моңы тәэсиреннән арынып, аңа җентекләбрәк, төпченебрәк карады.

Бергә яшәгәндә кешенең картайганы, үзгәргәне артык сизелми, уналты ел бергә узган гомер эчендә Зуфирәгә ире гел үзгәрмәгән шикелле, һаман яшь, чибәр егет рәвешендә булып күренә иде. Ә хәзер менә аның картайганлыгы нык сизелә. Кайчандыр Зуфирәнең башын әйләндергән егет тә димәссең үзен. Зуфирә сөйгән егетнең чәче дулкынланып, киң маңгаен түгәрәкләндереп каплап тора иде, ә бу кешенең чал керә башлаган сирәгәйгән чәче маңгай өстендә ике уем ясап артка чигенгән. Бит очларында ике чокыр бар иде, ә бу кешенең ике яңагында алар урынында тирән ике буразна сузылып яткан.

Ләкин болар гына зыян итмәс иде. Кайбер ирләргә сирәгәйгән чал чәч тә, җыерчыклар да килешеп кенә тора, йөзләренә бәреп чыккан зирәк акыл, ихтыяр көче, кешелеклелек, мөлаемлык аларны күп егетләрдән сөйкемлерәк итә.

Кызганычка каршы, еллар үтү белән кыяфәте үзгәрсә дә, күз карашы, йөзендә чалынган рух рәвеше үзгәрмәгән Эльвирның, аның яшькелт күзләре әле һаман балаларча беркатлылык, сафлык, ышанучанлык белән ярдәм сорап карыйлар. Ә мондый караш аның яшендәге ир-егетне бизи алмый шул инде.

Зуфирә, башын иеп: «Ә соң үзем?» – дип эченнән генә уйлап куйды. Әлбәттә инде, ул үзе дә егерме яшьлек кыз чагындагы төсле түгел. Элекке Зуфирә юк инде, элекке Эльвир да юк, алар икесе дә кайсыдыр ерак елларда калганнар, ә биредә, бу йортта, бу өстәл янында алар урынына бөтенләй башка бүтәннәр очрашкан. Аларга хәзер өр-яңадан бер-берсенә гашыйк булырга, өр-яңадан бер-берсенә күнегергә кирәктер, бәлки. Ләкин теге, үткәннәрдә калган яшь гашыйклар башларыннан кичкән хәлләрне үзләрендә калдырмаганнар, бу ике кешенең күңеленә салып җибәргәннәр. Ул хатирәләр бу икәүнең арасында җимерелмәс киртә булып тора.

Табын янындагы тынлык аларның өчесен дә бер-берсеннән торган саен ныграк читләштерде. Ярый әле дөньяда телевизор дигән нәрсә бар, ул коткарды, өйдәге шомлы тынлыкны таратып ташлады.

Зуфирә залдагы диванга Эльвирга урын җәйде, ә кызын эчке бүлмәгә – «мастерское»ндагы караватка үзе белән бергә яткырды.

Халидә, көрсенгәләп шактый вакыт әйләнгәч, тагын баягы «ник килгән» дә «кайчан китә» кебек сүзләрне озайта башлаган иде, Зуфирә, уйланып:

– Сиңа өлкәннәр турында андый катгый хөкем чыгарырга иртәрәк әле, – дип пышылдады. – Әтиеңнең күңеле беркайчан да начарлыкта булмады. Ул гел тигез, матур яшәүне тели иде. Ләкин алай барып чыкмады, һәркем дә үзе теләгәнчә генә яшәп бетерә алмый шул...

– Ничек инде үзе теләгәнчә булмасын? Безне ташлап китәргә кем кушкан аңа? Ничә тапкыр күрдем мин аларны урамда, оялмыйлар да, култыклашып баралар... Бусы мине күреп туктагач та, тегесе читләшми, һаман ябышкан килеш тора, күзен тасрайтып! Ничек мин шунда аның белән сөйләшим дә ничек итеп мин аңа әти дип дәшә алыйм?

– Ул теләгәнчә булмады шул, теге хатын теләгәнчә килеп чыкты. Аның ихтыяры көчлерәк булган, димәк. Әтиең йомшак күңелле бит синең.

– Йомшак күңелллеме? Алайса, нишләп авыру әбине ташлап чыгып китте, ә?

Халидә ярсып урыныннан сикереп торып утырды. Аның яшь йөрәге хәтта әтисенә дә тамчы гаделсезлекне гафу итәргә теләми иде.

– Үз язмышына үзе хуҗа була алмады ул, аның бар гаебе шунда гына, – дип кабатлады Зуфирә. – Ә язмышка хуҗа булу өчен бик зур ныклык кирәк. Ходай сиңа үзең теләгәнчә яшәргә язсын, Ходай сиңа бер нәрсә теләп, тормышта бөтенләй башкача көн күрүне язмасын!

– Аны Ходайдан сорап торасы юк. Һәркем теләгәнен һәм үзе яхшы дип тапканны эшләргә тиеш!

– Яшь шул әле син, – дип, аның чәченнән сыйпады Зуфирә. – Йокла әйдә, борсаланма, югыйсә миңа да йокы бирмисең...

Халидә, көрсенеп, әнисенә аркасы белән борылып ятты.

*** * ***

Ах, Халидә, Халидә, әгәр кеше үзе теләгәнчә генә яши алса икән...

Эльвирның уйлары изге, хыяллары матур иде... Менә алар икесе дә укуларын тәмамлыйлар, Эльвир матур-матур җырлар яза, филармониядә концертмейстер була. Ничек шәп яңгырый: «концертмейстер». Зуфирә кешеләрне таң калдырырлык, күңелләрне тетрәтерлек картиналар яза. Аларның ике балалары – бер ул, бер кыз туа. Кызлары музыкант була – фортепиано яки скрипкада уйнаучы, ә уллары – рәссам...

Кайда алар – Эльвир язасы җырлар? Кайда Зуфирәнең кешеләрне шаккатырырлык картиналары?

Яза алмады Зуфирә аларны. Училищедан бик зур өметләр белән чыккан иде югыйсә, аның «Укытучы» исемле картинасына – диплом эшенә бишле куйган иде комиссия. Әмма аның хәзергәчә халыкның бишлесенә лаек булырлык әсәр иҗат итә алганы юк әле...

Ә Эльвир... Хәтта укуын да тәмамлап чыга алмады ул. Өйләнешкәндә тагын бер ел укыйсы калган иде әле. Ләкин аны соңгы курска кертмәделәр, училищедан куып чыгардылар, ул хактагы приказны Зуфирә озын коридор стенасына эленгән тактадан үз күзләре белән укып кайтты. Эльвир үзе бу хакта әйтмәгән иде, ул, әлбәттә, төп фәненнән – музыкасыннан ярыйсы өлгереп бара иде, аңа сәләте дә җитәрлек, уйнарга ярата да иде. Тик менә тарихтан алдыра алмаган икән.

Шул чакта Зуфирәнең хәтеренә бер кыздан ишеткән сүз килде. Әле укыган чакта ук, Эльвир белән танышып йөрешә башлаган вакытта:

– Ә минем бер танышым синең егетеңне бик яхшы белә икән, – дигән иде. – Бергә укыйлар.

– Эльвир турында ни сөйли? – дип ярым шаярып сорады Зуфирә. Әмма җавап бик җитди яңгырады:

– Максатсыз кеше ул, ди. Ни өчен яшидер, нәрсәгә омтыладыр, аңлашылмый, ди. Үпкәләмә, мин ишеткәнемне әйтәм. Белеп торуың яхшырак, соңыннан үкенерлек булмасын...

– Үзенә карамаганга үч алуы түгел микән? – дип сорады Зуфирә, каушавын, рәнҗүен эченә йотарга тырышып.

– Егете бар ул кызның, бик яратышып йөриләр.

«Максатсыз»... Соңыннан кат-кат искә төште бу сүз. Еллар узган саен, кешеләрнең генә түгел, үзеңнең дә кемлегеңне яхшырак аңлый барасың. Хәзер шуны белә Зуфирә: яшьтән мавыгучан булды ул. Кешенең берәр матур, яхшы ягын күрсә, шуңа сокланып, аны һәрьяктан бик әйбәт дип күз алдына китерә. Соңыннан ул кешенең берәр җитешмәгән ягы ачылса, үзен алдангандай хис итә, рәнҗи, газаплана.

Аның балалар журналында эшләүче бер танышы бар, Мөршидә исемле. Зуфирәгә кат-кат әйтә ул:

– Нишләп син кешеләрне идеал итеп күз алдыңа китерәсең? Һәркемнең була яхшы ягы, була начар ягы. Моның миңа ошамаган яклары бардыр бит дип, алдан ук күңелеңә уеп куя торган бул. Аннары аның яхшылыгын күргән саен, сөенерсең, үзеңә рәхәт булыр. Инде начарлыгын күрсәң, артык көенмәссең. Табигый дип кабул итәрсең.

Мөршидә белән килешсә дә, аның хаклыгын белсә дә, күңеле-йөрәге белән моңа өйрәнә алмады Зуфирә. Эльвирның училищесын ташлавын да, үз-үзенә урын таба алмыйча, туктаусыз бер эштән икенчесенә күчеп йөрүен дә бик авыр кичерде, олы хәсрәт дип кабул итте. Үзе гел бишлегә генә укыганга, һәркем тапшырылган яки үзе теләп алынган эшне ахырынача башкарып чыгарга тиеш дип саный иде һәм шулай булмаганда ул чиксез гаҗәпләнә иде.

Шулай ук Эльвирның хыянәте дә Зуфирәнең башына сыймас бер хәл булып калды.

Ул чакта алар бер бүлмәле кечкенә квартирада яшиләр иде әле. Зуфирә мәктәптә укыта, Эльвир Культура сараенда һәвәскәрләр түгәрәгенең җитәкчесе иде. Каенана җәй башында Халидәне алып авылга кунакка китеп барды, алар икәү генә калдылар.

Ул хыянәт дигән нәрсә кинәт кенә булмагандыр инде, шактый элек башлангандыр, Зуфирә аны алданрак сизәргә тиеш иде. Артык беркатлы булмаса, эчендә җаны булган хатын иренең ятлар белән шаяруын тоймыймы соң! Ләкин сизмәде Зуфирә, үз күзе белән күргәнче, иренең тугрылыгына ышанып яшәде.

...Зуфирә дәрескә кергәч кенә белде: балаларга күрсәтергә дип әзерләп куйган альбомын өйдә онытып калдырган икән. Укучыларны мәктәп янындагы бакчага алып чыгып, этюд ясарга кушты да үзе тиз генә кайтып килергә булды: ерак ара түгел, егерме минутта әйләнеп килеп була иде.

Ишекне ачкач, бүлмә уртасында, шәрә беләкләрен күтәреп, чәчен төзәтеп торган яланаяклы ят хатынны күргәч, ул башта югалып калды: әллә соң саташып кеше өенә барып кердемме? Шулхәтле аптырады, бер читтәрәк басып торган Эльвирны башта шәйләмәде дә.

– Нишлисез сез монда? – дип, теленә килгән беренче сорауны әйтте.

Хатын, кулларын төшереп, нишләгәнне үзең аңламыйсыңмыни дигән сыманрак көлемсерәп карады, аның пешеп торган калын иреннәре арасыннан ике алтын теше ялтырап күренеп китте.

Шунда Зуфирә таныды: күрше ресторанның буфетында эшләүче хатын – Румия иде бу. Бервакыт, һәвәскәрләр концертына баргач, Эльвир аны, менә дигән драма артисткасы, әнә ничек матур укый шигырьне, дип, күккә күтәреп мактап утырган иде. Таланты ничектер, әмма төс-кыяфәте шәп иде хатынның. Буй-сыны менә дигән, ике бит алмасы янып тора, кара чәчләре иңнәренә таралып төшкән, хәтта ямьшек борын да кыяфәтен бозмый, аңа бер үзенчәлек кенә биреп тора иде шикелле. Бөтен зал аның шайтан уты шикелле яктырып торган зур коңгырт күзләренә карап дөньясын оныткан иде. Нәрсәдер вәгъдә итә, каядыр чакырып, ымсындырып елмая иде ул күзләр. Клубта аны, рәтләп җырлый белмәвенә карамастан, «Кармен» дип атап йөртәләр, берзаман кино

түгәрәге ниндидер һәвәскәр фильм төшереп азапланганда, аны төп рольгә куйганнар иде. Эльвир ул фильмга музыка язам дип хыялланып йөргән иде, бәлки, шул чактан ук башланган булгандыр дуслыклары.

Болар барысы да ишек төбендә басып торган Зуфирәнең башыннан мизгел эчендә йөгереп уздылар, җитмәсә, «Кармен»ның мыскыллы көлемсерәве янган йөрәккә керосин сипкәндәй итте. Зуфирә, үзен-үзе белештермичә, хатынга ташланды... Дөрес, «Кармен» аңа караганда гәүдәгә ныграк, калынрак иде. Әмма Зуфирә аны барыбер тәрәзәдән ыргытачак иде... Эльвир ирек бирмәде, кыя булып арага кереп басты, хатынының иңнәреннән кысып тотты. Зуфирә йодрыклары белән иренең күкрәгенә суккалады... Аның бераз сүрелгәнен сизгәч, Эльвир, иелеп, диван-карават астыннан үкчәсе ачык ак туфлиләр алды да Румиянең аяк астына ыргытты. «Кармен»ның аяк тырнаклары, канга манчылгандай, кып-кызыл итеп буялган иде...

Эльвир аны хатыныннан аркалап чыгарып җибәрде.

Зуфирә бу хәлне болай гына калдыра алмый иде. Ул, Культура сараена кереп, Румиянең адресын белде дә аларга китте.

Биш катлы панель йортның баскычлары себерелмәгән, ә өске катның түшәме тәртипсез малайлар кулы белән тап-тап итеп корымланган иде. Май чүлмәге тышыннан билгеле булган шикелле, йортта яшәүчеләрнең кемлеге дә ишек төбеннән үк беленә. Кыр-кырларына тигезле-тигезсез итеп күк киез кагылган ишекне кечерәк кенә буйлы, арык йөзле бер ир ачты. Нишләптер солдат гимнастеркасыннан иде ул һәм бу аны яшәртеп, бөтенләй малайсытып җибәрә иде. Зуфирәне күрүгә, аның йөзе тагын да озынчаланып, агарып китте, күзләре зур ачылды. Әйтерсең лә ул менә хәзер үзенә бик каты яра ясаячакларын белә, әмма котылу чарасын күрми иде. Яраланып егылган атлар үзләренә төбәлгән мылтык көпшәсенә шулай гаҗизләнеп карыйлардыр, мөгаен.

Әмма Зуфирә яралы атларны атарга сәләтле түгел иде. Ул тәтегә баса алмады. Бер генә мизгелгә башын иеп, иренен тешләп торды да, тыныч булырга тырышып:

– Румия өйдәме? – дип сорады.

– Румия?.. Өйдәме?.. – дип кабатлады ир кеше калтыранган тавыш белән. – Юк, ул эштә бит...

– Ярый алайса, эшенә керермен инде.

Шулай диде дә Зуфирә, мамык кебек йомшарган аякларын җайсыз басып, баскычтан төшеп китте.

Зуфирә, ире үзен гаепле санар, ә мин аны озак гафу итмәм, ялындырырмын, үкендерермен дип уйлаган иде. Ялгышты. Эльвир ялыну гына түгел, башлап сүз кушарга да ашыкмады. Гомумән, аның кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан да гаебен сизгәне күренми иде.

Алар икесе дә үз көйләре белән яши башладылар. Зуфирә китап-журналлар өчен рәсем ясый, кухняда үзенә кирәгенчә итеп җыелмалы өстәл ясатып куйды. Эльвирның андый эшкә кулы бармый иде, мәктәпнең балта остасын ялларга туры килде. Зуфирә кичләрен шул өстәл янында озак-озак утыра, әмма кирәкле рәсемнәр урынына кәгазьдә ямьшек борынлы, зур күзле хатын-кыз сурәте яисә яраланган ат шикелле тилмереп карап торган ир йөзе калкып чыга...

Ә Эльвир соң кайта, гадәттә, бераз салмыш була, кухняга кереп, чәйнектән салкын су салып, голт-голт эчә дә бүлмәгә чыгып китә. Әйтерсең лә хатынын күрми дә. Ашарга берәр нәрсә дә кирәксенми, ичмасам, тамагын әллә кайда туйдырып кайта!

Алар шулай сөйләшмичә ике атна яшәделәр. Ләкин сүз белән аңлашмасалар да, Эльвир хатынының күңелен йомшарту юлын тапты. Ул аккордеонын кулына ала да яшь чакта Зуфирә яраткан көйләрне уйнап җибәрә.

Сагынып килдем, күрми китәм... –

дип өзгәләнә аккордеон, көйнең әллә нинди тыкрыкларына кереп, адашып йөри, кемнедер эзли, эзли, табалмый... Сагышлы моң йөрәккә үтеп керә, үзәкне өзә, күзгә яшь тутыра, тәкатьсез итә... Әйтерсең лә Эльвир тылсымлы авазларны кармак итеп Зуфирәнең йөрәгенә ташлый, каптыра, кармакка бәйләнгән җепнең икенче очын үзенең хәрәкәтчән, озын, сизгер бармакларына ныгытып урап куя.

«Юк, беркайчан да гафу итмәячәкмен мин сине, беркайчан да!» – дип пышылдый Зуфирә, әмма сизеп тора: бу кармактан ычкына алмаячак, ычкынырга теләмәячәк аның йөрәге! Чөнки аның авырттыруы, сызландыруы да татлы. Зуфирәгә өстәлендәге кәгазьләр өстенә капланып елаудан башка чара калмый, ул фәкать елаганын Эльвир белмәсен иде дип курка.

Озак уйнамый Эльвир, аккордеонын куя да шакылдатып диван-караватны җәя. Үпкәләшкәннән бирле ул хатынына үч итеп, юри шул җайсыз, тар, биш яшьлек Халидәгә генә ярый торган урында йоклый. Моңарчы парлап йоклаган диван-караватка гына түгел, әнкәсенең зур шифоньер артындагы караватында тау булып күпереп торган чигүле тышлы зур мендәрләренә дә орынмый хәтта. Кызының кечкенә мендәрен баш астына сала да аның юрганын ябына. Башыннан ук бөркәнеп ята, аяклары юрган астына гына түгел, ятакка да сыймый. Инде ул бөтенләй тынып калгач кына

кухнядан чыккан Зуфирә аның «кара аны!» дигәндәй тырпаебрак торган зур баш бармагын, агарган үкчәсен күрә.

Өч атнадан каенана белән Халидә кайтты, аларны каршы алырга вокзалга Зуфирә белән Эльвир икесе ике яктан килеп бастылар. Үсеп, матураеп киткән кызының йомшак тәнен күкрәгенә кыскач, аның чәченнән аңкыган юкә чәчкәсе исен тойгач, Зуфирәнең йөрәгендәге таш тәмам эреп беткәндәй булды. Кыз бер кулын әнисенә, икенчесен әтисенә сузды, кош баласы кебек йомшак куллары белән һәр икесенең бармакларын кысып тотты, аларны аерылгысыз итеп бер-берсенә тоташтырып куйгандай итте.

Өч атна буена котсыз торган өйгә бердән ямь керде, җылылык иңде. Каенана вагоннан төшкәндә үк бөрешкән, картайган кебек күренгән иде, бусагадан атлап кергәч, тизрәк яту ягын карады. Чәй эчүгә күзләре йомыла башлаган Халидә үз урынына – әлеге шул диван-караваткa үрмәләде.

Зуфирә ирен гафу итәргә теләми иде әле. Ләкин нишлисең, икесенә бер урын калган, карт ана белән сабый каршында дәгъвалашу килешми... Зуфирә карышмакчы булып карады, пышылдап кына аңа рәнҗүләрен әйтмәкче булды, ләкин сүзләре бер назлану, җиңелчә үпкәләү сыман гына булып килеп чыкты. «Йә инде, ялгышлык белән генә булды, бәндә хатадан хали түгел. Сине генә яратам бит инде...» – дип, кайнар кочагына алган иренең сагынылган куенында бер йомарлам май кебек эреде дә төште Зуфирә...

Алар килештеләр, татулаштылар, ләкин хыянәтнең эзе калды, арада элекке сафлык, эчкерсезлек бетте. Зуфирә үзен ничектер, бөтенләй үк булмаса да, ярым ялгыз итеп сизә башлады, инде башка беркайчан да ире каршында ахыргача ачылып китә алмады.

Кухня яктан суыткычның гүләгәне ныграк ишетелә башлады, ишек ачылып китте бугай. Зуфирә, истәлекләреннән аерылып, башын мендәрдән калкыта төште. Әйе, бүлмә ишеге ачылган икән, дөресрәге, ачканнар, әнә караңгыда әллә нинди куркыныч өрәк кебек шәйләнеп, ак майка, кара трусик кигән шәүлә басып тора. «Зуфирә! – ди, каты пышылдап. – Зуфирә!»

Тавышка Халидә уянды, әллә бөтенләй дә йокламаган булганмы, караватны каты шыгырдатып әйләнде дә әнисенең күкрәгенә йомшак беләген салды. Ишек әкрен генә ябылды, шәүлә чигенеп юк булды.

Зуфирә үзалдына елмаеп куйды. Ах, Эльвир, Эльвир, инде картаеп киләсең, күпме гомер үтте, ә син һаман әле Зуфирәне элекке чаралар белән буйсындырмакчы буласың!

«Балык тирәнне, адәм яхшыны эзли!» – ди рус мәкале. Югыйсә адәм баласы балыкка охшарга тиеш түгел бит. Җайсызны үзенә җайлы итә белергә тиеш. Көчле, уңган кешеләр шулай итәләр дә. Ә менә Эльвир кебекләр, чыннан да, тирәнне эзләгән балык шикелле, җайлыны гына эзлиләр, җайсызлыкка бер генә дә түзә алмыйлар. Нәни кызы белән дә көе барда гына уйный-шаяра торган иде ул, бала елый башлады исә, хатынына яисә әнисенә илтеп тоттыра иде. Анысы ничектер табигый кабул ителә, ир кешегә бу килешеп тора иде сыман. Ә менә әниләре Сабира карчык авыруга сабышкач, Эльвирның бу холкы бик тиз сиздерде. Һәм... күңелне үзеннән биздерде.

Сабира карчык электән дә хәтерсез иде, үзе җыеп куйган әйберне эзләп җаны чыга торган иде, берәрсенә сүз кушам дисә: «Эльвир, Халидә, килен», – дип, хәтта әллә кайчан суга батып үлгән улы Хатипның да исемен кушып, бер-ике тапкыр санап чыга торган иде.

Боларына күптән күнеккәннәр иде инде. Ләкин менә беркөнне, Зуфирә мәктәптән кайтуга аш артыннан эчәргә дип кипкән җимешләр, шикәр комы өстенә эремчек салынган болганчык сыекча әзерләп куйган иде. «Әни, бу ни?» – дип сорады Зуфирә. «Күрмисеңмени, кампут». «Ә нигә эремчек салдың аңа?» – «Ник, ярамыймыни?» – «Компотка эремчек салмыйлар бит инде!» – «И-и, аптыратмасана, болай да башым тинтерәгән!»

Шуннан соң каенананың ашка шикәр салу, чәй янына килененең буяуларын китереп кую, ишекне шар ачык калдырып чыгып китү, кич ятар алдыннан: «Нишләп йөрисез, эшкә соңга каласыз!» – дип сукрану ише сәерлекләре еш кабатлана башлады. Ә беркөнне ул эштән кайткан киленен: «Кем син? Ни кирәк?» – дип каршы алды.

Җәй уртасында Эльвир белән Зуфирә, кызларын алып, өчәүләп диңгезгә бардылар. Сабира карчыкны авылдагы туганнарына кайтарып тордылар. Кире кайткач, карчык аларның берсен дә танымады. Эльвирдан бөтенләй курыкты: «Бу алагаем ир нишләп йөри монда, мине кияүгә бирмәкче булалармы әллә?» – дип, аннан качарга тырышты, Зуфирәдән: «Кем анасы син?» – дип сорашты. Карчыкны өйдә ялгызын калдыру куркыныч була башлады.

Эльвирны каты күңелле, шәфкатьсез дия алмас иде Зуфирә. Ул әнисен чын күңеленнән кызгана иде, аны терелтү өчен бөтен чараларны күрергә, кулыннан килгәнчә тырышырга әзер иде. Сабира карчык больницада чакта көнаралаш аның янына барып торды, өйдә чакта – карашты. Кызганычка каршы, авыруның язмышы бер якка хәл ителүен тиз арада көтеп булмый иде, озакка, ә бәлки, дистә елларга бара торган чир иде бу. Язмыш нинди гөнаһлары өчен бу чирне биргәндер Сабирага, кешегә зыян кыла белми иде, килен белән ыгы-зыгы чыгармый гына яши иде югыйсә.

Әкренләп, сиздерми генә, каенана кайчан ятканын-торганын, ни ашаганын-эчкәнен белмәс хәлгә килде. Ул бары тик бер генә нәрсәне уйлый, күрә, белә иде: Кама аръягындагы Мәүләшә авылын, зират очында инешкә арт белән утырган иркен, агачлы ихатаны, яшел чирәм үскән урамны һәм шунда каз бәбкәләре көтеп йөргән уналты яшьлек кызны – үзен. Аның бөтен омтылышы, бар хыялы бер ноктага төбәлде: Мәүләшә авылының зират очындагы яшел чирәмле, өянкеле ишегалдына кайтып китәргә. Инде ул ихатаның нигезе үк әллә кайчан юкка чыкканын, Мәүләшә дигән кечкенә авылның бар халкы биш ел элек күрше Баекка күчеп утырганын, Мәүләшә урамнары урынында хәзер шикәр чөгендере үсә торган иркен басу җәелеп ятканын Сабира карчыкның илле елга кире киткән зиһененә бернинди чара белән дә сеңдерү мөмкин түгел иде. Күп еллар шофер булып эшләп, бандитлар тарафыннан үтерелгән ирен дә, суга батып үлгән улын да, үзе кичергән кайгыларын да оныткан иде ул.

Аның Эльвирныкына охшаш яшькелт күзләреннән мөлдерәп сабыйлык, сафлык, гаҗизлек, ялвару карап тора иде. Һәм, ул күзләрне күргән саен, кызганудан Зуфирәнең йөрәге сызланып куя иде.

Баектагы туганнарына кайтарып карадылар – анда тора алмады карчык, кар дими, яңгыр дими, көнне-төнне белми, киенеп-нитеп тормый, ишек-капкаларның ачык чагын туры китердеме, кояш чыгышына таба күз тотып, Мәүләшәсен эзләп китә икән ул. Туганнар: «Моннан ары үз өстебездә тота алмыйбыз, чыгып китәр дә катып үләр, гөнаһысы безгә булыр, аны гына карап торырлык көчле кешебез юк, аны тыярга ирләр гайрәте кирәк», – дип хәбәр җибәрделәр. Эльвирның маңгае җыерылды, иреннәре кысылып, шома яңакларында чокырлар урынына буразналар ярылып керде керүен. Әмма телдән зарланырга кыймады, алып килде әнисен.

Тагын больницага салдылар карчыкны. Ләкин анда барган саен: «Кайтасым килә, кайтарыгыз инде!» – дип, үзәк өзгеч ялваруы белән Зуфирәнең җанын актаргандай итә иде ул. Үзе теләп алган чир түгел, Эльвирдан башка баласы юк. Өстәвенә үзен белә башлаганнан бирле әбисе кулында үскән, аны эти-әнисеннән дә ныграк яраткан Халидә бар бит әле. Ул әнисенә: «Алып кайтыйк әбине!» – дип ябыша, ай-вайга карамый иде.

Зуфирә күп уйланды. Бер кыйсса исеннән гел чыкмый иде.

Бер адәм үзенең картаеп хәлсезләнгән атасын крокодилларга ыргытырга сөйрәп бара икән. Артыннан кечкенә улы йөгереп килә, ди, моның. «Әй син нишләп йөрисең?» – дип сораган аннан әтисе. «Син картайгач, сөйрәп илтәсе юлны карап кайтасым килә», – дип җавап биргән аңа улы.

Алып кайтты Зуфирә карчыкны, Эльвирга каршы килеп алып кайтты.

Ләкин «өйгә кайтам!» дигәндә, Сабира карчык кала квартирасын түгел, – аның анда, таш капчыкта бер көн дә торасы килми иде, – үзенең Мәүләшәсен күз алдына китерә иде, билгеле. Ул ак яулыкка тегене-моны сала да чыга да китә, әллә ничә тапкыр шау-шулы шәһәр урамнарында каңгырап йөргән җиреннән көчкә эзләп таптылар.

Зуфирә, карчык белер-белмәс газ кабызып, бәла-каза чыгармасын тагын дип, кухня ишегенә йозак куйдырган иде. Ансына да Халидә каршы килде: «Нишләп син аны ябып асрыйсың? Кеше бит ул, хайван түгел!» – «Син мәктәптә, мин эштә, кайтып керүебезгә янып йә газга тончыгып үлеп куйса, нишләрбез?»

Урын өстендә яткан авыруны карау җиңелрәктер. Сабира карчыкның зиһене ничаклы зәгыйфь булса, тазалыгы шулхәтле яхшы иде. Чыгып китәм дип талпына башласа, Зуфирә аны үзе генә тыеп тора алмый иде. Бәхетенә каршы, ул карчыкның бер нечкә кылын тапты. Беркөнне ишектән керүгә: «Кызым, син өйдәме?» – дип сораган иде, шифоньер артындагы караватын шыгырдатып, Сабира карчык урыныннан кузгалды: «Монда, мин монда», – диде ул, әнисенә җавап биргән бала шикелле. Шуннан соң, карчык киреләнә башласа, Зуфирә аңа: «Кызым, тыңла әле сүземне!» – ди торган булды. Тик бер шарты бар иде: Халидәгә дәшкәндәй яратып, ягымлы итеп һәм аналарча таләпчән әйтергә кирәк иде бу сүзне. Юри-мырый әйткәнне тыңламый, ялганны сизә иде карчык.

Эштән кайтып керү белән, Зуфирә: «Син өйдәме, кызым?» – дигән сорауга каршы чыккан каенанасын җитәкләп, ванна бүлмәсенә алып кереп китә иде дә, резин перчаткаларын киеп, юындырырга керешә иде. Ул беркайчан да аны арусыз йөртмәде. Табын янында кулыннан ашата иде, чөнки соңга табарак карчык ашка да кул белән керә башлады, ә кайчак авырып китеп, ашыйсы килмәсә, каптырганны да өреп чыгара иде. Төннәрен шылт иткән тавышка да сикереп тора иде килен, чөнки карчыкның караңгыда чыгып киткән чаклары да булгалады.

Борынгы греклар болай дигәннәр: «Әгәр аллалар адәм баласын җәзаларга теләсәләр, алар аның зиһенен алырлар». Бу әйтемне болай дип тулыландырырга кирәк иде: «Әгәр Ходай Тәгалә кешене иң зур газапка дучар итәргә теләсә, еллар буе ул аннан зиһенен чуалткан кешене тәрбияләтер».

Белә иде микән Сабира карчык үзенең ничаклы бәхетсез икәнен, аңлый иде микән үз фаҗигасен? Аңламый иде бугай ул аны. Карчыкны фәкать бер генә нәрсә ашкындыра, борчый иде: кайтырга Мәүләшә авылына, үзенең уналты яшьлек чагына. Кайчак сирәк кенә, Зуфирә аның кулларын-битләрен юганда, карчык кинәт аңына килгәндәй була: «Син минем киленем бит!» – ди, күзләре

ачылып, нурланып китә, ләкин шунда ук бәбәкләре тагын сәламәт кешедә булмый торган тоныкелтыравык пәрдә белән каплана, карчык тагын ярты гасырга кире китә иде.

Юк, аңламый иде ул үз хәлен, газаплана белми иде. Аның газабы башкалар җилкәсенә төште. Бик авыр сынау булды алар өчен Сабира карчыкның бу чире.

Эльвир өйгә соңарыбрак кайта башлады, аннары кичләрен ресторанга эшкә йөри торган булды. «Акчасы булыр, – диде. – Ә өйдә минем ярдәмем күпме генә. Барыбер әни миннән курка, кача».

Төн урталары узгач кына кайта иде дә, ут та яндырмыйча чишенеп, авызыннан хәмер исе аңкытып, урын өстенә менеп ята иде ул.

Бу чорда Зуфирә Эльвирның хыянәте турында, Румия турында уйламаска тырыша иде. Бер мавыгу, юләрлек кенә булгандыр ла ул мөнәсәбәт, дип тынычландырырга тырыша иде үз-үзен. Хәзер инде менә аңлый: үтә торган гына түгел иде өйдәге көйсезлек һәм Эльвир бу көйсезлектән котылып торырга җай биргән бер генә мөмкинлектән дә баш тарта торган кеше түгел иде. Әгәр дә ул үз бурычын үтәү юлында бөтен кыенлыкларны җиңә торган көчле ихтыярлы һәм чын намуслы ир-ат булса, музыка өлкәсендә югалып калмас иде, даһи булып үсәр иде. Сәләтле иде бит ул! Ни хәл итәсең, бер Эльвир гына андый түгел, сәләтле кешеләр күп, даһилар аз.

Зуфирә хәзер аермачык күз алдына китерә Эльвир белән «Кармен» арасындагы хәлләрне. Менә Эльвир эч пошканнан ресторан буфетына керә. Болай гына, бераз тамак чылатып чыгар өчен генә. Ә прилавка артыннан аңа тылсымлы утлы, ымсындыргыч күзләре белән елмаеп «Кармен» карап тора. Эльвирдамы соң инде ул карашка каршы торырлык ихтыяр? Барыбер пычрандык бит инде дип уйлый ул. Күлдәвекнең уртасына бастың ни дә, кырыена бастың ни... Атналар, айлар буе көн саен әледән-әле кабатланып тора бу хәл. Эльвирның ихтыяры, авыру әнисе һәм кызы алдында намусын саклау теләге, туктаусыз тамган тамчыдан уелган таш шикелле, юкара бара, ныклыгын югалта бара, һәм, ниһаять, ул утлы күзләрнең сихеренә тәмам бирелә, алардан исереп, айнырга теләми дә.

Зуфирәнең боларны белмәве хәерлерәк булыр иде. Ләкин андый эш беленми каламы соң?

Бер дә бер көнне иренең костюмын чистартып азапланганда, кесәсеннән Румиянең паспорты белән сатучы таныкнамәсе килеп чыкты. Гадәттәгечә Эльвир өйдә түгел һәм аның кайчан кайтасы да билгесез иде.

Зуфирә янә теге таныш панель йортка китте. Ишек ачылып, тузгыган чәчле «Кармен»ның ут чәчеп торган күзләрен, алтын тешләрен күрүгә, Зуфирәне үз иренә, язмышына, үзенең көчсезлегенә, чарасызлыгына булган бар ачуы ургылып чыкты, ул, тыела алмыйча, кулындагы паспорт белән катыргы таныкнамәне оятсыз күзләргә томырды:

– Кая куйган идең син боларны, әйт, кайда калдырган идең?

Румия бу һөҗүмне көтмәгән иде, чигенергә дә җай юк, артта тар коридор, ә өйгә кереп үзен фаш итәсе, тавышны зурга җибәрәсе килми иде, күрәсең. Ул, ике кулы белән битен каплап, почмакка сыенды. Эчтән аның ире килеп чыкты, Зуфирә идәндә яткан үкчәсе ачык ак туфлине, – таныш туфлине! – иргә таба тибеп очырды:

– Син дә йөрисең шунда, мин – ир дип, җебегән!

Ир кеше җавап бирмәде, якынрак килеп, Зуфирәне беләгеннән эләктереп алды: «Йә, булды, җитте...» Аның саңгырау, хәтта бераз битараф тавышы Зуфирәне айнытып җибәрде. Кечкенә, арык булса да, кулында гайрәт бар икән, «әһ» дияргә ирек бирмәде, кулыннан авырттырып тоткан килеш, баскычтан алып төшеп китте.

Алар йорт каршындагы эскәмиягә чыгып утырдылар, ир кеше кесәсеннән тәмәке алып кабызды, тирән итеп суырды. Гаҗәпләнмәгән иде ул, ни булды дип төпченергә дә исәбе күренми иде. Үзе бу юлы да погонсыз гимнастерка кигән: «Мөгаен, берәр заводның хәрбиләштерелгән каравылында эшли торгандыр», – дип уйлады Зуфирә.

– Мәзәк кеше икәнсез сез, – диде, ниһаять, ир кеше. Аның күзләре бу юлы яраланган ат кебек түгел, ничектер көлемсерәп, хәтта Зуфирәне хуплап карый иде.

Аяк астында коелган өрәңге яфраклары кыштырдаша, салкынча җил ир кешенең сирәк аксыл чәчен мамык кебек тузгыта иде. Зуфирә сары яфраклардан такыя үреп кигәнен, суга карап үзенә, үзеннән дә бигрәк Эльвирга сокланган чагын исенә төшерде. Аңа салкынча булып китте, ул җилбәгәй җибәргән плащының чабуларын җыйды.

– Ә бәлки, мин түгел, син үзең мәзәк кешедер? Нинди ир инде син! Хатының башкалар белән типтерә, ә синең исең дә китми!

– Күнектем инде. Ун ел буена ничек күнекмисең...

– Ничек шуны әйтергә телең бара? Ир башың белән ничек чыдыйсың?

Ир кеше тагын тирән итеп тәмәкесен суырды да, Зуфирәгә карамый гына:

– Сез ничек түзәсез соң? – диде. – Сезнең урында булсам, мин, мәсәлән, бер көн дә болай яшәмәс идем... Хатыннарга нәрсә, балалары үзләре янында кала, алимент алар кесәсенә тама, закон алар ягында, квартира аларга...

– Нәрсәгә сезгә квартира? Әгәр мин сезнең урында булсам, ул хатын белән бер һаваны суларга да риза булмас идем!
– Ә нишләр идегез?
– Китәр идем! Җир читенә олагыр идем!
– Ә нигә китмисез соң? Кем тота сезне? Балагызны алыгыз да китегез! Ә мин китә алмыйм, китсәм, балам шул бозык хатын кулында кала!
Зуфирә әйтергә сүз тапмады.
– Йодрык болгау ансат ул, – дип дәвам итте ир кеше әкрен тавыш белән. – Кешегә акыл өйрәтү дә кыен түгел. Әле менә узганында үзегез дә бик батыраеп килгән идегез, авыз ачып сүз дә әйтә алмадыгыз, борылып китеп бардыгыз бит.
– Мин сезне кызгандым ул чакта.
– Без икебез дә бер үк дәрәҗәдә кызганыч инде. Ә бәлки, сез кызганычрактыр да әле. Чөнки мин бала хакына чыдап яшим. Минем акланыр чутым бар...
– Ю-ук, мин кызганыч түгел, кызганыч түгел! – дип сикереп торды Зуфирә. Әмма бу сүзен расларлык дәлил башына килмәде. Юл буе теге ирнең «кызганыч, кызганыч» дигәне аның чигәсенә бәреп баргандай булды.
Һәм Зуфирә шул кичне бунт күтәрде.
Халидәсе иптәш кызына күлмәк тегешергә китте – кызга ул чакта унбиш яшь иде һәм шул яшендә үк тегү эшенә бик оста иде инде ул. Зуфирә Казанда әле беркем өстендә күренмәгән, боргаланып тегелгән, җирдән сөйрәлеп йөри торган сары юбка, аның өстеннән челтәрле ак кофта киде, күзләрен шәмәхә пыялалы зур шакмак күзлек белән каплады, плащын иңенә генә салды да караватта, үз урынында яткан Сабира карчыкның өстеннән бикләп, «Аккош» ресторанына китте.
Гөрләп торган зур залның ишегеннән килеп керүгә, күп ирләрнең йөзе аңа таба борылды. Шулай булмаслык та түгел: чит ил журналыннан төшкән сыман модалы киенгән, сары чәче битен рам эченә алгандай итеп таралган, аккош шикелле салмак, әкрен адымнар белән башын югары тотып зал аша үтеп барган бу кызны берәү дә зиһене чуалган каенанасын үз баласы шикелле караучы, ире хыянәтеннән йөрәк мае сызган хатын дип уйламас иде, билгеле.
Ресторанның зур гына сәхнәсе булып, анда ыспай егетләр күзне чагылдырып ялтыраган барабаннарда, торбаларда уйный, аларның уртасында, ахак аккордеонын күтәреп, Эльвир басып тора, ә оркестр артындагы сөттәй ак пыяла экранда салават күперенең барча төсләре айкала иде – әйтерсең салават күпере боргаланып-сыргаланып заманча бии иде. «Төсле музыка» иде бу.
Зуфирә, оркестрны күрмәгәндәй, өстәлләр арасыннан түргә узды, берничә урында ирләр урыннарыннан торып, аны үзләре янына: «Рәхим итегез!» – дип чакырдылар. Әмма Зуфирә урын сайлаган иде инде: түр почмактагы өстәл янында өч ир-ат утыра, яннарында хатын-кыз заты юк, бер урын буш, ә алларында, өстәлдә, ярым бушаган шешәләр, тәлинкәләр тезелеп тора.
Ул килеп баскач, өлкәнрәге, кызарган киң чырайлы, сары мыеклы, юан муенлы абзый, мөгаен, авылдан килгән берәр начальниктыр, авыр гына урыныннан кузгалды да:
– Әллә урын эзлисезме, туташ? – дип сорады. – Әгәр үзегез генә булсагыз, рәхим итегез, утырыгыз.
Зуфирә йомшак кәнәфигә тезен тезгә чәнчеп утырды.
Каршысындагы кечкенә чырайлы, зур күзлеге астыннан борын очы белән ияге генә тырпаеп торган, керләнгән якалы кешегә дәште:
– Гафу итегез, сигарет белән сыйламыйсызмы?
Тәмәке кабызып, төтенен югарыга, ак түшәм тишекләреннән карап торган сөт төсле лампочкаларга өрде.
Эльвир кулына микрофон алды, ireннәрен кысып, йөрәккә мамык кебек ята торган йомшак тавыш белән: «Хөрмәтле кунакларыбызның үтенече буенча», – дигән булып, яңа җыр игълан итте. Аннары микрофонның таягын үз буена җайлап озайтты да кереш уйнады һәм, башын артка ташлый биреп, алай да авызын микрофоннан бик ерак алмыйча, җырлап җибәрде:

Үкенмимен инде, сыкранмыймын,
Ак чәчәкле язны дәшмимен.
Бар да үтте, алтын көзем җитте,
Кире кайтмас инде яшьлегем...

Аның ягымлы баритон тавышы микрофон аша көчәеп, бөтен залны биләп алды, күрше күршесен ишетмәс булды. Күңелгә ятышлы бу тавыш көйнең дә бөтен бормаларына керә иде. Ләкин иң кирәк җирендә нидер җитми: көйнең әйтеп бетереп булмый торган нечкә моңы, аркаларны чымырдатып, җаннарны сафландыра торган, кешене ашкындыра торган бер көче юкка чыга иде. Нишлисең, җырда да, тормышта да шул «чак-чак» дигән нәрсә җитмәде Эльвирга... Хәер, ресторанга тәннәрне чымырдата торган көй тыңларга килми кеше. Эльвирның җырын, Зуфирәдән кала, күңел биреп

тыңлаучы да юк иде. Берәүләр сикерешеп оркестр каршындагы мәйданчыкка чыктылар да, кем ничек булдыра ала, кем ничек тели, шулай сикеренергә, боргаланырга – ягъни биергә керештеләр. Икенчеләре, колак тондыргыч җыр, барабаннар дөбердәве, торбалар чинавы, аккордеонның кычкыруы аша, күршеләр белән өзелгән сүзне дәвам итәргә азапландылар.

Барысы да кызганнар, барысы да үзләрен көчле, әллә нәрсәләргә сәләтле, бернинди кагыйдәләр белән санашмас дәрәҗәдә тәвәккәл итеп тоялар кебек күренде Зуфирәгә. Күпләрнең тәвәккәллекләре, батырлыгы бер омтылышка – башка җирдә рөхсәт ителми торганны эшләргә, бәйдән ычкынуга юнәлгән... Бозыклык, гөнаһ һавадагы тәмәке төтененә, колак тондыргыч музыкага, җырга кушылып айкала кебек иде. Ә салават күпере биегән киң экран фонында, биеклектә басып торган озын, төз буйлы, эре сөякле, ак, чибәр йөзле җырчы аларга бу эштә фатихасын бирә, моның белән генә туктап калмаска, тагын да татлырак ләззәткә омтылырга өнди иде. Чөнки аның җыры яшьлекнең кыскалыгы, мәхәббәтнең сагышы, бу дөньяда тулы бәхетнең юклыгы турында сөйли иде. Ахыр килеп, һәркем күңелендә бер теләк туа: мөмкин булганны ычкындырмаска!

Ирләр Зуфирә каршына өч яктан бокалларын суздылар:

– Нәрсә эчәргә телисез? Акнымы? Коньяк? Шампанское?

Зуфирә аларның майлы күзләренә, чиксез соклануны, кызыгуны чагылдырган йөзләренә карап, эчтән генә көлемсерәп куйды: үзегезнең хатыннарыгыз, сөйгән кызларыгыз шушылай утырса, ни әйтер идегез икән? Ул, кулына бокал алып, юри Эльвирга күренерлек итеп күтәрде.

Җыр тәгәлләнде, торбалар, барабаннар тынды, салават күпере, боргаланган хәлендә, имгәнгән килеш, хәрәкәтсез туктап калды. Оркестрантлар, уен коралларын куеп, сәхнәдән төштеләр – тәнәфес башланды. Эльвирның үз ягына таба килгәнен күргәч, Зуфирә бокалын каршында утырган ирләргә таба сузды:

– Ягез, танышу хөрмәтенә!

– Бик рәхмәт, сезнең исәнлеккә!

Ләкин эчеп өлгермәделәр, Эльвир Зуфирәне күзләре белән йотардай булып утырган юан абзыйның иңенә кулын салды.

– Әз генә читкәрәк шуышыгызчы!

– Ә? Ни булган? Ни кирәк сезгә?

– Сездән берни дә кирәкми. Хатын белән бер-ике авыз сүз сөйләшәсе бар иде.

Юан абзый тәмам аптырап һәм куркып урыныннан торды. Эльвир утырды, абзыйны аркасы белән каплап, хатынына:

– Типтерәбезме? – диде.

– Син көн саен типтерәсең бит әле. Әллә миңа ярамыймы? Әйдә, икәүләшеп типтерәбез моннан ары!

– Бурычка эчәсеңме?

– Булса ни!

– Ә ничек түләрсең?

– Анысы минем эш!

Эльвир Зуфирәнең күзлеген тартып алды, очлары алтынсуланып өскә бөгелеп торган керфекләре арасыннан яшькелт нур бөркеп, күңелнең иң тирән почмакларын яктырткандай итте. Ул Зуфирә йөрәгендә һич тынмаган борчуны да күреп алды: өйдә каенана нишли икән? Әйбер-кара ватмасмы, ут-фәлән чыгармасмы, үзе интекмәсме? Халидә кайтып, икәүләшеп җәфаланып бетмәсләрме?

Әтәчләнеп, кыланып, уйнак күңелле, башсыз бәндәгә салышып утырган хатынының вөҗданында нинди ут янганын аңлап алды Эльвир.

– Ярый алайса, типтер. Җаны теләгән – елан ите ашаган!

Ул торып басты да сәхнәгә таба атлады. Зуфирә, елмаеп, тагын бокалын күтәрде:

– Әйдәгез, танышу хөрмәтенә эчәбез дигән идек бит!

Әмма өстәл тирәсендәге ирләрнең чырае үзгәргән, алар, айнып киткәндәй, Зуфирәгә куркып, шикләнеп текәлгәннәр иде.

Юан абзый нечкә тавыш белән:

– Без андый уеннарга катнашмыйбыз, сеңелкәш, – диде. – Син моннан күчеп үк утырсаң әйбәтрәк булыр. Киләсе кешебез дә бар безнең... Занятый бу урын.

Аңлый Зуфирә: шүрле абзыкайлар, типтерәселәре килә, ләкин андый-мондый дәгъва чыгудан уттан курыккандай куркалар.

Зуфирә кузгалып чыгып китмәкче иде. Ләкин торып басарга өлгермәде, кемдер аның беләгенә сак кына кагылды. Сыек гәүдәле яшь кенә бер егет икән. Биергә чакыра.

Сәхнәдә яңадан оркестр уйный, Эльвир җырлый иде. Зуфирә биючеләр арасына егет белән кара-каршы чыгып басты. Ничек боргалана-сикерә алса, шулай кыланып, кулларын өскә күтәреп биеде ул. Аның каршына әле бер егет, әле икенчесе килеп баса. Зуфирәнең хәрәкәтчән, ыспай гәүдәсенең бөтерелүе, салам төсле чәчләренең сибелүе, агарынган йөзендәге ярсу, ачу – бөтенесе Эльвир өчен

иде: кара, күр, мин дә мондагылардан ким түгел, бөтенесенең күзен шар итә алам, әгәр теләсәм, барысыннан уздыра алам! Сәхнә артында салават күпере бии, тирә-якта картлар-яшьләр, чибәрләр, ямьсезләр сикерешә, ә сәхнә уртасында басып торган күк костюмлы чибәр аккордеонист өздереп уйнаган көеннән башка берни күрми, ишетми иде шикелле...

Көй тәмамлануга, Зуфирә ишеккә юнәлде, сыек гәүдәле егет аның артыннан иярде. Зуфирә киенгәндә, ул да киенде, аның артыннан ияреп чыкты. Эльвирга үч итеп, Зуфирә аны троллейбус тукталышына кадәр яныннан кумады. Бары шунда гына, борылып:

– Ә син, энекәш, кая барасың? – диде. – Кара аны, хәзер ирем килеп җитәчәк, миннән ераграк тор.

Өй ишеген ачуга, эчтән тавыш-тын ишетелмәгәч, ул, шомланып:

– Кызым, син өйдәме соң? – дип сорады.

– Монда, мин монда, алырга килдеңмени? Күптән кайтасы килгән иде инде! – дип, караватын шыгырдатты каенана шифоньер артында.

Зуфирәгә Сабира карчык белән икесенең язмышлары уртак сыман тоелды: аларның икесен дә ташладылар, кызганмадылар... Ул, хәлсезләнеп, ишек яңагына сөялде. Халидә уянган икән, яланаяк әнисе янына килде:

– Ни булды, әни? Авырыйсыңмы әллә?

– Кызым, – диде Зуфирә. – Моннан соң без әтиең белән бергә яшәмәбез инде. Ник дип сорама, үскәч, барысын да аңлатырмын...

Халидә сорашып бәйләнмәде, ул әтисенең өйдән читләшкәнен күптәннән сизә иде инде.

Зуфирә кызын янына яткырды. Халидәнең кайнар тәне, татлы сулышы аның күңелен юатты, уйларын бер җепкә тезәргә көч бирде. Зуфирә бер нәрсәне бик яхшы аңлады: ул күпме генә тырышса да, хәзер инде Эльвир белән алар чын күңелдән яратышып, бер-берсенә ышаныч һәм ихтирам белән яши алмаячаклар. Аларның мөнәсәбәтендә нәрсәдер өзелде, аны ялгау мөмкин түгел. Ябыштырдым, ялгадым дип, үз-үзеңне алдарга мөмкин, ләкин ул һаман элекке эздән өзелеп торачак.

Шул көнне ул үзен ялгыз хатын дип күңеленә беркетеп куйды. Бар нәрсәне үзенчә хәл итә торган булды, тормышны үзе алып барды. Эльвирдан акча да сорамый иде хәтта, китап-журналларга рәсем ясый, анысы булмаганда, теләсә нинди эшкә алына: стенгазета ясарга да, лозунг язарга да. Берничә тапкыр Казан тирәсендәге колхозларга барып, авыл урамнарына куяр өчен плакатлар да ясап кайтты. Алар Халидә белән икесе дә өс-башларын менә дигән итеп үзләре тегеп кияләр, өйгә әллә ни кирәк түгел, кыскасы, акча җитә иде. Тик бу вак-төяк заказлар чын иҗат эшенә омтылган рәссам өчен зыянлы иде, билгеле, алар вакытны, көчне ала, кулны боза. Ләкин нишлисең дип уйлый иде Зуфирә, ялгыз хатынның язмышы шул инде...

«Мин синең белән бүтән яшәмәячәкмен!» – дигәч, Эльвир башта иреннәрен генә кыйшайтып куйды. Ләкин көннәр үтә торды, алар бик аз сөйләшәләр, аерым йоклыйлар иде. Тора-бара болай яшәүнең гадәткә керә барганын һәм араларның ерагайганнан-ерагайганын сизеп, Эльвир бер-ике мәртәбә хатыны белән ныклап аңлашырга омтылыш ясады, элекке чараны искә төшереп, аккордеонында уйнамакчы булды, ләкин Зуфирә аның сүзен тыңламый, ишеткәненә җавап бирми, ә аккордеон тавышы Сабира карчыкның котын очырып куркыта иде.

Шулай аралар тәмам суынып киткәч кенә, аларның квартира чираты килеп җитте.

– Мин синең белән күчмим, – диде Зуфирә иренә.

– Үзегез генә чыгарсыз алайса, – диде Эльвир тыныч кына һәм, чыннан да, артык ялынып тормады, киемнәрен генә алды да Румиясе янына күчеп китте. Теге гимнастеркалы ирнең ахыр чиктә сабыр канатлары сынып, үзе чыгып киткәнме, әллә хатыны куып чыгарганмы, ничек кенә булмасын, Румия ирек алган икән – Эльвирны йортка кертте.

Яңа квартирадан өлеш дәгъваламавы һәм әйбер-кара алмавы белән Эльвир үзенең вөҗданын тынычландырды. Яңа йортка күченгәндә, Сабира карчык тагын больницада иде, әйберләрне урнаштыруга, Халидә:

– Әни, әбине алып кайтыйк, – диде.

Фәрештә түгел иде Зуфирә, каенанасы китергән авырлыкларны сүзсез-авырсынусыз гына кичерде дип әйтү дөрес булмас иде. Гөнаһысы бар: эшендә дә, журнал редакцияләрендә дә зарланган чаклары булмады түгел, булды. Сөйләгән саен үзе дә аптырап: ничек түзәм икән, нәрсә хакына шундый газапларны үз иркем белән өстемә алдым икән, дип гаҗәпләнә, кайвакыт, яшь хатын карасын каенанасын, дип кызып китә һәм шул ук көнне карчыкны Румия өенә илтеп ташламакчы була иде. Ләкин өйгә кайтып кергәч, «кызым!» дигән сүзгә Сабира карчыкның: «Мин монда», – дип мөлдерәп караганын күргәч, җаны эри, аны мәче баласы урынына адаштырып, әллә кемнәрнең ишек төпләрендә интектереп йөртә алмаячагын аңлый иде.

Карчыкның хәле тәмам начарайды. Төннәрен бик тынгысыз йоклый, ул уянган саен Зуфирә уяна алмый, йокы баса иде, шуңа күрә, каенана төнлә кая да булса чыгып китеп каңгырып йөрмәсен йә өйдә берәр бәла-казага тармасын өчен, хатын караватта түгел, Сабира караваты янында, идәндә, аяк

астында йоклый торган булды. Карчык урыныннан кузгалды исә, өстеңә баса, сикереп торганыңны сизми дә каласың.

Бер уянып йокыны качыргач, күзләр йомылмый аптырата, башка әллә нинди уйлар килә. Зуфирә эченнән генә янындагы караватта авыр сулап, саташып йоклаган карчык белән сөйләшә. Карчыкны уяу итеп, үз акылында итеп күз алдына китерә ул.

«Менә син гомер юлыңны тәмамлап киләсең инде, әни. Әйт әле, сагынып искә алырлык нинәр эшләдең син бу дөньяда?»

«Минем яшьлегем...»

«Тукта, анысын күп сөйләдең бит инде. Калган гомерең турында сөйлә син миңа...»

«Гомеремнең чәчрәп торган гайрәтле елларын өй эшләрен карап үткәрдем. Атагызны иртән эшенә озатып калдым, кичен каршы алдым...»

«Ләкин кеше үзенә тиң башка берәүне карар-тәрбияләр өчен генә килми бит бу дөньяга, әни! Тормышыңның бар мәгънәсе шуның белән генә чикләндемени?»

«Атагыз мине туган ягымнан аерып алып китте. Үзенең эше авыр иде, ә минем кулымда һөнәрем юк иде. Ул сугышта чакта госпитальдә эшләгән идем дә бит, ул кайткач, тагын өйдә генә тора торган иттем. Ике бала да бар иде бит әле... Икесе дә ир балалар...»

«Әмма син улыңны намуслы итеп үстерә алмагансың, әни! Ул сине дә, мине дә, баласын да кызгана белми. Син аны шәфкатьсез итеп үстергәнсең! Ир баланың анасына йөз мәхәббәте булыр, аның туксан тугызы – хатынына, берсе балаларына күчәр, дип сөйли әбиләр. Эльвирның йөз мәхәббәте дә синнән китте – безгә килмәде. Кайда югалтты синең улың аларны, кая чәчте?»

«Олысы бик тәүфыйклы, бик игелекле бала иде дә бит, гомере кыска булды, һич уйламаганда харап булды балакаем. Әле атагызны җирләгәнгә ел да узмаган иде... Ничек чыдагандыр бу йөрәк ул кайгыларга...»

«Чыдамаган шул, әни, чыдап бетерә алмаган, шуңа хәзер син ярты гасыр гомереңне югалткансың. Әллә син аның мәгънәсез үткәнен сиздеңме? Шуңа күрә, кире кайтып, өр-яңадан яшәп карарга теләвеңме бу? Синен улың да мәгънәсез яши менә хәзер. Ул да берзаман, синең кебек үк, фаҗигагә юлыкмас микән? Нәрсә калачак аның яшәвеннән?»

Шулай уйланып ята торган иде Зуфирә каенанасының аяк астында. Аннары үз тормышына борылып карый да: «Ә мин, кырыкка җитеп, ни эшләдем соң әле?» – дип, үзеннән сорау ала башлый иде.

Ул караңгы, төпсез билгесезлектән кыска вакытка гына җиргә килгән, гомер су кебек ага, аның инде яшәгән хәтле дә яшисе калмагандыр, ул кире билгесез караңгылыкка китәр, юкка чыгар. Аның кайнар тәне, җиңел, салмак аяк атлавы, елмаюы, җитен чәчләре, эчендә кайнаган мәхәббәте, сагышы, хәсрәте, шатлыклары, моңы – бөтенесе юк булыр. Ә ул гомеренең чагылышын гына булса да кешеләргә калдыра алыр иде бит, үзе кылган хаталардан башкаларны кисәтеп, үзе кичергәннәрнең сабагын биреп, үзе аңлаган матурлыкка аларны да сокландыра алыр иде һәм аның хисләре чагылышы үзеннән соң да озак вакыт җирдә яшәр иде. Табигать аңа моның өчен шундый зур мөмкинлек – сәләт биргән, ә ул бу зур бүләкне файдаланмый, үзе белән бергә кара гүргә алып китмәкче!

Иртән Зуфирә редакцияләргә ашыга, заказлар ала, үзе өчен акварельләр яза иде. Соңгы вакытта аның берничә портреты – балерина, җырчы сурәтләре, әкиятләргә ясаган рәсемнәре – Татарстан рәссамнары күргәзмәләренә дә куелды.

Ләкин ул үзе моңа гына канәгать түгел иде.

Һәр газапның ахыры була. Сабира карчыкның интегүләренә дә бер чик килде. Кыш башында ул, ниһаять, дөнья куйды. Әллә кайчан юкка чыккан Мәүләшә авылын сагынып, шунда кайта алмаганга газапланып үлде. Соңгы вакытта ул еш хәлсезләнеп ята иде. Иртә белән әбекәйнең кузгала алмаганын күреп, табиб чакырдылар. Табиб дарулар эчәргә кушып китеп барды: үлә дигән уй Зуфирә белән Халидәнең башына кермәгән иде, карчыкны йоклый дип уйлаганнар иде, ә ул сулыш алудан туктаган икән. Моны белгәч, Зуфирәгә кыен булып китте: Эльвирны чакырырга да өлгерә алмадылар.

Аны күмеп кайтканнан соң, Зуфирә, ниһаять, бер җиңеллек кичерергә тиеш иде кебек. Ләкин алай булып чыкмады. Беренче атналарны бик кыен булды. Үлем җиленең өйгә керүе, гомумән, кеше күңеле өчен авыр нәрсә. Төннәрен кинәт сискәнеп уянып китә, аннары үзенең инде идәндә түгел, караватта ятканын абайлап, өйдә бер бушлык сизә иде Зуфирә. Көндез редакциягә яки нәшриятка барган чакларында, күнегелгән гадәт буенча, тизрәк эшен бетереп, өйгә кайтырга ашыга, бераздан гына аңына килеп: «Бәй, кая кабаланам болай? Ул юк бит инде...» – дип уйлап куя һәм бу уй аны тынычландырудан бигрәк сагышландыра да иде. Сабира карчык Зуфирәсез дөньяда яши алмый торган җан иясе иде. Ә бездән башка яши алмаган кешеләр күп түгел...

* * *

Хәер, әнә тагын берәүгә кирәк бит әле Зуфирә. Әлеге дә баягы шул Эльвирга. Әнә тагын ишекне ачты, бүлмәгә үк бер-ике адым атлады. Керми генә тор әле! Зуфирә караватны каты шыгырдатып әйләнде, кызын уятты: «Җайлабрак ят әле, кулым оеды».

Эльвир тагын шым булып чыгып китте.

Ул да кырыгын узып бара бит инде. Төннәрен берүзе уйланып ятканда, вөҗданына ни дип аңлата икән узган гомеренең мәгънәсен? Үзенең ярдәменә, мәхәббәтенә мохтаҗ өч кешенең – кызының, хатынының, әнисенең берсенә-бер игелек күрсәтмәвен, бары тик газаплар гына китерүен ни белән аклый икән? Тормыш ыгы-зыгысыннан котылырга тырышып, башларын миңгерәйтеп, эчләрен бушатып алырга дип ресторанга килгән кешеләрнең күңелен ачтым, дипме? Ике хатын арасында буталып йөрдем, дипме?

Ә бит дөньяда бөтенләй башкача, ашкынып, мәгънә белән яшәп була. Бар бит алай яшәүчеләр.

Өмит, мәсәлән.

Аларның кыяфәтенә бер караудан ук башкалардан аерып куясың, һәрхәлдә, Зуфирә аны бер күрүдә хәтеренә сеңдереп калган иде.

Узган елның август аенда, инде Сабира карчык хәсрәте бераз тынгач, Зуфирә Кара диңгез буена, Анапага барырга кузгалган иде. Халидә спорт лагеренда, Зуфирә ялгыз, кая барса да, нишләсә дә үз кулында, өйдә ни бар икән дип борчылып торасы юк. Мондый иркенлекне моңарчы күргәне юк иде аның.

Кечкенә чемоданы белән этюднигын күтәреп, аэропортка барып утырды. Ялгыз хатынның язмышы бер: китсә – озатучысы, кайтса каршы алучысы юк. Кадерле кешеләрне генә үбеп озаталар, сөенеп каршы алалар.

Билгесез юлга кузгалганда, гомумән, күңел алгысый, каушау, курку, сөенеч, аңлатып булмый торган тойгылар дулкыны белән тула. Көньякка Мәскәү аша очарга кирәк иде. Анда Анапа самолетына тиз генә күчеп утыра алырмы? Диңгез буенда ничек урнашыр, кемнәр белән очрашыр?

Билетын исәпкә алдырган чиратта Зуфирә бер диңгезче артына туры килде. Зәңгәр китель җиңенә өч сары тасма-шеврон тегелгән иде. «Капитан», – дип уйлады Зуфирә.

Форма кием, гомумән, ирләрне ыспайландырып, пөхтә итеп күрсәтә. Бу кешенең дә уртача буйлы, хәрәкәтчән, нык гәүдәсендә форма гадәттән тыш ипле утыра иде. Яны белән басып торганда, Зуфирә аның фуражка астыннан караган зирәк зәңгәр күзләрен күреп алды. Бу карашы аның чиста кырылган, нык иякле кырыс йөзен яктыртып, мөлаемлык өстәп тора иде. Үзен бик иркен, тыныч тота, олы юл алдыннан алгысауның әсәре дә сизелми, урыннан урынга күчеп йөрү аның өчен гадәти хәл иде булса кирәк.

Ул ялгызы түгел, соргылт кримплен пальто кигән, чал чәчен бөдрәләткән ябык кына бер апа белән иде. Чемоданын тапшырып, билетын регистрациягә биреп алгач, диңгезче чал апаны култыклап алды да, колагына иелә төшеп, елмаеп нидер сөйли-сөйли, читкәрәк алып китте. Аның тузан бөртеге кунмаган ялтыравык ботинкалары бетон идәнгә ябыштырып куелгандай нык баса, шул ук вакытта адымы җиңел иде.

Самолетта аларның урыны рәттән туры килде. Фуражкасын салгач, ачыграк күренде: диңгезченең шома итеп таралган коңгырт чәчләрендә, чигә турыларында чал бөртекләр җемелди иде. Ләкин бу аны тамчы да бозмый, киресенчә, аңа могтәбәр кыяфәт кенә өсти.

Самолетта күршең белән сөйләшеп китү гадәти хәл. Зуфирә тәрәзә янында утыра иде, диңгезче стюардесса күтәреп килгән подностан пластмасс стакан алып, аңа сузды:

– Сусамадыгызмы? Рәхим итегез!

Аның тавышы калын, куе иде. Капитаннарның тавышы, диңгез җилләре белән көрәшеп, тозлы һавада чарланып, карлы-бозлы давылларда чынныкканга күрә, бераз карлыккан булырга тиештер дә.

– Сез Мәскәүгәме? – дип сорады Зуфирә.

– Бераз гына арырак... Камчаткага.

– Ә ник кире якка очасыз? Мәскәү кайда да Камчатка кайда?

– Мәскәүдә йомыш бар. Аннан туры рейс белән очу уңайрак та.

Сүз шунда өзелде. Диңгезче Зуфирәнең кая баруы белән кызыксынырга теләк белдермәде, газета укырга кереште.

Мәскәү аэропортында аларга чемоданнарын бирми бик озак тоттылар, йөк ташучы кешеләр җитеп бетми икән.

Ниһаять, әйберләрне алгач, Зуфирә аптырап калды. Инде кая барырга, ничек төн үткәрергә? Башкалада аның танышлары юк, гостиница эзләп йөрергә дә соң. Зуфирә, нишләргә белмичә, стеналары тоташ пыяладан булып, биек түшәмендә йолдызлар кебек бихисап лампочкалар янып торган, үзе бер шәһәр хәтле зур аэровокзалны күздән кичерде. Капитан аның хәлен аңлады булса кирәк:

– Сез хәзер кая барасыз? – дип сорады.

– Минем самолет иртәгә иртән була. Көньякка очам.

– Ә аңарчы?
– Биредә урын җитәрлек.
Зуфирә мәйдан кебек иркен зал уртасына тезелгән кара күн тышлы утыргычларга ымлады.
Капитан бераз икеләнеп калды. Казанда алар бер-берсенә бөтенләй чит кеше булсалар, монда – ят җирдә – алар инде әзрәк үз кешеләр – якташлар иде. Ә якташны ярдәмсез калдыру гөнаһ эш.
– Алайса әйдәгез, – диде ул, катгый итеп.
– Кая?
– Гостиницага барабыз.
Җавап та көтеп тормыйча, Зуфирәнең кулыннан чемоданын алды да, артына борылып карамыйнитми, шәһәр ягына чыга торган пыяла ишеккә юнәлде.
«Россия» гостиницасында капитан Гасимовка урын калдырылган икән, ләкин Зуфирә өчен буш урын юк иде. Капитан аны урындыкка утыртты, янына чемоданнарны куйды да телефон-автоматтан каядыр шалтыратты. Ярты сәгатьтән Зуфирәгә дә ике кешелек бүлмәдә, бер хатын-кыз янында урын таптылар.
– Инде тамак ялгарга кирәк булыр. Егерме минуттан әзер булырсызмы? Мин сезнең ишеккә орынырмын, – диде капитан.
«Кара, ничек командовать итә! Корабтагы матросыңмы әллә мин синең?» – дип уйлады эченнән генә Зуфирә.
Әмма үзе белеп тора: капитанның аның белән шулай сөйләшергә хокукы бар иде. Ул, бүлмәгә керү белән, парадка әзерләнгән матрос шикелле тырышып, киенә-бизәнә башлады. Чемоданнан үзе теккән озын юбкасын тартып чыгарды, җиң очлары челтәрле кофта киде, баш артына тыгызлап төеп куйган сары чәчен сүтеп, тарап, иңнәренә салды, сөрмә тартты.
Капитан, аны бу рәвешендә күргәч, эченнән генә булса да аһ итәргә, зәңгәр күзләрен чет-чет йомып, сүз таба алмый торырга, Зуфирәнең әйткәннәрен баш иеп тыңларга тиеш иде.
Әмма Гасимов андагы үзгәрешне гүяки күрмәде дә.
– Әзерме сез? – диде баягыча катгыйлык белән. – Нинди тәкъдимнәрегез бар?
Ә менә тәкъдим турында Зуфирә бөтенләй уйламаган иде. Тагын капитан әйткәнне тыңларга туры килде.
– Ресторанга керсәк, ничек булыр?
– Мин каршы түгел, иптәш капитан! – дип, матросларча кискен итеп җавап бирде Зуфирә. Аның бу җавабында үртәү дә, үртәлү дә ишетелде.
– Алайса, бөтен тизлеккә алга, егерме өченче катка! – диде капитан, аның шаяруын күтәреп алып һәм ирен читләре белән генә елмаеп.
Гөлләр, сурәтләр белән бизәлгән ресторан залы зур булса да котсыз киң булып тоелмый, чөнки һәр өстәл аулаграк итеп куелган иде. Метрдотель капитанны ишек төбендә үк каршы алып, баш иеп, түрдәге өстәл янына озатты: «Рәхим итегез, сезнең урын менә биредә». «Кай арада барысын да җайлап өлгерә бу кеше», – дип, эчтән генә гаҗәпләнде Зуфирә.
– Монда да алдан сөйләшеп куйган идегезмени? – дип сорады ул.
– Корабының ярты сәгатьтән кайда буласын белмәгән капитан дөньяда юк ул... Безгә танышырга вакыт түгел микән? Минем исемем Өмит.
– Ә мин Зуфирә. Ялгышмагыз: Зу-фи-рә.
– Моңарчы ишеткән юк иде.
– Әни әйтә иде, чын фарсыдан кергән исем, дия иде.
Ашарга китерделәр. Зуфирә капитанның озын бармаклы, көчле кулларында уйнап кына торган чәнечке-пычакларга карады. Бу зур һәм нәзакәтле, шул ук вакытта вак әйберләрне дә бик пөхтә тота торган кулларның сурәтен ясыйсы килә иде.
Капитан әңгәмә корырга ашыкмады, карашын тәлинкәсенә төбәп капкалавында булды. Менә оркестр уйнап җибәрде, әнә берничә пар биергә чыкты, ә ул чәнечке-пычаклары белән тәлинкәсендә казына. Зуфирә кәгазь салфетка алып, сумкасыннан бер кап фломастер чыгарды. Игътибар итмисеңме, мине хатын-кызга да санамыйсыңмы? Без дә төшеп калганнардан түгел! Менә сезнең минем белән матроска приказ биргән капитан кебек... юк, капитан түгел, боцман шикелле эре генә сөйләшкән чагыгыз! Борын чөелгән, ияк гадәттәгедән дә ныграк тырпайган, киерелеп маңгайга күтәрелгән кашлар үзләре генә ни тора. Бусы булдымы? Ә менә бусы – телефоннан сөйләшкән чагыгыз! Ай-яй, авыз ерык, ә? Таныш начальник белән сөйләшәсезме? Йөздән бал тама, борын да алай очланмаган, ияк тә тырпаймаган... Менә бусы, кашны җыерып, чәнти бармакны тырпайтып, тавык кисәген пычак белән ботарлап азапланган минут...
– Нишлисез сез анда?
Зуфирә, башын күтәреп, мәгънәле көлемсерәп карады.
– Сезнең образны мәңгеләштерәм.
– Бирегез әле!

Өмит салфетканы үзенә тартты.

– Әһә, тешләшә дә беләсезмени әле сез! Ә башкаларны ясый аласызмы?

– Юк, – диде Зуфирә. – Мин фәкать сезне генә ясый беләм.

– Әнә теге официантканы ясап карагыз әле.

Зуфирә, яңа салфетка алып, берничә сызык белән, шөпшә биленә таянып, бар янында басып торган кызны сурәтләде. Ул үзенә охшаган да, шул ук вакытта эреләнеп торуы белән гаҗәп көлке дә иде. Өмит ашавын онытып, якташына беренче тапкыр кызыксынып һәм ихтирам белән карады.

– Әйтегез әле, Зуфирә ханым, бу һөнәргә кайда өйрәндегез?

– Иң элек мич алдында, күмер белән стеналарга сызгалап. Аның өчен арт сабагымны шактый укыттылар. Аннары урамда, такыр җиргә чыгарга туры килде. Соңрак кәгазьгә каләм белән ясап булганын ачыкладым.

Өмит, табышмак чишәргә теләгәндәй, рәсемнәргә шактый карап торды да:

– Да, бирсә, Ходай бирә инде андый сәләтне, бирмәгәнне тартып алып булмый, – дип куйды. – Ә менә мин рәссамнарга гомер буе кызыктым, ләкин балта сурәте ясарга да өйрәнә алмадым.

– Аның урынына менә мин машиналарны белмим. Шушы яшемә җитеп, ит тарткычның ничек итеп итне туравын аңлап җиткерә алмыйм.

– Машина тимерләрен линейка белән сызып ясыйлар. Боларны алай ясап булмый. – Ул рәсемнәргә ишарәләде. – Монда – мөнәсәбәт, хис, тойгы. Могҗиза!

Капитан, бик кызыксынып, Зуфирәнең тормышын,ниләр эшләвен сораша башлады. Карашы нурланды, керфегеннән гөлләр тама дип, шундыйлар турында әйтәдер халык дип уйлап куйды Зуфирә. Ничек сурәтләргә аны – кешенең керфегеннән гөл тамганын? Карашында сафлык, күңел җылылыгы чагылган итептер инде.

Очраклы юлдашка булмаганны сөйләп, хәйлә корып, боргаланып маташуның мәгънәсе юк, андый чакта, гадәттә, Ходай каршындагы кебек, иң яшерен серләреңне ачасың да саласың. Эчеңне бушатып бер юанасың, ичмасам, аннары кылганнарыңа, тормыш рәвешеңә башка берәүнең бәясен дә аласың. Һәркемнең кайчан да булса андый бәяне беләсе килә. Шул ук вакытта сереӊ кирәк-кирәкмәгәнннәргә фаш булмаячак, чөнки ул юлдашны бер күрәсең дә бүтән очрашмыйсың бит.

Зуфирә китап-журналлар өчен рәсемнәр ясавын, буш арада акварель белән шөгыльләнүен, зур әсәрләр эшләр өчен белеме, тәҗрибәсе җитмәвен, ире белән аерылуын, каенанасының чирен – барысын да кыска гына итеп сөйләп бирде.

– Өлкән буын каршында бурычымны тулысынча үтәдем дияргә була, – диде ул, үзалдына уйлангандай. – Кечесе үсеп җитте. Китап-журналлар өчен ясаган рәсемнәремне хуплап кабул итәләр. Акварель белән эшләргә яратам мин... Ләкин кулдан килерлекне эшләмәдем, иң мөһимен әйтә алмадым әле. Эчемдә ут кайный, дөрләп янган учак кебек, шуның, ичмасам, бер очкынын да кәгазьгә төшерә алмыйча гаҗизләнәм. Тирә-юньнең бар төсмерләрен, үзгәрешен, кешеләрнең йөзендә чагылган күңел кичерешләрен, яхшылыкны, яманлыкны – барысын йөрәгем аша үткәрәм, бөтенесен күңелемә җыям югыйсә, тик хисләремне, уйларымны рәсемнәр аша әйтә алмыйм. Каләмем көчсез, төсләр миңа буйсынмый... Кайчак шулай була бит: бер җырчының тавышы матур, көчле, көйнең дә бөтен борылышларына кереп, җиренә җиткереп җырлый. Ләкин аны тыңлаганда, беркайчан да ләззәттән һәм аңлатып булмый торган татлы бер ямансулыктан тән чымырдамый... Иртәгесен син аның җырын көйләп йөрмисең. Була бит шундыйлар... Ул кеше сине, үз хисләре белән яндырып, биеккә омтылдырмый... Менә мин шуның кебек... Кешеләрнең күңелен кузгата алмыйм. Бик телим югыйсә, тик барып чыкмый, эчемдә кайнаган ут белән кешеләрнең йөрәген җылыту юлларын белмим.

– Талант мәсьәләсенә килгәндә, сездә ул җитәрлек булырга тиеш, – диде Өмит, уйланып. – Гаҗәп җиңел тасвирлыйсыз бит кешеләрне! Ә андый талант барча рәссамнарга да бирелми. Ә бәлки, сезгә күңел хөрлеге җитмидер?

Зуфирә аның үзе турында сораша башлады: кайда туган-үскән, ерак диңгезләрдә йөрүче корабның капитаны булуга ничек ирешкән?

– Күп малайларның хыялы инде ул – капитан булу. Су ярата идем, җәйләрен авылыбыздагы инештән чыкмый идем. Сәяхәтчеләр турында күп китаплар укыдым. Максатыма ирештем – диңгез училищесына укырга кердем. Ә калганы – гомер үтү нәтиҗәсе.

– Ләкин үткән гомер кешене үзеннән-үзе генә күтәрми.

– Тормышта, судагы кебек, бер урында озак торып булмый: йә төпкә, йә алга, ярга.

– Нилектән кешеләрнең күңеле еракларга, әллә кайларга тартыла икән? Берәүләр бит туган җиргә кендеге белән береккән була. Язмыш кушып, чит җирләргә барып чыкса, илен сагынып саргая. Икенчеләр, үз ирекләре белән әллә кайларга китеп, үз-үзләрен афәтләргә дучар итеп, гомерләрен читтә үткәрә. Язмыш йөртә дип әйтеп булмый, үзләре теләп китәләр. Менә сез, мәсәлән...

– Моның серен сез, сәнгать әһелләре, аңлатырга тиеш инде. Мин дә күп уйладым бу хакта. Бигрәк тә диңгездә чакларда. Әлбәттә, туган як сагындыра. Ә кайтсаң, тагын диңгезгә ашкынасың... Менә Витус Беринг... Камчаткада аны бик ихтирам итәләр. Петропавловск каласының нигезен шул салган, шәһәрнең исеме дә аның кораблары «Изге Петр» һәм «Изге Павел» исеме белән атала. Даниядә туып үскән бит үзе. Мин ул илне ямьле, кечкенә, җылы өй сыман күз алдына китерәм. Уңайлы шәһәрләр, борынгыдан килгән сәнгать, ашап-эчәргә, күңел ачарга яратучы кешеләр. Табигате дә талгын, артык салкын да түгел, артык эссесе дә юк, күңелне җилкендереп бер йөзеп кайтыйм дисәң, диңгезе дә янында гына. Яшә, эшлә, оя кор, балалар үстер, теләсәң, сәнгать белән шөгыльлән. Ләкин Беринг моңа гына канәгать булмаган. Нишләптер Россиягә килгән, иксез-чиксез Себер киңлекләре аша үтеп, Охот диңгезен кичеп, кыргый һәм уңайсыз җиргә – Камчаткага барып җиткән, анда кораблар төзеп, тагын да салкынрак диңгезләргә чыгып киткән – Америка белән Азия арасында су бармы, алар тоташканмы-юкмы икәнен белергә. Диңгезләрдә йөрүнең кыенлыкларын белмәгәнмени ул? Күп юлдашларының, ә бәлки, үзенең дә шунда һәлак буласын уйламаганмыни? Белгән, һәммәсен бик яхшы аңлаган. Ләкин барыбер барган бит шунда. Бер генә түгел, ике сәяхәт ясаган. Яңа атаулар ачкан. Азия белән Американың тоташмаган икәнлеген ачыклаган. Күп юлдашларын югалткан һәм үзе дә Камчаткага кире кайтып җитә алмаган. Сөйләп бетергесез михнәтләр күреп, инде тәмам өметне өздек дигәндә, алар җиргә килеп җиткәннәр. Ләкин бу буш атау булып чыккан. Зәңгеләдән тәмам шешенгән Берингны аннан-моннан корыштырган куышка яткырганнар, бераз җылынмасмы дип, ярты гәүдәсен туфрак белән күмгәннәр. Аннары, хәле бик авырайганны күреп, туфракны алып ташламакчы булганнар. Ләкин Беринг, калдырыгыз, дигән, миңа шулай җылырак, дигән. Ул инде үләчәген, ямьле йорт кебек туган җирен – газиз Даниясен беркайчан да күрмәячәген белеп яткан. Ләкин үзен бик тыныч тоткан, хәтта шат күренергә тырышкан, чөнки башкаларның күңелен төшерүдән курыккан. Үзләренең билгесез атауда икәнлеген бик яхшы белсә дә, Беринг юлдашларына моны сиздермәскә, без Камчатка ярына кайттык, дип ышандырырга тырышкан. Ул шул хәлендә үлгән. Беринг атавын мәктәп дәреслекләреннән беләсездер бит? Шунда аның кабере. Күрәсез, ул кылганнары өчен дан да, мал да алмаган, рәхәтен дә күрмәгән, ләкин барыбер үзен үлгәндә дә бәхетле санаган. Безнең өчен шул юанычы бар тагын: бу экспедицияләрен башлаганда, Берингка кырык җиде яшь булган, ул алтмыш бер яшендә үлгән. Димәк, ниләрдер эшләргә безгә дә соң түгел әле, шулай бит?

– Сез дә Беринг кебекләр токымыннан инде алайса!

– Сезнең күңелдә дә бар ул тынгысызлык. Әле генә миңа сөйләп утырдыгыз бит. Кеше, сыер кебек, җылы абзарда гына яшәргә тиеш түгел. Ул үз кылганнарына, үз тормышына шәм яктысында, хәтта электр лампасы яктысында гына карарга тиеш түгел. Ул үзенә янар таулар яктысында карарга тиеш берзаман. Менә шул чакта ул үзенең чын дөрес бәһасен белә алыр. Дөрес, тынгысыз йөрәкләрнең барысы да океаннарга, җир читенә омтыла дип әйтеп булмый. Һәркайда, һәр өлкәдә бар алар.

– Бәлки, без аларны күреп, аңлап бетерә алмыйбыздыр, – диде Зуфирә, уйланып.

– Анысы инде сезнең эш – кешеләрнең хис-омтылышларын аңлау һәм башкаларга аңлату. Минемчә, адәм баласын әйдәп баручы көч – аның күңелендә, йөрәгендә кайнаган ялкын, хис. Кеше берәр нәрсәне башта күрә, сизә, тоя. Аннары гына акылы белән аңлый, өйрәнә. Барлык ачышлар шулай ясала бит. Сизүне, ашкынуны, омтылуны әйтеп аңлатып бирү кыен, аны көй белән, төсләр белән, кыскасы, сәнгать чаралары белән генә тасвирлап була. Ә моның өчен күңелең белән шул кичерешләрнең киңлеген һәм тирәнлеген тою зарур. Беринг кичергәннәрне үз йөрәгең аша үткәрми торып, башкаларга аңлатып булмый.

Зуфирә, дулкынланып, тәрәзәгә карады. Зур шәһәр хисапсыз утлары белән җемелди, мең төрле серне, катлаулы йөрәкләр тибешен чагылдыргандай булып күренә иде.

...Иртәгесен Зуфирә Анапага билгеләнгән рейс белән китмәде, иртүк аэропортка барып, билетын икенче көнгә алыштырды. Ул арада Өмит тә барасы җиренә барып килде.

Кичке якта алар шәһәр буйлап йөрергә чыгып киттеләр.

Аңарчы Зуфирә Мәскәүдә үткәндә-сүткәндә генә булып, ГУМ, ЦУМ кибетләре белән метродан башканы күрә дә алмый, шунлыктан шәһәр үзе дә баш әйләндергеч ыгы-зыгылы, кырмыска оясыдай кайнап торган, тынгысыз булып хәтергә сеңеп калган иде.

Бу юлы Мәскәү Зуфирәгә бөтен гүзәллеге белән ачылды. Алар Кремльдә йөрделәр, бакчаларда ял иттеләр, тын урамнарга барып чыктылар, хәтта ишегалларына кереп, бизәкләп эшләнгән борынгы биналарга соклandылар. Йөреп арыганнан соң, Музыкаль комедия театрында «Шат күңелле тол хатын»ны карадылар. Юл уңаеннан Өмит Зуфирәгә бер бәйләм чәчәк алып биргән иде. Спектакль тәмамлангач, Зуфирә аны, залдан үрелеп, сәхнәгә ыргытты. Монда чәчәкләрне күтәреп сәхнәгә менмиләр, ыргыталар гына икән.

Гостиницага кайтканда Кызыл мәйдан аша үттеләр. Халык аз, мәйдан тыныч иде. Билгесез солдат каберенә кертмиләр иде инде, ләкин ниндидер чит ил делегациясе өчен ачтылар, аларга

ияреп, Өмит белән Зуфирә дә кереп киттеләр. Төн караңгылыгында зураеп, көчле булып тоелган ут, ялкын телләренең шома мәрмәр ташларда чагылышы, тау булып өелеп торган чәчәкләрнең хуш исе, матур сын кебек хәрәкәтсез басып сакта торган солдатларның тантаналы кырыслыгы – болар барысы да үзе бер спектакль кебек тәэсирле иде.

Аннан соң туры гостиницага кайтасы килмәде. Алар Арбат урамы буйлап киттеләр.

Урамда җан иясе юк, көндезге ыгы-зыгының эзе дә калмаган, Зуфирә белән Өмитнең аяк тавышлары гына таш биналарның стеналарына бәрелеп яңгырый. Бизәп, сырлап, шул ук вакытта мәңге торырлык итеп нык салынган борынгы йортлар үзләрен төзегән, үзләрендә яшәгән һәм яннарыннан узган күп буын кешеләренең язмышын, хыялларын, йөрәк хисләрен саклый иде шикелле. Алар тавышсыз гына кыйсса сөйли, бу кыйссаны Зуфирәнең бүген гаҗәп нечкәреп, сизгерләнеп киткән күңеле генә аңлый кебек иде. Ләкин бер Зуфирәнең генә түгел икән.

– Ташка түгел, кешеләрнең йөрәкләренә баскан кебек. Шулай бит? – диде Өмит, пышылдап, әйтерсең лә йортларның кыйссасын өзүдән куркып. – Бер уйласаң, безнең гомер юлына бик күпләр үз йөрәкләрен түшәп калдырганнар бит. Беринг кебекләр һәр өлкәдә булган һәм алар алдагы буыннарның, ягъни безнең барыр юлыбыз такыр булсын өчен тырышканнар. Без яхшырак яшәсен, нәтиҗәлерәк эшләсен өчен, безгә җир читенә бару, диңгезләрдә йөзү җиңелрәк булсын өчен. Мин үзем дә, киләчәк буынның барыр юлына бер таш сала алсам иде, дим. Шунда гына кеше үзен бәхетле саный ала һәм Беринг шикелле яки Муса Җәлил кебек, үлгәндә дә, елмаеп, якты күңел белән үлә ала. Бу, әлбәттә, җиңел генә бирелми. Моның өчен күп нәрсәне, ә кайчак үзеңне корбан итәргә туры килә.

Әңгәмә үз җае белән көндәлек яшәешкә, шәхси тормышка килеп ялганды. Югары максатларга ирешү тырышлык кына түгел, корбаннар да таләп итә. Беренче чиратта гаилә тормышында кыенлыкларга, хәтта югалтуларга дучар ителәсең...

– Гаиләне арткарак чигендерергә туры килә шул, – диде Өмит. – Минем хатын да иҗат кешесе, тынгысыз җаннардан. Артистка. Сәнгать корбаннар сорый дип, бала булдырырга ашыкмады. Аннары мин – диңгездә, ә ул һаман театрда эзләнә... Эзләнгәндә киңәш-ярдәм кирәк, ә ире ерак... Ярдәмчеләр якыннанрак табыла андый чакта. Хәзер инде мин диңгездән кайткан айларда да очрашмыйбыз... Гаиләне корбан иттек, ә максатка ирешә алмадык. Монысы бераз зарлануга охшап китте бугай. Гафу итегез...

Ул, иелеп, Зуфирәнең кулын үпте. Сулышы бармакларны өтеп алгандай итте.

...Өмитнең самолеты иртүк очты, Зуфирәнең берничә сәгать көтәсе бар иде әле. Капитанның билетын яздырып, чемоданын тапшырып чыккач, икесе дә бу аерылуның озакка икәнлеген, ә бәлки, моннан ары мәңге очрашмаячакларын аңлап, балалар шикелле, кулга-кул тотынышып, читкәрәк барып бастылар. Алар кинәт икесе дә йөрәкләренең бер-берсенә нык җепләр белән бәйләнгәнен тойдылар. Менә хәзер ул җепләр өзеләчәк, алар инде өзелә дә башлаган, һәм йөрәктәге җәрәхәтләрдән кан саркый иде кебек.

Зуфирә, бизгәк тоткандай, бөтен тәне белән калтыранды, моны Өмиткә сиздермәскә тырышты.

– Ә син үзеңне янар таулар яктысында сынап карарга теләмисеңме? – диде Өмит. – Эзлим, таба алмыйм, дисең... Андый чакта, бөтен кысаларны җимереп, читкә китәргә, үзеңә, тормыш рәвешеңә, кешеләргә читтән торып карарга, яңа урында, яңа кешеләр арасында булырга кирәк... Ничек уйлыйсың?

– Ә нигә соң хәзер үк үзең белән бергә китәргә тәкъдим итмисең? – Зуфирә шаярган сыман елмаерга тырышты, ләкин иреннәре агач кебек хәрәкәтсез калганын тойды.

– Ерак рейсларга бик зур әзерлек белән, һәммәсен төптән уйлап чыгарга кирәк, Зуфирә... Әгәр дә син үзеңдә шундый әзерлек, тәвәккәллек тойсаң, хәбәр итәрсең, яме? Мин сине үз корабыма алырмын. Без, диңгезчеләр, матурлыкка, сәнгатькә бик сусыйбыз һәм аның кадерен дә беләбез. Ах, нинди кешеләр белән таныштырырмын мин сине! Бер Николаев кына ни тора! Исеңдә тот, Зуфирә: бәхетнең зурысы кыюларга, тәвәккәлләргә генә килә.

Ике якка да ачылган пыяла ишектән самолетка утыручыларны гына чыгаралар, озатучыларны үткәрмиләр иде. Өмит, халык арасында ашыгып иелеп, Зуфирәнең ирененнән үпте – гүяки аның йөрәгенә үз тамгасын салгандай итте. Зуфирә ике ягы да пыяла озын коридор буйлап аның ашыгып киткәнен карап калды. Әнә ул баскычтан төште, әнә зур автобуска утыра. Үзе күз алдында, ләкин арада пыяла, кычкырсаң да, тавыш ишетелми, теләсәң дә, туктатып булмый. Өмит, борылып, карашы белән аны эзләде, ләкин табалмады. Ничек күрә алсын ул Зуфирәне, йөзләрчә метрга сузылган пыяла тәрәзәләр бит ул, алар артында кайнаган меңләгән халык бит ул!

Автобус кузгалгач кына Зуфирәнең исенә төште: ул Өмитнең адресын алмаган иде...

* * *

– Зуфирә!

Бу юлы Эльвир чалбарын киеп кергән. Хатыны җавап бирмәгәч, караватын янына ук килеп, ак җәймә аша аның аягыннан тотып тартты.

– Зуфирә, дим! Тор әле!

Халидә уянган иде, билгеле, ләкин шым гына ята бирде, эш бу дәрәҗәгә җиткәч, атасы белән анасы арасына кысылуны яхшысынмады.

– Ни кирәк?

Эльвир, артка чигенә төшеп, караңгыда бик зур күренгән кулы белән үзенә таба кат-кат ишарә ясады:

– Чык әле! Бер генә минутка!

Зуфирә ашыкмый гына йомшак, җылы халатын алып киде. Чәчендәге тасманы сүтеп, кулы белән сыпыргалады. Зал ягына чыгып, ут кабызды.

– Кирәкми, кирәкми! – диде Эльвир, күзләрен чет-чет йомып. – Нәрсәгә кабызасың, гәзит укымабыз ла!

– Мөнәсәбәтләрне яктыртырга кирәк бит! Кат-кат керәсең, кызыңнан оялыр идең, ичмасам!

– Нәрсә оялырга! Уртак балабыз.

Эльвир хатыны белән башкачарак сөйләшергә ниятләп куйган иде булса кирәк, шактый сүрелгәне сизелде. Ә бәлки, сөйләшергә булмагандыр нияте. Ул теләгәнен күбрәк ишарә, караш, хәрәкәт, ахыр чиктә җыр, моң белән аңлата. Бу юлы да кочакламакчы булып Зуфирәгә үрелде.

– Сабыр!

Зуфирәнең боздай салкын сүзеннән дә бигрәк, йөзеннән, күзләреннән сирпелгән ят итү ирне чигенергә мәҗбүр итте.

– Йә, ни сүзең бар?

Эльвир, диванда таралып яткан ак җәймәгә утырып, чигәләрен ике учы белән уды. Бу минутта аны берничек тә ресторан сәхнәсендә, салават күпере биегән экран фонында, озын, сизгер бармаклары белән ялтыравык аккордеон клавишларына басып торган һиммәт егет дип күз алдына китереп булмый иде. Ярдәмгә мохтаҗ, көчсез, кызганыч бер малай булып күренде ул, хәтта кечерәеп киткәндәй иде. Зуфирәнең күңелендә ихтыярсыз, аның янына утырып, чигәгә кысылган кул аркаларын, чәчләрен сыйпап юату теләге уянды. Кешеләр күңелендә үзенә карата шундый тойгы уятырга оста иде Эльвир. Күрәсең, бу осталык та түгелдер, табигать биргән сәләттер... Зуфирә шуны уйлап, күңелендәге кызгану хисен басарга тырышты, ире янына түгел, өстәл кырыендагы урындыкка утырды.

– Эльвир, Беринг дигән кешене беләсеңме син?

Эльвир сорауны ишеткәнен белдермәде, чигәләреннән кулларын алмады.

– Даниядә туып үскән ул. Туган җирендә яшәргә дә яшәргә иде рәхәтләнеп. Ә ул никтер Россиягә килә, аннары аның иксез-чиксез көнчыгышына. Каторжаннарны Себергә җибәрә торган якка. Үзе теләп себер китә, дияргә була. Кораблар төзеп, Камчаткадан ерак диңгезләргә чыгып китә. Җилкәнле корабларда билгесез диңгезләрне гизгән бик күпләрнең һәлак булганын белә ул. Әмма бу аны куркытмый. Ахыр чиктә ул да билгесез атауда үлеп кала. Минем шуны беләсем килә: нәрсә мәҗбүр итте икән аны, рәхәт тормышны ташлап, әллә кая, җир читеннән ары чыгып китәргә?

Эльвир, башын күтәреп, аңа хәйран калып карады.

– Әллә саташа башлагансың инде, – диде, ниһаять. – Әни чире сиңа да йогып калды мәллә? Ниткән Дания? Нинди Беринг? Нәрсә син төн уртасында мәктәп дәреслеген сөйләп утырасың?

– Башымнан чыкмый.

– Бүтән кайгың булмагач, баш катырырга анысы да ярап тора инде...

Зуфирәнең сәер соравы Эльвирның уйларын чуалтты. Ул бераз зиһенен җыя алмый утырды.

– Адаштырдың син мине, бөтен тормышымны болгатып бетереп ташладың, – диде, ниһаять, сызланып. – Әгәр кеше төсле булсаң, мин дә бу хәлгә төшмәс идем.

– Син нәрсә, безне ташлап чыгып китүеңә мине гаепләмәкче әллә?

Төрлесен көткән иде Зуфирә, әмма мондыйны ук ишетермен дип һич уйламаган иде.

– Синең бу Беринг турындагы кыйссаларыңа, иҗат, тормыш мәгънәсе, максат дип туктаусыз кыбырсуыңа таш күңелле адәм дә чыдый алмас, билләһи! Үзеңнән дә, миннән дә даһи ясамакчы бит син! Кешечә генә яшәү җитми! Һаман буй җитмәгәнгә үрелеп җан тартышу... Инде буең җитмәсенә ышангач, кулыңны аска төшерергә, тартышудан туктарга кирәк! Тәнеңә дә, җаныңа да ял бирергә! Дәреслекләрне бик яхшы беләсең бугай, Тукайның «Төлке белән йөзем җимеше»н хәтерлисеңдер. Буй җитмәгәч, хайван да: «Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр, – ди. – Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә анлар, – ди». Буй җитмәгән әйбер эчкә килешми ул!

– Син, шул төлке шикелле, буй җитмәгәнне хурлап юанасың инде алайса.

– Соң, төлкедән дә ахмаграк түгел инде!

– Минем югарыга үрелүем һәм сине дә шуңа этәрүем эчеңә тигән дә, тынычрак урын эзләп, миннән китеп баргансың инде алайса. Шулай димәкчеме син?

– Ниһаять, үзең дә аңладың.

– Ә менә син мине аңламадың. Беринг юлыннан китәргә уйлап торам әле.

– Кая дисең?

– Еракка, җир читенә. Камчаткага, ә бәлки, аннан да арыдыр...

Эльвир, шаяртмыймы бу дигәндәй, аның күзләренә балаларча беркатлылык белән тутырып карады. Зуфирәнең үзәген өзә торган иттереп, акылдан шаштыра торган иттереп... Карады, уйланды.

– Ә, чыннан да, әйбәт фикер бит бу, – диде аннары. – Ничек моңарчы башка килмәгән. Урын алыштыру начар түгел. Җир читенә олагуның кирәге юк анысы. Аннан башка да әйбәт урыннар бар бит. КамАЗ шикелле үсеп, күтәрелеп килгән яңа калалар күпме. Йортлары салынып тора, тулай торaклары бар, Культура сарайларын, башкалардан уздырып, мәрмәргә төреп торгызалар. Һәммәсен уздырырга тырышып җырлыйлар, бииләр... Биетүчеләр кирәк анда, җырлатучылар... Минем ишеләрне кочак җәеп каршы алачаклар, барып, аккордеонны гына тартып күрсәтәсе...

– Ресторaннарның да бик шәпләрен җиткергәннәр, ди, анда, – диде Зуфирә, ачы көлемсерәп.

– Әйе, анысы да идея... – Шуннан соң гына Эльвир, хатынының кинаясен аңлап, күзен тутырып карап куйды.

– Күрәсең, безнең юллар төрле икән, – диде Зуфирә салкын гына. – Болай булгач, тәмам ачыкланды мөнәсәбәтләр. Инде хәзер тынычлап йокласак та була.

– Зуфирә!

– Минем башка кешем бар, Эльвир...

– Башка кешең? – Эльвир уйланып торды. Башка кешесе булса, Зуфирә аны – Эльвирны кертер идемени? Шуны уйлагач: – Кем ул? – дип сорады. – Кайда ул? Камчаткадамы әллә?

– Әйе, Камчаткада.

– Соң ул безнең очрашканны белми дә калачак бит? Аннан аңа ни зыян?

– Аннан зуррак шаһит бар монда, – диде Зуфирә.

– Кем?

– Минем вөҗданым. Вөҗданым, Эльвир! Аннары минем үткәннәрне кабатлыйсым да килми, сиңа күптән күңелем сүрелде инде.

Кире чыгып яткач, Зуфирә эченнән генә тагын шул ук сүзләрне кабатлады: «Үткәннәрне кабатлыйсым килми». Чыннан да, әгәр ул Эльвир белән килешсә, тагын бергә тора башласа, ни булыр? Өр-яңадан һәммәсе кабатланыр: ничек тә булса ярашып яшәргә тырышу, баштарак Эльвирның күпмедер тыелуы, аннары тагын салгалавы, тагын хыянәте... Тик бер узган юлны кыска арада, тиз үтәчәк ул.

Бер үк кантарлы сукмакны кат-кат таптаудан ни мәгънә? Гомер болай да кыска бит. Ничек диде әле Өмит? «Бәхет фәкать кыюларга, тәвәккәлләргә генә бирелә». Ә кыюлар, тәвәккәлләр гел яңа юллардан йөриләр...

Ул чакта, көньякта, Анапага баргач, Зуфирә үзе дә бу сүзләрнең раслыгын сынап караган иде.

Анапада ул «Биек яр» дигән турбазада ял итте. Аннан бер төркемне җыеп туристик походка алып киттеләр. Аркага авыр биштәрләр асып шактый юл уздылар алар. Диңгез буендагы бормалы-сырмалы, үрле-таулы сукмаклардан, ташлыклардан, комлыклардан, урман каплаган яшел калкулыклар күкрәгеннән...

Арып-талып, тиешле урынга барып җиткәч, кич белән учаклар ягып, шашлык кыздырырга кереште халык. Учак биек калкулыкта булганга, аннан диңгез күренми иде.

Төнлә Зуфирә диңгездә коенырга булды. Аңа иптәшкә кеше табылмады, бары тик бер кыз белән бер егет озата барырга ризалык бирделәр.

Алар текә үрдән аска төштеләр. Яр буеннан караганда, өстә калган туристлар да, учак та күренми иде, егет белән кыз үр ышыгына басып сөйләшә калдылар, Зуфирә су янына ук килеп чишенде.

Диңгез сулыш алгандай пышылдый, салмак дулкыннар вак ташлы ярны ялап-ялап уза иде. Серле, шомлы иде диңгез, тулы ай аның серлелеген генә көчәйтә, ерактагы корабның прожекторы, караңгылыкны пычактай ярып, су өстен саргылт нур канаты белән сыпырып үтә дә кинәт сүнә, тирә-юнь тагын да шомлырак булып кала иде.

Дөньяда бары ай, диңгез, Зуфирә генә иде шикелле. Салкынча су тәнне көйдереп алды, дулкыннар, аны эчкә кертергә теләмәгәндәй, ярга этәрде. Ул колач җәеп алар кочагына ташланды. Ә эчтәрәк дулкыннар аны иркәләп тирбәтте, бөтен тәнне хәрәкәт шатлыгы биләп алды, шул ук вакытта астан, кара су төбеннән нинди дә булса куркыныч җанвар килеп аяктан эләктереп алыр шикелле, күңелне курку да, үзеңнең куркуыңны җиңү куанычы да биләп алган, җырлыйсы килә, тантана итеп кычкырасы килә. Зуфирә колачын җәеп җибәргән саен, суда көмеш тәңкәләр сибелә. Нәрсә бу? Нинди тәңкәләр? Бу – Зуфирә ачарга тиешле сер иде.

...Иртәгесен тагын коенганда, сер ачыкланды: колач җәйгән саен сибелгән ул тәңкәләр – һава куыклары икән, алар ай яктысында шулай җемелдәп күренгән икән...

Соңыннан, Казанга кайткач, Зуфирә бу хакта Өмиткә язып җибәрде, бер бит тутырып рәсем ясады, анда йөгерек дулкыннарны, тулган айны, прожектор нурын, көмеш тәңкәләр чәчеп йөзгән үзен сурәтләде.

Әйе, саубуллашканда ул Өмитнең адресын сорарга онытkan иде, инде аны мәңгелеккә югалттым дип сызланган иде.

Көньяктан кайтып, журнал редакциясенә баруга, аның кулына конверт тоттырдылар. «Рәссам Зуфирәгә» дип язылган. Рәссам Зуфирә аны алгач, үз күзләренә үзе ышанмый торды. Өмит... Тапкан бит менә җаен, торган бит сүзендә. Андый егет тапмыймы соң, онытамы соң әйткән сүзен!

Җир читенең аръягыннан хатлар озак килә, ләкин алар бер-берсеннән җавап көтеп тормыйлар, җаннары теләгән саен язалар иде. Ә җан теләмәгән көн булмады. Соңгы елда Зуфирәнең иң бәхетле минутларына әверелде ул вакыт – Өмиттән хат алу һәм, кич утырып, чит-читләренә сурәтләр ясап, хатлар язу.

*«Синең хатларың рәсем ясалган матур хикәя шикелле,* – дип язган иде бер хатында Өмит. – *Зинһар, ешрак яз, плавбазага барган саен, буш кул белән кайтырлык булмасын. Миннән сәлам килми торса, үпкәләмә, океанда почта йөри торган шома юллар юк. Ә мин үзем синең хатларыңны һәр кичне дога урынына укыйм, шуннан соң матур төшләр керә».*

Зуфирә аның хатларын сүзен-сүзгә хәтерли. Менә әле хәзер дә, күзен йомып, күңеленнән укый:

*«Америка ярлары буенда сельд тотабыз. Монда безнең белән янәшә бик күп судноalar тора, төрлесе төрле илләрдән. Поляклар, инглизләр, немецлар, шведлар... Төнлә бөтенесендә утлар кабына, су өстенә тулы бер кала салып куйганнар диярсең».*

Зуфирә ул каланы аермачык күргәндәй була: биек-биек ак кораблар, аларда янган төрле төстәге утлар, ул утларның суда чагылышы – әкияттәгедәй матур күренеш.

*«Өч көн инде туктаусыз дулкын котыра, яңгыр коя. Безгә көненә өч тапкыр куе ботка пешерәләр, сыек аш пешереп булмый, казаннан чайпалып түгелә. Мондый чакта эш туктый, күңел төшенке була. Әле бүген карап торам, ашаганда өстәл аша кара-каршы утырган ике матрос әйткәләшеп алдылар: «Авызыңны чапылдатмый гына ашый беләсеңме син, юкмы?» – ди берсе. «Мин синең колагың селкенгәнгә чыдап утырам бит әле, сүз әйтмим», – ди икенчесе. Бер-берсенә бүре кебек карыйлар, ә ярга чыккач карасаң, алардан якын дуслар юк. Менә бит ул эшсезлек һәм кысанлык нишләтә кешене! Ләкин мин күңел төшенкелегенә бирешмим, судноның кайбер механизмнарын яхшырту турында тәкъдимнәр ясамакчы булам, шуларны уйлыйм, китаплар укыйм, иң мөһиме, синең хатларыңны укып юанам».*

География дәреслегендә шундый бер рәсем бар: түгәрәк Җир шарының ике ягында ике кеше басып тора, аларның аяклары бер-берсенә юнәлгән. Зуфирә үзе белән Өмитне дә шулай итеп күз алдына китерә иде: алар Җир шарының икесе ике ягында торалар, һәм аларны аерган бу шар кечерәйгәннән-кечерәя бара шикелле. Зуфирә хәтта аның йөрәк тибешен, аның сагышын һәм януларын тоя сыман. Бер-берсенә якын күңелләрне Җир шары да ерагайта алмый икән.

*«Балык килә, балык, күтәреп кенә өлгер! Егетләр палубада терекөмеш кебек тәгәрәп кенә йөриләр, күз өлгерми. Бөтенесе җан-фәрман эштә. Мондый чакларда безнең кәеф шәп инде. Бүген тагын плавбазага барачакбыз, синең бер кочак хатыңны берьюлы алырмын дип алдан ук сөенеп йөрим».*

Зуфирә үзе дә тормышында булганның барысын язарга тырыша, ләкин хатлары Өмитнеке кебек үк кызыклы, дәртле түгелдер кебек тоела. Ничек яшисең бит!

*«Бүген мин зур гына бер язучыбызның юбилеенда булдым әле. Китапларына рәсемнәр ясаган рәссам буларак, түргә утырттылар. Язучы белән хатыны менә болай утыралар иде* (рәсем), *кешеләр менә болай күңел ачтылар* (бииләр, җырлыйлар – рәсем). *Күрәсеңме, бөтен кеше парлы-парлы, мин генә моңлы-зарлы* (рәсем). *Ләкин мин бирешмим, сине исемә төшерәм дә борынны югары күтәрәм* (рәсем). *Соңыннан тын урамнардан берүзем ялгыз кайттым. Кызганыч, без синең белән Казан урамнарыннан бергәләп уза алмадык. Аларга түшәлгән йөрәкләр зар елап, горурланып, сагышланып һәм мактанып ниләр генә сөйләмәс иде безгә! Биналарның тавышсыз кыйссасын ялгызым тыңладым. Аларның ак стеналарына агачларның кара күләгәләре матур бизәк булып төшкән иде. Җил искән саен, бизәкләр тирбәлә – ак стенада кара бизәкләр... Үзләре тере, үзләре катлаулы, нәфис... Безнең борынгы бабаларыбыз милли нәкыш үрнәкләрен шундый бизәкләрдән алганнар бит инде – үләннәрнең, чәчәкләрнең, агачларның чагылышы ул нәкыш».*

Хатлар аларны бер-берсенә торган саен якынайтты, газиз, кадерле итте.

Алар инде очрашырга тиешләр, очрашмый кала алмыйлар, бу хакта хат аша килешеп тә куйганнар иде. Август аенда Өмит Камчаткадагы «Начики» дигән курортка ике путевка алып куячак һәм Зуфирәне кайтып алып китәчәк. Август – Камчаткада иң матур ай. Тыныч, җылы. Үләннәр кешедән биек булып үсә. Анда гына үсә торган татлы кара бөрлегәннең өлгергән чагы. Әле менә газеталар Камчаткада өр-яңа янар тау ата башлаган дип язалар. Тарихта күрелмәгәнчә, әллә

ничә авыз ясап ата икән. Өмит яза, аны барып карарбыз, ди. Гейзерлар үзәнендә йөрербез, кайнар күлләрдә коенырбыз, Тын океанга барырбыз, ди.

Күп көтәсе калмады, бер-ике атна гына. Дөрес, көнен атап язмый Өмит, ул хәтле ерактан кайчан кайтып җитәреңне алдан төгәл белү кыен шул. Кайтыр алдыннан телеграмма бирер. Зуфирә аны аэропортта каршы алыр.

Ул, шуларны уйлап, үзалдына елмаеп, татлы йокыга талды.

* * *

Иртәгесен Зуфирә, Эльвир белән кызы торганчы ук җыенып, әзер рәсемнәрне редакциягә илтергә китте. Журналның рәссамы, ак, ачык чырайлы, йомшак тавышлы Зәбир рәсемнәрне яратты, мактап кабул итте. Бүлмәдә тагын ике хатын-кыз утыра иде. Тәмам очынган Зуфирә, аларга борылып:

– Бәхетле кеше күрәсегез киләме? – диде.

– Килә, – диделәр, гаҗәпләнеп.

– Карагыз – мин ул! Камчаткага китәм!

– Камчаткага?

Эшләрен ташладылар, җанланып сораштыра башладылар. Ник бара? Озаккамы? Ничек курыкмыйча кузгала?

Зуфирә биек бинаның тугызынчы катыннан Идел белән Казансуның кушылган җиренә, елга киңлегенә сузылып яткан дамбаларга, аркасын бөкрәйтеп яткан күперләргә, йортлар арасында яшелләнеп яткан сазлыкка карады.

– Кайчан да булса бер кузгалырга кирәктер бит. Югыйсә соң булмагае!

Бүлмәгә торбалап төргән кәгазьләр күтәреп, кайчандыр Зуфирә белән бергә художество училищесын тәмамлаган, хәзер абруйлы график һәм ярыйсы гына картиналар авторы Илдус Зәйнуллин килеп керде. Күперенке бөдрә чәчендә ак бөртекләр күбәйгәннән-күбәя бара, калын иренле, киң борынлы түгәрәк йөзендә җыерчыклар пәйда булган, бил тирәләре калынаеп килә. Ләкин шуңа карамастан Илдус яшьләрчә киенеп йөри: кысып торган джинсы, шулай ук кысып торган чәчәкле күлмәк. Алай да бу кием аңа килешә, рухы яшьлеген белгертеп тора иде.

Илдус төргәкләрне бүлмә идәненә җәеп салды. Мәскәүгә күргәзмәгә җибәрергә дип әзерләгән картиналары икән бу.

– Туп-турысын әйтегез: кешегә күрсәтерлек җире бармы? – диде. – Анда йөз кызартканчы, монда дөресен беләсем килә.

Барысы да, Зуфирәне онытып, рәсемнәр өстенә иелделәр.

Кәгазь битләренә акварель белән КамАЗ күренешләре сурәтләнгән иде. Илдус анда төзелеш башланганнан бирле әледән-әле баргалап тора, барган саен дөнья хәтле портретлар, төзелеш күренешләре ясап кайта. Аның рәсемнәрендә актарылып ташланган, тау-тау итеп өелгән җир, төпсез чокырлар, ажгырып йөргән машиналар, ут чәчкән тимер эреткечләр, краннар, завод биналарының аркылы-торкылы тимерләре күп була, алар тирәсендә кырмыска кебек кайнашкан кешеләр кечерәеп кала иде. Гомумән, Илдусның картиналарында кискенлек, сызыкларның турылыгы, почмакларның катылыгы күзгә ташлана иде.

Дөрес, аның рәсемнәре бөек төзелештәге рухны, колачны, техниканың куәтен дөрес чагылдыра, шуның өчен рәссамны гел мактап торалар, сурәтләре альбомнарда, журналларда басылып чыга, төзелешкә керткән өлеше өчен медаль белән дә бүләкләнгән иде.

Ләкин сурәтләрдә, картиналарда күңел җылысы сизелми, Зуфирә әйтмешли, «аларга карагач, кешенең тәне чымырдамый» иде.

Бу сурәтләргә күз салу белән, Зуфирә бер нәрсәне тоеп алды: рәссам монда бөтенләй башкача язган, йөрәк җылысы белән сугарган. Аларга караган саен карыйсы килә. Менә бер яшь пар дуслары белән бергәләшеп истәлеккә карточкага төшәләр. Кияү белән кәләш кенә туй киемнәреннән, калганнары комбинезоннардан, яшь пар загстан туры эш урынына килгән булса кирәк.

Менә автобус эче, халык эшкә бара, каска кигән, билләренә чылбыр ураган монтажниклар басып тора. Урындыкта сырган бишмәтен биленнән кысып бәйләгән, шәлен кысып ураган бер кыз. Төзүче. Кулында тал бибиләре, йөзендә яшьлек язының ашкынулы яктысы...

– Мин сине мондый дип белми идем, – диде Зуфирә Илдуска.

– Кешене белмәү гаҗәпмени, без күп вакытта үзебезне үзебез дә белеп бетермибез.

...Зуфирә кайтканда өйдә Халидә генә, бүген ул эшкә икенче сменага барачак иде. Эльвирның да портфеле белән аккордеоны тора, үзе юк.

Зуфирә алдына кәгазь салып, акварель буяуларын якынрак тартты. Пумаласын алды. Эчке бер дулкынлану белән беренче сызыкны салды. Илдусның иҗатында «теле ачылган». Зуфирәнең дә «теле ачылырга» тиештер бит инде!

Кәгазьдә нык иякле кырыс йөз калкып чыкты, зәңгәр күзләр нур чәчеп, Зуфирәгә төбәлделәр, йөзнең кырыслыгын киметеп, кара кашлар дугаланып өскә күтәрелде. Аның баш очыннан салават күпере сузылды, яннан күбекләнеп дулкын күтәрелде...

Халидә әнисе янына килеп басты.

– Әни, әни, дим! Мин күрдем бит бу кешене! Нәкъ үзе!

– Кайчан күрдең, кайда?

– Бүген күрдем, үзебездә.

Зуфирә, гаҗәпләнеп, башын күтәрде.

– Ялгышмыйсыңмы?

– Билләһи менә! Ишектә рамдагы шикелле итеп басып тора иде.

– Кайчан?

– Бүген! Син чыгып киткәч! Мин юына идем. Шалтыраттылар. Шуннан... теге барып ачты. Ишетәм, сөйләшәләр. Ванный бүлмәсеннән чыксам, ул нәкъ рамдагы кебек басып тора. «Эштә ул, эштә», – ди... теге. «Ә сез аның кеме буласыз, абыйсымы?» – дип сорады капитан.

– Шуннан, шуннан ни дип җавап бирдегез?

– Миннән сорамады ич! «Мин аның ире», – дип җавап бирде теге...

– Ничек дип?

– Ну... шул инде. Әни, тукта әле, нәрсә син, ни булды? Ну, әйтсә әйтте инде...

– Шуннан... капитан ни диде соң?

– Сәлам әйтерсез, диде бугай. Ну хәтерләмим инде. Хушыгыз, диде кебек. Борылды да китеп барды.

– Ә син, син авызыңны ачып карап калдыңмы?

– Нишләргә тиеш идем соң мин? Әни... тукта әле... Ну, китте... Тагын килер...

– Берәр язу да калдырмадымы?

– Мин күрмәдем. Эчтә тора идем. Әни, дим!

Зуфирә бүлмә буйлап әрле-бирле йөрергә кереште. Бу ни була инде... Өмит кайткан, килгән, монда Зуфирәнең ире белән очрашкан... Кайда ул? Ни уйлап киткән? Килерме тагын? Нишләп йөрсен инде ир өстенә!

Башына шушы уй килгәч, Зуфирә бөтен ачыклыгы белән хәленең аянычлыгын аңлады. Өмит кайткан, ул Казанда, бәлки, бик якындыр, янәшә урамдадыр, ләкин Зуфирә аны берничек тә эзләп таба алмаячак. Ул хәзер Җир шарының каршы ягындагыга караганда да ераграк, чөнки хат та язып булмый...

Кич җиткәч, Эльвир килеп керде.

– Әйт әле, ник син үзеңне минем ирем дип игълан иттең?

– Ә кем соң мин сиңа? Туганың түгел ләбаса!

– Бүген үк чыгып кит, ишетәсеңме? Хәзер үк эзең булмасын!

Хәлбуки Зуфирә үзе дә аңлый: тузынудан ни файда? Ат урлаткач, абзарны бикләдең ни дә, бикләмәдең ни!

Эльвир чыгып китте, берәр сәгать урамда йөреп керде дә тагын кунарга калды. Аның белән ызгышып йөрүдән мәгънә юк иде инде, Зуфирә төн буе янында яткан кызын борчымаска, әйләнмәскә тырышып, ак түшәмгә карап ятты. Көн яктыруга торып чыгып китте. Ә сәгать сигезгә редакция ишек төбенә барып басты.

Һәрвакыт күтәренке күңелле Зәбир эшенә вакытында килә иде. Лифтта менгән арада ук, Зуфирә аңа йомышын әйтеп бирде. Капитан Гасимовны эзләп табарга кирәк, ничек булса да!

Зәбир аны серле елмаеп тыңлады.

– Кеше энә түгел, табылыр, – диде. – Аэропорт кассасыннан белешеп була. Әгәр Камчаткага билетны моннан алса, аның кайсы рейс белән очасын шартлатып әйтеп бирәчәкләр. Кассада таныш бар безнең. Хәзер шалтыратып карыйк, редакция үтенеп сорый, диярбез...

Чыннан да тиз ерып чыкты ул моны – Гасимов Өмитнең кайсы рейс белән Камчаткага очасы тәгаен мәгълүм булды. Ике көннән китәчәк икән.

Сәгатьләрне генә түгел, минутларны санап көтте Зуфирә. Минуты – ай, сәгате – ел, дигәннәре шулдыр, үтми җәфалады вакыт.

Зуфирә иртүк базарга барып, бер кочак чәчәк сатып алды. Ак, ал, кызыл, шәмәхә гладиолуслар. Озату хөрмәтенә түгел, очрашу бәйрәме итеп бирер ул аларны Өмиткә. Чәчәкләр белән бергә үзе аның күкрәгенә сыеныр, кеше-карадан да кыенсынып тормас... Тик аймылыш кына була күрмәсеннәр, очрашсыннар гына! Өмитне билетын алыштырырга күндерер, инде башка чара калмаса, үзе шушы кечкенә сумкасын тоткан килеш аның белән бергә утырып китәр...

Ян стеналары тоташ пыяладан булган вокзалның бусагасын атлап керүгә күреп алды аны Зуфирә. Кешеләргә бәрелә-сугыла аңа атылды. Ләкин нишләп соң әле капитан, йөзе белән аңа борылган килеш, бер хәрәкәтсез тора, нигә аңа каршы килми? Күрә бит ул аны, күрә... Нишләп соң

әле ул, Зуфирә якын килгәч, бөтенләй читкә борылды? Янәшәсендәге чал чәчле апага иелеп, нәрсәдер сөйләгән булып кылана?!

Зуфирә әле һаман берни аңламыйча, аңларга теләмичә, чәчәкләре белән аның китель җиңенә тегелгән сары тасмаларны сыдырып узды. Ә капитан чал апаның беләгеннән эләктереп, читкәрәк алып китте. Хәер, әнә Зуфирә тарафына күз сирпеде. Ияге белән ишеккә ымлады. Тышкы ишеккә... Бу ни дигән сүз? Күз алдында буталып йөрмә, чыгып кит, диюеме?

Ул Зуфирәне теге апага күрсәтергә теләмиме әллә? Ник? Ни өчен? Зуфирә узган елны да ул апаның Өмитне озатып калганын исенә төшерде. Кем ул? Өмитнең әнисеме, апасымы? Әллә тагын башка берәр туганымы? Хәер, «ирле хатынны» ничек инде туганнары белән таныштыра алсын ул? Гомумән, кемне дә булса туганнарга күрсәтү бик җаваплы эш, ул яшьрәк чакта гына җиңел эшләнә, олыгайган саен моңа җаваплырак карыйсың. Шулай булгач, Өмиткә үпкәләп буламыни? Шул ук вакытта алар каршына барып, бу чал чәчле карчык алдында Өмиткә: «Кичә минем өйдә сиңа очраган кеше ул минем ирем түгел, аерылган ирем генә», – дип аңлатып торып буламыни? Кем ышансын андый мәгънәсез сүзгә?

Шулхәтле якын, сөйкемле булып күренде Өмит бу минутларда һәм шулхәтле якын килеп булмаслык ерак иде ул.

Зуфирә кая басканын да сизмичә, кемнәрнеңдер чемоданнарына яны белән бәрелеп, аэровокзалдан чыгып китте. Аулак урын эзләп, кафе бинасы артына ук кереп качты һәм чәчәкләренә капланып елап җибәрде... Бераз күңеле бушагач, башын күтәреп, яшь аралаш биек койма артындагы такыр кырга – аэродромга карап тора башлады. Әнә ул кырның аргы башыннан, гөрелтесе белән бөтен тирә-юньне тетрәтеп, зур самолет күтәрелде. Кемнәрнең сөйгән ярларын алып күккә ашты икән? Әнә койма кырыннан гына сузылган юл буйлап, район үзәкләренә очучы кечкенә самолетларга пассажирлар ташый торган сары автобус пырхылдап узып китте. Аның тәгәрмәчләре күтәргән тузан Зуфирәнең юеш битенә, чәчәкләренә бөркелде.

Кинәт колакка аэродром дикторының «Мәскәү» дигән сүзе чалынды. Зуфирә дерт итеп китте. Нишләп тора әле ул монда? Өмит хәзер шушы самолет белән очып китәчәк бит!

Ул вокзалда юк иде. Теге апа ишек төбендә, Өмитнең таныш көрән чемоданы янында, як-ягына карангалап, басып тора. Күрәсең, Мәскәүгә очасы кешеләр чыгып китеп беткәннәр, ә Өмит юк, карчык шуңа борчыла иде бугай. Кая соң үзе? Әнә ишектән кабаланып килеп керде, йөзе нигәдер бик борчулы, үкенүле. Аны күреп, Зуфирә үзенең тагын бик аянычлы хата ясаганын аңлап алды: Өмит, мөгаен, аны эзләп йөргән, карчыктан читтә сөйләшергә теләгәндер. Ул күзе белән ишарәләп Зуфирәгә: урамга чык, шунда сөйләшербез, дигән булган! Ә Зуфирә, ахмак, кеше тапмаслык урында качып, суган суы сыгып торды. Соңыннан еларга вакыты булмас идемени? Инде хәзер соң иде, соң иде! Өмит аңа, сау бул дигәнне белгертеп, баш иде, карчык моны сизмәде, ул ашыга иде.

Алар икесе йөгерә-атлый вокзал аша кыр ягына чыгып, биек тимер койма буйлап самолетка утырта торган урынга киттеләр. Зуфирә ике куллап биек рәшәткәнең тимер таякларына ябышты. Чәчәкләр тимергә кысылып изелделәр.

Самолет баскычы янында басып торучы форма кигән ыспай гәүдәле кыз Өмитне ашыктыра иде. Баскычка менгәч, капитан борылып кул изәде. Зуфирә чәчәкләрен күтәреп болгады.

Өмит эчкә керүгә, ишек ябылды, баскыч аерылып читкә китте, самолет каты гөрелдәп, тетрәнеп урыныннан кузгалды да, борылып, әкрен генә тәгәрәп такыр кырның аргы башына юнәлде. Күп тә үтмәде, ул Зуфирәнең баш өстеннән очып үтте һәм Өмит белән ике араны минут саен күп чакрымнарга ерагайта башлады.

Шәһәр үзәгенә илтә торган троллейбуста Зуфирә чал чәчле апаны күздән ычкындырмаска тырышты. Кольцода төшкәч тә аның артыннан китте: шушы карчыкны күздән югалтса, Өмитне бөтенләй таба алмас кебек тоелды. Ичмасам, бер-ике авыз сүз алышасы иде. Карчыкка да ямансудыр, ул да якын кешесен озакка, еракка озатты бит. Өмитнең әнисе түгел микән әле...

Зуфирә, карчык артыннан ияреп, җир асты юлына төшеп китте, универмаг янына барып чыкты, ул утырган трамвайга сикереп менде. Карчык кассадан билет алганда, аның янына барып басты да:

– Гафу итегез, мин бүген аэропортта дустымны озаткан идем, – дип сүз башлады. – Сез дә шунда идегез, улыгызны озаттыгызмы?

– Юк, улымны түгел, сеңлемнең улын озаттым әле мин, – диде карчык, якты күзләре белән Зуфирәнең йөзенә туп-туры карап. Ул әйтерсең аның бөтен хәйләсен бик яхшы белеп тора иде. – Монда миннән башка туганы юк, үзләре Камчаткада яшиләр. Шуны бик ныгытып әйттем әле, моннан ары ялгызың адашкан каз шикелле йөрмә болай, дидем. Килен белән икәүләшеп, парлап кайта торган булыгыз, дип, колагына бик ныклап киртләдем. Килен бик әйбәт безнең, бик чибәр, тик соңгы елларны бәләкәй генә бозылышып алганнар иде бугай. Үгетләдем, килешегез, дидем. Икегез дә гөл кебек, арагызга керергә атлыгып торучылар күп булыр, дип әйттем. Дөнья булгач, төрлесе була, бозылышып та аласың, әмма дә ләкин яшьли сөешеп кавышканга җитми, дип әйттем...

Зуфирә, кабаланып:

– Ай, минем тукталышка җиткәнбез икән бит! – дип, ишеккә ташланды. Ашыгып төшеп калды да, каршы килгән трамвайга утырып, кире Кольцога китте, аңа кирәк автобусның тукталышы шунда иде.

Кайтты да биш бит тутырып хат язды. Ләкин җибәрмәде. Кәгазьгә язылган сүзләрдән ни мәгънә? Элегрәк арадагы Җир шары кечкенә, үтә күренмәле сыман тоела, Зуфирә аның аркылы йөрәге белән Өмитнең күңелен тоеп-сизеп тора иде кебек. Кинәт арадагы бөтен киртәләр – меңләгән чакрымнар, иксез-чиксез далалар, ерып үткесез урманнар, янар таулар, ташкын елгалар, океан дулкыннары – барысы-барысы үзләренең барлыгын сиздерде, алар артында Өмит юкка чыккандай булды. Бер генә чара калган иде: хат конвертына язасы адрес буенча барасы да, Камчатканың Петропавловск каласындагы Балыкчы Даны дигән урамны, андагы 17 нче йортны эзләп табып, 25 нче квартираның ишеген кагасы. Аны ачкан зәңгәр күзле кешенең күкрәгенә авып, күз яшьләреңә ирек бирәсе. Калганы аның ихтыярында булыр. Теләсә, яшәтер ул Зуфирәне, теләсә, аның гомеренә чик куяр. Чөнки ансыз яшәүнең бер кызыгы да юк Зуфирә өчен.

* * *

Касса тәрәзәсе артында утырган хатын:

– Камчаткага? – дип кайтарып сорады. – Сез анда яшисезме? Паспортыгызны бирегез. – Аннан карап, Зуфирәнең Казан кешесе икәнлеген белгәч: – Милициядән рөхсәт алып килегез, – дип өстәде. – Шунсыз без сезгә билет сата алмыйбыз. Чик буе зонасы ул.

– Ә рөхсәт булса, кайчанга билет булачак?

– Гадәттәгечә, егерме көн алдан сатыла билетлар. Милиция рөхсәтне ун көн эчендә әзерләп бирә.

Әйе, капитан Гасимовның сүзләре расланып кына тора: ерак рейсларга озаклап, ныклап әзерләнү тиеш...

Шактый күңеле төшеп, бер җәтмә азык-төлек күтәреп кайткан иде, лифт эшләми булып чыкты. Тугызынчы катка баскычтан йөгерә-атлый менеп бара иде, каршысына бөрешкән карчык тап булды. Ике куллап култыксага ябышкан, ах-ух килә, киез итек кигән аякларын көч-хәл белән өстери. Зуфирә йөгереп менгән шәпкә аның яныннан узып китте, аннары туктап, аска карады: «Йа Алла, бәхетем булып, озак яшәсәм, минем дә картаеп шушы көннәрне күрәсем бар бит әле. Ә бәлки, күп көтәсе дә калмагандыр... Барырсың аннары җир читенә!»

– Әби! Кая барасыз? Кибеткә булса, интегеп йөрмәгез, әйтегез ни кирәген, хәзер алып кайтып бирермен!

– Юк әле... уф... үземнең бер иреккә чыгып һава сулыйсы киләдер ие... уф... Таш капчыкта көн буе. Тын алыр хәл юк...

* * *

Унтугызынчы ноябрь көнне Камчаткадагы Петропавловск каласында көн шактый ямьсез иде. Соры болыт кисәкләре сопкаларга бәрелә-сугыла теткәләнеп каядыр ашыгып чаба, усал җил йортлар арасында тырпаеп калкып торган торбалардан ургылган кара төтенне өзгәләп очыра иде.

Сопка araларыннан боргаланып-сыргаланып сузылган урам буйлап килгән автобустан төшкәч, Зуфирә, көрсенеп, каршындагы бишәр катлы йортларга карады. Үз күзләре белән күрмәсә, Балыкчы Даны дигән романтик исемле урамны ул мәңге мондый дип уйламас иде. Җир читенә барып, нәкъ менә Казанның яңа районнарындагы кебек бертөсле шакмаклардан укмаштырылган типовой йортлар арасында йөрермен дигән уй аның башына да килмәгән иде.

Менә шушы урамга җибәргән бит инде ул үзенең сагыну-сагыш, өмет һәм ышаныч тулы хатларын! Шушында килгәннәр ул хатлар һәм шушы йортлар арасында, бүгенге ачы җил теткәләгән болыт һәм төтен кебек юкка чыкканнар... Һәрхәлдә, ул хатларга ике ай эчендә бер генә җавап та килмәде...

Ул таныш урам буйлап 17 нче йортка таба юнәлде. Таныш, чөнки ай буе таптый инде ул бу урамны, панель йортның көрәнгә буялган ишеген ачып, икенче катка әллә ничә тапкыр менде, йөрәк ярсуын басарга тырышып, ишек кыңгыравының коңгырт төймәсенә кат-кат, озак-озак басып торды. Әмма, кыңгырау күпме генә зыңгылдаса да, көрән ишек ачылмады, аның артыннан тавыш бирүче булмады.

Ләкин өметен өзми Зуфирә. Менә бүген, ниһаять, ул ишек ачылыр, бусага янында мәһабәт сынлы, зәңгәр күзле ир-егет күренер һәм ул Зуфирәне кочагына алыр дип ышана ул. Шуннан алар өй эченә керерләр. Зуфирә чәчрәп чыгарга торган күз яшьләрен тыярга тырышмас, яшь аралаш көлә-көлә үзенең бирегә нинди әйләнеч юллардан килеп ирешкәнен сөйләп бирер.

«Юлга чыкканыма өч ай инде, – дияр ул. – Мин монда турыдан гына түгел, Магадан аша килдем бит! Аннан килү ансатрак булыр дип өметләнгән идем дә, киресенчә, кыенрак булып чыкты. Анда мине белүче юк, пропуск бирмәделәр».

«Шуннан ничек килә алдың соң?» – дип сорар Өмит, шатлыгыннан балкып.

«Синең исемең бөтен киртәләрне җимерде», – дип җавап бирер, көлеп, Зуфирә.

Һәм, бик җиңел генә итеп, башыннан кичкәннәрне сөйләп бирер. Магаданның бер клубында стендтыр, плакаттыр ясап, ашарлык акча эшләгәнен... Күңеле һаман диңгез буена тартканын, буш вакыты булган саен этюдлар язганын...

Охот диңгезенең карап торуга ук салкын, корычтай кырыс, усал дулкыннарын, рәшәгә төренгән офыкны, сагышлы кычкырып очкан акчарлакларны төшерә иде ул кәгазенә. Аннары, йөзен җил салкынына каршы куеп, еракка карап, озак-озак басып тора иде. Җил, син нинди бәхетле, дип пышылдый иде ул, син аның чәчен сыйпап уза аласың... Дулкыннар, сез нинди бәхетле, сез аны иркәләп тирбәтә аласыз... Акчарлаклар, сез нинди бәхетле, сез аның баш очыннан аваз салып узасыз... Әйтсәнә, җил, әйтегезсәнә, дулкыннар, хәбәр бирегезче, акчарлаклар, кайсы диңгезләрдән уза минем зәңгәр күзле сөйгәнемнең хәвефле һәм авыр юллары?

Магадандагы яңа танышлары Зуфирәгә күпме әйттеләр:

– Йөрмә юләрләнеп, кайт кире Казаныңа, – диделәр. – Диңгезчеләр алар дулкын кебек – ярга бер мәлгә генә сыеналар да кире китеп күздән югалалар. Иярләп тә, йөгәнләп тә янында тотып булмый!

Әмма йөрәге янганда акыллы киңәш колакка керәмени?

Беркөнне шулай җил белән, дулкыннар һәм акчарлаклар белән серләшеп торганда, причал янындагы яссы палубалы баржа-плашкоут өстендә ашыгып әрле-бирле йөргән брезент киемле кешеләрне күреп алды ул. Юлга чыгалар икән болар дип уйлады, ярдан төшеп, якынрак килде.

– Әй, егетләр, кайсы тарафларга юл тотмакчы буласыз?

Агач мичкә тәгәрәтеп баручыларның берсе ачы җилдән кызарынган йөзен Зуфирәгә таба борды:

– Камчаткага.

– Мине дә утыртыгыз әле, ә?

– Пассажирлар алмыйбыз.

– Ә мин гади пассажир түгел, зур эш белән йөрим. Мине анда бик якын кешем көтә. Әгәр үзегез якын кешегезне көтеп, диңгезчеләр аңа ярдәм итмәсә, ни әйтер идегез?

Ир кеше зур бияләе белән маңгаен сөртте:

– Якын кешең диңгезчеме әллә?

– Ул – капитан!

– Капитанга әйтим әле.

Шулай диде дә аска төшеп китте теге. Озак тормады, кире чыкты:

– Сикер! – диде.

Зуфирә болай ук кинәт буласын көтмәгән иде, каушап калды хәтта. Аның үз янында этюдникгыннан, көзге пальто кесәсендәге паспортыннан һәм бер сум акчасыннан башка әйберсе юк иде.

– Әйткән сүзең хак булса, сикер палубага, – дип кабатлады ир кеше. – Ялганлаган булсаң, ычкын моннан, мин куып җитәрлек булмасын. Башка безнең күзгә чалынып йөрмә!

– Ал әле моны, – дип, Зуфирә башта этюднигын аңа ыргытты, аннары үзе сикерде. Причалның нык такталарыннан тирбәлеп торган палубага барып төшкәч, чайкалып егыла язды, аягына чак басып калды.

– Бар, трюмга шыл, – диде ир кеше, – безнең пешекче Марина янына. Палубага шәүләңне дә чагылдырасы булма.

Кая ул палубага чыгу! Стенага беркетелгән каты, тар ятактан ике атна буе башын да күтәрә алмады Зуфирә. Инде ни күнеккән Марина да сукрана иде, чөнки стеналарга, почмакларга бәрелеп аның да тәне күгәреп бетте – диңгезнең бик тә тынгысыз чагына туры килделәр...

Күрдем мин диңгездә йөрүнең рәхәтен, дияр Зуфирә, үртәп, Өмиткә. Кайсы хәтәррәктер: дулкынмы, балык сасысымы. Хикмәт икән ул ис, корабтагы һәр кадакка сеңгән, хәтта палуба белән трюмны бер итеп чабып йөргән маэмайдан да балык исе аңкый!

Плашкоут Зуфирәне Усть-Хайрюзово дигән поселокта төшереп калдырды да үз юлы белән китеп барды. Тәмам хәлсезләнгән иде ул, атна буе чайкалып, туры килгән һәрнәрсәгә тотынып йөрде.

Зуфирә Усть-Хайрюзоводан Халидәгә – җылы киемнәр, Магадандагы танышларына әйбер-карасын җибәрүләрен сорап хат язды. Посылкаларны Петропавловскиның Үзәк почтасына юлларга кушты.

Ниһаять, Петропавловскига килеп ирешә ул. Әмма Өмитне әлегәчә тапмады.

«Нишләргә белми аптырадым бит, – дип көлеп сөйләр ул Өмиткә. – Гостиницада урын юк, диләр, башны куяр җир табып булмый. Ахырда «Авача» дигән гостиницага җыештыручы булып

ялландым. Эш хакының яртысын яшәгән өчен калдырам, яртысы миңа... Шешәле сөт белән бер булка алам да шулар белән тамакны үткәрәм. Зарар юк, дип юатам үземне, сугыш вакытында безнең әниләргә монысы да тәтемәгән әле, түзгәннәр...»

Юк, бөтенләй үк мескен булып күренмәс Зуфирә Өмит каршында. Мин дә диңгезче булып китәргә ниятләдем бит әле, дияр. Бымырытыга художество җитәкчесе булып ялландым. «БМРТ – туңдыргыч зур балык тоту траулеры (большой морозильный рыболовный траулер) – исеме чытыр-пытыр булса да, мәгънәсе бик зур. Кадрлар бүлегендә хуплап каршы алдылар, синдәйләр безгә кирәк, диделәр, ихтыяҗ ифрат зур, диделәр».

Җае туры килеп торганда, ник мактанмаска!

«Алдан ук шактый акчасын да биреп куйдылар, хәзер инде гостиницада идән юып йөрмим, кунак булып кына яшим! Бер атнадан документлар әзер була, Находкага очачакмын, безнең БМРТ шунда ремонтта тора икән».

Шулай дияр Зуфирә, бер атнадан китәм, дип, юри куркытыр Өмитне. Аның нурлы күзләрендә гаҗәпләнү, соклану, курку кебек төрле хисләрнең алмашынуын рәхәтләнеп күзәтер ул. Әлбәттә инде, Өмит шундук каршы төшәр: «Юк инде, үзем ярда чакта, сине диңгезгә җибәрәмме соң!» – дияр. Һәм шундук әлеге кадрлар бүлегенә телефоннан шалтыратыр.

Әйе, ул кайткандыр, ул өйдәдер. Зуфирә аның кайдалыгын балык тоту флоты оешмаларыннан белешеп караган иде. Анда, «Төньяк балкышы»ында хәзер башка капитан, Гасимов яңа корабка күчте, диделәр. Нindигә? Анысын әйтмәделәр.

Дулкын кайчан да булса бер ярга килеп сугыла – диңгезчеләр дә әйләнеп кайта... Ул да бер кайтырга тиеш!

Менә таныш йорт, кырыйлары кителгән күксел бетон баскыч. Икенче катка менеп җиткәнче, Зуфирәнең йөрәге ярылмаса гына ярар иде... Менә таныш ишек... Зуфирә, коңгырт төймәгә үрелергә көч тапмыйча, бераз басып торды. Әгәр дә өйдәге кыңгырау тавышыннан соң, элеккеге кебек, ишек артында колакларны чыңлата торган тынлык кына булса?..

Зуфирә коңгырт, йомшак төймәгә орынды. Менә эчтән зыңгылдаган тавыш ишетелде, менә... Әллә бик теләгәнгә генә шулай тоеламы? Ах, бу йөрәк шулхәтле дөпелдәмәсә, колаклар чаң кагып чыңламаса! Чыннан да аяк тавышлары бит бу! Менә йозак ачкычы борыла, менә ишек үзе ачыла...

Зуфирә, хәле бетеп, стенага сөялде. Ләкин... Бу кем? Өмит буласы урында нинди ят ир басып тора?

Уртача буйлы, ыспай гәүдәле, яшьләрчә джинсы костюм кигән утызлар тирәсендәге җирән сакаллы бу кеше нәрсә дип шулхәтле сөенеп авызын ера?

– Сез... Сез биредә үзегез генәме? – дип, теленә килгән беренче сорауны бирде Зуфирә.

– Юк... Без икәү...

– Ә ул кайда?

Зуфирә йотлыгып эчкә карады, әмма анда беркем дә күренмәде.

– Менә ул – Донна.

Сакаллы кеше янында торган зур җирәнсу-сары этне аркасыннан сыйпады. Зуфирә ни дулкынланган булса да, бу ят кешенең йөзендәге үзгәрешне – аның елмаюы әкренләп сүнүен сизми кала алмады. Елмаюы сүнде – әмма аның яктысы авыз тирәсендәге сакал-мыегына йогып калды. Хәер, ирен тирәли төкләрнең аксылрак булуыннан гына шулай тоела иде бу. Ул да, Зуфирәне түгел, бөтенләй башка берәүне күрергә өметләнгән иде булса кирәк.

– Ә сезгә кем кирәк соң? – дип, тәмам җитдиләнеп сорады ул.

– Гасимов. Капитан Гасимов.

– Ул биредә тормый бит инде!

– Ничек тормый? Ул миңа хатларында шушы адресны күрсәткән иде.

– Сез – Зуфирә, – диде сакаллы һич көтмәгәндә. Аның авыз тирәсендә сакланган елмаю балкышы тагын бөтен йөзенә таралды. – Әйдәгез, рәхим итегез, хуш киләсез!

Һәм, артка чигенеп, юл бирде.

Менә нинди шартларда яшәгән икән Зуфирәнең Өмите диңгездән кайткан чакларында! Идән тулы кәгазь тартмалар, нindидер капчыклар, түр стенада майлы буяу белән язылган картиналар. Аларда Камчаткага килеп кулына буяу белән пумала алган һәр рәссам өчен хас сюжет – өч янар тау тасвирланган иде. Зуфирә, бер күз сирпеп алуга, аларның өйрәнчек кулы белән ясалганын, алгы план белән арткы планның бер-берсенә ябышмаганын күреп алды.

– Утырыгыз, – диде хуҗа, үзе тире җәелгән тар ятакка утырды.

Ятакның яртысына диярлек эт тиреләре өелгән иде.

– Сез монда ярангада яшәгән кебек көн итәсез икән, – диде Зуфирә, тиреләргә ишарәләп, һәм өстәл янындагы уңайсыз урындыкның кырына гына утырды.

– Итек тегәм мин алардан, миңа тире итексез булмый. Еш кына карга күмелеп ятарга туры килә, ә минем сул аягым бик туңа... Мин сезне башкачарак күз алдына китергән идем.

– Яшьрәк итепме?

– Әйе. Аннары, татар кызлары кара күзле, түгәрәк йөзле булырга тиештер бит?

– Мәҗбүри түгел. Ак кызларны да татарлыктан сызмыйлар. Сез үзегез кем буласыз соң?

Бу кешенең Зуфирәне тануы да, аңлашылмас елмаюы да, Өмитнең кайдалыгын әйтергә ашыкмавы да сәер иде һәм бу сәерлек Зуфирәнең эчен пошыра башлады.

– Николаев мин, Вадим Николаев. Өмитнең дусты һәм торакташы... идем... Ә ул үзе диңгездә бит хәзер.

– Кайчан кайта?

– Путина беткәч инде.

– Ә путина кайчан бетә?

– Плавбазага күчте бит ул... Башка кораблар кайтып беткәнне көтәчәк. Көнен-сәгатен кем белсен... – Николаев Зуфирәгә туп-туры төбәп карады. – Сез кемне яратканыгызны беләсездер бит!

– Диңгезче – дулкын кебек, ярга сугылып ала да кире китә, аны иярләп тә, йөгәнләп тә булмый, димәкче инде сез дә.

– Сез Камчатка әйтемнәрен дә белеп бетергәнсез икән инде.

– Магадан әйтеме ул.

– Анда да булдыгызмы әллә?

Зуфирә җавап бирмәде. Өмиткә дип әзерләп куйган кыйссаларын җиде ятка сөйлисе килмәде. Ул үзенең бер атнадан диңгезгә китәргә тиешлеген исенә төшерде. Бер атнадан! Аңарчы Өмит кайтырмы-юкмы, Зуфирә аны күрә алырмы-юкмы... Болай булгач, бәлки, очраша да алмаслар...

– Аңа... радиограмма биреп була торгандыр бит? – диде Зуфирә.

Николаев аңа туры җавап бирмәде, ишетмәгәндәй булды.

– Ә Өмит миңа сезнең хакта күп сөйләгән иде, – дип куйды үзалдына.

Шунда Зуфирә аның фамилиясен исенә төшерде. Әйе, бер сөйләшкәндә, Өмит аңа: «Николаев – дөнья бәясе кеше», – дигән иде түгелме? Шул кеше микәнни инде бу? Зуфирә аның ыспай гәүдәсен, һич елмаю нуры сүнми яктырып торган йөзен тагын бер тапкыр тартынмый-нитми күздән кичерде.

– Гафу итегез, мин сезне чәй белән дә сыйлый алмыйм, – диде Вадим. – Без монда, очып барган кошлар шикелле, бер тукталып ял итеп кенә чыгабыз. Гейзерлар үзәненнән Донна белән кичә генә кайтып төштек.

Җирәнсу-сары эт, хуҗасының сүзен расларга теләгәндәй, Зуфирәнең күзләренә туры карап, тезләренә ышкылып узды да аяк очына сузылып ятты.

– Менә бит ул ничек... – диде Вадим. – Бу минутта минем урында Өмит булса, яхшырак булыр иде.

– Яки киресенчә, минем урынга башка берәү килеп керсә, – диде Зуфирә, ачы көлемсерәп. – Шулай бит? Сез кемнедер көтәсез?

– Без Донна белән күптән көтәбез инде... – Эт, аның сүзен раславын белдереп, йөнтәс койрыгын селтәп куйды.

– Ул минем соңгы хатларымны алды микән? Сез белмисезме?

Вадим тире җәйгән ятактан торып, ян стенага терәп куелган өстәл янына узды, Зуфирә аның сул аягына җиңелчә генә аксавын сизеп алды.

– Соңгы хатларыгыз менә бередә.

Николаев төргәкләр, бөгәрләнгән дәфтәрләр һәм ачык китаплар арасыннан бер уч конверт табып алды. Менә алар – Зуфирәнең сагыну-сагышлары, күңел моңнары тулы хатлар! Ачылмаган да килеш аунап яталар!

– Үзе кайткач тапшырмакчы идем, – диде Вадим.

– Китерегез монда!

Хатларны ят кулларда күрү авыр иде, Зуфирә аларны Вадимнан ашыгып тартып алды да, кабаланып, бөгәрләп, сумкасына тыкты.

Аның биредә башка бер генә минут та торасы килми, ачык йөзле бу кешене дә, аның идәндә җәелеп яткан гамьсез этен дә күрәсе килми иде.

Шул ук вакытта ул үзенең хисләрен тыярга кирәклеген дә аңлады. Бу сакалбай нәрсәдер белә, нидер яшерә, Зуфирәнең язмышы өчен мөһим серне ачарга теләми. Бастырып сорашырга да кыен, телен тиз генә чишеп булмасы көн кебек ачык. Сабыр булырга туры килә, чөнки Өмит белән ике араны тоташтырып торган җеп шушы кеше аркылы уза... Шунлыктан Зуфирә ишекне шап итеп ябып йөгереп чыгып китә алмады, сумка биген бер ачып, бер шартлатып ябып, басып торуында булды. Әйтерсең лә аның итек табаннары җилемләнеп, күптән юылмаган, кыршылган идәнгә ябышып каткан иде. Ул танышлыкны сакларлык, шул ук вакытта горурлыкны югалтмаслык сүзләр эзләде.

Вадим, аның уйларын укыгандай, гади генә итеп:

– Мин сезгә шалтыратырмын әле, – диде. – Берәр яңалык булса, шундук хәбәр итәрмен. Хәлегезне аңлыйм. Чөнки икебездә бер ваем...

Ул тагын серле һәм ямансу итеп елмаеп куйды. Тик бу юлы аның елмаюы Зуфирә өчен түгел, ул зарыгып көткән башка берәү өчен иде булса кирәк. Әйе, һәркемнең үз гаме, Зуфирә кайгысын уйлап кына яшәмиләр!

– Донна, әйдә кунакны озатып куябыз!

Эт кәлтә елândай йомшак, сыгылмалы хәрәкәт белән торып басты, ашыкмый гына ишеккә юнәлде. Ә тышта күз ачкысыз буран купкан иде.

– Менә циклон да килеп җитте, быел беренчесе. Пурга башлана, – диде сагышланып Вадим. – Самолетлар очмый инде мондый чакларда.

– Озаккамы инде бу?

– Кем белгән! Бәлки, өч көннән туктар, ә бәлки, атна буена барыр.

«Шулаймы, көткән кешең тиз генә килә алмас дип куркасыңмы, – дип уйлады Зуфирә. – Ә минем өчен буран ничаклы озаграк котырса, шулхәтле яхшырак. Циклон корабларны ярга таба куа, шулай түгелме?»

Ә җил җирне-күкне бер итеп котырына, кар да болытлардан үз ихтыяры белән генә төшмидер, аны биниһая зур көрәкләр белән гыйфритләр ишеп төшерәдер сыман тоела иде. Зуфирә йөзен җилгә каршы борды: катырак ис, җил, ныграк селтәнегез, гыйфритләр, диңгездәге балыклар төпкә ятсын, кораблар ярларга ашыксын!

* * *

Иртән күзен ачуга, Зуфирә тәрәзә янына килеп басты. Ул яшәгән «Авача» гостиницасын урам яктан ресторан бинасы каплап тора. Ресторанның стеналары тоташ күксел бетоннан катырып ясалган, бер ягында да тәрәзәләр юк, керергә ишеге генә бар. Эчкә яктылык түбәдәге тишекләрдән төшә, ул тишекләрне кар капламасын өчен, һәрберсе өстенә текә кыек ясап куйганнар, кыекларның өч ягы – бетон, бер ягы – пыяла. Камчатка архитекторларының, материктагы коллегаларын уздырып, мөгез чыгарырга тырышуы нәтиҗәсендә туган сәер бер бина бу. Очлы кыеклар яссы түбә өстендә колаклар кебек тырпаешып торалар, шуңа күрә халык бу ресторанны «Авача» дип түгел, «Дуңгыз колагы» дип йөртә.

Өченче каттагы бүлмәсеннән караган Зуфирә шул «колаклар» арасында асылташлар белән бизәлгәндәй җемелдәп яткан кар мендәрләрен күрде, ә еракта сопка күкрәкләре турыннан кызулык белән ак томан кисәкләре оча иде. Күк зәңгәр, якты; кояш күтәрелеп килә. Вадимның сүзе дөрескә чыкмады: пурга туктаган иде.

Әмма Зуфирәнең күңелендәге сагыш китмәгән, өметсезлек болыты таралмаган иде. Нишләргә аңа, кая барырга, кемгә сүз кушарга? Зур бер шәһәрдә үзен япа-ялгыз хис итте ул.

Өстәлдәге кызыл телефон аппараты зыңгылдагач, ул сәерсенеп китте: моңарчы биредә аны кирәксенгән кеше юк иде. Бик сирәк кенә, анда да номерны ялгышып кына эләгәләр бу телефонга. Шуңа күрә ул башта трубканы алмаска да уйлаган иде, зыңгылдау өзми-куймый дәвам иткәч, сабырлыгы бетеп, талчыккан, битараф тавыш белән:

– Алло? Кем кирәк? – дип җавап бирде.

– Зуфирә, сөенче!

Зуфирәнең йөрәге сулкылдап куйды. Ләкин... бу Өмит тавышы түгел, аның тавышы калынрак, ә бу – нечкәрәк, таныш та шикелле үзе.

– Ник дәшмисез? Танымадыгызмы әллә? Бу мин – Вадим!

Вадим... Димәк, Өмит тә! Югыйсә нинди сөенче булырга мөмкин?

– Хәзер үк Халактырка аэропортына килегез! Миңа вертолет бирәләр, үзәнгә кирәк-яракны илтәм. Бер капчык бәрәңгене калдырып булса да, сезне алып барам!

Вадимның тавышында чиксез тантана яңгырый, әйтерсең алтын таулар вәгъдә итә! Зуфирәнең исә, киресенчә, күңеле төште.

– Йә, нәрсә телсез калдыгыз, – диде Вадим тагын да көррәк тавыш белән. – Такси алыгыз да – Халактыркага! Җылырак киенегез!

– Ярый... – диде, ниһаять, Зуфирә.

Ул ашыкмый гына шкафтан төлке якалы пальтосы белән төлке бүреген алып киде, көзге каршына басты. Кызыл төлке аның маңгае өстенә төшкән сары чәченә бик килешеп тора, ак йөзен яшәртеп җибәрә. Колагына кызы Халидәнең тавышы ишетелгәндәй булды:

«Ник үзеңә берәр чәшке бүрек алып кимисең син, әни? Чәшке бүрек модада бит хәзер. Әйдә, кибеттән якалыклар алабыз да дөньяда юк фасонлы бүрек тектерәбез. Сызымын үзем ясап бирәм».

«Синең әниеңә чәшке бүрек килешмәс шул, кызым. Төлкенең дә кыйбатлысы, көмешсыман-карасы бармый, җирәне, саф татарча иттереп әйткәндә, кызылы кирәк. Ишеткәнең бармы синең бер

җырны: «Кызыл да гынай төлке – урман күрке, батыр да гынай егет – ил күрке...» Аны сузып-сузып Мәрьям Рахманкулова җырлый».

«Ә матур кыз?» – дип елмаеп сорый Халидә.

«Матур да гынай кыз – күз күрке. Белдеңме инде? Күз күрке булган кызга урман күрке – кызыл төлке килешә...»

Шулай сөйләшкәннәр иде берзаман. Шуннан соң Халидә базардан табып алып кайтып биргән иде бу тиреләрне. Нишли икән анда Халидә? Ничек яши икән? Хатларында бик юатып яза да бит, бәлки, әнисен борчымаска теләведер?

Зуфирә, көрсенеп, урамга чыкты, узып барган машинага кулын селтәп туктатты.

Вадим аны аэропортның бер катлы бинасы янында, ап-ак кар келәме өстендә күгелҗем бизәк булып утырган яшь каеннар төбендә каршы алды.

– Ә беләсезме, әгәр юлыбыз уңса, сез Гейзерлар үзәненә кыш көне барган беренче турист булачаксыз. Анда хәзер җәй көне дә беркемне кертмиләр. Өлкәнең катгый карары бар. Халык күп йөрсә, тапталып бозылуыннан куркалар.

– Капкасын бикләп куйдылармы әллә?

– О, аның капкасы бер генә түгел, әкияттәге кебек – җитмеш җиде. Камчаткада унар ел яшәп тә, ул үзәнне күрә алмаган кешеләр күп.

Ул борылды да, сул аягына аксый төшеп, аэровокзал эченә юнәлде. Диспетчер бүлмәсендә шул мәгълүм булды: Зуфирәне утырту бәрабәренә Николаев кышлык азык-төлегенең бер өлешен аэропортта калдырырга тиеш, чөнки вертолет фәлән килограммнан артык йөк алмый, аның әле бер мичкә запас бензин да күтәрәсе бар икән: һава бозылып, вертолет адашса, ярдәм сорап барырга якын-тирәдә генә авыллар юк!

Ниһаять, барысы да үлчәнде, килешенде, вертолет һавага күтәрелде. Очучылар кабинасы ягыннан брезент көпшә суздылар, аннан кайнар һава өретелә икән. Ләкин Зуфирә ул көпшәне тезенә салып, җылынып кына утырырга теләмәде, уртадагы кызыл бензин мичкәсен, капчыкларны, тартмаларны әйләнеп, әле бер як тәрәзәгә, әле икенчесенә килде.

Уң якта – лазурь белән буялган төсле иксез-чиксез зәңгәр дала – Тын океан җәйрәп ята. Кайдадыр, хыял ирешмәс ераклыкларда, Зуфирәнең сөйгәнен яшергән, ул гына да түгел, Өмитнең иң кайнар хисләрен үзенә алган киңлек...

Сул тәрәзәдән текә күкрәкле, очлы түбәле таулар – сопкалар күренә. Алар арасыннан карасуланып елгалар ага, алар бөгәрләнеп ташланган тимер тасмалар кебек, кискен борылышлар ясап, диңгез тарафына сузылганнар.

Елга буендагы уйсулыкларга, сопкаларның сөзәк итәкләренә урман үскән. Мондагы урманнар бездәгечә түгел икән: кәкре-бөкре кәүсәле ташкаен агачлары бер-берсеннән биш-алты адым ара калдырып утыралар, кар өстендә аларның һәрберсе генә түгел, күләгәләре дә аермачык булып күренә.

Биредә бер нәрсә икенчесен күләгәләми, табигатьнең һәр бизәге менә мин дигәндәй иркенәеп, чекерәеп тора. «Эчкерсез, саф күңелле кешеләрнең уй-хисләре шикелле», – дип уйлап куйды Зуфирә. Күңелне сафландыра, уйларны югары күтәрә торган бер гүзәллек бар иде бу җирдә.

– Әнә, күрәсезме, сопкага аю менеп киткән, – диде Вадим, Зуфирә янына килеп һәм мотор гөрелтесен басарга тырышканнан шактый кычкырып. – Хәзер өнендә ятарга тиеш ул. Берәр нәрсәдән өркеп уянган шатундыр, мөгаен...

Алда океан киңлегеннән тар гына тасма белән аерылган зәңгәр күл күренде. Аның карлы ярларында соры кошчыклар кайнаша иде. «Кыр үрдәкләре мәллә?» – дип гаҗәпләнеп уйлап бетермәде Зуфирә, озын тәпиләре белән тиздән суга кереп, озын муеннарын бөгеп, башларын суга чумдырган кардай аккошларны күреп алды. Әнә аларның бер төркеме, вертолет шавыннан өркеп булса кирәк, талгын хәрәкәт белән һавага күтәрелде, муеннарын сузып, кар каплаган дала өстеннән кырыс сопкаларга таба очып китте.

– Аккошлар! – дип пышылдады Зуфирә, үз күзләренә үзе ышанып бетә алмыйча. – Кар өстендә аккошлар!

– Алар көзен китмиләр, биредә кышлыйлар, – диде Вадим, Зуфирәнең гаҗәпләнүен хуплагандай. – Шумная елгасын да, Лиманны да кышын боз капламый, җим җитәрлек.

Алай икән, тамаклары ачыкмый, җылы суда тәпиләре туңмый икән кошкайларның. Ләкин барыбер үзәк өзгеч булып тоелды бу күренеш Зуфирәгә – кар өстендә аккошлар. «Ничек яшисез сез биредә, аккошкайлар, ничек көн итәсез? – дип пышылдады ул, салкын пыялага иреннәрен терәп. – Болытлардан ишелеп төшкәндәй булып җепшек кар яуганда, аяктан егарлык ачы җилләр искәндә, пурга котырынганда ничек җан саклыйсыз? Нигә, башка кошлар кебек, җылы якларга китеп котылмыйсыз? Шулхәтле газизмени соң туган җир?»

Җанны тетрәтерлек итеп рәсемдә тасвирлыйсы иде бу күренешне. Иксез-чиксез зәңгәр киңлекне, кырыс, мәгърур сопкаларны, бөгәрләнеп аккан, таш араларыннан үзенә юл салган мәңге катмас

елгаларны, һәм алар өстеннән очкан аккошларны! Кешеләр күңелендә ашкынулы, дәртле җыр кузгатырлык булсын иде ул картина!

Вертолет сулга борылды да сопкаларга таба юнәлде. Каршыда, ерактa, текә күкрәкле тауның үткен пычак белән телеп алгандай яссы булып күренгән түбәсеннән бөтерелеп кара болыт күтәрелеп чыкты, кызыл ялкын теле ургылды.

– Карым вулканы ата! – диде Вадим, кычкырып.

Менә ничек ата икән ул янар тау – ерактан караганда салмак, әмма, тыелгысыз хәрәкәт белән сулыш алгандай, ут-төтенне биеккә, күк гөмбәзенә бөрки икән!

Ә аның артында, күк гөмбәзенең зәңгәрлеге аркылы нинди аллы-гөлле тасмалар дугайланып сузылган тагын?

Бәй... бу бит... салават күпере! Авызыннан ут-ялкын бөркегән янар таудан диңгезгә таба бизәкле күпер сузып куйган. Тагын күз җитмәслек офыкка, тагын Өмиткә таба. Әллә соң Зуфирәнең өендә чакта ук тәрәзәсеннән күренгән, аның күз алдында ялган салават күперенең дәвамымы бу һәм ул тагын аңа юл күрсәтәме?

Юкка гына булмаска тиеш иде бу.

Вертолет тар гына тарлавык буйлап оча башлады, янар тау да, салават күпере дә күздән югалды. Ике яктан текә булып биек яр күтәрелә, аста, таштан ташка сикереп, зәңгәр елга ага иде.

Ниһаять, килеп җиттеләр, ахры, вертолет, тәгәрмәчләрен көрткә батырып, күкрәге белән кар мендәренә ятты. Зуфирә, кабинадан чыгуга, бот төбеннән көрткә чумды.

Сулда текә үр, уңда бушлык булып, аннан тагын биек яр күтәрелә иде, алар шул үр белән бушлык арасындагы киң булмаган мәйданда басып торалар. Бераздан, колаклар мотор шавыннан арына төшкәч, чыжылдаган, быгырдаган, сызгырган сыман сәер авазлар ишетелде.

– Менә шушы инде ул – атаклы Гейзерлар үзәне! – диде Вадим горурлык белән.

Үзән? Кайда үзән? Тауны ярып төшкән тарлавык лабаса бу!

– Ә бусы – минем йортым!

Кыя күкрәгендәге мәйданчыкта фанер белән тышланган ике катлы өй тора иде.

Бата-чума кар ерып, шунда таба киттеләр, иркен өйалды аша үттеләр. Эчтә зур плитә, такта өстәл, эскәмия – көн күрү өчен иң кирәкле нәрсәләр генә бар икән. Ләкин иң күзгә ташланганы – бөтен стеналарны тоташ урап алган киштәләр һәм аларга тыгызлап тезелгән китаплар иде. Бер якта зур кара такта, өстәлдә ачык китап-дәфтәрләр. «Тәрәзәләре генә бар, югыйсә нәкъ менә Әбүгалисина мәгарәсе булыр иде», – дип уйлап куйды Зуфирә.

– Кыш көне аскы катның тәрәзәләрен кар каплый, көрәп бетерерлек булмый, шуңа күрә икенче катны ясарга туры килде, – диде Вадим, аның күңелендә чагылып үткән сорауга җавап биреп.

Тар баскычтан менеп, өсне дә карап төштеләр, анда да шул ук кырыс мохит – каты ятак, такта өстәл, китаплар, дәфтәрләр иде.

Очучыларның берсе – өлкәнрәге – мич яга башлады, яшьрәге Вадимга вертолеттан әйбер-кара ташышырга булышты. Вадим кыска тунын салып, күлмәкчән генә калды, җирән сакалы өстендә ике бит алмасы кызарып чыкты, маңгаен тир бөрчекләре каплады, ә үзе һаман күтәренке рух белән житез атлап йөри, авыр-авыр капчыкларны, әрҗәләрне күтәреп, билдән кар ерып килгәндә дә аның аксаганы бөтенләй сизелми иде.

Ниһаять, ул, җиңел сулап, тирләгән битен сөртеп алды да, эскәмия астыннан зур-зур киез итекләр тартып чыгарып, Зуфирәгә:

– Аяк киемегезне алыштырыгыз, – диде.

– Берүзегезгә шушы хәтле киез итек алдыгызмы?

– Монда кеше күп килә. Камчаткага аяк баскан һәр кадерле кунакка, сыйның иң зурысы итеп, Гейзерлар үзәнен күрсәтергә тырышалар. Космонавтмы ул, академикмы, танылган артистмы. Ә аларның күбесе – сезнең кебек ышанычсыз халык, ялтыравык ботинка киеп йөри.

Алар тышка чыгып, уң яктагы бушлыкка таба киттеләр. Тарлавык төбендә таштан ташка сикереп аккан елга ярына килеп баскач, кыштан язга күчкәндәй булдылар. Яр тирәсендә кар эрегән, яшел чирәм үскән, юеш балчыкта аяклар тая иде. Текә ярдан аска төштеләр. Бирерәге таш тишекләреннән кайнар тамчылар чәчри, су буенда төрле төстәге таштан матур бизәкле түгәрәк мәйданчыклар ясалган иде.

Менә шундый мәйданчыкларның берсеннән, кызыл чәчкәлесеннән, күкрәк авызыннан кайнап чыккандай саңгырау аваз ишетелде, пар бөркелде, биек ярдан узып, өскә су фонтаны күтәрелде. Биткә кайнар дым бәрелде, күз алдында пар баганасы бөтерелде.

Менә нинди икән ул гейзер! Зуфирә карап туя алмады, су таш чәчәкләр өстенә коелып төште, җир бер көрсенде дә тынды, томан таралды.

Ә ярдагы таш тишекләреннән кайнар тамчылар чәчрәвен, елга челтерәвен дәвам итте. Монда җирнең кайнар кан тамырлары ачылган, йөрәк тибеше ишетелә, сулыш алганы сизелә иде. Монда күк гөмбәзе дә түбәнәйгән, якынайган сыман тоела, ә Зуфирә, авыз тирәсендә елмаю балкышы

сүнми торган якты карашлы кеше белән янәшә, гүяки җирнең күк белән сөйләшкән ноктасында басып тора иде.

– Һәр гейзерның үз бизәге, үз биеклеге, үзенең ата торган вакыты бар. Алар бер-берсенә охшамаган.

«Кешеләр кебек икән», – дип уйлады Зуфирә.

– Әйдәгез, хәзер өскә менәбез. Таеп егыла күрмәгез. Минем арттан гына барыгыз. Бу казанда кайнаган ләмнең кайнарлыгы алтмыш градус. Берзаман ялгышып аю кереп пешкән иде. Ә менә бу таш тишеге «җәһәннәм авызы» дип атала. Күрәсезме, аждаһа авызына охшаган, ә эченнән бгыырдаган тавыш ишетелә. Гөнаһ ияләрен пешекли.

– Ә «оҗмах капкасы» бармы соң биредә?

– Карале, анысы бөтенләй башка килмәгән бит, – дип кабынып китте Вадим. – Андый исем кушарлык урыннар бар. Әнә каршы ярдан агып төшкән шарлавыкны күрәсезме? Аның астына басып коенсаң, оҗмахка кергәндәй буласың. Шундый рәхәт, үзе шифалы. Аякны шунда дәвалыйм. Тотармын да «оҗмах капкасы» дип шуңа кушармын әле! Беләсезме, бу үзәнгә беренче булып аяк баскан кеше – хатын-кыз бит. Геолог Татьяна Петровна Устинова. Кырык беренче елны, кайдадыр, кемнәрдер сугыш башларга әзерләнеп яткан вакытта, җирнең иң зур могҗизаларыннан берсен ачкан ул. Бер нәрсә тынгы бирмәгән аңа: нилектән Шумная елгасы иң зәмһәрир суыкларда да бозланып катмый?

Зуфирә эченнән генә Вадимның бу сүзләренә каршы төште: «Юк, алай түгел, кар өстендә очкан аккошлар тынгы бирмәгән аңа! Ни өчен алар җылы якларга китмиләр, шушы елга буенда кышлыйлар? Шуның серен ачасы килгән аның, шул омтылыш аны беркем аяк басмаган авыр юлга чыгарган, кыргый сопкалар арасыннан биеклеккә ашкындырган».

– Берзаман ул үзенең юлдашлары белән хәл алырга дип елга буена туктаган, – дип дәвам итте Вадим. – Тыныч кына утыралар икән шулай, ни күзләре белән күрсеннәр: каршыларында җир уфылдап куйган, пых-пых пар бөркелгән, кайнар су атылып күтәрелгән. Котлары очкан боларның, аяк астыбыздан янар тау ата башлады, ахрысы, дип курыкканнар. Бары тик кайнар су атып туктагач кына, Устинова: «Бәй, бу соң гейзер бит!» – дип кычкырып җибәргән.

Әйе-әйе, ул нәкъ менә шулай чын хатын-кызларча итеп, «бәй» дип кычкырып куйгандыр. Зуфирә аны җылы яулык бәйләгән, мөлаем йөзле гап-гади бер хатын итеп күз алдына китерде. Шулай шаккатып җирнең йөрәк тибешен тоеп, күкнең якынлыгын хис итеп басып торгандыр ул шушы ноктада, һәм бөек кеше икәнлеген белгәндер бу минутта.

– Ул ачкан могҗиза бөтен кешене таң калдырган, – дип дәвам итте Вадим сүзен. – Аңарчы бит гейзерларны бары өч кенә урында – Исландиядә, Америкада һәм Япониядә генә бар дип исәпләгәннәр. Ә биредәге гейзерлар андагылардан күчлерәк, зуррак, матуррак булып чыккан.

«Һәм күңелне сафландыра, рухны моңарчы син белмәгән биеклеккә күтәрә торганнары», – дип өстәде күңеленнән Зуфирә. Шагыйрь Эдуардас Межелайтисның шундый бер шигыре бар: «Мин җир белән күкне тоташтырып торам: кояш нуры минем аша җиргә үтә, жир сулышы минем аша күккә менә», – дигән ул. Җирнең нәкъ менә шушындый ноктасына килеп баскач кына үзеңнең кояш нуры белән җир сулышы тоташканлыктан яралган табигать баласы икәнлегеңне тоясың да инде...

Алар, карга батып, ләмгә таеп, үрләргә менеп-төшеп шактый озак йөрделәр. Зуфирә зур итекләргә абынып әллә ничә кат егылды, куаклардагы аккош мамыгына охшаш бәсләрне коеп, ябышып аягына басты.

Арып-талып, әмма күтәренке рух белән өйгә кайтып керделәр, очучылар белән бер табактан кайнар ит консервасы ашадылар, шушы үзәндә үскән алтын тамыр төнәтмәсен авыз иттеләр.

Очучыларның өлкәнрәге, түгәрәк йөзле, кыю карашлысы элекке килүләрендә булган хәлләрне искә төшереп утырды. Бер килеп өй ишеген ачсалар, ни күзләре белән күрсеннәр, эскәмиядә россомаха ята икән. Идән астын казып кергән, ул керүгә, идән тактасы шап итеп кире үз урынына яткан. Очучы белән Вадим, моны тотмакчы булып, икесе ике яктан якын килмәкчеләр икән. Ә теге ерткыч, сары күзләрен елтыратып, боларның һәр хәрәкәтен күзәтә, менә-менә өсләренә ыргылмакчы... Мондый көчле һәм сизгер җанварны коры кул белән тотып булмасын бераздан гына аңлаганнар. Ишекне ачык калдырып чыгып торганнар аннары.

Күңелле көлешеп, сөйләшеп утыру рәхәт иде. Ләкин очучылар ашыктыра башлады:

– Килгәндә салават күперен күрдегезме? Һава бозылырга ул. Тизрәк кузгалыйк!

Халактырка аэропортына кояш баер алдыннан кайтып җиттеләр. Вадимны бер танышы «Волга» машинасы белән каршы алды. Ул каяндыр тимер кыршаулы сап-сары агач тәпән белән олы бәйләм сүс бау алып килде, аларны машинаның багажнигына урнаштыра алмый шактый азапланды.

– Нәрсәгә кирәк ул сезгә? – дип сорады Зуфирә.

Мондый тәпәннәрне аның авыл җирендә дә күптән күргәне юк иде инде.

– Теләсә нәрсәгә ярый бу! Гөмбә тозлыйсыңмы, кәбестәме – менә дигән.

– Ә бавы?

– Анысын үзәндәге сукмак кырыйларына сузып куям. Килгән-киткән кеше ялгыш басып пешмәсен өчен. Гейзерит ташларны таптатмаска да яхшы. Тәртип кирәк безнең эштә!

Зуфирә башын чайкады:

– Бу заманда кем инде тәпәннәр белән әвәрә килә!

Вадим тураеп басты, Зуфирәнең күзләренә бик җитди итеп, хәтта әрнеп карады:

– Сез дә шулай уйлыйсызмыни? Аңламыйсызмыни? Әгәр, беләсегез килсә, тормышның асыл мәгънәсе нәкъ менә шушылай хуҗалыкны кайгыртып, табигать белән бердәмлегеңне тоеп яшәүдә дә инде! Кешеләр, мәшәкатьтән котылабыз дип, үзләрен бик күп нәрсәләрдән мәхрүм итәләр. Инде сез дә шуны аңламагач, башкаларга ни кала! Сезнең хакта Өмит, сизгер күңелле рәссам, дип сөйли торган иде ләбаса!

Ул багажник авызыннан күренеп торган тәпәнне кискен хәрәкәт белән кире тартып алды. Шофер килеп, әйберләрне машина эченә куярга киңәш итте, шулай итеп, Зуфирәгә урын калмады. Ул автобуска утырды.

Аннан төшкәч, тукталып, башын күтәреп карады. Офыкны каплап, өч янар тау шәфәкъ нурларында яктырып тора иде. Алар бик якын тоела, йөгереп китсәң, сулышыңа кабынганчы барып та җитәрсең шикелле. Иң биегенең очыннан күксел томан күтәрелә, күк гөмбәзенә ягылып, алсу-кызгылт төскә маныла. Томан түгел, янар тауның кайнар сулышы иде бу. Ә түбәнрәк, тау биленә күгелҗем шәл булып җиңел болыт уралган да җирне үзенең күләгәсе белән каплаган...

* * *

...Иртән Вадим телефоннан шалтыратты:

– Мин Өмитнең сезгә биргән бер вәгъдәсен үтәдем булса кирәк, – диде. – Ул сезгә гейзерларны күрсәтермен дигән булгандыр бит?

– Ул миңа океанны күрсәтергә сүз биргән иде.

– Ә-ә, әлбәттә... Әйдәгез алайса, бүген океан ярына барыйк.

Ә нигә бармаска? Зуфирәнең бүген бер эше дә юк иде.

Ярты сәгатьтән гостиница ишеге төбенә кечкенә яшел автобус килеп туктады. Аннан Вадим белән Донна төштеләр.

– Сезнең әле шәхси автобусыгыз да бармыни? – дип сорады Зуфирә.

– Камчаткадагы бөтен нәрсә – минеке! – дип шаяруга чынны кушып җавап бирде Вадим.

Автобус аларны шәһәрдән алып чыкты да итәкләре белән бер-берсенә тоташып утырган өч янар тау яныннан ары алып китте. Таулар артында авыл, аның янында сыер фермасы күренеп калды, ә уң якта яшелчә түтәлләре сузылып ята иде. Түтәлләр озын, араларына тирән канаулар казылган, алары язын ташу сулары аксын өчен, ә җәйге коры көннәрдә сугару өчен кирәк икән.

Вадим элегрәк балыктан гайре азык-төлекне Камчаткага кораблар белән материктан ташырга туры килгәнен, хәзер исә өлкәнең үзен яшелчә, ит-сөт белән тәэмин итү бурычын куйганын сөйләп барды.

– Бу галимнәр нишләп соң моңарчы шушы якларда үсәрлек алмагач сортлары китереп чыгармыйлар? – дип сукранып куйды аннары. – Мичуриннан соң ул эш белән ныклап шөгыльләнүче дә юк, ахрысы. Әгәр күңел биреп тотынсаң, үсмәгән нәрсә юк бит монда.

Түтәлләр океан ярына ук барып тоташты.

Автобустан төшүгә, Зуфирә карашын ераккка төбәде.

Тын океан, исеменә туры килгәнчә, тыныч иде. Күз күреме җиткәнчә ераклыкта тоташ зәңгәрлек белән җәйрәп ята иде ул. Мондый нурлы, шул ук вакытта салкын, тыгыз җил белән ышкып чистартылгандай саф зәңгәрлекне Зуфирәнең беркайчан да күргәне юк иде әле. Дөрес, ул аны вертолеттан күрде, ләкин ярдан караш бөтенләй башкача икән. Еракта, күз күреме чигендә, диңгезнең күкрәге калкуланып, кабарып тора, анда, су белән күк гөмбәзе арасында, киң бушлык бардыр кебек тоела.

Ул бушлыктан тыгыз, салкын, тынгысыз җил агылып чыга, ярга якынрак килгән саен, диңгезнең өстен ныграк тынгысызлый, тибрәтә, тибрәлү көчәеп, дулкынга әверелә. Ниһаять, дулкыннар, кабарынып, күбекләнеп, ярга таба чаба башлыйлар. Текә сыртлы дулкыннар, читтән караганда, көмеш яллы зәңгәр чаптарларны хәтерләтә сыман. Иге дә, чиге дә юк ул күз иярмәс тизлек белән чапкан көтүләрнең. Алар тирәнлектән берсе артыннан икенчесе күтәрелеп чыгалар да томырылып киләләр, инде ярга сикерәбез дигәндә генә, кире суга чума башлыйлар, ниһаять, көмеш ялларын кара комга сирпеп, чоңгылга төшкәндәй юк булалар. Тыелгысыз рәвештә, бертуктаусыз бара бу хәрәкәт. Каян чабып килә икән дә, кая китеп югала икән ул чаптарлар? Зуфирә, юеш кара комда тирән эз калдырып, дулкыннарга каршы атлады. Иелеп суга үрелде, әмма көмеш ял урынына аның аяк очында чыжылдап ак күбек эреде.

«Диңгезче – дулкын кебек, ярга бер генә сыена да кире китеп күздән югала, аны иярләп тә, йөгәнләп тә булмый» дигәннәре тагын искә төште.

– Күрәсезме, әнә сулдарак ниндидер җанварлар кайнаша, әллә сивучлар, әллә касаткалар инде, – диде Вадим.

Чыннан да нәрсәдер бар анда, әнә судан шома башлар калыккандай булды, әнә күгелҗемләнеп сыртлар кабарган шикелле. Якын гына кебек үзләре, ә күз ачык кына аера алмый. Диңгез араларны якынайтып, ымсындырып тора шул...

Кичен Вадим аңа Авача култыгын күрсәтергә булды.

Катерда аларны зурлап каршы алдылар, капитан үзенең рубкасына чакырды.

Океаннан кайткан зур кораблар барысы да яр буендагы причалларга терәлеп туктый алмый, күбесе култык уртасында якорь сала икән. Алар белән яр арасында, шәһәрдәге трамвай шикелле, кечкенә катер йөреп тора.

Менә ул, эреле-ваклы баржалар арасыннан узып, диңгездәй иркен култык суына чыкты. Кичке эңгер-меңгердә балкып, каршы яктагы Вилючинская сопкасының карлы түбәсе шәфәкъ нурын тотып тора, акчарлаклар нәрсәгәдер өзгәләнеп кычкыра, катерны як-яктан тыгыз дулкын юа иде.

– Су салкындыр хәзер, – диде Зуфирә.

– Биредә аның җылынганы да юк, – диде капитан.

– Җәен дә коенырлык булмыймы әллә?

– Йөрәк януына чыдый алмаганнар чумып чыга. Гыйшык уты көчәеп киткәндә яки махмырдан интеккәндә ифрат та шифалы, диләр.

Катер култык киңлегендә серле сарайлар сыман үзенә чакырып торган корабларның берсеннән икенчесенә ашыкты. Биек кораблардан аның палубасына бау култыксалы тар баскычлар төшерәләр, ә тәбәнәкләренең янтыгына катер үзе борыны белән генә төртелеп тора, кешеләр палуба тирәли сузылган бау аша авырлык белән үрмәлиләр.

Өмитнең корабы нинди икән? Әлбәттә инде, биектер. Тирбәлеп торган текә, тар баскычтан ул, мәгърур кыяфәттә сынын туры тотып, нык адымнар белән төшәдер...

– Капитан, капитан! – дигән карлыккан тавышка Зуфирә борылып карады. Рубка палубадан шактый биек булганга, ишекне ачып бу сүзләрне әйткән кешенең сакал баскан йөзе бусага өстенә куелган сыман тоела иде.

– Капитан, мин «Кыю»да төшәргә тиеш идем, өлгерә алмадым, зинһар, тагын бер әйләнеп кил инде.

– Авызыңны ачып тормаска иде! Икенче рейс белән килерсең!

– Капитан, мин вахтага соңарам!

– Яп ишекне! Чит кешегә рубкага керергә ярамаганны белмисеңме әллә?

Ишек ябылды, әмма бер-ике кораб янында тукталуга тагын ачылды:

– Капитан, ә капитан!

Капитанның да йөрәге таш түгел икән:

– Күңел йомшак чак, шайтан вәсвәсәсенә биреләм инде, кунаклар хөрмәтенә генә, – диде.

Ләкин капитанның яхшылыгы юкка булып чыкты. Катер «Кыю»ның янтыгына борынын төртү белән, буш палубага форма кигән берәү йөгереп чыкты да:

– Кирәкми! Төшермә! Кире кит! – дип, катерны этәргәндәй көчле хәрәкәт ясап кулын селтәде.

Палубага бау аша үрмәләп азапланган сакаллыга капитан:

– Кире чык! Кире чык, диләр сиңа! – дип кычкырды.

Зуфирәгә кызык булып китте:

– Кешене эштән куу булды түгелме соң бу? – диде ул, Вадимга борылып. – Шушылай бер кул селтәү белән бичараның язмышы хәл кылындымыни инде? Кая монда профсоюз? Кайда ике якны да тыңлап гадел хөкем чыгаручы җәмәгатьчелек?

– Диңгез бәхәсләшү урыны түгел, – диде Вадим. – Корабта капитан сүзе – закон. Иртәгә идарәгә барыр да рәхәтләнеп бәхәсләшер әнә.

«Диңгездә сабан туйлары булмый, анда законнар каты, – дигән иде Зуфирәне эшкә алганда ак чырайлы ябык кеше. – Ял-мазар да юк. Балык килгәндә, үз эшегездән башка да вахта торырга туры килер. Бар кеше белән бергә эшләрсез. Алты сәгать эш, алты сәгать ял. Атналар буе шулай».

Эш дигәне шул булачак икән: Зуфирә, кулына брезент бияләйләр киеп, балыкның эресен вагыннан аерып торачак. Ул үзенең Охот диңгезендә интеккәннәрен исенә төшереп, тетрәнеп куйды. Рәтләп эшли алмаса, аны да шушылай бер селтәнү белән чуттан сызып ташларлар микән?

Алар өчәүләшеп – Вадим, Зуфирә, Донна – палубага чыгып бастылар. Корабларда төрле төстәге бихисап утлар кабынган, аларның чагылышы су өстенә киң юллар һәм тар сукмаклар салган. Каралып яткан култык кочагында моңарчы күз күрмәгән кала күтәрелгән диярсең. Тагын Өмитнең хатка язган сүзләре искә төште: «Диңгез өстендә үзенә бер шәһәр төзелгән сыман тоела...» Бу хыялый шәһәргә каршы, ярга сырышып, сопка итәкләрен киртләп менгән чын каланың утлары

җемелдәшә. Су өстендәге кала белән яр буендагы кала үзләренә генә аңлаешлы телдә сөйләшәләр шикелле.

– Сез шәһәр утларының корабларга ни әйткәнен аңлыйсызмы? – дип сорады Зуфирә Вадимнан.

– Аңлыйм, әлбәттә. «Сәлам сезгә, кораблар, – ди шәһәр, – ерак диңгезләрдән исән-сау кайттыгызмы? Юлларыгыз бик авыр булмадымы? Карлы-бозлы давыллар хәлегезне алмадымы? Усал дулкыннар тәнегезне какшатмадымы?»

– «Юлларыбыз җиңел булмады, әмма без сынатмадык», – дип җавап бирә аңа кораблар, шулай бит? – дип, аның сүзен ялгап алып китте Зуфирә. – «Без кар-бураннарга да, биек дулкыннарга да бирешмәдек, чөнки син безгә иң батыр улларыңны биреп җибәргән идең. Шуңа күрә бүген утларыбыз шушылай якты балкый да. Синең батыр йөрәкле тынгысыз улларың тагын ерак юлларга ашкына, кала, аерылышуларга әзер тор!»

«Улларымның юлы уң булсын, алар альбатрос кошлардан да кыюрак, чыдамрак булсын өчен, мин барысын да эшләрмен», – ди кала.

«Түз, диңгез сабырларны, чыдамнарны гына үз итә», – диде кала Зуфирәгә якты утлары белән.

*** * ***

Алар әкрен генә шәһәрнең үзәк урамы буйлап киттеләр. Мондый урам башка бер генә калада да юктыр: аның бер ягында таш биналар, икенче ягында – яр кырыенда – причаллар, диңгез краннары, баржалар, катерлар. Кала белән корабларның кул бирешеп күрешкән ноктасы.

Урам тын, күктән бәс коела, лампочкалар тирәсендә, вак күбәләкләрдәй, кар бөртекләре бөтерелә иде.

Менә алар бер кечкенә бакча турысына килеп тuктадылар. Биредә тынлык, пакьлек аеруча нык сизелә, уртада, челтәрдән ясалгандай нәфис ябалдашлы агачлар ышыгында – бер һәйкәл күренә иде. Алар, капкадан кереп, эчкә үттеләр. Гади генә һәйкәл иде бу – биек нигез өстенә якорь куелган, аңа, тынлыкны һәм тынычлыкны сакларга теләгәндәй, калын кар мендәре яткан.

Сукмактан һәйкәлгә таба тирән эзләр илтә иде. Кар явып кына киткән әле, ә кемдер килгән инде.

– Лаперуз истәлегенә куелган һәйкәл бу, – диде Вадим. – Минемчә, безнең шәһәрдәге һәйкәлләрнең иң мәгънәлесе һәм матуры... Бу кеше Франциядә туган, унбиш яшеннән корабларда йөзгән, кырык алты яшендә кораблары-ние белән океанда юкка чыккан. Каберенең кайсы диңгез төбендә икәнен дә белгән кеше юк. Ләкин менә үлгәненә ике гасыр инде, җирдә әллә ничә буын алышынды, ә кешеләр һаман аның һәйкәле янына килә. Мин дә киләм, уйланам, кешеләрнең аңа булган сүнмәс мәхәббәтенә гаҗәпләнәм, һәм бер сорау туа минем күңелдә: бу кешене исән чагында өзелеп сөйгән берәр хатын-кыз булды микән? Сагынып-саргаеп көткән бердәнбер яры булганмы аның? Нишләптер бу хакта бер генә энциклопедиядә дә, белешмәдә дә язмыйлар. Ул фәлән-фәлән диңгезләрдә йөзгән, аның карамагындагы фәнни-тикшеренү кораблары фәлән дә төгән дип аталган, фәлән бугазга аның исеме кушылган... Ләкин тере кеше булган бит ул, чын мәгънәсендә кайнар йөрәкле ир-егет булган, башкалар янып сөя белгәнне, ул гына сөймәгәндер дисезме?

– Андый ашкын йөрәкле кешеләрнең сөю хисе башкаларга караганда да көчлерәктер әле, – диде Зуфирә.

– Мавыккандыр, сөйгәндер, билгеле! Ләкин ул туган илен дә, сөйгән ярын да ташлап, каядыр күз күрмәгән якларга, хәвефле юлларга чыгып киткән. Шундый омтылыш була кеше күңелендә, әйтеп-аңлатып булмый торган талпыну ашкындыра аны. Лаперузның ватандашы, бөек фикер иясе Вольтер болай дигән бит: яңа ачыш ясаган кешеләр, шул ачыш юлында берничә адым гына атласалар да, чын мәгънәсендә бәхетлеләр, дигән. Ләкин бу бәхет кешегә бик кыйбатка төшә түгелме? Аның бәрабәренә кеше башка бәхетләрдән мәхрүм булмыймы? Әйтик, туган илдән, сөйгән ярдан аерылуны халык зур бәхетсезлеккә саный. Ә Лаперуз кебекләр үзләрен шул бәхетсезлеккә дучар итәләр, аннан зур бәхет эзләп китәләр. Ничектер бәхет белән бәхетсезлек бер-берсенә килеп урала. Яңа ачышлар ясаган кешеләрнең язмышында күпчелек очракта фаҗига ята. Алыгыз Магелланны: утыз бишкә җиткәч өйләнә, ул сәяхәткә киткәндә бердәнбер улы туып кына кала. Шуннан соң ул аны күрә алмый, ерак җирләрдә башын сала, гаиләсе бөлә. Мондый мисаллар тагын бар. Билгесезлек диңгезенә чыккан һәркем үзенең мәхәббәтен, һәр кеше өчен газиз булган барча әйберне ярда калдырырга тиеш микәнни? Яңа ачыш юнәлешендә берничә генә адым атлаган кеше дә барча кешеләргә хас бәхеттән мәхрүм ителергә тиеш микәнни? Шушы ике бәхетне берьюлы тоеп яшәү мөмкин түгел микәнни?

Зуфирә моңа ни дип тә җавап бирә алмады. Ул үзе, шушы ике бәхетне берләштерергә омтылып, бирегә килде бит...

Алар бакчадан чыктылар. Донна күләгәдәй тавыш-тынсыз арттан иярде.

– Мин, әлбәттә, Магеллан да, Лаперуз да түгел, – дип дәвам итте Вадим. – Ләкин минем дә үз океаным, үтәсе юлларым бар. Сез Гейзерлар үзәнендә булдыгыз, бәлки, аңлагансыздыр.

– Әйе, ул үзән үзе бер билгесез диңгез, – диде Зуфирә.

– Күңелем шунда береккән, башка җирдә яши алмыйм. Мин аның серләрен ачарга, аны башка кешеләр өчен саклап калырга тиеш. Ләкин шушы иманымны иң якын, иң газиз кешегә аңлатудан гаҗизмен. Дөрес, ул аны аңлый да шикелле, ләкин ул минем иманымны үзенеке итеп кабул итә алмый, ул үзәнне минем кебек ярата алмый... Сез хатын-кыз, иҗат, хис кешесе, бәлки, миңа ярдәм итәрсез, бәлки, аның күңеленә ничек ачкыч табарга икәнен әйтерсез?

Тагын бераз тын гына бардылар. Вадим Зуфирәдән тиз генә җавап көтми, аның бары тик эчендәге зарын кемгәдер сөйлисе, серен уртаклашасы килә иде булса кирәк.

– Мин үзәндә беркайчан да эч пошудан интекмим, гейзерларның көндәлеген алып барам, хайваннарны, үсемлекләрне күзәтәм, күп укыйм. Анда эш тулы бер тикшеренү институтына җитәрлек, ә мин берүзем бит.

– Гафу итегез, сез кем булып эшлисез соң? – дип сорады Зуфирә.

– Урманчы мин, штатта гап-гади лесник булып саналам.

– Лесник... кынамыни?

– Ә нигә шулхәтле гаҗәпләнәсез? Урманчы – урман хуҗасы, зур кеше. Ә Гейзерлар үзәненең хуҗасы – дөньяда бер генә! Ләкин мин дә адәм баласы, йөрәк таш түгел. Үзәнгә элегрәк туристларны күп китерәләр иде, мин аларны озатып йөрим. Төркем арасында әле берсенең ягымлы елмаюы, әле берәр зифа буй-сын чагылып китә. Йөрәк сулкылдап куя. Әмма күңелне җәлеп иткән кеше китеп бара, мин аны башка очратмыйм... Берничә ел шулай дәвам итте минем тормыш. Ләкин, бәхетемә димме, бәхетсезлегемә димме, язмыш мине берәү белән очраштырды, ниһаять. Ул җәйне мин Кронока заповеднигында урманчы булып санала идем. Гейзерлар үзәненнән ерак түгел, диңгез буенда. Кайсыдыр акыллы башына заповедникта электр станциясе төзү фикере килгән бит. Берзаман геологлар килеп төште, трактор белән җир казыйлар, тыр да пыр урман сукмакларыннан машина куалар. Бөтен җәнлек-җанварны куркытып, качырып бетерделәр. Ул гынамы, бер ишесе рәхәтләнде киек итенә, тиенде кызыл балыкка, уылдыкка. Үзләренә җитәрлек итеп кенә тотмыйлар, тартма-тартма тутырып, өйләренә озаталар. Урманда әледән-әле мылтык ухылдап тора. Мин йөргән булам чабып, төрле оешмаларга жалу язам, браконьерларны эзәрлеклим, мылтыкларын тартып алам, җәтмәләрен тураклыйм. Безнең арада каты сугыш башланды дияргә була. Ләкин геологлар арасыннан берсе, зифа буйлы, ак йөзлесе күңелгә якынаеп китте бит. Көн саен очрап тора үзе, язын үсеп киткән гөл шикелле күңелгә һаман тирәнрәк тамыр җәя. Сизәм: үзе дә торган саен ягымлырак елмая бу миңа.

«Бер дә гаҗәп түгел», – дип уйлап куйды Зуфирә.

– Тиз аңлаштык без моның белән. Бергә урманнарда йөргәннәрне, кайнар елгаларда коенганнарны сөйләп тормыйм инде. Гашыйклар арасында була торган гадәти хәлләр анысы. Ике ай эчендә бик тиз үсте безнең мәхәббәт. Мин, язылышыйк, кешечә яшик, дигән идем, ә ул язмышларны ныгытып бәйләргә ашыкмады. Кем аңлап бетерсен сезне – хатын-кызларны! Мин ул җәйне бик кызуланып теге Гейзерлар үзәнендәге йортны салу артыннан чаба идем. Йа Алла, ул йортның ничек салынганын, миңа күпмегә төшкәнен белсәгез икән! Хан сараена торырлык булды! Кирәк-ярагын табасы, бар нәрсәне вертолет белән ташыйсы! Аның вертолетын да, кил, бирәбез, дип кенә тормыйлар бит... Ләкин мин ул җәйне ару-талуны белмәдем, усалландым, берәрсе каршы килсә, бугазын чәйнәп өзәргә әзер идем. Аңарчы без Донна белән палаткада кышлый торган идек. Ә хәзер Ленаны ничек палаткада яшәтим? Җитмәсә, бәби көтәбез. Минем бәхетне, минем гайрәтне күрсәгез иде ул чакта! Фантазер! Минем ул очынуым Магелланның хатыны белән баласын үзе белән алып чыгып китәргә теләве кебек үк буш хыял булган икән... Ленам торган саен ныграк моңая, ләкин мин моңа әллә ни борчылмыйм, хатын-кызның четерекле чагы дип аңлатам үземә. Ул өзми-куймый мине үзе белән Ленинградка китәргә үгетли, ә мин, монда яшибез, дим, башканы ишетергә дә теләмим, билгеле. Озак бәхәсләштек без шулай, әмма мин аны үз яныма аударуыма ышанып яшәдем. Берзаман, Петропавловскига врачка күренергә барам, диде бу. Ансыз булмый бит инде, беләм. Мин өйгә мич чыгарып азаплана идем, эшнең тыгыз чагы, үзен генә вертолетка утыртып озаттым. Ике көн көтәм кайтканын, өч көн, инде вертолет та ике тапкыр килеп китте, ә бу кайтмый да кайтмый гына бит! Эчкә пошаман төште минем. Киттем моны эзләп шәһәргә. Ә анда аны Ленинградка кайтып китте диделәр. Башыма суккандай, миңгерәп тордым бераз, аннары билетка чаптым. Икенче көнне үк мин дә моның артыннан очтым. Ишекне Лена үзе ачкач, аның сау-сәламәт икәнлеген күргәч, бар үпкәләрем онытылды, түбәм күккә тиярдәй булды. Сүз әйтә алмыйм, телем көрмәкләнә. Кире борылып чыгып киттем, бардым кибетләргә, ни бар акчама алдым күчтәнәчләр, бәби кирәк-яраклары. Кайттым, Ленага кочагы белән тоттырдым. Кич җитте, Ленаның әти-әнисе, туганнары табын янына җыелды. «Котлагыз безне, дим, без бит ир белән хатын хәзер, озакламый бәбиебез булачак». Барысы да тасраеп миңа карап утыралар. Лена өстәл астыннан минем аякка баса, чыгыйк әле, ди. Чыктык күрше бүлмәгә. «Ни сөйлисең син? – ди бу. – Нинди бәби? Бернинди бәбиебез дә булмаячак безнең!» – «Син... син баланы юк итәргә дә өлгердеңмени? Чыгып кит...

Югыйсә мин сине үтерәчәкмен!» Ул чыгып китте, ә мин караватка аудым. Кич буе яныма беркемне кертмәдем. Аннары тордым да беркем белән саубуллашмый-нитми чыгып киттем. Кайттым кире заповедникка. Дөньям җимерелгән кебек йөрим шулай. Беркөнне кулыма телеграмма китереп тоттыралар: *«Катер белән киләм, каршы ал!»* Заповедник конторасыннан «газик» машинасы сорап алдым, пристаньга барабыз. Урман юлыннан каршыбызга йөк машинасы килә икән, яныбыздан выжт итеп узып китте. Кабинасында өч кеше, кулларында мылтык – ауга барышлары. Мин үзебезнең шоферга, кире борылып, тегеләрне куарга куштым. Без куабыз – тегеләр җиткерми, без чабабыз – тегеләр аның саен кызулый. Ну безнең «газик» бит, йөк машинасы артыннан ничек тә җитәбез инде. Ике машина янәшә бара башлагач, мин, җаен туры китереп, тегеләрнең подножкасына күчтем. Ә аларның шоферы рульне боргалый, мине агач кәүсәсенә бәрдереп сыдыртып төшермәкче...

Зуфирә кәкрәеп-бөкрәеп үскән ташкаен агачларын күз алдына китерде: бәрелсә, Вадимның сөякләрен дә җыеп ала алмаслар иде.

– Мин кузовка үрмәләдем, – дип дәвам итте Вадим. – Ниһаять, болар миннән котылып булмасын аңладылар. Туктадылар. Берсе кабинадан атылып чыкты да миңа төзәп атып та җибәрде. Мин төшеп азаплана идем, пулясы аякка тиде. «Ахмак, – дим моңа, – нишлисең? Төрмәдә черисең киләме әллә?» – «Син күптәннән минем бәгыремдә таш булып утырасың, – ди бу, – миңа хәзер нишләсәм дә бер җавап бирәсе, үтерәм!» – ди. Хикмәт шунда: ул Ленага кызыгып йөргән иде, мин комачауладым... Күрәм: лаякыл исерек бу. Тизрәк җиргә сикердем дә, машина артына ышыкланып, пистолетымны тартып чыгардым. Кара-каршы атышабыз. Ул исерек бит, бүтән тигезә алмады, ә мин аның муенына һәм, гафу итегез, касыгына тигездем. Ул арада пристань ягыннан кешеләр килеп чыкты, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алдылар. Ә мин, Ленаны күрүгә, исәнме урынына: «Син дә йөрисең шунда ачу китереп!» – дип кычкырганымны сизми дә калдым.

– Әйе шул, – диде Зуфирә, уйланып. – Әгәр Лена белән мөнәсәбәтләрегез шулхәтле катлаулы булмаса, браконьерлар белән очрашу бу кадәр фаҗигагә китермәс иде, мөгаен. Сез артык ярсыгансыз, гасабилангансыз, сезгә карап алар ярсыган. Минем баштан да узганы бар андыйрак хәлнең...

Зуфирә үзенең Эльвир өчен Румия белән дәгъвалашып йөргәннәрен исенә төшерде. Йа Алла, чыннан да шулай түбән тәгәрәгән чаклары бар идемени аның? Кемне сөясең бит, түбәнне сөйсәң, аның дәрәҗәсенә төшкәнеңне сизми дә каласың. Ничек диелә әле халык җырында: «Сөяр булсаң, сөймә, җаный, үзеңнән түбәннәрне!»

Вадим Зуфирә белән килешеп бетмәде:

– Атышуда Ленаны турыдан-туры гаепләп булмый анысы. Без еш кына үзебез сөйгән ярларга каты бәгырьле булабыз... Шуннан соң без ике яралыны машина әрҗәсенә сузып салдылар. Юл дыңгырдык бит, поселокка барып җиткәнче, минем имгәнгән аягымны ике кулы белән тотып кайтты Лена.

– Ә кем бәйләде, дәвалады?

– Шин салу, бәйләү хәтлесен үзем дә беләм инде, үзәндә берьялгызы яшәгән кешегә аны белмәү мөмкин түгел. Вертолет икенче көнне килеп җитте. Мине Мәскәүгә озаттылар. Катлаулы операциядән соң аягым җиде сантиметрга кыскарып калган иде. Рәхмәт Елизаровка, үз методы белән озайтты менә.

– Ә Лена?

– Мәскәүдә чакта мин аны яныма китермәдем. Рәнҗүем бик көчле иде... Яныма галимә карчыклар килеп йөрде, гейзерларның кадерен белүчеләр. Ифрат ярата алар мине.

– Ә теге браконьер?

– Ул хәзер төрмәдә. Алты ел бирделәр. «Кайту белән иң беренче эшем итеп, Николаевны эзләп табам, барыбер җир йөзендә яшәтмим» дигән сүзләрен китереп ирештерделәр инде. Сез хатын-кыз, әйтү кыен, ләкин... кешеләр бит без! Минем пуля аның ирлеген зарарлаган, шуны гафу итә алмый икән.

– Әгәр ул әйткән сүзендә торса? Үзәнгә килеп, сагалап йөрсә? Курыкмыйсызмы?

– Ә беләсезме, Зуфирә, кеше өчен мәхәббәттән дә, яшәүнең үзеннән дә кадерлерәк нәрсәләр бар. Аны сүз белән әйтеп тә булмый торгандыр, җыр яки сурәтләр ярдәмендә, йөрәктән йөрәккә хис белән генә күчереп буладыр. Башым исән чакта китә алмыйм мин үзәннән...

– Донна да ярдәм итә алмас, ахрысы, сезгә...

Зуфирә күләгә кебек ияреп килгән эткә борылып карады, тегесе аның тезенә килеп ышкылды.

– Минемчә, эт усалрак булырга тиеш, – дип өстәде Зуфирә. – Ә бу, гафу итегез, ахмаграк кебек тоела миңа.

– Ахмак түгел, бик акыллы, сизгер ул. Мин үзем аңардагы явызлыкны бетерергә тырыштым, җан иясен тешләргә өйрәнмәсен, усал итеп өрмәсен, беркемне дә әзәрлекли белмәсен, дидем. Күрәсез, ерткычны да яхшы күңелле итеп була! Ә кешеләр үзара мөнәсәбәтләрен үзләре хәл

кылырга тиеш дип исәплим. Ул бандитка гына бирешеп тормам! Мине бүтән нәрсә гажизләндерә: ничек итеп Лenaның йөрәгендә дә үз күңелемдәге талпыну уты кабызырга, ничек итеп анда гейзерларга мәхәббәт уятырга? Ташлап китмәсен иде ул безне, гейзерларны да, мине дә! Минем белән бергә үзәндә яшәүне бәхетнең зурысы дип санасын иде, тәкатьсез булсын иде!

Зуфирә кыргый тарлавыктагы ялгыз йортны күз алдына китерде. Кышын тәрәзәләрен кар томалап куя икән. Әбүгалисина мәгарәсе... «Ә син Әбүгалисинадан уздырмакчы, мәгарәгә сөйгән ярың белән бергә кермәкче! – дип эчтән көлемсерәп уйлады ул. – Кем белән диген әле! Ленинград каласында туып үскән кыз белән! Ничек көн үткәрсен ул анда! Ә аннан чыкса – тышта аюлар, россомахалар... Хәер, тышта гына түгел, аларның әле өйгә бәреп керә торган гадәтләре дә бар икән бит! Шуның өстәвенә өй тирәсендә әлеге дә баягы үч алырга килгән бандит килеп сарып йөрсә?..»

– Ә ул һаман мине үз ягына аударырга тырыша. – Вадимның сүзләре Зуфирәнең аңына көчкә килеп җитте. – «Украинада туып үскән егет бит син, кулыңнан килмәгән эш юк, ди. Берзаман кыргыйларча яшәүдән туярсың, акылга утырырсың, барыбер миңа килерсең, көтәм», – дип яза. Хәзер менә үзе килеп үгетләмәкче.

– Үзегез әйттегез бит, ике бәхет бергә килми, дип. Менә мин дә талпынып килдем, ләкин кая соң ул бәхет? – диде сагышланып Зуфирә.

– Сезгә дә җиңел түгел... Һәм мин сезне өметләндерә дә алмыйм.

– Ник дөресен әйтмисез? Ни булды соңгы өч ай эчендә?

– Бер киңәшем бар барын... Театрда булдыгызмы әле? «Ә аннары тынлык» дигән спектакльне карагыз әле. Шунда, мөгаен, үзегез аңларсыз.

*** * ***

Спектакль карт ата-ана белән аларның балалары арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында булып чыкты. Хәер, аның каенанасы мөнәсәбәтенә бераз ишарә бар иде барын. Тик анысы үткәннәрдә калды бит инде, үкенече дә юк. Вадимның серле киная белән театрга барырга кушуын ничек аңларга? Зуфирә башта бик сәерсенде. Ләкин әкренләп үз борчуларын онытты, сәхнәдә барган вакыйгалар аны бөтенләй башка дөньяга, бүтән язмышларга алып кереп китте...

Кайдадыр бик еракта, Җир шарының икенче ягында яшәп яткан карт белән карчык гомер кичергән йорт-җирләрен сатарга мәҗбүр булалар да балалары кулына калалар. Ләкин биш баланың берсе дә аларны үзенә алырга теләми. Бәхәсләшә, дәгъвалаша торгач, алар мондый карарга киләләр: әти-әниләрен берәм-берәм чиратлашып карарга. Шулай итеп, берсе – анасын, икенчесе атасын үзенә ала. Илле ел буе бер көн дә бер-берсеннән аерым яшәмәгән кешеләрне балалары аера... Алар икесе ике ерак шәһәргә китәргә тиешләр. Икесе дә инде башка очрашмаячакларын беләләр, әмма бер-берсенең күңелен аяп, саубуллашканда бу хакта ләм-мим сүз ычкындырмыйлар.

Бу ике бичараның фаҗигасе иркен залда, кызыл бәрхет утыргычларда утырган йөзләрчә кешеләрнең күңелен биләп алды. Аеруча карчык тетрәндерде, бөкрәебрәк килгән гәүдәсенең һәр хәрәкәте, күкрәк түреннән чыккан калын йомшак тавышы белән халыкның йөрәген уч төбендә тоткандай итте, сокландырды, кызгандырды һәм елатты.

Соңыннан карт белән карчыкны әллә ничә тапкыр пәрдә алдына чакырып чыгардылар, туктаусыз:

– Браво, Казанская, молодец, Казанская! – дип кычкырдылар.

Димәк, бу карт артистка – Казанская. Бәлки, Казаннандыр? Алай булуы да ихтимал, шәһәрдә Татарстаннан килгән кешеләр күп, кем белән генә очрашма, татар дуслары белән мактаналар.

Зуфирә театрга килеп рәхәт сәгатьләр үткәрде, Вадимның кинаясе генә аңлашылмады.

Икенче көнне Зуфирә, телефоннан шалтыратып, шуны сорамакчы иде, Вадим аңа авыз ачарга да ирек бирмәде:

– Кич белән безгә килегез, бездә бүген уңыш кичәсе була!

– Нинди кичә?

– Уңыш кичәсе, җәен җыйган уңышны барлыйбыз. Килегез, үкенмәссез, кызык кешеләр була.

Кич җилле, буранлы, автобуслар шыгрым тулы иде, Зуфирә билгеләнгән вакытка төгәл барып җитә алмады. Вадим белән Донна аны тукталышта каршы алдылар. Урамнан өйгә барып кергәнче, Вадим шуны аңлатты: алар һәр көзне шулай җыелышып, җәен нәрсәләр күргәннәрен сөйлиләр, фотолар, слайдлар карыйлар икән. Ишекне җиләк кебек пешкән, ак йөзле, соры күлмәкле һәм куе соргылт чәчле хатын-кыз ачты.

– Лена, – дип таныштырды аны Вадим һәм Зуфирәнең кемлеген аңлатты. Хатын ваемсыз ачык чырай белән исәнләште.

Аның кемлеген бер карауда бәяләп куйды Зуфирә: рус хатын-кызларына хас ягымлылык балкып торган ачык йөзле, бераз пошмасрак, дөньяда үзе дә рәхәт яшәргә ярата торган һәм башкаларны да тынычландыра, күңелләрне күрә белә торган кеше иде бу. Өйгә ямь бирүчән сөйкемле хатын һәм

күпне гафу итә белүчән, йомшак куллы, тәмле телле, кайгыртучан ана булыр өчен яратылган җан иясе. Ирләрнең андыйларны яратмавы мөмкин түгел.

Лена, соры песи шикелле, йомшак хәрәкәт белән артка чигенде, хәер, песигә генә түгел, янында торган Доннага да охшаган иде бугай ул!

Вадим Зуфирәне башка кунаклар белән таныштырды: икесе дә озын буйлы, туры сынлы, ыспай киемле ир белән хатын, берсе – геолог, икенчесе сейсмолог икән. Какча яңаклы, эчке бер дулкынланудан янып торган күзле яшь ирне Борис диде, анысы өлкә телестудиясенең операторы булып чыкты. Иң соңыннан, ничектер бераз ясалма хәрәкәт белән, башын артка ташлап, туры кара чәчен икегә аерып озынча йөзе тирәли салындырып төшергән бер хатын-кыз урындыктан торып басты. Аның үз-үзен тотышы да, бик үк чибәр булмаган йөзе дә, челтәрле ак кофта белән озын кара юбка кигән нечкә билле төз сыны да игътибарны җәлеп итә, хәтердә сеңеп кала торган иде.

– Клара, – дип, озын бармаклы тар кулын Зуфирәгә сузды ул. Аның күкрәк түреннән чыккан калын йомшак тавышы бик таныш булып тоелды. «Кайчан күрдем соң әле мин бу кешене? – дип уйлады Зуфирә. – Хәер, бер күрсәң, онытылырлыкмыни? Күргәнем юк үзен, ә тавышы бик таныш...»

– Сез Казаннан икәнсез, – диде Клара, бәрхет күзләре белән генә елмаеп. – Безне якташлар дияргә була. Дөрес, мин үзем Чиләбе өлкәсеннән, Пласт шәһәреннән. Алай да сәхнә өчен фамилиямне Казанская дип алдым. Чөнки ирем Казаннан минем. Бәлки, ишеткәнегез бардыр: Гасимов, Өмит Гасимов, капитан?

Зуфирәнең аяк астында идән чайкалып киткәндәй булды. Димәк, кичә бөтен театрны үз ихтыярына буйсындырып торган карт кортка – шушы артистка һәм ул... Өмитнең хатыны?

Һушына килә алмый күпме торгандыр Зуфирә, ниһаять, аның аңына Вадимның тавышы килеп ирешә, алай да әле сүзләре томан аша ишетелгән кебек иде:

– Кызганыч, бүген менә арабызда Өмит юк, иң кызыклы кыйсса аныкы була торган иде.

Клара, башын артка ташлап, күкрәк тавышы белән көлеп җибәрде:

– Ә мин аны сезнең янга бүтән җибәрмим, җибәрмим, җибәрмим! Килсәк тә, икәү бергә җитәкләшеп киләбез дә җитәкләшеп кайтып китәбез. Ленаны да котыртып куям, сезне ялгыз калдырмасын. Югыйсә сезнең, үзегезне буйдакка санап, айлар буе монда икәүләшеп бездән качып ята торган яман гадәтегез бар!

– Үзегез гаепле, – диде Вадим, аның шаяруына кушылмыйча, җитди итеп. – Араларны үзегез өзәсез. Мәңгегә өзгәндәй итәсез дә аннары ике арага тагын җеп суза башлыйсыз...

Аның бу сүзләрендә аермачык булып үпкәләү сизелсә дә, Клара моны аңламамышка салышты:

– Хатын-кызның аз гына капризы булыр инде. Ә сез гафу итәргә өйрәнегез. Шулай бит, Зуфирә, мин дөрес әйтәм бит!

Зуфирә тел тибрәтергә көч тапмады. Вадимның беренче очрашканда ук: «Ул бирегә кайтмас инде», – дигән сүзләренең мәгънәсе аңлашылды. Димәк, Зуфирә монда килер юлларда адашып йөргән арада, Өмит белән хатыны килешеп куйганнар, шуңа күрә Вадим хатларны Өмиткә бирмәгән.

– Кунаклар, табын янына рәхим итегез! – диде Лена.

Шунда гына Зуфирә як-ягына әйләнеп карады. Бүлмә танымаслык булып үзгәргән, капчыклар, тартмалар каядыр юкка чыккан, идән юылган, өстәлгә ак ашъяулык җәелеп, матур савыт-саба тезелгән. Тәрәзәдә сары пәрдә... Зуфирәнең элекке килүендә бар иде микән ул, әллә анысын да Лена элгәнме?

Хәер, Лена аяк баскан урын, тылсым белән дигәндәй, үзеннән-үзе ямьләнеп китәргә тиеш иде шикелле.

Өстәлдә, чәчәкле тәлинкәләрдә ит, кәтлит, кыздырылган ипи телемнәре, кызыл балык, уылдык, кысла ише ризыклар һәм нибары бер шешә кызыл шәраб тора иде. Хуҗабикәнең сыен мактадылар, тик Зуфирә генә тамагыннан ни үткәнен тоймады.

Сыйның иң зурысы – монда җыелган кешеләрнең «җәйге уңышы» иде. Геолог, төрле төстәге ташлар күрсәтә-күрсәтә, кайсы урында нинди казылма байлыклар ачканнарын сөйләде. Аның хатыны Толбачик вулканының кайчан атачагын ни рәвешле алдан белгәннәрен, булачак янар тау янына галимнәрне, журналистларны алдан ук чакырып куйганнарын әйтте.

– Монда без барыбыз да үз кешеләр, яшереп-нитеп маташма, дөресен генә әйт әле, тагын кайчан җир тетрәячәк? – дип сорады аннан сузып кына иренчәк тавыш белән Лена. Ул урындыкта шундый җәйлап, иркә мәче кебек күзләрен кысып, рәхәт итеп утыра, аркасыннан сыйпап җибәрсәң, мырлап куяр кебек тоела иде. – Югыйсә әнә кайберәүләр бик аяныч хәлләрдә калгалыйлар икән. Усть-Камчатскийда төнлә җир тетри башлагач, бер хатын урам уртасына ялангач килеш йөгереп чыккан, ди. Ваннада коенып яткан чагы булган да куркуыннан киенәсен оныткан. Тора икән шулай халык арасында көзге кебек ялтырап. Без дә шундый хәлгә калмыйк тагы!

Барысы да җиңелчә генә көлешеп алдылар.

– Коена бирегез! – диде сейсмолог хатын, шаярып. – Мин үземнең дус-ишләрне кыен хәлгә куймам, ванналардан чыгыгыз дип, алдан хәбәр итәрмен!

Аннары, утны сүндереп, эпидиаскоп аша слайдлар карадылар. Какча яңаклы, янып торган күзле оператор Толбачик вулканының атканын вертолеттан төшереп йөргән икән. Чакрымнарча биеклеккә ыргылган ут-ялкын, төтен-сөрем баганаларын, тирә-якка сибелгән зур-зур ташларны (аларны вулкан бомбалары дип атыйлар икән), су урынына эреп аккан комташ елгаларын, ул елгалар агымына эләгеп дөрләп янган урманнарны, үзәннәрне... Нинди кечкенә, зәгыйфь, көчсез булып күренә икән кеше үзе бу һәлакәт, дәһшәт һәм шул ук вакытта гүзәл кодрәт каршысында!..

Ләкин барыннан да бигрәк үзәкне өзгәне, җанны тетрәткәне шушы дәһшәт каршында барча тереклек ияләренең бердәмлекләрен тоюы булды. Менә боланнар палатка янына сыенганнар, кешеләрдән ярдәм көтәләр, тычканнар, аяк арасына ышыкланып, күктән яуган ташлардан котылу чарасын эзли, ялкынга эләгеп көйгән кошчыклар, учка кунып, тамчылап су эчә... Зур дәһшәтләр вакытында безнең барыбызны да бер үк язмыш көтә, без барыбыз да җир балалары, без бер-беребезгә ярдәм итәргә тиеш, ди иде гүяки бу күренешләр. Менә кайчан аермачык сизелә икән ул тереклекнең бердәмлеге!

Вадимның слайдлары исә тереклек ияләренең рәхәт, тыныч, мул һәм гүзәл бер мохиттә яшәүләре турында иде. Куаклар янында боланнар, җиләк ашап йөрүче аю, тездән җылы суда тыныч кына басып торган аккошлар... Аларның тынычлыгы кеше өчен дә дөньяның – тыныч, ямьле, яшәүнең рәхәт булуы хакында сөйли.

Вадим, елмаеп-көлемсерәп, үзе төшергән кадрларны аңлата, аның бөтен кыяфәтеннән җан тынычлыгы, хәтта бераз гамьсезлек бөркелеп тора иде. Бу – Зуфирә белгән киеренке рухлы, таләпчән һәм хәрәкәтчән Вадим түгел иде. Ленаның гамьсезлеге йокканмы аңа, әллә бу – аның сөйгән яры янында бөтен җаны белән вакытлыча гына ял итеп алуымы? Ни генә булмасын, Вадим да, үзе әйтмешли, табигать баласы бит!

Зуфирә тагын борылып Ленага карады: һаман шулай җайлы итеп, күзләрен кыса төшеп, рәхәт чигеп утыра. Җиңдем дип уйлый торгандыр, бәлки. Ләкин, юк, ялгыша Лена. Бу – вакытлы гына килешү, диңгезнең беразга гына тынып торуы, менә озакламый офык тирәнлегеннән ургылып чыккан тыгыз җил аның өстен тынгысызлаячак, дулкыннар кубачак, чоңгыллардан күтәрелгән көмеш яллы тулпарлар Вадимны үзләре белән алып китәчәк. Тагын еракка, җирнең тамырлары ачылган, йөрәк тибеше һәм сулышы ишетелгән төшкә...

Ә бәлки, киресенчәдер, Лена Вадимның иманын кабул иткәндер, аның белән калырга ниятләгәндер? Ай-һай ла, бу иркә песи йомшак диваннарсыз, сары пәрдәләрсез, фирменный бутербродларсыз һәм күңелне кытыклый торган яңалыклар алып килә торган дус-ишләрсез яши алырмы икән?.. Шәһәрдә үскән бала бит ул, аңа телевизор, трамвай, зур кибетләр, пар белән җылытылган, йомышка йөри торган почмагы үз эчендә булган йорт кирәк. Аның каны да Вадим канына караганда сыеграктыр, аграктыр, ул әкренрәк, талгынрак ага торгандыр... Ул канның агышын көчәйтерлек, бу йокымсыраган күңелне кузгатырлык берәр көч бармы бу дөньяда?

– Хәзер сүзне Кларага бирәбез, Кларага, Кларага, – диде һич көтмәгәндә калкынып, дәртләнеп Лена. – Ну, Клара, котлыйбыз, бөтен шәһәр сиңа гашыйк. Соңгы ролең белән син һәммә кешене хәйран иткәнсең. Мин дә иртәгә үк театрга барам. Шуннан берәр монолог укып күрсәт әле! Әйдәгез, кул чабып сорыйбыз!

Казанская бераз ясалмарак, мәһабәт хәрәкәт белән нечкә сынын турайтып торып басты. Зуфирәгә ул кыланчык булып күренде: «Кара чәч, кара юбка, ак йөз, ак кофта һәм шундый кискен хәрәкәтләр... Саесканга охшаган!» – дип уйлады ул, көнчелеген тыя алмыйча.

– Спектакльне кабатлауның нигә кирәге бар? – диде Клара, сәхнәдә күнеккән гадәт буенча, кирәгеннән артыграк кычкырып. – Мин сезгә бер җыр җырлап күрсәтим әле. Георгий Поротовтан камчадалларның борынгы ыруг җырын отып алдым, тыңлагыз.

Ул, башын чайкап, чәчләрен таратып җибәрде, кулларын стенадагы өч янар тау сурәтенә таба сузып, күкрәк түреннән чыккан калын, йомшак тавыш белән, моңарчы Зуфирә беркайчан да ишетмәгән ят, ләкин бәгырьгә үтеп керә торган аһәң белән, моңлы һәм дәртле итеп башлап җибәрде:

Ковран тавы өсләреннән
Аккошлар очып бара...

Ул, кулларын баш очына күтәреп, очып китәргә теләгәндәй омтылыш ясады, челтәрле озын җиңнәре кош канатларыдай җилпенде...

Ук атты төзәп аларга
Бер аучы – йөзе кара...
Ук тиде аккош кызына,
Канаткаен сындырды,
Аның елау авазыннан

Таш таулар сыкрап торды...

Җырчы, сызлануны үзе кичергәндәй, кулларын тигезле-тигезсез җилпеп, сыгылып төште. Ул җырны гына түгел, камчадалларның борынгы биюен дә өйрәнгән иде. Бу инде кичә бөтен театрны тетрәндереп торткан карчык та, бераз кыланчык, саесканга охшаган артистка да түгел, бу – текә күкрәкле кыялар белән зәңгәр диңгез очрашкан урында, җирнең эссе карынында яралган җан иясе иде. Ул үзенең барча тереклек ияләре белән бер тамырдан үскәнен бөтен йөрәге белән тоеп тора, ул үзен ак далалар өстеннән талпынып очкан аккошлар белән бер нәселдән дип саный. Ул тәне аша җирнең йөрәк тибешен күккә таба үткәрә һәм кояш нурын җиргә тоташтыра. Ул үзенең табигать, бөтен тереклек дөньясы белән бердәмлеген янар таулар яктысында бар галәмгә белдерә, шул бердәмлекнең тантанасын игълан итә...

Ике егет – ике аккош
Ашкынды кыз янына,
Күтәрделәр кызны алар
Көчле канатларына.

Юк, бу җыр гына түгел, йөрәкләрдән йөрәкләргә кайнар хис, тереклекнең мәңгелегенә һәм гаделлеккә ышаныч агыла. Бик борынгы ата-бабалардан, кайчандыр тереклек яралган гасырлардан безнең йөрәккә килеп тоташкан моң бу.

Ковран тавы өсләреннән
Алар бергә очтылар,
Туганлыкка, тугрылыкка
Дан җырлады аккошлар...

Клара кыргыйлык һәм нәфислек кушылган хәрәкәт белән кулларын соңгы тапкыр җилпеде дә, башын иеп, йөзендә серле елмаю саклап, тынып калды.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Барысы да хисләрен, соклануларын аңлатудан гаҗиз иделәр. Зуфирә уң ягына борылып карады да шаккатты: моңарчы песи кебек йокымсырап утырган Лена танымаслык булып үзгәргән иде. Аның күзләре зур ачылып актырган, аларда киек җәнлек күзендәге кебек сизгер ут кабынган, гәүдәсе турайган, киеренкеләнгән, әйтерсең лә каядыр сикерергә яки тыелгысыз омтылыш белән йөгерергә әзерләнгән иде. Дивандагы мендәрдә аунарга күнеккән өй песие түгел иде инде бу, ә бәлки, кара урманда ботактан ботакка сикереп яшәүче кыргый селәүсен иде...

«Чын сәнгать мондыйларның да күңелен кузгата, кан агышын кызулата ала икән, Вадим хаклы, – дип уйлады Зуфирә. – Кеше күңелләрен шушы рәвешле бер генә кузгату өчен гомереңне багышласаң да үкенерлек түгел. Менә нәрсә аңлата икән ул Өмитнең «үзеңне янар таулар яктысында сынарга кирәк» дигән сүзләре!»

– «Мэнго» кызлары күрсә, көнләшеп үләр иде, – диде, ниһаять, тынлыкны бозып Лена.

– Ах, шушылай рәхәтләнеп уйнарлык пьеса язучы булсын иде! – дип көрсенде Клара. – Янар таулар фонында, шушы җирдә туып үскән саф һәм эчкерсез, олы йөрәкле, нәфис һәм батыр кызны уйныйсым килә!

Ул карашын янә түрдәге өч янар тау сурәтенә төбәде.

Зуфирәне беренче караудан ук сәерсендергән өйрәнчек рәсем иде ул, анда алгы план белән арткы планның бер-берсенә ябышмаганлыгы күзгә ташланган иде. Хәзер бу рәсемне кинәт барысы да өр-яңадан күргәндәй булдылар.

– Вадим, син әллә картиналар язуыңны бөтенләй ташладың инде? Кайчан алыштырасың бу иске рәсемеңне? – дип сорады сейсмолог хатын.

– Мин рәссам түгел, оста барда кулың тый, диләр. Безнең арада бүген чын рәссам бар бит!

Барысы да, борылып, Зуфирәгә төбәлделәр. Аның исә янар таулар яктысында да сынатмаслык казанышлары юк иде шул әле, юк иде. Ул үзен бу кешеләр арасында чит-ят итеп тойды, ашыгып хушлаша башлады. Вадим белән Донна аны озата чыктылар.

– Җә, безнең дуслар хакында ни әйтерсез? – дип сорады Вадим.

– Ник сез миңа Казанская турында алдан әйтеп куймадыгыз?

– Кешенең кан саркыган йөрәгенә ничек итеп пычак кадыйсың... Театрда һәммәсен үзегез аңларсыз дип уйлаган идем, ә сез...

– Ул чыннан да искиткеч талант. Ленаны үз иманыгызга китерергә теләсәгез, бу эшне Кларага гына кушыгыз. Кеше күңелен теләсә нишләтә ала ул. Нигә сез бу үтенеч белән миңа мөрәҗәгать иттегез?

– Өмит белән аларның мөнәсәбәте бик катлаулы иде. Миндә түгел иде кайгылары, үзләренеке дә баштан ашкан иде. Алар арасында буталырга яхшысынмадым...

– Хәзер аралары җайланган бит инде! – диде Зуфирә, сызланып. – Хәзер инде Клара белән рәхәтләнеп сөйләшә аласыз, минем кирәгем дә калмаган!

Зуфирә саубуллашып та тормыйча, борылып урам буйлап китте. «Ник чакырдыгыз мине монда, ник таныштырдыгыз? – дип рәнҗеде ул эченнән. – Минем алданасым килә, хыялларым дөньясында тагын бераз гына булса да яшисем килә! Яшьлектә генә ул һаман дөреслекне ачыкларга омтыласың, олыгая барган саен, ялганга ышанып булса да, хыялыңда гына булса да, бәхет дәрьясында йөзәсең килә!» – дип пышылдады ул каршы искән җилгә. Җил аның ялваруын авызыннан өзеп алып китте дә, җавап итеп, йөзгә кар бөртекләре китереп бәрде.

Бүлмәсенә кайтып кергәч, Зуфирә төлке якалы пальтосы белән төлке бүреген караватына ташлады да күптән кулына алмаган этюдникгын ачты. Хәзер инде ул Өмитнең портретын ни өчен яза алмаганын аңлаган иде. Ул аны бик өстән генә – кыю карашлы романтик итеп, тынгысыз күңелле, намуслы һәм ыспай, чибәр кеше итеп кенә күз алдына китергән. Аның фаҗигаләрен, язмышының бөтен катлаулылыгын белмәгән. Әйе, Өмит кебекләр көчле, гайрәтле, алар башка кешеләр татый алмаган бәхетне даулап алалар, ләкин шул ук вакытта гади кешеләр өчен бик кадерле, газиз нәрсәләрдән мәхрүм булалар. Бу аларга җиңел генә бирелми... Портретта аның зур бәхете, җиңүе генә түгел, менә шул катлаулы язмышы, фаҗигасе дә чагылырга тиеш.

Зуфирәнең кулы астында фломастер белән сызган сызыклар җанланды, хәрәкәткә килде. Әйе, кешеләрне тасвирлаганда да, табигатьне сурәтләгәндә дә, бу катлаулы мәгънәне, җан газапларын һәм җиңү тантанасын – үз-үзеңне җиңү тантанасын! – тулысынча күрсәтә алсаң гына уңышка ирешәсең.

Биек сопкаларның шәфәкъ нурына коенган ак түбәләрен генә күрсәтү җитми, аларның биленә уралган болыт күләгәсендәге җирне дә күрсәтә белергә кирәк. Иркен диңгезләрдә чапкан көмеш яллы җитез тулпарларның каян күтәрелгәнен һәм кая киткәнен, офык янындагы упкынның тирәнлеген, суга бата-чума уйнаган җанварларның мәһабәтлеген аңлата белергә кирәк. Утлар кабызган корабларның матурлыгын гына түгел, аларның шәһәр утлары белән ниләр сөйләшкәнен тасвирларга кирәк. Шуларның барысына да үзеңнең мәхәббәтеңне, соклануыңны, йөрәгең сызлавын куша белергә кирәк. Син кичергәннәр, төсләр һәм сызыклар аша җанланып, картинаны караган һәр кеше йөрәгендә шундый ук соклану, мәхәббәт, йөрәк сызлавын һәм талпыну уятырлык булсын...

Менә Өмитнең йөзе, киерелгән кашлары астында нурлы күзләре. Бу күзләрдә аның давыллы диңгезгә мәхәббәте, батырлыгы һәм Зуфирә белән, Клара белән булган катлаулы мөнәсәбәте... Өмитнең хатыны белән ике арада нинди хәлләр булганын белеп бетерми Зуфирә, ләкин талантлы, тормышта һәм иҗатта комсыз, ашкынуларда тәкатьсез ике кешенең үзара мөнәсәбәте берничек тә гади генә була алмый. Берсе дулкын кебек, икенчесе яр кебек булса, аларга җиңелрәк булыр иде, чөнки дулкын, бер булмаса, бер ярга килеп сыена. Ләкин Өмит белән Клара икесе дә диңгездәге көмеш яллы чаптар шикелле. Гомер юлын янәшә чабып узу насыйп булырмы аларга? Монысы инде аларның үз эше. Зуфирәнең алар арасына керергә хакы юк... Аның шушы олы йөрәкле кешеләр алдында баш июе һәм бу чигенешнең җиңел генә бирелмәве дә чагылырга тиеш портретта.

Зуфирә кинәт үзендә бер җиңеллек сизде, җаны канатлангандай булды, ул канатлар күтәреп алып киттеләр, карлы далалар өстеннән талпынып очкан аккошлар кебек, аның күз күреме киңәйде. Шул ук вакытта тормышның бөтен ваклыклары аста калды, күзгә күренмәс булды, Зуфирә үзен гаҗәеп кодрәтле, саф, бөек итеп хис итте. Аның өчен тормышның олы бер мәгънәсе ачылды һәм ул мәгънә мәхәббәтнең үзеннән, хәтта кешенең гомереннән дә кадерлерәк, өстенрәк иде...

Онытылып эшләде Зуфирә. Кинәт идәннең бер якка шуышканын тоеп: «Ялыктым», – дип уйлады. Ләкин пумалачыгы төшеп киткәч һәм түшәмдәге лампочканың чайкалып торганын күргәч, ул җир тетрәгәнен аңлады. Коридорга тавышлар ишетелде, кемнәрдер аның ишеге турыннан ашыгып узып китте.

Ул тәрәзә янына килде. Тышта буран тынган, кар очканы күренми иде. Зуфирә, тынын кысып, тагын идәннең шуышканын көтте. Ләкин тетрәү башка кабатланмады. Коридорда тавышлар тынды, тышта кар өстендә яткан яктылык таплары юкка чыкты күрәсең, тәрәзәләр караңгыланды, башка бүлмәләрдә утларны сүндерделәр.

Зуфирә дә караватка ятты, әмма күзенә йокы кермәде, киресенчә, күңелендәге дулкын көчәйде генә. Аның күзләреннән ирексездән яшь акты, татлы күз яшьләре иде бу. Ул үзендә бүген зур борылыш булганын, үзенең гомерендә иң бәхетле минутларын кичергәнен аңлый иде. Аңа бүген бөек сер ачылды... Бу бәхет бик сирәк кешеләргә генә бирелә, яңа утрауларга аяк баскан диңгезчеләргә, яңа ачышлар ясаган галимнәргә, барча кеше күңелләрен тетрәтә алган артистларга таныш хис иде бу, Вольтер әйткән чын бәхет иде.

– Рәхмәт сиңа, Өмит, – дип пышылдады Зуфирә. – Син миңа шушы бәхеткә ирешү юлын күрсәттең.

Шунда Өмитнең үтәлми калган бер вәгъдәсе хәтеренә килде: кайнар күлдә коенмады бит әле Зуфирә!

...Ул беренче автобус белән Паратунка авылына килеп төшкәндә, коену бассейны ачылмаган иде әле.

Зуфирә авылны карап килергә булды. Ап-ак кар түшәлгән урам тыныч, йортлар-ихаталар нәкъ Татарстан авылларындагыча иде, әмма анда-санда ындыр артларыннан пар күтәрелә, Вилючинская сопкасының түбәсендә иртәнге кояш нуры яна – үзенең җир читендә икәнлегеңне сизеп-тоеп торасың.

Пыяла түбәле теплица ишеге төбендә диңгезче киемендәге егет кар көрәп азаплана иде. Урта юлдан аңа таба тирән эз салынган, Зуфирә шул эзләргә басып, егет янына китте.

– Исәнмесез! Бу нинди теплица?

– Санаторийныкы.

– Кайнар чишмәләр белән җылытыламы?

– Шулай инде, – диде егет. Аның кем белән булса да сөйләшәсе килә иде булса кирәк, кыска-кыска сорауларга озын итеп җавап бирергә тотынды. Көрәк сабына таянып, үзенең Белоруссиядән икәнен, армиягә диңгезче хезмәтенә алынса да, корабларда йөзә алмавын, авырып китүе сәбәпле менә шушында күчерелүен сөйләп бирде. – Нәрсә монда, кар да җил, җәйне күрми дә каласың, – диде ул сагышлы тавыш белән. – Ә безнең Белоруссиядә кыш бөтенләй булмый диярлек. Анда хәзер дә җылы әле!

Ул теплица ишеген ачып, Зуфирәне эчкә алып керде. Түшәмгә хәтле үрмәләгән помидор сабаклары корый башлаган иде инде.

– Уңышны җыеп алдылар, шулай да сезгә авыз иттерерлек кенә табып була, – диде егет.

Һәм, чыннан да, эчтәнрәк ике кызыл помидор алып чыгып бирде. Шулай итеп, Зуфирәгә Камчатканың тагын бер сыен татып карау насыйп булды. Кем сыйлады диген әле! Белоруссия егете!

Зуфирә, рәхмәт әйтеп, егетнең сагышлы ак йөзенә карады. Әйе, бу кеше өчен тормышның олы бер мәгънәсе ачылмый калыр, мөгаен. Өмитләр, Вадимнар, Клаpалар омтылган биеклек аны ымсындырмас. Егетнең күзләре зәңгәр, ләкин аларга диңгез зәңгәрлеге йокмаган, алардан Белоруссиянең рәшәле, йомшак, аксыл күге карый шикелле.

Ул күзләрнең томанлы яктылыгы Зуфирәгә ияреп барды. Татарстанның рәшәле офыгын, урман-кырлардагы төсләрнең берсеннән икенчесенә талгын гына күчешен, аларның күзгә йомшаклыгын, күңелләрне тынычландыра торган җылылыгын искә төшерделәр алар. Һәрнәрсәнең матурлыгын, зурлыгын тою өчен, чагыштырып карарга кирәк, диләр иде, хак икән. Яшьлекнең кадере – картайгач, сөйгән ярның кадере – аерылгач, туган җирнең кадере чит җирләргә киткәч ныграк беленәдер, күрәсең...

Хәзер инде Зуфирә салават күперенең яралган чагын ничек тасвирларга кирәклеген белә иде. Ерак диңгезләрдән әйләнеп кайткач, ул үзендә туган җиренең гүзәллеген дә бөтен зурлыгы белән кешеләргә аңлатырлык көч, илһам табар.

Бассейн ачылган иде инде. Зуфирә кызыл граниттан салынган, бакырдан чүкеп ясалган сурәтләр белән бизәлгән бина эченә керде. Аңа өс-баш алыштыра торган урынны күрсәттеләр, бассейнга чыкканчы кайнар душта коенырга киңәш иттеләр.

Бассейн үзе бинаның икенче ягында, ачык һавада икән. Аңа таба илтә торган таш сукмакка резин көпшәләрдән кайнар су агып тора, ләкин барыбер урыны-урыны белән ялан аягың бозга басып чирканып куя. Алай да душта кызып чыккан тән туңарга өлгерми, ун-унбиш адымнан соң карлы ярдан кайнар күлгә керәсең.

Бассейн өстен пар каплаганга, читләре күренми иде. Әле бик иртә, Зуфирә берүзе иде. Ул, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, җырлый-җырлый, бассейнны иңләп-буйлап туйганчы йөзде. Судан элекке Зуфирә түгел, бөтенләй башка кеше чыккандай булды. Әйтерсең лә җирнең кайнар күкрәгеннән саркып чыккан бу шифалы су аның тәнен генә түгел, бөтен күңелен юды, аны барчаваклыклардан арындырды, чистартты, дәрт, куәт өстәде.

* * *

– Диңгезчене йоласына туры китереп озатырга кирәк, – диде Лена. – Соңгы кичне бергәләп ресторанда типтерәчәкбез.

– Безнең гостиница каршындагы ресторанга керергә була, – диде Зуфирә. – «Дуңгыз колагы»на...

– Кит әле! Таптың! – дип каршы төште Лена. – Чын диңгезче океанга китәр алдыннан һәм кайткач шунда керәмени? «Океан»га барабыз. Без кемнән ким?

...Алар ишектән барып кергәндә, түрдә музыкантлар уен коралларын көйлиләр иде. Кечкенә сәхнәдән җирән чәчле таза егет сикереп төште дә аларга каршы атлады, баш иеп, сәлам бирде:

– Сез мине хәтерлисезме? – диде Вадимга. – Узган җәйне Гейзерлар үзәненә барырга ярдәм иткән идегез.

Ул шунда ук метрдотель белән сөйләште, аларны түрдәге өстәлләрнең берсе янына утырттылар. Лена, күзләрен мәче кебек кыса төшеп, ак муенын нәфис борып, музыкантның колагына нәрсәдер пышылдап алырга да өлгерде.

Беренче карашка «Океан» Казандагы «Аккош» рестораныннан күпкә калыша иде. Зурлыгы да алай ук түгел, бизәлеше дә. Түр стенада бер кабынып, бер сүнеп торган төсле лампочкаларны күргәч, Зуфирә үзалдына елмаеп куйды: «Бусы – төсле музыка ясарга тырышулары микәнни? Кая инде боларга салават күперен биетү!»

Ләкин биредә хөкем сөргән рух бөтенләй башка иде. Күпләр диңгездән кайткан гына, алар айлар буе алны-ялны белми эшләгәннәр, аяусыз дулкыннар белән көрәшкәннәр. Тозлы җилдән йөзләре каралган, каты баулардан куллары тырналган, тирбәлеп торган палубада йөреп аяклары талган. Ниһаять, менә алар исән-сау кайтып нык җиргә басканнар. Күңелләрендәге куаныч, алгысау тик кенә утырырга, тыныч кына әңгәмә корырга ирек бирми, аяклар үзләреннән-үзләре биеп китә...

Борынгыдан шулай булган, җирдә диңгезләр һәм диңгезчеләр барында шулай булачак.

Оркестр дәртле көй уйный, халык онытылып бии, бу өермә, теләсәң-теләмәсәң дә, үзенә тарта.

– Мин бүген монда тамашачы гына, бүген королева – Зуфирә, – диде күзләрен ягымлы кысып Лена. – Вадим, чакыр дама765ны!

Вадим уртага чыкты да, чүгеп-чүгеп бии башлады, моны күреп Зуфирәнең күңелендә курку чалынып узды: «Ә аягы соң! Аягы!» Ләкин курку шунда ук узды, алар бер көйне икенчесенә тоташтырып биеделәр дә биеделәр. Көйләр кемгәдер багышлана багышлануын, ләкин анысы мөһиммени! Көй ул – уртак хәзинә, кемнең күңеле кабул итсә – шуныкы!

Ләкин бу нәрсә? Ни дип игълан итә әнә оркестрдагы җирән чәчле егет? «Гейзерлар үзәненең генераль директоры Вадим Николаев һәм аның белән биюче Татарстаннан килгән кунагыбыз хөрмәтенә!» диме?

Юк, монысы Зуфирәнең колагына ялгыш ишетеләдер, «Ай, былбылым»ны мондагы музыкантлар каян белсен! Ләкин әнә уйныйлар бит, өздерәләр генә, бөтен зал типтереп бии шул көйгә:

Ай, былбылым, вай, былбылым,
Агыйделнең камышы...

Соңыннан, инде чыгып китәр алдыннан, Зуфирә түзмәде, җирән чәчле музыкант янына барып сорады:

– Каян белдегез сез татар көйләрен?

– Диңгезчеләр арасында татарлар күп бит. Николаевның кунаклары хөрмәтенә нинди генә көй уйнасаң да аз, шундый кеше ул!

Шулай үтте соңгы кич, аерылышыр вакыт җитте. Гостиница ишеге төбендә саубуллашканда, Лена, кем белә бит нәрсә буласын дип, серле елмаеп, Зуфирәгә үзенең Ленинград адресын язып бирде.

Ләкин бу соңгы сөйләшү булмаган икән. Зуфирә, бүлмәсенә кереп, әйбер-караларын җыеп азапланганда, телефон шалтырады:

– Зуфирә, синең акча янчыгың минем сумкада калган бит, – диде Лена. – Дүрт сум акчасы һәм бер лотерея билеты белән.

– Билеты отса, миннән бүләк булыр, – диде Зуфирә.

– Инде отты да дияргә була. Тик отыш – синеке! Сиңа сюрприз бар!

Зуфирә аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

– Кирәкми! Зинһар, берни әйтмә! Без хушлаштык бит инде! Китте дип санагыз мине, очты дип!

Ул җавап та көтмичә трубканы куйды.

Ләкин йөрәге сулкылдавын баса алмады. Бермәлне үзе үк шалтыратырга омтылган иде, ләкин тыелып калды: кирәкми, кирәкми! Нигә газапларны озайтырга!

...Автобус шәһәрдән караңгылы-яктылыда чыгып китте. Соңгы йортлар турыннан узгач, каерылып бер арткы тәрәзәдән карады Зуфирә. Яктырып килгән һавада, ике биек багана өстенә куелган җилкәнле ике кораб күрде ул. Беринг хөрмәтенә куелган кораблар – җир читендәге каланың символы иде бу. Кораблар, җилкәннәрен җилпеп, хәерле юл теләп калды сыман.

Елизово аэропортында озак көтәргә туры килмәде. Зуфирәнең юлы башта Хабаровскига, аннары Владивостокка, аннары Находка портына иде.

Үзенең рейсын игълан итүгә, Зуфирә тар ишектән беренче булып узды. Шул мәлдә, бөтен аэровокзалны яңгыратып, микрофоннан хатын-кыз тавышы: «Хабаровскига очучы пассажир Надыйрова, сезне белешмәләр бюросы янында көтәләр!» – дип игълан бирде. «Мине! – диде Зуфирә. – Өмит!» Ул үз-үзен белештермичә, кире ишеккә ташланды, ләкин аннан тыгызланып каршыга халык керә, ә билет тикшереп торучы форма кигән хатын, йокысы туймаудан кәефсез

чыраен тагын да ныграк чытып, аны beləгеннән тотып туктатты: «Сез кая тагын? Күрмисезмени, комачаулыйсыз!»

Зуфирә айнып киткәндәй булды: чыннан да, кая ашкына ул? Халык аша үрелеп, залга карады, белешмәләр тәрәзәсе янында Вадимны, Доннаны, алар белән янәшә Өмитне күреп алды.

Зуфирә күзләре туйганчы карый алмады, халык агымы аны үзенә ияртеп эчкә алып кереп китте.

Аннары инде ул үзен тәмам кулга алды, халык арасында буталырга, күзгә ташланмаска тырышты. Тик самолет баскычыннан менгәндә карамый түзә алмады: тимер койма артындагы халык арасында Өмит, йолдызлар арасындагы тулган ай шикелле, әллә каян күзгә ташланып тора иде...

Самолет күтәрелде дә, киң борылыш ясап, көньякка юл алды. Ә алда, өч янар тауның түбәсендә, иртәнге кояшның беренче нурлары балкый иде.

*1977*

## Эчтәлек

Яшьлектә биргән антка тугрылык. *Л.Хисмәтова*

**Хикәяләр**

Чаллы баскычлары
Күрше бәхете
Кар сулары
Ай сүрелгән чак иде
Узма, гомер!
Сары тюльпаннар
Көндәшләр
Бер күрүдә яраттым
Сөюләрне үлчи торган бизмән бар микән?
Серле сурәткә гыйшык
Әти күрше фатирда яши...
Саф мәхәббәт турында бер кыйсса
Яшь егеткә ир-егеттән бер киңәш

**Повестьлар**

Казан каласы – таш кала
Егетлеккә бер адым
Янар таулар яктысында

Литературно-художественное издание

**Маликова** Мадина Габдулхаковна

**Рассказы о чистой любви**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Маликова** Мәдинә Габделхак кызы

**Саф сөю турында кыйссалар**

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы *Р.Ф.Әхияров*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.10.2010.
Форматы 84Х108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 23,52.
Тиражы 3000 д. Заказ О-1472.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.